Ләбиб Лерон

# Бәхеткә биш минут кала

Пьесалар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2012

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
Л 47
**Лерон, Л. Л.**

Бәхеткә биш минут кала : пьесалар / Ләбиб Лерон ; [кереш сүз авт. Ә. Закирҗанов]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 431 б.

ISBN 978-5-298-02185-2

Әлеге китапка язучының төрле елларда иҗат ителгән пьесалары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
ISBN 978-5-298-02185-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Лерон Л. Л., 2012

## ӘХЛАК МАТУРЛЫГЫ САГЫНДА

Үткән гасырның сиксәненче елларында әдәбият мәйданына килеп, хәзер инде ир уртасы буларак акыл-тәҗрибә туплаган һәм татар сүз сәнгатен төпкә җигелеп тартучыларның берсе – М. Җәлил исемендәге Республика премиясе, Татарстан Язучылар берлегенең Ф. Хөсни, А. Алиш исемендәге бүләкләре иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ләбиб Лерон. Әдәби җәмәгатьчелек аны балалар язучысы – лирик, юмористик шигырьләр, шаян хикәяләр, әкиятләр, мәзәкләр остасы һәм зурлар өчен язылган лирик-публицистик тезмә әсәрләр, эпиграммалар, пародияләр авторы буларак яхшы белә.

Язучының иҗат диапазоны киң булып, ул байтак еллар инде драма төрендә дә уңышлы эшләп килә. Балалар өчен язылган берничә пьесасы Әлмәт, Минзәлә театр сәхнәләрендә уйнала, «ТНВ» телеканалыннан күрсәтелә, зурларга аталган пьесалары Буа һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге татар театрлары репертуарына кертелә, кайберләре «Яңа татар пьесасы» җыентыкларында, шулай ук «Казан утлары» жур-налында басылып чыга.

Әдипнең әлеге китабына өлкәннәр һәм балалар өчен язылган пьесалары туплап бирелә, һәм ул, драматург буларак, Л. Леронның үз иҗат йөзе, иҗат стиле булуын күрсәтә. Өл-кәннәр өчен язылган әсәрләрендә ул заман рухын ачык тоемлаучы, укучы-тамашачының борчу-мәшәкатьләре, шатлык-куа-нычлары белән яшәүче тынгы-сыз җанлы шәхес булып ачыла. «Бәхеткә биш минут кала» (2005) пьесасы тормыш-яшәешнең егет – кыз, ир – хатын,

ата – ана һәм бала мөнәсәбәте кебек гаять четерекле мәсьәләләренә багышлана. 30 – 40 ел вакыт аралыгын үз эченә алган вакыйга-күренешләр ретроспектив алым ярдәмендә укучы-тамашачы күз алдыннан үткәрелә. Автор татар тамашачысы аеруча үз иткән мелодраматик пафоска нигезләнгән тормыш материалына мөрәҗәгать итә. Әсәрдә ул сагышлы мәхәббәт тарихын, бәхетсез язмышларны һәм шуларга үрелеп барган җыр-музыканы, үткәннәр аша бүгенгегә һәм киләчәккә баруны аңлаткан күренешләрне үз эченә ала.

Вакыйгалар үзәген, яшьлек мәхәббәтенә хыянәт итеп, хис-кичерешләрендә һәм эш-гамәлләрендә адашып калган Газинур язмышы алып тора. Автор беренче күренешләрдә үк киләчәк каршылыкларның нигезен билгеләячәк интрига тудыра: егетне апалы-сеңелле ике кыз ярата икән. Газинур үзе Нәфисә белән бергә булырга омтылса да, ныклык күрсәтә алмый, үткен, чая, усал Гөлчирә теләкләрен үтәп, аңа өйләнергә мәҗбүр була. Аларның ике балалары туа. Әмма тормышка ике төрле караштa булган, әхлак төшенчәсен төрлечә аңлаган ир белән хатын бергә озак яши алмый, аерылыша.

Менә 30 – 40 ел үткәч, алар очраша. Ул исә, үткәннәрне хәтердә яңарту белән бергә, моңа кадәр сер булып калган гыйбрәтле һәм фаҗигале хәлләргә ачыклык кертү, ахыр чиктә барысының да, беренче чиратта Газинур белән Гөлчирәнең гомер юлына, эш-гамәлләренә бәя бирү дә булып тора. Мондый алым, укучы-тамашачыда кызыксыну тудырып, әлеге геройлар язмышын бөтен барлыгы белән күңеленнән кичерергә мөмкинлек бирә. Ә язмышлар, чыннан да, гаять катлаулы һәм каршылыклы. Улы Райнурга ялгызы белем һәм тәрбия биргән Гөлчирә авыру баласын – Илнурны – балалар тудыру йортында калдырып чыккан икән. Моның өчен ул үкенеп яшәсә дә, ялгышларын төзәтү мөм-кинлеге юк. Газинур исә авыру (телсез) улын үзенә ала һәм аны тәрбияләп үстерә, тормышта үз урынын табарлык кеше итә. Газинурны бөтен барлыгы белән яраткан Нәфисә аннан балага уза. Улы Фәннур үсеп җиткәч, ана вакытсыз гүр иясе була.

Әлеге хәлләрне укучы-тамашачы күз алдыннан үткәреп, автор геройларын әхлакый сынауга дучар итә. Аларның бәхетсез язмышына кем гаепле? Бер-берсен кичерә алырлармы? Драматург геройларын аклау яисә хурлау юлыннан китми. Үзенең йомшаклыгы аркасында барысын да гомерлек борчуга салган Газинур үкенү хисе кичерә. «Үкенерлек гамәлләр кылма икән дөньяда... Соң аңладым мин моны», – ди ул. Әлеге сүзләр авторның укучы-тамашачыга теләге булып та яңгырый. Үзенең хаталарын соңарып аңлап, Газинур барысыннан да кичерүләрен сорый. Телсез булу өстенә гомерендә ана назын күрмәгән Ил-нурның әнисе Гөлчирәне кочаклап алуы туганнарның дуслашу-татулашу билгесе булып тора. Әхлакый сынауны үтә алмаганнарны да автор кичерү ягында. Иң мөһиме, аларның хаталарын аңлавы, соңарып булса да тәүбә итүе дигән фикерне яклый ул.

Драматург иҗатында тормыштагы матди һәм рухи байлык, аларга караш-мөнәсәбәт мәсьәләсе даими урын ала. Шуңа бәйле аның геройлары сайлау алдына куела, сыналу үтә. Укучы-тамашачыны да «Нәрсә ул бәхет?», «Яшәү мәгънәсе нәрсәдә?» кебек фәлсәфи сораулар турында уйланырга этәрә. Әлеге

җитди мәсьәлә үзәккә куелган «Кычыткан чыпчыгы» моңсу комедиясендә вакыйга Гөлсинә һәм Рәүф гаиләсе яши торган фатирда бара.

Тормыш шартлары йогынтысында Гөлсинә укытучылык эшен ташлап, базарда сату итә. Беренче күренешләрдә үк әлеге хатын акча колы, яшәү мәгънәсен байлык туплауда гына күрүче булып ачыла. Ире Рәүф аның бу сыйфатын яратмаса да, карашларын үзгәртә алмый. Бу гаиләнең зур бер борчу-кайгысы бар – аларның балалары юк. Шуңа бәйле ир белән хатын арасында әйткәләшү-каршылыклар еш була. Беркөнне аларга Гөлсинәнең авылда яшәүче сеңлесе, Рәүф әйткәнчә, «кычыткан чыпчыгы» Фирая килеп керә һәм тормышларында җитди үзгәрешләргә китерә. Вакыйгалар барышында үзара ярдәмләшеп яшәү, актив тормыш позициясе булу, яшәештәге рухи матурлыкларны күрә белү, шуларга таяну кебек сыйфат-билгеләр кешенең асылын билгели дигән нәтиҗәгә киленә. Пьесадагы каршылыкның чишелеше буларак, телефоннан шалтыратып, Гөлсинәнең балага узуын хәбәр итәләр. Шул рәвешле автор, заманның мөһим темасын үзәккә алып, шактый җитди әхлакый һәм социаль мәсьәләләрне күтәрә һәм укучы-тамашачысын да шулар турында уйланырга чакыра.

«Экстрасенс» пьесасы (автор үзе шаян пьеса дип атый) үз-гәртеп корулар башланып, элекке кыйммәтләр абсурд хәлгә җиткән, яңалары формалашмаган дәвер вакыйгаларын күз алдына бастыра. Чынбарлыкта бу чорда икътисади тотрыксызлыктан файдаланып, һәртөр бушкуыклар, шарлатаннар күбек кебек өскә калка һәм халыкның беркатлылыгыннан файдаланып, аны алдау эшенә керешә. Ил күләмендә танылу алган, үзләрен экстрасенслар дип атаган Чумак, Кашпировский һ. б. үрнәгендә аерым төбәкләрдә үз Чумаклары, Кашпировскийлары пәйда була. Шуңа охшаш вакыйганы нигез итеп алып, автор авыл тормышындагы аерым күренешләрне, үзара мөнәсәбәтләрне, мәгънәсез эш-гамәлләрне шактый усал фаш итә. Беренче карашка әсәрдә үз итеп көлү өстенлек итә кебек. Клуб мөдире Гибралтарның авыл карчыгы Миңниса, юләр малай Кафил, колхоз рәисе Самат, җилбәзәк хатын Фатыйма белән әңгәмәләрендә авыл тормышы, кешеләрнең яшәү рәвеше, теләк-омтылышлары шактый ачык төсмерләнә. Алар артында кешеләр күңелендә хакимияткә, тормыштагы үз-гәрешләргә ышаныч булмау, шул ук вакытта һәртөр күз буяучыларга соңгы тиенен чыгарып бирергә әзер булу халәте һәм болар өчен әрнү ята. Пьесадагы һәр герой, штрихлар белән генә бирелсә дә, киң планда чор типлары буларак күзаллана. Авторның уңышы булып Кафил образы тора. Юләр малайның эш-гамәле, сөйләме артында тормыш дөреслеге чагыла. Ә инде әсәр ахырында аның экстрасенс рәвешендә башкалар белән идарә итә башлавы – тор-мышның асты-өскә килү билгесе. «Җүләр Кафил түгел, сез, кешеләр, үзегез бит акылдан язган түгелме соң?» дигән сорау турында уйлануга китерә драматург. Әсәрнең жанрына бәйле һәртөр сүз уйнатулар, җор сөйләм, уңышлы мәзәкчән диалоглар халык уеннарыннан килә торган традицияләрнең дәвамы буларак күзаллана. Болар барысы да фаш итүгә, геройларның бер-берсеннән һәм үз-үзләреннән көлүгә китерә.

Авторның тормыш-яшәешнең төрле яклары, заман тудырган проблемалар турында уйланулары нәтиҗәсе булып «Казыйханда- кунакта»

пьесасы тора. Вакыйгалар нигезен шактый таныш хәл-күренеш алып тора: заман бае Шакир үзенең гаять затлы кунак-ханәсенә 20 елга якын күрешмәгән классташларын җыя. Автор укучы-тамашачыга яңа эчтәлек, гыйбрәтле ситуация тәкъдим итә. Үзләрен кем һәм ни өчен чакыруын әлегә аңлап җиткермәгән композитор Нәсим, галимә Фәридә, шагыйрь Камилнең истәлек-хатирәләре әкренләп яшь вакытта Саескан кушаматы тагылган Шакирга күчә. Мәктәп елларында ук көнчел булуы, кеше әйберенә кызыгып яшәве искәртелә. Очрашу сәбәпчесе Шакир һәм хатыны Кәримә кергәч, сөйләшү башка юнәлеш алса да, ул, асылда, Шакир тормышы, аның рухи дөньясы, теләкләре турындагы әңгәмә буларак дәвам итә. Сөйләшү барышында көтелмәгән хәл ачыклана: Шакир Камилнең шигырьләрен сатып алуын, үз исеменнән китап итеп чыгаруын, Нәсимнән сатып алган музыканы да (симфонияне) үз исеменнән Япониягә конкурска җибәрүен әйтә. Ул Фәридәнең тарихка багышланган, тиздән язылып бетәчәк хезмәтен сатачагына да шикләнми. Шул рәвешле бөтен нәрсә сатыла һәм сатып алына дип уйлаучы (ул аңа инанган) татар баеның әхлаксыз йөзе ачыла. Шакир классташларының хезмәтен генә түгел, үзләрен дә сатып алу теләген яшерми. Әмма ул шактый җитди каршылыкка очрый. Җәмгыятьнең иҗат кешеләрен яклый алмавы аркасында үзләренең яшәеш принципларыннан читләшсәләр дә, Нәсим һәм Камил, алар артыннан Фәридә дә Шакирның яшәү фәлсәфәсен кире кага. Алай гына да түгел, иренең чын йөзе тулысынча ачылгач, хатыны Кәримә дә аны ташлап китә.

Автор әсәрендә гуманист буларак чыгыш ясый. Тормыш итүнең нигезендә, билгеле, акча ята, әмма ул кешенең асылын билгеләүче фактор булырга тиеш түгел. Рухи кыйммәтләрне яклаганда һәм саклаганда гына Кеше шәхес булып яши ала дигән фикерне укучы-тамашачыга җиткерә драматург.

Үзен халкына хезмәт итүче дип санаучы әдип милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланмый булдыра алмый. Ә соңгысы исә күптөрле сәбәп-шартларга бәйле булса да, икесе аеруча мөһим урын алып тора: теле, традицияләре, гореф-гадәтләре, гомумән, халыкның күп гасырлар дәвамында буыннан буынга тапшырылып килгән яшәү рәвеше сакланышы һәм милләтне берләштерүгә хезмәт итүче дингә йөз белән борылуы. Алар исә беренче чиратта милли мохитне саклап һәм яклап торучы авыл белән бәйле. Элегрәк тә, хәзер дә әдипләр авыл темасына даими мөрәҗәгать итә, шуңа да монда яңа материал табуы шактый кыен. Л. Лерон «Иман» драмасында моңа ирешә. Әсәрдә, ил каршындагы бурычын үтәп, 40 ел гомерен чит илләрдә үткәргән ирнең туган җиренә кайтуы, авылдашларының язмышын үз язмышы буларак кабул итүгә килүе, киң планда иманга кайтуы сурәтләнә. Автор һич тә тар рамкаларда калмый, аны гореф-гадәтләр сак-ланышы (әнә авыл җитәкчесе Сабан туе батырына чучка бүләк итмәкче), туган як табигатен саклау, авылның киләчәге, кеше гомере, яшәү мәгънәсе, яшьлек мәхәббәтенә тугры калу, ата-ана каршындагы бурычыңны үтәү кебек әхлакый, социаль һәм фәлсәфи төшен-чәләргә караш-мөнәсәбәт борчый. Вакыйгалар аша Л. Лерон укучы-тамашачысын әлеге мәсьәләләр турында уйланырга, бәхәсләшергә чакыра. Шуңа да төп герое Арслан язмышы укучыны битараф калдырмый,

гыйбрәт алырга, корсак колы гына булмыйча, яшәешнең асылын билгеләүче кыйммәтләр сакланышы өчен борчылып яшәргә өнди. Кеше кайда гына яшәсә дә, ул туган җирен онытмый. Әсәрдә ул мифологик образ Ак бабай аша яңгыраш ала. Арсланны туган ягына кайтырга чакыручы, йорт нигезе югалу куркынычы турында кисәтүче әлеге образ кеше иманы символы булып тора.

Автор халыкның тапкыр гыйбарәләреннән, мәкаль-әйтемнәреннән уңышлы файдалана. Алар һич тә ясалма булмыйча, герой сөйләменә, автор карашларына ачыклык, өстәмә мәгънә кертүгә хезмәт итә. Л. Лерон иҗатына хас бер үзенчәлек булып, аның реминисценция алымыннан эзлекле файдалануы тора. Ул төрле буын шагыйрьләрнең классик үрнәк дәрәҗәсендәге шигъри юллары аша фикер-карашларын тагын да калкытып куя, мәгънә тирәнлегенә ирешә.

Л. Лерон үзенең эзләнүләрендә яшәешнең төрле якларына, шул исәптән тормышның караңгы якларына яисә үз юлын тапмыйча югалып калган, җинаять сазлыгында батып калган язмышларга да мөрәҗәгать итә. «Коры куык» моңсу комедиясендәге Фарис шундый «маргинал» герой. Төрмәдән чыгып туган өенә кайткан бу адәм актыгы авылдашы, энкече Мирзәкигә теләсә нәрсә сөйләп, булдыксызлыгын, шарлатанлыгын, әтисе әйткәнчә, «коры куык» булуын күрсәтеп үзеннән көлдерсә дә, аның шундый язмышка дучар булып яшьлеген әрәм үткәрүе, әти-әнисенең әрнүләре тирән борчылу хисе уята. Әсәр ахырында Фарисның бертуган энесе Зөфәрнең Әфган җирендә барган сугышларда һәлак булуы хәбәре әлеге борчуны фаҗига буларак үстерә. Ул исә укучы-тамашачы күңелендә Фарис алып барган яшәү рәвешенә нәфрәт уятып кына калмый, мондый аянычлы хәлләрне булдырмау юллары турында уйланырга этәрә.

Тормыш-яшәештәге, аерым кешеләрдәге кимчелекле як-ларны сәхнә теле белән фаш итү максатында сурәтләүнең яңадан-яңа юлларын эзләп, Л. Лерон Г. Исхакый, Г. Камал, И. Богдановлардан килүче традицияләрне үстерә, яңа алымчараларга актив мөрәҗәгать итә. «Алтын күкәй, яки Киндерсюрприз» көнкүреш комедиясендә тавык кетәклегеннән килеп чыккан алтын күкәй бөтен авыл тормышын үзгәртеп ташлый. Катнашучыларның чын йөзен ачуга хезмәт итүче образ-деталь сәхнә әдәбиятында таныш алым, әмма Л. Лерон аннан бүгенге авылга бәйле заман мәсьәләләрен калкытып кую өчен файдалана. Әлеге детальгә нисбәтле килеп чыккан абсурд күренешләр, мәзәкчән хәлләр, аерым геройларның үз-үзләрен яисә бер-берсен фаш итүләре артында авторның рухи һәм матди кыйммәтләр, чынлык һәм ялган, авыл кешесенең хыял-өмете һәм чынбарлык турындагы борчулы уйланулары ята. Сөйгән кызы Фирүзәнең үзсүзле, горур, бераз көнчел әнисен юмалау өчен Ләззәт тарафыннан эченә пар балдак салып тавык оясына куелган «киндерсюрприз» авыл кешеләренең дә күзен ача, аларны битарафлыктан чыгара. Киләчәктә ул яшәешне, авыл тормышын үзгәртүгә, актив эшчәнлеккә этәрер дигән өмет туа.

Җыентыкның «Балалар өчен әкият-пьесалар» дип аталган икенче бүлегенә яшь тамашачылар өчен язылган пьесалар туп-лап бирелгән. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен язылган пьесаларга гаять зур

таләпләр куела. Бала беренче тапкыр театр залына керә, яңа сәнгать төре белән якыннан таныша. Әлеге танышлык аның күңелендә мәңге сакланачагына шикләнмәскә мөмкин. Ә инде яшь тамашачы театр залында утырып караган спектакль аны әлеге олы һәм серле сәнгатьне алга таба да юлдашы итәргә яисә күңелен кайтарырга мөмкин. Шуңа да спектакль нигезенә салынган пьесаның эчтәлеге, вакыйга-күренешләрнең балага таныш һәм аңлаешлы булуы, психологик үзенчәлекләренә туры килүе, акыл сатмыйча гына кертелгән тәрбияви фикер-карашларның чагылышы һ.б. әһәмиятле урын алып тора.

Драматург әлеге үзенчәлекләрне тирәнтен аңлап яза. Пьесаларында балаларга таныш әдәби дөнья тудырып, герой-ларының борчу-мәшәкатьләре белән яши, әхлакый сынаулар аша үзләрен танып белергә, шәхес буларак формалашуда ясаган беренче адымнарын бәяләргә өйрәтә. Әдипнең осталыгы яшь укучы-тамашачының акылына, күзаллавына тәңгәл килерлек вакыйга-күренешләрне сурәтләүдә һәм шунда бала урынын ачык билгеләүдә чагыла. Моңа ирешү өчен Л. Лерон төрле юллар, әдәби эзләнүләр аша бара. Берсе яңа тема-сюжетлар, образлар иҗат итү белән бәйле. Шуның бер чагылышы буларак, «Чәпәләй һәм Тәпәләй маҗаралары» әкият-пьесасында автор йорт җәнлекләре мәче һәм эт, кимерүчеләр төркеменнән булган тычкан кебек тере һәм агач кебек җансыз табигать дөньясы вәкилләре катнашындагы маҗаралы хәлләр тәкъдим итә. Йорт тычканнары Чәпәләй һәм Тәпәләй белән йорт җәнлекләре Мырау һәм Һауһауҗанның үзара каршылыкта булуын һәр бала белә. Вакыйгалар барышында мәче белән этнең ялкаулыгына ачуы килгән Тылсымлы агач сихер ярдәмендә каршы якларның урыннарын алмаштыра. Сәхнәдә гайре табигый күренеш башлана: үзләрен мәчеләр дип хис иткән тычканнар куркып калган мәче һәм этне төрлечә кимсетә, хурлый, хәтта тотып ашау белән куркыта башлый. Тычканнарның үз-үзләрен тотышы – төрлечә мактанышулары, кыланчыкланулары, әдәпсез сөйләшүләре – алардан йөз чөереп, мәче һәм эткә теләктәшлек уята. Әмма барысын да табигый хәленә кайтаруның шарты бар: тырышлык, хезмәт кую, ягъни агач яфракларына язылган тылсымлы сүзләрне уку. Мырау һәм Һауһауҗанның әлегәчә укырга өйрәнә алмаулары өчен үкенүләрен күреп, күрше мәчесе Мыргали ул сүзләрне укып бирә:

Эшсөяр булсаң әгәр,
Белемле булсаң әгәр,
Булсаң тырыш һәм зирәк –
Тармассың мондый хәлгә!

Әлеге юлларны мәче һәм эт кенә түгел, балалар да үзләренә мөрәҗәгать дип кабул итә һәм шул рәвешле уңышлы тәрбияви «дәрес» бирелә.

Ә инде «Чәпәләй һәм Тәпәләйнең Яңа ел маҗаралары» дип аталган пьесада автор укучы-тамашачыга гыйбрәтле вакыйга тәкъдим итә. Тынгысыз һәм тәртипсез Чәпәләй белән Тәпәләй «ватылып беткән юлга керергә ярамый» дигән билгене алып китәләр. Яңа ел күчтәнәче алып килүче Кыш бабай һәм Кар кызы утырып килгән машина бу юлга керә һәм ватылып кала. Бу хәлдән соң Мырау һәм Һауһауҗан, шулай ук Кыш бабай- һәм Кар кызы

Чәпәләй белән Тәпәләйгә киңәшләр бирәләр, тәртипле булырга, һәр гамәлеңне ахырын уйлап эшләргә чакыралар. Тычканнарда үзгәреш башлана. Кыш бабайның бүләкләр тутырылган капчыгын онытып калдыруы төп сынау булып тора. Никадәр генә кызыкса-лар да, Чәпәләй һәм Тәпәләй бүләкләрне Кыш бабай һәм Кар кызына илтеп тапшыралар, аларның зур рәхмәтенә, хөрмәтенә лаек булалар. Гомумән, Чәпәләй һәм Тәпәләй образлары, Л. Леронның уңышлы табышы булып, аларның маҗаралары киләчәктә дә дәвам ителеп, тулы бер цикл тәшкил итәр дип уйлыйм.

Л. Лерон балалар өчен язган пьесаларында киң таралыш алган халык авыз иҗаты үрнәкләренә даими мөрәҗәгать итә. Әдип, бер яктан, фольклор әсәрләрен заманга яраклаштырып, үзгәртеп эшләсә, икенче яктан, аларда урын алган сюжет эчтәлеген, геройларын, төрле мотивларны, детальләрне уңышлы файдалана. Драматургка хас әдәби үзенчәлекне бил-геләгән әлеге алымнар берничә максатка хезмәт итә. Берсе, автор фольклор әсәрендә киң урын алган яшәү рәвеше, макталган сыйфат-билгеләр аша укучысында туган халкының традицияләренә, гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияли, икенчесе, текст белән танышканда яисә сәхнәдән караганда укучы фольклор әсәре белән автор пьесасын чагышты-ра, уйланулары аша билгеле бер нәтиҗәгә килә. Л. Лерон «Аңгыра сарык җүләре» экият-пьесасында балаларга фольклор әсәре буларак та, Г. Тукайның «Кәҗә белән сарык» экияте аша да таныш мотивка мөрәҗәгать итә. Автор һич тә әлеге әсәрләрне кабатламый. Бәрән һәм Кәҗәмил белән Бүретдин, Төлкиназ, Аюлла каршылыгында беренчеләрнең җиңеп чыгуын тасвирлап, баланы үз көченә ышанырга, иң кыен чакларда да чыгу юлын табарга мөмкин дигән фикергә китерә. «Урмандагы тамаша»да автор үзенең геройлары Тазамат һәм Хыялбай белән бергә укучысын шүрәлеләр, диюләр яши торган дөньяга алып китә һәм Г. Тукайның атаклы «Шүрәле»сендә бармакларын бүрәнә ярыгына кыстырган Шүрәленең оныклары Чүрәле, Түрәле, Бүрәле белән очраштыра. Шүрәлеләр кешеләрнең хәйләкәрлегеннән һәм явызлыгыннан куркып яшиләр икән. Сәбәбен болай аңлаталар: «Сезнекеләр урманга килеп, учак ягалар да ниндидер тилерткеч су эчәләр, без аңламый торган сүзләр катыштырып җырлар җырлыйлар. Аннары бер-берсенә: «Син – хайван! Син – шүрәле!» – диләр дә әүмәкләшә башлыйлар... (...) Утаткыч белән җәнлекләрне үтерәләр. (...) Әллә нинди тозак-лар куялар». Мондый кешеләр диюләрне үзләренә буйсындырганнар һәм, алар, бер-берсенә ярдәм итешеп, начарлыклар кылып яшиләр икән. Вакыйгалар барышында егетләр хәйлә юлы белән Шартуар диюнең бармакларын нәкъ Тукайдагыча бүрәнә ярыгына кыстыралар һәм аның тәүбә итүенә ирешәләр. Бераздан исә урман пычратучы, җәнлекләргә тозаклар куючыларны очратып, аларның да бармакларын бүрәнәгә кыстыруга ирешәләр. Әмма явыз уй-теләкләреннән баш тартмаучы әлеге кешеләрне азат итмиләр, шул хәлдә тәүбә итәргә калдыралар. Ә инде хыял дөньясыннан реаль дөньяга кайткан малайларга Галия исемле кыз күрше авылда ике кешенең, бармаклары кыс-тырылган бүрәнә күтәреп кайтып, хурлыкка калулары турында сөйли. Шул рәвешле автор таныш сюжетны өр-яңа материалда файдалана һәм кызыклы, мавыктыргыч әсәр тудыра.

Драматургның «Без барабыз бәйрәмгә», «Яңа ел биштәре» әкият-пьесалары бәйрәм рухында язылулары белән кызык-лы. Аларда укучыларга яхшы таныш геройлар хәрәкәт итә, вакыйга-күренешләрдә изге гамәл кылу, бер-береңә ярдәм итү, өлкәннәрне тыңлау кебек әхлакый сыйфатлар яклана, һәртөр начарлык кире кагыла. Л. Лерон сурәтләнгән вакыйгаларга балаларның үзләрен дә катнаштыру алымын уңышлы файда-лана. Аның геройлары әледән-әле залга – тамашачыларга мөрәҗәгать итә, теге яисә бу әхлакый мәсьәләгә җавап сорый. Бу исә баланы тагын да мавыктыра, үз гамәлләренә бәя бирү теләге дә тудыра. Л. Леронның «Ишегалды» әкияте тезмә формада язылуы белән игътибарга лаек. Автор, атаклы әкиятчебез А. Алишның «Сертотмас Үрдәк» әкиятендәге мотивны файдаланып, укучыларына яңа эчтәлек, яңа геройлар тәкъдим итә. Күпсанлы йорт хайваннары, җәнлекләре, кыргый җәнлекләр катнашындагы пьесада яхшылык һәм явызлыкка, хөрмәт һәм хыянәткә бәйле әхлакый нәтиҗәләр чыгарыла.

Л. Леронның уй-фикерләргә, җитди бәхәсләргә, гыйбрәтле хәл-күренешләргә бай сурәтле дөньясына һәм серле, мавыктыргыч әкияти вакыйга-күренешләренә рәхим ит, хөрмәтле укучы!

*Әлфәт Закирҗанов,*
әдәбият галиме, тәнкыйтьче

**Пьесалар**

# БӘХЕТКӘ БИШ МИНУТ КАЛА

*Ике пәрдәле мелодрама*

КАТНАШАЛАР:

Газинур (Нургази).
Нәфисә.
Гөлчирә.
Райнур.
Фәнүсә.
Фәннур.
Хәдичә.
Илнур.
Сәрия.
Баш табиб.
Беренче егет (Гаптери – Гаптерәүф).
Икенче егет.
Чая кыз (Фатыйма).
Егетләр, кызлар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Үткән гасыр, алтмышынчы еллар ахыры.
Кичке эңгер-меңгер. Яшьләр җыйналып, үзара җырлап-биеп, төрле уеннар уйнап күңел ача торган урын. Бер як читтә таган тора. Арткы өлештә авыл өйләре күренә, баганадан төшкән ут көлтәсе бер матур йортны аеруча яктырта. Шунлыктан йорттагы һәм капкадагы кояш, пар күгәрчен сурәтләре бик яхшы шәйләнә.
Г а з и н у р керә. Солдат киеменнән. Яланбаш. Сул култы-гына гармун кыстырган, уң кулына чәчәк бәйләме тоткан. Гармунын ипләп кенә җиргә куя да, өс-башын рәтләштергәләп алгач, таган янына килә.

Г а з и н у р *(таганга килеп)*. Һайт! *(Үз тавышыннан үзе дә куркып, дерт итеп куя.)* Куркыттыммы, Нәфисә?! *(Таган-«Нәфисә» дәшми.)* Син... син... тагын да матурайгансың... Нәфисә! *(Күренмәс Нәфисәнең чәчләреннән сыйпый.)* Мин сине... шундый сагындым... Нәфисә! *(Чәчәк бәйләмен исенә төшерә.)* Ә бу чәчәкләр... әйе... сиңа бу... Нәфисә! *(Чәчәкләрне «Нәфисә»гә суза, «тегеʼ»се алмагач, таган утыргычына куя.)* Менә... мин кайттым... ике ел үтте дә китте.

И к е е г е т керә. Газинур аларны күрми. Егетләр Газинурның сөй-ләшкәнен шыпырт кына тыңлап торалар. Берсе бармагын чигәсе тирәсендә биетеп ала. Егетләр тавышсыз гына көлешәләр.

Г а з и н у р *(чәчәк бәйләменә карап)*. Ярый әле минем хатларга җавап язып тордыгыз... тордың... Нәфисә. Служить иткәнне сизмәдем дә... Бер дә сөйләшмисең, Нәфисә... Мине күргәч, телеңне йоттың инде әллә? Гөлфирә ни хәлдә соң? Һаман синең белән командовать итәме? Айт-два, айт-два, диме? Теле белән биетәме әле дә? Юк, юк, үпкәли күрмә, Нәфисә! Гөлчирә апаң турында болай гына сораштыруым... Ул да миңа хат язгалады бит. Шуңа искә төшерүем, Нәфисә! Нәфисә, дим, үпкәләмә инде... Телисеңме, җырлыйм хәзер... *(Гармунын алып, кабат таган янына килә.)* Ул җырны синең ишеткәнең бар инде...

Газинур чәчәк бәйләмен җиргә куя да таган утыргычына утыра. Егетләр, кычкырып көлмәс өчен, көчкә түзеп торалар.

Г а з и н у р *(гармун шыңгырдатып, кирәкле көйне табып)*. Тыңлыйсыңмы, Нәфисә? Бу җырны сиңа багышлыйм.
Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный;
Минем күңелем сине уйлый,
Күк күгәрчен, сандугачым,
Синең күңелең кемне уйлый?

Күк күгәрчен гөрлидер,
Гөлләр чәчәк атканда;
Син җаныемнан хәбәр көтәм,

Күк күгәрчен, сандугачым,
Таң сызылып атканда.

Егетләр пырхылдап көлеп җибәрә. Газинур җырлаудан, уйнаудан шып туктый. Гармунын таганга куя.

Беренче егет. Ха-ха-ха! Үлә яздым! Ха-ха-ха!

Икенче егет. Болай кычкырып көлалмыйча интек-кәнем юк иде! Үтердең син безне, Газинур! Ха-ха-ха!

Егетләр, икесе тиң сыгылып төшеп, буыла-буыла көләләр.

Газинур. Егетләр, исәнмесез!

Беренче егет. Уф! Көлеп кенә үлмәсәк... *(Торып баса.)* Исән әле без!

Икенче егет *(көлә-көлә, тураеп басып)*. Сә-сә-сәлам, Газинур! Кайттыкмы?

Кочаклашалар.

Беренче егет. Ну сагынгансың да икән кызларны!

Икенче егет. Таганны, диген! Сәгать буе сөйләште бит таган белән.

Беренче егет. Кочаклап та үбәдер ие, без генә мишәйт иттек!

Газинур. Җитте инде сезгә, егетләр!

Икенче егет. Армиядә булмагансың бугай син, бер дә ябыкмагансың!

Беренче егет. Күреп тордың бит, сизмәдеңмени?! Театр уйнап яткан ул анда. Көрәк сабын кочаклап, җырлаган да җырлаган, җырлаган да җырлаган.

Газинур. Көлмәгез инде, егетләр. Аңлагыз хәлемне. Сагынып кайттым бит. Сезне, авылны...

Беренче егет. Нәфисәне...

Икенче егет. Гөлчирәне...

Газинур. Аларны да, башка кызларны да...

Беренче егет. Юк инде, шалишь, брат! Башка кызлар турында уйлама инде син. Алар – безнеке! Без сагынып кайттык аларны!

Икенче егет. Ай-яй, нәфесең зур икән синең! Болай да берүзеңә ике кыз!

Газинур. Миңа Нәфисә дә җиткән.

Беренче егет. Апасыннан бигрәк матур сеңлесе, дисеңме?! Ашыкма, Газинур, уйла. Гөлчирә дә бик чибәр.

Икенче егет. Чибәрен чибәр... Артык чая, зәһәр түл-ке! Аның итәге астына керсәң, чыгалмавың бар – монысы факыт! Шулай бит, Габдерәүф?

Беренче егет. Шулай, анасына охшаган...

Газинур. Мин бит бүген үк өйләнергә җыенмыйм!

Икенче егет. Кем сине кыстый әле...

Шау-гөр килгән тавышлар ишетелә.

Б е р е н ч е  е г е т. Киләләр!

Я ш ь л ә р  керә. Килүчеләр (егетләр) Газинур белән кочаклашып күрешәләр. Көлешәләр. Күңелле ыгы-зыгы.

И к е н ч е  е г е т *(гармунны Газинурга сузып)*. Әйдәле, уйнап җиффәр, Газинур!

Ф а т ы й м а. «Җырлыйк әле»не уйна, Газинур җаным! *(Башка кызларга карап.)* Кушылабызмы, кызлар?! Егет-ләр! Сезгә дә кагыла. Кара-каршы әйтешеп җырлыйбыз!

Егетләр – бер якка, кызлар икенче якка басып, җырларга әзерләнәләр.

Б е р е н ч е  е г е т. Әйдә, Фатыйма, җырлый башла!

Ф а т ы й м а *(кулына микрофон тоткан кыяфәт ясап)*. Тыңлагыз, тыңлагыз! Колхоз радиосы сөйли. Бүген, 1969 елның 26 маенда, Газинур Шәйхиевнең армиядән исән-сау кайтуы хөрмәтенә зур концерт була. Билет бәясе бушлай! Башлап җырлый атказанган Фатыйма! Вәйт!

Фатыйма җырлый башлый, башкалар аңа кушыла.

Б е р г ә. Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле;
Чәчәк кебек яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

К ы з л а р. Безнең авыл егетләре
Барысы да маладис:
Ясап интегәсе дә юк –
Борын тулы холодец!

Көлешәләр.

Е г е т л ә р. Үзегезне белегез, мәми авызлар! *(Җырлый-лар.)*
Кызлар кия сары ыштан,
Безгә карасы да юк.
Хәзер кызлар үзе килә,
Безгә барасы да юк.

К ы з л а р. Булмаганны! Безме?! И-и, хәчтерүшләр! *(Җырлыйлар.)*
Безнең авыл егетләре
Пуф-пуф тәмәке тарта.
Борын чөеп йөргән була,
Үзе канауда ята.

Е г е т л ә р. Булмас! Безнең арада андыйлар юк! *(Җырлыйлар.)*
Безнең авылның кызлары
Сөтләргә су кушалар.
Егетләрне бүләлмичә,

Талашып сугышалар!

К ы з л а р. Ялган! *(Җырлыйлар.)*
Көтү кайта, көтү кайта –
Әлсерәгән бер тәкә...
Безнең авыл егетләре
Барысы да бүтәкә!

Үзара төртмә сүзләр әйтешеп көлешәләр.

Ф а т ы й м а *(Газинур каршына басып)*. Әйдә, Газинур, бию көен дә уйнап җибәр әле! Инде ике ел җүнләп биегән юк!

Б е р е н ч е е г е т. Кичә генә җенләнеп биедең бит, Фатыйма!

Ф а т ы й м а. Кичә бит ул! Мин аны әллә кайчан оныттым инде. Уйна, Газинур!

Газинур уйный, Фатыйма очынып бии, бүтәннәр кул чабып тора.

Ф а т ы й м а *(биюдән туктый, Газинур каршына килеп)*. Бүген алсаң, бүген үк сиңа чыгам, Газинур! Син – гармунчы, мин – биюче, менә дигән пар без!

Шулвакыт Н ә ф и с ә керә.

Б е р е н ч е е г е т *(Нәфисәне күреп)*. Парлашмыйча гына тор әле, Фатыйма! Күктә... Нәфисә йолдыз кабынды!

Г а з и н у р *(урыныннан торып)*. Нәфисә!

Нәфисә белән Газинур бер-берсенә карашып торалар.
Башкалар бер читкәрәк китәләр. Фатыйма да теләмичә генә аларга иярә.

Б е р е н ч е е г е т. Нишлибез? Боларның үбешкәннәрен карап торабызмы, әллә кайтып йокы бүсәбезме?

Ф а т ы й м а. Йокы мичкәсе булдың инде тәки! Гаптери! Аркасын мичкә тери! Бар, кайт та йокла, авызыңа сускиеңны кабарга онытма!

Б е р е н ч е е г е т. И шуның теле!.. *(Кулларын өскә сузып.)* Ходаем, зинһар, җәллә мине! Берүк Фатыймага өйләндерә күрмә! Беренче кичтә үк сугышып бетәчәкбез!

Ф а т ы й м а. Исем китте иске чикмән итәгенә! Бик кирәгең барые!

И к е н ч е е г е т. Сезнең сугышканны... *(Газинур белән Нәфисәгә карап.)* Боларның үбешкәнен көтсәң, безгә монда гына пенсиягә чыгарга кала... Киттек әйдә!

Б е р е н ч е е г е т. Кая барабыз?

И к е н ч е е г е т. Шәүлегән болынына. Кайбер җитди сәбәпләр аркасында кичке уен шунда күчерелә... Киттек!

Яшьләр, Газинур белән Нәфисәгә борылып карый-карый,
теләр-теләмәс кенә китәләр.

Г а з и н у р. Нәфисә! Киттеләр...

Н ә ф и с ә. Киттеләр шул... Исән-сау гына кайттыңмы, Газинур абый?

Г а з и н у р *(Нәфисәгә таба атлап)*. Мин сине сагындым, Нәфисә! Бик-бик сагындым!

Н ә ф и с ә *(Газинурга якынлашып)*. Мин дә!

Г а з и н у р. Мин үлеп-бетеп, үлеп-бетеп сагындым сине, Нәфисә!

Нәфисәне кочакламакчы була, кыз читкә тайпыла.

Н ә ф и с ә. Мин дә, Газинур абый!

Г а з и н у р. «Абый» димә, син бит миннән ике генә яшькә кече.

Н ә ф и с ә. Ярар соң, Газинур!

Г а з и н у р *(кабат кочакламакчы булып)*. Син тагын да матурайгансың, Нәфисә!

Н ә ф и с ә. Син дә... ябыккансың бераз!

Г а з и н у р. Армиядә хезмәт итү кәнфит ашау түгел шул, Нәфисә.

Н ә ф и с ә. Аңлыйм инде...

Г а з и н у р. Һәрвакыт сине уйладым, Нәфисә!

Н ә ф и с ә *(шаяртып)*. Йоклаган чакта дамы?

Г а з и н у р. Әйе, йоклаган чакта да! Нигә көләсең? Мин бит йоклаганда гел төш күрә идем. Ә син һәрвакыт төшкә кердең.

Н ә ф и с ә. Мин дә төшләремдә гел синең белән саташтым. Каршыма елмаеп киләсең дә... үтеп китәсең. Елмаеп киләсең дә... үтеп китәсең. Бер сүз дә әйтмисең.

Г а з и н у р. Әйткәнмендер инде... Ишетмәгәнсеңдер генә.

Н ә ф и с ә. Төнлә уянып китә идем дә, тәрәзәгә карап, айны эзли идем... Тапкач, сине сагынып җырлый идем. Пышылдап кына инде...

Г а з и н у р. Нинди җыр җырлый идең, Нәфисә?

Н ә ф и с ә. Күңелгә килгәнне инде.

Г а з и н у р. Күңелеңә килгән шул җырны җырлале, Нәфисә.

Н ә ф и с ә *(җырлый)*.

Учак яктым, учак яктым,
Төннәр яктырсын өчен.
Ниләр генә эшлим икән
Хәлем яхшырсын өчен?

Төнге җилләр тузгыталар
Учакның күмерләрен.
Учак күмерләре кебек
Яна бит гомерләрем.

Учак яна, учак яна,
Сүнгәнче янар инде.
Хәлләремне тик ялгыз ай
Аңласа аңлар инде...

Г а з и н у р. Искиткеч җыр бу, Нәфисә!

Шулвакыт, атылып-бәрелеп дигәндәй, Гөлчирә килеп керә дә
Газинурны кочаклый, үбә башлый.

Г ө л ч и р ә. Исән-сау кайттыңмы, Газинурым-күз нурым?! Сагынып беттем үзеңне! *(Нәфисәне яңа гына күр-гәндәй.)* Бәтәч, син дә монда икәнсең әле! Нишләп торасың монда? Бозауны эзләп чыгып киткән идең бит...

Н ә ф и с ә. Мин... ни менә... Газинурны... абыйны очраттым да...

Г а з и н у р. Гөлчирә, без... ни... торадыреек әле менә.

Г ө л ч и р ә. Сукыр түгел... Күрәм торганыгызны. *(Таган янындагы чәчәкләргә күзе төшә.)* Чәчәкләр! *(Җәһәт кенә барып ала.)* Рәхмәт, Газинурым-күз нурым! *(Газинурны янә кочаклап, үбеп ала.)* Нинди матур чәчәкләр! Безнең бакча артыннан җыйгансыңдыр инде?!

Г а з и н у р. Син нәрсә инде, Гөлчирә. Сезнең бакча артында мондый чәчәкләр үсмидерие бит моңарчы. Әнә теге төштән җыйдым мин аларны.

Г ө л ч и р ә. Кайдан җыюың мине кызыксындырмый инде анысы. Иң мөһиме – җыйгансың! Миңа дип! Рәхмәт, Газинур!

Н ә ф и с ә. Мин... мин кайтыйм инде, булмаса.

Г ө л ч и р ә. Әле син китмәдеңмени, Нәфисә?

Нәфисә китәргә дип борыла.

Г а з и н у р. Бергә кайтырбыз, Нәфисә. Караңгы да төшеп килә икән инде.

Г ө л ч и р ә. Караңгыдан курыкмый ул. *(Газинурны култыклап ала.)* Киттекме?

Г а з и н у р *(бер Нәфисәгә, бер Гөлчирәгә карап, җилкәсен сикертеп)*. Киттек соң... *(Җәһәт кенә гармунын ала.)*

Бергә китәләр. Нәфисә җырлаган җырның көе яңгырый. Ут сүнә.

## **И К Е Н Ч Е   К Ү Р Е Н Е Ш**

Егерме беренче гасыр башы. Утыз-утыз биш еллап вакыт узган. Иртәнге як. Шәһәр читендәге бистә. Төзелеп бетеп килүче коттедж. Коттеджның диварына, капкасына авыл йортында сурәтләнгән кояш һәм пар күгәрчен рәсемнәре ясалган. Ишегалдының бер өлешенә, җәй көннәрендә ашау-эчү, шулай ук килгән-киткән кешеләр белән сөйләшеп-гәпләшеп утыру өчен дип, беседка сыман бер нәрсә корылган. Бер читтәрәк таган тора. Шул таганда бер ир агачтан нидер юнып утыра. Ир дигәнебез – шактый өлкәнәя төшкән Г а з и н у р. Биредә аны билгеле бер вакытка кадәр Нургази дип йөртәләр. Газинур-Нургазиның төс-кыяфәте, килеш-килбәте бик үзгәргән. Аны баштагы мәлләрдә тамашачы танымавы да ихтимал.
Җиңел машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Бераздан, кесә телефоны аша кем беләндер сөйләшә-сөйләшә, Р а й н у р керә.

Р а й н у р. Фәнүсә апаң үзе килә! Үзе! За рулём! Минем вакыт юк! Сиңа әнине генә алып киләсе була. Аңладыңмы? *(Газинурга.)* Сәлам, Нургази абый!

Газинур башын кагып исәнләшә.

Бензиның бармы? Булмаса, үз акчаңа заправить ит! Егерме литр! Акчасын килгәч бирермен!

Г а з и н у р. Райнур, әйт әле шофёрыңа, берәр йөрәк даруы да алсын! Корвалолмы, нитроглицеринмы шунда...

Р а й н у р. Ә? Хәзер! Марсель, слушай, йөрәк даруы да ал! «Корвалол» дисеңме, Нургази абый?!

Г а з и н у р. Әйе. Нитроглицерин да ярый.

Р а й н у р. Марсель! Корвалол и нитроглицерин ал! *(Га-зинурга дәшә.)* Валидол да кирәкмиме?

Г а з и н у р. Алсын!

Р а й н у р. Ал! Валидол да ал! Нинди май алыштыру инде ул бүген?! Йөреп тора бит әле машина. Иртәгә алыштырырсың! Әнине алып киләсе бар, дидем бит! «Коттеджны күрәсе килә!» дип, бер ай тинтерәтә инде. Всё! Акаеп чапма! Кара аны, яныңда әни барын онытма! Гут бай! Мерси боку! *(Телефонын кесәсенә тыгып куя.)* Көн шәп бүген, ә?! Җырлап кына йөрерлек! *(Җырлый.)*

Хатын алдым, коттедж салдым,
Машинам да өр-яңа.
Заманның артына тибеп
Яшәү кирәк дөньяда...

И-и-их!.. *(Аякларын тыпырдатып биеп ала.)* Йә, хәлләр ничек, Нургази абый? Коттежны шәп сакладыңмы? Бомж-лар, төсле металл чәлдерүчеләр иснәнеп йөрмәдеме?

Г а з и н у р. Аллага шөкер, сыңар эт тә күренмәде. Барысы да тәртиптә!

Р а й н у р. Маладис син, Нургази абый! Син монда булганда, минем җан тыныч. Нәрсә, йөрәгең бүген дә шалить итә мәллә? Дарулар, дисең...

Г а з и н у р. Юк, борчымый әлегә. Әмма гарантия биреп булмый. Мотор эштән чыгып килә. Клапаннар тузды...

Р а й н у р. Ничего! Медицина көчле хәзер! Клапанна-рыңны момент алыштырып куярлар. *(Нургази кулындагы агач кош сынына ымлап.)* Күгәрченеңне ясап бетердең мәллә?

Г а з и н у р. Юк әле. Күзләренә нур иңдерәсе калды.

Р а й н у р. Бик озак маташтың инде моның белән.

Г а з и н у р. Бүләккә ул.

Р а й н у р. Кемгә?

Г а з и н у р *(хәйләкәр елмаеп)*. Монысы – сер! Әлегә.

Р а й н у р. Буяп та җибәрсәң, нәкъ чын күгәрчен була инде бу!

Г а з и н у р. Буявын малай буяр инде. Буярга ул мачтер! Вчүтеки рәссам бит! Табигать күренешләрен коеп кына куя. Рәсемгә кулы ята малайның...

Р а й н у р. Сиңа охшаган... Сүз дә юк! Менә бит коттеджны нинди картинка иттегез! Молодцы, Нургази абый! Карале, минем башка бер

гениальный фикер килде. Әйт Илнурга, ясасын миңа картина. Сатып алам! Өйнең иң шәп җиренә үзегез эләрсез!

Г а з и н у р. Эләрбез! Анысы гына бездән тормас. Кичә малай бер картинасын ясап бетерде. Миңа бик ошады!

Р а й н у р. Алам! Бүген үк алып килсен! Әни дә күрер!

Г а з и н у р. Ул аны сатмас инде.

Р а й н у р. Миңамы? Мин бит аны сатып алам! Күпме сорый – акчасын шулхәтле бирәм!

Г а з и н у р. Малай аны бүләк итмәкче була.

Р а й н у р. Кемгә?

Г а з и н у р . Сезгә! Фәнүсә белән икегезгә. Яңа коттедж белән котлап!

Р а й н у р *(бүләкне хәзер үк кулына алгандай куанып)*. Уһ-һу-һу! Рәхмәт, Нургази абый! Бүләккә каршы түгел мин! Акчага да ала идем. Үзең беләсең, мин деловой кеше! Ну, искусствоны яратам да инде мин, Нургази абый! Шишкин! Пушкин! Салават! Буяу! Картон! Карандаш!.. Кыстати, Илнур нишли соң әле бүген? Әни килгәч, мәҗлес ясап аласы булыр. Курыкма, Нургази абый, чит-ят кеше булмый. Үзебез генә гүләйт будем! Илнурны да чакырырсың!

Г а з и н у р. Рәхмәт чакыруың өчен. Әбизәтелне әйтермен Илнурга да! Балыктан кайтмагандыр әле ул. Балык каптырган арада, искиз-мискизлар да ясармын, дигән иде.

Р а й н у р. Искиз-мискиз, дисеңме?! Анысы нәрсә тагы?

Г а з и н у р. Искиз-мискиз ул ни була инде... шул... ничек итеп аңлатыйм икән?.. Ну инде... Булачак яңа картинаның ние инде... мие... черновигы! Черновой варианты! Татарчасы каралама буламы әле? Ну, скелет инде. Ите-мазары кунмаган сөяк-санак димме... кайсыдыр ки шул мәгънәдә... Аңлата алдыммы мафиози башыңа?

Р а й н у р. Мафиози?! Минме мафиози?! *(Кычкырып көлә.)* Нинди мафиози булыйм мин, Нургази абый? Алар янында мин – ерунда! Но байлык бар! Бусын отрицать итмим! *(Йодрыгын төйнәп.)* Хватка да бар! Ерт... ерт... татарча шундыйрак нинди сүз бар әле, Нургази абый?

Г а з и н у р. Ертлачлыкмы?

Р а й н у р. Вот, вот! Ерт-лач-лык! Менә шул бар миндә. Үземә тиешлене алмыйча калган юк! Мин этисез үскән малай, Нургази абый! Мине әни үстерде... Әни! Һәм... и... урам кеше итте! Урам мине бернидән дә, беркемнән дә курыкмаска өйрәтте. Урам ул – искусство! Шишкин! Пушкин! Салават! Этләр янында – эт, төлкеләр янында – төлке, бүреләр янында бүре булырга өйрәндем мин!

Г а з и н у р *(шаяртып)*. Каян гел синңа гына очрап торды соң ул төлкеләр, бүреләр? Зоопарктан качканнарые мәллә? Якын-тирәдәге урманнан килеп, адашып йөриләриеме?

Р а й н у р. Көлмә-көлмә, Нургази абый! Кешеләр турында сүз барганны син бик яхшы аңладың...

Г а з и н у р. Ахмак түгел идем кебек моңарчы.

Р а й н у р. Кеше – дөньяда иң заразы ерткыч!

Г а з и н у р. Бөтен кеше дә ерткыч була алмый инде, Райнур.

Р а й н у р. Бөтен кеше дә ерткыч, Нургази абый. Мин беләм инде... Уһу-һу! Мин бит шулар арасында кайнашам! Шулар белән бергә яшим! Ерткычлар арасында миңа да ерткыч булырга туры килә! Барыбыз да ерткыч!

Г а з и н у р. Берүк ачуланма, Райнур... Әниең... Әниең дә ерткычмы?

Р а й н у р. Әниме?! Әни ул... әни! Ул – святой человек! Ангел! Фәрештә!

Г а з и н у р. Фәрештәләр бала тапмый бугай бит?! Гафу...

Р а й н у р. Мине тапкан бит әле! *(Көлеп җибәрә.)* Шәп әйттемме, Нургази абый?!

Г а з и н у р *(көлеп)*. Ничава!

Р а й н у р. То-то! Әтигә килсәк... Әти дә ерткыч! Баласын ташлап качкан ерткыч! Настоящий ерткычлар да алай итми! Ну, ничего, андый әтиең булганчы, булмавы яхшы!

Газинур кулындагы күгәрченен җиргә төшереп җибәрә яза –
чак тотып кала.

Маңка агызып, елап ятмадым. Үстем, кеше булдым! Менә нинди шәп коттедж салдым! Чудо бит!

Г а з и н у р. Чудо инде, чудо!

Р а й н у р. Әйдә, Нургази абый, госкомиссия председателе килгәнче, әнине әйтәм, өй эчләрен тагын бер карап чыгыйк. Мактанышып та алырбыз! Мактаганны яратам мин!

Г а з и н у р. Мактаганны кем яратмый инде... *(Урыныннан кузгала.)*

С ә р и я керә.

С ә р и я. Күршеләр!

Р а й н у р *(йорт болдыры янында тукталып)*. Оһо!

С ә р и я. Исәннәрмесез, күршеләр!

Г а з и н у р. Исән әле, Сәрия сеңлем.

Р а й н у р. Сәлам, сәлам, чибәр күрше! Кер әйдә, Сәриюшка! *(Сәрияне яратып күздән кичерә.)* Үзең – чудо! Күл-мәгең – чудо! Импортный икәне күренеп тора!

С ә р и я *(мактаганга күңеле булып)*. Үзем тектем дисәм, барыбер ышанмассыз!

Р а й н у р. Супер! Классно выглядишь, Сәриюшка! *(Сәрия янына килә.)*

Г а з и н у р. Мин кайтыйм, булмаса. Малай да кайткандыр. Күгәрченне дә буяп бетерәсе бар. Мин кирәкмимдер бит әле, Райнур?

Р а й н у р. Юк, юк, Нургази абый. Бар, үз эшләреңне эшли тор. Илнурга әйтергә онытма. Бергә киләсез, яме?!

Г а з и н у р. Әбизәтелне киләбез!

С ә р и я. Нургази абый, син ясаган менә бу кояшка, күгәрченнәргә карап сокланып туя алмыйм. Бигрәк матур! Кулларың алтын икән!

Г а з и н у р. Алтын дип, гап-гади куллар инде, крестиянский!

Р а й н у р. Нургази абый маладис кеше ул. Аның куллары гына түгел, ул үзе алтын! Высшая проба!

Г а з и н у р. Бу хәтле мактауга... Кайтып салмыйча булмас, ахры!..

Р а й н у р. Син бит салмыйсың, Нургази абый!

Г а з и н у р. Салган чаклар бар иде!.. Шутка!

С ә р и я. Нургази абый, Илнур кайда соң әле? Күренми бер дә.

Г а з и н у р. Иртән иртүк су буена киткән иде. *(Чыгып китә.)*

Р а й н у р *(аның артыннан карап калып, Сәриягә)*. Самородок! Шәп кеше! Минем әти шундый кеше булган булса... Кем булыр идем икән мин? Глава правительства?! Юк, президент! *(Тавышын калынайтып.)* Президент Райнур- Шәйхиев! Шәймиев кебек шәп яңгырый бит фамилия, ә, Сәриюшка?!

С ә р и я *(чытлыкланып)*. Супер! Классно, үзең әйтмешли!

Р а й н у р. Чибәр син, Сәрия! Күзләрең, карашың ут синең! Яндыра, көйдерә! Шул күзләреңә карап җырлыйсы килә! *(Җырлый.)*

Кайларда гына булмадым,
Айда гына йөрмәдем.
Синең кебек гүзәлкәйне
Бер җирдә дә күрмәдем...

С ә р и я. Хатының килсә, күрсәтер әле сиңа «гүзәл-кәй»не...

Машина туктаган тавыш ишетелә.

С ә р и я. Әнә Фәнүсә килде дә бугай инде...

Р а й н у р. Кажется, да... *(Сәриягә.)* Болай гына кермәгәнсеңдер бит, Сәриюшка? Йомышыңны әйтеп кал!

С ә р и я. Йомыш дип... Миңа Илнур кирәк иде дә инде... Су буена киткән икән бит.

Р а й н у р. Аңлашылды-ы-ы, мадумазель-туташ...

Ф ә н ү с ә, Х ә д и ч ә һәм Ф ә н н у р керә. Фәннур кулында зур сумка. Фәнүсәнең көмәнле икәне беленеп тора.

Х ә д и ч ә *(әүвәл Сәрияне күреп)*. И-и, бу дөньяның тарлыгы! Нишләп йөрисең монда, Сәрия? Әллә син дә Райнурның хатынымы? Хи-хи-хи!.. Фәнүсәкәем, бер дә көндәшең барлыгы турында әйткәнең булмады. Хи-хи-хи... *(Райнурга.)* И-и, хәзерге байлар яшәп тә күрсәтә инде. Берүзеңә ике хатын! Хи-хи-хи... *(Фәннурга.)* Ә син бердәнбер хатыныңны да асрый алмыйсың, җан көеге!..

С ә р и я. Мин... ни... Илнур янына дип...

Р а й н у р. Нинди ике хатын? Фәнүсә – минем бердән-берем. *(Фәнүсәне кочып, битеннән үбеп ала.)*

Ф ә н н у р. Башта исәнләшергә кирәк, Хәдичә!.. Исән-нәрмесез!

Фәннур, сумкасын бер читкә куеп, Райнур белән күрешә. Аннары Сәрия белән исәнләшә.

Ф ә н ү с ә *(Хәдичәгә)*. Менә шушы була инде безнең коттедж! Райнур тырышты! *(Райнурга сыена.)*

Х ә д и ч ә *(сузып)*. И-и-и-и! Без дә кеше булып яшәгән булабыз! *(Фәннурга.)* Менә, күр, кешеләр нинди хан сараенда яшәп ята!

Райнур, башын югары чөеп, горурланып басып тора.

Ф ә н ү с ә. Райнур йокы күрмәде инде, көне-төне чапты.

Р а й н у р. Чабасың инде, бер генә яшибез бит! Яшәп калырга кирәк!

Х ә д и ч ә *(Фәннурга)*. Ишеттеңме, директор кисәге?! Райнур нәрсә ди әнә! Яшәп калырга кирәк, ди. Ә син «Мәктәп! Мәктәп!» дип өтәләнгән буласың! Юкны бушка аударып йөрисең шунда! Өйгә кайтып та кергәнең юк! *(Башкаларга карап әйтә.)* Җиде укучыга унсигез укытучысы бар аның! Хи-хи-хи!.. Шуларның тамагын туйдырам дип йөри, үзе ач – авызын ачса, үпкәсе күренеп тора! Хи-хи-хи... Макаренко несчастный!..

Ф ә н н у р. Җиде түгел, йөз дә егерме җиде укучы!..

Х ә д и ч ә. Барыбер инде. *(Сәрия янына килә.)* Син дә бу тирәдә яшисең мәллә? Фәнүсәләр белән берәр ничек туган-мазар түгелдер бит? И-и-и, йортлары матур да инде, име?!

С ә р и я. Гаҗәп инде, гаҗәп!

Райнур Фәнүсәне бер читкәрәк алып китә. Фәннур, болдыр янына килеп, агач бизәкләрне сыйпаштырып-караштырып йөри.

Р а й н у р *(Фәнүсәгә генә ишетелерлек итеп)*. Кемнәр бу? Кайдан таптың боларны?

Ф ә н ү с ә. Хәдичәне танымадың мәллә? Минем группадашым бит! Университетта бергә укыган идек, синең аны күргәнең бар.

Р а й н у р. Хәтерләмим бер дә.

Ф ә н ү с ә. Ничек инде хәтерләмисең?! Группадашлар белән бер очрашканда син дә бар идең бит! Ресторанда бер-гә утырдык. *(Фәннурга ишарәле.)* Ә бу – аның ире, Фәннур исемле. Хәдичәне узган атнада Казанда очраткан идем, коттеджны күреп китәрсез дип, кунакка чакырдым. Менә бүген автовокзалдан каршы алдым үзләрен.

Р а й н у р. Машиналары юкмыни?

Ф ә н ү с ә. Бар, диләр... «Москвич». Иске икән. Юлда ватылыр дип курыкканнар.

С ә р и я *(Хәдичәгә)*. Мин дә бит монда яшим. Әнә тегендә генә безнең коттедж. Безнең дип, Раил абыйларның коттеджы инде.

Х ә д и ч ә . Раил?! Ул да монда яшимени?

С ә р и я . Әйе. Әле менә хатыны белән икесен чит илгә – Анталиягә җибәрдем! Балаларыгыз белән ял итеп, дөнья күреп кайтыгыз, мин әйтәм! Үзем дә бер атна элек кенә Гарәп Әмирлегеннән кайттым...

Х ә д и ч ә . Да-а-а... Гомер буе тирескә чумып яшәгән чая Фатыйма белән Габдерәүф балалары да кеше булган диген, ә! Дистрофик абыең белән кайчандыр бер партада утырган идек. Дәрес буе йоклар ие... Да-а-а... Дөнья бу диген!.. Әйтәм аны, бер дә авылга кайтканыгыз юк...

С ә р и я . Әти белән әни үлгәч, кемгә кайтасың инде?! Авылда бүтән туган-тумачалар да калмады.

Х ә д и ч ә . Шулай инде, шулай. Якын туганың булмагач, чит кешегә кайталмыйсың, дөрес! Күңелем киң дип кенә булмый әле ул. Бөтен нәрсә кыйммәт бит хәзер. Сөт-каймагы да үзеңнән артмый!

С ә р и я . Елга ике-өч мәртәбә чит илгә чыгып керәм. Как-никак, туристик агенствода эшлим бит! Путёвкалар белән эш йөртәм!

Х ә д и ч ә *(кинәт үзгәреп, дәртләнеп)*. Кит аннан! Чынлапмы? Фәннур, ишеттеңме? Сәрия чит илләргә ял итәргә җибәрә торган җирдә эшли икән бит! Әстәгым! Менә бит, ә! Сәриякәем! Кадерле авылдашкаем! Авылдаш кына түгел, чыбык очы тиешле туганнар да бит әле без, Сәриякәем! Фатыйма апаның туганнан туган абыйсы безгә дә җизни тиешле бит!

Р а й н у р . Табын әзерләргә кирәктер ич, Фәнүсә? Булышыйммы, матурым?

Ф ә н ү с ә *(Хәдичәнең тавышына охшатып)*. Хәдичәнең сайраганын тыңлап, онытылып киткәнмен. Әйе шул, әйдә, өйгә керик әле, Райнуркаем!

Р а й н у р . Сез сөйләшә торыгыз, без момент!

Өйгә кереп китәләр.

Х ә д и ч ә . Менә бит, ә! Көтмәгәндә-уйламаганда! Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына! Шушыдыр инде ул дөньяның хикмәте! Без дә Фәннур белән икәү берәр чит илгә барырга дип уйлап кына торадырыек! Болай булгач, барабыз! Иң якын туганың путёвкалы урында эшләп тә бармасаң... Безгә путёвканы ярты бәясенә эшләрсең инде, җаныкаем, Сәриякәем! Ничек тә җаен табарсың!

Ф ә н н у р. Тинтерәтмәле Сәрияне! Бетмәде инде шул соранууларың!

Х ә д и ч ә. Нинди сорану булсын! Нинди сорану булсын! Соранумыни бу?! Әй, ике туган сөйләшкәндә, бака боты кыс-тырып тормасана! Үзенең сыңар туганы да юк, сүз әйткән була тагы! Менә шулай сөйләштек, Сәриякәем! Кайчанрак бару мәсьәләсен хәл иткәч, тагын конкрет сөйләшербез әле, име?

С ә р и я. Авылдашларга кулдан килгәнчә булышмыйча булмас инде...

Х ә д и ч ә. Авылдашлар гына түгел... Туганнар, дим бит инде, туганнар без! Безгә туп-туры кайт!

С ә р и я. Рәхмәт чакыруың өчен!

Х ә д и ч ә. Рәхмәтне без дә әйтербез... Алла боерса! Чит илгә барып кайткач... И-и-и-и!.. *(Сәрияне кочаклап ала.)* Шундый туганнарың булганда, иллә рәхәт дөньяларда яшәве!

И л н у р керә. Бер кулында – пакет-сумка, икенчесе белән кармак сабы тоткан. Барысы белән дә баш кагып кына исәнләшә.

С ә р и я. Исәнме, Илнур җаным?! *(Кармакка ишарәләп.)* Балык тоттыңмы әллә? Килькиләр әләгәме, минтайлармы?

Илнур, елмаеп, «юк» дип башын селки. Хәдичә аңа сәерсенеп карап тора. Фәннур Илнурны игътибар белән күзәтә.

Х ә д и ч ә. Телсез мәллә бу чибәр егет?
С ә р и я. Бүген дә рәсем ясадыңмыни, Илнур?

Илнур «әйе» дип баш кага. Тагын ниндидер ым-хәрәкәтләр ясый.

С ә р и я. Ни әйткәнеңне аңламыйм шул, Илнур җаным.
Ф ә н н у р *(кинәт җанлана төшеп)*. Әти монда түгелме, дип сорый ул.

Хәдичә Фәннурга гаҗәпләнеп карый.

С ә р и я. Нургази абыймы? Баягынак китте шул. Өйгә кайтам, диде.

Илнур китмәкче була. Өйдән Р а й н у р чыга.

Р а й н у р. О-о, Илнур! Сәлам, рыбак! Салют!

Илнур баш кагып исәнләшә.

Р а й н у р *(ишарәләр белән дә сөйләп)*. Нургази абыйга да әйттем. Сиңа да әйтәм. Хәзер минем әни килеп җитәчәк. Коттедж карарга! Нургази абый белән сине дә ждём-с! Нургази абыйны кайтып алып килә торсаң да була. Фәнүсә хәзер өстәл әзерләп бетерә. Понял, Илнур?

Илнур «әйе» дип баш кага да «киттем» дигән ишарә ясый.

Р а й н у р. Яхшы! Көтәбез! Ждём-с!
С ә р и я. Мин дә кузгалыйм әле. Озак тордым. Күр-шеләрнең хәлен белеп чыгыйм дип кенә кергән идем. Әйдә, Илнур җаным, киттек! *(Илнурны култыклап ала.)*

Бергә чыгып китәләр.

Р а й н у р. Әни килгәч, син дә кер, Сәрия!

Сәриянең тавышы гына ишетелә: «Яра-а-ар! Рәхмәт!»

Х ә д и ч ә. И-и-и... Нинди чибәр егет! Теле юк диген, ә?! Ата-анасына гомерлек хәсрәт инде бу, мәңгелек хәсрәт!

Р а й н у р. Әнисе юк аның... Әнисез үскән ул!

Х ә д и ч ә. Менә бит, ә! Әнисез дә икән, өстәвенә телсез дә! *(Фәннурга.)* Син баягынак аңлап сөйләшкән кебек булдың... Кайдан беләсең син телсезләр телен?

Ф ә н н у р. Мин бит университетта укыганда махсус курсларга йөрдем. Телсезләр мәктәбендә практика да уздым әле. Дөнья бит, кайвакыт телсезләр телен белүнең дә кирәге чыгып куя. Әле менә син беренче тапкыр авызыңны ял иттердең. Миңа сөйләшергә җай чыкты!

Х ә д и ч ә. И хәчтерүш! Полиглот булган берәү! Бер җөмләне көчкә әйләндердең... Сөйләшергә җай чыкты, дип, авыз тутырып әйткән буласың тагы... Каяле, Фәнүсәкәемә булыша торыйм, ичмасам! Кара инде бу баскычны! Кара инде бу ишекне! И-и-и! Галәмәт инде, галәмәт! *(Сөйләнә-сөйләнә кереп китә.)*

Р а й н у р. Әйдә, Фәннур дус, хатыннарсыз гына сөйләшеп утырыйк әле. Кайчан безгә мондый җай чыга...

Беседкадагы утыргычка утыралар.

Ф ә н н у р. Коттеджың шәп булган! *(Йортка карап.)* Моңа бит бик күп агач кирәк, акча турында әйтмим дә инде. Анысы – само собой! Күренеп тора: йорт хуҗа-сы – бул-дыра торган кеше!

Р а й н у р *(мактаганга күңеле булып)*. Байлык үзен-нән-үзе килми, диләрме әле?! Укырга, укырга и эшләргә кирәк! Иң главные – уйлап эш итә белергә кирәк! Ә-әз генә ошибка, малейший ялгышлык җибәрдеңме – беттең. Конец! Гут бай, Америка! Сау бул, Кәҗә бистәсе!

Ф ә н н у р. Хатынның... Хәдичәне әйтәм, сөйләгәне колак очында эленеп калган... Син крупный бизнесмен бит әле?! Машиналар белән эш йөртәсең бугай?!

Р а й н у р. Крупный дип... Ну да! Известный бизнесмен... да! Райнур Шәйхиевне чит илләрдә дә яхшы беләләр! Уважают!

Ф ә н н у р *(гаҗәпләнеп)*. Шәйхиев?! Син Шәйхиевме-ни?

Р а й н у р. Ну да! Шәйхиев! Райнур Шәйхиев!

Ф ә н н у р. Мин дә... минем дә фамилиям... Шәйхиев бит!

Р а й н у р. Да? Не может быть! Неужели Шәйхиев?

Ф ә н н у р *(Райнурча әйтеп)*. Ну да!

Р а й н у р. Без бит адашлар, алайса! Тёзки! Тот бишне, адаш! *(Фәннурга кулын суза.)*

Кул бирешәләр.

Ф ә н н у р. Агай-энеләр дә түгел микән әле без? *(Көлә.)* Ха-ха-ха!..

Икәүләп көлешәләр.

Р а й н у р. Ә нигә?! Всё может быть! Ха-ха-ха! Синең... отчествоң ничек? Ха-ха-ха!..

Ф ә н н у р. Ха-ха-ха! *(Көлү аралаш.)* Газинурович!..

Р а й н у р *(кинәт очкылык тотып)*. Ыйк! Ничек... Газинурович?! Правда што ли?

Ф ә н н у р *(көлүеннән туктый алмыйча)*. Ха-ха-ха!.. Ну да!..

Р а й н у р. Постой! Мин дә Газинурович бит!

Ф ә н н у р. Вәйт әкәмәт! Әллә чынлапмы? Икеләтә адашлар булып чыктык түгелме соң? Тот тагын бишне!

Янә кул бирешәләр. Көлешәләр.

Р а й н у р. Без братлар түгелме икән әле? Анекдоттагы кебек, ә?! Ике мишәр очрашкан, ди бит. Шәһәр мунчасында. «Син кайсы яктан?» – дип сорый икән берсе. «Ульяннан!» – ди икән икенчесе. «Мин дә Ульяннан бит!» – дигән сорау биргәне. «Кайсы авылдан?» – «Кулаткадан». – «Вай, мин дә Кулаткадан». – «Син кем малае?» – «Фәлән әзи малае!» – «Кит аннан! Мин дә Фәлән әзи малае бит! Бак! Без братлар икән, вай!» – «Исәнме, брат!» – «Саумы, брат!» – «Атай нишләп ята?» – «Катты!» – «Ничек «катты»?» – «Паталукка бакты да катты!» Ха-ха-ха!..

Ф ә н н у р. Ха-ха-ха... Менә бит, ә! Менә бит, ә! Братлар диген! Ха-ха-ха!

Әйбәт костюм, ап-ак күлмәк кигән, галстук таккан Г а з и н у р керә.

Г а з и н у р. Тук-тук!

Р а й н у р. Кер әйдә, Нургази абый! Кил әле монда тиз-рәк!

Г а з и н у р *(Фәннур белән күрешеп)*. Исәнме, энекәш!

Ф ә н н у р. Фәннур булам. Исәнмесез, абый!

Г а з и н у р. Бик каты көлешәсез... Анекдот сөйлисездер әле?!

Р а й н у р. Точно, Нургази абый! Каян белдең?

Г а з и н у р. Ир-атлар очрашса, йә анекдотлар сөйлиләр инде, йә хатын-кызларның гайбәтен саталар... Икенең берсе! Шулай түгелмени?!

Р а й н у р. Пачти! Ха-ха-ха!..

Көлешәләр.

Ф ә н н у р *(Газинурга)*. Абый, ботинкагызның шнуры сүтелгән.

Г а з и н у р. Хәтерсез баш! Бәйләргә онытты микәнни?! *(Ботинкасына иелә.)*

Р а й н у р. Нургази абый, без монда... Ха-ха-ха!.. Фән-нур белән адашлар булып чыктык бит әле!.. Юк, пачти быратлар!.. Ха-ха-ха!..

Өйдән Ф ә н ү с ә чыга.

Р а й н у р. Фәннур да, мин дә...

Ф ә н ү с ә *(кесә телефонын тоткан кулын алгарак сузып, Райнурга карап)*. Шәйхиев!

Шулчак Газинур башын кинәт калкыта, Райнур белән Фәннур Фәнүсәгә таба борыла.

Ө ч е с е  б е р г ә. Ә?

Райнур белән Фәннур башта Газинурга, аннан бер-берсенә карап, дәр-рәү көлеп җибәрәләр. Аларга Фәнүсә дә кушыла. Газинур, ярамаган эш өстендә тотылган малай кебек, бермәл нишләргә белмичә тора, костюмын рәтләштергәндәй итә, кулларын буташтырып ала...

Г а з и н у р. Мин... Миңа әйтәсең дип торам, Фәнүсә! *(Бармагын колак тишегенә тыгып селкетеп ала.)* Яшь бара, колак та дөрес ишетми башлады...

Ф ә н ү с ә *(көлүеннән туктап, Райнурга)*. Телефоныңны өйдә калдыргансың, Шәйхиев! Сиңа Марсель шалты-рата! Мә, сөйләш!

Фәнүсә телефонны Райнурга бирә дә өйгә кире кереп китә.

Р а й н у р. Әйе, Марсель! *(Сәгатенә карап.)* Яхшы! Молодец! Хәзер каршы алабыз! Карале, анда – безнең урам башында – кемгәдер бүрәнәләр китереп аударганнар. Юл-да да яталар... Сак бул, кума! Понял? Ярый, давай!.. Хәзер каршыгызга чыгабыз. Связь окончен! *(Телефонын кесәсенә тыгып куя.)* Коттеджны кабул итәргә госкомиссия килә! Әни килә! *(Газинурга.)* Нургази абый, бар, иренмә инде, кайтып Илнурны алып кил!

Г а з и н у р. Кайтмады бит әле ул!

Р а й н у р. Кайтты инде, кайтты! Әле генә монда сине эзләп килгән иде.

Г а з и н у р. Каршыга очрамады. Аймылыш булганбыз инде алайса.

Р а й н у р. Шулайдыр. Илнурга әйт, картинасын алып килергә онытмасын!

Г а з и н у р. Әбизәтелне! Мин язу язып калдырган идем калдыруын... *(Икеләнеп тора.)*

Р а й н у р. Давай, Фәннур... Адаш! Бырат! Без икәү әнине каршы алыйк!

Ф ә н н у р. Әйдә, быр-рат! Ха-ха-ха!

Көлешә-көлешә чыгып китәләр. Газинур, җитдиләнеп, бермәл алар чыгып киткән якка карап тора. Аннан таган янына килеп, аны атындырып җибәрә. «Күк күгәрчен» көе яңгырый.

Г а з и н у р *(авыр сулап)*. И-их!

Ерактан (яшьлектән) Газинурның җырлаганы ишетелә.

Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный...

Ут сүнә. Музыка.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Үткән гасыр. Җитмешенче еллар башы. Спектакль башындагы күренеш. Таганның ватык булуы, әүвәлге матур өйнең томан аша гына күренгәндәй шәйләнүе, бу урынның чүплеккә әйләнгәнлеге күпмедер вакыт узганлыгын искәртә төсле.
Бер-берсенә сыенып, салмак кына атлап, Нәфисә белән Газинур керә. Нәфисәнең җилкәсендә Газинурның пиджагы. Газинур белән Нәфисәнең үз-үзләрен тотышы яшь ир белән яшь хатынны хәтерләтә. Газинур мыек җибәргән, Нәфисә, чәчләрен җыеп-өеп, җитмешенче елларга хас булган причёска ясап куйган.

Нәфисә. Без гел шулай, кешеләрдән качып-посып яратышып яшәрбез микән, Газинур?

Газинур. Борчылма, Нәфисә. Тиздән бергә булырбыз! Гөлчирә белән аерылышыйм инде... Аннан соң мин – мәңге синеке!

Нәфисә. Аерылышабыз, дисең дә диюен... Гөлчирә апа сине ычкындырмас шул!

Газинур. Ычкындырыр, нибуч! Болай яшәп булмаганлыгын бер аңларга тиеш бит инде ул! Яратмыйм мин аны, хет үтер, яратмыйм!

Нәфисә. Нигә өйләндең соң алайса?

Газинур. Үзе бит... Гөлчирә бит...

Нәфисә. Характерың йомшак шул синең, Газинур. Үз сүзеңне каты итеп әйталмыйсың. Җебегән син! Шуңа күрә Гөлчирә апага өйләндең дә! Дөресрәге, Гөлчирә апа сиңа өйләнде!

Газинур. «Апа» димәле шуны!

Бермәл тын торалар.

Нәфисә. Мин көн саен елыйм, Газинур. Ишетәсеңме, көн саен! «Кайчаннан бирле?» дип ник сорамыйсың, Газинур?

Газинур. Без Гөлчирә белән бергә яши башлаган көн-нән бирледер инде.

Нәфисә. Юк шул, тагын да алдарак! Син армиядән кайткан көнне елый башлаган идем мин. Хәтереңдәме, шушы урында очрашкан идек?

Газинур. Истә.

Нәфисә. Гөлчирә апа... Гөлчирә апа сине өйгә хәтле култыклап кайтты. Ә мин сезнең арттан күз яшьләремә буылып атладым... Аннары, лапас өстендәге печәнлеккә менеп, төне буе илереп еладым. Кулымнан бәхет кошы ычкынганын сизеп, шуны аңлап еладым мин... Хәзер дә елыйм, Газинур.

Газинур. Елама, Нәфисә! Телисеңме, мин сиңа хәзер бер шигырь сөйлим?

Нәфисә. Үзеңнекеме әллә?

Газинур. Юк инде, син нәрсә! Балта сабынаияләшкән кул белән каләм тотып буламыни...

Нәфисә. Син бит шигырьләр укырга яратмый идең, Газинур!

Г а з и н у р. Соңгы вакытларда күңелем әллә нишләде... Шигырьләр укып, алардан юаныч эзли башладым... Сагышлы шигырьләрдә безнең язмыш чагылып ята кебек. Менә... тыңлале:

Елыйсың. Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Юкса бит ир-егеттә дә
Шау тимер йөрәк түгел.

Беләм, әйе, ялгышканбыз –
Ак һәм кара буталган.
Безгә тиешле учактан
Чит кешеләр ут алган.

Назлар кире кайтсалар да,
Язлар кайтмас кабаттан.
Без генәме үз канатын
Давылларда канаткан?

Ялгышканда көлгәнбез бит,
Елмайганбыз бит әле!
Хәзер дә көлик, капланып,
Күз яшьләре үтәли...

Елыйсың... Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Миндә дә бит шау тимердән
Ясалган йөрәк түгел.

Күз яшьләрен сөртеп ала.

Н ә ф и с ә *(елап)*. Җылата торган шигырь. Кем язган икән моны? Нәкъ безне күздә тоткан диярсең...

Г а з и н у р. Зөлфәт дигән шагыйрьнеке. Беренче тапкыр укыган чакта, сине уйлап, минем дә күзләремә яшьләр килгән иде. Хәзер дә менә җылатты... Җебегән, дип дөрес әйттең син миңа, Нәфисә. Әйе, җебегән мин! Елак мин! Слабак! Аумакай! Үз бәхетемне үзем аяк астына салып - таптый яздым...

Н ә ф и с ә. Таптадың бугай инде син аны, Газинур...

Г а з и н у р. Алай димәле, Нәфисә! Әле соң түгел...

Н ә ф и с ә. Соң инде, Газинур. Бергә булсак та, без барыбер бәхетле булалмаячакбыз...

Г а з и н у р. Ничек? Нигә? Алай димәле, Нәфисә...

Н ә ф и с ә. Син Гөлчирә апаны ташлап китсәң дә, улыңны ташлый алмаячаксың, Газинур! Син менә айдан артык инде авылда. Үзең мине уйлыйсыңдыр, ышанам. Ә җаның белән, күңелең белән улың янында икәнеңне сизеп торам бит мин... Яратасың син улыңны, үлеп яратасың!

Шулай түгелмени, Газинур?! Юк, син җавап бирмә. Үзеңне дә, мине дә алдарга тырышма.

Г а з и н у р *(урыныннан торып)*. Син шушы сүзләрне әйтергә дип алып килдеңмени мине монда, Нәфисә? Нәфисәм, күгәрченем минем...

Н ә ф и с ә. Күгәрченнәр парлы була, Газинур.

Г а з и н у р. Гел елыйм, дип ялганлыйсың син, Нәфисә. Яратмыйсың син мине. Яратсаң, мондый сүзләр сөйләмәс идең. Бергә булыйк, дияр идең.

Н ә ф и с ә *(сикереп торып)*. Яратам, Газинур, яратам! Ләкин кеше ярын сөяргә хакым юк минем! Моңарчы сөй-дең бит әле, диярсең. Сөйдем! Ялгыштым! Әмма мин ялгышканымны соңга калып булса да аңладым! Без тәүге тапкыр шушы урында үбештек, шушы урында вәгъдәләр бирештек, «Мәңге бергә булырбыз!» диештек. Без адаштык, Газинур!

Г а з и н у р *(Нәфисәне кысып кочаклап)*. Нәфисә!

Н ә ф и с ә. Газинур! Без бүгеннән соң кабат очрашмабыз, ахрысы. Син китәрсең кебек бүген!

Г а з и н у р. Алай димәле, Нәфисә! Китәргә уйлаганым да юк!

Н ә ф и с ә *(шигырь укып)*.

Без дигәнчә генә барса икән,
Булса икән без дигәнчә генә.
Тимерченең чүкечедәй, сиңа
Килеп төшә тормыш, яньчә генә –
Барса икән без дигәнчә генә...

Мин дә шигырьләр укыйм, Газинур! Алардан мин күңелемә юаныч табам. Алар соңгы минутымача юаныч булырлар кебек.

Г а з и н у р. Алай димәле, Нәфисә...

Н ә ф и с ә *(әкрен генә җырлап)*.

Һаваларда очкан кошлар
Ничек кавыша микән?
Без кавышалмый ялгыштык,
Кошлар ялгыша микән?

Һаваларда очкан кошлар
Кая китәләр микән? –
Минем кебек янып-көеп,
Гомер итәләр микән?

Һаваларда очкан кошлар
Кай җиргә төшә микән?
Дөньяда минем барлыгым
Исеңә төшәр микән?..

Ашыгып-кабаланып, Г ө л ч и р ә керә. Ул шәһәрчә киенгән.

Г ө л ч и р ә. Гулящийлар! Заразылар! Себеркеләр! Ишет-тергәннәр иде аны! Дөрес икән! Оятсызлар! Ябышып каттыгыз мәллә? Мине күргәч тә аерыла алмый торасыз... Чән-челгереләр!..

Нәфисә Газинурның кочагыннан чыга.

Г а з и н у р. Чәпчемәле, Гөлчирә. Күрдең инде... Әйбәтләп кенә сөйләшик!

Г ө л ч и р ә. Чәпчемәм менә! Артыңны кысып, тик кенә тор, сөйрәлчек тәре! Сиңа сүз бирелмәгән! Авылга качып котылмакчы булган берәү! Качармын менә!

Г а з и н у р. Качмадым мин синнән. Чыдарлык, түзәрлек хәл калмагач киттем. Яратмыйм мин сине!

Г ө л ч и р ә. Мин синнән «Яратасыңмы?» дип сорамыйм. Тик кенә тор! Малаең больницада ята, ә син себерелеп йөрисең, имгәк!

Г а з и н у р. Улым?!

Н ә ф и с ә. Больницада?!

Г ө л ч и р ә *(Нәфисәгә)*. Бәреп үтергәнче, югал күз алдымнан!

Г а з и н у р. Кычкырма Нәфисәгә! Аның бер гаебе дә юк!

Г ө л ч и р ә. Әкият сөйләмә! Мин монда әкият тыңлар-га килмәдем! Син кабахәтнең... *(Нәфисәгә ымлап.)* Бу явызның да... икегезнең дә сволочьлар икәнегезне бик яхшы беләм! Арттан пычак кадаучылар сез! Җаныгызны алам әле мин сезнең! Бүген разборка ясап торырга вакытым юк! Машина көтеп тора. *(Газинурга.)* Киттек, хәшәрәт! Малаең сине таптыра! *(Нәфисәгә.)* Ә син, кеше семьясын бозучы, исеңдә тот: моннан соң әгәр икегез турында ялгыш бер кыек сүз ишетсәм, капут сиңа! *(Газинурга.)* Аңладыңмы, җир бит?!

Г а з и н у р *(Нәфисәгә карап)*. Нәфисә, малай бит, больницада икән бит.

Н ә ф и с ә. Хуш, Газинур...

Г ө л ч и р ә. Алдыңа кара! *(Газинурны эткәләп-төрткәләп алып чыгып китә.)*

Нәфисә, куллары белән битен каплап, тораташ булып басып кала.
Ут сүнә. Музыка.

П ә р д ә .

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге коттеджлы күренеш. Фәннур күтәреп кергән зур сумка бая ничек куелган булса, урынында һаман шул килеш тора. Өйдән көлешә-көлешә Ф ә н ү с ә белән Х ә д и ч ә чыга.

Х ә д и ч ә. Бәхетең бар икән, Фәнүсәкәем! Кайнанаңнан уңгансың! Бик сирәк киленнәргә генә тәти мондый бәхет! Но яхшы кайнана белән яшәүнең бер авыр ягы бар! Рәхәтнең дә бер михнәте бар дигәндәй, бар бер авыр ягы! Рәхәтләнеп, ду китереп, кара яндырып талашалмыйсыз инде түлке! Ә талашасы килә-ә-ә!.. Табак-савыт юган чакта юри генә бер тәлинкәне идәнгә төшереп чәлпәрәмә китерәсең... Кайнананың шунда бер ялгыш сүз ычкындыруы җитә... Шундук мәхшәр кубачак югыйсә! Юк! «Сөенечкә булсын!» дигән сүзе белән синең гениальный планыңны җимерә дә ташлый. Гөлт итеп кабынам дип торган бөтен ачуың шул минутта юкка чыга да куя. Дөньядагы бөтен әшәке сүзне пулемёт кебек сиптерергә торган авызыңның җырылганын сизми дә каласың. Бик акыллы, бик затлы, бик укымышлы, үзе гомер буе сыер сауса да, бик интеллегент хатын иде минем кайнана да!..

Ф ә н ү с ә. «Иде» дисең, үлдемени?!

Х ә д и ч ә. Әйе. Урыны җәннәттә булсын! «Җәйләүләрдә сыер сауды Гөлмәрьям...»

Ф ә н ү с ә. Нишләп бик иртә үлде соң? Әйбәт тә яшәгәнсез үзегез...

Х ә д и ч ә. Әйтсәм ышанмассың, Фәнүсәкәем! Аны яшьлек мәхәббәте гүргә кертте.

Ф ә н ү с ә. Аңлап бетермәдем, ничек? Нинди яшьлек мәхәббәте?

Х ә д и ч ә. Яшь чакта ул безнең авылдагы бер егетне үлеп яраткан булган. Кавыша алмаганнар. Хәлләр булган инде анда. Сөйләсәң, үзе бер китаплык! Телевизордан барган хәзерге сериаллар аларның мәхәббәте янында пүчтәк кенә!

Ф ә н ү с ә. Нигә бергә була алмаганнар? Араларына чит кеше кергәнме?

Х ә д и ч ә. Чит кеше дип, бертуган апасы. Егетенең башын әйләндергән дә, үзенә өйләндереп, шәһәргә алып тайган!..

Ф ә н ү с ә. Кайнанаң, гомер буе үкенеп, мәхәббәтен сагынып яшәгәндер...

Х ә д и ч ә. Мәхәббәтен сагынып яшәве хак. Сорап килүчеләр бар иде. Бик чибәр иде бит минем кайнана. Аннары горур да иде!

Ф ә н ү с ә. Нык яраткан булган икән егетен.

Х ә д и ч ә. Әйтәм бит, үлеп яраткан, дим! Беләсеңме, Фәнүсәкәем, шигырьләр язган әле ул! Бер калын блокнот... Барысы да мәхәббәт турында. Үзе үлгәннән соң чемоданыннан таптык. Соңгы битендәге шигырен иртәгә үләсе дигән көнне язып куйган. Ул бит Рамазан аенда үлде. Таң алдыннан. Авырып та йөрмәде югыйсә... Изге кеше булган инде. Ходай җанын Рамазан аенда алганга күрә әйтүем.

Ф ә н ү с ә. Карале, Хәдичә, баядан бирле әйтергә, сорарга кыймыйча торам. Кайнанаң кияүгә дә чыкмаган... Ә ничек?.. *(Өй тарафына башы белән ишарәләп.)* Ирең... Фәннурың дөньяга килгән соң? Әллә...

Х ә д и ч ә. Әйе! Әүлия икәнсең. Нәкъ син уйлаганча! Фәннурның туу турында таныклыгында әтисенең исеме языл-маган – прочерк! Ул

вакытта язмаганнар бит, сызып ташлаганнар да вәссәлам! Атасы шул егет икәнен бөтен авыл белгән югыйсә. Авыл белгәнне кайнанамның әти-әнисе ишетми каламы, ишеттерүчеләр табылган... Алар да күптән гүр иясе инде.

Ф ә н ү с ә. И язмыш диген, ә?! Фәннурның тууын әтисе белде микән соң?

Х ә д и ч ә. Юктыр. Белмәгәндер. Баласы барлыгын белгән булса, йөрәге түзмәс иде, хет бер кайтып күрер иде. Фәннурга атасыз үсәргә насыйп булган инде. Ярты ятим! Кирәк чакта ата назын, кирәк чакта ата каешын татымаганга күрә, хуҗалыкчан булып үсмәгән дә инде ул менә. Гаиләдәге бөтен эш, бөтен авырлык минем җилкәдә хәзер! Күтәр, Хәдичә! Һоп-па! Тарт, Хәдичә! На! На! «Ял ит, Хәдичә! Тыр-р-р!» диюче юк!

Ф ә н ү с ә. Безнең Райнур да ятим үскән инде анысы...

Х ә д и ч ә. Ул хет чын хуҗа булып үскән. Әнә нинди коттедж салдырып куйган! Патша сарае диярсең!

Ф ә н ү с ә. Фәннурың төпле кешегә охшаган. Сиңа аның белән тормыш итүе җайлыдыр.

Ф ә н н у р чыгып тыңлап тора.

Х ә д и ч ә. Наоборот! Аңа минем белән җайлы! Булган хатын эләкте үзенә. Әйтәм бит, өйдәге бөтен эш минем җилкәдә! Кибеттән товарны мин алып кайтам! Сатам! Берәрсенә укол кадатырга кирәк булса, мин чабам. Кем массаж ясый? Мин! Туйларны кем гөрләтеп алып бара? Хәдичә! Шәһәрдәге балаларына, оныкларына дип, кемгә оекбашлар бәйләргә заказ бирәләр? Алтын куллы Хәдичәгә!

Ф ә н н у р *(кинәт телгә килеп)*. Акчаны бик ярата инде ул безнең Хәдичә!

Х ә д и ч ә. Әстәгым! Тыңлап торган икән! Ышпион! Кем акча яратмый инде?! Тиле!

Фәнүсә белән Фәннур кычкырып көлә.

Ф ә н ү с ә *(Фәннурга)*. Карыныгыз ачтымы әле? Түзегез инде бераз. Нургази абыйлар килеп җитсен, ди бит Райнур. Көткән-көткән көтик, булмаса!.. Әллә капкалап аласызмы соң?

Ф ә н н у р. Мин тук. Рәхмәт, Фәнүсә.

Х ә д и ч ә. Берүзем ашап утырмам инде. Килешеп бетмәс. Бая сиңа ризык әзерләшкәндә тегесен-бусын капкандай иткән идем. Ашказаны тынычланган кебек булды.

Ф ә н ү с ә *(Фәннурга, өйгә ишарәләп)*. Райнурлар нишли әле анда?

Ф ә н н у р. Госкомиссия рәисе бик таләпчән булып чыкты. *(Көлә.)* Һаман тикшерә! Өйрәтә! Киңәшләрен бирә. Бер дә гомер буе столовойда эшләгән кеше димәссең! Йорт салу эшен белеп сөйләшә.

Ф ә н ү с ә. Исең китмәсен. Минем кайнанам шундый инде ул! Белмәгән нәрсәсе юк. Фатирына сантехник та чакырмый ул. Берәр нәрсәсе ватылса, Райнурга да әйтеп тормый, үзе рәтли дә куя.

Х ә д и ч ә. Нәкъ минем төсле икән!

Г а з и н у р белән И л н у р керә. Илнур да киенгән-ясанган, кулына чүпрәк белән капланган картина тоткан. Газинур кара күзлектән.

Г а з и н у р. Көттердекме? *(Хәдичәгә.)* Исәнме, сеңлем?

Хәдичә баш кагып исәнләшә.

Ф ә н ү с ә. Юк, зыян юк. Әйдәгез, узыгыз! Райнур! Нургази абыйлар килде!

Х ә д и ч ә. Абзый кеше кара күзлек киеп җиппәргән әле! Килешеп тора үзенә!

Г а з и н у р. Кояш күзне чагылдыргач... Кигән булдым әле менә...

С ә р и я керә. Ул да яңа, матур күлмәк кигән.

С ә р и я. Мин дә килеп җиттем әле!

Ф ә н ү с ә. Әйдә, уз, Сәрия!

Сәрия Илнур тирәсенә барып баса.
Өйдән башта Р а й н у р, аннан бераз гына калышып, Г ө л ч и р ә чыга. Гөлчирә дәрәҗәле урында эшләгән хатын-кызлар төсле заманча киенгән.

Р а й н у р. Оhо! Все в сборе! *(Гөлчирәгә борыла.)* Әни! Таныш бул! Нургази абый! *(Газинурга.)* Бу минем әни була инде. *(Илнурга карый.)* Ә бу – Илнур. Искусство кешесе! Рәссам! Киләчәктә Шишкин, Пушкин, Салават кебек очень известный буласы кеше. Коттеджны алар бизәкләп чыкты инде, әни!

Райнур таныштырганда, Газинур, Илнур һәм Гөлчирә баш кагышып исәнләшәләр.

Ә менә бу гүзәл туташ – безнең яңа күршебез Сәрия! Сәрия, бу – минем әни!

Сәрия белән Гөлчирә кул бирешеп күрешәләр.

Х ә д и ч ә *(үпкәләгән булып)*. Райнур, ә мине кем таныштыра?

Р а й н у р *(кыланып)*. Глубоко извиняюсь, мадам!.. Хәдичә! *(Фәннурга ишарәләп.)* Фәннурның чибәр хатыны! Үзем белән таныштырып тормыйм. *(Фәнүсәне кочаклап ала.)* Фәнүсә! Минем хатын! Все похвальные слова – мне, претензии – к ней! Ха-ха-ха! Шутка! Таныштыгызмы? Әйдәгез, хәзер барыбыз да өйгә керәбез...

Г а з и н у р. Райнур, без башта бүләкне тапшырыйк инде...

Р а й н у р. Бүләк?! Ах, да-да...

Х ә д и ч ә *(кинәт)*. Стоп-стоп-стоп! Туктагыз әле, сез ашыкмый торыгыз! Без бүләк бирмәдек бит әле! Фәннур! *(Сумкасы янына килә.)* Мәрткә киткән кеше кебек басып торма, кил, җәтрәк! Чыгар бүләкне!

Фәннур сумкадан җиз самавыр ала.

Коттедж өчен үтергән бу самавыр! Антиквариат! Мондый самавырлар бик кыйммәт тора хәзер! Беләсегез килсә, Кукмара байлары – бертуган Комаровлар эшләткән самавыр бу! Менә монда язуы да пичәте бар. *(Укый.)* «БР. КОМАРОВЪ»! Братья Комаровы, ягъни...

Гөлчирә самавыр янына килә.

Г ө л ч и р ә. Авылда безнең дә шундый самавыр бар иде...

Фәннур сумкадан кечкенә чәйнек ала да Хәдичәгә бирә.

Х ә д и ч ә. Бусы – чәй пешерергә. Бергә укыган чакта Фәнүсә чәйсез торалмыйдырые. Шуны уйлап алып килдем. Мә, Фәнүсәкәем! Эчегез рәхәтләнеп! *(Чәйнекне Фәнүсәгә тоттыра.)*

Гөлчирә самавырны күтәреп, төбен карый.

Г ө л ч и р ә *(кинәт кычкырып)*. Әстәгым! *(Самавырны кулыннан төшереп җибәрә яза, кире куя.)*

Х ә д и ч ә. Бәтәч! Гөлчирә апа да безнеңчә сүләшә белә икән бит! Әстәгым, ди...

Р а й н у р<br>Ф ә н ү с ә *(икесе бергә)*. Нәрсә бар, әни?

Г ө л ч и р ә. Безнеке... безнекенә охшаган кебек димме соң... Астындагы язуы да нәкъ шундый. Сәер...

Хәдичә самавырның астын карый.

Х ә д и ч ә *(язуны текәлеп укып)*. Әх-мәт-нур... Әхмәт-нур?! *(Фәннурга.)* Синең бабаңның исеме бит бу! Тапкан урын! Самавыр төбенә исемен язып куймаса... Урлап китәрләр дип курыккандыр инде... И-һи-һи!.. Фәннур, нәрсә карадың соң син? Башкасын алгансың бит! Бутагансың... *(Башкаларга карап ала.)* Бездә мондый самавыр икәү иде. И-һи-һи-һи!.. Астын карап тормаганбыз инде.

Ф ә н н у р. Икәү дип... Мин бүтән самавыр күрмәдем өйдә.

Х ә д и ч ә. Нәрсә генә күрәсең соң син! Оятлы иттең бит мине... И-һи-һи-һи!.. Кире алып китәрбез инде алайса...Яңадан тегесен алып килербез әле бер килгәндә.

Р а й н у р. Бүләкне кире алып китмиләр инде, Хәдичә. Рәхмәт! Барыбер тегесе дә шундый, дисең. Бүген үк тәмләп чәй эчәрбез, шулай бит, Фәнүсә!

Ф ә н ү с ә. Әйе. Борчылмагыз ул хәтле, Хәдичә, Фән-нур...

Р а й н у р. Бу самавыр антиквариат кына түгел, искусство бу! Шедевр! Шишкин, Пушкин, Салават! И братья Комаровы! Хәзер үзен уважать иткән кешеләр мондый редкий әйберләрне бик оценить итә. Рәхмәт сезгә бүләгегез өчен! Вот это подарок!

Райнур самавырны беседкадагы өстәлгә куя. Гөлчирә самавырга карап-карап ала.

Г а з и н у р. Безнең бүләк антиквариат түгел инде, Райнур. Берүк гаеп итмәгез... Каяле, Илнур, күрсәт әле картинаңны!

Р а й н у р. Син нәрсә, Нургази абый! Нинди сүз ул?!

Илнур, картинаны төрелгән чүпрәгеннән арындырып, барысына да – хәтта тамашачылар да күрерлек итеп бер җайлы урынга сөяп куя.

С ә р и я. Бигрәк матур ясагансың, Илнур җаным! Авылны искә төшерә... Безнең авылда да шундый өй бар иде элек. Күптән кайтканым юк, хәзер бар микән?

Р а й н у р. Мин шәһәрдә туып үскән кеше. Но... авыл да минем өчен бик якын. Әни авылдан булгангадыр инде. Шәп картина булган бу, Илнур! Молодец!

Ф ә н ү с ә. Гаҗәеп булган бу, Илнур! Рәхмәт, Нургази абый, рәхмәт, Илнур!

Башкалар да картинаны сокланып карыйлар. Газинур Гөлчирәне күзәтә. Гөлчирә картина янына килә. Кинәт ул дерт итеп куя.

Г ө л ч и р ә. Ничек?! Бу бит... бу бит... безнең өй! *(Артка чигенә.)*

Ф ә н н у р *(әле картинага, әле Гөлчирәгә, әле Хәдичәгә карап)*. Юк, бу... бу – безнең өй!

Х ә д и ч ә. Әйе шул!

Р а й н у р. Как так?! Ничек «безнең өй»? Ничек сезнең өй? Сез нәрсә! Бу... картина бу! Искусство! Комаров! Пушкин! Салават!

Г ө л ч и р ә. Бу – мин үскән өй! *(Хәлсезләнә.)*

Р а й н у р *(әнисен тотып)*. Фәнүсә, урындык бир! Стоп, үзем алып киләм, сиңа ярамый. *(Райнур өйдән тиз генә урындык алып чыга.)* Утыр, әни!

Х ә д и ч ә. Фәннурларның элекке өе дә нәкъ шушындый иде. Күптән сүттек инде.

Ф ә н н у р. Охшаш өйләр һәр авылда да буладыр инде ул. Кем белә, бәлки, бер үк оста эшләгәндер...

С ә р и я. Әйтәм аны, миңа да бик таныш. Каян беләм икән моны дисәм... Әйе шул, Фәннур, сезнең өй бит бу!

Р а й н у р. Хет убейте, ничего не пойму! Әни?! Что за чертовщина?!

С ә р и я *(нәрсәнедер исенә төшереп)*. Пар күгәрчен! Кояш!

Р а й н у р. Ну и что! Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың, Сәрия?

С ә р и я *(коттеджга, капкага ишарәләп)*. Боларда да шул ук бизәкләр. *(Картинага төртеп күрсәтә.)* Монда да! Гаҗәп!

Х ә д и ч ә. Нәрсәсе гаҗәп инде! Күгәрчен тек күгәрчен, кояш тек кояш! Болары – агачтан, болары буяп ясалган.

Ф ә н ү с ә. Охшаш икән шул.

Г ө л ч и р ә *(картинага карап)*. Мин бу өйдә үстем!

Р а й н у р. Ни сөйлисең син, әни? Син яшәгән өйне Илнур кайдан белсен! Шулай килеп чыккан инде. Илнур, үзе дә белмичә, син яшәгән өйгә похоже өй ясаган. Вот и весь секрет! Талант дип атала бу, әни бәгърем! Илнур – великий талант! Великое искусство! Шишкин!..

Ф ә н ү с ә *(көлеп)*. Пушкин!..

Х ә д и ч ә. Салават!..

С ә р и я. И братья Комаровы!.. *(Илнурга яратып карый, төртеп ала.)* Һәм Илнур! Шулай бит, Илнур!

Г ө л ч и р ә *(Илнурга)*. Кайлардан алып ясадың син бу рәсемне?

Илнур этисенә ишарәли.

Г а з и н у р *(кесәсеннән фотосурәт чыгарып)*. Менә бу карточкага карап ясады ул.

Сурәтне Гөлчирәгә бирә, аны Райнур ала.

Р а й н у р. Похож... очень похож! *(Сурәтне әнисенә бирә.)*

Фәннур, Фәнүсә, Сәрия һәм Хәдичә, Гөлчирәнең артына басып, әле картинага, әле карточкага карыйлар.

С ә р и я. Копия!

Х ә д и ч ә. Тач охшатып ясаган! Әстәгым!

Ф ә н ү с ә. Картинадагы өй тагын да матуррак!

Ф ә н н у р. Безнең өй бу... Точно!

Г ө л ч и р ә *(Фәннурга текәлеп карап торгач, Газинурга)*. Сезгә каян килеп эләкте бу карточка?

Г а з и н у р . Каян дип... Кайчандыр бер танышым бир-гән иде.

Г ө л ч и р ә *(шикләнеп)*. Ул танышыгыз әллә Газинур исемле идеме?

Г а з и н у р. Әйе. Газинур исемле иде.

Г ө л ч и р ә. Сал күзлегеңне, Газинур! Таныдым мин сине!

Газинур күзлеген сала. Барысы да, сәерсенеп, аңа карап тора.

Р а й н у р. Ни сөйлисең син, әни? Бу бит Нургази абый!

Г ө л ч и р ә. Ялгышасың, улым... Бу кеше – Нургази түгел... бу... бу...

С ә р и я *(үзалдына сөйләнеп)*. Нур-гази... Гази-нур... Гази-нур... Нур-гази...

Г ө л ч и р ә. Бу – сиңа ата тиешле кеше!

Р а й н у р. Чёрт побери! Нинди ата? Нургази абый дип торам бит инде мин сиңа, әни! Нургази абый бу!.. Плотник! Ә бу – Илнур!

Г ө л ч и р ә. Илнуры кемдер, белмим... Ә бу кеше чынлап та сиңа ата тиешле кеше!

Фәннур белән Хәдичә бер-берсенә карашып алалар. Фәннур да үзен сәер тота башлый: тиктомалдан җилкәсен сикертә, кулларын һавада болгап ала, әле картинага, әле Газинурга карый.

Р а й н у р. Чёрт побери! Ышанмыйм! Ни сөйлисең син, әни? *(Газинурга.)* Әйт, Нургази абый, бер сүз! Алай түгел, диген! Әниең ычкынган, Райнур, диген!

Г а з и н у р. Әниең дөрес әйтә, Райнур... Әйе, мин – синең әтиең!

Авыр тынлык.

Р а й н у р. Чёрт побери! Не верю! Юк минем әтием! Юк! Алдашмагыз! *(Газинурны җилтерәтә.)* Син минем әти түгел, шулай бит, Нургази абый?! Әйт, шулай, диген!

Газинур дәшми.

*(Башкаларга карап.)* Сез ышандыгызмы болар сүзенә? Фәннур, син ник дәшмисең? Аңлыйсыңмы син монда берәр нәрсә?

Г ө л ч и р ә *(Газинурга)*. Моңарчы бар дип тә белмәдең. Утыз елдан соң малаең кирәк булдымы? Кирәк булгандыр шул! Байлыгы бар бит!

Г а з и н у р. Син ни сөйлисең, Гөлчирә?! Кирәк түгел миңа бернинди дә байлык!

Г ө л ч и р ә. Алдашма! Безне эшчеләр тулай торагында ач-ялангач калдырып ташлап качтың син!

Г а з и н у р. Качмадым мин. Синнән, сездән китүемнең сәбәбен үзең бик яхшы беләсең...

Ут сүнә. Музыка.

### И К Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш

Кабат янган ут тулай торак бүлмәсен яктырта.
Бүлмәдә өстәл, урындык, зур карават, шифоньер һәм бала арбасы шәйләнә.
Г ө л ч и р ә караватта утыра. Г а з и н у р бүлмәдә арлы-бирле йөренә.

Г а з и н у р. Мин ышанмыйм! Ничек инде сау-сәламәт туган бала үләргә мөмкин?!

Г ө л ч и р ә. Сау-сәламәт булмаган шул менә, йөрәге слабый булган.

Г а з и н у р. Син хет күрдеңме соң сабыебызны?

Г ө л ч и р ә. Врачлар әйтте, үзеңнең дә хәлең мөшкел, синең белән бер хәл булуы бар, диделәр. Укол кадап кына тынычландырдылар.

Г а з и н у р. Сабыйның үле гәүдәсен нишләп безгә җирләргә бирмәделәр?

Г ө л ч и р ә. Әйттем бит инде, мине жәлләгәннәрдер...

Г а з и н у р. Сине жәлләсәләр, мин бар бит әле!

Г ө л ч и р ә. Мин сиңа әйтеп бетермәгән идем, әйтмәм дигән идем. Гарип булып туган иде безнең балабыз.

Г а з и н у р. Ничек «гарип булып»?

Г ө л ч и р ә. Әйе, башы да тиешледән артык зур булган, туганда еламады да ул, сау бала түгел, диделәр врачлар. Детский церебральный паралич, диделәр. *(Куллары белән битен каплап елый.)* Тугач та миңа күрсәтмәделәр бит. Шикләнгән идем аны, юкка булмаган икән...

Г а з и н у р. Безнең нәселдә булмаган хәл! Һич башыма сыймый. Юк! Ышанмыйм мин моңа. Ышанмыйм! Барыбер нидер яшерәсең кебек син, Гөлчирә!

Г ө л ч и р ә. Райнурыбыз булганга сөен, Газинур. Шуңа куаныйк.

Арбадан бала елаган тавыш килә. Гөлчирә арбаны селкетә.
Музыка.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Коттедж ишегалдындагы күренеш. Ут Ф ә н н у р белән Х ә д и ч ә н е генә яктырта.

Х ә д и ч ә. Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы, Фәннур?

Ф ә н н у р. Аңлашыла башлады... Гөлчирә апа – әнинең апасы! Ә бу абзый...

Х ә д и ч ә. Синең атаң! Әстәгъфирулла! Райнур синең бертуганың... Әк-кә-мә-әт!..

Ф ә н н у р *(бармагын аызына куеп)*. Тс-с-с!

Алар янына С ә р и я килә.

С ә р и я. Фәннур, Нургази абый, то есть Газинур абый, синең әтиең булып чыга түгелме соң?

Ф ә н н у р. Тс-с-с! Тавышланма!

С ә р и я. Ә нигә? *(Авызын учы белән каплый.)* Молчу!

Сәхнә тулысынча яктыра. Р а й н у р, иелгән башын тотып, беседкада утыра. Ф ә н ү с ә болдырга сөялгән. И л н у р Газинурга «мин китәм» дигән ишарә ясый.

Г а з и н у р. Китми тор. Бу сөйләшү сиңа да кагыла...

Илнур таганга барып утыра. Сәрия аның янына килеп баса.

Г ө л ч и р ә. Әйе, икенче улыбыз... Райнурның энесе авыру булып туды. Тугач та үлде.

Р а й н у р *(башын күтәреп)*. Мин бу турыда в первый раз слышу! Чёрт побери! Кругом тайны веков!

Г ө л ч и р ә. Мин бик каты стресс кичердем. Мин дә үләсе идем. Уколлар белән генә алып калдылар. Ә син безне шул хәлдә калдырып качтың!

Г а з и н у р. Әйттем бит инде. Качмадым мин! Бергә яшәүнең мәгънәсе калмаганга, синең коточкыч кеше икән-легеңне аңлаганга киттем.

Р а й н у р. Ничек «коточкыч»?! Минем әни – фәрештә! Ул мине берүзе үстерде! Кеше итте! *(Торып басып, Газинурга кычкыра.)* Ә син! Миңа әти тиешле кеше! Син кайда идең мин үскәндә? Ишегалды малайлары мине «Казанская сирота» дип кыйнаганда, син кайда идең? Хәзер дә помню: бервакыт базарда йөргәндә бер сатучы хатынның алмаларына кызыктым. Берсе шундый кып-кызыл иде! Авыздан сулар килә... Озак басып торганмындыр, наверно. Анысын не помню! Помню сатучы хатынның: «Вор! Мальчишка – вор!» – дип акырып җибәргәнен... Помню, грузчикларның мине тотып алганнарын, с удовольствием кыйнаганнарын!.. Син кайда идең шул чакта?

Г ө л ч и р ә. Син миңа ник дөресен әйтмәдең, улым? Хәтерлим, син бит: «Таныш түгел малайлар кыйнады», – дидең.

Р а й н у р. А какая разница?! Син барыбер бернишли алмый идең.

Г ө л ч и р ә. Алма сатып алып биргән булыр идем.

Р а й н у р. Ул барыбер мин кызыккан алма булмас иде... И потом, мин бит дурак түгел. Синдә акчаның барлы-юклы гына икәнен чамалый идем. Кырык ямаулы чалбарымнан ничек туйганымны үзем генә беләм! Яңасын алмассыңмы дип, кайларга гына яшермәдем мин аны! Батарей артыннан да тартып чыгардың, шифоньер астыннан да табып алдың. Карават астында яткан киезката эченнән дә...

Г а з и н у р *(Гөлчирәгә)*. Мин бит алиментны вакытында җибәреп тордым. *(Райнурга.)* Кием-салым гына алырлык иде.

Г ө л ч и р ә. Җибәрдем, имеш! Суд аша койрыгыңнан тотып тормаган булсам, җибәрер идең микән?

Г а з и н у р. Нишләп җибәрмәскә! Ятимлекнең ни икәнен беләм мин. Үзем дә яшьли әтисез калган кеше. Минеке аянычрак та әле. Әти миңа теге дөньядан акча җибәреп тормады!

Г ө л ч и р ә. Бутама! Авыл ятиме белән шәһәр ятиме – икесе ике кеше. Аерма җир белән күк арасы!

Г а з и н у р. Алай аерма бик зур булгач, ник малайны авылга алып кайтып яшәмәдең соң? Кайтырга оялдыңмы? Әллә курыктыңмы?

Г ө л ч и р ә. Минме? Кемнән? Нәрсәдән? Әйт, авылга кайтып кеше күзенә күренмәслек нинди начарлык эшләдем мин?

Г а з и н у р. Анысын син үзең беләсеңдер инде...

Р а й н у р. Әй-әй! Кояштан тап эзләмә!

Г ө л ч и р ә. Җаны пычрак кеше башкалардан кер эзләр, диләр. Синә тач туры килә бу сүз!

Г а з и н у р. Ул сүзне кем әйтә бит әле! Анаңны кояшка ук тиңләп ялгышмыйсыңмы, Райнур? Дөрес, ул сине караган, үстергән... Үзең әйткәндәй, кеше иткән!.. Ләкин... Ләкин... Син белеп бетермәгән нәрсәләр дә бар әле...

Р а й н у р. Не темни!..

Г а з и н у р. Анаң да... кайбер нәрсәләрдән минем хәбәрдар икәнемне төшенеп җитми әле...

Г ө л ч и р ә *(сагаеп)*. Күзгә төтен җибәреп, ни сөйләгән буласың син?

Г а з и н у р. Төтен, дисең... Кайчандыр син үзең күзгә төтен җибәрдең...

Х ә д и ч ә. Төтен дә төтен, диләр... Тәмәке тарткан, тәмәке өргән кеше юк... Сез берәр нәрсә аңлыйсызмы соң?

Ф ә н н у р *(коры гына)*. Хәдичә! Тик кенә тор!

Х ә д и ч ә. Тик кенә торып булмый бит, аяклар арыды.

С ә р и я. Җиргә утыр, Хәдичә.

Х ә д и ч ә. Әстәгым, монысы да командовать иткән була... *(Башын читкә борып, әллә кая карагандай итә.)*

Г а з и н у р *(Илнурга карап алганнан соң, Гөлчирәгә)*. ДЦП дигән идеңме әле?

Гөлчирә дәшми.

Әйе, шулай дигән идең. Детский церебральный паралич, дигән идең. Син бусын алдамагансың. Врачлар, чыннан да, шундый диагноз куйганнар. Ә менә синең «бала үлде» диюең?!

Гөлчирә кинәт торып баса да кире урынына утыра.

Бусы коточкыч ялган булып чыкты! Ни йөрәгең белән әйтә алдың син аны?

Ф ә н ү с ә *(шаккатып)*. Бала исән булып чыктымыни?! *(Корсагын кадерләп сыйпап ала.)*

Р а й н у р. Син нәрсә? Ничек исән булсын! «Үлде» диде бит әни! *(Гөлчирәгә.)* Әни, шулай дидең бит?!

Гөлчирә дәшми.

Г а з и н у р *(Гөлчирәгә)*. Син үзең тудырган баладан!.. Исән балаңнан!.. Ваз кичкән кеше! Гөлчирә!

Г ө л ч и р ә. Мин... мин аны... ул баламны гомер буе эзләдем... Гомер буе!

Гөлчирә белән Илнурдан кала барысы да тораташ булып басып тора.
Күңелдәге авыр хисләрне көчәйтеп музыка яңгырый.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бала тудыру йорты. Баш табиб бүлмәсе. Бүлмәдә Б а ш т а б и б белән Г а з и н у р.

Б а ш т а б и б. Менә шундый хәлләр, иптәш... Шәйхи-ев!.. Сезнең хәбәрдар булмавыгыз, бернәрсә дә белмәвегез мине чын-чынлап гаҗәпкә

калдырды. Әйе, без дә әйттек хатыныгызга. Баланы калдыра аласыз, дидек. Ирегез белән киңәшегез, уйлашыгыз да конкрет бер фикергә килегез, дидек. Беренче балагыз сабый гына икәнен белгәнгә күрә дә шулай киңәш иттек. Фатирыбыз да юк, диде. Тулай торак тулай торак инде ул... Гаилә корып җибәргән чакта җан асрап торырга гына ярый. Хезмәт хакыгыз да аз икән. Андый акча белән сау-сәләмәт бала үстерүе дә, ай-һай, җиңелдән түгел, ә сезнең бала...

Г а з и н у р. Үз баламны үземә бирегез. Мин аны ничек тә карап үстерермен.

Б а ш т а б и б. Сез баланың ни дәрәҗәдә авыру икәнен беләсезме? Ул, күпме генә тәрбияләсәң дә, савыкмаска мөмкин.

Г а з и н у р. Нинди генә булса да, ул – минем балам! Минеке!

Ут сүнә. Кабат янган ут әүвәл Г ө л ч и р ә н е генә яктырта.

Г ө л ч и р ә. Син киттең... Без калдык... җанымны кая куярга белмим... бәргәләнәм... Баланы калдырып чыкканыма үкенәм... Роддомда калган шул балам турында уйлыйм... Төннәрем саташып уза... газапланам, янам... Шашар чиккә җиттем!.. Син ышанмыйсыңдыр инде... Түзәр әмәлем калмагач, кабат роддомга киттем... Соңга калдың, диделәр. Илереп, ялварып, тезләнеп сорадым кайдалыгын. Юк, әйтмәделәр. Хәтта акча да тәкъдим итеп карадым... Врачлар башларын гына чайкадылар... Ахыр чиктә: «Балагыз бездә юк! Бүтән берни дә әйтә алмыйбыз», – диделәр.

Язмыш каршында мин көчсез идем... Аңлашырга, сөй-ләшергә син юк... Яраланган, канатлары каерылган кош хәлендә калдым. Аңлыйсызмы?! Бәгырь кисәген – нарасыен югалткан кош хәлендә!.. Урамда, хастаханәдә берәр гарип бала күрсәм, йөрәгем жу итә. Шул чакта «Минем бала түгел микән бу?» дигән уй үзәкләремне өзеп ала иде. Гөнаһсыз сабыйның йөзеннән, күзләреннән сине, мине хәтерләткән таныш билгеләрне, охшаш чалымнарны эзлим... Ярый әле шундый чакларда Райнур юаныч булды... Райнур да булмаса... Белмим, мин бу сүзләрне сөйләп утыра алган булыр идем микән?..

Г а з и н у р. Матур сөйлисең, Гөлчирә. Сүзләрең кәнфит кебек. Үкенгән дә сыман үзең. Әйт әле миңа, бераз гына булса да яраттыңмы син мине?

Г ө л ч и р ә. Алдашудан хәзер ни файда? Соравыңа җа-вапны әйтмәсәм дә беләсең. Әйе, мин сине яратмадым! Беләм, син дә яратмадың мине!

Р а й н у р. Яратышмагач, нишләп өйләнештегез соң сез, чёрт побери?

Г а з и н у р. Мин җебегән булганга күрә! Миңа үз бәхетем, үз мәхәббәтем өчен көрәшергә кирәк булган да бит. Ялгыштым. Төзәтә алмаслык хата ясадым. Сөйгәнем өчен һичкайчан гафу итмәслек хата

булды ул! Бу – минем иң зур үкенечем! Үкенерлек гамәлләр кылма икән дөньяда. Соң аңладым мин моны.

Г ө л ч и р ә. Син ялгыштың, мин ялгыштым... Ялгышмыйча яшәгән кеше бар микән бу дөньяда?

Г а з и н у р. Хәзер синең шушы соравыңа гына бергәләп җавап эзлисе калды. Син үз ялгышың турында уйла! Үз ялгышың өчен җавап тот!

Г ө л ч и р ә. Кем алдында, синең алдыңдамы?!

Г а з и н у р. Синең эгоистлыгың минем тормышымны харап итте.

Г ө л ч и р ә. Алай икән, барысына да мин гаепле икән... Кешедән гаеп табу җиңел ул! Үзең соң, үзең! Нишләп үзеңне бер дә гаепле санамыйсың? Минем дә тормышым җимерелде бит!

Г а з и н у р. Әгәр син безнең арага кермәгән булсаң... Син сукыр түгел идең, безнең яратышканыбызны белеп, күреп тордың! Авылда бүтән егетләр дә бетмәгән иде югыйсә... Ю-ук! Сиңа сеңлең яраткан егет кирәк! Нишләп ул бәхетле булырга тиеш тә, син түгел! Шулай уйладың син. Мине ярату кирәк түгел иде сиңа. Ничек тә үзеңнеке итү генә кирәк иде. Иң тәмле ризык башта кемгә? Сиңа! Иң матур күлмәк кемгә? Сеңлеңә түгел, билгеле, сиңа! Бирмәсәләр, даулагансың, елап куркыткансың... Сабый чактан ук шулай булгансың син!

Г ө л ч и р ә. Каян беләсең син, бәлки, киресенчә булгандыр...

Г а з и н у р. «Мин! Миңа!! Минеке!!!» Барысы да син дигәнчә, син әйткәнчә булырга тиеш! Өйдәгеләреңне шуңа күнектергәнсең. Безнең кавышырга җыенуыбызны белгәч, ду килгәнсең. Арабызны бозу өчен безгә бер-беребез турында нахак сүзләр сөйләргә дә тайчанмагансың! Кызганыч, болар турында мин соңыннан гына белдем...

Ут сүнә.

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кабат янган ут шәһәрнең аулак бер аллеясын, андагы эскәмияләрне яктырта. Якында гына тимер юл вокзалы икәнлеген искәртеп, поезд кычкырткан тавыш ишетелеп ала. Икесе ике яктан чыккан Г а з и н у р белән Н ә ф и с ә, бер-берсен танып, үтеп киткәч кенә, кинәт тукталып калалар.

Г а з и н у р *(артына борылып)*. Нәфисә! Синме соң бу? Исәнме!

Н ә ф и с ә *(бермәл дәшми торганнан соң)*. Мин исән. Син дә исән икәнсең әле, Газинур...

Г а з и н у р. Күземә күренәсең мәллә дип торам...

Н ә ф и с ә *(барасы ягына карап)*. Электричкага ашыгам...

Г а з и н у р. Ничек соң хәлләрең, Нәфисә?!

Н ә ф и с ә. Шәһәрдә тынчу... Һавасы һава түгел... Авылдан киткәннәр ничек чыдыйдыр... Мин монда ярты көн дә тора алмыйм икән.

Г а з и н у р. Яши-яши иялэшәсең инде.

Н ә ф и с ә. Шәһәрдә күгәрченнәр юк, ахры. Берне дә күрмәдем дисәм... *(Газинурга карап ала.)*

Г а з и н у р. Нишләп булмасыннар!.. Базарда, көнбагыш сатучылар янында бик күп алар! Вокзал тирәсендә чутсыз! Көнбагышны бик яраталар инде...

Н ә ф и с ә *(китмәкче булып)*. Электричкага билет аласым бар... Оныта язганмын!..

Г а з и н у р. Ашыкмале, Нәфисә... Электричкалар күп йөри алар... Сөйләшик әле... Күрешмәгәнгә ничә ел бит! *(Бераз уйлана.)* Җиде елдан артып киткән инде...

Н ә ф и с ә. «Күк күгәрчен күктә уйный, күләгәсе җирдә уйный...» Кызык, шәһәр күгәрченнәре күктә уйный микән?

Г а з и н у р. Сәерләнгәнсең димме?! Ачуланма, зинһар, шулай дигәнгә. Мин синең хәлеңне сорыйм, син күгәрченнәр турында сөйлисең... Күгәрчен кайда да күгәрчен инде ул!

Н ә ф и с ә. Шәһәр күгәрченнәре авылныкылар шикелле җырлый белмидер әле...

Г а з и н у р. Нишләп белмәсеннәр! Авылдагы гөлдерү шәһәрдә дә гөлдерү инде ул! Карале, Нәфисә, ни... күгәрченнәрне онытып торыйк әле. Үзебез турында сөйләшик. Нишләп без...

Н ә ф и с ә. Соң инде аңлашырга, Газинур. Син безнең мәхәббәтебезгә хыянәт иттең, Газинур.

Г а з и н у р. Ничек мин? Киресенчә, син үзең мине... миңа... ну... мин армиядә чакта... Рәшит белән йөр-гәнсең...

Н ә ф и с ә. Рәшит белән? Кайчан? *(Нидер исенә төшереп.)* Аһ!.. Әйе шул... Аңлашылды...

Г а з и н у р. Нәрсә аңлашылды?

Н ә ф и с ә. Рәшит белән йөргәнем аңлашылды. *(Кинәт.)* Ни сөйлисең син, Газинур?

Г а з и н у р. Балага узган булгансың... төшерткәнсең...

Н ә ф и с ә. Ә? Мин киттем... *(Китә башлый.)*

Г а з и н у р. Дөрес сүзгә җавап юкмыни, Нәфисә?

Н ә ф и с ә. Кем әйтте сиңа бу сүзләрне? Син шуңа ышандыңмы?

Г а з и н у р. Апаң әйтте... Гөлчирә!

Н ә ф и с ә. Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Менә бит, ә?! Үзем дә белмичә Рәшит белән йөргәнмен. Рәшит... Рәшит... синнән балам була язган бит... Бер тапкыр клубтан бергә кайткан идек... Гөлчирәгә сүз ясарга шул җиткән икән. Рәхмәт, күземне ачтың. Синең хыянәтеңне дә кичерә алмаган идем. Инде бу сүзләрне дә ишеткәч... *(Китмәкче була.)*

Г а з и н у р *(Нәфисәне тотып)*. Туктале, Нәфисә... Минем нинди хыянәтем турында сөйлисең син?

Н ә ф и с ә. Оныткан булсаң, исеңә төшер... Исеңә төш-мәсә, Гөлчирәдән сора – ул әйтер...

Г а з и н у р. Гөлчирә?..

Н ә ф и с ә. Ул белә, ул әйтер сиңа...

Г а з и н у р. Нәрсә дип?

Н ә ф и с ә. Үзеңне белмичә, бер гаепсез, мескен Рәшит-кә, миңа яла яккан буласың... Мин синең сүзләреңә ышанып, очынып йөрдем. Бергә булуыбызны, бәхетле яшәвебезне күз алдына китереп, татлы хыялга бирелә идем. Ә син ике куянны бергә тотмакчы булгансың, Гөлчирәгә дә кызыккансың икән... Мине дә алдалап йөрткәнсең... Яратам, сөям, имеш!

Г а з и н у р. Ни сөйлисең син! Кызыкмадым мин Гөлчи-рәгә! Яратмадым да!

Н ә ф и с ә. Кызыкмагач, яратмагач... Ник өйләндең соң?

Г а з и н у р. Сине бит... Рәшит белән дип... Гөлчирә әйткәч... Сиңа үч итеп... Өйләндем инде!

Н ә ф и с ә. Шул гына микән? Ай-һай! Ник әйтмисең, койрыгым да бозга каткан иде, дип?

Г а з и н у р. Нинди койрык, нинди боз тагы?

Н ә ф и с ә. Өйләнешкәнче син Гөлчирә белән... Үзе әйтте... Корсакка уздым, диде...

Г а з и н у р. Ә?! Ёлки зелёные!.. *(Үз-үзен кая куяр-га белмичә, әрле-бирле йөренә.)* Ёлки зелёные! Бу бит... бу бит... Сүз табалмыйм әйтергә! Син... син шуңа ышандыңмы?

Н ә ф и с ә. Ышандым! Син дә ышангансың бит!

Г а з и н у р. Гөлчирәдән мин моны ук көтмәгән идем! Нишләп шул вакытта ук бу турыда әйтмәдең, Нәфисә? Аңлашкан булыр идек!

Н ә ф и с ә. Соң инде дип уйладым. Аннан соң, ашыктыгыз бит... Шәһәргә киткәнегезне мин белми дә калдым...

Г а з и н у р. Авылга кайткач та әйтмәдең. Гөлчирәне ташлап, синең янга дип кайткан идем бит югыйсә...

Н ә ф и с ә. Балагыз тугач, хак булган икән дип уйлап куйдым да... Бу турыда бүтән сүз кузгатып торуны кирәксенмәдем. Искене яңартудан ни файда? Аннары Гөлчирә артыңнан кайтты да... тагын китеп бардың...

Г а з и н у р. Бала, диде бит... Райнур авырый, диде. Авырмаган иде... Алдаган гына булган Гөлчирә. Безнең бергә булудан, кавышуыбыздан курыккан. Шуңа коты очкан булган. Ирен сеңлесе тартып алса, оят бит!

Н ә ф и с ә. Ә миңа, ул тартып алгач, шундый «рәхәт» булды! Нинди хәлдә калганымны үзем генә беләм! Әмма мин шул чакта да синең бәхетле булуыңны теләдем! Ходайдан ялварып сорадым...

Г а з и н у р. Күрәсең, догаң кабул булмаган, Нәфисә... Мин киттем инде Гөлчирәдән...

Н ә ф и с ә. Беләм, Газинур...

Г а з и н у р. Сиңа да кайталмадым...

Н ә ф и с ә. Икенче балагыз турында да ишеттем. Минем рәнҗеш төшкәндер дип ялгыш уйлый күрмә, Газинур. Мин рәнҗемәдем сиңа, Газинур! Дөрес, бик каты үпкәләдем анысы. Әмма рәнҗемәдем! Син бәхеткә лаек идең, Газинур!

Г а з и н у р. Син дә лаек идең, Нәфисә! Бәлки әле, соң түгелдер безгә...

Н ә ф и с ә. Соң инде, Газинур... Минем балам үсә! Мин ялгыз түгел инде...

Г а з и н у р. Бала?

Н ә ф и с ә *(Газинурга сынаулы караш ташлап)*. Әйе, балам бар...

Г а з и н у р. Димәк, Гөлчирә күпмедер хаклы булган икән...

Н ә ф и с ә. Кем хаклыдыр, Гөлчирәме, синме, минме... Хәзер бу минем өчен ул хәтле мөһим түгел. Иң мөһиме – син һаман да үзгәрмәгәнсең икән, Газинур! Һаман да элекке Газинур булып калгансың. Хуш, Газинур! *(Китә башлый.)*

Г а з и н у р. Нәфисә, мин озатам сине...

Н ә ф и с ә. Кирәкми, Газинур. Мин адашмыйча бара беләм инде хәзер... Хуш! *(Китә.)*

Нәфисәнең соңгы сүзләре кабат яңгырый: «Мин адашмыйча бара беләм инде хәзер... Хуш!»

Г а з и н у р. Нәфисә!

Газинур кайсы якка китәргә белмичә басып кала. Музыка.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә – Г а з и н у р, Г ө л ч и р ә, Ф ә н ү с ә, Ф ә н н у р, Х ә д и ч ә, И л н у р, С ә р и я. Барысы да бермәл тын калып тора. Газинур Илнур янына килә.

Г а з и н у р. Күгәрченне алып килергә оныттык бит! Илнур, улым, әллә кайтып алып киләсеңме? Буявы да кипкәндер инде...

Илнур, урыныннан кузгалып, һәммәсенә дә караш ташлап ала да бер сүз дәшмичә генә чыгып китә.

Г ө л ч и р ә *(аның артыннан карап калып)*. Бу егет бер дә сөйләшми, телен йоткан мәллә?

Газинур авызын ачып, нидер әйтергә җыенгач кына, Сәрия телгә килә.

С ә р и я. Ул... ул... телсез ул, Гөлчирә апа!

Г ө л ч и р ә. Шулаймыни?! И-и, бахыр, бигрәк сөйкемле егет үзе!..

Газинур, эчке бер ярсу белән, кинәт таганны атындырып җибәрә. Сәрия аны атындыруыннан туктата да утыргычка утыра.

С ә р и я. Атындырыгыз әле мине, Газинур абый!

Газинур таганга арты белән борыла.

Г ө л ч и р ә. Бая игътибар итмәгән идем... Син бу таганны уйлап ясагансың икән!.. Нәфисәне алып килеп атындырасың гына бар инде!..

Ф ә н н у р *(үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә ярсып кычкыра)*. Җитте! Туктагыз!

Барысы да сискәнеп, өнсез калып, Фәннурга карыйлар.

Х ә д и ч ә. Фәннур! Син нәрсә? Тынычлан әле!

Ф ә н н у р *(үзен кулга алып)*. Гафу итегез, мин сездән әнинең рухын рәнҗетмәвегезне сорыйм!

Г ө л ч и р ә. Монда синең әниеңнең нинди катнашы бар?

Х ә д и ч ә. Гөлчирә апа... Син әле телгә алган Нәфисә... безнең әниебез! Фәннурның әнисе!

Барысы да Хәдичә белән Фәннурга шаккатып карап тора.

Р а й н у р. Я уже ничего не понимаю!

Г ө л ч и р ә *(Фәннурга)*. Син... *(Урыныннан тормакчы була да кире утыра.)* Син... Нәфисәнең улымы?

Газинур бер-ике адым атлый да туктап кала.

Г а з и н у р *(Фәннурга текәлеп)*. Йа Хода! *(Йөрәген тота.)*

Райнур кесәсеннән дару алып, Фәнүсәгә суза.

Р а й н у р *(Газинурга ишарәләп, Фәнүсәгә)*. Мә, тизрәк бир аңа.

Фәнүсә беседка өстәлендәге шешәдән су агызып ала да Газинур янына килә.

Ф ә н ү с ә. Мәгез, Нургази абый... Газинур абый... йөрәк даруы бу! Су белән эчеп җибәрегез!

Р а й н у р. Йөрәк даруына су кирәк түгел... Аны тел астына гына куялар!..

Г а з и н у р *(даруны авызына кабып)*. Рәхмәт!..

Ф ә н н у р. Мин сезне... сине бик озын буйлы итеп күз алдыма китергән идем... Киң җилкәле итеп... Ә син бәләкәй кеше икәнсең!

Г а з и н у р. Яшь чакта озын идем мин!..

Х ә д и ч ә *(киеренкелекне җиңеләйтергә теләп)*. Хи-хи-хи!.. Мені таныштыгыз да! Хи-хи-хи!.. *(Фәннурның җитди карашын күреп.)* Уф!

*(Кулын, җилпәзә итеп, чырае тирәсендә селки.)* Чыдар әмәлләр юк бу эссегә!.. Мунча кебек пәрәме!

Г а з и н у р *(Фәннурга)*. Син Нәфисәнең улымыни? Хәл-ләре ничек әниеңнең?

Бер-берсенә текәлеп карап торалар.

Х ә д и ч ә. Ул, ул сезнең дә улыгыз! *(Фәннурга.)* Әллә ялгыш ычкындырдыммы?! *(Авызын учы белән каплый.)*

Фәннурдан, Хәдичәдән, Сәриядән кала барысы да шок хәлендә.

Г а з и н у р. Син минем улыммы? Ничек инде? Нәфисә миңа бу хакта берни дә әйтмәде...

Ф ә н н у р. Кирәк дип тапмаган, димәк!

Р а й н у р. Братья Комаровы, чёрт побери! Вот это сюрприз! Әни, син ник бер сүз дә әйтмисең? Язык проглотила что ли? Күрмисеңмени, минем родной брат нашёлся! Әле берсе дә юк иде... И вдруг эти!.. Брат!.. Радоваться надо! Но не могу!

Г ө л ч и р ә *(Газинурга зәһәр караш ташлап)*. Адәм тәганәсе! «Хәлләре ничек Нәфисәнең?» дип торган була, җитмәсә! Хәлен белгәнсең бит инде. Күрмисеңмени нәтиҗәсен?!

Ф ә н н у р. Мин сездән тагын бер кат үтенеп сорыйм, рәнҗетмәгез әнинең рухын!

Г а з и н у р. Рухын? Ул... Нәфисә... *(Башын тота.)*

Ф ә н н у р. Әйе...

Г а з и н у р. Кайчан?

Х ә д и ч ә. Кырыгын уздырдык инде... Күмгәндә бөтен авыл халкы җыелды...

Г а з и н у р *(үзалдына)*. Кичер, Нәфисә! Белмәдем... Кайталмадым... *(Күз яшьләрен сөртә.)*

С ә р и я *(урыныннан кузгалып, әле Газинурга, әле Гөлчирәгә карап)*. Әкәмәт кешеләр булып чыктыгыз әле сез, авылдашлар!

Гөлчирә дә, Газинур да аңа гаҗәпсенеп карый.

С ә р и я *(әле Газинур, әле Гөлчирә янына килеп)*. Без туган авылыбызга юлны бөтенләй оныттык түгелме соң? Синең дә, Газинур абый, синең дә, Гөлчирә апа, авылга әллә кайчаннан бирле кайтмаганыгыз аңлашылды. Сез авылдан ваз кичкәнсез бит! Бу миңа да кагыла... Минем дә байтактан кайтканым юк... Әни үлгәннән бирле. Йа Хода!.. Әти-әниләребез каберенә зиярәт кылып килүне дә онытып барабыз икән бит! Искә төшкәндә генә, шәһәр мәчетләренә кереп, муллаларга хәер биреп, үлгәннәр рухына дога укыткан булабыз да булуын... Ләкин... Минем ни әйтергә теләгәнемне аңлагансыздыр инде...

Сез: «Кем соң әле син шулхәтле акыл сатарга?» – дип уйлыйсыздыр... Сез хак-лы. Мин сезнең өчен беркем дә түгел. Бары авылдашыгыз гына... Бары Фатыйма кызы гына...

Г ө л ч и р ә
Г а з и н у р (икесе бергә). Кайсы Фатыйма кызы?

Гөлчирә белән Газинур бер-берсенә карашып алалар.

С ә р и я. Ходай безне монда тикмәгә генә бергә очраштырмаган, ахрысы... Фәннур белән Хәдичәне бүген күр-мәгән булсам, мин дә Нәфисә апаның вафаты хакында белмәгән булыр идем әле. Онытгык без авылны, оныттык андагы кешеләрне!.. Кем исән, кем юк – белмибез. Бары үз дөньябыз гына дөнья... Әйе, авылга кайтмау сәбәбен һәркем үзенчә аңлата ала. Сез «Сәбәбе тирәндә!» диярсез, ялгышыгызны сылтау итәрсез. Мин дә «Авылда туганнарым калмады, нигезебез таралды...» дип аклана алырмын. Без шулай үз-үзебезне юата алабыз анысы. Ләкин ничек кенә aклансак та, барыбер әллә кемнәр без!.. Нәфисә апа да, җанашым, китеп барган икән!.. Урыны җәннәттә булсын!.. Кичер мине, Фәннур! Кичер, Хәдичә! Кичерегез безне, авылдашлар!

Г ө л ч и р ә. Кыяфәтең генә түгел, сөйләшүең дә әниең төсле. Матур сөйлисең. Тик мин сиңа минем өчен сөйләргә кушмадым, сеңелкәем.

Г а з и н у р. Яшь кенә булса да, дөресен сөйли! Нигә, шулай түгелмени?!

Г ө л ч и р ә. Минем үз авызым бар. Нәрсә турында сөй-ләргә, кемнән кичерүен сорарга мин үзем белермен!.. Фатыйма кызының авылга кайтмавын мин гаепләп сөйләмим бит әле!

С ә р и я. Сез мине дөрес аңламадыгыз, Гөлчирә апа. Мин сезне гаепләргә җыенмыйм. Гаепләргә уйлаганым да юк. Сез күргәнне мин күрмәгән. Күрергә дә язмасын!..

И л н у р керә.

Г а з и н у р. Улым, алып килдеңме?

Илнур «әйе» дигәнне аңлатып баш кага. Гөлчирә, дерт итеп, Илнурны беренче күргәндәй текәлә. Илнур Газинурга күгәрченне бирә.

Г а з и н у р *(Райнур белән Фәнүсә янына килеп)*. Бу сезгә!

Райнур белән Фәнүсә, бер-берсенә карашып алып, нишләргә белмичә торалар.

Г ө л ч и р ә. Ул җансыз кош белән нишләсеннәр алар?

Г а з и н у р. Алыгыз, ал! Бу – сезгә, дөресрәге, туасы балагызга, оныкка.

Райнур башын читкә бора. Фәнүсә, читенсенеп кенә, күгәрченне ала.

Ф ә н ү с ә. Рәхмәт, Нур... Газинур абый!

Г ө л ч и р ә. Барысын да алдан уйлагансың икән! Хәер, Күгәрчен Сафа малаеннан ни көтәсең инде. Кушаматың ук кычкырып тора бит. Атаң, безнең өйне салганда, бөтен җирне күгәрченнәр белән чуарлап бетергән иде. Инде син монда күгәрченнәр тутыргансың!.. Үзеңчә, мине мыскыл итәргә теләвеңдер. Шуларны көн саен күреп, җаны газап-лансын, диюеңдер.

Г а з и н у р. Ничек аңласаң, шулай аңла. Әмма минем күңелемдә яман уйның булганы юк! Ә инде... «барысын да уйлагансың» диюеңдә күпмедер хаклык бар. Әйе. Ләкин мин уйлаганча гына килеп чыкмады. Хәтта... *(Фәннурга карап ала.)* Көтелмәгәнчә үк килеп чыкты. Бу минем генә түгел, Ходай эше дә, ахры. Шулай тиеш булган, димәк... Әйе, мин синең белән бүген очрашасымны белгән идем! Очрашмаган да булыр идем, әмма җитди сәбәп бар.

Р а й н у р. Чувствую, кажется безне тагын нindiдер сюрприз көтә!

Г а з и н у р. Минем әйтеп каласы сүзләрем бар.

Г ө л ч и р ә. Үләргә җыенмыйсыңдыр бит әле?.. Йөрәк дисәң... Кемнең авыртмый ул хәзер?! Мин дә көн саен дару эчеп кенә торам...

Р а й н у р. Әни, аз гына туктап тор, ә! Тыңлыйк. Сөй-ләсен...

Г а з и н у р. Дөнья хәлен белеп булмый. Үлеп китүем дә бар. *(Райнурга.)* Мин сезнең... Илнур белән икегезнең, юк, *(Фәннурга карый.)* өчегезнең бергә дус булуыгызны телим!

Р а й н у р. Без болай да почти дуслар. Әйе бит, Илнур?! Шулаймы, Фәннур?! Йә, шул гынамы? Мин нindiдер сюрприз көтәм тагы!

Г а з и н у р. Алай әйтергә яраса, сюрприз да бар! Ил-нур – сезнең энекәшегез! Илнур – синең бертуган энекәшең!

Көтелмәгән хәбәрдән Илнур белән Райнур, бер-берсенә карашып, ни әйтергә белмичә торалар. Илнур, беренче кат күргәндәй, Гөлчирәгә текәлә.

Г ө л ч и р ә *(шок хәлендә)*. Бертуган энекәше?!

Г а з и н у р *(Илнурга)*. Мин сиңа, әниең сине тапкан чагында роддомда үлде, дигән идем... Кичер мине, улым! Синең өчен шулай яхшырак булыр дип уйладым. Менә ул синең әниең!.. Ул исән!

Г ө л ч и р ә *(дулкынланып)*. Улы-ым! Балам!

И л н у р *(бер-ике адым атлый да туктапып)*. Ән-ни! *(Кинәт, ашкынып, Гөлчирәне кочаклап ала.)* Ән-ни-и!..

Тетрәндергеч мизгел.

С ә р и я *(бераздан)*. Хикмәт! Барыгызның да исемнәрендә «нур» бар... Гази-нур!.. Рай-нур!.. Фән-нур!.. *(Әнисен кочаклаган Илнур янына килеп, аның аркасыннан сыйпагандай итә.)* Ил-нур!..

Ф ә н ү с ә *(Райнурга)*. Син – бүген дөньяның иң бай кешесе, Райнур!

Р а й н у р *(бермәл учы белән күзләрен каплап тора да, учын кире алып)*. Кажется... әй-йе!.. *(Кулын Фәнүсәнең җилкәсенә сала.)*

Х ә д и ч ә *(Фәннурга)*. Син бер дә тирләми торганыең, Фәннур?! *(Фәннурның күлмәк кесәсеннән кулъяулык алып, аның маңгаен, күз төпләрен сөртә.)*

Ф ә н н у р. Кояш бит... Кыздыра!..

Газинур Райнур белән Фәнүсә янына килә.

Г а з и н у р *(Райнурга)*. «Бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте... Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне...» *(Икесенә дә карый.)* Яратышып яшәргә язсын сезгә! Берүк ялгышмагыз! Безнең язмыш сабак булсын... *(Райнурның иңсәсенә кулын куя.)* Кичералсаң, кичер, улым!..

Райнур Газинурны кочаклый. Бераздан Газинур, башын игән хәлдә, Фәннур белән Хәдичә янына килә.

Г а з и н у р *(Фәннурга)*. Мин белмәдем синең барлы-гыңны... *(Башын күтәрә.)* Синең алдыңда да гаебем зур минем! Әниең алдында да мин бик гаепле... Нишлим? Хаталарны төзәтергә соң инде. Миңа шундый язмыш насыйп булган, күрәсең. Тоташ үкенечләрдән, әрнүләрдән торган язмыш! Син дә кичер мине, улым!.. *(Фәннурны кочаклый.)* Син бәхетле булырга тиеш! *(Хәдичәгә карый.)* Сез бәхетле булырга тиеш! Арагызга берүк чит-ятларны кертмәгез! Аңлыйм. Сез минем үгет-нәсыйхәткә мохтаҗ түгел. Шулай да... Бәхетле булыгыз!

Музыка.

П ә р д ә.

*2005*

# КЫЧЫТКАН ЧЫПЧЫГЫ

*Ике пәрдәле моңсу комедия*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Г ө л с и н ә.
Р ә ү ф.
Ф и р а я.
А з а т.
Р ә ш и д ә.
С у к б а й.

## Б Е Р Е Н Ч Е  П Ә Р Д Ә

Шәһәр фатиры. Бүлмәдәге заманча җиһазларга карап, хуҗаларның бай тормыш алып баруын чамаларга мөмкин. Пәрдә ачылганда, бер почмакта, ноутбук янында, өстәл лампасы яктысында, Р ә ү ф утыра. Шактый зур савытлы бик матур гөл күтәреп, Г ө л с и н ә керә.

Г ө л с и н ә *(«АББА» җырын көйләп)*. Мани, мани, мани-и-и... Деньги гони-и-и... Аһа-а-а...Оһо-о-о... Менәтрәк! *(Гөлне өстәлгә куя.)* Бигрәкләр дә яратам инде шушы гөлне... *(Яфраклардагы тузанны сөрткәндәй итә, җырлый.)*

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгырькәем, мине күрде исә...

Хәерле көн, матуркаем, гөлкәем! Сагындым да инде үзеңне, бәгырькәем?! Хәзер, хәзер... *(Такмаклап көйли.)* Йөгереп чыктым бакчага, бастым алтын акчага... Гомер буе хезмәт итте-е-ем... Үзебезнең патшага... *(Сабагыннан тотып, кинәт гөлне савыттан чыгара.)* Менәтрәк! *(Савыт төбеннән ниндидер төргәк алып, йөрәгенә якын китерә.)* Исәнгенәмесез, җанкисәккәйләрем?

Р ә ү ф. Дурдом! Ычкынасың бугай инде.

Г ө л с и н ә. Җә инде, һаман-һаман чәпчемә! Утыр әле! Акча санаганны ярата ул! *(Төргәкне сүтә.)* Синең эшләгәнең ашарга да җитми, мин тапканны рәхәтләнеп санап була, ичмасам. *(Тәмләп, акча санарга керешә.)* Берәү, икәү, өчәү...

Р ә ү ф. Нәрсә, язуымны, рухи ризыгымны ташлап, синең белән бергә базарга чыгыйммыни инде?

Г ө л с и н ә. Синең ул язган-сызганың, синең ул рухи ризыгың духилык та акча бирә алмый... Сигез, тугыз, ун... Чык базарга! Чәпчергә вакытың калмас... Тугыз, ун... Ун булды түгелме соң инде?! Ялгыштырдың бит!

Р ә ү ф. Эһ, наданым!.. Наданым!.. Мин базарда чиләнер өчен тумаган!

Г ө л с и н ә. Биш, алты... Мин... мин... җиде, сигез... Эшлим бит әле... Тугыз, ун...

Р ә ү ф. Сиңа ярый... Син... *(Тукталып кала.)*

Г ө л с и н ә. «Син – җүләр!» дисеңме?! Көләргә булды-расың син... Петросян! Шамкай сыңары! Эш-мазар дисәң, ни теләгең, ни рәтең юк... Тугыз, ун...

Р ә ү ф. Сагынам Парижны! Дюма! Мопассан! Эйфель манарасы... Их, дөньясы!..

Г ө л с и н ә. Кит әле, ачуымны китереп тормале! Бер күрмәгән Парижны сагыналар димени, җүләр!

Кыңгырау тавышы яңгырый.

Бер тынгы юк. Тагын кем инде бу? *(Рәүфкә.)* Кая чабасың? Акчаны яшермәдем бит әле! *(Кабаланган вакытта бер кәгазь акчаны идәнгә төшерә.)* Булды бугай инде. Бар, ач ишекне! Уф, акчага карап ләззәтләнергә дә ирек бирмиләр...

Азат керә.

Азат. Ник озак ачмый торасыз? Качып кына акча санызйсыз мәллә?

Гөлсинә. И-хи-хи!.. Азат кергән икән! *(Читкә карап.)* Акча санаысыз мәллә, ди... Әүлия! Рәүф, исәнләшергә кайчан өйрәтәсең инде син бу баламутны?

Азат. Тел туздырып, һаман-һаман исәнләшеп тормыйлар инде, Гөлсинә апа! Рәүф абый белән кичә кич кенә исәнләштем. Шулай бит, Рәүф абый, әйеме?! Менә! Рәүф абый раслады. Синең белән дә, Гөлсинә апа, исәнләшкән идем өченчекөн!

Гөлсинә. Җүнләп исәнләшә дә белмисең, бүтән кертмим мин сине!

Азат. Кертмим дигәннән... Тыңлагыз, бер анекдот сөйлим... Ике бабайның кызлар янына аулак өйгә барышы икән. Берсе икенчесенә әйтә: «Баруын барабыз инде, кертмәсәләр нишләрбез?» – ди. Икенче бабай: «Кертмәсәләр кайтырбыз да китәрбез... Менә кертсәләр нишләрбез?!» – ди икән. Ха-ха-ха!..

Азатка кушылып, Рәүф тә көлә.

Гөлсинә. Алдан ук әйтеп куям: акча юк! Үзебез дә коргаксыдык. Ипи алырлык та рәт калмады. Бирмиләр бит, Азат җаным, вакытында түләми интектерәләр... И бу кемнәрне... нәчәлестеваны... хуҗаларны әйтәм... Кеше акчасыз ничек яшәргә тиештер...

Азат *(идәндәге акчаны күреп ала, күргәнен сиздерми)*. Мине әлегә... әлеге... бу акча дигәнең кызыксындырмый, Гөлсинә апа. Өйләнәм мин! Котлый аласыз. Туйдым буйдак тормышта-а-ан... Үзем генә беләм хәлкәйләремне!

Гөлсинә *(көлеп)*. Берүк өйләнә күрмә! Менә мин дә ашыгып өйләнгәнемә үкенеп бетә алмыйм...

Азат. Ә?! Әһә! Әйтсәң, каты әйтәсең дә инде, Гөлсинә апа...

Рәүф. Тыңлама син аны, Азат. Син мине тыңла. Менә мин...

Гөлсинә. Азат, кесәңдә кулъяулыгың юкмы? Сөртергә әзерлән Рәүф абыеңның күз яшьләрен... Мин бәхетсез дип, хәзер җылап җибәрәчәк. *(Такмаклый.)*

Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште, дип.
Рәүф абыең елый,
Авызкаем пеште, дип...

Рәүф. Менә, менә, күрдеңме инде, Азат? Өйләнмә. Өйләнсәң – бетәсең. Өйләнгәнче, син болай ит... Путёвка ал да Парижга барып кайт!

Өйләнгәч, Парижны түгел, Мамадышны да барып күрә алмаячаксың! Их, сагындым Парижны!

А з а т. Аңламадым, Рәүф абый... Ничек инде... *(Иҗекләп.)* Са-гын-дым, Па-риж-ны...

Г ө л с и н ә. Игътибар итмә Рәүф абыеңа. Вакыт-вакыт шулай тиле-милеләнеп ала ул. Кызың үзе beләме соң әле?

А з а т. Ә? Нәрсә?

Г ө л с и н ә. Кәбестә! Йөргән кызың үзе беләме, дим?

Р ә ү ф. Азатка – азатлык! Тыңлале... Париж турын-да минем дустым Марсель Галиев ни дип әйтә: «Париж – Европаның таҗы. Аны күргәч, күзгә яшь килде: соклanудан, их, без дә яшибез икән дигән нәүмизлектән...»

Г ө л с и н ә. Җитте инде, шамакайланма! Чистый бер французский Шамкай булдың!

А з а т. Өйләнәсе кызны мин кичә генә күрдем әле. Ну матур да инде! Искиткеч! Супер! Фәрештә! Нефертити кебек гүзәл!

Г ө л с и н ә. Ни... ни... нинди Кефир түти кебек?

А з а т. Син үзең Кефир түти! Борынгы Мисыр патшабикәсе ул Нефертити! Бик чибәр булган... Кичә мин күргән кыз шикелле!

Г ө л с и н ә. Аңлашылды. *(Шаярып.)* Кызыңның исеме ничек соң, Азат бәбкәм?

А з а т. Белмим әле, Гөлсинәттәй. Танышырга өлгермәдем.

Р ә ү ф. Мин беләм... Өйләнгәнче Сылу Гүзәлева да Сылу Фәрештәева... Өйләнгәч, барысының да исем-фамилиясе бер – Змея Иблисова!

А з а т. Көлмә, көлмә, Рәүф абый. Син күрсәң, үзең дә гашыйк булыр идең аңа! Во! М-м-ма!

Г ө л с и н ә *(Рәүфкә)*. Хәзер! Гашыйк булып кына карасын! Күр әле, күзләрен мутландырып, аяк өсте изри башлады. Оҗмахтагы хур кызлары кочагына кереп бара диярсең... Күрсәтермен мин сиңа матур кызларны! *(Азатка.)* Бар, бар, әллүр моннан! Телеңә салынып торма. Сыптыр! Җә тумаган тайның билен сындырырсың... Танышмаган-сөйләшмәгән үзе... Мужыт, сәвсим телсездер ул синең Ниффер титең?! Мужыт, күзләре кылыйдыр... *(Күзләрен кылыйландырып күрсәтә.)* Менә мондый булса, кереп качар тишек тапмыйча йөрерсең... Атлап йөргәнен күрдеңме? *(Титаклап күрсәтә.)* Мужыт, аксактыр ул? Өйләнәм, өйләнәм, имеш!

А з а т. Ышанмыйсыз мәллә?! Менә күрерсез әле!

Г ө л с и н ә. Туеңа чакырырга онытма. Бөтенесенә дә барабыз!

Р ә ү ф. Мин барысына да баралмам, ахры. Язасым бар! Туй мәҗлесләрендә фикерләрем чуалучан минем.

А з а т. Әй, сезнең шуткагыз! Бер генә мәртәбә өйләнәм мин, Алла теләсә!

Г ө л с и н ә. Чистый башны катырдың син безнең! Чыгып китәсеңме инде, юкмы? Элек шундый тыныч яшәп ята идек. Әллә каян күченеп

килдегез дә... Авыртмаган башка тимер тарак булдың тәки! Киләсең дә керәсең, киләсең дә керәсең... Керәсең дә акча сорыйсың... Син бит безнең уллыкка алган үги балабыз түгел!

А з а т. Ярый әле искә төшердең, Гөлсинә апа. *(Идәндәге акчага текәлә.)* Акча дигәннән... Акча сорар алдыннан бер анекдот. Бер ир хатынына әйтә икән: «Карале, безнең газиз улыбыз минем пыртманиттан акча чәлдергән бит!» Хатыны әйтә: «Нишләп улыбыз алган дип уйлыйсың? Бәлки, мин алганмындыр?!» – ди. Ире әйтә: «Юк, син алмагансың... Син тиененә чаклы кырып-себереп алган булыр идең. Ә монда бераз калган әле...» Ха-ха-ха!.. Гөлсинә апа, акча биреп тор инде.

Р ә ү ф. Биреп торыгыз инде, диген, агач тел!

А з а т. Әйе, биреп торыгыз инде... Идәнгә төшкән әнә шул акчагызны!

Г ө л с и н ә. Очлы күз булырсың икән! *(Җәһәт кенә акчаны алып, учына яшерә.)* Безнеке түгел ул! Монда ни... кем әле... шул кергәние... *(Рәүфкә.)* Әйт инде, син дә бар идең лә?!

Р ә ү ф. Әйттең бит үзең... Шул кергәние!

А з а т. Әртистләр дә инде сез, кадерле вә гыйззәтле күршекәйләр. Хәтта мине, татарның булачак Райкинын да уздырасыз!

Г ө л с и н ә. Нинди Райкин, нинди Райкин... Карт студент син! Мәңгелек студент! Син артист булганчы, татар театрлары ябылып бетмәгәе. Беләсеңме кем кергәние безгә? Рәшидә кергәние, вәйт! Уф! *(Иркен сулыш алып, акчаны халат кесәсенә тыга.)* Шул сорап керер, шуңа бирерсең әле, диде.

А з а т. Сорап кердем бит инде менә! Бирегез...

Г ө л с и н ә. Сиңа бирергә димәде ул. Кемгә әле...

А з а т. Рәшидәгәме?

Г ө л с и н ә. Әйе. Рәшидәгә. Туктале, Рәшидәгә түгел инде... Нишләп Рәшидә үз акчасын үзенә калдырсын!

А з а т. Аңлашылды, бирмисез инде?!

Р ә ү ф. Миндә юк. Булмагач – биралмыйм.

Г ө л с и н ә. Кеше акчасын биралмыйбыз шул, Азат энем.

А з а т. Алайса, биш ярым бәрәңге биреп торыгыз. Тагын полтора суган. Бер стакан тулар-тулмас сыек май да бирсәгез...

Г ө л с и н ә. Күптән шулай диләр аны. Тулар-тулмас! Баядан бирле – акча, акча... *(Аш бүлмәсе тарафына атлый.)* Кредит бирә торган банк түгел лә без...

А з а т. Әнинең авылга кайтып китүе бер дә минем файдага булмады әле, Рәүф абый. Акча җиткереп булмый, Гөлсинә апа җаным! Бер-ике... өч-дүрт телем ипи дә эләктер инде! Колбаса белән...

Г ө л с и н ә *(чыгып)*. Каклаган каз ите дә кирәкмиме?

А з а т. Әллә бармы? И-и-и... Каклаган каз итен үлепләр яратам инде мин! Рәхмәт инде, Гөлсинә апа. Күп кирәкми, ике лезвие калынлыгы җитә, җәме.

Г ө л с и н ә. Сиңа җитәдер дә... Ни бит... Ачуланма инде, Азат үскәнем. Кичә, бик каты эч әзләнгәч, сиңа гына дип саклап токтан каз итен, чәйнәп-чәйнәп, менә болай иттер-реп, суыр-рып-суыр-рып ашап бетердек.

Р ә ү ф. Җә инде, Гөлсинә, ашказанын котыртып сөйләмә. Аңын югалтып егыла бит хәзер Азат.

А з а т. Садистлар сез! Ярар, хәзергә болары да җитеп торыр... Икенче юлы кергәч, берәр тәмле әйбер бирерсез! Кара икра! Кызыл икра! Гөбәдия! Мантый! Алдан ук рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Үтерический шәп күршеләр сез! Болай булгач, ачтан үлмибез! Чыгып китәр алдыннан тагын бер анекдот. Психиатр кабинетына мүкәләп бер ир заты килеп керә. Авызына нидер капкан бу. Психиатр әйтә: «Ой, безгә мәче килгән түгелме соң?» – ди. Ир заты, бер сүз дә әйтмичә, почмакка таба мүкәли. Психиатр, аны күзәтә-күзәтә: «Ялгышканмын, маэмай икән ич бу!» – ди. Ир заты, бер сүз дәшмичә, икенче почмакка таба мүкәли. Психиатр, аңа текәлеп карап тора-тора да янә әйтеп куя: «Ә-ә, белдем-белдем, керпе икән бит син! Юк, ташбака!» – ди. Ир заты авызындагы электр үткәргеч чыбыкны кулына ала да болай ди: «Мужик, син миңа тыныч кына Интернет кертергә мөмкинлек бирәсеңме инде, юкмы?!» Ха-ха-ха!..

Г ө л с и н ә. Нәрсә, безгә психиатр кирәк дип төрттер-мәкчеме инде син?!

Р ә ү ф. Азатка – азык!

А з а т. Ә-әй... Кызык түгел сезнең белән! *(Чыгып китә.)*

Г ө л с и н ә. Азаттан гарык! Азат түгел бу – газап! *(Ке-сәсендәге акчасын башкалары янына куя.)* И-и, җанкисәккәйләрем, берегез күрше малаена чүт кенә корбан булмыйча калды. Акча сорап безгә керәләр димени, җүләр! Рәшидәдән сорарга кирәк иде сиңа. Үзе ялгыз, үзе бай! Ә без кем? Без кем, ә?

Р ә ү ф. Мескеннәр без, Гөлсинә, мескеннәр... Акча колына әйләнгән вак бәндәләр. Менә кем без!

Г ө л с и н ә. Әйдә, әйдә, акыллы сүзләр сөйләгән булып кылан. Каян килгән... кем әле... философ сыңары! Платон! Сократ! Домкрат!

Р ә ү ф. Домкрат түгел, Демокрит!

Г ө л с и н ә. Тагын кемнәр бар әле? Шопенгауэр! Кант!

Р ә ү ф. Ә син Плюшкин! Акча! Акча! Акча колына әйләнеп беттең инде. Шул акча дип, байлык артыннан куам дип... Туганнарың белән дә аралашмый башладың. Абыеңның, энеңнең хәлләрен белешмәгәнеңә дә ничә ел бардыр инде. Сеңлеңне дә, балдызны әйтәм, тәмам онытттың.

Г ө л с и н ә. Мин түгел, алар мине оныттылар. Оныт-салар тагы. Кирәкләре бер тиен! Алардан башка дөньяга килдем, алардан башка да яши алам, шөкер!

Р ә ү ф. Алай димә, алар синең якын туганнарың. Тормышта төрле чак була. Жәл, минем туганнарым юк. Алар булса, минем тормыш бөтенләй икенче төс алыр иде.

Г ө л с и н ә. Мин бар. Шул җитмимени сиңа? Мин синең атаң да, анаң да!

Р ә ү ф. Син бит минем туган түгел. Хатын гына бары! Гап-гади хатын! Үзең беләсең, без бербөтен түгел. Бәхетебезнең бер чите китек. Безне туган итә торган...

Г ө л с и н ә. Торасың да шулай дисең, торасың да шулай дисең...

Р ә ү ф. Бәлки, безгә аерылышыргадыр, ә?! Детдомнан бала алыйк, дидем... Кирәкми, дисең. Болай яшәп булмый бит инде. Һәрхәлдә, мин бүтән болай яши алмыйм. Яшәүнең кызыгы юк. Мәгънәсе бөтенләй калмады. Киләчәк турында уйлыйсы да килми хәтта. Инде кырыкны тутырып киләбез бит. Әле ярый язуым бар да, бердәнбер хыялым бар...

Г ө л с и н ә. Тагын шул Парижмы?

Р ә ү ф. Бала турында хыял...

Г ө л с и н ә. Бала, бала... Нишлим соң, Ходай Тәгалә бирмәгәч?! Бармаган врач, күренмәгән им-томчы калмады... «Гаилә үзәге»ннән дә хәбәр юк! Бәдбәхетләр! Аңа түккән акча...

Р ә ү ф. Тагын акча. Шул акча дип уйлаганга балабыз юк безнең. Инде мин ул «Гаилә үзәге»нә дә өметләнмим. Дөньядан тәмам читләштек. Матурлыкны күреп, тоеп яшәүдән мәхрүм булып гомер чигәбез. Кем әйтмешли, кырыктан соң – шырыкка... Ә яшисе килә адәмчә итеп, шайтан алгыры!

Г ө л с и н ә *(кинәт ярсып)*. Яшә! Бар, башканы тап! Кем сиңа комачаулый?! *(Үксергә тотына.)* И бәхетсез башкайларым...

Кыңгырау тавышы ишетелә. Рәүф ишек ачарга дип китә.

Г ө л с и н ә. Ачмый тор! *(Акчаны яшерә. Күз яшьләрен сөртә.)* Тагын кем йөри инде... Хәерсез! Ач хәзер!

Рәүфнең тавышы ишетелә: «О-о! Кем килгән безгә?! Кычыткан чыпчыгы! Кер әйдә, балдыз, уз түрдән! Как раз сине искә төшереп тора идек. Апаң күз яшьләрен түгеп утыра иде кадерле вә газиз туганнарын бик сагынып...»
Рәүфтән алда Ф и р а я күренә.

Ф и р а я *(көмәнле)*. Сәлам! Көтмәгән идегезме?

Г ө л с и н ә *(Фираяның корсагын күреп)*. Аба-ау! Полный пакет субцидии! Моңа «Гаилә үзәге» дә, акча да кирәкми. Базарга барып, карбыз йотып кайттың мәллә?

Ф и р а я *(кочаклашып күрешеп)*. Исәнме, апа! Нихәл, җизни? Уф, ардым! Расих абыйлардан килеш. Сезгә кү-ү-үп итеп сәлам тапшырырга куштылар. Расих абый суткалы эштә икән. Минем белән килалмады. Сезгә дигән күчтәнәчләрне җизни белән барып алырбыз инде. Име, җизни?! Абау, апа, ник җылыйсың? Җылама! Мине күрдем дигәч тә... И-и, сагынгансыздыр шул. Мин дә бик сагындым үзегезне!

Г ө л с и н ә. Җизнәң, аерылышабыз, ди.

Р ә ү ф. Егерме ел бергә торабыз, аерылышып булмый. Шуңа җылый.

Ф и р а я. Ничәнче тапкырын аерылышасыз инде сез, апа? Йөзгә тулдымы әле, җизни? И күңелледер ул аерылышабыз дип җылап яшәүләре! Кияүгә чыксам, мин дә сезнең кебек яшәр идем, Алла теләсә! Аерылышасың – кавышасың, аерылышасың – кочаклашасың... Идиллия!

Г ө л с и н ә. Ә сиңа кавышырга да, аерылышырга да кирәкми. Син, абау, ирсез бала табарга җыенасың мәллә?

Ф и р а я. Ә нигә?! Барыбер табак-савытны юасы бит әнигә! Кызык әйттемме? Минем сүзләр түгел. Бер балалар шагыйре шулай дип язган. Борчылма, апа. *(Көмәненә ишарәли.)* Моны төшерергә килдем мин!

Г ө л с и н ә. Нәрсә дип әтисез бала үстерергә...

Р ә ү ф. Син нәрсә, Фирая! Үз акылыңдамы син, кычыткан чыпчыгы?

Ф и р а я. Җизни! Мин кычыткан чыпчыгы түгел... *(Корсагын сыйпый.)* Мин хәзер сумкалы көнгерә! *(Көнгерә кебек сикергәләп йөри.)*

Р ә ү ф. Карале, көнгерә, зоопарктан качмагансыңдыр бит?!

Ф и р а я. Юк, цирктан качтым мин, җизни. Сез белмәгәч тә, безнең авыл циркка әйләнде бит хәзер. Алкаш клоуннар, жонглёр хатыннар, ләмдә йөзүче дуңгызлар күрәсегез килсә, безнең авылга кайтыгыз. Билет бәясе бушлай. Рәхим итегез! *(Кәнәфигә утыра.)* Эш юк, бәйрәм күп. Чәй урынына аракы... Диңгез тубыктан... Пир на весь мир!

Г ө л с и н ә. Әткәй-әнкәй булмагач, тәмам юлдан язгансың икән, сеңлем. *(Фираяның көмәненә ымлый.)* Атасы кем? Безнең авылныкымы? Мин беләмме ул кешене?

Ф и р а я. Син түгел, үзем дә белмим, апа. Караңгы иде. Әллә Касыйм, әллә Вәсим... Әллә урыс, әллә әрмән... Туктагыз әле, сорау яудырып тинтерәтмәгез! Ашарга бирәр нәрсә бирегез! Безнең ашыйсы килә!

Р ә ү ф. Карале, Фирая, әрмән дигәннән... Бездә әрмәннәр ашый торган ризык юк бит. Корсагыңдагы әрмәнчик, Ашотикны әйтәм, безнең токмачлы ашны яратыр микән? Бәлки, аңа шашлык белән коньяк кирәктер?!

Ф и р а я. Җизни, борчылма, ни бирсәгез, шуны ашыйбыз, шуны эчәбез. Талымлап тормыйбыз – үзбәк пылавын да яратабыз, грузин хачапуриен да сыптырабыз, украин салосыннан да баш тартмыйбыз. Урысның тозлы кәбестәсен урабыз гына! Мариның гөмбәсен, чуашның самагунын, башкортның балын...

Г ө л с и н ә. Гүләйт итеп тә карагансың икән, ыштыр бит! Авылга кайтырбыз дип кенә торадырыек... Кеше күзенә күренерлегем калмаган икән... Булсаң да булырсың икән адәм гыйбрәте! Дружба народов! Тфү!

Ф и р а я. Ашатасызмы сез кадерле туган-тумачагызны, әллә юкмы?

Р ә ү ф. Хәзер, балдыз. *(Фираяның корсагына карап елмая.)* Хәзер, хәзер, хөрмәтле вә гыйzzәтле төрле милләт вәкилләре. *(Аш бүлмәсенә китә.)*

Ф и р а я *(кычкырып)*. Кичәге аш булса да ярый!

Г ө л с и н ә. Кичәге ашны ашыйсың килсә, иртәгә килергә иде, дивана. Тибәме?

Ф и р а я. Кем?

Г ө л с и н ә. Балаң кыймыйлдыймы, дим?

Ф и р а я. Ә-ә, моны әйтәсең икән... Тибә. Кушаяклап тибә! Эчне тишеп, күлмәкне ертып чыкмаса ярый инде. Грузин булса, алар шундый халык... *(Лезгинка биеп ала.)* Ярар, булды. Цирк тәмам!

Г ө л с и н ә. Төшерәм дип ялгышмыйсыңмы, Фирая сеңлем?

Ф и р а я. Апа, атасына... аталарына кирәкмәгән бала белән кая барыйм мин? *(Тирә-ягына карый.)* Ярый сезнең бөтен җирегез җитеш. Минем бит шушы күлмәгемнән башка бүтән яңа киемем дә юк. Кышкы сапожки бар икән тагы! Җизни кухняга кереп батты. Иртән ашамаган иде мәллә?

Г ө л с и н ә. Рәүф! Газ плитәсен табалмыйсың мәллә, тинтәгем минем? Акылсызкаем!

Ф и р а я. Шундый яратып әйттең җизнигә. Рәхәтләнеп спектакль карармын дигән идем... Аерылышып уйнамыйсыз инде, болай булгач...

Г ө л с и н ә. Кем белә, кем белә...

Р ә ү ф тәлинкә күтәреп чыга.

Р ә ү ф. Бер Ходай белә! Микроволновкада җылыттым. У-ух, исе дә исе... Специфический!

Ф и р а я. Җизни, апа, ачуланмагыз инде. Миңа аш кәстрүле белән кирәк!

Г ө л с и н ә. Казаны белән түгелме?! Бу сиңа ресторан мәллә? Бездә әндри казнасы юк!

Р ә ү ф. Әйе шул, шул арада бөтенләй истән чыккан. Сез күбәү бит әле – бер ясле! *(Кире кереп китә.)*

Г ө л с и н ә. Фирая, акыл өйрәтергә җыенмыйм, име. Тагын бер кат уйла. Уйла, сеңлем!

Ф и р а я. Уйлыйсы уйланган инде, апа... Временное увлечение, кесерево сечение и... гуляй, Фираюшка! Пролетарий всех стран, соединяйтесь! Мама, чаю, мама, чаю, мама, чаю не хочу...

Г ө л с и н ә. Әллә нәрсәләр беләсең син, сеңлем.

Ф и р а я. Замана җимеше мин, апа, замана җимеше! Гламур кыз! Шундый сүз дә беләм әле мин!

Г ө л с и н ә. Гыламур... Корсаклы кыз дигән сүзме инде ул?

Ф и р а я. Безнеңчә тәти кыз була инде ул, апа. *(Урыныннан тора.)* Аш җылынганчы, әйләнеп керим әле. Мин хәзер. *(Чыгып китә.)*

Р ә ү ф *(аш бүлмәсеннән чыгып)*. Прошу к столу!

А з а т керә.

А з а т. Рәхмәт, рәхмәт! Әле генә ашаган идем. Сез бик кыстагач, тагын ашамый булмас.

Р ә ү ф. Туктале, күрше, сиңа түгел әле бу!

Г ө л с и н ә. Бар, бар, чык. Безнең бернәрсәбез дә юк! *(Азатны куа.)*

А з а т. Чыгам, чыгам... Карагыз әле, нәрсәгә кергән идем әле мин? Ярар, исемә төшкәч, тагын керермен... *(Чыга.)*

Р ә ү ф. Кая китте балдыз?

Г ө л с и н ә. Ашың да җитмәс бу гыламурга, акчаң да... Чыгып китте әле. Хәзер керәм, диде.

Р ә ү ф *(ишек тарафына карап)*. Да-а... Исәнме, кода-а! Авыл яшьләренә дә шәһәр чире йокты. Бетте авыл, бетерделәр! Пычракка батты дөньясы! Их, сагындым Парижны! Шундый сагындым!

Ф и р а я керә.

Ф и р а я. Тагын бер кат сәлам!

Р ә ү ф *(Гөлсинәгә)*. Менә, ичмасам, балдыз ике мәртәбә исәнләште. Азат түгел инде, әйеме?

Ф и р а я *(артына борылып)*. Заходи, дядя Коля! Заходи, гостем будешь. Тут все свои.

Тартынып кына С у к б а й керә. Гөлсинә авызын ачкан килеш катып кала. Рәүф тә шок хәлендә басып тора.

С у к б а й. Здрасте!

Ф и р а я. Дядя Коля, болар – минем бик якын кешеләрем! Таныш бул, бу – минем кадерле апам Гөлсинә, ә монысы – минем бик шәп җизнәм! Рәүф исемле. Ә бу, таныш булыгыз, дядя Коля. Мин Фирая булам инде, дядя Коля, бая әйткән идем бугай. Ашың җылындымы, җизни? Без ашарга әзер!

Г ө л с и н ә. Ме... ме... менәтрәк! Нишләвең бу, Фи... Фи... Фирая? *(Кашына башлый.)* Кемне алып кердең син? Бетләтеп үтерәсең бит безне!

Р ә ү ф. Балдыз... Кычыткан... чып... чып... *(Үзе дә сизмәстән кашына.)*

С у к б а й. Может, мне лучше уйти... Я потом зайду...

Ф и р а я. Дядя Коля! Потом суп с котом... Ашагач китәрсең! Сине куып чыгарган кеше юк монда. Шулай бит, җизни?! Име, апа?!

Г ө л с и н ә. Китәм, ди бит. Ник үтереп кыстыйсың кешене. Китсен!

А з а т керә.

А з а т. Тук, тук! Ишегегез ачык. *(Сукбайны күрә.)* Гөл-синә апа әйтмешли, менәтрәк! Кунакларыгыз бар икән. *(Рәүфкә.)* Туганнарыгыз мәллә, Рәүф абый?

Г ө л с и н ә. Әһә, туганнан туганнар. Әтиләр бер, бабай башка!

А з а т *(Сукбайга карап)*. Әтиегезмени? Исәнмесез, бабай! *(Күрешә.)* Ә бу матур кыз-хатынны кем дип белик? Исемең ничек синең, туташ-ханым?

Ф и р а я. Думбра! Сез дип сөйләш, дировня!

А з а т. Сез... исәнмесез, Думбра апа җаным? Исемегез бик оригиналь! Таныш булыйк: минеке – Барабан!

Р ә ү ф. Полный квартет. Азат, син нәрсәгә кердең?

А з а т. Ашарга! Матур гына сөйләшә идегез бугай, бүл-дердем, ахры?!

Г ө л с и н ә. Азат! *(Пауза.)* Акча юк!

А з а т. Кирәкми миңа акча. Миңа тоз кирәк! Бер кашык, чүмәкәем!

Г ө л с и н ә. Рәүф, биреп чыгар инде шуңа. Кабы белән тоттыр – ашасын туйганчы! Лавр яфракларын да бир!

Р ә ү ф. Анысы нигә тагы?

Г ө л с и н ә. Бүтән кереп йөдәтмәс өчен!

Р ә ү ф *(кухнядан җәһәт кенә әйләнеп чыгып)*. Мә! Башка вакытта иркенләп сөйләшербез, яме.

А з а т. Рәхмәт, Рәүф абый! Рәхмәт, Гөлсинә апа! Баегач кертермен. Чыгып киткәнче бер анекдот!

Г ө л с и н ә. Анекдот капчыгы булдың инде тәки... Җитте, сөйләмә!

Р ә ү ф. Сөйләсен инде әйдә. Яңадан тиз генә кермәс, бәлкем.

А з а т *(китешли, Фираяга)*. Карале, Мандолина, оша-дың син миңа... Гут бай, мерси мадам! Чао! *(Чыгып китә.)*

С у к б а й. Давайте-ка, я тоже уйду...

Р ә ү ф. Давай-давай... Әллүр иттек!

Ф и р а я. Нет! Апа! Җизни! Бу бит дядя Коля! Дя-дя Ко-ля бу!

Г ө л с и н ә. Сеңлем, чат саен алар – дядя Колялар, дядя Ванялар! Әйдә, ташы барысын да безнең өйгә! Сыйла, кунак ит! Урын иркен! Зал зур бетләр сугыштырырга... Баланың атасы да бу түгелдер бит?!

Ф и р а я. Ни булды сиңа, апа? Син элек мондый түгел идең! Минем кебек, сезнең кебек үк кеше бит ул дядя Коля!

Р ә ү ф. Әйдә ярар, ашасын инде.

А з а т керә. Нәрсәдер сорамакчы була, исенә төшерә алмый.

А з а т. Әй, оныттым. *(Чыгып китә.)*

С у к б а й. Дорогуша! Фираюшка! Может не надо...

Г ө л с и н ә. Дөрес! Не надо!

Ф и р а я. Дядя Коля, дим! Ашыксаң, әнә кресло, утырып садись! Сине мин кунакка чакырдым. Җизни аш җылытты безнең өчен. Шулай бит, җизни?! Минем апа ашны тәмле итеп пешерә белә ул! Әйдә, дядя Коля, мактап ашыйк әле апаның ашын.

Р ә ү ф. Апаң түгел, мин пешердем.

Ф и р а я. Ах, да, җизни пешергән!

С у к б а й. Как скажешь, как скажешь... Вообще-то, мне торопиться некуда... Так вкусно пахнет! А ложки у вас есть?

Р ә ү ф. Есть аш чүмече, то есть половник. Надо?

Г ө л с и н ә. Барыгыз җәтрәк кухняга! Башым әйләнә, күңелем болгана башлады...

Ф и р а я *(Гөлсинәне кочаклап алып)*. Апа җаным, син дә балага узмагансыңдыр бит?!

Г ө л с и н ә. Вон кухняга! Барыгыз, дим, кире уйлаганчы! Кулларыгызны юыгыз! Шуннан чыкмагыз!

Ф и р а я. И апам, кадерлем минем, бик зур рәхмәт сиңа, яме! Рәхмәт, җизни, сиңа да! Сезгә дип килә идем... Күрәм: ишегалдыгыздагы эскәмиядә дядя Коля моңаеп утыра. Дядя Коля икәнен белми идем әле очрашканчы. Исәнмесез, мин әйтәм... Мин ишегалдыгыздагы бөтен кеше белән дә исәнләштем үзе...

Р ә ү ф. Нәрсә, әле монда бөтен ишегалды да керәчәк мәллә?

Г ө л с и н ә. Фирая! Марш!

Ф и р а я. Аңладым, апа. Без инде ашый башладык. Әйдә, дядя Коля!

С у к б а й. Заранее большое спасибо вам! *(Аш бүлмәсенә кереп китешли.)* Благодарю. Мир этому дому. Всё у вас будет хорошо!

Р ә ү ф. Менә сиңа кычыткан чыпчыгы! Һава торышын үзгәртергә җыена бу, «дядя Коля» дип кенә тора, бертуган абыйсы диярсең!

Г ө л с и н ә. Сукбае чыгып киткәч, иманын укытам мин аның! Өйгә килеп керергә өлгермәде – хуҗа булып алды. Вредитель!..

А з а т керә.

А з а т. Исемә төште! Ни... Сезнең...

Г ө л с и н ә *(Азатның өстенә барып)*. Террорист!.. Колорадо жугы!..

А з а т. Әй, тагын онытТым! *(Чыгып тая.)*

Г ө л с и н ә. Безне бөлдерергә килгән... Ә син, туганнарың белән аралашмыйсың, дисең... Әнә күрдеңме берсен! Дәшми калсак, шәһәрдәге бөтен бомж хәзер безнең туганга әйләнәчәк!

Р ә ү ф. Дядя Коля димәктән... Чырае бер дә урысныкына охшамаган...

Г ө л с и н ә. Таптың сүз... Бомж бомж инде, аны урыска, татарга аерып карыйсы юк. Аларның барысының да чырае бер үк. Бомж бит ул «без определённого места жительства» дигәнне аңлата.

Р ә ү ф. Алай дип кистереп әйтмәс идем...

Г ө л с и н ә *(аш бүлмәсе ягына ишарәләп)*. Өеңдә бардак... Ә син фәлсәфә сатып торасың! Мә-га-нә-сез! Бар, лутчы теге Субсидиягә әйт, табак-савытларны өеп калдырмасын, әйбәтләп юып, сөртеп куйсын! Сукбаена ялгыш ышкыла күрмә, бете йогуы бар. Мин ышкылмаган килеш тә кычытына башладым инде.

Рәүф аш бүлмәсенә кереп китә.
Р ә ш и д ә керә.

Р ә ш и д ә. Сез нәрсә, әллә хәзер ишегегезне бикләмисезме? Шар ачык! Аяк киемнәрегезне караклар, бомжлар чәлдереп китмәсен.

Г ө л с и н ә. Без бомжлардан курыкмыйбыз. *(Аш бүлмәсе ягына карап, кычкырыбрак әйтә.)* Хәзер алар безгә туганнардан да кадерлерәк!

Р ә ш и д ә. Кунакларыгыз бар мәллә?

Г ө л с и н ә. Синнән бер дә кеше өзелми бит. Менә без дә калышмаска булдык әле.

Ф и р а я, С у к б а й һәм Р ә ү ф аш бүлмәсеннән чыга.

Р ә ш и д ә *(Сукбайны күреп, гаҗәпләнүе чиктән аша, чиркануы йөзенә чыгып читкә тайпыла)*. Ба! Приют ачтыгыз мәллә?!

Г ө л с и н ә. Ишетмәдеңмени, бүген бит Бөтендөнья сукбайлар көне! Бездән соң хәзер сиңа керәләр. Өстәлең әзерме?

Р ә ш и д ә. Бәй, Сукбайлар көне дә бармыни ул хәзер? Бер дә ишеткәнем юк иде.

С у к б а й *(күрешмәкче булып, Рәшидәгә кулларын сузып)*. Здрасте, мадам!

Р ә ш и д ә *(җирәнеп)*. Бик исән әле! Күрешеп тормыйк! Абзый, воздушный поцелуй гына, яме...

С у к б а й. Вы очень красивая женщина! У вас глаза доб-рые. И вообще, вы – прелесть! Я вас...

Г ө л с и н ә. Үзе бомж булса да, хатын-кызга комплиментлар әйтә белә, мәхлук! Она у нас ещё и добрая, и щедрая, и гостиприемная! И квартира у неё большая, и кастрюля... Ой, как она гостей любит! Рәшидә, чакыр инде кунакларны үзеңә! Без сыйладык, хәзер синең чират! Первый – бездән, второй – синнән!

Р ә ш и д ә. Бомжлар сыйлап ятасым гына калган иде... Аллам сакласын!

Ф и р а я. Сәлам, Рәшидә апа! Мине танымадың мәллә?

Р ә ш и д ә. Бәррәч! Фирая түгелме соң син? Котымны алдың! Мин бит сине дә бомж дип торам. Саумы, сеңлем? *(Көмәненә ишарәли.)* Кай арада өлгердең?

Ф и р а я. Күп сүз – чүп сүз, диләр безнең авылда, Рәшидә апа. Базарда тоттым да карбыз йоттым! Җизни! Кырыну приборларың кайда синең?

Р ә ү ф. Нәрсәләр дисең? Нәрсәне кырасыз тагы? Кайда дип, шунда инде – урынында, ваннада! Ә нигә?

Г ө л с и н ә. Әллә, Ходаем...

Ф и р а я. Әйдә, дядя Коля... Гламур егет ясыйбыз хәзер синнән.

С у к б а й *(кыенсынып)*. Может не надо. Утром только помылся.

Р ә ү ф. Минем бритва, минем «Жиллет»...

Р ә ш и д ә *(йөзен чытып)*. Юынгансыңдыр инде, әйе! Йөз кат юындырсаң да, кеше ясап булмый синнән. Гөлсинә, нәрсә карап торасың, кертмә моны ваннаңа!

Г ө л с и н ә *(Фирая белән Сукбайга каршы төшеп)*. А ну-ка, отойди! Только через мой труп! Фирая! Нишләвең бу?! Остановись! Тукта!

Р ә ш и д ә *(Гөлсинә янәшәсенә басып)*. Въезд запрещён! Тут шлагбаум! Дверь там, скатертью дорога.

С у к б а й. Да-а... Ничего не поделаешь... В России живем: куда не глянь, везде шлагбаумы. Спасибо за гости-приемство! Живите с Богом! Мир этому дому, всё у вас будет хорошо! И дети, и все... *(Акрын гына чигенә.)*

Ф и р а я. Апа! Рәшидә апа! Китегез әле юлдан! Шампунегез бармы, җизни?

А з а т керә.

А з а т. Шампунь дигәннән...

Р ә ү ф. Сиңа нинди шампунь кирәк, Фирая, майлы чәч өченме, әллә кавыклы чәч өченме?

А з а т. Шампунь дигәннән... Авыз чайкарга берәр стакан шампанскиегыз юкмы?

Р ә ш и д ә. Бар, бар! Боларда юк әйбер генә юк!

Г ө л с и н ә *(Азатка)*. Үтерәсең бит инде, теләнче тамак! Нету ничего, нету!

А з а т. Күкәегез генә бардыр әле... Күкәй дигәннән... Бер анекдот! СССР заманы... Бер авыл карты кибеткә килгән... «Кызым, миңа носки бир әле», – дигән ул сатучыга. «Күкәйгә генә бирәбез», – дигән сатучы кыз. «Ә миңа аякка кирәк иде шул!» – дигән карт... Ха-ха-ха!.. *(Чигенә-чигенә.)* Ярый, ярый алайса... Күкәйгә бераздан керермен... *(Чыгып китә.)*

Г ө л с и н ә. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорар, диләр... Шушы буладыр инде ул! *(Рәшидәгә.)* Син дә яхшатланып тормасана! Бомжны үзеңә алып кер дә юындыр! Без ашаттык, мунча кертү – синнән! С лёгким паром!

Ф и р а я. Сез ни сөйлисез, ә? Ни әйткәнегезне колагыгыз ишетәме? Безнең кебек үк кеше бит ул дядя Коля! Кемнәрнеңдер газиз баласы! Сездән, миннән аермасы шул: дядя Коля сугышта булган, михнәтләрне күп күргән! Ә сез... Их, әйтер идем инде...

Г ө л с и н ә. Кибет янындагы сугыштамы?! Ну и что! Ул нәрсә сөйләмәс! Сугыштан исән калган икән, шуңа сөенеп яшәсен. Сугышырга кем кушкан – шул ашатсын! Мин кушмадым...

Р ә ш и д ә. Дөрес әйттең, Гөлсинә. Яшәсен кешечә, яшәсен безнеңчә! Эшләсен! Ничу шакшыланып йөрергә! Таптылар бер кызык: эчәләр-эчәләр дә урамда яши башлыйлар... Рәхәт, бер кайгысы юк, уйларга кирәкми. Бог дал, Бог взял. Яшәү — байдан, үлем — Ходайдан!

Сукбай бүтәннәргә сиздермичә генә чыгып китә.

Ф и р а я. Сез, сез... Әллә кемнәр сез! Дядя Коля, әйдә, кыенсынып торма... Сугыштагы кебек батыр бул! *(Як-ягына карый, артка борыла.)* Дядя Коля-я-а-а!.. *(Көмәнен тотып чыгып йөгерә.)*

Ут сүнеп ала.
Шул ук бүлмә. Г ө л с и н ә белән Р ә ү ф.

Р ә ү ф *(эзләнеп)*. Син күрмәдеңме?

Г ө л с и н ә. Ни икәнен әйтеп сөйләш. Нәрсә эзләгәнеңне каян белим мин...

Р ә ү ф *(хатыны янына килеп)*. Бүре башын!

Г ө л с и н ә. Абау! Котымны алдың!

Р ә ү ф. Тукай сарыгы мин... Бүре башын эзлим. Бә-ә-ә-ә!

Г ө л с и н ә. Сарык икәнеңне беләдерием. Әмма Тукай сарыгы икәнеңне белмидерием моңарчы. Бүре башы белән нишлисең? Аш пешерәсең мәллә?

А з а т керә.

А з а т. Кеше котыртып, тагын ашау турында сөйләшәсезме?

Г ө л с и н ә. Аза-а-ат! Югал күз алдымнан!

А з а т. Хәлегезне белергә генә кергәнием... Кыстамагач, утырып тормыйм инде алайса... Берәр нәрсә кирәк булса, миңа да керегез. Тартынып, кыенсынып тормагыз. Мәрхүм бабай әйтмешли, бары – бергә, югы – уртак! *(Чыга.)*

Г ө л с и н ә. Геморройдан да хужы бу мөртәт!

Р ә ү ф. Гөлсинә! Уен-муен түгел... Пинжәкне күрмәдеңме? Бер сәгать буе табалмый интегәм бит инде. Чалбар да юк!

Г ө л с и н ә. Астыма кыстырып утырган идем менә. Каян белим! Башымны катырмале!.. *(Кинәт урыныннан сикереп тора.)* Стоп! Пинжәк, дисеңме?! Чалбарың да юкмы? Трусикларың урынындамы? Бар, кара!

Р ә ү ф *(кинәт башына сугып)*. Һоп-па! *(Ашыгып, күр-ше бүлмәгә кереп китә.)*

Г ө л с и н ә. Менә сиңа корсаклы Хәйрия фонды! Мать Тереза! Шуның гына эше бу! Чарасын күрмәсәк, таратып бетерәчәк бөтен әйберне...

Р ә ү ф *(кәгазь кисәге тотып.)* Послание из космоса! Галәмнән безгә хәбәр бар! *(Укый.)* «Җизни! Апа! Җизнинең кайбер киемнәрен алдым. Кем өчен икәнен әйтмим. Борчылмагыз, бурычлы булып калмам. Сезне яратып: Кычыткан чыпчыгы». Йә, ничек? Аңлашылдымы?

Г ө л с и н ә. И Ходаем! *(Кабаланып, күрше бүлмәгә кереп китә дә, гөл күтәреп, шундук кире чыга. Гөл төбеннән акчаны алып, тиз-тиз санарга керешә.)* Бер, ике, өч... Ярабби Ходаем!.. Дүрт, биш... *(Санап бетергәч, лып итеп урындыкка утыра. Паузадан соң.)* Исән! *(Башын өскә күтәрә.)* Рәхмәт, Ходаем! Яхшылыгыңны мәңге онытмам... *(Рәуфкә карый.)* Бу синең трусик-прусик кына түгел... Тагын саныйм әле! Берәү, икәү, өчәү... *(Иреннәре генә кыймылдый.)* Аллага шөкер, касса исән!

Р ә ү ф. Банкка салган булсак, бу хәтле өтәләнмәс идең!

Г ө л с и н ә. Яңа машинага җыябыз бит! Иртәгә дөлфәт дисәләр нишләрсең?!

Р ә ү ф. Дөлфәт түгел, дефолт!

Г ө л с и н ә. Беләм лә! Шул дефолт аркасында банкта ничә тапкыр акчабыз акырып янды. Болай, ичмасам, җан тыныч! Ул-бу килеп чыкса да, хет берәр нәрсә алып өлгерергә була... Уф, котым ботыма төште перәме! Ничек котылырга бу каламбур, галәмбур кызыйдан?

Р ә ү ф. Гламур кыз...

Г ө л с и н ә. Беләм лә! Сиңа әйтәм, әй, Тукай сарыгы! Башыңны эшләт бераз. Бетәбез бит!

Р ә ү ф. Карап, тыңлап торам да... тагын бер карап куям. Син бит кайчандыр үзең дә нәкъ Фирая кебек идең!

Г ө л с и н ә. Яшь чагында һәркем яшь була. Картайдыммыни хәзер? Нәрсәм ошамый?

Р ә ү ф. Яшең турында әйтмим лә! Кешелеклерәк идең син элек. Ярдәмчел идең. Хәтереңдәме, бер сәрхуш абзый машина астына чүт эләкми калгач, без аны, култыклап, өенә кадәр озатып куйдык. Мәтрүшкәле чәен дә эчтек әле. Чәй эчкәндә генә белдек: абзыйның хатынына бик катлаулы операция ясаганнар икән... Хатыны исән калу шатлыгыннан бер чүлли эчеп бетергән... Шул чакта башта син әйткән идең, әйдә, абзыйга булышыйк, дип... Идәннәрен дә юып йөрдең... Исеңдәме?! Күңелең матур булганга яраттым да инде мин сине...

Г ө л с и н ә. Яши-яши күңел ямьсезләнергә дә мөмкин. Тормыш үзгәртә ул кешене. *(Акчаны кабат гөл төбенә яшерә.)* Син дә бит элеккеге Рәүф түгел хәзер... Тукай сарыгы!.. *(Гөлне күтәреп, икенче бүлмәгә кереп китә.)*

Р ә ү ф *(ачуы килеп)*. Ә син, ә син шул сарыкның хатыны! Их, дөньясы!.. Башны кая куясы...

Кыңгырау тавышы. Рәүф ишеккә таба китә. Тынлык.

Г ө л с и н ә *(икенче бүлмәдән чыгып)*. Йә теге теләнче тамак бу, йә теге Хәйрия фонды... Тагын сукбаен ияртеп кайтмаса ярый инде...

Р ә ш и д ә керә.

Р ә ш и д ә. Төне буе төшемә кереп интектерүе җитмәгән, инде тагын ишегалдында очрады.

Р ә ү ф. Кем турында сүз бара, Рәшидә?

Р ә ш и д ә. Кем турында булсын инде – дед Мазай турында!

Г ө л с и н ә. Нинди дед Мазай?

Р ә ш и д ә. Теге... беркөнне сездә күргән бомж инде – дядя Коля! Фираяның сукбае! Текәлеп карап калды миңа, мин сиңайтим... Берәр тәңкә бирим мәллә дигәнием... Әй, мин әйтәм, бетмәс монда хәерчеләр. Атлаган саен бит алар хәзер. Бет шикелле бөтен җирне бастылар. Хөкүмәт тә шуларны берәр кая олактырмый, ичмасам! *(Үзе дә сизмәстән кашынып куя.)*

Г ө л с и н ә. Абау, Ходаем, әллә бет йоктыргансың инде?! Шатыр-шотыр кашына башладың. Бик селкенеп сөй-ләшмәле. Бетең идәнгә коелмасын тагы. Рәүф, дим, якын торма Рәшидәгә, читкәрәк кит!

Р ә ү ф. Сүзләреңне үлчәп сөйлә инде бераз. Безгә хәзер бет кенә җитмәгәние!

Р ә ш и д ә. Ие, ие! Аллам сакласын, диген! Ул арада бет йога димени? Мин бит ул ишегалды карачкысына терәлеп басып тормадым. Еракта́н ук күрдем дә, янынннан выжт итеп үттем дә киттем.

Г ө л с и н ә. Карале, Рәшидә, әллә йортка кертәсеңме үзен? Юындырасың, киендерәсең дә менә дигән кеше итәсең. Эт асраганчы...

Р ә ш и д ә. Эт асраганчы, бет асра, дисеңме әллә?

Р ә ү ф. Шәп фикер! Берьюлы ике куян атасың, Рәшидә... Җәмгыятькә дә файда, үзеңә дә!

Р ә ш и д ә. Миңа нинди файда?

Г ө л с и н ә. Бәй, ирле буласың!

Р ә ш и д ә. Сез нәрсә! Көлмәгез әле миннән. Фатирымны приют та, картлар йорты да итәргә җыенмыйм. Башыма тай типмәгән әле! Үзегез кертегез фатирга. Сугышта катнашкан ди бит, льготасы булыр!

Г ө л с и н ә. Безгә мать-одиночка да бик җиткән! *(Баш түбәсенә күрсәтә.)* Менә моннан льготасы!

А з а т керә. Хатын-кыз күкрәге төшерелгән алъяпкыч кигән.
Башында – повар башлыгы.

А з а т. Бик тәмле иттереп төче коймак пешермәкче идем. Он юклыгы исемә төште! Аптырагач, табада ит кыздырырга булдым. Ярты кило гына итегез юкмы? Сыер йә сарык ите булмаса, куян ите дә ярый. Алдан ук әйтеп куям: елан ите кирәкми!

Г ө л с и н ә. Саранча да болай ук куркыныч түгелдер, билләһи... Рәүф, китереп бир миңа чебен үтергечне. Бәреп үтерә-ә-әм мин моны!

А з а т. Нервы беткән бит синең, Гөлсинә апа... Сручны бүлнискә барып ят! Рәүф абый, сузмагыз... Кеше бүген бар ул, иртәгә юк дигәндәй...

Р ә ү ф. Азат, күрше булсаң, күрше бул... Бер ярты сәгать үзеңнән ял иттер безне, зинһар!

А з а т. Күрше хакы – Тәңре хакы, диләр... Аңладым! *(Чыгып китешли.)* Ярты сәгать, дидеңме әле?! Пока!

Г ө л с и н ә *(башын тотып)*. Ходаем, тыныч тормыш бир!

Р ә ш и д ә. Алай икән... Күршегез мут малай икән... Чәй эчеп тормыйм, кыстамагыз! Үзегез парлашып кич утырырга керегез. Бер кило көнбагыш алдым. Рәхәтләнеп идән чүпләрбез! Гәп сатарбыз. Таныш-белешләрне чәйнәп алырбыз.

Г ө л с и н ә. Чакыруыңа рәхмәт. Үзебезнең тузан суырткыч белән керикме?

Р ә ү ф. Мин кермим! Этеңнән куркам!

Р ә ш и д ә. Эттән курыкма син, кешедән курык! Ке-ше – иң куркыныч җан иясе! Эт нәрсә ул, эт эт инде. Сатана – друг человека!

Г ө л с и н ә. Алай димә! Кеше кешегә дус һәм иптәш! Кеше – җирнең чәчәге!

Р ә ү ф. Әйе, кеше чәчәк кебек: үзе кайда, исе дә шунда.

Р ә ш и д ә. Әллә тилерә башладыгыз инде? Сез тәмам диванага әйләнгәнче чыгып китим әле тизрәк! *(Чыгып китә.)*

Г ө л с и н ә. Уф! Туйдым бүген кешедән. Беркемне дә күрәсем килми.

Ф и р а я керә.

Ф и р а я. Мине дә күрәсең килмиме, апа?

Г ө л с и н ә. Сине дә.

Ф и р а я. Мин китсәм сагынырсың әле, апа. Сагынырсыз!

Г ө л с и н ә. Сагынасы килә башлады инде.

Р ә ү ф. Гөлсинә! Җүләр сатып утырма әле. Син нәрсә!

Ф и р а я. Җизни! Апа! Миндә бер яңалык бар: поликлиникада булдым, тагын бер тапкыр анализлар тапшырдым. Иртәгә минем язмыш хәл ителәчәк! *(Ашыгып, икенче бүлмәгә кереп китә.)*

Рәүф белән Гөлсинә, бер-берсенә карашып, Фирая кереп киткән бүлмәгә текәләләр.
Ут сүнә. Бераздан кабат яна.
Шул ук бүлмә күренеше.

Ф и р а я берьялгызы моңланып утыра. А з а т керә, сиздерми генә тыңлап тора.

Ф и р а я *(җырлый)*.

Бакчадагы гөлләремнең
Шау чәчәк аткан чагы.
Минем газиз башкаемның
Уйларга баткан чагы...

Йөгерә-йөгерә бара идем
Хыялым каршысына.
Ничекләр генә түзәем
Язмышым ачысына.

Бакчамдагы гөлләремнең
Шиңә бит чәчкәләре.
Мөлдерәмә күзләремнән
Ага бит яшькәйләрем...

Йөгерә-йөгерә бара идем
Хыялым каршысына.
Ничекләр генә түзәем
Язмышым ачысына...

И Ходаем, сабырлыклар бир миңа! *(Куллары белән йөзен каплый.)*

А з а т. Тук-тук! *(Кыңгырау төймәсенә баскандай итә.)* Челтер-пелтер! Ишек ачык икән... Бигрәк матур итеп җырладың, туташ... ханым... Күптән мондый җыр тыңлаган юк иде!

Ф и р а я *(күз яшьләрен сөртеп, кинәт шат күңеллегә әйләнә)*. Сәлам, Барабан! Шикәр кирәкме, борычмы? Әйдә, варенье белән сыйлыйм үзеңне!

А з а т. Шикәр кирәкми, борыч ашамыйм... Мин Карлсон түгел. Вареньега исем китми. Миңа син кирәк!

Ф и р а я *(көмәненә ишарәләп)*. Без икәү бит!

А з а т. Миңа димәгәе! Хет өчәү бул! Корсагыңа караганда, бер көтү булмагае әле!

Ф и р а я. Шаккатасы юк. Безнең нәселдә була торган хәл. Әтинең апасының кызы берьюлы өч бала тапты.

А з а т. Әтиеңнең апасының кызының өч баласының этиләренә миннән кайнар сәлам тапшыра тор! Туйда әйбәтләп таныштырырсың...

Ф и р а я. Нинди туйда?

А з а т. Безнең... синең белән минем туйда!

Ф и р а я. Барабан булса да булырсың икән!

Шулвакыт телефон шалтырый.

Ф и р а я *(трубканы алып)*. Алло! Әйе! Әйе... Әйе... Ничә сум кирәк дисез? Ничә мең? *(Трубканы кулыннан төшереп җибәрә яза.)* Шулхәтле үк кирәкмени?! Рәх... рәхмәт сезгә! *(Трубканы куя, башын тотып лып итеп утыра.)* Андый акчаны мин каян табыйм?

А з а т. Кем ул? Нинди акча турында сөйләштең син?

Ф и р а я. Ә... юк... ни бу... *(Үзен бик тиз кулга ала.)* Карале, күп белмә – тиз картаерсың!

А з а т. Картаясы килә бит! Туйдым перспективасыз яшьлегемнән! Әни һаман авылдан кайтмый. Стипендия пачти көнендә бетә.

Ф и р а я. Эшләргә кирәк, эшләргә! Хезмәт кешене бизи, диләрме әле?!

А з а т. Бизи... Ике җирдә эшлим инде, барыбер җитми.

Ф и р а я. Убыр кебек ашыйсың, ызначит... Диета тот!

А з а т. Болай да диетада инде. *(Пауза.)* Чык үземә кияүгә! Ошыйсың син миңа. Матур итеп яшәрбез! Балаңны бергәләп үстерербез!

Ф и р а я. Стоп, стоп... Тукта! Йөргән кызың юкмыни соң?

А з а т. Сиңа охшаган берәү бар барын... Читтән генә яратып йөрим мин аны.

Ф и р а я. Заочно, димәк. Кыюсызланып йөрмә. Беләсеңме, сандугач белән сыерчык бер-берсеннән шулхәтле аерылып тора. Тәк шту мәхәббәтеңне аңлат та менә шул кызга өйлән!

А з а т. Кызларга бай егет кирәк шул аларга! Машинасы булсын, акчасы чишмә кебек ташып торсын... Минем нәрсәм бар? Фатир бар да

инде... Кешелеккә кия торган кәчтүм-чалбар бар дигәндәй... Пачти һөнәрем бар... Иң мөһиме – мәхәббәткә тугры йөрәгем бар!

Ф и р а я. Мин менә байлыкка карамас идем...

Г ө л с и н ә белән Р ә ү ф керә.

Г ө л с и н ә. Без кайттык! *(Азатны күреп.)* Менәтрәк! Һо-һо! Теле-теле-тесто, кияү һәм невеста! Бездән чыкканың юк... Тәки өйләнергә йөрисең бугай син, Азат?!

А з а т. Тәкъдим ясаган идем... Менә сез вакытсыз кайтып мишәйт иттегез.

Р ә ү ф. Аңа сиңа кадәр мишәйт иткәннәр инде... Әрмәннәр!..

А з а т. Әрмәннәр дигәннән... Бер анекдот! Урыс, грузин, әрмән бер самолётта очып баралар икән. Грузия өстеннән очканда, грузин: «Безнең кызлар чәчәк ярата!» – дип, чәчәкләр сибә. Әрмәнстан өстеннән очканда, әрмән: «Безнең кызлар акча ярата!» – дип, кәгазь акчалар чәчә. Рәсәй өстеннән очканда, урыс: «Безнең кызлар сезне ярата!» – дип, тегеләрне самолёттан тибеп төшерә... Ха-ха-ха!..

Р ә ү ф. Бaҗай, афәрин! Давай, тимерне кызуында сук! Фирая, уйлап торма, ризалаш! Мондый шәп егетне бүтән беркайдан да табалмыйсың.

Ф и р а я. Үтерепләр кыстады инде, уйлап карыйсы булыр!

Г ө л с и н ә. Нәрсә уйлап торырга... Ишекне алып кына куярга кирәк. Азат барыбер гел бездә!

А з а т. Алай димә, Гөлсинә апа, менә бит чыгып барам. Фирая, уен-муен түгел, мин чынлап әйттем. Уйла, яме! *(Чыгып китә.)*

Г ө л с и н ә. Акчасы булмаса да, чиста күңелле егет!

Р ә ү ф. Баҗайлыкка кандидатлар арасында Азат – беренче! Сомнений быть не может!

Ф и р а я. Ташлагыз әле шул шаяруыгызны! Минем үз хәлем хәл!

Г ө л с и н ә. Аңлыйбыз, сеңлем, сукырлар түгел – күреп торабыз! Безнең сиңа бик җитди сүзебез бар.

Р ә ү ф. Утыр әле, Фирая!

Утырышалар.

Г ө л с и н ә. Сеңлем, ничек аңлатыйм икән...

Р ә ү ф. Аңлатып торма. Балдыз сабый бала түгел. Тот та әйт!

Г ө л с и н ә. Сеңлем... Төшермә син балаңны... Тап!

Ф и р а я. Апа...

Р ә ү ф. Тап та...

Г ө л с и н ә. Безгә бир!

Ф и р а я *(сикереп торып)*. Сез ни сөйлисез, апа? Җизни?

Р ә ү ф. Без күп уйладык. Үзең белеп, күреп торасың... балабыз юк.

Г ө л с и н ә. Бир безгә балаңны, сеңлем!

Ф и р а я. Апа! Туктале!

Г ө л с и н ә. Син яшь әле. Тагын табарсың! Аңла инде, хәлебезгә кер... Бу бала безгә бик кирәк!

Р ә ү ф . Баласыз тормыш тормыш түгел ул. Бөтен ягыбыз җитеш. Бала гына юк! Фирая, балдыз...

Г ө л с и н ә *(ялварып)*. Сеңлем...

Ф и р а я. Апа! Җизни! *(Өзгәләнеп.)* Сез уйлаганча гына булса икән ул! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Музыка.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Беренче пәрдәдәге күренеш.*

Кыңгырау шалтырый. Бераздан С у к б а й керә,
кулында пакет-сумка.

С у к б а й. Здрасте! *(Түр ишеккә таба бара.)* Хозяева!

Шикле кеше кебек, анда-монда каранып торганда, А з а т керә.
Сукбай аны күрми.

А з а т. Әһә! Эләктеңме, карак? *(Сукбайга ташлана.)* Нәрсә урладың?

Икәүләшеп әүмәкләшә башлыйлар.

С у к б а й. Послушай, брат...

А з а т *(Сукбайның аркасына асылынып)*. Кем брат? Бомж тебе брат! Заткнись! Сейчас получишь, карак!

С у к б а й. Друг, товарищ, отстань, а! Сейчас всё объясню...

А з а т. Бур син! Нинди дус булыйм мин сиңа! Хәзер милициягә тапшырам!

С у к б а й. Ну что ж... Если так не понимаешь... *(Кинәт Азатны идәнгә егып сала, аның кулын каера.)*

А з а т. А-а-а... авырттырасың бит, бандит... Җибәр кулны!

С у к б а й. Тихо! Будешь меня слушать?

А з а т. Сындырасың бит кулны... Җибәр, дим! Буду, буду!

С у к б а й. Молодец, холодец! *(Азатның кулын ычкындыра.)* Запомни навсегда: я – не вор!

А з а т *(кулларын угалап)*. Карак булмагач, ник керәсең чит кеше фатирына? Күрмисеңмени, хуҗалары өйдә юк! Күрсәт, нәрсә ул сумкаңда? *(Идәндә яткан сумканы алып, аннан пиджак белән чалбар тартып чыгара.)* Бу бит... бу бит Рәүф абыйның киемнәре! Карак түгел, дип торган буласың... Урлагансың бит!

С у к б а й. Воруют ночью, днём берут! Урламадым мин аны...

А з а т. Ха! Татарча сайрый башлады! Безнеңчә дә сөйләшә беләсең икән!

С у к б а й. Белмәскә! Татар бит мин!

А з а т. Нишләмәкче идең Рәүф абыйның киемнәрен урлап?

С у к б а й. Слушай, җегет, һаман бер сүз чәйнисең дә бит... Син үзеңнең хәзер нинди ситуациядә калганыңны беләсеңме?

А з а т. Нинди ситуация? Нәрсә сөйлисең син?

С у к б а й. Хәзер аңларсың. Кайда монда телефон? *(Җәһәт кенә телефон янына барып, трубканы кулына ала, сөйләшкән булып кылана.)* Алло, милиция! Мин монда карак тоттым!

А з а т. Кем карак? Син нәрсә!

С у к б а й. Кулыңда кемнең киемнәре ул? Үзеңнекеме? Түгел! *(Трубкага.)* Дежурный!

А з а т *(каушый төшеп)*. Бомж... абый... Абзыкаем, туктале! *(Телефонга килеп тотына.)* Мин урламадым... Син нәрсә! *(Киемнәрне идәнгә ташлый.)*

С у к б а й. Каптың син, бырат! Киемнәрдә бармак эзләрең калды... Ничек диләр әле, все улики против вас, гражданин подсудимый!

А з а т. Мин сине прастуй бомж дип кенә белә идем... Хәйләкәр, юк, бик явыз бомж булып чыктың әле... Аферист икән бит син! Авантюрист!

С у к б а й *(катгый итеп)*. Утыр! Тыңла! Тышкы кыяфәтенә генә карап, кешегә бәя бирергә беркайчан да ашыкма. Менә син мине бомж дип атадың... Карак, дип тә әйттең... Бәлки, мин миллионердыр? Син каян беләсең минем акча юклыкны? Минем хәер сорашканымны, теләнгәнемне күргәнең бармы?

А з а т. Юк.

С у к б а й. Шулай булгач, сүзләреңне уйлабрак әйт. Бомж бомж инде ул – хәер эстәүче, дисеңдер... Ләкин минем беркайчан да акча теләнгәнем булмады. Гарип-гораба түгел мин, тилемсә дә түгел, Аллага шөкер!

А з а т. Нишләп мондый хәлгә төштең соң, абзый?

С у к б а й. Үзем төшмәдем мин, бырат... *(Бармагын өскә чөеп.)* Төртеп төшерүчеләр булды. Әйт әле, син гәзит-мазар укыйсыңмы?

А з а т. «Сәхнә» журналын укыштыргалыйм шунда... Татарның атаклы артисты Азат Әфләтунов турында, ягъни минем турыда да үтереп мактап язмадылар микән дип кенә...

С у к б а й. Утыр. Тыңла. *(Кесәсеннән газета чыгара.)* Ә мин көн саен укыйм. Менә кара, гәзит тышына ат башы чаклы хәрефләр белән ни дип язганнар? «Сукбайлар белән ничек көрәшергә?» дигәннәр! Әйтерсең нindidер бер бандит мин! Сукбайлар белән түгел, аларны шундый юлга этәргән сәбәпләр белән көрәшергә кирәк. Син дә кеше, мин дә кеше... Без барыбыз да кешеләр! Күккә карап, йолдыз санап кына яшәмә син, дускай... Атлаган чакта аяк астыңа да иелеп кара – анда да җанлы тормыш бара... Аңлаталдыммы, быр-рат?

А з а т. Бу пинжәк, бу чалбар... Рәүф абыйның киемнәре сезнең кулга ничек килеп керде? Шуны гына аңлый алмый торам...

С у к б а й. Ә-ә-ә... боларны әйтәсеңме?.. *(Киемнәрне пөхтәләп төрә дә кире сумка эченә тыга.)* Боларны миңа Фирая... син беләсең бугай Фираяны, киярсең дип биргән иде. Җизнәсеннән алып торган булган. Фираяның күңеле саф, рәхмәт аңа. Нияте изге булса да, мин боларны киялмыйм. Мин – ир кеше. Мин аякта басып торам. Тормыш төбенә төшеп яшәсәм дә, горурлыгымны югалтмадым әле мин. Шуңа кире китердем мин бу киемнәрне. Фираяны да бик күрәсем килгән иде...

А з а т *(урыныннан сикереп торып)*. Менә хәзер аңлашылды! Сиңа Фирая кирәк икән. Күзең төштеме? Белеп тор: мин аны сиңа бирмим! Фирая – минеке. Минеке генә булачак!

С у к б а й. Әтәчләнмә, җегет!

Күрше бүлмәдә тавышлар ишетелә. Г ө л с и н ә белән Р ә ш и д ә күренә.

Р ә ш и д ә. Балконыгыз бик матур булган. Мин дә шулай эшләтәм! Осталарның телефон номерын бирерсең әле, яме?

Г ө л с и н ә. Бирермен, бирермен... *(Азат белән Сукбайны күреп.)* Йа Хода! Балконга да чыгар хәл юк, шантрапалар шундук өйне басып ала. Нишлисез монда? Азат, сиңа әйтәм?! Тагын теге бомж!

Р ә ш и д ә. Ишегеңне бикләргә кирәк иде, Гөлсинә. Проходной дворга әйләнгән бит фатирыгыз!

С у к б а й. Здрасте! Извините...

А з а т. Гөлсинә апа, хәзер аңлатам...

Г ө л с и н ә. Кирәкми миңа синең аңлатуың... Барыгыз, икегез дә аттырыгыз моннан! Әллә бездә әндри казнасы бар дип белдегезме? Югалыгыз күз алдымнан!

А з а т. Аңладым. Мин... мин... югалам... *(Чыгып китә.)*

С у к б а й. Ещё раз здрасте! Не скажете, как мне найти Фираю? Бик кирәк иде!

Г ө л с и н ә. Күзең чыкмагандыр бит. Юк монда Фирая. Әттәч-бәттәч! Әллә татарча да белә инде?!

Р ә ш и д ә. Нишләп сөйләшмәсен! Үзебезнең Татарстаныбыз сукбае бит ул! Син шуны әйт, хәзер ничек куып чыгарабыз бу җан көеген?

С у к б а й. Мин сезне беләм! Вас Рашидой зовут. Так ведь?!

Р ә ш и д ә *(мыскыллы елмаеп)*. Мине белүеңнән би-и-ик үсенеп, очынып киттем инде менә, өтәләнгән үрдәккәем! Перәме летаю менә! Высоко-высоко летаю! Гөлсинә, дим, ник дәшмисең? Отвечай! Куып чыгар бу имгәкне!

С у к б а й. Вы о чём? О чём речь, дорогуша моя?

Р ә ш и д ә. Дорогуш мой, иманыңны укытканчы отвались, яме?! Гөлсинә, дим! Куып чыгар җәтрәк!

Г ө л с и н ә. Иди, иди... До свидание! *(Рәшидәгә.)* Каты әйттемме?

Р ә ш и д ә. Тагы да каты итеп әйт! Бүтән кермәслек булсын!

С у к б а й *(урыныннан торып, кулындагы сумканы Гөл-синәгә сузып)*. Передайте Фирае вот это, пожалуйста. Пожалуйста!

Р ә ш и д ә. Ала күрмә берүк! Бомба булмасын тагы!

С у к б а й. Не бойтесь, это не бомба, Рашида җаным. *(Сумканы кәнәфигә куя.)*

Р ә ш и д ә. Җаным, дип торган була тагы... Хәчтерүш! Много болтаешь, давай, отчаливай по хорошему! А то милицию вызывем!

Г ө л с и н ә. Точно! Нишләп башта ук әйтмәдең аны. Хәзер позвоним! *(Телефонга таба бара.)*

С у к б а й. Подождите! Я сейчас уйду.

Р ә ш и д ә. Давно пора! Типкәләп чыгарганчы, тизрәк олак!

С у к б а й. Такие милые суперженщины, и так грубо обращаются с мужщиной суперменом. И не стыдно вам?

Р ә ш и д ә. Уф, үләм! Күр әле моның сөйләшүен... Каян килгән суппер-пуппер мужик! Гөлсинә, звони в милицию!

Г ө л с и н ә. Уже звонить итәм...

С у к б а й. Не надо, я сам уйду. Спасибо за гостеприемство! Мир этому дому!

Р ә ш и д ә. Давай-давай, быстро шагай, бомж бабай! Иди туда, не знай куда, бүтән килмә сюда.

С у к б а й. До свидание, Рашида. До встречи! Покорно извиняюсь. Гафу итегез! *(Чыгып китә.)*

Г ө л с и н ә. Үзем генә куып чыгара алмый идем мин моны. Ярый әле син булдың, Рәшидә.

Р ә ш и д ә. Сумкасын да биреп чыгарасы калган тегеңә. Нәрсә икән эчендә, ачып карарга иде бит.

Г ө л с и н ә *(кинәт)*. Не подходи!

Р ә ш и д ә. Уф, куркыттың! Урысча кычкырмале. Үзебезчә әйтсәң дә аңлыйм бит мин. Ничек беләбез инде моның эчендә ни бар икәнен?

Г ө л с и н ә. Хәзер Рәүфкә әйтәбез. Сумканы аңа актартабыз. Рәүф!

Р ә ш и д ә. Әллә Рәүф өйдәме?

Г ө л с и н ә. Өйдә булмыйча, кайда булсын тагы.

Р ә ш и д ә. Вәйт тиле син, Гөлсинә. Ник аны башта ук әйтмәдең? Бомжны куып чыгара алмыйча күпме чиләндек. Кайда соң, нишли соң ул Рәүф? Йоклый мәллә?

Г ө л с и н ә. Юк. Яза. Темнушкада. Темнушканы кабинет итте бит!

Р ә ш и д ә. Барыбер аңламадым, Рәүф нишли дисең?

Г ө л с и н ә. Яза, дим!

Р ә ш и д ә. Нәрсә яза? Пишетме, әллә май язамы?

Г ө л с и н ә. Опера яза! Нишләп май язсын инде, менәт-рәк! Сыер юк бит безнең. Прусты яза, пишет! Кичә дә төнлә язды. Бүген дә темнушкадагы кечкенә өстәленә кадалып утыра. Сөенеп торам әле менә. Язмаганына бер ун ел булган иде бит!

Р ә ш и д ә. Яза башлаган, димәк... Бик әйбәт! Атаклы язучы хатыны булып, затлы күлмәкләр генә киеп, кичәләрдә, банкетларда порхать итеп йөриселәрең алда икән әле!

Г ө л с и н ә. Авызыңа бал да май! Амин! Яза гына күрсен берүк... Юкса соңгы вакытларда кая бәрелергә-сугылырга белмичә йөридерие... Рәүф! Рәүф, дим! Чык әле монда!

Р ә ш и д ә. Бомба бар, диген! Атылып чыксын!

Кулларын язгалап, киерелеп Р ә ү ф чыга.

Р ә ү ф *(кәефләнеп)*. Күгәрченнәр гөрләшәләр безнең өйнең түрендә... Серләшәбезме?

Р ә ш и д ә. Серләшү генәме! Бомж белән типтерәбез! Әл-лә син бернәрсә дә ишетмәдеңме? Көпә-көндез фатирыңны талап, хатыныңны, мине урлап чыгып китә яздылар бит!

Р ә ү ф. Сине урласалар да ярый... Хатынкаема тия күрмәсеннәр! Нәрсә, берәр чит кеше керде мәллә?

Р ә ш и д ә. Рәүф, сручно врачка барып, колагыңны күр-сәт. Соңга калганчы, атып кал: ишетмисең икән бит син, бәгырькәем! Әле генә бомж булды монда – Фирая сукбае!

Г ө л с и н ә. Ашыйсың килмиме, Рәүф җаным?

Р ә ш и д ә. Нинди ашау, ниткән ашау? Өеңдә бомба шартларга тора!

Р ә ү ф. Аңлатып сөйләгез әле, нинди бомба?

Р ә ш и д ә. Менә бу сумканы ачып карарга куша сиңа Гөлсинә. *(Сумканы Рәүфкә китереп тоттыра да читкәрәк китеп колакларын каплый.)* Открой давай!

Г ө л с и н ә *(Рәүф артына елышып)*. Подожди!

Р ә ү ф. Ачтым. Шуннан?

Г ө л с и н ә. Вытаскивай!

Р ә ү ф. Нишләп икегез берьюлы урысча сөйләшә башладыгыз әле?

Р ә ш и д ә. Почему, патамушто монда бомж булды.

Г ө л с и н ә. Шуның белән гел урысча сөйләштек тә, хәзер менә үзебезнең телгә күчалмыйча интегәбез. Әйдә, нәрсә бар анда, чыгар!

Р ә ү ф. Ха! Минем кәчтүм-чалбар түгелме соң бу?

Р ә ш и д ә. Урлаткан идең мәллә? Бомж булуы гына җитмәгән, карак та икән бит теге иблис!

Г ө л с и н ә. Шул бомжны киендерәм дип, Фирая бездән сорап тормыйча гына алып чыгып киткән иде бу киемнәрне. Сукбае ошатмаган, күрәсең, кире керткән!

Р ә ш и д ә. Сайланган була икән әле, үзенең кем икәнен белмичә!

Р ә ү ф. Ә мин... *(Көлеп җибәрә.)* Берәр юньле әйбер дип торам тагы!

Көлешәләр.

Йә, ярый... Сезнең сүз бетмәс... Ә мине теге бүлмәдә – темнушкада бөек эшләр көтә! Роман көтә! *(Кереп китешли.)* Кирәк булсам чакырырсыз!

Р ә ш и д ә. Баядан бирле сорамакчы булам... Гөлсинә, ниме соң... «Гаилә үзәге» белән ничек булып бетте сезнең?

Г ө л с и н ә. И Рәшидә, аптыраган инде... Беренче тапкыр биргән анализлар белән барып чыкмады бит, үзең беләсең... Рәүф «Бала, бала!» дигәнгә генә анализларны икенче тапкыр бирергә ризалаштым... Әле бер хәбәр дә юк! Әллә ни өметләнмим дә инде...

Р ә ш и д ә. Алай димәле син... Әнә Гүзәлияләр... Пробиркада үстереп, балалы булдылар... Хәзер сөенеп беталмыйлар!

Г ө л с и н ә. Утка керосин сипмә әле, Рәшидә. Ходайдан шулай язгандыр...

Ут сүнә.
Музыка. Ут кабат янганда, Ф и р а я берьялгызы вальс бии.
Биюдән туктап, залга якынаеп, шигырь сөйли. А з а т аның сөйләгәнен бер читтә тыңлап тора.

Ф и р а я. Мәхәббәтнең канат җиле
Миңа да тигән иде.
Яратуыма сөенеп,
Бәхеткәйләргә тиенеп
Яшисем килгән иде...

Йолдызларның атылганын
Мин дә бит күргән идем.
Теләгем кабул булыр дип,
Бәхетем ташып торыр дип
Куанып йөргән идем.

Насыйп булмас, ахры, яшәү
Ярым өчен җан атып.
Гомер учагым сүрелә,
Өметкәйләрем өзелә –
Сына сабыр канатым...
Сына сабыр канатым...

А з а т. Фирая!

Ф и р а я. Азат?!

А з а т. Син монда икәнсең. Мин сине көне буе эзләдем. Юк, мин сине гомерем буе эзләдем! Менә таптым, ниһаять! Шигырьне матур сөйлисең икән син... Үзең яздыңмы?

Ф и р а я. Сиңа барыбер түгелмени?!

А з а т. Мин дә шигырь сөйли беләм... Кичә, алма ашый-ашый, төне буе яздым. Менә тыңлап карале.

Көч-гайрәтне күрсәтәм дип,
Таулар күчерәсе юк...

Әгәр минеке булмасаң,
Мәңге кичерәсем юк!
Шәпме?

Ф и р а я *(көлеп)*. Бу шедеврыңны язган чакта ничә кило алма ашап бетердең инде?

А з а т. Алмадан соң ярты кило груша да ашадым әле мин! Аннары ике әфлисун, өч мандарин, бер киви, ярты лимон...

Ф и р а я. Кыйбатка төшкән икән!

А з а т. Иҗат корбан сорый! Бүтән язмам, ахры... Эчем авырта...

Ф и р а я. Җәл. Берәр шәп шагыйрьгә кияүгә чыгармын дип хыялланган идем... Булмады!

А з а т. Андый нәтиҗә ясарга ашыкмале син... Кем белә, эч авыртуы беткәч, бәлки, мин тагын шигырьләр яза башлармын...

Ф и р а я. Шагыйрь булуда гынамыни хикмәт! Иң мөһи-ме – кеше бул син, Азат!

А з а т. Мин сине яратам, Фирая!

Ф и р а я. Ә мин сине яратмыйм, Азат... Аңла, зинһар, ярата алмыйм мин сине!

Ут сүнеп ала.
Ут кабат янганда Р ә ү ф «иҗат бүлмәсендә», өстәл янында ноутбук-ка текәлеп утыра, ара-тирә клавишларга баскалап ала. Үз-үзеннән канәгать түгеллеге сизелә.

Р ә ү ф. Шайтан алгыры! Тема шәп! Сюжет менә дигән! Нишләп язалмыйм соң мин, ә?

Караңгыдан Ф и р а я т а в ы ш ы ишетелә: «Язалмаячаксың да, иптәш автор! Чөнки син, җизни, ялгыш юлдан киттең!»

Р ә ү ф. Ә? Нәрсә? *(Як-ягына каранып ала.)* Беркем дә юк.

Ф и р а я *(аерым ут яктысы белән пәйда булып)*. Мин монда, җизни, синең күңелеңдә.

Р ә ү ф. Ә? Әллә саташа башладым инде?! Балдыз?! Синең тавыш бит бу?! *(Колак тишекләренә бармакларын тыгып селкетә.)* Гөлсинә читтән карап торса, ычкынган бу, диячәк... Валлаһи! *(Башын тотып уйга чума.)*

Ф и р а я. Йә, нәрсә яздың инде син, җизни? Авыл кызының мәхәббәт маҗаралары, корсакка узуы, авылдан качып шәһәргә килүе, шәһәрдәге маҗаралары... И вәссәлам! Шул гынамы? Юк, җизни!.. Син мине белмисең әле... Син берни дә белмисең. Син күзаллаганча түгел, бөтенләй бүтән кеше мин! Җанымда – давыл! Йөрәгемдә ут кайный! Роман дип зурдан купкансың да кубуын... Синең матур ялганың, буш сүзләрең беркемгә дә кирәк түгел, җизни! Моны беркем дә укымаячак. Яз! Җаннарны елатырлык, йөрәкләрне тетрәндерерлек итеп чынбарлыкны яз! *(Ут белән бергә югала.)*

Р ә ү ф. Нәрсә булды бу? *(Кинәт урыныннан торып, уң кулын Ленин кебек алга суза.)* Во! Баш эшли башлады... Дөрес юлдан багасың, иптәш язучы! *(Кабат урынына утыра.)* Дөрес юлдан атлагыз, алга, иптәшләр!

С у к б а й   т а в ы ш ы: «Юкны бушка аударып, зерәгә ыштан туздырма син, туган. Язсаң яз, курыкмыйча!»

Р ә ү ф. Монысы кем тагы? Сукбай?! Дядя Коля, синме бу?

С у к б а й *(ут аны да аерым яктыртып)*. Язасың икән, тормышчан итеп яз син! Нәрсә, тормыш төбенә төшкән бер мәхлук бәндә генәмени мин? Үзен, бер тамагын гына кайгыртып яшәүче пошмас җанмыни мин? Нәрсә, тормышка, җәмгыятькә карата бер фикерем дә юкмыни минем? Сукбайлыкка төшүемнең сәбәбен ник язмыйсың? Чөнки белмисең. Минем кебекләр дөньяда миллион! Һәрберсе үзе бер ачы язмыш! Гәзитләрдә өзлексез чәйниләр: «Сукбайлар белән көрәшергә кирәк! Сукбайларны каядыр олактырырга кирәк!» – диләр... Әйтерсең сукбайлар илне талаучы, кеше җанын кыючы бандитлар... Сукбайлар белән түгел, аларны тудырган социаль сәбәпләр белән көрәшергә кирәк!

Р ә ү ф. Круто!

С у к б а й. Яз!

Рәүф, Сукбай сөйләгән вакытта, ноутбукка текәлеп, клавишларга кызу-кызу баса башлый.

Яз, туган!

...Без частька килер алдыннан гына бик каты бәрелеш булган. Теге яктан да, бу яктан да кырылганнар. Безнекеләр бер дошманны эләктергәннәр. Каршыбызга шуны китерделәр. Аяклары яраланган моның. Куркынган күз-ләрен мөлдерәтеп җирдә ята бу. Лейтенант Ильичёв Рязань егете Роман Шустриковны строй алдына чыгарды. Роман якташы Есенинга охшатып шигырьләр яза иде:

Россия – великая страна,
Россия – родина моя!
Ты иногда так многословна,
Как баба немая!

Менә шул шагыйрь егеткә лейтенант дошманны атып үтерергә боерды. Роман әйтә: «Не могу стреляйть! Он же без оружия!» – ди. «Стреляй!» – ди лейтенант. «Не могу!» – ди Роман. «Ты что, гад, врага жалеешь?» – дип, Ильичёв Шустриковның якасыннан эләктереп алды. Мин түзмәдем, араларына барып кердем дә лейтенантка: «Если тебе так хочеться, сам стреляй!» – дидем. Татарлыгым чыраема чыккан булгандыр... «Ах ты, чаплашка!» – ди бу миңа. Шуннан соң пистолетын минем чигәгә китереп терәде дә: «Тогда ты стреляй, татарская морда! Приказываю!» – дип акырды. Дошманның күзләре акаеп чыкканын гына хәтерлим... Аттым...

...Шуннан соң күп бәрелешләрдә катнаштым. Илгә исән-сау кайттым. Әмма теге күзләр... Кая гына барсам да,ниләр генә кылсам да, гел мине эзәрлекләделәр. Дөньяның, яшәвемнең яме, гаме бетте. Аракы эчеп, онытылмакчы булдым – сазга кереп баттым... Ватанны дошманнан сак-лагыз дип, безне ут эченә ыргыттылар. Соңыннан барысы да аңлашылды – зерә сугышканбыз икән. Мокыт сәясәтчеләрнең шәхси амбициясен яклап, бер мәгънәсезгә күпме яшь гомер өзелде. Рязань егете Роман Шустриков та һәлак булды... Меңәрләгән егетләр чит җирдә башларын салдылар! *(Сүгенгән сыман итеп.)* Родина-мать! Илгә солдатлар һәм эчкечеләр генә кирәк икән! Мать твою! *(Югала.)*

Рәүф дәртләнеп язуын дәвам итә. Ут сүнә.
Ут янганда, Гөлсинә белән Рәшидә өстәл янында утыра.

Гөлсинә. Менә шундый хәлләр, Рәшидә... Абыйларда кунды микән? Борчыла башладым инде. Һаман юк!

Рәшидә. Борчылма, Фирая югала торган кыз түгел ул, кайтыр. Бая, күземә генә күрендеме соң, бер песи кухнягызга таба кереп киткән сыман тоелды. Син бит эт-мәче яратмый идең!

Гөлсинә. Ә-ә-ә... аны әйтәсеңме? Бүген иртән подъезд ишеге төбеннән алып кердем. Мине күрде дә аякларыма килеп ышкына башлады. Күзгә карап, үзенчә мырлаган була. Нәрсәсе беләндер яраттырды үзен. Алып кердем әле менә. Ошатса, бездә калыр, урын иркен! Бер гәзиттә укыган идем, өйдә мәче булса, бала туарга мөмкин икән, дип...

Рәшидә. Элек мондый түгел идең. Әллә сеңлеңә охшый башладың инде?! Фатирыгызга ул сукбай алып керә, син – мәче дигәндәй...

Гөлсинә. Бүген дә йоклый алмадым. Әллә нәрсә шунда... Гел уйланып яттым. «Тик икәү без, уй да мин!» дип Габдулла Тукай әйткәнме әле?! Шуның шикелле...

Рәшидә. Кем әйткәнен үзең яхшы беләсеңдер... Син бит педуниверситет бетергән кеше! Берме-икеме ел укытып йөрдең түгелме соң?!

Гөлсинә *(авыр сулап)*. Әйе-е... Бар иде укытып йөр-гән чакла-ар... Кешечә түләгән булсалар, әле дә яраткан эшемдә әвәрә килер идем! Балаларны ярата идем...

Рәшидә. Базарыңны ташла да кайт укытучылык эшеңә!

Гөлсинә *(авыр сулап, көйләп)*. Сордыр шул инде, соңдыр шул инде...

Рәшидә. Җүләр сатып утырма! Яраткан эштә эшләүгә ни җитә! Ул яктан минем бәхет булды. Көн саен яңа кешеләр, төрле язмышлар белән очрашам. Кешеләр бит безгә паспорт алырга, паспорт алыштырырга дип кенә килмиләр. Эч серләрен бушаталар, киңәшләр сорыйлар, ярдәм өмет итәләр... Булдыралган кадәр хәлләренә керергә тырышасың... Әле менә кичә соцзащита кызлары безгә бер адәмне алып килде. Заманында менә

дигән гармунчы булган! Теге... дед Мазай кебек, әй лә, Фираяның дядя Колясы кебек, бомж хәленә калган. Документларын югалткан. Документлары чёрт с ним! Быел кыш, исерек килеш карда ятып, ике кулын өшеткән, бахыр. Кискәннәр! Яңа паспортка кул куярга кирәк бит инде хәзер... Ничек куйды дип уйлыйсың? Авызы белән! Беркемгә кирәге калмаган үзенең. Исерек белән торасы килмәгәндер инде, хатыны бүтән иргә кияүгә чыккан. Туганнары да моннан баш тарткан. И җәлләдем дә инде үзен!

Г ө л с и н ә. Сәер кеше син, Рәшидә! Әле җәллисең шул бомжларны, әле күралмыйсың...

Р ә ш и д ә. Кая бара бу замана? Туганга туган кирәк түгел, аналар балаларын ташлап кача... Аңламассың бу дөньяны!

Г ө л с и н ә. Мин монда үзебезнең Фираяны аңламыйм. Ә син дөнья дисең!

Р ә ш и д ә. Фирая кебекләр җитми бугай бу җәмгыятькә! Замана Фираяларга кытлык кичерә... Их, тагын бер-ике... йөз Фирая... Һәм...

Г ө л с и н ә. Син дә Рәуф кебек сөйләшә башладың... Әйдә, бик тәмле пирогым бар. Чәйләп алыйк!

Кухняга кереп китәләр.
Ф и р а я керә. Причёскасын үзгәрткән.

Ф и р а я. Әллә беркем дә өйдә юк инде?

А з а т керә.

А з а т. Мин бар!

Ф и р а я. Абау, котны алдың!

А з а т. Кайтканыңны тәрәзәдән күрдем дә кердем әле менә. Сагындым үзеңне! О-о! Причёскаңа игътибар итми торам икән! Тагын да чибәрләнгәнсең димме?! Карале, чынлап әйтәм, әйдә, чык миңа кияүгә!

Ф и р а я. Мин бит болай да кияүдә инде, Азат. Ирем бар минем. Үзебезнең районда, зур урында эшли. Бик яратам мин аны. Ул да мине ярата. Уч төбендә генә йөртә.

А з а т. Ышанмыйм. Яратса, бу хәлдә ялгызыңны гына чыгарып җибәрмәс иде.

Ф и р а я. Бик мөһим эш белән командировкага китте шул ирем. Мине дә үзе белән алып барырга бик теләгән иде. Эш кешесенә комачау булып йөрисем килмәде. Гел шалтыратып, хәлемне белешеп тора.

А з а т. Ну-ну! Ышандыра яздың. Син нәрсә, мине кеше аермый дип беләсең мәллә? Минем абый да зур урында эшли. Әмма мин җиңгәчәйнең синеке шикелле прастуй күлмәк киеп, Вьетнам базарыннан сатып алган алкалар тагып йөргәнен хәтерләмим.

Ф и р а я. Күзең үткен икән... Мин бит махсус шулай киендем. Алкаларның да очсызлысын тактым. Апаны көнләштерәсем килмәде. Йөрәге янмасын әле, дидем. Иремә дә сүз китерәсем килми.

А з а т. Ну-ну!

Ф и р а я. Ышанмасаң ышанмыйсың инде. Акча биреп ышандыра алмыйм. Әйтәсемне әйттем, Азат. Бүтән әйттермә, яме. Матур кызлар белән дөнья тулы. Шулар арасыннан үзеңә тиң яр табасына ышанам мин. Бәхетле бул!

А з а т. Миңа син кирәк, Фирая. Мин сиңа чынлап гашыйк. Яратам мин сине! Туасы балаңны да, үзеңне дә мәңге яратачакмын! Күңелем алдамый минем, без барыбер бергә булачакбыз!

Ф и р а я. Ха-ха-ха!.. Ирем ишетсә бу сүзләреңне, икебезне дә... *(Корсагын сыйпый.)* Юк, өчебезне дә харап итәчәк!

А з а т. Борчылма, ишетми ул. Командировкада, дисең бит.

Ф и р а я. Командировкада булса да, әллә кайда еракта түгел бит ул – Чабаксарда гына!

А з а т. Хет күрше бүлмәдә генә булсын – курыкмыйм мин синең ireңнән. Дөресен генә әйткәндә, юк бит синең ireң, шулаймы?! Алдыйсың син. Ялгышып балага узгансың да, хәзер үзеңне үзең юатып, алдашып торган буласың. Юк синең ireң! Сүзләрең белән алдаласаң да, күзләрең алдамый синең!

Ф и р а я. Ирем бармы минем, юкмы, анда синең эшең булмасын. Югал күз алдымнан, бар, чыгып кит! Яратмыйм мин сине!

А з а т. Чыгып китәм. Пока. Әмма, син тынычлангач, кабат керәчәкмен! Белеп тор! Без барыбер бергә булачакбыз! *(Кырт борылып чыгып китә.)*

Ф и р а я *(үзгәләнеп)*. Их, Азат, Азат... Күңелең саф синең. Нишлим, сине өметләндерә алмыйм бит. Хәлләремне үзем генә беләм... *(Җырлый.)*

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Күреп алдым бүре баласын.
Белмәдем шул, алда язмышымның
Уттан алып суга саласын...

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Никләр күрдем бүре баласын?
Белмәдем шул килер көннәремнең
Сагышларга мине саласын...

Аланнарда җиләк җыйган чакта
Кызарып ла бетте кулларым.
Берәр вакыт сиңа, бәгырькәем,
Илтер микән гомер юлларым?..

Телефон шалтырый.

Ф и р а я *(трубканы алып)*. Алло! Әйе! Әйе!

Ул сөйләшкән чакта, ишек тарафында Р ә ү ф күренә. Аны күреп, Фираяның йөзе тагы да яктыра.

Сәлам, җизни! *(Трубкага.)* Рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Шундый куанычлы хәбәр әйттегез! Ходай сезгә дә һәрчак мәрхәмәтле булсын! Тагын бер мәртәбә зур рәхмәт сезгә! Җизни, кайттыңмы?!

Р ә ү ф *(шаярып)*. Сине сагынып кайттым, балдызым-йолдызым...

Р ә ш и д ә *(кухнядан чыгып)*. О-о-о! Югалган кеше табылган! Кайларда йөрдең, Фираюшка?

Г ө л с и н ә. Кайда йөрсен, сукбайлар янында инде... Белмисеңдер әле син: сукбайларның атаманы бит ул хәзер! Жанна д’Арк!

Р ә ш и д ә. Бер дә арык түгел... Таза, матур!

Р ә ү ф *(кинаяләп)*. Балдыз булдыра ул, молодец! Чи-бәрлеге бар, үҗәтлеге җитәрлек, тәвәккәллеге хәттин ашкан... Аның өчен ике дөнья – бер моржа... Кая тели, шунда бара. Ни тели, шуны эшли.

Г ө л с и н ә. Тормозсыз трактор белән бер – алдында очраган бар нәрсәне җимереп бара...

Р ә ш и д ә. Баруын тырт-пырт барадыр да бит... *(Күк-рәкләрен куллары белән селкеткәли.)* Буферы изелеп-яньчелеп беткәч нишләр менә?!

Р ә ү ф. Балдыз, тыңлама син боларны. Барыбер акыллы сүз әйтмәсләр!

Г ө л с и н ә. Кайлардадыр себерелеп, эшерелеп йөргәнче, туасы балаң турында уйлар идең, ичмасам! Артистка!

Ф и р а я. Дөрес әйттең, апа. Артистка! Әйе, минем гомер буе артистка буласым килде...

А з а т керә.

А з а т. Гафу итегез, тамагым тук... Бер әйбер дә кирәк-ми...

Г ө л с и н ә. Наконец!

А з а т. Әлегә кирәкми!

Р ә ү ф. Бүлдермәгез әле Фираяны!

Ф и р а я. Кечкенәдән бирле хыялланам инде мин. Хыялым әллә кайчан ук чынга ашкан да булыр иде, бәлки. Әнине карарга кирәк иде... Син бит, апа, чыктың да киттең! Күчтәнәч итеп бер кило конфет-прәннек апкайта идегез дә... Әнкәй шуны ел буе күршеләргә сөйли иде... Ә мин фермада эшлим. Сыерларга, бозауларга Галиябану булып, Сәрвиназ булып уйныйм... Укырга керә алмыйча калдым... Әнине карадым...

Г ө л с и н ә. Син нәрсә beləсең соң? Менә син сыерлар, бозаулар, дисең. Минем белән укыган Әлфияләрнең, Санияләрнең, Рәфидәләрнең бер көтү бала-чагасы бар. Ә минем?

Ф и р а я. Апа, хәзер кайта аласың. Бала-чагалар юк хәзер. Болын хәтле мәктәптә ике-өч бала селкенеп йөри. Балалар бакчасы ябылды. Хәзер хатыннар авылда да бала тапмый.

Р ә ш и д ә. Между прочим, рәтле ир булса, мин бүген үк бала табар идем! Берне генә түгел, бишне! Орлыгы юк! Их, яхшы мужик булса!

Затлы киемнән С у к б а й керә, бер кулында – ниндидер төргәк,
икенче кулында – бик матур чәчәк бәйләме.

С у к б а й. Кем әйтте юк дип! Бар ул яхшы мужик!

Барысы да Сукбайга гаҗәпләнеп карый.

Ф и р а я. Дядя Коля! *(Сукбайның кочагына ташлана.)*

С у к б а й. Киләчәгең шушы чәчәкләр кебек гүзәл булсын, сеңлем!

А з а т. Амин! *(Сукбай кулындагы чәчәкләргә үрелеп.)* Кая, китер чәчкәләреңне... Үзем бирәм Фираяга!

С у к б а й. Минем үземнең кулларым бар. Мә, Фирая!

Ф и р а я *(чәчәк бәйләмен алып)*. Рәхмәт, дядя Коля!

С у к б а й. Акча алып килдем сиңа, Фирая! *(Төргәктән орден-медальләр чыгара.)* Шушыларны сатам!

А з а т. Ә нәрсәгә сиңа акча, Фираякаем?

Ф и р а я. И Азат, ошыйсың син миңа. Бүген үк кияүгә чыгар идем сиңа. Тик сине дә, үземне дә бәхетсез итәсем килми!

Г ө л с и н ә. Нидән бәхетсез? Азат бик шәп егет! Менә дигән кияү!

А з а т. Миндәй затлы кияү дөньяда бүтән юк! Әни дә шулай ди... Үзем дә шулай уйлыйм...

Ф и р а я. Аңламыйсыз шул сез... Авырыйм мин... Врачлар үзләре дә нәрсә икәнен төгәл белмиләр. Тикшеренер өчен генә дә бик күп акча кирәк. Бик күп!

А з а т. Бик күп акча?! Миндә ничаклы бар икән? *(Чалбар кесәләрен капшаштыра.)*

С у к б а й. Фирая! Барысы да әйбәт булыр. Бәлки, операция кирәк тә булмас. Врачлар да ялгыша. *(Өскә төртеп күрсәтә.)* Барысы да Иң Главный Врач кулында!.. Ул беркайчан да ялгышмый! Болар гына җитмәсә, минем банкта да байтак акчам бар. Менә паспорт белән генә проблема! Әйле-шәйле йөргәндә югалткан идем. Яңа паспорт алалсам...

Р ә ш и д ә. Нет проблем! *(Орден-медальләрне тотып карый.)* Мин сине үзем паспортлы итәм... Син минем яшьлек мәхәббәтем Кыямны хәтерләттең. Аның да шушындый бүләкләре булгандыр. Ул да сугышта иде. Син кайткансың, ә аны кайтардылар...

С у к б а й. Әйе, мин кайттым, к сожалению!

Р ә ш и д ә. Ходай гомер биргән икән, куанып яшәргә кирәк, дядя Коля! Син бит герой!

С у к б а й. Тормыш төбенә төшкәнгә кадәр минем исемем Камил иде. Камил дип дәш, Рәшидә!

Р ә ш и д ә. Хәзер генә аңладым мин сине, Камил... Кемевич?! Күрсәткәндер сиңа дөнья...

К а м и л. Күрсәтте, еламаска өйрәтте... *(Орден-медальләрне өстәлгә куя.)* Балаларга тел, әдәбият, тарих, милләт турында, шәхеснең асылы, яшәүнең мәгънәсе хакында сөйлисе кеше идем мин. Пединститутта ике ел укып калдым – армиягә алдылар...

Р ә ү ф. Әйе, син күргәннәрне дошманыңа да күрергә язмасын!

Р ә ш и д ә *(орден-медальләрне кадерләп тотып, Камил янына килеп)*. Гафу ит мине, Камил... Гафу итегез, зин-һар!

К а м и л. Нигә? Ни өчен?

Р ә ш и д ә. Синнән чирканганым, җирәнгәнем өчен!

Г ө л с и н ә. Мине дә кичерә күр, дядя Коля! Мин... без... әллә кемнәр без! Адәм баласы шулай гел ялгыша инде ул.

А з а т. Камил туган, миңа үпкә саклама, яме... Теге чакта... Икәү әүмәкләшкәндә, кулыңны каерып авырттырдым бугай...

К а м и л. Синме?! Минем кулнымы?!

А з а т. Ә, юк... Гафу ит, киресенчә булды бугай шул...

Р ә ү ф. Барыбызны да гафу ит, солдат!

К а м и л. Сез түгел, башкалар гафу сорарга тиеш... Бездән! Яуда ятып калганнардан да, исән-сау кайта алганнардан да! Кылган гамәлләре өчен халкыннан гафу үтенә алган илнең генә үзен бөек держава дип йөртергә хакы бар! Әлегә мин андый хәлнең булганын хәтерләмим... *(Бераз паузадан соң Рәшидәгә карый.)* Рәшидә! Син чынлап та мине паспортлы итә аласыңмы?

Р ә ш и д ә. Итәм, дидем бит!

А з а т. Мин беләм, Рәшидә ханым беркайчан да ике сөйләшми. Ул югалткан паспортыңны да табып бирергә мужыт!

К а м и л. Фираяга бик күп акча кирәк. Һәм бик тиз кирәк!

Ф и р а я. Камил абый, бәлки, ул миңа инде кирәк тә булмас. Шулай да бик зур рәхмәт сиңа!

А з а т. Төшенкелеккә бирелмәскә! Ишетәсеңме, Фирая?! Авылда шәп йортыбыз бар безнең. Буш тормасын дип, хәзерге вакытта анда әни яшәп ята. Шул йортны сатабыз! Әни риза булачак. Әнием бик әйбәт минем!

Р ә ш и д ә. Ниткән сүз ул? Ул йортны сатканчы күпме вакыт уза... Фираяга үзем бирәм акча!

Г ө л с и н ә. Туктагыз әле сез! Безне бөтенләй оныттыгыз! Без бар бит әле монда. Яраткан җизнәсе булганда, бертуган апасы булганда, нишләп сездән алып торсын инде ул... Шулай бит, Рәүфкәем?!

Р ә ү ф. Әйе, шулай. Без – Фираяның иң якын кешеләре. Без дә булышмасак...

Г ө л с и н ә. Мин хәзер! *(Икенче бүлмәгә кереп китә.)*

Ф и р а я. Сез нәрсә инде. Мин сезне борчымаска уйлаган идем, җизни.

Р ә ү ф. Их син, кычыткан чыпчыгы! Нинди борчу ди ул! *(Килеп кочаклый, үбеп ала.)*

Г ө л с и н ә бүлмәдән гөл күтәреп чыга.

Г ө л с и н ә. Хәзер, хәзер... *(Гөл төбеннән төргәкне ала.)* Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Файдасы тиярлек булсын бу акчаларның! Мә, сеңлем, син дә бисмилланы әйтеп ал!

Ф и р а я. Апа, нишлисең син?.. Җизни, үзегезгә кирәк-тер бит?..

Г ө л с и н ә. Безгә син кирәк, сеңлем! *(Акчаны биреп, Фираяны кочаклый.)* Син кирәк!

Р ә ү ф *(хатыны белән балдызын кочагына алып)*. Дөрес әйттең, Гөлсинә! Безгә син кирәк, балдыз!

А з а т *(Фирая алдына тезләнеп)*. Юк, Фирая миңа кирәк... Миңа!

К а м и л. Фирая барыбызга да кирәк!

Фирая кинәт апасы белән җизнәсе кочагыннан чыга да башта Азат белән, аннары Камил, соңыннан Рәүф белән биергә тотына. Башкалар бер үк вакытта сөенеп тә, гаҗәпсенеп тә, сәерсенеп тә аңа карап торалар.

Ф и р а я *(биюдән туктап)*. Балалар җыры! Җырлый Фирая Әлдермешева! *(Дәртле-күңелле итеп җырлый.)*

Учлап-учлап җиргә сиптем
Сары тары ярмасы.
Чырык-чырык чыркылдаша
Ике чыпчык баласы...

Чырык-чырык, чырык-чырык!
Ике чыпчык баласы!..
Миңа тары сибәсе дә,
Сезгә чукып аласы...

Фирая, кинәт җырлаудан туктап, Гөлсинә янына килә.

Ф и р а я. Рәхмәт апа, рәхмәт сезгә! Барыгызга да!.. Тик... Кичерегез мине... Кичерегез! Юк минем бернинди дә балам! Уйнадым гына мин! Мәгез, тотыгыз баланы!

Күлмәк эченнән мендәр тартып чыгара да өскә чөя,
аны Азат тотып ала.

Р ә ш и д ә. Вот артистка, ә! Нәрсә булды инде бу?

А з а т. Нәрсә булсын... Выкидыш! Вык-кидыш! Вык-кидыш! *(Шатлыгыннан мендәрне кочып, «Ламбада» биюен бии башлый.)* Баласы булмагач, ире дә юк инде аның!

Г ө л с и н ә *(аптырап)*. Бала?! Балам?! Син безне алдадың?! Ышанмыйм!

Ф и р а я. Алдамадым, апа. Мин чынлап уйнадым.

А з а т. Браво! Браво!! Афәрин!!! Искиткеч шәп уйнадың! *(Мендәрне үбә, сөя.)* Талант син, Фирая, талант! *(Мендәрен кочаклаган килеш, Фирая алдына тезләнә, баш ия.)* Син, син – иң гүзәл актриса! Булмаган бала өчен рәхмәт сиңа! Рәхмәт сиңа мендәр өчен!

Р ә ү ф. Бармактан суырып язасы да юк... Менә ул тормыш үзе биргән сюжет! Роман геройлары безнең арада!

Г ө л с и н ә. Ышанмыйм, ышанмыйм!..

Ф и р а я. Апа! Апам! Бәгырь кисәгем!

Г ө л с и н ә. Минем сиңа әйтер сүзем юк!

Ф и р а я *(күз яшьләрен сөртеп)*. Апа! Җизни! Зинһар, мине аңларга тырышыгыз... Минем бик тә, бик тә артистка буласым килде!..

А з а т. Син хәзер үк артистка инде, Фирая!

Ф и р а я. Авылымны да бик яратам мин. Аны яшәтәсем килә! Яшисем килә минем!

К а м и л. Син яшәячәксең, Фирая!

А з а т. Без әле яшибез, Фирая! Дөньяның артына тибеп яшәячәкбез!

Ф и р а я. Сезнең алда уйнап, үземне тагын бер кат сыныйсым килде... Сынаттым!

Р ә ш и д ә. Сынатмадың, Фирая...

А з а т. Булдырдың!

Ф и р а я. Апа! Син... сез... өйдә юк чакта... «Гаилә үзәге»ннән шалтыраттылар! Синең balaң булачак, апа! Җизни! Сезнең балагыз булачак!

Г ө л с и н ә. Ә?! Чынлапмы? *(Үзәк өзгеч тавыш белән.)* Рәү-е-еф!!!

Р ә ү ф *(Гөлсинәне кочагына алып)*. Кадерлем минем, бер-дәнберем! Гөлсинәм минем!!! Шатлык бер килсә, ишелеп килә ул... Без Парижга барачакбыз! Мине симпозиумга чакыралар. Сине дә үзем белән алам!

А з а т *(Рәүф белән Гөлсинә янына килеп)*. Сез иң бәхет-ле кешеләр бүген! Сезнең хөрмәткә миннән бер анекдот!..

Р ә ү ф. Азат, берүк хәзер сөйләмә... Башка вакытка калдыр, яме!

А з а т. Ихтыярыгыз...

Г ө л с и н ә. Ашыйсың килмиме, Азат?

А з а т *(хисләнеп)*. Аһ... ниһаять! Затлы кешедән татлы сүз! Рәхмәт, рәхмәт... Бераздан, ямегез! *(Камил белән Рәшидә янына килә.)* Күрәзәлек итү сәләтем юк югын... Әмма күңелем сизә... Сез бергә булачаксыз, дуслар! Миннән фатыйха!

Р ә ш и д ә. Авызыңа бал да май!

К а м и л. Азат, гел бергә булыйк, аерым торыйк!

Көлешәләр.

А з а т *(Фирая янына килеп)*. Фирая! Фираякай! Син...

Ф и р а я. Мин риза!

А з а т. Кычыткан чыпчыгым мине-е-ем!.. *(Фираяны күтәреп ала.)*

Дәртле, күңелле музыка.

П ә р д ә.

*2009*

# ЭКСТРАСЕНС

*Ике пәрдәлек шаян пьеса*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Г и б р а л т а р – авыл клубы мөдире, үзен «клуб директоры» дигәнне кулайрак күрә.
М и ң н и са – авыл карчыгы.
Л ә й с ә н – Гибралтарның кызы.
С а л а в а т – авыл егете, Ләйсәнне ярата.
Х ө б б е л – шәһәрдә слесарь булып эшләп кайткан авыл җилкуары, эчкече.
К а ф и л – тиле яшүсмер.
Ф а т ы й м а – җилбәзәк хатын, Кафилнең анасы.
С а м а т – Гибралтарның абыйсы, колхоз рәисе.
Г а л л ә м – бушкуык «экстрасенс».
Р и ф а т – Галләмнең «ярдәмчесе».
А в ы л х а л к ы.

Вакыйга СССР таркалган көннәрдә бер авыл клубында бара.

## Б Е Р Е Н Ч Е П Ә Р Д Ә

Авыл клубы сәхнәсе. Сәхнәдәге һәммә җиһазның иске икәнлеге күзгә бәрелеп тора. Ян-яклардагы һәм арттагы бәрхет пәрдәләрнең аскы өлешләре тузып, ертылып беткән.
Сәхнәнең уң ягында, алда, фанердан эшләнгән трибуна тора. Трибунага СССР гербы төшерелгән. Герб уртасы чәрдәкләнеп беткән. Арттагы пәрдәгә «Хуш киләсең, Яңа ел!», «Хуш киләсең, экстрасенс әфәнде!», «Саулык – зур байлык! », «Акчаң булса, саулыгыңны кайгырт!» дигән лозунглар эленгән. Боларга иштәш һәм шулай ук әүвәлге елларны искә төшереп торган лозунглар зал стеналарында да бар: «Сәнгать – халыкныкы! *В. И. Ленин*», «Партия – ум, честь и совесть советского народа», «Религия – опиум народа», «Кеше кешегә дус һәм...» (Лозунг шушы урында ертылган.)
Сәхнәнең сул ягында, алгы тарафта, марля тарттырылган ишек тора. Ишек өстенә «Директор Гибралтар Мансурович Кәшәфетдинов» дип язылган.
Аңлашылганча, бу бүлмә – клуб мөдире бүлмәсе, шул ук вакытта грим салу бүлмәсе дә.
Зал ягыннан шау-шу ишетелә. Кулларын «Юк-юк!» дигән төсле сел-ти-селти: «Бар, бар, Миңнисаттәй, йөрмә аяк арасында чуалып! Кайт та ят өеңдә! Син яшисен яшәгән инде...» – дип кычкыра-кычкыра, Гибралтар үз бүлмәсенә таба атлый. Аның артыннан: «Нишләп чуалыйм мин синең аяк арасында. Нишләп кайтыйм мин өйгә... Кайтмыйм әле!..» – дип сөйләнә-сөйләнә, таякка таянган, бер кулы белән чәйнек тоткан Миңниса карчык кыймыл-кыймыл килә. Ул, сәхнәгә менү өчен куелган

баскычка абынып, гөпелдәп егыла. Чәйнеге кулыннан ычкынып тәгәрәп китә, суы түгелә.

М и ң н и с а. Әстәгъфирулла! Суым! Хараплар булды сукаем! *(Азапланып тора да Гибралтар кереп киткән ишеккә карый.)* Синең артыңнан җитешәм дип, Гыйбрәт улым, аяксыз калам инде... *(Әүвәл кулындагы таякның кәкре башы белән чәйнекнең тоткасыннан эләктермәкче була, алай булдыралмагач, көч-хәл белән генә иелеп, чәйнекне ала. Көрсенә.)* Азапланып алып килгән суымны хараплар гына иттем...

Миңниса карчык ишектән эчкә үтәм дигәндә генә, ишек турысында кинәт пәйда булган Гибралтарга бәрелеп, чак кына артына утырмый.

М и ң н и с а. Лә хәүлә вәлә куәтә! Тәмам котымны алдың, Гыйбрәт улым...

Г и б р а л т а р *(ярсып)*. Миңнисаттәй! Күпме тукыйм инде мин синең шалкан үскән колагыңа. Әйтмә миңа Гыйбрәт дип! Әйтмә! Канса да кансов, минем исемем – Гыйбралтар... Аңладыңмы, бабуля? Гыйб-рал-тар!

М и ң н и с а. Аңладым, аңладым, Гыйбрәтләр улым... Аңламыйммы соң! Сиксәнне генә узсам да, Аллага шөкер, ул кадәрле үк томана карчык түгел әле мин. Би-ик аңладым, Гыйбрәтләр улым...

Г и б р а л т а р *(биленә таянып)*. Уф! Җелегемне син генә корытасың, Миңнисаттәй. Бу чәчләрем агарса, синең аркада гына агарачак! *(Кулы белән башын сыйпаганда, башының ярым пеләш икәнен шәйли.)*

М и ң н и с а. Китчәле, Гыйбрәт улым, булмастайны сөй-ләмә... Юк чәчеңне ничек агартыйм мин. Булмаганны. Сезнең бөтен нәселегездә чәчләрегез агарганчы коелып бетеп бара.

Г и б р а л т а р. Җә, җә, булды. Җитте. Безнең нәселгә үк кереп чокчынма.

М и ң н и с а. Чокчынма, дип... Үзең «пеләшем агара» дип әйтеп-әйтеп әйткәнгә күрә генә әйтүем.

Г и б р а л т а р. Булды, булды. Җитте. Бүтән миңа Гыйб-рәт дип тә, Гыйбрәтләр дип тә әйтеп-әйтеп әйтмә. Бик әйтәсең килеп телең кычыта икән, Кәшәфетдинов әфәнде, диген. Ишетсен колагың! Экстрасенс иптәшләр алдында оятка калдырма. Адәм хуры итмә мине! Җәле, әйтеп кара, Кәшәфетдинов әфәнде, диген...

М и ң н и с а. Әйтәм, әйтәм. Ник әйтмәскә. Хәзер әйтеп әйтәм. Авызымдагы төкерегемне генә йотып җибәрәм дә... *(Авыз тирәсен әле таяк тоткан кулы белән, әле чәйнеклесе белән сөртеп ала.)* Кә-шә-фет-дин-уф... уф... әф... әф-ән-де... Кәш-шә-бет...бет...

Г и б р а л т а р. Стоп! Стоп! Нәгаләт! Нишләп бет булыйм мин, телеңә тилчә чыккыры! Йөз яшькә җиткәнсең, ә үзең кешенең исем-фамилиясен дә җүнле-рәтле әйтә белмисең.

М и ң н и с а. Каян килеп йөз яшь булсын. Сигез дистәне дә түгәрәкләмәгән әле мин. Җитмешкә яңа җитеп киләм. Нишләп йөз булсын...

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Йөз булмаса – булыр. Бу мәңге арымас телең белән син йөз дә бер яшькә дә җитәрсең әле.

М и ң н и с а. Авызыңа бал да май, Гыйбрәт у... у... *(Гибралтарның акайган карашын күреп, ялгышын төзәт-мәкче була.)* Кә-шә-бет-дин-уф... уф... әф...эф-ән-де... улым! Бирсен Ходай берүк! Әле бүген кылубка икестырасилус та килә дип тә әйтеп-әйтеп әйтәләр бит. Ул икестырасилус та сихәтләндереп китсә, Аллаһы Тәгалә дә мәрхәмәтеннән ташламаса, йөз иллегә дә җитәрбез, иншалла.

Г и б р а л т а р. Җитәрсең, җитәрсең. Аңарчы бөтен авылны нервынныйга әйләндерәсең әле син.

М и ң н и с а *(чәйнегенә ишарәләп)*. Менә суым түгелеп хараплар булды бит әле. Икестырасилуска шифа иңдерергә дип алып килгәнием. Тагын алып киләсем була инде. Чишмәдән очыртып кына алып кайтканыем...

Г и б р а л т а р. Очырткансыңдыр инде бик, бу ташбака аякларың белән. *(Кулындагы сәгатенә карый.)* Синең белән әвәрә килеп, ярты көнем әрәм булды. Бар, бар, торма монда бакча карачкысы кебек. Кайт өеңә! Мунча як!

М и ң н и с а. Мунча?! Нишләп әле тиктомалдан мунча ягыйм мин?

Г и б р а л т а р. Тиктомалдан түгел. Кирәк булганга!

М и ң н и с а. Кемгә кирәк булганга? Сиңамы? Синең бит, Гыйб... әйем лә... Кә-шә-бет-дин-уф эф... эф-ән-де, улым, үзеңнең алагаем зур мунчаң бар. Эскерт чаклы.

Г и б р а л т а р. Миңа түгел, Ходай бәндәсе. Синең үзеңә кирәк. Экстрасенс иптәш сеанстан сиңа кайтыр. Юлдан килгән кеше. Мунчаң бик әйбәт кенә булыр үзенә. Берочтан үзеңне дә карар.

М и ң н и с а. Мунчадамы?

Г и б р а л т а р. Абзардамы, диген тагын... Нишләп мунчада карасын инде, өеңдә карар!

М и ң н и с а. Чынлаплар әйтәсеңме, Гыйбрәт улым? *(Ялгышын төзәтмәкче була.)* Әфәнде улым? Карт кешене шаяртуың гына түгелдер бит?!

Г и б р а л т а р. Чынлап инде, чынлап! Ахирәт корткаларыңны да чакыр. Сине карагач, аларны да карар.

М и ң н и с а. И-и-и... Бигрәкләр дә кешелекле кеше инде син... эф-фән-де улым. Аллаһы Тәгаләдән рәхмәтләр яусын үзеңә. Берүк мәрхәмәтеннән ташламасын. Минем ни инде... ырматиз. Аякларым бик яман сызлап интектерә. Төннәр буе улап чыгам.

Г и б р а л т а р. Мин, җүләр, нинди бүре улый соң дип, төннәр буе йоклый алмый ятам тагы. Син булгансың икән, Миңнисаттәй.

М и ң н и с а. Көлмә, көлмә, улым... әфәнде. Менә шул... ике... ике... икестырасилуста инде бөтен өметкәйләр. Икестырасилусларның куллары бик шифалы була икән дип әйтеп-әйтеп әйтәләр бит. Аннан соң, беләкләрем дә бик каты сызлый. Билкәем авыртып җәфалый. Күкрәгемдә дә нәрсәдер өзелеп-өзелеп киткәндәй була. Тешләрем дә капка баганалары кебек селкенеп тора. Аларын да карар микән икестырасилус?

Г и б р а л т а р. Карый инде, карый. Кайсы төшеңне күр-сәтсәң, шул җиреңне карый. Бар, бар... Кайт та тизрәк, мунчаңны як! Дасвидание!

М и ң н и с а. Кайтам, кайтам... Очыплар кайтам. Рәхмәт-лар яусын үзеңә, эф-фәндекәем! *(Баскычтан залга төшәргә азаплана.)* Шушы җәһәннәм баскычыннан гына төшәм дә кайтам... Кайтам да дөрләтеп җибәрәм мунча мичен. Абыныплар гына хараплар булмасам... Лә хәүлә вәлә куәтә...

Шулай быдыр-быдыр сөйләнә-сөйләнә, чәйнеген шалтырата-шалтырата, Миңниса чыгып китә.

Г и б р а л т а р. Үземнең дә кайчак баш эшләми тора. Әллә кайчан ук шулай дип кенә алдап-йолдап җибәрәсем калган икән бу карт үрдәкне. *(Миңниса чыгып киткән якка карый.)* Персидәтелнең алтыпочмаклы мунчасына бармыйча, синең туксан тугыз җирдән йомран кебек җил сызгырып торган черек утын өеменә кайтты ди экстрасенс. Аның башына тай типкән ди... Әһе, көтеп тор!

Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Л ә й с ә н керә. Колакларында наушник. Ул колакларында яңгыраган ниндидер җыр тәэсирендә селкенгәләп, башын дәртле чайкалдырып, сәхнәгә менә. Кулына микро-фон тоткан кыяфәт ясап җырлый башлый.

Л ә й с ә н. Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсуланам,
Бәгырькәем, сине күрдисәм...

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга да Ләйсәннең кыланмышын күзәтә.

Г и б р а л т а р. Кызым! Ләйсән, дим! Нишләвең бу?

Ләйсән Гибралтарны күреп ала. Җыр тәэсиреннән арына алмыйча селкенүен дәвам итә.

Л ә й с ә н. Әти! Экстрасенслар килмәдеме әле? *(Науш-нигын сала.)*

Г и б р а л т а р. Юк әле. Ниемә кирәк алар сиңа?

Л ә й с ә н *(селкенүеннән туктап, әтисе янына килеп)*. Болай гына соравым. Бөтен авыл халкы көтә бит. Чиләк-ләп, чәйнекләп ташый-ташый, колонканың суын бетерәләр инде.

Гибралтар *(кызының кыска күлмәк итәгенә ишарәләп)*. Тагы да кыскарак күлмәгең юк иде мәллә?

Ләйсән *(боргаланып)*. Бар иде. Табалмадым. Әни каядыр яшереп куйган бугай.

Гибралтар. Дөрес эшләгән. Бар, монда чуалма. Хәзер кешеләр килергә тиеш монда. Экстрасенслар килеп төшсә, «Кайдан килгән цирк артисты бу?» дип уйларлар үзеңне.

Ләйсән. Уйласалар тагы. Бик исем китте.

Гибралтар. Бар, кызым, бар. Кайтып, озынрак күлмәгеңне ки. Минем эшем күп. Төшке ашка кайтып тормам. Әниеңә әйтерсең. *(Бүлмәсенә кире кереп китә.)*

Ләйсән янә сәхнә уртасына чыгып баса.

Ләйсән *(хыялга-хискә бирелеп)*. Җырлый Ләйсән Фәт-хетдинова!

Шулвакыт Салават керә.

Салават. Ниткән Фәтхетдинова ул тагы? Кәшәфет-динова бит син!

Ләйсән. Салават?!

Салават. Салаватын Салават... Тик Салават Фәтхетдинов кына түгел. Салават Корбыев булыр абзаң!

Ләйсән. Фи! *(Җирәнгән сыманрак.)* Кор-бы-ев... Шу-шы да булдымы фамилия. *(Сокланып.)* Фәтхетдинов! Менә бу фамилия ичмасам!

Салават. Шул Салават Фәтхетдиновың белән җенләнәсең бугай инде. Күбрәк мине уйла син, мине! *(Ләйсәнне кочып алмакчы була.)* Мин дә Салават бит!

Ләйсән *(читкә тайпылып)*. Тс-с-с! Әти монда! *(Чытлыклана, кылана.)* Синең фамилияң җүнле түгел шул... Кор-бы-ев... Ләйсән Кор-бый... Юк, яңгырамый... Фамилияңне кыскартсаң да булмый... Пшыйк!

Салават. Бабай Корбый исемле булганга мин гаепле түгел инде.

Ләйсән. Аннан соң, җырлый да белмисең...

Салават. Минме? Җырласам, синең Салават Фәт-хетдиновың шикелле генә җырламыйм инде мин.

Ләйсән. Хәчтерүш! Мактанган була тагы. Салават Фәтхетдиновка җитәргә әле сиңа. Сыерлар тоз ялаганда, бозаулар ими имә. Минем бабай синең ишеләргә шулай ди. *(Салаватның борынына бармагын тидереп ала.)* Вәйт!

Салават. Көлмә, көлмә... Синең бабаң белеп әйтми ул... Син менә мин җырлаганны тыңла башта. *(Җырларга әзерләнә.)*

Ләйсән *(нәфис сүз осталарына охшатып)*. Сәхнәдә – Салават Фәтхетдинов! Әй лә... Салават Корбыев!

С а л а в а т *(нәкъ Салават Фәтхетдинов кебек кыланып, сөйләмтавышын да аңа охшатып)*. Кадерле тамашачылар, әбиләр, апалар, кызлар! Хәзер мин сезгә өр-яңа бер җыр сылаем!

Л ә й с ә н *(кулларын чәбәкләп)*. Афәрин!

С а л а в а т *(җырлый)*.

Урамнардан уйнап киткәнем бар,
Иптәш итеп бала-чаганы.
Акыл тешем күптән чыккан инде,
Акыл ягы гына чамалы-ы-ы...

Мин һаман да унсигездә кебек,
Йөрәк һаман шулай түземсез.
Тик унсигез яшьлек кызлар гына:
«Абый, абый! Салават абый!
Салават абый! » – диләр, шунсы күңелсез...

Л ә й с ә н. Браво, Салават! Афәрин, Салават! *(Бармагын авызына кабып сызгырып җибәрә.)*

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Салават Фәтхетдинов килгән мәллә дип торам. Нинди бака туе монда? *(Ләйсәнгә.)* Әле син кайтып китмәдеңмени?

С а л а в а т. Без... ни... Гибралтар абый... Ләйсән бит әнә... Җырларга куша...

Л ә й с ә н. Минме? Мин куштыммы? Җырлый белсәң ярар иде...

Г и б р а л т а р. Барыгыз, бар... Чуалмагыз монда. *(Ләйсәнгә.)* Әйттем бит инде мин сиңа, кызым.

Л ә й с ә н. Китәбез, эти, китәбез. Киттек, Салават... *(Мыскыллы елмая.)* Фәт-хет-ди-нов!

С а л а в а т. Ә син... ә син... *(Сүз табалмый тора.)* Мәчтүрә!

Чыгып китәләр.

Г и б р а л т а р *(артларыннан кычкырып)*. Ләйсән! Туп-туры өйгә кайт! *(Үзалдына.)* Филармония! Тфү! *(Кулын селтәп ала да бүлмәсенә кереп китә.)*

Тышта җыр тавышы ишетелә. Бераздан зал ишеге ачылып китә дә аннан салмыш Х ө б б е л керә. Изүләре шыр ачык. Каралып беткән юка чүпрәк кепкасын алдын артына әйләндереп кигән. Алпан-тилпән килеп, яшелле-зәңгәрле тавыш чыгарып җырлый-җырлый, сәхнәгә таба атлый.

Х ө б б е л. Югарочтан түбәночка
Тәгәрәтәләр мичкә.
Әби, кызың бигрәк нечкә,
Түзәр микән бер кичкә?..

*(Хөббел җырның соңгы ике юлын янә бер мәртәбә кабатлый да, баскыч турысына җиткәч туктый. Гибралтар бүлмәсенә карап кычкыра.)* Гыйбрай! Выходи, подлый трус!

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Нәрсә акырасың, одеколон бүчкәсе?

Х ө б б е л. Син үзең бүчкә! *(Гибралтарның бүлтәйгән корсагына ишарәли.)* Ит бүчкәсе!

Г и б р а л т а р. Хөбби, эчкәнсең икән, буеңа сеңдер. Ничу монда кешене мыскыл итәргә!..

Х ө б б е л *(көйләп)*. Не шуми, друг, а то вдруг... *(Бармагын кыңгырау төймәсенә баскандай итә.)* Челтер-рефун! Здрасте! Слесаря вызывали?

Г и б р а л т а р. Әйдә, әйдә, артистланма! Керсәң кер бүлмәгә, кермәсәң – дүрт ягың кыйбла! Минем болай да вакыт юк! *(Бүлмәсенә кереп китмәкче була.)*

Х ө б б е л *(баскычтан менмәкче була, ләкин артка сөрлегеп)*. Гыйбрай! Руку давай! А то баскычың өскә шуа...

Г и б р а л т а р *(Хөббелгә якынрак килеп, кулын сузып)*. Әйдә, әйдә, тизрәк бул. Персидәтел килгәнче сөйләшеп куярга кирәк.

Х ө б б е л. Ыслушай, Гыйбрай! Төкерәм мин синең персидәтелеңә! Мин үзем персидәтел! Понял!

Г и б р а л т а р. Понял, понял. Тагын йөз грамм манчысаң, район башлыгы булырга да ерак калмый сиңа. Әйдә, кер тизрәк!

Х ө б б е л. Кермим! Монда гына алып чык!

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

Х ө б б е л. Ыслушай, Гыйбрай! Әллә син дә исәр Кафил кебек полоумный инде? Әле генә йөз грамм манчытам дип әйттең бит...

Г и б р а л т а р. Ну, зимагур... Ну, Хөбби...

Х ө б б е л. Саранланма, Гыйбрай. А то Хөббел умирай... Давай, быстро шагай! Одеколонның махмырын үзең беләсең – егылдым-үлдем булыр... Ник чакырганыңа үкенерсең аннары...

Г и б р а л т а р. Бүлмәгә кереп салсаң булмыймы?

Х ө б б е л. Булмый. Кәтигәрический против. Синең бүл-мәнең исе ярамый миңа. Аллергия! Теге вакытны кереп эчкәнгә да үкенеп беталмыйм. Очкылык тотып, өч көн мучыйтсы иттем.

Гибралтар үз бүлмәсенә кереп китә. Хөббел, кулларын артка куеп, канәгать елмаеп, сызгырына-сызгырына, ишек төбендә йөренә. Яртылаш аракы салынган стакан тотып, Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Мә, кеше күргәнче салып куй. Закуска юк. Кипкеңне иснәрсең.

Х ө б б е л. Аның иснәрлеге калмады инде. *(Стаканны кулына тота.)* Ну саран да кеше инде син, Гыйбрай. Шуны тутырып булмый идеме? Җә, ярар, кабат алып чыгарсың. *(Аракыны җәһәт кенә авызына коя да*

*Гибралтарның пиджак очын тотып исни.)* Үземнең кәчтүмгә «Тройной» одеколон түгелгән иде. Җә, укшып, аракыны кире чыгарып әрәм итәрмен...

Г и б р а л т а р. Булдымы, Хөбби?

Х ө б б е л *(бераз дәшми торганнан соң)*. Пока булды. Яхшы пошёл. Давай, әйт инде хәзер... Ник чакырдың?

Стаканны Гибралтарга бирә. Гибралтар аны кесәсенә тыга.

Г и б р а л т а р. Менә-менә экстрасенс иптәш килеп җи-тәргә тиеш.

Х ө б б е л. «Экстра» дисең, берәр аракы заводы директоры мәллә?

Г и б р а л т а р. Мин сине тыңладым. Йөз грамм эчердем. Хәзер инде син мине тыңла. Юк-бар сораулар бирмә. Экстрасенс ул – чирле кешеләрне дәвалый торган иптәш-әфәнде. Менә шул иптәш-әфәнде главный ярдәмчесе белән бергә безнең авылга килә.

Х ө б б е л. Аңлашылды.

Г и б р а л т а р. Нәрсә аңлашылды?

Х ө б б е л. Синең ул экстрасинусың безнең авылны терелтергә дип килә.

Г и б р а л т а р. Авылны түгел, авыл халкын терелтергә килә.

Х ө б б е л. Барыбер инде. Авылы да чирле, кешеләре дә. Мин генә сау-сәламәт! Шәһәрдә слесарь булып эшләп кайтмаган булсам, мин дә сезнең кебек чирләшкәгә әйләнгән булыр идем.

Г и б р а л т а р. Тыңла, Хөбби. Сөйләп бетергәнне көт. Менә шул экстрасенсның главный ярдәмчесе беркөнне килеп мине күреп китте. Шул әйтте, бер-ике кеше әзерләп куй, диде. Мәһәреннән тормабыз, диде. Без кушканны эш-ләр, диде.

Х ө б б е л. Аңлашылды.

Г и б р а л т а р. Нәрсә аңлашылды?

Х ө б б е л. Димәк, мин маймыл булам. Шимпанзе, ягъни мәсәлән. Ә синең экстрасинусың тәҗрибә үткәрә... Күпме эчәргә кирәк?

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

Х ө б б е л. Соң... Нәрсә булсын инде? Аракы! Ул экстрасинусың миңа аракы эчерә, мин исермим. Ул миңа тагын эчерә, мин исермим...

Г и б р а л т а р. Дөрес аңламагансың, Хөбби. Аракыны син соңыннан эчәсең. Ә сәхнәдә басып кына торасың.

Х ө б б е л. Һәйкәл кебекме?

Г и б р а л т а р. Әйе. Һәйкәл кебек. Ләкин минем үз гомеремдә селкенеп торган һәйкәл күргәнем юк әле. Селкенмичә басып торалasыңмы?

Х ө б б е л. Бер дә әйтә алмыйм бит. Моңарчы алай басып торган булмады. Коймага сөялеп торган бар. Бәлки, сөялеп кенә торыргадыр?

Г и б р а л т а р. Ярар, монысын экстрасенс иптәш килгәч хәл итеп бетерербез. Бәлки әле, урындыкта гына утырып торырсың.

Х ө б б е л. Яхшы! Тик син урындыкның тазасын әзерләп куй. Ялгыш аяклары чыгып очарлык булмасын... Ятарсың аннары идәндә адәм мәсхәрәсе булып!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Анысын гына карармын. Син риза инде алайса? Кара аны, падвадит итмә!

Х ө б б е л. Шту син! Шту син! Беләсең бит инде, Гыйбрай... Аракы бирәм дисәләр, мин лампочка шикелле эленеп торырга да риза.

Г и б р а л т а р. Килештек алайса?! *(Хөббелгә кулын суза.)*

Х ө б б е л. Килештек... *(Хөббел дә кулын суза да кинәт кире ала.)* Ә-ә-ә... юк!

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы?

Х ө б б е л *(хәйләкәр елмаеп)*. Тагымы? Алып чык тагы! *(Гибралтарның кесәсендәге стаканга ымлый.)* Шуннан соң по рукам!

Г и б р а л т а р. Булсаң да булырсың икән бүрәнкә авыз.

Х ө б б е л. Җә, җә, чәпчемә. Алып чыксаң алып чык... А то... киттем-бардым булыр...

Гибралтар бүлмәсенә кереп китә дә аракылы стакан
тотып кире чыга.

Г и б р а л т а р. Сеанска алданрак килеп утырырсың. Ка-ра аны! *(Стаканны Хөббелгә суза.)*

Х ө б б е л *(җәһәт кенә эчеп куя да җиңен иснәп)*. Синең бүлмәгә килергәме?

Г и б р а л т а р. Нишләп минем бүлмәгә булсын... Залга! Алгы рәткә утырырсың. Анда сиңа урын булыр.

Х ө б б е л. Понятно! Экстрасинусыңа әйтеп куй. Хөббел килә, диген! Бармотухалар белән вакланмасын. Денатураттан болай да туйган! Чын аракысы булмаса, сәхнәгә атлау түгел, үрмәләп тә менмим. Безовсяки алдаусыз әйтәм. Мин әйтсәм – үзең беләсең... Хөббел әйттеме, ул – закун!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Бар, кайтып бераз йоклап ал... Кеше кыяфәтенә кер...

Х ө б б е л. Менә монысы булмас, Гыйбрай. Йоклап ятып, авызга керергә торган аракыдан колак кагасым юк! Шалиш! Үзең беләсең, мин йокласам каты йоклыйм. Ник шунда калхузыгызның барлы-юклы сигез тракторы килеп пытырдамый – селкенмим дә!

Г и б р а л т а р. Анысы бар икән шул... Син, алайса, ничек тә йоклама инде, Хөбби.

Х ө б б е л. Есть, тавариш генерал! Один солдат умирал, Хөббел абзаң өендә, калганнары пелиндә!.. Гыйбрай! Мин киттем... Закускалар хәстәрләп куй! Первый... Втарай... И тагдалие... *(Җырлый-җырлый залга төшеп китә.)*

Зимагурны шуннан таныйм –
Сул ягында кесәсе.

Кесәсеннән күренеп тора
Одеколон шешәсе-е-е... *(Чыгып китә.)*

Гибралтар *(артыннан карап)*. Филармония! Закуска сиңа... Первый... Втарай... Тфү! Тот капчыгыңны! *(Бүлмәсенә кереп китмәкче була.)*

Шулвакыт, су тутырылган ун литрлы банка күтәреп,
залга Кафил керә.

Кафил *(Гибралтарга таба килә-килешкә кычкырып)*. Дирехтыр абзый! Менә-ә! Булды!

Гибралтар *(Кафилгә бермәл текәлеп карап)*. Булдымы, бырат? Булса, күтәр ыштаныңны!

Кафил атлавыннан туктый да, бер кулы белән банканы кочаклап, икенчесе белән чалбарын күтәрмәкче була.

Кафил. Чалбарыңны диген, дирехтыр абзый... Ыштан түгел бит бу... Хәзер күтәрәм...

Гибралтар. Нишлисең син, яп... яланаяк! Төшереп ватасың бит банканы!

Кафил. Яп-яланаяк бернишләмим... *(Каушаудан банкасын чүт кулыннан ычкындырмый.)* Үзең бит, дирехтыр абзый... Үзең бит күтәрергә кушасың, ы-ы... чалбарны... *(Бер кулы белән чалбарын өскә тартып тора.)*

Гибралтар. Вәйт, тиленәр сыңары! Күтәрмә ыштаныңны, төшер! Мин бит болай гына әйттем. Сүз өчен генә. Әйдә, кил монда тизрәк! Сак бул, банканы вата күрмә!

Кафил *(кузгалмыйча)*. Төшериммени, дирехтыр абзый?

Гибралтар. Нәрсәне?

Кафил. Чалбарны-ы...

Гибралтар *(ярсуыннан үзен-үзе кая куярга белмичә)*. Үзем дә җүләрләнәм бугай инде. Кафил туган! Быр-рат! Ускәнем! Акыллым! Тилекәем! Тимә ыштаныңа! Җибәр кулыңны каештан! Зинһар, ике кулың белән дә тот банканы. Хәзер акрын гына кил монда. Берүк сак атла...

Кафил баскыч янына килеп җитә.

Кафил. Баскычтан менимме, дирехтыр абзый? Мин менә беләм!

Гибралтар. Мен әйдә, мен. Ә юк! Стоп! Җә банканы харап итәрсең. Шунда гына тор. *(Баскычтан төшә дә Кафил кулыннан банканы ала.)*

Кафил. Мин маладис, әйеме, дирехтыр абзый?

Гибралтар *(баскычтан менә-менә)*. Маладис, маладис... Уф!..

Кафил аның артыннан иярә.

К а ф и л. Җывачка бирерсең инде, җәме, дирехтыр абзый?! Маладис та булгач...

Г и б р а л т а р *(банканы сәхнә уртасындагы башка сулы савытлар янына идәнгә куеп)*. Бирермен, бирермен... Берне түгел, икене бирермен... *(Билен турайтып баса.)* Уф!.. Авыр икән шул бу!

К а ф и л. Авыр шул, дирехтыр абзый. Мин дә көчкә күтәрдем!

Г и б р а л т а р. Чишмәдән алгансыңдыр бит суны?

К а ф и л. Әйе, дирехтыр абзый! Чишмәдән алдым. Мин тагын маладисмы?

Г и б р а л т а р. Маладис, туган, маладис!

К а ф и л *(сөенеп)*. Алайса, тәмәке дә бирерсең инде, җәме, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Тәмәке? Нәрсәгә ул сиңа?

К а ф и л *(ботинкасының очы белән идәнне чокып)*. Тартырга инде, нәрсәгә булсын тагы...

Г и б р а л т а р. Синең бит башың яшь, Кафил туган. Нәрсәгә дип тартасың аны?

К а ф и л. Кызык бит.

Г и б р а л т а р. Нәрсәсе кызык аның?

К а ф и л. Авыздан төтен чыгуы кызык.

Г и б р а л т а р. Һе! Төтен моржадан да чыга ул. Менә анысы кызык, ичмасам!

К а ф и л. Ю-ук, морҗаныкы кызык түгел. Авыздан чыкканы кызык. Хөббел абзый танавыннан да чыгара белә. Анысы тагы да кызык!

Г и б р а л т а р. Хөббел абзаңа карама син. Алкаш бит ул! Ул сиңа әллә кайсы җирләреннән чыгарып күрсәтер. Син менә миңа кара – миннән төтен чыкмый бит!

К а ф и л. Ы-ы-ы... Син бит дирехтыр абзый! Дирехтыр абзый булсам, миннән дә төтен чыкмас иде.

Г и б р а л т а р. Җә, ярар, күп сүз – чүп сүз. Тәмәке юк! Кәнфит бирәм.

К а ф и л. Кәнфит кирәкми. Җывачка бир! Күп итеп акча да бир. Тәмәке алырга җитәрлек булсын! Җәме, дирехтыр абзый?!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар... *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

К а ф и л *(үзалдында сөйләнеп)*. Тиле дигәч тә... Чишмәгә йөгертмәкче була мине. Барды ди ул хәтлүк еракка. Колонкада су була торып...

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Мә, Кафил туган! Тәмләп чәйнә! *(Бер сагыз бирә.)*

К а ф и л. Берәү генәмени? Икене бирәм, дидең бит?!

Г и б р а л т а р *(кесәсеннән янә бер сагыз чыгарып)*. Әй, монысы кесә төбендә онытылып калган икән...

К а ф и л *(сагызны алып)*. Ә акча?

Г и б р а л т а р. Уф!.. Авызында сагыз, кулында сагыз... Үзең дә чистый сагыз булырсың икән... Мә, мә! Бөтен булганы шул. Бүтән юк.

К а ф и л *(кәгазь акчаны алып)*. Тәмәке алырга җитәме бу, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Җитә инде, җитә! Тәмәке алмасаң, ике сагызга какырас җитә. Бар, бар! Кибеткә чап инде хәзер!

К а ф и л *(китмәкче була да, кинәт туктап)*. Дирехтыр абзый!

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы? Нишләп китмисең инде?

К а ф и л. Тагын алып килимме?

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

К а ф и л. Су алып килимме тагы? Тегесен түк тә, банканы бир...

Г и б р а л т а р. Уф! *(Башын тота.)* Бар әле, бар! Җитә миңа бу су, җитә! Экстрасенс өшкереп бирсә, бер елга җитәрлек! Бар, бар! Нишлим мин ул хәтле су белән?

К а ф и л *(сагызын тәмләп чәйни-чәйни)*. Эчәрсең. Менә тагы! Битеңне юарсың... Су кирәк була инде ул. Сусыз яшәп булмый. Без өйдә чәйне гел су белән эчәбез...

Г и б р а л т а р. Уф!.. *(Йөренә.)* Уф!.. Чыда, газиз башкаем! Чыда! Бу тилеләр арасында миңгерәүләнә күрмә берүк! Кемнәр белән бәйләндем бит! Кемнәр белән бәйләндем... Кайдан гына килеп чыкты бу чәнчелгере экстрасенслар?! Үтерәләр бит мине монда хәзер... Аңгырайтып үтерәләр!..

К а ф и л. Алып килимме инде, дирехтыр абзый? *(Бармагы белән битараф кына борын тишегендә казына.)*

Г и б р а л т а р. Аһ, Ходай бәндәсе, синең телеңне бәйләп куеп та булмый бит, ичмасам...

К а ф и л. Ә нигә бәйләргә аны? Эт түгел лә ул – тел. *(Телен чыгарып, үз теленә карамакчы була.)* Нигә бәйләр-гә аны?

Г и б р а л т а р. Низна-ю! Низна-ю! Атвались атсюды!

К а ф и л. Мин дә урысча беләм... Бер сүз беләм... Хөббел абзый шәһәрдән өйрәнеп кайткан. Шул өйрәтте. Әйтимме, дирехтыр абзый?

Гибралтар сүз әйталмый, куллары белән «кирәкми» дигән хәрәкәтләр ясый.

К а ф и л. Персидәтел абзый белми икән ул сүзне. Мин аңа беркөнне әйткән идем... Аңламады. Шуннан ул мине йодрыкларын төйнәп куарга тотынды. Миннисаттәйләр өенә чаклы куды... Тоттырмадым! «Пафтаринука! Пафтаринука!» дигән була... Нәрсә дип әйтүе булгандыр... Әй, тиле кешенең нәрсә әйткәнен аңлап буламыни аны!

Г и б р а л т а р *(көч-хәл белән)*. Үт-терә-сең!.. Бар, чыгып кит!

К а ф и л. Филдшер абзыйны чакырыйммы, дирехтыр абзый? Хәзер алып киләм мин аны. Өендә микән, ат печәргә китте микән?..

Кафил чыгып китмәкче була. Каршысына ашыгып керүче Самат очрый. Самат Кафилгә йодрыгын селки. Тегесе, телен күрсәтеп, җәһәт кенә чыгып сыза.

Самат. У-ух, мин сине, тиле тәре!

Самат, җил-җил атлап, мөдир бүлмәсенә таба атлый. Гибралтар, сызланып-ухылдап, аны көтеп тора.

Гибралтар *(күрешергә кулын сузып)*. Саумы, абый? Өеңдә бер көедер бит? Җиңги сау-тазамы?

Самат *(күрешеп)*. Нәрсә булсын аңа? Селкенә шунда.

Гибралтар. Селкенгәч ярый инде. Селкенмәсә нишләр идең...

Самат *(лозунгларны бер кат күздән кичереп)*. Син нәрсә, үләргә җыендың мәллә? Бөтенләй төсең качкан. *(Зал ягына ишарәләп.)* Нишләп йөри ул Фатыйма тилесе?

Гибралтар *(кулын селтәп)*. Әй... Экстрасенс өшкергән су файдалырак булсын дип, Ерак чишмәдән су китерткән идем. Башымны катырып чыгып китте. Тилебәрән орлыгы ашаган, дуңгыз малай...

Самат. Чучка, диген! Чучкасы хужырак.

Гибралтар. Барыбер инде.

Самат. Тилегә йомыш кушмасаң, башка кеше беткән идеме?

Гибралтар. Ун литрлы шешә белән су алып килде. Аны Хөббелгә кушалмыйм бит инде. Аңа кушканчы, шушы җүләре лутчырак булмасмы дигән идем...

Самат. Су дигәннән, миңа да ике битун су китереп куярлар. Сәхнәнең урта бер җиренә куйдырт.

Гибралтар. Шулай итәрмен, абый.

Самат *(сәхнәдәге банкаларга, шешәләргә карап йөри, сулы бер аракы шешәсен кулына ала, борынына ук якын китереп иснәп)*. Чынлап та су икән. Аракы мәллә дип торам. *(Шешәне кире урынына куя.)* Артистлар икәүме әле алар?

Гибралтар. Икәү, икәү, абый. Экстрасенс иптәш и ас... ас... ассис... тисент! Үзе и ярдәмчесе.

Самат. Килгәч, аларны ашханәгә алып барырсың. Анда аларга коешто әзерләнеп куелган. Үзең оештырырсың. Алар белән минем булалмавым ихтимал. Штобы тәртип булсын! Артыгын җилпетмә! Калганнарын үзеңә алырсың. Шулар чутыннан списать итәрбез.

Гибралтар. Рәхмәт, абый. Барысын да син әйткәнчә эшләрмен. Экстрасенс иптәшләр довольный калырлык итеп эшләрмен.

Самат. И ишшё! Иптәшләргә әйтеп куярга онытма. Концерттан соң миңа кайталар. Җиңгәң мич каршында нәрсәдәр маташтырып калды анда.

Гибралтар. Концерт дип, концерт түгел инде ул, абый. Сеанс.

Самат. Неважны анысы. И ишшё! Түләү мәсьәләсендә борчылмасыннар. Сөйләшкәнчә, бер сыер – аларныкы! Какырас көтүдән бер сыер күбенеп, үлә язып кайткан иде. Шуңа тагын бер сыерны

плюсовать итәрмен. Күз төшереп йөргән бер кысыр сыер бар иде. Шуны икебезгә хәл итәрбез.

Г и б р а л т а р. Рәхмәт, абый. Болай да гел булышып торасың инде.

С а м а т. Бертуганга да булышмагач, кемгә булышыйм тагы. Чит-ят авызларга *(бармагын өскә күтәреп)* болай да китеп бара инде. Вакытыннан файдаланып калырга кирәк! Кара аны, иптәш артистларга «күбенеп үлә язган сыер иде» дип ычкындыра күрмә тагы!

Г и б р а л т а р. Син нәрсә инде, абый! Колхоз серен сатарга кем дип белдең син мине!

С а м а т. И ишшё! Иптәшләрнең концертын ачып бер-ике сүз әйтергә килеп җитәрмен. Йомгаклау сүзен дә үзем әйтерменме, әллә сиңа әйтергә туры килерме – анысын на месте хәл итәрбез. Обстоятельствага карап...

Г и б р а л т а р. Яхшы. Шулай итәрбез, абый.

С а м а т. Кая, ниме, тамак чылатырга берәр нәрсәң юкмы? Минем машинада бар барын...

Г и б р а л т а р. Сорап торасың тагы, абый. Әбизәтелне бар. Әйдә, керик минем кабинетка.

Абыйсын бүлмәсенә уздыра. Шулвакыт зал ишегеннән бәйрәмчә киенгән, бизәнгән-ясанган Ф а т ы й м а керә. Кергәч тә чәчләрен төзәткәләп ала.Аннан, тырт-тырт басып, Гибралтар бүлмәсенә
таба атлый.

Ф а т ы й м а *(ишек янына килеп җитәр-җитмәстән)*. Гибралтарчик! Син мондамы?

Фатыйма ишекне ачам дигәндә генә, Гибралтарның башы күренә.

Г и б р а л т а р. Монда булсам ни диярсең? Нәрсә кирәк, Фатыйма?

Ф а т ы й м а *(кыланчыкланып)*. Нихәл, Гибралтар? Мин эчкә узыйммы соң, син монда чыгасыңмы дигәндәй...

Г и б р а л т а р *(ишектән гәүдәсен яртылаш кына чыгарып)*. Ни йомыш?

Ф а т ы й м а. Йомыш дип...

Гибралтарны этәреп, авызындагы ризыкны тәмләп чәйни-чәйни, С а м а т чыга.

С а м а т. Син нишләп фермада түгел?

Ф а т ы й м а. И-и... Самат Мансурович та монда икән. Исәнмесез, Самат Мансурович!

С а м а т *(төксе генә)*. Исән әле. Мин әйтәм, син нишләп фермада түгел, дим?

Ф а т ы й м а. Калхуз эшен эшләп үләр хәлем юк әле, Самат Мансурович. Әзрәк ял итим, дидем. Кафилгә дә күз-колак булырга кирәк.

С а м а т. Нинди ял ул тагы? Казаннан себерелеп кайтканыңа ничә ел! Җүнле-башлы эш күрсәткәнең юк. Һаман ир-атларның аяклары арасында чуаласың... Туймасаң туймыйсың икән!..

Ф а т ы й м а. Туярсың сезнең белән. Тол хатынның күңелен күрерлек җүнле ир-ат та юк бит авылда.

Г и б р а л т а р. Башкаларга яраган сиңа ярамый инде...

Ф а т ы й м а. Башкаларга ярый торган кирәкми миңа, үземә ярый торган кирәк!

С а м а т. Үзеңә яраганны Казаннан эзлиләр аны, авылга кайтып егылмыйлар...

Ф а т ы й м а. Казанның исеменнән башка ние бар соң аның?

Г и б р а л т а р. Чит илгә бар әнә.

Ф а т ы й м а. Бик барырыем да, акчам гына юк. «Сыер, сыер! Сөт! Сөт!» дигән булып, көне-төне изаланасың, акча түләргә уйлаган кеше юк.

С а м а т. Җә, җә, чәпчемә Фатыйма. Синдә акчаның беткәне юк. *(Гибралтарга.)* Ярый, Гибралтар, мин ашыгам. Бетмәс монда Фатыйманың кирле-мырлы сүзләре. Ка-ра аны, мин әйткәннәрне онытма. Тәртип булсын!

Г и б р а л т а р. Барысы да тәртип булыр, абый. Борчылма.

Самат чыгып китә.

Ф а т ы й м а. Сау булып торыгыз, Самат Мансурович. *(Гибралтарга.)* Эчеп чыгарга кергәнме абыең?

Г и б р а л т а р. Анда синең ни эшең бар? Җә, ник кил-деңә Монда килгәнеңне хатын белсә, бәреп үтерә бит хәзер сине.

Ф а т ы й м а. Фи! Курыктым ди синең карачкыңнан. Син калтырап яшә аны!

Г и б р а л т а р. Үзең дә әллә кем түгел. Кагылма аңа! Аның сиңа зыяны тигәне юк әле.

Ф а т ы й м а. Тиеп кенә карасын! Малаеңны илтеп кулыңа тоттырырмын. Карарсыз шунда бергәләп!

Г и б р а л т а р. «Кафил минем малай түгел!» дип күпме әйтергә була инде сиңа, ә! Тапкан бер сүз... Синең малай! Синең малай! Казанда тапкан балаңның атасы нишләп мин булыйм? Миннән дурак тумый.

Ф а т ы й м а. Бәр-рәч! Казанга килеп, мине күрмәдем дигән буласың мәллә? Синеке булгач, кемнеке дип әйтим тагы?

Г и б р а л т а р. Ышан сиңа. Син бит сайланып тормыйсың. Кемнең чалбар каешын күрсәң, шуңа барып тотынасың. Бар, бар, йомышың булса әйт тә тай! Синең белән сайрашып торырга вакытым юк минем.

Ф а т ы й м а. Мин дә синең белән сайрашырга дип кил-мәдем. Белешергә генә дип килдем.

Г и б р а л т а р. Нәрсә белешергә?

Ф а т ы й м а. Экстрасенс авылда кунадыр бит?

Г и б р а л т а р. Куна. Шуннан?

Ф а т ы й м а. Кайда куна?

Г и б р а л т а р. Куначада!

Ф а т ы й м а. Шаяртма әле, Гибралтар. Мин бит чынлап сорыйм.

Г и б р а л т а р. Сиңа кайда кунса да барыбер түгел-мени?

Ф а т ы й м а. Кунар җире булмаса, миндә урын бар.

Г и б р а л т а р. Соңгарак калдың шул. Абый... ту ест... персидәтел аларны үзләренә алып кайта.

Ф а т ы й м а. Ничек «аларны»? Экстрасенслар икәү мәллә?

Г и б р а л т а р. Әһә. Берсе – ас... ас... сис... тисент. Ярдәмче ягъни.

Ф а т ы й м а *(шатланып)*. Соң, алайса, ярдәмчесе миңа кайтсын!

Г и б р а л т а р. Син нәрсә, бройлер тавык! Алар аерым-аерым йөрми инде. Персидәтелгә икән персидәтелгә! Всё! Бар, дасвидание! Бүлдереп йөрмә эш кешесен.

Ф а т ы й м а. Китәм, китәм... Кумасаң да китәм. *(Төзәтенеп-ясанып алгандай итә.)* Ниме соң... *(Көязләнеп.)* Үзең сеанстан кайтышлый миңа сугылып чыкмыйсыңдыр? Хәер, синең карачкы да киләдер әле клубка...

Г и б р а л т а р. Хатын анда булмый минем. Кичкә аналарына китәргә тиеш. Бар, бар, сырпаланма. Кәнтәйләнмә. Минем бүген вакытым юк.

Ф а т ы й м а. Кызганыч... Бүген бигрәк моңлы чагым иде!

Г и б р а л т а р. Ымсындырма. Барыбер ымсынмыйм. Болай да синең белән авыз бер пеште инде.

Ф а т ы й м а. Авызың пешмәсен дисәң, өреп кабалар аны. Үзең гаепле. Чәчәкле трусигыңны мунчада калдырып китмәскә иде.

Г и б р а л т а р. Ә сиңа кем кушкан аны хатынга китереп бирергә?

Ф а т ы й м а. Бәр-рәч! Мин бит аны синекедер дип бел-мәдем. Карачкыңа күрсәтергә генә алып барган идем. Мин аңа: «Су буеннан таптым. Гибралтарныкы түгелме?» – дигәнием... Ә ул, миңгерәү: «Гибралтарныкы икәнен каян беләсең? Күргәнең бармыни?» – дип, үзе чәчемә ябышты. Хәзер бит трусик-носкилар кыйбат тора. Бәлки, синең бүтән трусигың юктыр дип уйладым...

Г и б р а л т а р. Бик каты уйлагансың шул. Ә бит аны миңа, минем үземә бирә ала идең.

Ф а т ы й м а. Башта сиңа илтеп бирергә уйлаган идем дә, курыктым. Синеке булып чыкмас та, син миңа «Кемнеке бу?» дип бәйләнерсең дип курыктым. Самат абыеңның ялгыш онытылып калган оекбашларын күреп тә пыр тузындың бит. Хөббелнең тишек майкасы өчен дә күпме җенләндең. Алар чәй эчәргә генә кергәннәр ие. Мунча бик эссе булгач, салып торганнар ие. Ахырдан икесе тиң онытканнар булып чыкты.

Г и б р а л т а р. Нәрсә, алар сиңа икәүләп чәй эчәргә кер-деләрмени?

Ф а т ы й м а. Нишләп икәүләп керсеннәр инде. Син биг-рәк тагы. Самат абыең беркөнне кич кергән ие, Хөббел – икенче көнне иртән... Башын төзәтергә. Ә син алардан соң кердең – тужы чәй эчәргә...

Г и б р а л т а р. Што-то бер дә чәй эчкәнемне хәтерләмим.

Ф а т ы й м а. Хәтерләрлек хәлдә иденңмени соң – лыгырык иден бит. Ул каешыңны әйтер идем... Чынлап тартсаң өзелергә тора... Каеш дигәннән, синең каеш түгелдер бит минем өйдә?

Г и б р а л т а р. Минеке үзем белән. Бәлки, малаеңныкыдыр?

Шулвакыт К а ф и л керә.

Г и б р а л т а р. Гомере озын булыр, нәгаләт!

К а ф и л *(керә-керешли)*. Дирехтыр абзый! Син әле үлмәденңмени?

Г и б р а л т а р. Нишләп үләргә тиеш әле мин, ахмак?

К а ф и л. Үлми тор, җәме, дирехтыр абзый. Филдшер абзый килалмый. Эче китә икән. Патифун Гайшәнең бозавын печкән булган. Шуларда әллә нәрсә ашаган. Хәлең бик начарайса, үзең аның янына бар, җәме, дирехтыр абзый! Филдшер абзый шулай дип әйтергә кушты.

Г и б р а л т а р. Хәзер, шул сандугач янына гына барасым калды...

Ф а т ы й м а *(көлеп)*. Памушнигың да үзең сыңары икән... Әйдә, улым, кайтыйк өйгә. Сеанска кадәр мунча да кереп чыгасым бар...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, Кафилне да алып кит әнә. Мунча кертерсең!

Ф а т ы й м а. Әйдә, Кафил улым.

К а ф и л. Исәр мәллә син, дирехтыр абзый? Әни белән мунча керергә. Мин хәзер зур бит инде! Өйләнгән булсам бер хәл ие. Ул чагында хатын белән керерием...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, әниең белән кайт! Шунда мунчада өйләндерер ул сине берәр кыз белән.

К а ф и л. Кит әле, дирехтыр абзый. Мунчада өйләнмим мин!

Ф а т ы й м а. Өйләнмә, өйләнмә, улым. Бу дирехтыр абзыең әллә ниләр сөйләр ул. Тыңлама син аның сүзләрен. Тиле бит ул!

Г и б р а л т а р. Тилерерсең дә монда сезнең белән. *(Фатыймага.)* Бар инде, бар... Буксовать итеп торма монда. Мунча пәриләреңне көттермә.

Ф а т ы й м а. Киттем, киттем. Улым, үз вакытың белән кайтырсың. Дирехтыр абзыеңны тагын бераз йончыт та.

Г и б р а л т а р *(Кафилгә)*. Ә син нишләп торасың, бас-тырык?

К а ф и л. Бә-әй! Оныттың дамыни? Филдшер абзыйга барып килдем бит. Әйт инде, маладис, диген!

Г и б р а л т а р. Бар, бар, маладис!..

К а ф и л. Хәзер акча бирәсеңме инде, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Нинди акча ул тагы?

К а ф и л. Бә-әй... Маладис, дидең бит...

Г и б р а л т а р. Уф! Бар әле, бар... Башны катырмале! Миндә акча ясый торган машина юк!

К а ф и л. Алайса, җывачка бир!

Г и б р а л т а р *(ачуына чыдый алмыйча)*. Вәйт, ананңны эт орган!.. Үз башыма гына ияләштердем мин сине. *(Йөзен чыта.)* Карале... Монда минем акчам да, сагызым да юк. Бетте! Иртәгә алып килермен.

Чәйнәмичә түзәрсең әле... Аһ... Бер дә кирәкмәгән вакытта... Мине хәзер зур эшләргә чакырып ил дәшә...

К а ф и л *(аңламыйча)*. Кем дәшә дисең, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Атаң башы! Ил дәшә, дим! Ил дәшә! Зур эшләргә чакырып!.. *(Үрсәләнә.)* Хәзер мин тиз генә тәһарәт алып керәм...

К а ф и л. Нәрсә, дирехтыр абзый, әллә синең дә эчең китәме? Филдшер абзыйныкы шикелле...

Г и б р а л т а р. Булсаң да булырсың икән сумала сагызы! Ыслушай, мин хәзер киләм. Син монда гына торып тор. Алай-болай мин юкта ят абзыеңнар күренсә, мине «хәзер килә ул» диярсең. Аңладыңмы?

К а ф и л. Аңладым, дирехтыр абзый. Сине сорасалар, «тышка чыккан иде, хәзер керә ул» дип әйтермен.

Г и б р а л т а р *(теләсәң нишлә дигәнне аңлатып, кулын селтәп)*. Уф, ычкынам бугай инде... *(Ашыга-кабалана ишеккә таба бара.)*

Ишек тарафында М и ң н и с а күренә.

М и ң н и с а. Гыйбрәт улым...

Г и б р а л т а р *(кулларын гасабиланып селтәп)*. Мин монда юк, мин юк! Әйдә, әйдә, атчаливай!..

Чыгып китәләр.

Кафил идәнгә утыра да, бармакларына төкереп, ботинкаларын сөрткәләргә тотына.

К а ф и л. Дирехтыр абзыйныкы шикелле ялтырап торсыннар әле...

Үз эшеннән канәгать булып торып баса да әрле-бирле йөренергә тотына. Кинәт машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Кафил, сагаеп, ишек тарафына текәлә. Бераздан иңнәренә юл букчалары аскан Г а л л ә м белән Р и ф а т керә.

Г а л л ә м *(Кафилне ерактан ук күреп алып)*. Әссәламегаләйкем!

Машина кузгалып киткән тавыш ишетелә. Кафил, бер сүз дә дәшмичә, боларга карап борын тишеген казып тора.

Г а л л ә м *(Рифатка)*. Чукрак бугай бу. *(Түргә таба атлый-атлый кабат исәнләшә.)* Әссәламегаләйкем!

Кафил һаман дәшми.

Р и ф а т. Хатипыч, тучны саңгырау!

К а ф и л. Нишләп саңгырау булыйм мин, вәйт тиле!

Р и ф а т. Алайса, нигә Галләм Хатипыч сәламен алмый-сың?

К а ф и л. Миңа бу абзыйның бер нәрсә бирәм дигәне юк бит әле!

Рифат та, Галләм дә, Кафилгә сәерсенеп карап, аны баштанаяк күздән кичерәләр.

Г а л л ә м. Син нәрсә, энекәш, әллә бераз *(чигәсендә бармак уйната)* полоумныймы?

К а ф и л *(уң кулының баш бармагын борынына төртеп, калган бармакларын селкеткәләп)*. Син үзең шундый!

Г а л л ә м. Рифат, кая килеп эләктек без?

Р и ф а т. Клуб инде бу, клуб. Әнә бит лозунглар язып элгәннәр... *(Кафилгә.)* Кайда директорыгыз? Кәшәфетди-нов кайда?

К а ф и л *(башын югары күтәреп)*. Мин калдым дирехтыр абзый урынына.

Рифат белән Галләм бер-берсенә карашалар.

Г а л л ә м. Бу авыл да барып чыккан икә-ән... Сыерны алып китеп булса ярый инде.

Р и ф а т. Персидәтел, бирәбез, диде. Борчылма, Хатипыч! *(Кафилгә.)* Исемең ничек синең, быр-рат?

К а ф и л. Кафил абзый мин, абзый!

Галләм, кулларын артка куеп, стенадагы язу-лозунгларны укый-укый йөренә.

Р и ф а т. Менә нәрсә, Кафил быр-рат...

К а ф и л. Дирехтыр абзый, диген! Мин бит аның урынына калган кеше!

Р и ф а т *(Кафилгә йөзен чытып карап)*. Ярар, синеңчә булсын. Менә нәрсә, дирехтыр абзый... Бар әле, син җәһәт кенә Кәшәфетдиновны эзләп тап! Кунаклар килде, диген... Экстрасенслар... Сручны монда килсен!

К а ф и л. Аны эзлисе юк. Тышта ул!

Р и ф а т. Бар, алып кер!

К а ф и л. Юк, чыкмыйм! Минем эчем китми лә.

Г а л л ә м. Да-а-а... Килеп җиттек, кода! Җүнләп каршы алучы да юк. Персидәтеле дә каядыр тайган. Тегесе юк, бусы юк! Оештыруың җитмәгән, быр-рат...

Л ә й с ә н керә.
Кафил, кулларын артка куеп, болар тарафына карый-карый йөренә.

Р и ф а т *(Галләмгә төртеп)*. Шәп, каһәр!

Г а л л ә м *(бармагын Рифатка «Во!» дип тырпайтып)*. Минеке бу! Класс!

Л ә й с ә н *(оялып)*. Исәнмесез!

Р и ф а т. Әссәламегаләйкем, туташ!

Л ә й с ә н. Сез экстрасенслармы?

Г а л л ә м. Шулайрак иде, туташ, ачуланмасаң.

Л ә й с ә н. Нишләп ачуланыйм инде мин сезне. Киресенчә, сөенәм генә! Миңа бик кирәк идегез сез. Ярдәм итсәгез, сез генә ярдәм итә аласыз.

Р и ф а т. Безнең Хатипыч любой чирдән дәвалый. Кайсы төшегез авырта, сылукай? Әйтегез, тартынмагыз.

Л ә й с ә н. Мин авырмыйм. Чирләрем юк минем.

Г а л л ә м. Как так? Үзегез ярдәм сорыйсыз, үзегез авырмыйсыз. Што-то аңлашылып җитмәде әле бу.

Л ә й с ә н. Мин... мин... яратам аны!

Г а л л ә м *(як-ягына каранып)*. Кемне яратасыз? *(Ка-филгә ишарәли.)* Аны мәллә?

Р и ф а т *(әле Ләйсәнгә, әле Кафилгә карап)*. Да-а... Юкәдә икән чикләвек!

Л ә й с ә н. Юк ла инде. Сез нәрсә! Аны яратам мин... *(Бушлыкка ишарәли.)* Салават Фәтхетдиновны!

Г а л л ә м<br>Р и ф а т *(бергә)*. Ә?!

Л ә й с ә н. Ну инде... җырчы Салават Фәтхетдиновны!

Г а л л ә м. Кыз-зык... Ә мин нишли алам?

Л ә й с ә н. Минем аның белән танышасым килә.

Р и ф а т. Соң, концертына барасың да танышасың инде.

С а л а в а т керә, тыңлап тора.

Л ә й с ә н. Ул мине күрүгә үлеп гашыйк булсын иде. Ә моның өчен бары тик сез генә булыша аласыз.

Г а л л ә м. Ничек итеп?

Л ә й с ә н. Сез мине үзегезчә өшкерәсезме шунда... Әллә берәр әфсен-төфсен укыйсызмы... Әй, сез бит экстрасенс-лар, үзегез беләсездер инде. Сез миңа шулай итеп ярдәм итегез – Салават Фәтхетдинов мине күргәч минсез яши алмаслык булсын!

Р и ф а т. Моны гына булдыра ул Хатипыч. Шулай бит, Хатипыч?

Г а л л ә м. Әлбәттә! Мин Чаллыда сеанслар биргәндә, Салават минем һәрбер сеанска килә. Миравай егет! Минем сеансларга пастаянны йөри-йөри менә шулай танылды инде ул халыкка. Хәзер нормальный халык аның концертына чаба да минем сеанска килә. Теләсәң, мин синең үзеңне дә җырчы итәм. Мәшһүр җырчы итәм!

Л ә й с ә н *(тагын да очынып-куанып)*. Чынлапмы?

Г а л л ә м. Только синең белән индивидуаль сеанс үткәрергә кирәк. Берничә мәртәбә. Сезнең авылда мин бер генә сеанс бирәм. Теләсәң, мин сине үзем белән алып китәм. Берничә көндә җырчы итәм мин сине. Салават Фәтхетдиновның да артыннан калмаслык итәм. Китәсеңме минем белән? Ризамы?

Л ә й с ә н. Риза, риза, китәм!

С а л а в а т. Китми генә тор әле, яме!

Һәммәсе дә Салаватка борылып карый.

Г а л л ә м *(Ләйсәнгә)*. Кем бу? Йөргән егетең мәллә?

Л ә й с ә н *(көлеп)*. Нинди йөргән егетем булсын! Салават кына ич бу! Классташ!

С а л а в а т. Беркая да җибәрмим мин сине, Ләйсән. Башыңны җүләргә салып йөрмә. Әйдә, киттек! *(Галләмгә.)* Кеше котыртып, алдап йөрмәгез монда. Әнә әби-чәбиләрнең башын катырыгыз! *(Ләйсәнне ишеккә таба тарткалый.)* Киттек!

Л ә й с ә н *(ачуланып)*. Нишләп минем арттан йөрисең син һаман? Туйдырып бетердең инде тәмам. *(Галләмгә.)* Мин риза! Мин әле сезнең сеанска да киләм!

Галләм, аңлашылды дигәнне аңлатып, елмаеп кулын селти. Салават Ләйсәнне өстерәп диярлек алып чыгып китә. Кафил һаман йөренә.

Р и ф а т. Кыз шәп!

Г а л л ә м. Үзсүзле. Китәчәк бу безнең белән. Үзе керәчәк кочакка! *(Кулын кулга сугып ала.)* Сыерны алырга да, кызны эләктерергә дә – әллүр моннан!

Р и ф а т. Хатипыч, бу авылда арттырып җибәрергә тырышма инде, җәме! Тәге юлы да чүттән генә фаш ителми калдык. Сүзләрне дә үлчәп кенә сөйлик. Алданганнарын сизсәләр, башларыбызны бот арасына да кыстырырга күп сорамаслар!

Г а л л ә м. Курыкма, Рифат дус. Сизмәсләр! Сиздермәбез! Абзаңның Сәлмән карт оныгы икәнлеген онытма. Миндә аның каны ага! Атаклы им-томчы иде минем бабай. Кайлардан гына килмиләр иде Сәлмән карт янына! Хәтта им-том, бозым-китем дигәндә үзләре дә махы бирмәгән марилар да, чувашлар да юл сапты безгә. Үлән белән дә, гипноз белән дә дәвалады бабай. Үлеп-бетеп, сөйрәлеп, күтәрәмгә калып килгәннәрнең һәммәсе дә савыгып, рәхмәтләр әйтеп кайтып китә иде... Их, бабайда булган сәләт миндә дә булса!

Р и ф а т. Акча бирәләр идеме соң бабаңа? Әллә шул коры рәхмәтләрне генә учлап кала идеме?

Г а л л ә м. Бирәләр иде... Тик алмый иде бабай... Авызына кереп чыгыйм! Әти белән мин өнәмәгән шундый гадәте бар иде бабайның. Кыстап-кыстап бирмәкче булалар... Юк, алмый тек алмый бабай. Әти сүгенеп ята мунча өйалдында... Махмырдан интегеп. Мин ухылдыйм печәнлектә. Бабайның тетмәсен тетәбез икәүләп.

Р и ф а т. Яп-ялангач кыз каршында тун өстеннән толып кия башлаган кебек булган икән гел... Бабаңны әйтәм... Импотент несчастный! Учыңа суырылып акча керсен, ә син шуны җилгә сибеп җибәр... Үзеңне уйламасаң да, калтырап яткан малаең белән ухылдап интеккән оныгың турында уйларга кирәк бит инде, ә! Махмыр бит ул любой авырудан да яман...

Г а л л ә м. Махмыр дигәннән... Бабайның Брежневны эчүдән биздерә язганы турында сөйләгәнем бар идеме сиңа?

Р и ф а т. Күптән үлгән Брежневта эшем юк. Менә сине дә, атаңны да айныталмаган бабаң. Анысы – факт!

Г а л л ә м. Тырышуын тырышты бабай... Безне дәвалау чарасын гына табалмады. Теләсә нәрсә эчеп бозылган организмга каршы көрәшергә... Ай-һай!..

Р и ф а т. Хатипыч! Тс-с-с! Кемдер керә, ахры.

Г и б р а л т а р керә.

Р и ф а т *(сөенеп)*. Әнә үзе!

Г и б р а л т а р. О-о-о... Кунак әфәнделәр килеп җиткән икән! Исәнмесез! Вәгаләйкемәссәлам! Саумысыз! Здрасте!

Күрешә. Кафил дә Гибралтарга кулын суза. Гибралтар ялгыш аның белән дә күрешә.

Г и б р а л т а р *(Кафилнең кулына сугып)*. Кит әле!.. Нишләп сәнәгеңне сузасың... *(Галләмгә.)* Әйбәт кенә килеп җиттегезме, иптәш-әфәнделәр?

Г а л л ә м. Әйбәт. Зарланырлык түгел.

К а ф и л. Мин бу абзыйларга сине хәзер керә, дидем... Мин маладисмы, дирехтыр абзый?

Р и ф а т. Маладис, маладис...

Г и б р а л т а р *(Кафилгә)*. Бар, бар, юлыңда бул.

К а ф и л *(Рифат янына килеп)*. Мин маладисмы?

Р и ф а т. Маладис, дидем бит инде. Маладис!

К а ф и л. Алайса, акча бир!

Р и ф а т *(Гибралтарга)*. Бу кем? Рэкетир мәллә?

Г и б р а л т а р *(исе китмичә кулын селтәп)*. Хужы! Ти-ле ул. Игътибар итмәгез... Ничек соң планнар? Капкалап алабыз мәллә?

Г а л л ә м *(үзен эре тотып)*. Капкалап алу зыян итмәс, иптәш...

Г и б р а л т а р *(башын ия төшеп)*. ...Кәшәфетдинов әфәнде булам!

Г а л л ә м. Бик яхшы! Очень приятны! Капкалап алмыйча булмас, Кәшәфетдинов әфәнде. Сеансны ач килеш үткәреп булмый. Энергия кирәк!

К а ф и л *(Рифатка)*. Алайса, җывачка бир!

Г и б р а л т а р. Бирегез инде шуңа берәр нәрсә! Үзенекен алмыйча туктамый ул. Мине генә бүген өч кат чишендерде инде.

Рифат кесәсеннән бер кәгазь акча алып, Кафилгә бирә.

К а ф и л. Юмарт абзый икәнсең... Тәки бирдең.

Р и ф а т. Юмарт түгел мин, саран! Понял?

Г и б р а л т а р. Урысча аңламый ул... кем... асси...сентент әфәнде.

Г а л л ә м. Кешеләр заряжать итәргә сулар китерә башлаган икән...

Г и б р а л т а р. Әлбәттә. Кәнишне. Әнә бит... *(Сәхнәдәге сулы савытларга ишарәли.)* Сулы савытларына урын занимать итә башладылар инде. Так шту, барысы да тәртиптә булыр.

Гибралтар сулы савытлар янына барып, аларны санап йөри.
Шул вакытта Галләм белән Рифат үзара сөйләшеп ала.

Р и ф а т. Эш пешәргә тиеш, Хатипыч!

Г а л л ә м. Сыерны эләктереп китсәк, базарда матур гына хакка төртербез. *(Гибралтарга.)* Кәшәфетдинов әфәнде, түләү мәсьәләсе шул сөйләшкәнчәдер бит инде? Сыер суйгансыздыр?!

Г и б р а л т а р. Барысы да тәртиптә булыр, иптәш-әфән-деләр. Сыерны иртәгә иртән суячаклар. Сез итне свежий килеш алып китсен дип шулай итәргә булдык. Каршы түгелсездер бит?

Г а л л ә м. Юк, юк. Што сез! Бигрәк шәп! *(Канәгать елмаеп, Рифатка.)* Класс!

Г и б р а л т а р *(болар янына килеп)*. Карыныгыз ачкандыр... Әйдәгез, экстрасенс әфәнделәр, ашханәгә кереп чыгыйк. Әйдәгез, әйдәгез. Рәхим итегез, әфәнделәр! *(Ишеккә таба ишарәли.)*

Чыгарга баралар.

К а ф и л. Дирехтыр абзый, мин дә барыйммы? Минем дә ашыйсым килә!

Г и б р а л т а р *(борылып карамыйча гына)*. Син генә җитмәгән иденң!..

К а ф и л *(Гибралтар артыннан ияреп)*. Син үзең дә маладис кеше инде, дирехтыр абзый...

Г и б р а л т а р *(кинәт артына борылып, Кафил тавышы белән)*. Син кая барасың?

К а ф и л. Ашарга! Үзең әйттең бит, дирехтыр абзый. Син генә җитмәгән идең, дидең.

Г и б р а л т а р. Тәмам миемне череттең! Бар, анаң янына кайт та аша! Әйдә, әйдә, кыймылда!

Чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Клуб ишеге төбендә Г и б р а л т а р белән Г а л л ә м басып тора. Сеанска килүчеләр белән берәм-берәм исәнләшеп, алар клубка кереп китәләр.

Г а л л ә м. Халык җыела... *(Сәгатенә карый.)* Башлар-быз да инде, мөгаен... Теге сөйләшенгән кешеләрегез кил-гәндер бит?

Г и б р а л т а р *(кемнедер көтеп)*. Хәзер, хәзер, экстрасенс әфәнде... Берсе менә хәзер килеп җитәргә тиеш. *(Куана.)* Әнә үзе дә килә...

Алпан-тилпән атлап, болар янына Х ө б б е л килеп баса.

Х ө б б е л. Здрасте? Слесаря вызывали? *(Честь бирә.)*

Г а л л ә м *(Гибралтарга иелә төшеп)*. Урыс мәллә бу?

Г и б р а л т а р. Юк, юк, аның татарчасы шундыйрак. Хөббел бу. *(Хөббелгә.)* Бар инде, бар, керә тор. Урын ала тор!

Х ө б б е л. Кайчан салабыз? *(Чайкалып куя.)* Гыйбрай, наливай!

Г и б р а л т а р. Соңыннан, соңыннан. Керә тор. *(Хөббелне эткәли.)*

Х ө б б е л. Только без рук, пажалысты. Я сам! *(Кереп китә.)*

Г а л л ә м. Бу төтен булган түгелме соң инде?

Г и б р а л т а р. Аның төтен булмаган чагы да юк. Тик сез борчылмагыз. Барысы да сез әйткәнчә булыр. Керәбезме?

Г а л л ә м. Барыгыз, бар, сез керә торыгыз. Атмосфераны ачыклый торыгыз. Мин бер-ике минуттан керермен. Халыкка җиткерәсе энергияне тәртипкә китерим. Минем ассистент белән кирәкле нәрсәләрне хәстәрли торыгыз. Сөйләшенгән кешеләрегезнең исенә тагын бер кат төшерегез.

Г и б р а л т а р. Яхшы. *(Кереп китә.)*

Галләм спортчылар сыман кулларын, аякларын хәрәкәтләндереп ала, башын уңга-сулга боргалый, бармакларын язгалагандай итә. Ашыгып кына Л ә й с ә н керә.

Л ә й с ә н. Уф! Соңга калдым дип торам. Башланмаган икән әле. Хәерле кич!

Г а л л ә м. Хәерле кич, хәерле кич, туташ! Сез тагын да сылуланып киткәнсез дип әйтимме... Нәкъ Нефертити кебек гүзәлсез!

Л ә й с ә н *(үзен мактаганга күңеле булып)*. Ә кем соң ул Нефертити?

Г а л л ә м. Үзен күргән-белгәнем юк. Кайчандыр яшәгән бер патша хатыны бугай шунда.

Л ә й с ә н. Ә-ә-ә... Әллә берәр чит ил җырчысымы дип торам тагы.

Г а л л ә м. Ничек соң, гүзәл туташ, баягы уеңнан кире кайтмадыңмы әле?

Л ә й с ә н. Юк, юк! Мин сезнең белән китәм! Салават Фәтхетдиновсыз яши алмыйм мин!

Г а л л ә м *(икеләнгән булып)*. Ни бит, туташ... Аның хатыны да бар бугай...

Л ә й с ә н. Булса ни! Мине күргәч, аерып җибәрә ул аны!

Г а л л ә м. Молодец! Шундый тәвәккәл кызларны яратам мин. Синнән менә дигән җырчы чыгачак. Бөтен дөньяга атаклы итәм мин сине! Әти-әниең ризадыр бит?!

Л ә й с ә н. Фи! Алардан сорап торам ди! Мин хәзер үземә үзем хуҗа.

Г а л л ә м. Ә егетең? Баягы егетеңне әйтәм?

Л ә й с ә н. Әй, егетмени әле ул? Бер бәйләнчек шунда. Сагыз!

Бу сүзләрне Салават тыңлап тора.

Әле үзеннән көчкә котылдым.

С а л а в а т. Миннән котылдыңмы?

Л ә й с ә н. Уф! Әнә тагы ияргән. *(Салаваткa.)* Мин сиңа әйттем бит инде. Йөрмә минем арттан, дидем!

С а л а в а т. Алдыңнан артка карап йөри алмыйм мин. Алай атлавы җайсыз.

Г а л л ә м. Да-а... Сагыз икән шул бу. Стиморол – устойчивый вкус!

С а л а в а т. Абзый, син тик кенә тор, яме! Шундый итеп установка бирермен, сәламәтлегеңне ныгытырга ун сыер саткан акчаң да җитмәс.

Л ә й с ә н. Ник бәйләнәсең әле син аңа, карт кешегә?

Г а л л ә м. Ярый, ярый, мин болай гына... Сүз уңаеннан гына... *(Салаваткa.)* Ирләр булыйк, бырат! Бәхетле булыйк! Минем үз юлым, синең үз юлың дигәндәй...

С а л а в а т *(Ләйсәнгә)*. Әйдә, киттек!

Л ә й с ә н. Тарткалама мине. Мин сеанска керәм!

С а л а в а т. Алайса, мин дә керәм!

Л ә й с ә н. Мишәйт итеп утырсаң, бүген ук Салават Фәт-хетдинов янына китәм! *(Галләмгә елмаеп.)* Экстрасенс абый белән бергә китәбез!

Шулай сөйләшә-төрткәләшә кереп китәләр. Галләм дә алар артыннан керергә омтылганда гына, Ф а т ы й м а пәйда була.

Ф а т ы й м а. Киче дә киче! Нинди матур! Ап-аяз күк йөзе...

Г а л л ә м. Йолдызлар җемелди... Исәнмесез, ханым-туташ!

Ф а т ы й м а. Исәнмесез, экстрасенс әфәнде! *(Капылт шикләнеп.)* Сез экстрасенстыр бит?

Г а л л ә м. Әлбәттә. *(Гәүдәсен турайта.)* Атаклы экстра-сенс. Галләм Сәлмән! Сезне кем дип белик?

Ф а т ы й м а. Фатыйма. Туташ дисәгез дә ярый. Фатыйма гына дисәгез дә була. Сез бүген сеанстан соң персидәтелгә кайтасыз икән дип ишеттем. Теләгегез булса, миндә дә урын бар!

Г а л л ә м. Теләк дип... Бик кызык тәкъдим бу! Шушындый гүзәл туташ чакыруына каршы килеп тә булмас, ахры. Персидәтел белән киңәшләшкәннән соң, бер уртак фикергә килербез дип уйлыйм.

Шулвакыт Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Экстрасенс әфәнде, сезне халык көтә. *(Фатыйманы күрә.)* Ә-ә... Фатыйма... Син тоткарлап торасыңмыни әле иптәш-әфәндене?!

Ф а т ы й м а. Нишләп тоткарлыйм ди? Исәнләшеп кенә тора идем.

Г а л л ә м *(Фатыймага)*. Сөйләшербез әле. Әйдәгез, Кәшәфетдинов әфәнде. Әйдәгез, туташ!

Гибралтар Фатыймага сәерсенеп карап ала.
Галләм белән икесе кереп китәләр.

Ф а т ы й м а. Сөйләшербез, сөйләшербез... Туктале, кайдадыр күргәнем бар кебек бу чукынчыкны... *(Бераз исенә төшерергә тырышып тора да клубка кереп китә.)*

Ут сүнеп ала. Пәрдә ачыла. Гибралтар бүлмәсе караңгыланып калган. Төрле яктан янган ут көлтәләре бары тик сәхнәне генә яктырта. Сәхнә алдындагы сулы банкалар, шешәләр, мискиләр, чәйнекләр тагын да ишәйгән. Урта бер җирдә кырык литр су сыешлы ике бидон тора. Савытлар тирәсендә тастымалларга куелган төрле ризыклар – ипи, бәрәңге, кишер, бәлеш һ. б. да шәйләнә. Трибуна янәшәсендә өстәл һәм ике урындык бар. Залда кемдер кул чаба башлый, аңа бүтәннәр дәррәү кушыла. Алдагы рәттә утырган С а м а т урыныннан вәкарь генә тора да, тамашачыларга карап, кулын өскә күтәрә – кул чабуларны туктатырга ишарә ясый.
Бер читтәрәк Г и б р а л т а р басып тора.

С а м а т *(учына төкереп)*. Кыхым!.. Кыхым!.. Уважаемые... кадерле авылдаш иптәшләр! И ишшё... иптәш калхузчы иптәшләр! И тагдалие...

Х ө б б е л *(утырган җиреннән башын калкыта, бер бармагын тырпайткан кулын өскә чөеп)*. Короче, пред! Краткость – сестра таланта! *(Башы кинәт салынып төшә.)*

С а м а т *(Хөббелгә карап)*. Күз алдыннан югалтыгыз әле шул дуңгыз боламыгын! *(Очкылык тота.)* Ыйк!

Гибралтар тиз генә Самат янына килә дә аның колагына нидер пышылдый.

Ф а т ы й м а. Йоклый инде ул, Самат Мансурович, йок-лый!

С а м а т. Ладны, алайса йокласын!.. Ыйк!.. Иптәш кадерлеләр!.. Ыйк!..

Гибралтар үз бүлмәсенә кереп китә дә стакан белән су алып чыга, аны Саматка суза.
Самат стакандагы сыеклыкны эчеп җибәрә дә йөзен чыта.

С а м а т *(авызын кулы белән җилләтеп)*. Аракы бит бу!

Халык көлә. Хөббел башын калкытып як-ягына каранып ала.
Гибралтар «әйе шул» дигәнне аңлатып башын селки.

Х ө б б е л. Аракы? Кайда ул? Миңа да бирегез!

С а м а т. Юк, юк, аракы түгел... Су икән, су! Ят, ят, йоклап ал!

Х ө б б е л. Не командуй, капитан! *(Башы салынып төшә.)*

Ф а т ы й м а. Ят та йокла инде, Хөббел тәре! Самат Мансуровичны тыңларга мишәйт итмә.

Зал ишегеннән М и ң н и с а  к а р ч ы к  килеп керә дә, кыймыл-кый-мыл атлап, Гибралтар янына килә. Самат та, бүтәннәр дә, бермәл сүзсез калып, аның атлап килү рәвешен күзәтеп торалар.

М и ң н и с а *(Гибралтарга, әмма бүтәннәргә дә ишетелерлек итеп)*. Булды, кем, Гыйбрәт улым. Мунчам булды!

Самат әле Гибралтарга, әле Миңнисага карый. Гибралтар берни дә аңламаган кыяфәт чыгарып ала.

Г и б р а л т а р. Бик әйбәт, Миңнисаттәй, бик әйбәт. Бар инде, утыр берәр урынга!

Гибралтар, төрткәли-төрткәли, Миңнисаны залга таба этәреп җибәрә. Миңниса сөрлегә.

М и ң н и с а. Әстәгъфирулла! *(Борыла.)* Бөтен авыл керерлек булды мунчам. Би-ик әйбәт булды, кем... Ул эссесе... ул эссесе... *(Утыра.)*

С а м а т. Короче...

Х ө б б е л *(башын калкытып)*. Во! Понял всё-таки... *(Башы салынып төшә.)*

С а м а т. Безобразие! *(Хөббелгә ачу белән карап ала.)* Короче, иптәшләр, безгә иптәш артистлар килде. Әйдәгез, иптәшләр, кул чабып каршылыйк әле артист иптәшләрне! *(Кул чаба башлый.)*

Гибралтар да, бүтәннәр дә аңа кушылып кул чабарга тотыналар. Сәхнәгә, үзен эре, дәрәҗәле тотып, Г а л л ә м  һәм, аннан бераз калышып, Р и ф а т  чыга. Икесе дә башларын иеп ала.
Самат белән Гибралтар кул чаба-чаба үз урыннарына утыра.

Г а л л ә м. Әфәнделәр! Ханымнар! Кадерле әбиләр, бабайлар! Энекәшләр, сеңелкәшләр! Минем дөньякүләм танылган экстрасенс булуым турында ишетеп беләсездер инде?! Шулай да үзем белән һәм *(Рифатка ишарәли)* бик тә сәләтле тугры ярдәмчем белән сезне таныштырып үтү зыян итмәс дип уйлыйм. Мин, белгәнегезчә, атаклы экстра-сенс Галләм Сәлмән булам!

Р и ф а т *(нәфис сүз осталары шикелле кулларын җәеп)*. «Дөньяны савыктыру» ассоциациясенең вице-премьер урынбасары әгъзасы... *(Тавышын тагы да күтәрә төшә.)* Член Галләм Сәлмән!

Халык гөрләтеп кул чаба. Галләм, канәгать елмаеп, башын иеп ала.

Г а л л ә м *(бер кулын Рифатка таба җәеп)*. Тиздән үзе дә тулы хокуклы халыкара экстрасенс әгъзасы-члены булачак Рифат Җәгъфәр!

Көчле кул чабулар астында Рифат башын иеп ала да сәхнәдә үзләре өчен әзерләнеп куелган өстәл янына килеп утыра.

Ф а т ы й м а *(урыныннан капылт торып)*. Галләм, Галләм... *(Шулай үзалдына сөйләнгәннән соң, Галләмгә дәшә.)* Карагыз әле, экстрасенс әфәнде! Минем сезне кайдадыр күргәнем бар кебек төсле тоела?!

Г а л л ә м *(сагаеп)*. Минеме?

Ф а т ы й м а. Әһә!

Г а л л ә м. Бик мөмкин, туташ. Чөнки мин бик күп җирләрдә кешеләргә давалау сеансларын үткәрәм. Шунда күрүегез ихтимал.

Ф а т ы й м а. Юк-юк, минем сеансларга моңарчы йөргәнем булмады. Менә кайдадыр күрдем инде сезне... Таныш сыман...

С а м а т. Фатыйма! Синең күрү-күрмәвең безне кызыксындырмый. Бүлдермә артистларны! Утыр урыныңа!

Ф а т ы й м а. Менә кайдадыр күрдем инде... *(Утыра.)*

Г а л л ә м. Әфәнделәр, иптәшләр! Миңа үз-үзегезгә ышанган кебек ышана аласыз. Мин дәвалый алмаган чир дөньяда юк! Гастрит, язвы желудкы, йөрәк, бавыр, сидек- куыгы, күкәйлекләр, аналыклар минем өчен пүчтәк нәрсәләр. Бөер ташларын «ә» дигәнче алып атам!

Р и ф а т. Галләм Хатипыч, әгәр теләсә... Ягъни мәсәлән, кирәк дип санаса... Бөернең үзен дә алып ташларга мужыт!

Халык гөрләтеп кул чаба.

Г а л л ә м *(ике кулын күтәреп, учларын халыкка таба төбәп)*. Әфәнделәр, ханымнар! Мин әле генә сезгә установка бирдем. Мин сөйләгән арада, сезнең барлык авыруларыгыз әкренләп юкка чыгачак. Дөрес, кайберәүләрегезнең чирләре бүген үк чыгып бетмәскә дә мөмкин. Чөнки, үзегез беләсез, чир ул – бик явыз нәрсә. Кабахәт нәрсә, мин әйтерием! Аны җиңәр өчен шактый тырышырга кирәк, энергияне байтак сарыф итәргә кирәк.

Хөббел, үзен белештермичә, башын бер яктан икенче якка чайкалдыра.

Г а л л ә м. Хәзер сез... *(Хөббелгә ишарәли.)* Әнә иптәш-әфәндегә минем установка тәэсир итә дә башлады.

Галләм, ике кулын күтәргән килеш, залга карап,
сәхнә буйлап йөренә.

Г а л л ә м. Хәзер сез гәүдәләрегездә гадәттәгедән үзгә җылылык тоячаксыз. Хәзер җылыначаксыз...

Галләм, шулай сөйләнә-сөйләнә, Гибралтар бүлмәсенә кереп китә.
Рифат, урындыкка утырган килеш ике кулын күтәреп, Галләмнең «дәвалау сеансын» дәвам итә.

Галләм бүлмәгә керүгә, Гибралтар бүлмәсендә ут кабына – Галләмнең ни эшләгәне тамашачыларга күренеп тора. Ул кулына шешә алып, андагы эчемлекне стаканга коя һәм тиз генә эчә.

Галләм *(чыгышлый кулы белән авызын җилләтеп ала, үзе нидер чәйнәп)*. Менә хәзер сез җылындыгыз... Җылындыгыз... Барыгыз да җылындыгыз... Хәтта минем үземә дә эссе була башлады... *(Хөббелгә карый.)* Бу иптәш-әфәнде... күренеп тора... артыгы белән җылынган... Иншалла, күренеп тора, аңа файда булачак...

Рифат, Галләм күренүгә, кулын хәрәкәтләндерүдән туктата. Хөббел һаман башын чайкап утыра, үзе берөзлексез ухылдый.

Фатыйма *(ике кулын да мәктәп укучылары шикелле күтәреп, сүз сорый. Рөхсәт-мазар көтеп тормастан урыныннан торып)*. Галләм әфәнде!

Галләм. Тыңлыйм сезне, туташ.

Фатыйма. Галләм әфәнде, сез Казанның берәр ресторанында официант булып эшләмәдегезме?

Галләм *(аптырап)*. Сез нәрсә, туташ! Сез нәрсә! Мин бит экстрасенс! Андый эштә эшләргә сез мине кем дип белдегез?!

Фатыйма. Гафу итегез... Менә кайдадыр күргәнем бар инде сезне. Тавышыгыз да таныш кебек. Исемегез дә таныш сыман... Исемә генә төшерә алмыйм.

Ләйсән. Мишәйт итмәгез инде, Фатыйма апа!

Галләм *(Фатыймага)*. Сез мине кем беләндер бутыйсыз, ахры, туташ?!

Фатыйма. Бутыйммы-бутамыйммы, әмма йөзегез таныш инде менә...

Самат. Фатыйма, дим! Туктыйсыңмы-юкмы син артист иптәшне тинтерәтүдән?

Фатыйма. Бете-бетте... Туктыйм, Самат Мансурович... *(Утыра.)*

Галләм. Әфәнделәр! Ханымнар! Хәзер мин...

Шулвакыт залга Кафил килеп керә.
Еш-еш сулый-сулый, борынын лышт-лышт тарта-тарта, борын астын куллары белән алмаш-тилмәш сөртә-сөртә, Саматка таба якыная.
Самат белән үз арасында шактый ара калдырып туктый,
аңа карап тора.

Самат. Нәрсә терәлеп каттың, кисәү таягы?

Кафил. Мыскыл итсәң, әйтмим алайса. *(Борынын тартып куя.)*

Самат. Нәрсә әйтмәкче буласың тагы, холодецлы борын?

Кафил. Менә хәзер әйтмим дә әйтмим инде. Үзеңә үпкәлә. Бик кирәкле сүз әйтәдерием...

С а м а т. Теге көнне әйткән урысча сүз булса, матри! Торма каршымда сураеп! Ике дә уйламыйм, миңгерәү башыңны ыштан төбеңә тыгып куям!

Ф а т ы й м а. Сез нәрсә инде, Самат Мансурович... Кафилгә җикеренергә ярамый аңа. Врачлар кушмый. Бар, утыр, улым, берәр урын табып.

Галләм әле Фатыймага, әле Кафилгә карап ала.

К а ф и л *(чалбарын тотып)*. Әллә тиле инде син, пер-сидәтел абзый... Ыштан түгел бит бу, чалбар! Шуны да белмисең... Ыштанны әбиләр кия бит аны. Үзең персидәтел абзый булып йөргән буласың...

Г а л л ә м *(Саматка)*. Персидәтел әфәнде... *(Кафилгә.)* Иптәш дивана...

С а м а т. Хәзер, хәзер, разговорны бетерәбез, иптәш артист әфәнделәр *(Кафилгә.)* Бар, барып утыр берәр җиргә. Торма минем каршымда дурака валәйт итеп!

Кафил, башын селкеп, күзләрен уйнатып, Саматка карый-карый, бер читкәрәк китеп баса.

К а ф и л. Мин әйтәсе килгән сүзне беләсең килсә, сора син, җәме, персидәтел абзый...

Самат аңа «яп авызыңны» дигәнне аңлатып, йодрыгын селки.

Г а л л ә м. Әфәнделәр! Ханымнар! Әбиләр һәм бабайлар! Хәзер мин берәр авыруның минем тарафка килүен сорыйм.

Ул шулай диюгә, залдагыларның һәммәсе дә диярлек урыннарыннан кузгала. Атылып, Ләйсән дә килеп җитә.

Г а л л ә м. Стоп! Стоп! Стоп! Утырыгыз, зинһар-пажалысты, урыннарыгызга! Миңа бер авыру ир-ат кирәк! *(Гибралтарга карый.)* Гибралтар әфәнде!..

Ләйсән, сөмсере коелып, урынына кире барып утыра.
Гибралтар урыныннан сикереп тора да йокымсыраган Хөббелгә ишарәли. Башкалар урыннарына утыра. Гибралтар белән Рифат Хөббелне урыныннан күтәрергә азаплана. Кафил дә шулар
тирәсендә кайнаша.

Х ө б б е л *(башын күтәреп)*. Что такуй? Милиция што ли? Не пойду! *(Карыша.)* Мин шып-шыр аек патамушто!

Г и б р а л т а р. Хөббел! Хөббел, дим! Уян!

Х ө б б е л. Ә син татармыни?

Г и б р а л т а р. Татар инде, татар. Уян тизрәк! *(Галләмгә.)* Бу – безнең атаклы механизаторыбыз! Ике смена эшләгән иде – арыган.

Х ө б б е л. Никогда! *(Гибралтарга.)* Син татарча җырлый беләсеңме? Әйдә җырлыйбыз... *(Шыңшый.)* Тала, тал-ла, тала, тал-ла, тала ике беләге-ем... Их!.. Яклый мине, саклый мине-е-е... әнкәмнең догалары-ы-ы... *(Гибралтарга.)* Син кем? Полковник милиции?

С а м а т. Рәткә кертегез инде шул алкашны җәтрәк!

К а ф и л. Хөббел абзый, уян инде, айны! Бу бит дирехтыр абзый!

Х ө б б е л *(башын бик нык селкеп)*. У-у-у-ух! *(Гибралтарны танып.)* Ментлар сине дә каптырдымыни, Гыйбрай? *(Бармагын селки.)* Нельзя пить! Понял? Давай, Гыйбрай, сто грамм наливай! Беткән баш беткән... *(Чайкала.)*

Г и б р а л т а р. Потом, потом...

Х ө б б е л *(бармагын иреннәренә терәп)*. Тс-с-с-с! «Ты сказала шёпотом: а что потом? А что потом?..» *(Бармагын өскә чөя, тавышын көчәйтә.)* Поэз-зия! Евтушенко! Понял?

Г и б р а л т а р. Понял, понял... Тушёнканы да аңламаска! Ит күрмәгән кеше мәллә мин!

Рифат Галләм каршына урындык китереп куя.

Г и б р а л т а р. Хөббел, утыр менә шунда. Экстрасенс әфәнде хәзер сине дәвалый. Тыныч кына утыр!

Х ө б б е л. Понял! Утырам. Утырам – тартам, кирпеч бар – раствор юк!

Гибралтар белән Рифат үз урыннарына барып утыра.
Кафил шул тирәдә йөренә.

Г а л л ә м *(Хөббелгә текәлеп карап)*. Әфәндем, сездә – менингинт авыруы.

Х ө б б е л *(чайкалып)*. Ә? Не понял што-то... Нишләп Ленин мент булсын... Ленин ул – юлбашчы! Укырга, укырга һәм и тагын укырга кушкан ул безгә! Наданнар!

Г а л л ә м. Сез, иптәш-әфәнде, хроник баш авыртуы белән җәфаланасыз...

Х ө б б е л. Точно! *(Башын тота.)* Дөрес әйттең. Минем баш пастаянны авырта. Менә әле дә перәме чатный. Юкмы берәр нәрсәң?..

Г а л л ә м. Хәзер мин сезнең баш авыртуыгызны бетерәм... *(Ике кулын күтәреп, Хөббелнең баш тирәсендә йөртә.)* Хәзер юып алгандай итәм мин аны...

Хөббел, чайкала-чайкала, урындык аркасына терәлә. Кинәт урындык җимерелеп, Хөббел идәнгә мәтәлә. Бераз ухылдый да гырлап йокыга китә.

К а ф и л *(Хөббелне торгызмакчы булып)*. Хөббел абзый! Хөббел абзый!

Г а л л ә м. Иптәш дивана! Пажалысты, тимәгез аңа. Йокласын. Ярты сәгатьтән чын кеше булып уяна ул. *(Гибралтарга.)* Гибралтар әфәнде, әйдәгез, бу иптәш divananы... Тфү!.. әфәндене сезнең кабинетка кертик тә салыйк әле без! *(Рифатка.)* Ә син, дускаем, сеансны дәвам итә тор.

Галләм белән Гибралтар Хөббелне, култыклап, директор бүлмәсенә алып кереп китәләр. Бераздан анда Галләм белән Гибралтарның аракы эчкәне шәйләнә.

Р и ф а т *(Кафилгә)*. Кил әле монда, быр-рат. Хәзер мин сине гипнозлыйм.

К а ф и л. Нишләтәм дисең, абзый?

Р и ф а т. Мин сине йоклатам хәзер. Курыкма, курыкма... Шундук уятам мин сине.

К а ф и л. Акча бирәсеңме соң?

Р и ф а т. Бирәм, бирәм... Мә, хәзер үк бирәм. *(Кесәсеннән кәгазь акча алып, Кафилгә тоттыра.)*

М и ң н и с а *(Фатыймага)*. Әллә акча өләшәләрме, кызым? Пенсиядәгеләргә дә бирәләрме?

Ф а т ы й м а. Бирәләр, бирәләр. Сиңа да бирәләр. Янчы-гыңны әзерләп куй.

М и ң н и с а. Әлхәмделлиллаһи шөкер...

С а м а т. Тик кенә утыр әле, яме, Миңнисаттәй. Мишәйт итмә халыкка!

М и ң н и с а. Бетте, бетте, Гапсамат улым... Янчыгымны гына кулыма тотыйм да... *(Күлмәк итәген күтәреп, оек керешенә кыстырылган янчыгын ала.)*

Р и ф а т *(ике кулы белән Кафилгә «йоклау энергиясе» җибәрергә азапланып)*. Син йоклыйсың хәзер, йок-лыйсың...

К а ф и л. Теге икестрасин абый белән икегез эчкән даруны да бирәсең мәллә?

Р и ф а т. Йоклыйсың... *(Күзләрен акайтып.)* Ә? Йокла, дим!

К а ф и л. Йоклыйсы килми минем. Ашыйсы килә! Ашарга бир әле.

Р и ф а т *(кызарынып-бүртенеп)*. Мин сиңа сталавай мәл-лә?! Йокла җәтрәк!

Ф а т ы й м а. Улым, йокла инде, йокла! Интектермә абзыеңны...

К а ф и л. Әйем лә, йокламыйм!

Р и ф а т. Йоклыйсың, йоклыйсың...

К а ф и л. Синең машинаң бармы? Минеке бар. *(Кесәсеннән уенчык машина тартып чыгара.)* Менә! Йөрүен йөри... Утырып кына булмый. *(Идәнгә машинасын куеп йөрткәләмәкче була.)* Выж-жыйн...

Р и ф а т. Иелмә! Сүндер машинаңны! Тфү! Тыгып куй кесәңә. Атып бәргәнче!.. Йоклыйсың, йоклыйсың...

К а ф и л. Рульдә йокларга ярамый. Авария була!

Р и ф а т *(ярсып)*. Яшер машинаңны он-талкан иткәнче!

К а ф и л *(машинаны кесәсенә тыгып куя да кулындагы акчаны әйләндереп-әйләндереп карап)*. Бу акчага күкәй алып буламы?

Р и ф а т *(кулларын һаман хәрәкәтләндерә-хәрәкәтлән-дерә кычкырып)*. Нинди күкәй ул тагы?

К а ф и л *(битараф кына)*. Тавыкныкы инде. Әтәчләр күкәй салмый ла... Минем күкәй ашыйсым килә. Безнең тавык бүчкәдәге суга төшеп үлде. Йөзә белми икән ул...

Р и ф а т *(хәлсезләнеп)*. Ыслушай, мин сиңа миллион күкәй бирәм... Тыгынырсың... йокла, яп-яланаяк!

К а ф и л *(ботинкаларын карап)*. Әйем лә... Яп-яланаяк йокламыйм. Минем аяклар өши алайса...

С а м а т *(кычкырып)*. Йокла, диләр сиңа, миңгерәү тәре!

Г а л л ә м директор бүлмәсеннән ике кулын залга төбәп килеп чыга. Шактый кызмача икәнлеге сизелә. Г и б р а л т а р үз урынына чыгып утыра.

Г а л л ә м. Хәзер сез бик каты җылындыгыз инде... Сизәсезме? Мин сизәм.

М и ң н и с а *(Фатыймага)*. Нәрсә дип әйтә ул?

Ф а т ы й м а. Сиңа әйтми ул. Дәваланып кына утыр!

Р и ф а т *(Кафилне читкәрәк этәреп)*. Бар, читтәрәк тор. Яңадан кабатларбыз сеансны... *(Үз урынына барып утыра.)*

Г а л л ә м. Мин, әфәнделәр, иптәшләр, туташлар, ханымнар... Мактанып әйтмим, име... Мин – халыкара категорияле экстрасенс. *(Бармагын өскә таба төби.)* Өстәгеләр, то есть тегендәгеләр белән мин даими элемтәдә торам. Теләсәм – яңгыр, теләсәм, боз яудыра алам. Име?! Теләсәм, болытларны куып таратам. Мин хәтта, име, җир тетрәүләрне дә булдырмый кала алам. Моңарчы сезнең авылда җир тетрәмәгән икән – бу минем тырышлык нәтиҗәсе. Бу авылда җир тетрәмәскә тиеш – мин шундый установка куйдым...

Ф а т ы й м а *(янә кулын күтәреп, урыныннан торып)*. Карагыз әле, Галләм Сәлмән әфәнде... Әйтегез әле... Сез Казанның берәр бүлнисендә гинеколог булып эшләмәдегезме?

Г а л л ә м *(айнып киткәндәй)*. Ничек? Мин... гинеколог?! Сез нәрсә, әби җаным! Әйттем бит инде, мин – экстра-сенс!

Ф а т ы й м а. Гафу итегез инде... Менә кайдадыр күр-гәнем бар инде...

С а м а т. «Сифилистән лечить итә торган бүлнистә эш-ләмәдеңме?» дип кенә сорыйсың калды инде, телеңә тилчә чыккыры!

Ф а т ы й м а *(үзе дә сизмичә)*. Чыннан да! Галләм әфән-де, сез сифилис... тән... *(Як-ягына каранып, кинәт туктап кала.)* Кайдадыр күрдем инде мин сезне... Гафу итегез...

С а м а т. Утыр инде урыныңа канса да кансов!

Г а л л ә м *(Фатыймага)*. Туташ-ханым, име... Минем үземә дә сезне кайдадыр күргәнем бар кебек тоела... Сез миңа шундыйрак сорау-мазар бирмәгән идегезме?

Ф а т ы й м а *(сәерсенеп)*. Әй-йе... Ике мәртәбә... бирдем...

Г а л л ә м *(җиңелчә чайкалып)*. Во! Әйттем бит, сезне күргәнем бар кебек тоела дип... Күргәнем булган, ызначит!

Галләм кул хәрәкәтләре белән Фатыйманы йоклатырга тырыша. Миңниса, урыныннан торып, Гибралтар янына килә.

М и ң н и с а. Гыйбрәт улым... Кәшәбет... бет... бет... динуф... әф... әп...

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы?

М и ң н и с а. Мунчам суынып бетмәде микән инде?

Г и б р а л т а р. Мин каян белим!

М и ң н и с а. Бик кызу булгач, күсе тишекләрен томаламаган идем. Суынмаса гына ярар иде инде...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, мунчаң холодильникка әйлән-гәнче тизрәк кайт та шул тишек-тошыкларыңны томалый тор...

М и ң н и с а. Шулай итим алайса... *(Кузгала.)* Кәнсирт бетүгә, әртистләрне алып кайтырсың инде, җәме, Гыйбрәт улым... Кәшәф... фет... бет...

Г и б р а л т а р. Бар инде, бар... Җәтрәк кыймылда. Өеңдә генә утыр. Мунчаңда гына утырсаң да ярый... Күселәр кереп тулмасын. Беркая да чыгып китмә...

Миңниса китә. Самат Гибралтарга сәерсенеп карап тора.

Г и б р а л т а р *(Саматка)*. Көне буе нервыны талкыды инде... Артистларны... ту ест... экстрасенс әфәнделәрне үземә алып кайтам, ди... Аптырагач, котылу өчен, мунча як, дип әйткән идем...

Г а л л ә м. Җитәкче әфәнделәр, сез бераз гәпләшә торыгыз, без ярдәмчем белән, име, теге иптәш-әфәнденең хәлен белеп чыгыйк әле...

Галләм белән Рифат Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Галләмнең аракыны шешә авызыннан гына эчкәнлеге, Рифатның бер-бер артлы ике стакан аракыны авызына озатканы шәйләнә.
Сәхнәдә Кафил, Галләм шикелле кулларын өскә күтәреп, залдагыларны «дәвалый».

К а ф и л. Хәзер тереләсез... Хәзер тереләсез... Дирехтыр абзый, син дә тереләсең... Персидәтел абзый да терелә хәзер...

С а м а т. Нишлисең син, җил тегермәне? Төш хәзер үк сәхнәдән!

К а ф и л. Хәзер җылынасыз... Хәзер йоклыйсыз... Яп-яланаяк йоклыйсыз...

С а м а т *(бармак изәп, Кафилне үз янына чакырып)*. Кил әле монда, Миңнисаттәй сыңары...

К а ф и л *(шүрли-шүрли генә Саматка таба якынлашып)*. Кыйнарга уйласаң, «Пожар!» дип кычкырам! *(Ара калдырып туктый.)*

С а м а т. Курыкма, курыкма, урыс теле ызнатогы... Сиңа кагылып кулымны пычратмыйм... Җә, әйт әле, баягынак нәрсә әйтмәкче идең?

К а ф и л. Әйтсәм ачуланмыйсыңмы соң?

С а м а т. Юк, юк, давай, әйт!

Г а л л ә м белән Р и ф а т чыга. Рифат үз урынына утыра.

К а ф и л. Филдшер абзый әйткән ие... Персидәтел абзыеңны эзләп табып әйт, дигән ие...

С а м а т. Дальше. Шуннан?

К а ф и л. Менә шул инде.

С а м а т. Соң, тилекәем... Нәрсә әйтергә кушты соң сиңа фельдшер абзыең?

К а ф и л. Ә-ә-ә... Әйе шул... Филдшер абзый әйтте... теге... бу икестрасиннарга дигән... теге... күбенеп кайткан сыер үлеп ята, дигән ие... Үлгәнче суйыйк микән, дигән ие... *(Битараф кына.)* И-и... үлгәндер инде ул сыер...

С а м а т *(урыныннан сикереп торып)*. Чурт! Ник аны баягынак ук әйтмәдең, маңка тәре!

К а ф и л *(артка чигенеп)*. Бә-ә-ә-әй, мин бая ук әйтмәкче идем... Үзең бит... Әйттермәдең... Кызык икән син!..

С а м а т *(Кафилгә)*. Ну сине! *(Гибралтарга.)* Продолжайте! *(Кабаланып чыгып китә.)*

К а ф и л *(Гибралтарга Самат булып кыланып)*. Быра-далжайте!

Г и б р а л т а р. Төш сәхнәдән, нәгаләт!

К а ф и л. Әгәр миңа кычкырсаң... Кул болгаучы менә бу бырач икестрасин абзыйга әйтәм...

Г и б р а л т а р. Нәрсә әйтәсең?

К а ф и л *(сәхнәгә куелган Гибралтар банкасына иша-рәләп)*. Бу банкада чишмә суы түгел, ә колонка суы дип әйтәм...

Г и б р а л т а р. Ә?! Аһ, дивана!

К а ф и л *(Гибралтарга ике учын төбәп)*. Хәзер син тереләсең, дирехтыр абзый... Хәзер йоклыйсың, дивана!

Г а л л ә м *(Кафилгә)*. Карап-карап торам да мин сиңа, иптәш дивана әфәнде... Синдә нидер бар бит... Мин сине икенче ярдәмчем итеп алам... Ие!

К а ф и л *(Галләмнең әйткәнен ишетмичә)*. Хәзер сез дә йоклыйсыз, хәзер тереләсез...

Р и ф а т *(урыныннан сикереп торып, кул чабып)*. Афәрин, быр-рат!

Ул, шулай кул чаба-чаба, Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Анда аның авызыннан гына аракы чөмергәне шәйләнә.

Г а л л ә м *(Кафилгә карап)*. Талантлы егет! Дивана булмасаң, менә дигән экстрасенс чыгасы үзеннән!

К а ф и л. Сөйләшмә! Хәзер йоклыйсың... Хәзер тереләсең... Хәзер чирлисең...

Р и ф а т керә.

Г а л л ә м. Ха-ха-ха! *(Рифатка.)* Настоящий экстрасенс бу! Сине дә уздыра, авызына кереп чыгыйм!

Фатыйма кинәт колагын шомрайта. Кафил һаман кулларын хәрәкәтләндереп йөргүен белә.

Р и ф а т *(көлгән булып)*. Мине үк уздыра алмас анысы, Галләм Хатипыч... Әмма бу, күренеп тора, клад бу, клад! *(Кафилгә.)* Исемең ничек әле синең, быр-рат?

К а ф и л. Нигә? Кафил!

Р и ф а т. Фамилияң?

К а ф и л *(аңламыйча)*. Нәрсә?

Р и ф а т. Ну-у... Атаңның яки бабаңның исеме ничек?

К а ф и л. Атамныкымы? *(Фатыймага.)* Кем әле минем атам?

Ф а т ы й м а. Шул инде... Ни...

Р и ф а т. Ни дигән исем буламыни? Нияз мәллә?

Г а л л ә м. Атаңның исемен дә белмисеңмени, авызыңа кереп чыгыйм!

Фатыйма янә колагын шомрайта, кинәт урыныннан капылт кына сикереп тора.

Ф а т ы й м а *(Галләмгә)*. Таныдым бит мин сине, грузчик тәре! Тәки таныдым!

Г а л л ә м *(шикләнеп)*. Сез нәрсә! Кем грузчик?

Рифат әле Галләмгә, әле Фатыймага карый.

Ф а т ы й м а. Авызыңа кереп чыгыйм! *(Галләмга таба килә.)* Алкаш! Менә, улым, шушы булыр инде синең атаң.

Г а л л ә м *(әсәренеп)*. Бу? Минем улым?!

Г и б р а л т а р *(калкынып)*. Ә син миңа сылтап маташкан идең, тагарак!

Һәркем Гибралтарга борылып карый. Гибралтар, ялгыш ычкындырганлыгын аңлап, урынына сеңә. Ләйсән сикереп тора да лып итеп кире утыра.

К а ф и л. Әти! *(Галләмне барып кочаклый.)* Исәнме, әтием! Минем бырач әтием! Икестрасин!

Ф а т ы й м а. Әйтәм бит, кайдадыр күрдем, дип... Мин сине шул сүзеңнән таныдым...

К а ф и л. Әти! Икестрасин!

Р и ф а т. Да-а... Килеп җиттек, кода-а...

Г а л л ә м *(Кафилдән котылырга теләп, артка чигенеп)*. Сез нәрсә? Сез нәрсә?! Нишләп мин бу дуракның атасы булыйм. *(Фатыймага.)* Мин сине беренче тапкыр күрәм, әби!

Ф а т ы й м а *(күкрәгенә калкыта төшеп)*. Йә, йә, исеңә төшер!

Л ә й с ә н *(Галләм белән Фатыйма арасына кереп)*. Нәрсә бу? Аңлатыгыз җүнләп. Фатыйма апа, нишләп син кешегә яла ягасың? Чит-ят кешегә...

Ф а т ы й м а. Тыгылма, үскәнем! Яшь әле син... Нишләп ят булсын, Кафилнең атасы миңа ят була димени?!

К а ф и л. Әти! *(Кочакларга азаплана.)* Икестрасин әтием! Мин дә икестрасин булам!

Л ә й с ә н. Галләм абый, әйтегез бер сүз! Юк, әйтмәгез. Әйдә киттек! *(Галләмне өстери, Кафил аңа чат ябышкан.)* Мин сезнең белән китәм. Хәзер үк!

Г и б р а л т а р. Нәрсә!!! Нәрсә дидең?

С а л а в а т. Бу картлачка ияреп китәм, ди. Көне буе шашынып йөри инде кызың. Тыяр хәл юк!

Л ә й с ә н. Китәм шул! Бер гаепсез кешегә бәйләнәсез.

Г а л л ә м. Җибәрегез мине! Мин алкаш түгел! Мин элек тә аз гына эчә идем. Дәваландым мин! Үз-үземә установка бирдем. Җибәрегез мине!

Г и б р а л т а р. Ләйсән, кит аннан! Кил монда!

К а ф и л. Әти! Мин дә әтиле булдым!

Р и ф а т. Харап булды сыер...

Г а л л ә м. Ни сөйлисең син... Нинди сыер... Мин харап булып ятам монда. Җыйна әйберләрне!

Ф а т ы й м а. Безгә кайтасыңдыр инде, Галләмчик? Таныдың, ниһаять... Казанда, мин базарда сату иткәндә, син грузчик булганыңны исеңә төшергәнсеңдер алайса. Әнә кара малаеңа! Тач үзең инде!

К а ф и л. Әти! Тач син бит мин!

Ләйсән нишләргә белми тора, аның янында Салават.

Л ә й с ә н. Ничек инде? Дөрес түгел бу? Ышанмыйм!

Г а л л ә м. Кәшәфетдинов әфәнде, зинһар, коткар! Сыерыгыз үзегезгә булсын! Үзем бирәм бер сыерлык акча!

Г и б р а л т а р. Атвались! Кызым, кил монда!

Л ә й с ә н. Сез... Сез мине Салават... Салават Фәтхетдинов белән таныштырам, дидегез... Сез мине алдадыгызмы?

Г а л л ә м. Белмим мин сезнең ул җырчыгызны. Күргәнем дә юк! Җибәрегез мине!

Л ә й с ә н. Карт алдакчы!

К а ф и л. Әйтмә минем этигә алай дип! Минем эти – икестрасин! Мин дә икестрасин. Хәзер дәвалыйм мин сине. Тәти сүзләр генә сөйләшә торган итәм. *(Кулларын- хәрәкәтләндерә.)* Хәзер син тереләсең... Хәзер син җырлыйсың...

Ләйсән чигенә, Салаватка сыена.

К а ф и л *(Салаватка)*. Син дә җырлыйсың... Икәүләп җырлыйсыз...

Шулвакыт шаккатарлык хәл була: Ләйсән белән Салават, кулга-кул тотынган килеш, бер-берсенә карап, үзләре дә сизмәстән җырлый башлыйлар. Башкалар сәерсенеп, гаҗәпсенеп күзәтә.

Л ә й с ә н
С а л а в а т *(икесе бергә).*

Кош баласы очар чак җиткән –
Кош баласы канат кагына...
Очып китмәс борын чит җиргә,
Туган ягын инде сагына.

Авыл өсләп урап узалар...
Чит җирләргә кошлар кузгала...
Сөйгән ярың монда кала бит,
Син дә китмә инде, кыз бала-а...

Кош баласы очар чак җиткән –
Канат ныгыткан ул кай ара?
Кошлар юлы, ай-һай, озын бик –
Барасы җир әллә кайларда...

К а ф и л *(башкаларга да карап, кулларын хәрәкәтлән-дереп)*. Барыгыз да җырлыйсыз!

Б а р ы с ы  б е р г ә. Авыл өсләп, урап узалар...
Чит җирләргә кошлар кузгала...
Сөйгән ярың монда кала бит,
Син дә китмә инде, кыз бала...

Җыр тәмамлануга, барчасы, бер-берсенә карап, әле Кафилгә караш ташлап, сәерсенеп тора. Үзара: «Әкәмәт! Могҗиза бу! Авыл белән ычкындык мәллә? Әкият бит бу!» – диешкәннәре ишетелә.

Г а л л ә м. Нәрсә бу? Әллә чынлап та гипнозладымы безне бу ти... ти... бу малай актыгы?!

Рифат, үз әйберләрен җыйнап, Гибралтар бүлмәсеннән чыга.

Р и ф а т. Хатипыч, мин әзер! Киттек!

Г а л л ә м. Туктап тор әле. Хикмәт әле монда! Әгәр дә бу малай чынлап та... минем малай булса...

К а ф и л *(Галләм каршысына килеп басып)*. Улым, диген, әти! *(Кулларын хәрәкәтләндереп ала.)*

Г а л л ә м *(кыяфәтендә, үз-үзен тотышында үзгәреш сизелеп)*. У-у-у-лым!

К а ф и л. Маладис, әти! Чын әти икәнсең! Мә, җывачка бирәм... *(Кесәсеннән сагыз алып, Галләмгә бирә.)* Бая чәй-нәп бетермәгән идем...

Г а л л ә м. Рәх-мәт, у-у-лым!

К а ф и л *(Гибралтарга ишарәләп)*. Дирехтыр абзыйга әйт рәхмәтне. Җывачканы ул бирде!

Г а л л ә м *(Гибралтарга)*. Рәх-мәт, ди-дирехтыр абзый!

Р и ф а т *(Галләмгә)*. Син нәрсә, Хатипыч... Полоумныйланасың... Башыңа артык китте мәллә? Тайдык әйдә!

Г а л л ә м. Туктале, тукта... Баш кайгысы түгел... Мәсьәлә җитди әле монда...

Кафил Рифат янына килеп баса. Аны, әле генә күргәндәй, баштанаяк күздән кичерә.

К а ф и л. Нихәл, саран абзый? Терелтимме сине дә? Яп-яланаяк тереләсең... *(Кулларын Рифатның сәерсенгән чырае тирәсендә йөртә.)* Хәзер тереләсең... Тереләсең... Әйбәт кеше буласың...

Г а л л ә м *(үзалдына сөйләнеп)*. Әллә моңа Сәлмән бабайның җаны күчкән инде... о-пэ-эр-эс-тэ-у-фэ! Кыланмыш-лары тач бабайныкы!

К а ф и л *(Рифатны җәфалап)*. Челт-мелт итмә күзеңне, саран абзый! Хәзер терелтәм мин сине...

Р и ф а т *(Галләмгә)*. Пажалыста, Хатипыч... Ал әле малаеңны... Күзгә керә бит инде...

Г а л л ә м *(кузгалмакчы була, кузгалалмый)*. Аяклар йөрми бит, быр-рат...

К а ф и л. Хәзер тереләсең... Хәзер яп-яланаяк йоклыйсың...

Р и ф а т. Энекәш... Акча бирәм... Күзгә генә кермә... *(Кесәсеннән акча чыгармакчы була.)*

К а ф и л. Акча кирәкми миңа... Мин акчасыз терел-тәм...

Р и ф а т. Бабаң сыңары икәнсең! Алайса... күкәй бирәм... *(Янә кесәсенә тыгыла.)*

К а ф и л. Күкәең дә кирәкми... Хәзер йоклыйсың... Йоклыйсың...

Рифат аягүрә йоклап китә.

Г и б р а л т а р. Вәйт, нәгаләт! Әллә аягүрә үлде инде?!

Ашыгып С а м а т килеп керә.
Бернәрсәгә дә игътибар итмәстән, туп-туры Кафил янына килә.

С а м а т. Әһә! Әле син һаман мондамыни? Түләтәм! Сыер хакын түләтәм! Ыспырафкаң бармы дип тормам!

Ф а т ы й м а. Ник җикерәсең безнең малайга? *(Галләмгә карап ала.)* Атасы юк дип беләсең мәллә?

С а м а т. Тик кенә тор әле син! *(Кулын селти.)* Түләтәм!

К а ф и л *(артына чигенеп)*. Сыерны суйдыгыз дамыни, персидәтел абзый?

С а м а т. Үлгән сыерны суялар димени, ахмак!

К а ф и л *(Галләмгә якынаеп)*. Персидәтел абзый, бер әйбер әйтимме? Минем әтием табылды. Икестрасин! Мин дә икестрасин! Хәзер мин сине терелтәм...

С а м а т *(уйламыйча гына)*. Сыерны терелт син... *(Кинәт.)* Ә?! Нинди әти тагы?! Кем ул? *(Әле үзенә, әле Гибралтарга карый.)*

Г и б р а л т а р *(Галләмгә ишарәләп)*. Әнә каршында тора әтисе.

С а м а т *(Галләмгә)*. Син? *(Кафилгә карап.)* Моның... әтисе?! *(Фатыймага төртеп.)* Моның... нисе?

Ф а т ы й м а. Нисе түгел, ире! Улыбызның атасы, минем ирем! Әйеме, Галләм?!

Галләм бермәл нишләргә белмичә басып тора. Ул арада Кафил
Рифатны уята. Рифат ни булганын аңышмый.

Г а л л ә м. Ни дип әйтим инде, иптәш персидәтел әфәнде?.. Малай минем Сәлмән бабайга охшаган да кебек инде... Бер караганда...

С а м а т. Икенче караганда... ничек?

Г а л л ә м. Икенче караганда, минем экстрасенслык хываткысы да бар сыман... шикелле... кебек... тоела үземдә...

Р и ф а т. Хужы! Бүгеннән член-әгъза...

С а м а т. Членында эшем юк... Миңа димәгәе, хет Алланың кашка тәкәсе белән туганлашыгыз! Мине данный моментта бер генә нәрсә кызыксындыра: кайсыгыз түли сыер акчасын?

Р и ф а т. Мин – юк! Минем түләрлек акчам юк. Мин кешегә тагылып йөрүче генә...

С а м а т. Койрык штоли син тагылып йөрергә? Түләгез! Ике сыер өчен! Колхоз малын ни позволю әрәм-шәрәм итәргә!

К а ф и л. Персидәтел абзый, пысыйхланма... Мин хәзер терелтәм сине... Мин бит икестрасин! Үлгән сыерны да терелтәм...

Г а л л ә м. Ул-лым... Берүк мал-туарларга алынма. Хайваннардан ерак йөр. Кешеләр дә җиткән безгә!

К а ф и л. Ярар, әти. *(Саматка.)* Мин хәзер терелтәм сине... Әйбәт кеше итәм...

Самат дерелди-калтырый башлый.

Ф а т ы й м а. Әллә, Ходаем, әшәке женнәре чыга инде...

К а ф и л *(Гибралтарга)*. Дирехтыр абзый, сине дә терелтәм...

Г и б р а л т а р. Юк, юк, кирәкми. Мин болай да әйбәт кеше... Эчмим, тартмыйм... Гүләйт итмим... *(Селкенә башлый.)* Бүтән...

Гибралтар бүлмәсеннән Х ө б б е л чыга. Кулында – буш стакан.

Х ө б б е л. Гыйбрай! Наливай!

Кафил Хөббелгә таба борыла, селкенә башлаган Хөббелнең кулыннан стаканы төшеп китә.

Х ө б б е л. Не надо, я сам! *(Бер чүгәли, бер тора.)* Бер! Ике! Бер! Ике!

К а ф и л. Әни! Әти! Күрәсезме? Мин – икестрасин! Мин терелтәм...

Барысы да төрле хәрәкәтләр ясап селкенәләр.
Абына-сөртенә М и ң н и с а к а р ч ы к керә.

М и ң н и с а. Әстәгъфирулла! Шайтан туе мәллә монда? Лә хәүлә вәләкуәтә...

Башкаларга кушылып, ирексездән Миңниса карчык та төрле хәрәкәтләр ясарга тотына. Музыка көчәя.

П ә р д ә.

*1992–2002*

## КАЗЫЙХАНДА КУНАКТА

*Ике пәрдәле драматик комедия*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Ш а к и р – яңа татар бае, 40 яшьтә.
К ә р и м ә – Шакирның хатыны, 40 яшьтә.
А с и я – аларның кызлары, 18 яшьтә.
Н ә с и м В а ф и н – композитор, 40 яшьтә.
Ф ә р и д ә Г а й с и н а – галимә, 40 яшьтә.
К а м и л Г а б д у л л а – шагыйрь, 40 яшьтә.
А н ж е л а – 24 яшьтә.
Р ө с т ә м – 19 яшьтә.

Вакыйга безнең көннәрдә, бер затлы кунакханәдә, тагы да төгәлрәк итеп әйтсәк, кунакханәдәге ресторанның VIP-залында бара.

## Б Е Р Е Н Ч Е   П Ә Р Д Ә

А н ж е л а белән Н ә с и м.

А н ж е л а. Әйдәгез, абый, бу залга рәхим итегез!

Н ә с и м. Рәхмәт, матурым! Сине күрүдән бик мәмнүн булдым! Исемеңне дә әйтсәң...

А н ж е л а. Анжела мин, абый. Анжела!

Н ә с и м. Жәл... Бик кызганыч!

А н ж е л а. Ни дидегез, абый?

Н ә с и м. Жәл, минәйтәм! Син чибәрне очратасымны белмәдем! Паспортымны үзем белән алган булыр идем.

А н ж е л а. Паспорт?! Нигә ул? Аңламадым, абый?

Н ә с и м. Сине туп-туры загска алып китәргә иде исәп! Язылышырга! Кавышкан булыр идек! Пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп, чөкер-чөкер килеп, үлгәнче яшәр идек!

А н ж е л а. Соңга калдыгыз шул, абый җаным. Мин күптәннән кеше кешесе!

Н ә с и м. Кем ул? Кая ул кеше? Килсен монда! Әй! Кемнәр бар анда? Китерегез фәләнне! Хәзер мин аны... Бәргәләп! Дөмбәсләп! Изеп ташлыйм! Бах-бах! Гөрс-гөрс! Менә шулай! Әйбәт кеше иде... Урыны җәннәттә булсын!

А н ж е л а. Сез аны җиңә алмаячаксыз! Киресенчә! Ул сезне сытачак! Менә болай! Менә болай итәчәк! А-ау! Абый җаным, сез кайда? Ау!

Н ә с и м. Ау! Ау! Мә, усал телеңне бәйләргә бау! Син мине белеп бетермисең әле, асыл кошым, җанкисәгем! Мине бу дөньяда беркем дә сыта алмый!

А н ж е л а. Браво! Афәрин! Мин сезгә соклана башладым!

Н ә с и м. Миндә гайрәт! Миндә көч!

А н ж е л а. Сездән курка үрмәкүч!

Н ә с и м. Көләргә ашыкма, бала! Миндә бетмәс-төкәнмәс энергия! Миндә ут-ялкын!

А н ж е л а. Калай мич икәнсез! Аңлашылды! Ярый, абый! Әйбәтләп урнашыгыз! Җайлашыгыз! Сый-нигъмәтләр өстәлдә! Берәр нәрсә кирәк булса, менә бу төймәгә басыгыз! *(Чыгып китә.)*

Н ә с и м. Ни! Карале, Аджика! Тфү! Кем әле?! А-ан... жела! Сорый алмый калдым нечкәбилдән... Нәгаләт! Бирегә мине кем чакырды соң? Оһо! Пианино да бар монда! Ноталар! У-у! Таныш көй! «Саубуллашу вальсы»! Саҗидә Сөләйманова шигыре! Мәсгут Имашев көе! Башкара... Башкара татарның бөек композиторы Нәсим Вафин! Көчле кул чабулар! Алкышлар! Рәхмәт! Рәхмәт! Хәзер уйнап җиффәрәбез, хәзер... Тә-ә-әк! Сүзләре, сүзләре... Ничек башланадырые әле? Әһә! Исемә төште! *(Уйный башлый, җырлый.)*

Ак алъяпкычларда ак канат,

Күңел оча, гүя акчарлак...

Ф ә р и д ә белән А н ж е л а керә. Анжела Фәридәгә «урнашыгыз» диган сыман ишарә ясый да югала. Нәсим Фәридәне күрми.

Ак канат иңнәрдә,
Җилферди җилләрдә,
Күңел оча ерак җирләргә...

Ф ә р и д ә *(җырның кушымтасына кушылып)*.
Аерылыр чак җитә, дусларым,
Сизелмәде ун ел узганы.
Хуш, мәктәп, үз күрдең,
Яшәргә көч бирдең,
Канат куеп безне үстердең...

Н ә с и м *(Фәридәне күреп ала, уйнаудан туктап)*. Бәрәкалла! Кем бу дисәм, минем яшьлек мәхәббәтем икән! Сәлам, Фәридә!

Ф ә р и д ә. Нихәл, классташ!

Н ә с и м. Ал да гөл! Бер казанда кайныйбыз... Күреш-мәгәнгә әллә никадәр вакыт үткән!

Ф ә р и д ә. Сагынуың шулкадәр генә, димәк! Без яраткан көйне уйнадың. Хәтерлисеңме?! Безнең классның иң яраткан җыры иде бит ул!

Н ә с и м. Кемдер нәкъ менә шул җырның ноталарын күрсәтеп куйган...

Ф ә р и д ә. Әллә сине дә чакырдылармы?

Н ә с и м. Соравыңа каршы сорау: кем чакырды икән безне?

Ф ә р и д ә. Ресторанда булмаганыма... У-һу-һу!

Н ә с и м. Безгә чакыру кәгазен кем җибәрде икән, дим?

Ф ә р и д ә. Белмим. Сыйларга уйлаган булсалар, ашыксыннар! Университетта дәресләрем бар! Фәннәр академиясенә дә сугылырмын дигән идем.

Н ә с и м. Ашыксаң, әнә өстәл тулы ризык! Сыйлан рәхәтләнеп!

Ф ә р и д ә. Монда бит җиләк-җимеш кенә! Аш ашыйсым килә. Токмачлы өй ашы!

Н ә с и м. Өй ашын өеңдә ашыйсың инде, сабакташ!

А н ж е л а керә.

А н ж е л а. Апа, чак кына түзегез, яме! Сез теләгән токмачлы аш бераздан булачак! Киләсе кешеләр килеп бетсен инде! Зинһар, сабыр итегез! Җимеш капкалый торыгыз! Банан бар әнә, әфлисун, киви, фейхуа!

Ф ә р и д ә. Рәхмәт, сеңлем! Моңарчы фей... хуасыз яшәдем... Түзәргә калгач, түзәрмен инде!

Н ә с и м *(көйләп)*. Түзәргә икән түзәргә, бернигә карамыйча... Иң мөһиме, ни күрсәк тә халык белән, ил белән бергә!

А н ж е л а. Гафу итегез... *(Чыга.)*

Ф ә р и д ә. Әллә безне тыңлап торалар инде?!

Н ә с и м. Шыпырт! Без монда күзәтү астында. Берүк ашау-эчү турында сүз ычкындыра күрмә! Токмачлы аш турында бигрәк тә! Ләм-мим! Юкса харап булабыз! Тсс!

Ф ә р и д ә. Әс... әс... әстәгы... фирулла!

Н ә с и м. Ха-ха! Әллә курыктың инде?!

Ф ә р и д ә. Элек тә шамакай идең... Еллар гына үзгәртә алмый икән кешене! Төпле егет булмадың шул! Таянырлык булсаң, мин сине ташламый идем!

Н ә с и м. Аһ! Менә ничек икән! Син? Мине ташладың?

Ф ә р и д ә. Әйе! Мин ташладым бит сине!

Н ә с и м. Ничек инде?! Киресенчә! Мин! Үзем! Сине ташладым!

К а м и л керә.

К а м и л. Театрга эләктем инде әллә? Дөрес кердемме соң? *(Күзлегенең пыяласын сөртеп ала.)* Ха! Таныш йөзләр! Нәсим! Фәридә! Әссәламегаләйкем!

Н ә с и м. Камил?! Син нишләп йөрисең монда?! Вәгаләйкемәссәлам!

Ф ә р и д ә. Исәнме, иманым Камил!

К а м и л. Юмористлар сез! Артистлар! Ниһаять, сез бергә икән! Котлыйм! Бәхетле булыгыз, яшьләр!

Н ә с и м. Ташлале! Әллә ниләр сөйләмә! Безгә элек кавышасы иде аны! Яшь чакта! Күңелле чакта! Хәзер нишлим мин бу галимә белән?!

Ф ә р и д ә. Бик кирәгең барые!

К а м и л. Туктагыз әле, туктагыз! Кочаклашырга өлгермәгәннәр, инде ызгыша да башладылар! Әйдәгез, кыстагыз мине! Сезнең хөрмәткә бер рүмкә! Юк! Бер стакан! Мөлдерәмә тутырып! Нарзан!

Ф ә р и д ә. Камил, син дөрес аңламадың! Минем бу көйсез кияү белән алыш-бирешем юк!

Н ә с и м. Мин дә бу ханымның кем икәнен белмим! Дөрес, Фәридә Гайсина дигән бер ханым-туташ... имеш... тарихи темага ниндидер мәкаләләр яза икән дип... ишеткәләгән бар шикелле... сыман кебек үзе! Бәлки, ялгыша торганмындыр...

К а м и л. Берни дә аңламыйм! Әй, башымны тинтерәт-мәгез әле! Мине зурлап чакыргансыз! Рәхмәт, рәхмәт! Табыныгыз бик күркәм күренә!

А с и я керә.

А с и я. Гафу итегез! Миңа әти кирәк иде! Күрмәдегезме минем әтине?

К а м и л. Мин монда, кызым!

А с и я. Акыллы гына кешегә охшагансыз, абый! Әйте-рием инде бер сүз! Башка кешеләр бар! Юк, күрмәдем, дип кенә әйтеп булмый идеме?! Гут бай! Чау! Па-почка! *(Чыгып китә.)*

Н ә с и м. Бик усал кызга охшаган!

К а м и л. Миңа кемнедер хәтерләтте ул! Әһә! Юк! Исемә төшми! Баягынак ни дидем әле, хөрмәтлеләрем?!

Ф ә р и д ә. Табын... бик күркәм...

К а м и л. Ә-ә-ә... Әйе! Кыстагыз инде әйдә!

Н ә с и м. Мин сине чакырмадым, әфәндем!

Ф ә р и д ә. Мин дә!

К а м и л. Ничек инде?! Менә бит чакыру кәгазе!

Н ә с и м. Аңламаганнар өчен кабатларга мәҗбүрмен, хөрмәтлем! Мин чакырмадым! Чөнки үзем дә чакырулы!

Ф ә р и д ә. Рәхим итегез, классташ әфәнделәр! Карагыз, күрегез! Миндә дә сезнеке шикелле чакыру кәгазе!

К а м и л *(такмаклап-көйләп)*. Бүген мине бер мәҗлескә чакырдылар. Килгән идем, «кайтып кит» дип акырдылар... Шайтан алгыры! Кем чакырды соң мине, алайса?!

Н ә с и м. Дикъкать! Сөекле вә газиз халкымның кадерсез вәкилләре! Игътибарны бер генә секундка миңа юнәлтәбез! Бүген нинди көн? Кайсы ай? Беренче апрель түгелме?!

Ф ә р и д ә. Нишләп апрель булсын! Көз бит инде! Әбиләр чуагы!

К а м и л. Тышта – көз! Өйдә – без! Җырлыйбыз, әйдәгез!

Н ә с и м. Ташлале! Димәк, сентябрь! Әллә октябрьме?

Ф ә р и д ә. Календарь юкмыни соң бирәрегездә?

Н ә с и м. Кесә телефоны булса да ярый!

К а м и л. Мин – шагыйрь! Кесәмдә каләм генә!

Ф ә р и д ә. Ә мин телефонымны өйдә калдырганмын!

Н ә с и м. Аңлашылды! Сине, әфәндем, сине, ханым, һәм мине, кыскасы, безне кемдер шаярткан!

К а м и л. Алданганыбызны таныйк та... тайыйк моннан! Поэма язасым бар! Кабат күрешкәнгә кадәр!

Н ә с и м. Ашыкма! Бергә китәбез! Күптән түгел генә симфония тәмамладым. Искиткеч шәп! Шуны Япониягә конкурска җибәрергә исәп! Җиңсәм, миннән сезгә бүләк!

Ф ә р и д ә. Поэма! Симфония! Каян килгән эшем кешеләре! Барыгыз, бар! Берүзем рәхәтләнеп сыйланыйм әле! М-м! Хөрмәсе дә хөрмәсе!

К а м и л. Поэманы мин иртәгә дә язалам! У-у-у! Киш-миш!

Бигрәк тәмле бу йөзем!
Бигрәк өлгер мин үзем:
Табындагы бар йөземне
Ашап куйыйм берүзем!

Н ә с и м. Шулхәтлеерактан! Акча түләп! Трамвай белән килеп!

К а м и л. Бу сый-хөрмәт иртәгә булмаячак!

Н ә с и м. Ашамыйча-эчмичә!

К а м и л. Шулай бит, яшьти?!

Н ә с и м. Шушы табынны ташлап китсәм?! Мин кем булам инде?

К а м и л. Дивана!

Ф ә р и д ә. Плюс җүләр!

Н ә с и м. Килешәм!

Ф ә р и д ә *(сәгатенә күз төшереп)*. Ай! Сезнең белән сайрашып!.. Соңга калдым! Телефон кирәк! *(Камилгә.)* Синеке юк та юк! *(Нәсимгә.)* Синеке – кибеттә! Монда телефон бардыр әле! Мин хәзер керәм! *(Чыга.)*

Н ә с и м. Бик мөһим эшләрен читкә куеп, бирегә килгән кадерле кунагыбыз, мөхтәрәм Нәсим әфәнде! Сине монда бүтән кыстаучы булмас, ахры! Иркенләп утыр! Рәхәтләнеп аша! Туйганчы эч! Кызлар коч! Кызлар дигәннән... Монысына өметләнмим, әлбәттә!

К а м и л. Кызлар кия кызыл итәк,
Безгә карасы да юк.
Хәзер кызлар үзе килә,
Безгә барасы да юк!

Ш а к и р керә. Кара күзлектән.

Ш а к и р. Әфәнделәр! Монда кунакларның һәр теләген үтиләр. Сезгә нинди кызлар кирәк? Блондинкалармы? Бар! Брюнеткалар кызыксындырса, пожалысты! Шатенкалар кирәкме? Табабыз! Кайсы милләт кызын телисез? Татар, урыс, чуваш, ар... Вьетнам кызларына ничек карыйсыз? Нигретянка да бар!

Н ә с и м. Безгә мари булса да ярый! Чибәр генә булсын!

Ш а к и р. Димәк! Ике мари кызы! Сезнеке!

Н ә с и м. Йә, нишлибез? Сүз сезгә, иптәш шагыйрь?!

К а м и л. Мин пас! Вакытым юк! Мин ашыйм! Иртән бер тәгам ризык капмаган кеше мин!

Н ә с и м. Ишеттеңме, иптәш? Ул ашый!

Ш а к и р. Импотент түгелдер бит?!

К а м и л. Мин ашыйм! Мин берни дә ишетмим! Мин ашыйм!

Н ә с и м. Иртә белән каһвә дә эчмәгән идем. Кызлар да җәлке! Карале, командир... Ничә тәңкә тора?

Ш а к и р. Нәрсә?

Н ә с и м. «Нәрсә» түгел, кем! Берсе күпме тора?

Ш а к и р. Ә-ә-ә... Сезгә – бушлай!

Н ә с и м. Сәвсим бушлаймы?!

Ш а к и р. Сәвсим! Сезнең өчен түләп куелган!

Н ә с и м. Түләнгән?! Кем түләде?

Ш а к и р. Әйтмәскә кушты!

Н ә с и м. Камил! Син түләдең што ли?

К а м и л. Мин – шагыйрь! Түләү ише мәсьәләләр белән минем шәхси секретарем шөгыльләнә...

Н ә с и м. Каян килгән буржуй шагыйрь! Секретарь, имеш! Туктале! Әллә чынлап?

К а м и л. Кәнишне!

Н ә с и м. Чибәрме?

К а м и л. Бик матур егет!

Н ә с и м. Тфү! Пачти ышанган идем...

Ш а к и р. Бәлки, сезгә малайлар кирәктер? Бездә алар да бар!

Н ә с и м.<br>К а м и л. Нәрсә?!

Ш а к и р. Кирәкми икән кирәкми... Ихтыярыгыз! Миңа әйтергә куштылар. Мин сезгә җиткердем.

К а м и л. Туктале! Кем әйтергә кушты?

Ш а к и р. Гафу итегез, мине клиентлар көтә! *(Чыга.)*

К а м и л. Берни аңламыйм! Нәрсәдер не то!

Н ә с и м. Монда ялгыш эләкмәдек микән?

К а м и л. Безне башкалар белән бутыйлардыр, бәлки?!

Н ә с и м. Чакыру билетларын кая куясың? Исем-фамилияләр безнеке язылган бит!

К а м и л. Алайса, кем чакырды соң безне?

Ф ә р и д ә керә.

Ф ә р и д ә. Җегетләр! Башыгызны катырмагыз! Мин чакырдым!

Н ә с и м.<br>К а м и л. Син?!

Ф ә р и д ә. Әлбәттә!

Н ә с и м. Ышанмыйм!

К а м и л. Мин Фәридәгә ышанам! Чөнки! Чөнки аның сине күрәсе килгән!

Н ә с и м. Ә сине? Сине ник чакырган?

К а м и л. Иптәш итеп! Сиңа! Шулай бит, Фәридә?!

Ф ә р и д ә. Сүзләрең дөреслеккә якын. Мин сезнең икегезне дә сагындым! Яшьлек үтеп бара, җегетләр! Бүген кем бар, иртәгә кем юк дигәндәй... Үткәннәрне, балачакны, яшь вакытларны искә төшереп утырасы килде! Бер шәһәрдә яшибез! Ара-тирә генә күрешкәлибез. Исәнме, сәлам, диешкән булабыз. Шуның белән шул! Ә бит бар иде безнең дә яшь чаклар!..

К а м и л. Кесә тулы борчаклар!..

Н ә с и м. Ташлагыз әле! Ътте-китте яшьлек, дип җылап утырганчы, әйдәгез, җырлыйбыз! Их, алмагачлары!.. Сайрый сандугачлары...

Ф ә р и д ә. Ишеттегез микән? Беләсез микән? Безнең байтак сабакташ күптән бакыйлыкка күчте... Берәм-берәм китәләр... Их! Дусларым, дус-ишләрем! Нәзирә... Наил... Салават... Дания... Айрат...

К а м и л. Айрат?! Нәзирә?! Мин ишетмәгән идем!

Н ә с и м. Кими барабыз... Бернишләп булмый!

К а м и л. Урыннары оҗмахта булсын!

Ф ә р и д ә. Хәбәрләшеп торырбыз, бер-беребезне онытмабыз, диештек! Кошлар кебек очып киттек тә...

Н ә с и м. Югалдык!

К а м и л. Адаштык!

Н ә с и м. Кайсыбыз кайда? Белгән юк!

Ф ә р и д ә. Тегендә! Без кабат! Барыбыз да! Берәр вакыт! Җыелырбыз микән? Малайлар, ә?!

Н ә с и м. Әлбәттә! Кыямәт көнендә!

К а м и л. Фәридә! Син безне чакырып, дөрес эшләдең. Рәхмәт сиңа! Телисеңме, мин сиңа бер шигырь укыйм?

Н ә с и м. Миңа да укы! Тик җылата торган булмасын, яме.

Ф ә р и д ә. Янда шагыйрь бар әле... Әйдә, сөйләп карале!

Н ә с и м. Фәридә! Шагыйрьләр өлешенә кермә берүк! Зинһар, учёный гына булып кал!

Ф ә р и д ә. Талантым ташый! Иртәгәдән көй дә яза башлыйм әле!

Н ә с и м. Ходаем! Музыка дөньясын афәттән саклый күр берүк!

К а м и л. Интеллигенция! Сезгә әйтәм! Тел көрәштерүдән тәки туктый алмыйсыз бит, ә?!

Ф ә р и д ә. Камил, укы!

Н ә с и м. Укы, дускай!

К а м и л. Ак күлмәк кигән идем,  
Каралмас дигән идем...  
Гел шатлыктан торган дөньям  
Таралмас дигән идем...

Каралды күлмәкләрем,  
Таралды дөньяларым...

А с и я керә.

А с и я. Гафу итегез! Монда Рөстәм килергә тиеш! Зинһар, аңа әйтегез әле... Мин матурлык салонында булам!

Ф ә р и д ә. Сеңлем, телефоның кулыңда... Кайда икән-легеңне нишләп үзең әйтмисең?

А с и я. Мин аңа бик каты үпкәләдем! Без сөйләшмибез!

Н ә с и м. Алай икә-ән...

Ф ә р и д ә. Дуслашырсыз әле, сеңлем... Мәхәббәт шундый нәрсә инде ул... Ызгыштыра да, кочаклаштыра да!

Н ә с и м. Бу мизгелләрне хәтереңдә калдыр, сеңлем! Бу алтын сүзләрне мәхәббәт белгече әйтте! Афәрин, Фәридә ханым!

А с и я. Сез бик кызык кешеләр икәнсез!

К а м и л. Миңа үпкәләмисеңме инде? Әтиеңне таптыңмы?

А с и я. Таптым да, тапмадым да... Мин сезгә ачуланмыйм, абый! Зинһар, Рөстәмгә әйтергә онытмагыз инде! *(Чыга.)*

Ф ә р и д ә. Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...

Н ә с и м. Бөек Тукай! Нинди матур итеп әйткән!

Ф ә р и д ә. Нишләп Тукай булсын! Такташ, диген! Хөр-мәтле наданым!

Н ә с и м. Беләм лә! Синең реакцияңне генә тикшерәсем килгән иде!

К а м и л *(хисләнеп)*. Сагыш тулы шигыремә кинәт
Бәреп керде әрсез Матурлык!..

Ф ә р и д ә. Утырышыгыз әле, җегетләр! Бер сөйләшик әйдә туйганчы!

К а м и л. Бервакыт качышлы уйныйбыз... Су буенда... Икәү бергә камышлар арасына качтык...

Н ә с и м. Бер такмаза искә төште, җәмәгать!
Әти китте базарга,
Миңа хатын карарга.
Әти дә юк, хатын да юк,
Үзем киттем базарга!
Базар буе камышлык,
Бер кыз белән таныштык...

Ф ә р и д ә. Бүлдермә кешене, әдәпсез!

Н ә с и м. Пардон!

К а м и л. Күзләр – күздә... Куллар – кулда... Вакыт та, дөньяның барлыгы да онытылды... Тик икәүбез: ул да мин! Бермәл иреннәрем аның иреннәренә якынлаша башлады...

Н ә с и м. Интересно!

Ф ә р и д ә. Тсс!

Н ә с и м. Димәк, ул дигәне син! Аһ! Ә мин ул чакта сиңа ышанган идем!

Ф ә р и д ә. Җә инде, әртисләнмә! Тыңлап бетер!

К а м и л. Бу безнең беренче үбешүебез иде.

Ф ә р и д ә. Мин кем турында сүз барганын чамалыйм.

Н ә с и м *(җырлап)*. Онтылмый беренче саф мәхәббәт, Онтылмый Агыйдел сылуы... Ә мин инде күптән оныттым!

Ф ә р и д ә. Җансыз кеше син!

Н ә с и м. Мин бит сине оныттым, димәдем! Тәүге мәхәб-бәтем турында әйтүем! Карале, нишләп син гел миңа бәйләнәсең, ә! Яратмыйм мин сине! Бетте-китте!

Ф ә р и д ә. Ой-ой-ой! Кирәгең бер тиен! Исем китте иске чикмәнгә!

К а м и л. Бүген мин сезне кавыштырып, өйләндереп, култыклаштырып берегезнең фатирына кайтарып куймасам, газиз ата-анам кушкан исемем Камил булмасын!

Н ә с и м. Едва ли! Бөтенләй исемсез калуың бар!

Ф ә р и д ә. Акыллы кеше сүзен бүлдермә. Тыңлап кына тор!

К а м и л. Тыңлар әле, тыңлар, Алла теләсә! Кияү башлы кешегә охшаган!

Н ә с и м. Көлмә, көлмә! Үзеңә дә камыт табарбыз!

Р ө с т ә м керә.

Р ө с т ә м. Исәнмесез!

Ф ә р и д ә. Исәнме, Рөстәм! Әйдүк, түргә уз!

Р ө с т ә м. Сез минем исемне каян беләсез?

Н ә с и м. Маңгаеңа язылган бит! Әнә, бар, көзгедән кара!

Р ө с т ә м. Чынлап әйтәсез дип торам! Язылмаган ич!

К а м и л. Энем, принцессаң матурлык салонында!

Ф ә р и д ә. Ул салон монда каядыр күземә чалынды... Бар, эзләп тап сөеклеңне!

Р ө с т ә м. Сез барысын да беләсез?!

Н ә с и м. Без – атаклы күрәзәчеләр! Бирегә халыкара симпозиумга җыелдык!

Ф ә р и д ә. Ник алдыйсың инде, ә?

Н ә с и м. Әйе, кичер, гафу ит, егетем... Бу ханым күрәзәче түгел! Бозымчы! Монда ялгыш эләккән!

К а м и л. Энем, тыңлама син бу абыеңны! Алдашмыйча торалмый ул. Аның бүген өянәге кузгалган көн.

Р ө с т ә м. Кызык! Мин бер кешене беләм. Аның да өянәге бик еш була. Тик аңа карарга куркыныч! Идәндә тәгәрәп йөри, авызыннан күбекләр чыгара...

Ф ә р и д ә. Абау, җаным! Берүк Ходай күрсәтмәсен!

К а м и л. Нервынныйдыр ул. Моның нервысы нык!

Н ә с и м. Бырат! Кызың бик чибәр. Янында гына йөрт! Чәлдерә күрмәсеннәр!

Р ө с т ә м. Чибәр икәнен үзем дә беләм! Мин аны беркемгә дә бирмим!

К а м и л. Синең кебек чакта мин дә шулай уйлаган идем... Дөнья бу, энем!

Н ә с и м. Өлкәннәрнең сүзен ишет, үзеңчә эш йөрт!

Р ө с т ә м. Рәхмәт сезгә. Киңәшләрегезне һәрвакыт истә тотармын! Мин китим инде...

Н ә с и м. Китәргә рөхсәт итәм!

Р ө с т ә м. Сау булып торыгыз! *(Чыга.)*

К а м и л. Онытма, энем, дөнья бу!

Ф ә р и д ә. Пар килгәннәр. Күз тимәсен!

Н ә с и м. Яшьлегемне искә төшердем, әле генә шуны төшендем!

Ф ә р и д ә. Үсеш бар. Тәки такмакчыга әверелеп барасың син дә!

К а м и л. Ике тигез яшь мәхәббәт хөрмәтенә оештырылган күркәм мәҗлесебез дәвам итә. Халык әйтсә, хак әйтә, дибез. Бу чыннан да шулай. Халкыбызның мондыйрак бер әйтеме бар: «Тормышта иң зур байлык – сәламәтлек». Тагын бер бик зур байлык бар. Нәсим, монысын сиңа карап әйтәм. Ул байлык – хатын-кыз. Ягъни бу очракта Фәридә ханым! Яхшы хатын – ярты бәхет ул! Яхшы хатынның ире дә яхшы була. Әйдәгез, сезнең хөрмәткә берне күтәреп куйыйк! Гафу итегез! «Нарзан» гына эчәргә мәҗбүрмен. Ярамый! Булды вакыт – күп шаярдык... Хәзер сүз кадерле кәләшкә бирелә!

Н ә с и м. Кем ул кадерле кәләш?

Ф ә р и д ә. Тилегә салынма инде, җаным! Күреп торасың ич: монда асыл зат мин генә!

К а м и л. Фәридә, тот микрофонны!

Ф ә р и д ә. Бер яшь егет бик кайгырып утыра икән. Шулай бик озак утырган бу. Менә бермәлне моның янына бер акыл иясе килеп туктаган. Егет моң-зарын әйткән моңа. «Таң атканчыга кадәр генә вакытым бар, – дигән ул. – Атам явыз кеше кулыннан һәлак булды. Сөйгән кызымны бүген төнлә урлап китәргә җыеналар. Иң якын дусларым кунакка чакырды. Нишләргә дә белмим: әүвәл атам өчен үч алыйммы, сөйгәнемне коткарыйммы, әллә дусларым янына барыйммы?» Акыл иясе әйткән: «Атаң өчен син теләсә кайсы вакытта үч алаласың. Әгәр сөйгән кызың үзе теләми икән, аны һичкем урлый алмый. Ә инде дусларыңны югалтасың икән – син аларны кире кайтаралмыйсың! Дусларың белән очраш, алар сиңа ярдәм итәр!» – дигән. Егет дуслары белән очрашкан. Ул алар белән таңга хәтле бөтен проблемаларын хәл иткән. Әйдәгез, дуслар өчен, дуслык өчен алма согыннан авыз итик!

Н ә с и м. Валлаһи газыйм, ятьмәңә эләктерәсең бит мине! Караул! Кешеләр, коткарыгыз!

Ф ә р и д ә. Ул кадәр авызыңны ачма. Үпкәң күренә! Кичә кычкырырга иде. Бүген соң инде!

К а м и л. Соң инде, хуш инде. Иртәгә кыш инде...

Н ә с и м. Әнкәй гел әйтә бит югыйсә... Һәр чакырган җиргә барма, дошманнарың тозагына эләгүең бар, ди... Хараплар гына булдым. Никләр тыңламадым икән сине, әнкәй бәгърем!

Ш а к и р керә.

Ш а к и р. Сүзегезне бүлдерсәм, гафу итегез! Күңелсез түгелме, дуслар?

Ф ә р и д ә. Юк, юк! Борчылмагыз!

Н ә с и м. Бар да яхшы, бырат! *(Көйләп җырлый.)* Башка берни дә кирәкми...

Ш а к и р. Теләгегез булса, саунага керергә мөмкин.

К а м и л. Мин ашыйм!

Ф ә р и д ә. Рәхмәт. Соңыннан!

Ш а к и р. Яхшы. Гафу итегез! *(Чыга.)*

Н ә с и м. Йа Хода!

К а м и л. Борчылма ул кадәр! Ни күрсәк тә, халык белән бергә!

Ф ә р и д ә. Бу кеше миңа кемнедер хәтерләтте... Бая телефоннан сөйләшергә чыккач та күземә чалынган иде... Ул чакта да уйлап куйган идем... Кемгәдер бик каты охшаган... Менә әйтә генә алмыйм!

Н ә с и м. Юкка башыңны авырттырма, Фәридә! Ну чтуж! Менә мин дә этигә охшаган!

К а м и л. Иллә дә очраштык әле, әйемегез?! Чакыруыңа рәхмәт, Фәридә!

Ф ә р и д ә. Исемә төште! Беләсезме, кемгә охшаган бу кеше?

Н ә с и м. Әйтсәң беләбез!

Ф ә р и д ә. Шакирга! Йөреше тач шуныкы!

К а м и л. Шакир?! Нинди Шакир? Илһам Шакир мәл-лә?

Ф ә р и д ә. Син нәрсә!

Н ә с и м. Бәлки, Җәвид Шакирдыр?!

Ф ә р и д ә. Бә-ә-әй! Үзебезнең Шакирны белмәскә инде сез!

Н ә с и м. Синең Шакирыңны без каян белик!

К а м и л. Шакир... Шакир... Самат Шакир дигән язучы бар иде... Кем соң ул? Безнең кавемме? Язамы, сызамы дигәндәй... Түрәләр затыннан булса... Минем алар белән алыш-бирешем юк!

Н ә с и м. Мин бер җырчыны беләм. Ләкин аның исеме Шакир түгел... Шакирә!

Ф ә р и д ә. Саесканны белмәскә инде сез!

К а м и л. Саескан?!

Ф ә р и д ә. Әйе! Классташ! Ничә ел бер партада утырдыгыз бит!

К а м и л. Ә-ә-ә... Аны әйтәсең икән! Минем бит аны мәктәпне тәмамлаганнан бирле күргәнем юк.

Н ә с и м *(Фәридәгә)*. Тапкансың аңа охшаган кешене. Шакир бит ул нинди иде! Юка иде – чыра кебек! Озын иде! Ә бу – бөтенләй башка кеше!

Ф ә р и д ә. Минем дә Шакирны күрмәгәнемә бишбылтыр! Барыбер теге адәм аңа кайсыдыр ягы белән охшаган!

К а м и л. Таптыгыз сөйләшер тема!

Н ә с и м. Кстати! Шакир дигәннән... Ә сез беләсезме? Минем аксак булуыма ул гаепле бит!

Ф ә р и д ә. Кит аннан!

Н ә с и м. Ышанмыйсызмы әллә? Чынлап шулай! Бу турыда минем моңарчы беркемгә дә сөйләгәнем булмады.

К а м и л. Саескан, саескан... Күкәй эчкән, май эчкән! Утырдык шул бер партада аның белән...

Ф ә р и д ә. Сораштырганым булды. Беркем белми. Кайда икән ул хәзер?

Н ә с и м. Тыңлыйсыгыз килмәсә сөйләмим!

К а м и л. Әйдә, бушат эч серләреңне!

Ф ә р и д ә. Мин белмәгәнием...

Н ә с и м. Мәктәптә укыганда мин чаңгы ярышларында катнаша идем. Исегездәдер?!

К а м и л. Истә булмыйча! Мәктәп чемпионы идең бит!

Ф ә р и д ә. Районнан җиңеп кайтканыңны хәтерлим әле.

Н ә с и м. Ул чакта физкультурадан Шамил абый укытты. Мине гел үсендереп, канатландырып тора. Ярыштан ярышка йөрим. Чемпион, диләр! Рәхәт! Чираттагы ярышка әзерләнгән вакыт. Беләсез бит инде, мәктәп артында гына чаңгы юлы бар иде. Көн саен шунда шуам. Беркөнне Шакир килде минем янга. Ул да чаңгы таккан иде. Әйдә, шуып, әйләнеп киләбез, ди. Кыстый бу. Мин шуа-шуа арыган идем. Бүгенгә җитәр, дип, бүтән шумаска итәм. Иптәш булырсың, бер генә әйләнеп килик инде, дип ялына Шакир. Эңгер-меңгер чак. Караңгы төшә башлаган иде инде. Караңгыдан шүрлидер дип тә уйлаганмыйндыр, бәлки.

Ф ә р и д ә. Дөрес уйлагансың! Куркаклыгы бар иде Шакирның!

Н ә с и м. Тәки ризалатты бу мине. Киттек. Мин – алдан, Шакир – арттан... Шуабыз! Көн саен кимендә унар тапкыр шуган юл. Таныш юл. Күз йомып та шуа ала идем диюем! Кирәк бит! Бер калкулыктан түбәнгә таба шуып та киттем... Һәм әллә нәрсә булды шунда!

К а м и л. Мин хәтерлим әле ул чакны. Чанага салып кайттылар сине. Мәктәпкә Шамил абый күтәреп керде. Син акырасың!

Ф ә р и д ә. «Аягым! Аягым!» дип кычкырасың. Мин дә хәтерлим!

Н ә с и м. Мин ул урынны кабат тиз генә барып күрал-мадым. Шамил абый әйтте шикелле. Кемдер махсус чокыр- казыган, дигән иде! Мин шул чокырга эләккәнмен, имеш! Мәтәлгәнмен! Чаңгым чәрдәкләнеп сынган! Менә бу аягыма чаңгы таягы кадалып кергән иде. Чокырга эләгеп мәтәл-гәнемә башта ышанмадым! Чөнки ул чокыр мин шуганда юк иде бит! Ул юлдан күптән түгел генә шуып узган идем!

Ф ә р и д ә. Алайса, Шакир икәнен каян белдең?

Н ә с и м. Мин әле хәзер дә нәкъ менә Шакир дип тәгаен генә әйтә алмыйм. Фараз гына кылам.

К а м и л. Сине шуарга үтереп кыстаган бит. Димәк, Шакир! Мин моңа ышанам!

Ф ә р и д ә. Көнләшкәндер, күрәсең... Барыбыз да бала-чага гына идек шул. Ничә яшь булды микән ул чакта безгә?

Н ә с и м. Нишләп бала-чага булыйк! Җиденчедә инде мин кызлар белән чуп-чуп үбешә идем!

Ф ә р и д ә. Каян килгән Ромео! Үбешкәнсеңдер, әйе!

К а м и л. Шакир турында уйлап торам әле һаман... Минем бик матур авторучкамны суккан иде бит ул! Бишенчедә укыганда! Шул искә төште!

Ф ә р и д ә. Кеше әйберсен чәлдерергә ярата иде шул.

Н ә с и м. Саескан кушаматы шуның өчен тагылды бит инде аңа!

Ф ә р и д ә. Гайбәтен саттык Шакирның... Берүк Ходай кичерсен безне! Бу минутларда очкылык тотып интеккәндер инде, мескен!

К а м и л. Нәсим! Уйна әле берәр күңелле көй!

Ф ә р и д ә. Әйе! Үзеңнекен!

Нәсим пианинога таба бара. Шулчак бүлмәгә матур көй агыла башлый. Һәммәсе дә аптырап, як-якка карангалап алалар, гаҗәпсенеп көй тыңлыйлар.

К а м и л. Бу ни бу?

Н ә с и м. Минем көй! Гаҗәп?!

Ф ә р и д ә. Искиткеч көй!

Н ә с и м. Ничек монда килеп эләккән бу? Кем уйната моны? *(Анжела күрсәтеп калдырган төймәгә баса.)* Алло! Мине ишетәсезме?

К а м и л. Нишлисең син?

Н ә с и м. Алло! Аджика!

Ф ә р и д ә. Өстәл белән сөйләшә бит! Күрмисеңмени?

А н ж е л а керә.

А н ж е л а. Тыңлыйм сезне, абый!

Н ә с и м. Бу көй каян килеп эләкте монда?

А н ж е л а. Белмим. Ләкин ул бездә байтактан бар инде. Бик матур көй, шулай бит?

Н ә с и м. Синең байтактан дигәнең ничә көн була инде ул?

А н ж е л а. Ну-у-у... Биш көнләп кенә бар инде! Бәлки, алтыдыр... Нигә сорыйсыз, абый?

Н ә с и м. Гаҗәп! Гаҗәп! Һәм бик сәер! Берни дә аңламыйм! Бу – мин язган симфония! Мин аны күптән түгел генә тәмамладым! Беркемгә дә бирмәдем югыйсә! Ничек монда килеп эләккән?

Ф ә р и д ә. Шәп композиторны халык бик тиз таный ул!

К а м и л. Әле син көй язмагансың, ә ул инде күптәннән халык күңелендә!

Н ә с и м. Көлмә, көлмә!

А н ж е л а. Сез көйләр язасызмыни, абый? Композитормыни сез? Мин бик күп композиторларны беләм. Мәсәлән, Бетховенны! Безнең этебезнең исеме дә шундый! Бахны беләм! Аһа! Моцарт! Аһа! Рөстәм Яхин! Татарстан гимны көен ул язган. Шулай бит?! Мин беләм! Аһа! Беләсезме, мин аеруча Мендельсон маршын яратам!

Ф ә р и д ә. Кияүгә бик еш чыгасыңдыр син, сеңлем?! Шуңа күрә яратасыңдыр ул көйне! Загста гына уйнаталар түгелме соң аны?

А н ж е л а. И апа! Нишләп еш кияүгә чыгыйм! Шул... айга бер туры килә кайчак!

К а м и л. Кара син аны!

Ф ә р и д ә. Әстәгъфирулла!

А н ж е л а. Ышана күрмәгез тагы! Алдады-ым!

Н ә с и м. Көйнең каян килеп эләккәнен әйталмадың инде, сеңлем, тәки?!

А н ж е л а. Хәзер белешеп карыйм. Берәр нәрсә ачыкласам әйтермен! Яме, абый?!

Н ә с и м. Яхшы!

Анжела чыга.

К а м и л. Сәерме?

Н ә с и м. Бик сәер!

К а м и л. Бу дөнья бу! Яшәү мөмкин
Пропискасыз килеш!
Әмма бүген бер сорауга
Җавап табу тиеш!
Килүен автобус белән килдем! Кем мине такси белән кайтарып куя?

Н ә с и м. Эчмичә исерден! Нинди кайту ди! Ташлале! Әйдә, укы тагын шигырь!

К а м и л. Яттан белмим! Соңгы вакытта хәтер начарланды. Янымда китабым юк!

Кулына поднос тотып, Ш а к и р керә.

Ш а к и р *(Камилгә)*. Рәхим итегез!

К а м и л. Нәрсә бу?

Ш а к и р. Китап!

К а м и л. Күрәм!

Ш а к и р. Күргәч!

К а м и л. Кем китабы?

Ш а к и р. Кулыгызга алып карагыз, шагыйрь иптәш!

К а м и л *(подностан китапны ала, тышлыгына карап)*. «Яшьлегем аланнары»! Матур исем! Тышлыгы да бик матур! Минем дә шундыйрак исемле бер шигырем бар! Авторы кем бу китапның?

Ш а к и р. Китап сезнең кулда ич! Анда авторы күрсәтелгән! *(Чыгып китә.)*

К а м и л *(кинәт артык гаҗәпләнеп)*. Моның булуы мөмкин түгел!

Н ә с и м. Ни бар? Ник шаккаттың?

Ф ә р и д ә. Кулында башка шагыйрьнең затлы китабын күреп, Камил көнләшүдән үлә язды!

К а м и л. Бу... бу... минем китап бу! (Китапны тиз-тиз генә караштырып ала.) Минем шигырьләр!

Н ә с и м. Кая, кая! Карыйм әле! Синеке шул!

Ф ә р и д ә. Миңа да күз төшерергә рөхсәт итегез!

Н ә с и м. Бик затлы китап! Идәнгә төшереп җибәрә күрмә!

Ф ә р и д ә *(китапны бармаклары белән сыйпап)*. Юкка чыкты! Әкәмәт! Карагыз әле! Юкка чыкты, дим!

Н ә с и м. Нәрсә юкка чыкты?

Ф ә р и д ә. Хәрефләр! Сөрткән кебек итеп... Болай гына иткән идем... Исем дә, фамилия дә юкка чыкты!

Н ә с и м. Вәйт замана! Нәрсә генә уйлап чыгармыйлар!

К а м и л *(башын тотып)*. Ялгыш... Әйттем... Минем шигырьләр түгел алар!

Ф ә р и д ә. Бәррәч! Монда башка исем пәйда булды. Ша-кир... Ка-зый-хан... Шакир Казыйхан!

Н ә с и м. Кем ул?

Ф ә р и д ә. Понятия не имею! Белмим!

К а м и л. Шакир?! Казыйхан?! Шулай булыр дип уйлаган идем аны...

Н ә с и м. Нинди сәер урын булды соң бу?! Сюрприз арты сюрприз! Хәер, сюрприз да түгел бугай инде... Минем көй... Синең китап... инде хәзер синеке түгел! Яки мин дурак! Яки кемдер монда безнең белән дурака валәйт итә! Сез берәр нәрсә аңлыйсызмы соң хет? Мин – юк!

Арыган кыяфәттә К ә р и м ә керә.

К ә р и м ә. Уф! Көчкә эзләп таптым! Исәнмесез! *(Як-ягына җәһәт кенә каранып ала.)* Дөрес кергәнмендер бит?!

Ф ә р и д ә. Әллә Кәримә инде?!

К а м и л *(сагаюлы тавыш белән)*. Кәримә?! *(Артка чигенә.)*

К ә р и м ә. Сез кемнәр? Фәридә?! Син түгелме соң бу?

Н ә с и м *(Фәридәнең каршына басып)*. Әйе, бу – Фәридә. Мин – Нәсим. Таныдыңмы?

К ә р и м ә. Нәсим! Таныдым! Фәридә! Сине дә. Сез һаман бергә икән.

Ф ә р и д ә. Бергә дип...

Н ә с и м. Минем сөекле хатыным. Өч малай белән ике кыз үстереп яткан булабыз.

К ә р и м ә. Үзе бер мәктәп бит бу!

Ф ә р и д ә. Ышанма. Алдый ул. Малайлар икәү генә. Но игезәкләр. Кызлар, киресенчә, өчәү.

Н ә с и м. Минем чир йогышлы булып чыкты, ахрысы. Ышанма, Кәримә. Бу ханым алдаша. Син кияүдәме? Мин буйдак.

Ф ә р и д ә. Кызый! Сине күрмәгәнгә! Җә! Җә! Кайда яшисең? Кайда эшлисең? Берни белмим. Кияүдәме син? Балаларың бармы? Ирең кем?

К ә р и м ә. Кияүдәмен. Моңарчы Себердә яшәдек. Бер кызыбыз бар. Ирем – бизнесмен.

Ф ә р и д ә. О-о-о! Олигарх! Яңа татар бае, димәк!

К ә р и м ә. Пачти.

Н ә с и м. Кәримә, олигархка кияүгә чыгып дөрес эш-ләгәнсең. Миңа... яисә... әнә теге иптәшкә кияүгә чыккан булсаң, бер рәхәт күрмичә, гомер буе чиләнеп яшәгән булыр идең!

К ә р и м ә. Теге иптәш дигәнең кем ул?

Ф ә р и д ә. Син бик яхшы беләсең аны.

К ә р и м ә. Ник арты белән тора? Бик оялчан мәллә?

Н ә с и м. Кәримә ханымның синең нурлы йөзеңне күрәсе килә. Бер генә минутка борылмассыз микән, шагыйрь әфәнде?

Камил борыла.

К ә р и м ә. Син?!

Н ә с и м. Әйе. Ул. *(Камилгә.)* Әйт инде, әйе, мин, диген.

К а м и л. Мин сезне белмим, ханым! Һәм белергә дә теләмим!

К ә р и м ә. Гафу итегез! Мин сезне бер белгән кешем дип торам. Ялгышканмын икән. Тагын бер кат сездән түбәнчелек белән гафу үтенәм!

Н ә с и м. Нәрсә?! Бу нинди кәмит тагы? Ничек инде? Син! Һәм син! Бер-берегезне белмисез?! Фәридә! Нишлиләр болар? Миңа карале, Фәридә! Мин кем?

Ф ә р и д ә. Татар композиторы!

Н ә с и м. Юк, исемемне әйт. Таныйсыңдыр бит?!

Ф ә р и д ә. Син – Нәсим.

Н ә с и м. Син – Фәридә. Ә болар кемнәр?

Ф ә р и д ә. Бу ханым безнең классташ – Кәримә. Ә бу әфәнде...

Н ә с и м. Шулай ук безнең классташ! Камил исемле. Ә нишләп классташлар бер-берсен танымый? Ниткән кылану бу?

Ф ә р и д ә. Нәсим, сәбәпләре бардыр... Минемчә, шулай.

К ә р и м ә. Без ничек барыбыз да монда җыелдык әле?

Н ә с и м. Ничек «ничек»? Нигә андый сорау бирәсең? Сине дә Фәридә чакыргандыр бит?

К ә р и м ә *(чакыру кәгазенә карап)*. Юк! Монда Фәридәнең исеме язылмаган!

Н ә с и м. Фәридә, аңлат классташка! Әйт безгә! Кем чакырды мине? Камилне?

Ф ә р и д ә. Белмим! Мин сезне чакырмадым!

Н ә с и м. Әл-пи-ти-си! Иске авыздан яңа сүз! Бая! Монда! Саф татарча! Кем әйтте соң? «Мин чакырдым!» диюче син идең бит, идрит-кудрит! Беренче апрель көнне дә болай алданганым юк иде.

Ф ә р и д ә. Мин үзем дә синең хәлдә.

К а м и л. Шикләнгән идем аны! Сый-хөрмәт өчен рәхмәт! Сау булыгыз! Мин киттем.

Камил китмәкче була. Кинәт, җәһәт-җәһәт атлап, Ш а к и р керә. Кыяфәте үзгәргән, күзлексез.

Шакир. Сәлам, классташлар!

К ә р и м ә. Шакир?! Сине дә чакырдылармыни?

Ш а к и р. Кәримә, не мешай! Камил, китәргә ашыкма! Барыгызны да мин чакырдым!

Ф ә р и д ә. Әйттем бит Шакир дип!

Н ә с и м. Алдашма! Шакирга охшаган, диден син!
К а м и л. Нинди кәмит бу?!
К ә р и м ә. Шакир! Бер-бер хәл булмагандыр бит?!

А с и я белән Р ө с т ә м керә.

А с и я. Әти! Син чакырдың, мин килдем!
Ш а к и р. Бик әйбәт!
Р ө с т ә м. Исәнмесез!
Ш а к и р. Мин бу егетне чакырмадым.
А с и я. Әти! Ул минем белән килде.

А н ж е л а керә.

А н ж е л а. Токмачлы аш кертергәме?
Ш а к и р. Юк!

Барысы да Шакирга карый.
Музыка.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге күренеш. К ә р и м ә белән К а м и л.

К ә р и м ә. Танымаганга салыштым, дисең инде... Шулай бик нык үзгәргәнменмени?! Алай дисәң... Фәридә дә, Нәсим дә шундук таныды. Ә син... юк! *(Камилчәрәк итеп.)* «Белергә дә теләмим!» Нигә? Ни өчен? Сәбәбе ни? Монда, киресенчә, мин сине танымаска тиеш идем!

К а м и л. Чынлап та, ханым, мин сезне белмим! Валлаһи, танымыйм!

К ә р и м ә. Ханым, имеш! Мин сине кичердем инде, Камил! Зерәгә танымаган булып кыланасың!

К а м и л. Сезгә миннән ни кирәк?

К ә р и м ә. Сез, димә! Мин икәү түгел! Миңа синең монда җүләр сатып тормавың кирәк! Мине тануың кирәк! Кәримә мин! Синең мәхәббәтең! Ялгышмасам, тәүге мәхәббәтең!

К а м и л. Минем тәүге мәхәббәтем үлде! Үлде! Унтугыз ел элек!

К ә р и м ә. Ни сөйлисең син, Камил! Менә ич мин! Мин исән! Мин сине кичердем, гафу иттем! Безгә аңлашырга кирәк! Хәзер үк!

К а м и л. «Мин кичерде-ем...» «Мин гафу итте-ем...» Аһ! Берәү кичергән икән! Аһ! Берәү гафу иткән икән! Минем беркемнән дә гафу сораганым юк! Моңарчы андый хәл булмады! Һәм алга таба да булмас!

К ә р и м ә. Юкка ярсыма, Камил! Минем синең алда бер гаебем дә юк!

К а м и л. Ха-ха-ха! Каян килгән әүлия! Күзгә карап ни сөйли бит! Хатны оныттың дамыни?!

К ә р и м ә. Нинди хат? Аңлатып сөйлә!

К а м и л. Миңа урау юллар аша килеп ирешкән хатың турында сүз бара. Соңгы хатың. Хәер, хат дип тә әйтеп булмый аны. Ике җөмләдән торган салкын сүзләр җыелмасы.

К ә р и м ә. Мин ул хатны хәтерләмим.

К а м и л. Ә мин хәтерлим.

К ә р и м ә. Сиңа ике җөмләле хат язганымны хәтерләмим.

К а м и л *(түш кесәсеннән кәгазь кисәге алып)*. Укы! Мин бу язуны унтугыз ел саклыйм инде. Унтугыз ел да бер ай... һәм дә унике көн.

К ә р и м ә *(укып)*. «Мин башканы сөям! Яратсаң, мине борчыма, хуш! Кәримә». Син шушыңа ышандыңмы? Мин сиңа мондый хат язмадым.

К а м и л. Мин синең почеркыңны таныйм. Тилегә санама мине.

К ә р и м ә. Мин сиңа бернинди хат язмадым. Әгәр алдасам, ипи тоткан кулым корысын!

К а м и л. Ул чакта ниләр кичергәнемне белсәң икән! Минем өчен син үлдең. Башны ташлап җәһәннәм читенә олактым. Көнем, төнем, бөтен дөньям буталды! Һәм беркөнне... Мин дә үлдем! Табиблар коткарып калды!

К ә р и м ә. Ходаем! Бу язуны кем тапшырды сиңа?

К а м и л. Хәзер соң инде. Үкенүдән файда юк.

К ә р и м ә. Ә мин ниләр генә уйламадым ул чакта! Син югалгач. Миңа бит сине күрше Петровка авылының юлдан язган бер марҗасы белән качкан диделәр.

К а м и л. Син ышандыңмы шуңа?

К ә р и м ә. Ышандым. Сиңа рәнҗедем.

К а м и л. Рәнҗешең төште. Мин гомер буе газап чигеп- яшим. Берьялгызым. Марҗа белән качкан, дигәннәр. Нишләп соң Петровкага барып, шул марҗаның үзен күрмәдең?

К ә р и м ә. Бардым. Алып баручылар булды. Ул марҗа чынлап та авылдан чыгып качкан иде. Синең белән качкан, диделәр.

К а м и л. Син кияүдәме? Һе, сорау биргән мин җүләр! Мин бая ук төшенгән идем инде... Балдагыңны күрдем...

К ә р и м ә. Сыйныфташлар безне югалтканнардыр...

К а м и л. Минем сиңа сүзем бар, Кәримә!

К ә р и м ә. Без аңлаштык шикелле, Камил! *(Чыга.)*

К а м и л. Э-э-эх! *(Чыгып китә.)*

Пауза. Музыка. А с и я белән Р ө с т ә м керә.

А с и я. Әйдә инде! Курыкма!

Р ө с т ә м. Курыкмыйм ла... Яхшы түгел. Әтиең бик каты итеп әйтте бит.

А с и я. Ә син җебемә. Әти кеше шулай кырыс булырга тиеш инде ул. Усал һәм куркыныч булырга тиеш. Бүре кебек!

Р ө с т ә м. Минем Шакир абыйга бернинди дә начарлык эшләгәнем юк. Ә ул мине барыбер өнәми.

А с и я. Яхшылык та эшләгәнең юк әле.

Р ө с т ә м. Сиңа өйләнсәм, шул була инде яхшылык.

А с и я. Мин кияүгә чыксам өйләнерсең.

Р ө с т ә м. Мин уйлыйм әле...

А с и я. Нәрсә турында уйлыйсың?

Р ө с т ә м. Өйләнергәме сиңа? Әллә өйләнмәскәме? Шул хакта баш ватам.

А с и я. Әти мине сиңа бирер микән? Әллә юк микән? Шул турыда баш ват син.

Р ө с т ә м. Бирми кая барсын! Минем кебек шәп җегетне көндез чыра яндырып эзләсә дә табалмый ул, дигән булам да булуын! Сизенәм. Әтиең сиңа бай кияү эзли. Ә минем кесәм буш. Дөрес, әлегә.

А с и я. Шулай булгач, юк өчен кайгырма. Син яратасың мине. Мин дә сөям сине. *(Пианино янына килә.)* Әйдә, мин уйныйм, син җырла.

Р ө с т ә м. Син башла. Мин кушылам.

Музыка.

А с и я
Р ө с т ә м *(бергәләп җырлыйлар)*.

Сине күрсәм, әллә нишлим –
Урын тапмыйм үземә.
Ике битем уттай яна,
Син карасаң күземә...

Утларга кермәс идем,
Суларга кермәс идем...
Син булмасаң, бу сөюнең
Барлыгын белмәс идем.

Сине күрсәм әллә нишлим –
Коелам да төшәмен...
Идән әллә кая китә,
Юкка чыга түшәмем.

Утларга кермәс идем,
Суларга кермәс идем...
Син булмасаң, бу сөюнең
Барлыгын белмәс идем.

Сине күрсәм әллә нишлим –
Телем телгә бәйләнә...
Очып йөргән бер хыялый
Күбәләккә әйләнәм.

Утларга кермәс идем,
Суларга кермәс идем...
Син булмасаң, бу сөюнең
Барлыгын белмәс идем.

Яшьләр җырлаган вакытта Шакир, Фәридә, Нәсим, Кәримә һәм Камил керә. Җырны тыңлап бетергәч, Шакирдан кала барысы да яшьләрне алкышлап кул чаба.

Фәридә. Браво! Мондый талантлы яшьләр булганда татар җыры яшәячәк! Базда дары бар әле!

Нәсим. Үзең җырлап карале! Афәрин!

Кәримә. Булдырасыз, балалар!

Камил. Сездә моң бар! Татар моңы! Бу бик зур нәрсә!

Асия. Рәхмәт!

Рөстәм. Рәхмәт!

Шакир. Бака туен бетердек! Укырга, укырга һәм укырга кирәк әле минем кызга! Җә, утырыштык! Җайлаштык! Менә шушы инде минем сюрприз!

Нәсим. Аппартаментың шәп.

Фәридә. Барысын да уйлагансың. Ни генә юк монда! Саунасы нинди затлы!

Нәсим. Не намекай, пожалысты.

Фәридә. Ул кунакханә бүлмәләре.

Нәсим. Отель, диген! Хәзер татарлар да шулай дип сөйләшә.

Фәридә. Отель-мотель, ресторан, кафе.

Нәсим. Исеме ничек матур, ә! «Казыйханда кунакта»! Үзе казый, судья, ягъни мәсәлән, үзе хан!

Шакир. Казыйхан бабай хөрмәтенә! Йә, урысчасы ничек? Урысчасы? «В гостях у Казихана»! Шәп бит!

Фәридә. Шәп кенәме соң! Супер! Ул бильярд бүлмәсе! Бу бүлмәгә генә карагыз! Искиткеч!

Шакир. Мактануым түгел... Мин моны бер ел дигәндә төзеп бетердем.

Нәсим. Акчаң булмаса төзерсең, бар!

Камил. Бүген барысын да акча хәл итә. Шуңа да бүген күпләрнең табынганы – акча!

Нәсим. Мин табынмыйм. Чөнки юк ул миндә.

Фәридә. Шакир, булдыргансың! Молодец!

Кәримә. Минем өчен дә сюрприз булды бу. Шаккаттым.

Шакир. Мин моны кызым Асия белән булачак киявемә бүләк итәчәкмен.

Асия *(Шакирны килеп кочаклап)*. Рәхмәт, әтием!

Ш а к и р. Ә син, егет, кияү булырга ашыкма! Кызым, минем күз тоткан кешем бар. Шуңа бирәм сине. Хәлле егеткә.

А с и я. Кирәкми ул миңа. Бу байлыгың да кирәкми. Мин Рөстәмне генә яратам.

К ә р и м ә. Шакир! Асия! Әрепләшмәгез!

А с и я. Юк! Мин моңа риза түгел! Без монда артык! Киттек, Рөстәм!

Ш а к и р. Асия! Беркая да китмисең! Утыр әнә тегендә!

А с и я. Минем язмыш минем үз кулымда! Ничек телим, шулай яшим! Нопасаран!

Р ө с т ә м. Без җиңәрбез!

А с и я. Молодец, Рөстәм!

Чыгып китәләр.

К ә р и м ә. Асия! И бала!..

Ш а к и р. Туктатма! Китсен! Ашаган табагы янына сыер да кайта. Кайтыр, нибуч...

Ф ә р и д ә. Бала гына бит әле болар! Ни әйткәннәрен үзләре дә аңламый торган вакытлары.

Ш а к и р. Аңлыйлар! Үзләренә кирәкне бик яхшы аңлыйлар!

К ә р и м ә. Бала күңеле – бәллүр! Саксыз орынып, чел-пәрәмә китерүең бар.

Ш а к и р. Йә, ярар! Бетердек сүз боткасын! Мин ни дисәм, шул булачак!

Н ә с и м. Дөрес. Ир-ат сүзе закон булырга тиеш.

Ф ә р и д ә. Баканың да койрыгы булырга тиеш.

Н ә с и м. Пардон! Мерси, мадам!

К а м и л *(Шакирга)*. Син безне монда ресторан белән сауна күрсәтергә генә чакырмагансыңдыр, шәт?! Минем уйлавымча, бу әле башы гына! Шулаймы?!

Ш а к и р. Дөрес уйлыйсың, иптәш шагыйрь әфәнде!

Ф ә р и д ә. Тиктомалдан ничек безне искә төшердең, Шакир?

К а м и л. Ялгышасың, Фәридә! Ул безне тиктомалдан гына искә төшермәгән... Ул безне гел исендә йөрткән! Безне монда җыюы да алдан ук планлаштырылган! Шулай бит, олигарх иптәш!

Ш а к и р. Тәк, тәк, тәк. Дөрес сукалыйсың. Тагын дәвам ит!

К а м и л. Синең максатың – бездән көлү! Байлыгың белән мактануың – шуңа бер мисал! Имеш, сез кем дә мин кем! Без дә төшеп калганнардан түгел!

Ф ә р и д ә. Фантазёр да инде син, Камил! Башыңа әллә нинди уйлар килә. Дөрес, Шакирның байлыгы бар. Нигә, бай кешенең кемне дә булса кунак итәргә хакы юкмыни? Безне чакырган Шакир. Классташларын чакырган. Кунак итәсе килгән. Син дә, мин дә, Нәсим дә чакыралмыйбыз

бит менә. Нигә? Чөнки акчабыз, кайсыдыр ки матур итеп әйтсәк, сәмәнебез җитенкерәми.

Ш а к и р. Рәхмәт, Фәридә. Ярый әле мине аңлаучы син бар.

Н ә с и м. Фәридә ул гел шундый. Тумыштан ук миһербанлы бала булды.

К а м и л *(өстәлдән китап алып)*. Бу ни бу?

Ф ә р и д ә. Китап.

К а м и л. Мин Шакирдан сорыйм.

Ш а к и р. Минем китап. Тышлыгына язылган бит, Шакир Казыйхан, диелгән.

К ә р и м ә. Әллә син дә китап яздыңмы, Шакир? Кайчан яздың? Менә тагын бер сюрприз!

К а м и л. Дөрес. Китап тышлыгында – синең исем. Ә моның эчендә – минем шигырьләр. Безләргә аңлатып бир, каян килеп эләкте сиңа бу шигырьләр?

Ш а к и р. Сатып алдым.

К а м и л. Кемнән?

Ш а к и р. Сезләрдән.

К а м и л. Мин сиңа шигырьләремне сатмадым.

Ш а к и р *(кесәсеннән кәгазь алып, Камилгә сузып)*. Та-ныйсыңмы? Синең расписка. Копиясе. Оригиналы – сейфта.

Ф ә р и д ә *(Камил кулыннан кәгазьне алып)*. Монда... саттым, диеп язылган шул.

К а м и л. Мин сатып алучының Шакир икәнен белмәдем.

Ш а к и р. Сиңа агент җибәрдем. Үземнең ышанычлы кешемне.

Н ә с и м. Камил! Димәк, саттың шигырьләреңне?

К а м и л. Саттым.

Н ә с и м. Димәк, бу иптәшкә синең претензияләрең юк?

К а м и л. Мин шигырьләремне чарасызлыктан саттым. Әнием бик авыр хәлдә иде минем. Дарулар кыйммәт. Акча юк. Ә монда шундый мөмкинлек килеп чыкты. Аннары шуны да уйладым. Йә, әйтегез, кемгә кирәк ул шигырь хәзер?

Ф ә р и д ә. Безгә кирәк.

К ә р и м ә. Мәсәлән, миңа кирәк. Мин шигырь китаплары укырга бик яратам.

К а м и л. Ышанмыйм. Сезнең бу сүзләрегез буш сүзләр! Беркемгә дә кирәкми шигырь! Мокытлар һәм маңкортлар синең белән идарә иткән заманда хәл шулай булырга тиештер, күрәсең.

Ф ә р и д ә. Инде шагыйрь кеше үзе шулай дип торгач...

Н ә с и м. Пессимист син, Камил. Өмет белән яшәргә кирәк!

К а м и л. Нәшриятларда шигъри кульязмаларны алмыйлар. Халык хәзер шигырь укымый, дип кенә җиффәрәләр. Мин шуңа күрә саттым да инде. Югалып әрәм булганчы, кемдер дөньяга чыгарыр дип уйладым. Хет

Алланың кашка тәкәсе исеме белән чыксын, тик шигырьләрем яшәсен дидем. *(Шакирга.)* Ә Алланың кашка тәкәсе син булгансың икән. Рәхмәт!

Ш а к и р. Минем синең алда гаебем юк. Сат, дидем. Син саттың. Мин сатып алдым. Мин – бик бай кеше! Телим икән, хәтта любой министр портфелен сатып алалам! Мин үз көчем белән шундый дәрәҗәгә ирештем!

К а м и л. Мактанма! Күреп, белеп торабыз! Сезгә, теген-нән урлап, моннан талап баеган каракларга, бездәйләрнең язмышын җимерү берни тормый.

Н ә с и м. Нинди язмыш? Нинди карак? Камил дус, ни сөйлисең син? Монда караклар юк! Без – барыбыз да классташлар! Без –дуслар! Сөйләшик шул хакта.

К а м и л. Мин караклар белән дус түгел.

К ә р и м ә. Син Шакирга яла якма, Камил! Авызыңнан чыккан сүзләрне җил алсын. Шакир карак түгел. Ул – саф күңелле кеше. Ул – намуслы кеше. Ярдәмчел кеше. Йөрәгендә шәфкать бар аның. Мин беләм, әле күптән түгел генә Шакир бер балалар йортына ун мең сум акча бирде.

Ф ә р и д ә. Ун мең?! Минем бер айлык хезмәт хакым! Күп бит бу!

К а м и л. Синең өчен күп ул. Череп баеган кешегә төкерек кенә.

К ә р и м ә. Мин сине бөтенләй белмәгәнмен. Бик кара эчле, көнчел кеше икән бит син, классташ!

Ш а к и р. Кәримә дөрес әйтә. Кеше бәхетеннән көнләшмә син, туган!

К а м и л. Мин синең туганың түгел.

Ш а к и р. Алайса... классташ!

К а м и л. Кызганычка каршы...

Ф ә р и д ә. Җәмәгать! Дусларым! Ун мең биргән! Бу бит... Моңа бит... Тагын ун мең өстәсәң, бер компьютер сатып алырга була!

Н ә с и м. Миңа бик тонкий намёк булды инде бу. Аңладым, Фәридә җаным! Алла теләсә, минем хезмәт хакын да кушып, алырбыз сиңа кампьютер. Бер ай ризыксыз ничек тә түзәрбез әле.

Ф ә р и д ә. Фатир өчен түләргә акча каян алырбыз икән?

К ә р и м ә. Нишләп кредитка алмыйсыз? Алай бик җайлы бугай бит.

Н ә с и м. Илдә чыпчык үлми, диләр... Бер җай чыкмыйча калмас. Менә симфониямне Японияга конкурска җибәрсәм... Кем белә, бәлки, җиңүче булырмын...

Ф ә р и д ә. Әйе шул. Урыслар әйтмешли, чем чёрт не шутит.

Ш а к и р. Мин ул симфонияне конкурска җибәрдем инде.

Н ә с и м. Ә?!

Ш а к и р. Ул хәзер минеке.

Н ә с и м. Ничек?

Ф ә р и д ә. Мин ялгыш ишетмәдемме?

К ә р и м ә. Шакир! Аңламадым?! Ничек син җибәрдең?

Ф ә р и д ә. История повторяется, Нәсим! Димәк, син дә симфонияңне саттың?!

Н ә с и м. Мин... мин... ант итәм! Валлаһи газыйм! Сатмадым!

Ф ә р и д ә. Күземә карап әйт! Чынлапмы?

Н ә с и м. Чынлап!

К а м и л. Димәк, бер генә юл кала... Урлау!

Н ә с и м. Мин бит аны бүген генә кулыма тоттым.

К а м и л. Тотсаң ни! Урлауны бүтән юл белән хәл иткәннәр.

Ф ә р и д ә. Бүтән юл белән?! Ничек? Тагын ничек урлап була?

К а м и л. Хуҗаның игътибарсызлыгыннан файдаланып! Фатирына кереп! Яисә эш урынында булып! Шунда сурәткә төшереп аласың. Йә фотоаппарат белән. Йә кесә телефоны белән. Черт-черт! «Ә» дигәнче, симфония кесәдә!

Ф ә р и д ә. Әйе шул. Болай итеп тә була икән.

К а м и л. Сорау туа. Урлаучы кем? *(Шакирга.)* Минем ни әйтергә теләгәнне син беләсең. Синең ни әйтергә җыенганыңны мин беләм! Җә, нишлибез, әкә?

А с и я белән Р ө с т ә м керә.

А с и я. Тагын без әле бу. Гафу итегез. Мин сумочкамны онытып калдырганмын.

Р ө с т ә м. Асия, таптым! Менә сумочкаң!

А с и я. Ни булды сезгә? Ягез әле, барыгыз да елмаегыз!

Ф ә р и д ә. Сеңлем! Чү! Зинһар, бүлдермә!

А с и я. Аңладым. Авызга су каптым.

К ә р и м ә. Мин ышанмыйм моңа! Бу була торган хәл түгел! Шулай бит, Шакир?

Ш а к и р. Ә нишләп булмасын?! Нәсим генә димәгән. Минем дә композитор буласым килә! Бөтен дөньяга билгеле композитор!

А с и я. Әти – композитор. Круто!

Р ө с т ә м. Чынлап әйтәсезме соң?

К ә р и м ә. Башкалар язганны урлапмы, Шакир?!

Ш а к и р. Әйе. Урлап.

К ә р и м ә. Мин ышанмыйм. Син алдыйсың. Син юри әйтәсең, Шакир! Әйт инде, шаярттым, диген.

К а м и л. Саескан, саескан, күкәй эчкән, май эчкән...

Н ә с и м. Кәримә! Нигә шулкадәр өзгәләнәсең?

К ә р и м ә. Шакир... минем ирем!

Ф ә р и д ә. Әстәгъфирулла!

А с и я. Мин – аларның кызы!

Р ө с т ә м. Ә мин – булачак кияүләре.

Н ә с и м. Ничек?! Камил, ишеттеңме?

Камил. Уф, эссе! Һавасы тынчу. Монда кондиционер юк, ахры. Җиллләтәсе иде...

Фәридә. Нишләп эссе булсын? Киресенчә, җиләс.

Кәримә. Ишетмәгәннәр өчен әйтәм. Шакир – минем ирем!

Нәсим. Әйе-е-е. Кичә үлгән булсам, бүген белмидерием!

Шакир. Бу тормышта мин нәрсәгә дә булса ирешкәнмен икән, ызначит, монда Кәриманең дә өлеше бар! Шулай дип аңларга кирәк.

Камил. Шулай дип аңладым да. Минем шигырьләрне сатып алуда да... *(Нәсимгә.)* Синең симфонияне урлауда да... Кәримәнең өлеше зур, димәк. Нигә гаҗәпләнергә?! Бу шулай булырга тиеш тә! Муж и жена – одна сатана! Ә мин җүләр булганмын!..

Асия. Что за чушь несёте? Рөстәм! Син берәр нәрсә аңладыңмы?

Рөстәм. Пытаюсь понять... Пока не получается...

Кәримә. Мин белмәдем! Мин берни дә белмәдем! Шакир, нишләп алай эшләдең? *(Өстәлдән китапны ала.)* Син ничек бу шигырьләрне үзеңнеке итә аласың?! Болар бит Камилнең шигырьләре! Миңа багышлаган шигырьләре! *(Укый.)* «Мин ерактан сине эзләп киләм... Офыкларда очрашырбыз – беләм!..»

Шакир. Сиңа багышланган икән, бик яхшы! Мин бу хакта син әйтмәсәң дә белә идем. Мин акча түләдем! Барысы да законно! Алар хәзер минем шигырьләр!

Кәримә. Нәсимнең симфониясен ник урладың? Ничек кулларың барды?

Шакир. Ялгышасың... Мин урламадым. Миңа китереп бирделәр. Эше барның ашы бар. Китергән кешегә акча түләдем. Шулай ук Нәсимгә дә.

Камил. Сатмадым, имеш.

Фәридә. Күпме түләде?

Нәсим. Сез нәрсә! Ник бәйләнәсез әле? Минем бер-кемнән акча алганым юк!

Шакир. Өеңдә пианиноңда уйнамыйсың мәллә?

Нәсим. Уйныйм.

Шакир. Уйнагач! Клавишлар өстендәге егерме меңне күргәнсеңдер бит?! Конвертта иде!

Нәсим. Бурычым күп иде... Мин ул акчаны квартплатага тоттым!

Фәридә. Менә сиңа күктән төшкән бәхет! Көй язасың. Ходай сиңа шундук акча түли! Син сөенә-сөенә бурычларыңнан котыласың! Иллә дә рәхәт заманнар килде!

Кәримә. Нинди акча бу дип, бер дә уйлап карамадыңмыни соң?

Нәсим. Минем бурычларым турында күпләр белә. Баерак берәр дустым әҗәткә калдыргандыр дип уйладым.

Шакир. Без квиты! Аңлашылдымы инде?! Ә сез мине карак димәкче буласыз.

Ф ә р и д ә. Түләдем, дисең. Заказчик. Син бик куркыныч кеше икәнсең бит, Шакир!

Ш а к и р. Астыртын эш йөртүчеләр куркыныч! Ә мин андый түгел. Минем эчемдәге – тышымда. Алганмын икән, алдым, дим. Түлим икән, тиешлесен түлим. Менә син, Фәридә, борынгы бабаларыбыз турында китап язасың...

Ф ә р и д ә. Ә син каян беләсең? Минекен дә урладың мәллә? Кайчан? И Ходаем!

Ш а к и р. Беләм. Урламадым. Син аны миңа үзең бирәчәксең.

Ф ә р и д ә. Андый хәл беркайчан да булмаячак!

Ш а к и р. Мин әйтсәм, хәтта менә монда китереп бирәчәксең! Сезнең дөньяны өйрәндем мин. Сездә дә хәлләр не ахти. Бер-берегез өстеннән донослар язасыз.

Ф ә р и д ә. Минем язганым юк!

Ш а к и р. Сыңар җөмлә дә яза алмаганнар доктор наук булып йөри! Мин үзем хәтта хәреф тә таный белмәгән шундый бер академикны беләм. Алар өчен синдәй коллар тир түгә.

Ф ә р и д ә. Мин беркайчан да кол булмаячакмын. Өмет-ләнмә.

Ш а к и р. Мин беләм. Сезнең арада да караклар бар. Бер-берегезнең хезмәтен чәлдерергә генә торасыз.

Ф ә р и д ә. Мин андый түгел.

Ш а к и р. Күреп торам... Мин әйткәннәр белән килешәсең... Андый хәлләрнең булганлыгын таныйсың, димәк.

Н ә с и м. Карале! Безгә хөкем чыгарган буласың! Син кем соң әле ул кадәр?

Ш а к и р. Мин – Казыйхан!

Ф ә р и д ә. Миңа димәгәе! Хет Батый хан бул! Мин сиңа гомер буе газапланып эшләгән хезмәтемне сатмаячакмын!

Ш а к и р. Карап карарбыз. Моңарчы барысы да мин дигәнчә булды.

К ә р и м ә. Шакир! Тирәнгә үк кереп батканчы тукта! Зинһар өчен, дим!

Ш а к и р. Ә син кысылма! Яп авызыңны! Заткнись!

Кәримә хәлсезләнеп өстәлгә таяна. Аны Рөстәм култыклап ала,
якындагы кәнәфигә утырта.

А с и я. Әти! Тавышыңны күтәрмә әнигә! Беләсең ич, әнинең давлениесе югары! Аңа дулкынланырга һич ярамый!

Р ө с т ә м. Су эчеп куегыз әле, хәл кереп китәр.

Ш а к и р. Кысылмасын! Өйрәтмәсен! Мин нишләргә кирәклеген үзем беләм!

К ә р и м ә. Зинһар, дим!

Ш а к и р *(Асиягә)*. Әйт анаңа, дәшмичә торсын!

А с и я. Дәшми, дәшми... Әни!

Ш а к и р. Сез үз күләгәгездән үзегез куркып яшәүчеләр! Сез мескеннәр! Сез булдыксызлар! Милләт, халык димим... Хәтта үзегезне яклап көрәшерлек тә хәлдә түгел сез! Сезгә үз тынычлыгыгыз кадерле!

К а м и л. Мин, мәйданнарга чыгып: «Газиз халкым! Ник дәшмисең? Бетерәләр бит сине!» – дип лаф ормыйм. Дөрес! Минем натурам андый түгел! Мин трибун түгел! Әмма мин үземчә көрәшәм! Булдыра алганча! Минем дәгъваларым, таләпләрем шигырьләремдә!

Ш а к и р. Ә ул шигырьләргә хәзер мин хуҗа. Димәк, синең өчен мин көрәшәм булып чыга.

К а м и л. Мин әле язачакмын. Тагы да шәпләрен.

Ш а к и р. Яз! Мин тагын сатып алачакмын.

К а м и л. Шиш! Син әле генә шапырындың: мин астыртын кеше түгел, диден. Син астыртыннарның да астыртыны! Син кабахәт кеше!

Ш а к и р. Но-но! Чамалап әйт сүзеңне!

К а м и л. Син минем кадерле кешемне – сөйгән ярымны тартып алдың! Син минем иҗатымны сатып алдың! Инде син минем үземне сатып алмакчысың! Булмас!

Ш а к и р. Әйе, мин теләгәнчә булды! Сөйгәнеңне тартып алдым! Алдап-йолдап булса да, барыбер Кәримәне үземнеке иттем!

К ә р и м ә. Алдап-йолдап?! Шакир! Бу ни дигән сүз?

Ш а к и р. Ничек аңлыйсың килсә, шулай аңла. Ул гына түгел, мин дә яраттым сине.

К ә р и м ә. Яратмагансың! Син мине алдагансың... Хәзер генә төшендем. Син барысын да оештыргансың икән. Барысын да уйлап эшләгәнсең. Камилгә минем исемнән хат тапшыртуны да син оештыргансың. Тәмам йөдәтеп бетергәч, мин ул записканы сиңа язып биргән идем. Ә син аны үз файдаңа боргансың икән.

Ш а к и р. Әйе! Әйе! Мин үз бәхетем өчен көрәштем. Мин җиңдем.

К а м и л. Бирде дөнья кирәкне...

Ф ә р и д ә. Еламаска өйрәттең... Елаттың... Камил!

К ә р и м ә. Җиңдем дияргә ашыкма, Шакир!

Ш а к и р. Мин синең белән кызым өчен дип тырыштым! Мин сезнең өчен дип яшәдем! Мин сезне бәхетле иттем!

К ә р и м ә. Урланган бәхет. Кирәкми миңа мондый бәхет!

Н ә с и м *(көйләп)*. Гел урлау да урлау булган саесканның бар эше...

Ш а к и р. Әй син, Аксак Тимер! Телеңә хуҗа була бел! Икенче аягыңны да имгәтмәгәем!

Н ә с и м. Янама! Мин синнән курыкмыйм!

К ә р и м ә. Әле соң түгел. Акылыңа кил, Шакир!

Ш а к и р. Миңа совет бирүче кирәкми. Мин теләсә кемнең киңәшенә мохтаҗ түгел!

К ә р и м ә. Мин теләсә кем түгел. Мин – синең хатының!

Ш а к и р. Женщина! Молчи!

А с и я. Җикеренмә, әти!

Р ө с т ә м. Тынычланыгыз инде. Булды. Җитте.

К ә р и м ә. Шакир! Үтенеп сорыйм! Камилнең шигырьләрен кире үзенә кайтар! Гафу үтен!

Ш а к и р. Үткән эшкә салават, диләрме әле?! Мин гафу үтенерлек эш эшләмәдем!

К а м и л. Кирәкми, Кәримә! Мин әле тагы да әйбәт шигырьләр язачакмын!

К ә р и м ә. Япониягә хәбәр җибәр, Шакир! Симфониянең авторы Нәсим икәнлекне әйт!

Н ә с и м. Вак җанлы бик күп кешеләрне күргәнем булды. Синең кебекне моңарчы очратканым юк иде!

Ш а к и р. Яз! Яңа көйләр иҗат ит! Борчылма! Квартплатаңны вакытында түләп барырсың! *(Фәридәгә.)* Син дә китабыңны тиз тәмамларга тырыш! Мин көтәм!

Ф ә р и д ә. Мыскыл итмә ул кадәр, Шакир!

Ш а к и р. Мин – шагыйрь! Мин – композитор! Тиздән тарих фәннәре докторы, академик булачакмын! Тыңлагыз!

Кесәсеннән пульт алып, аны каядыр юнәлтеп ала.
Бүлмәгә көй агыла.

Т а в ы ш. Шакир Казыйхан шигыре һәм көе. Җырлый Шакир Казыйхан.

Ш а к и р *(көйне туктатып)*. Менә тагын бер сюрприз! Йә, ничек?

Ф ә р и д ә. Шашкансың бит син, Шакир!

Ш а к и р. Үзе шагыйрь! Үзе композитор! Үзе җырчы! Үзе продюсер! Үзе академик!.. Татар дөньясында тагын шундый кем бар?

К а м и л. Сине җүләрләр йорты көтә! Чамалыйсыңмы шуны?

Ф ә р и д ә. Менә сиңа мә! Кояш сүзендә биш хата ясый идең бит син!

Ш а к и р. Сүздә – ерунда! Тормышта ясамаска кирәк хатаны! Кызым, Асия, кил әле монда!

А с и я. Нигә? Килдем.

Ш а к и р. Син – минем горурлыгым, кызым! Син – минем яшәвемнең максаты!

К ә р и м ә. Шакир! Соңгы тапкыр сорыйм: Япониягә хәбәр җибәрәсеңме? Камилнең шигырьләрен үзенә кире кайтарасыңмы?

Ш а к и р. Юк, җибәрмим дә, кайтармыйм да!

К ә р и м ә. Алайса... Мин синнән китәм!

Ш а к и р. Китә бир! Дүрт ягың кыйбла!

Ф ә р и д ә. Бу сүзләрең өчен үкенерсең, Шакир! Әмма соң булыр!

Ш а к и р *(өстәлдәге төймәгә басып)*. Анжела! Кер әле монда!

А н ж е л а керә.

А н ж е л а *(Шакирга)*. Тыңлыйм, әфәндем! Ләкин миңа чын исемем белән дәшүегезне үтенәм.

Ш а к и р. Мин хатынны аердым, Анжела!

А с и я. Әти, син үз акылыңдамы? Нишлисең син?

Р ө с т ә м. Болай гына әйтәдер ул, Асия.

Ш а к и р. Үз акылымда. Анжела, мин әйткәнне ишеттеңме?

А н ж е л а. Мин – Айзадә. Ишеттем.

Н ә с и м. Айзадә?! Матур исем. Үзебезчә.

А н ж е л а. Мин бөтен сөйләшүегезне дә тыңлап тордым. *(Көзгегә ишарәли.)* Көзге артыннан барысы да яхшы күренә икән. Әйбәт уйлап тапкансыз, әфәндем.

К а м и л. Нинди әфәнде булсын ул.

Ш а к и р. Мин сиңа өйләнәм, Анже... Айзадә.

А н ж е л а. Харап итмәгез мине, Шакир абый! Зинһар өчен, бирегез паспортымны! Минем яратып йөргән егетем бар.

А с и я. Әти, нинди паспорт турында сөйли ул?

Ш а к и р. Ризалаш! Барыбер мин дигәнчә булачак!

К ә р и м ә. Син нишләп бу баланың паспортын алдың? Бир! Хәзер үк!

А н ж е л а. Минем гарип энем бар. Аяклары йөрми. Германиядә дәвалап була икән дип ишеттек. Барыр идек – акчабыз юк!

Ф ә р и д ә. Һаман да шул акча-а, акча-а!

А н ж е л а. Шакир абый, булышам, диде дә... Паспортымны алды...

К а м и л. Саесканнан тагын ни көтәсең!

А н ж е л а. Ике ай бар инде... Ул ни кушса, шуны үтәп йөрим...

Ф ә р и д ә. И бала, бала!.. Хараплар иткән икән сине!

К ә р и м ә *(Шакирга)*. Җаның юк икән! Бир хәзер үк аңа паспортын! Юкса...

Ш а к и р. Нәрсә «юкса»? Ни әйтмәкче буласың?

К ә р и м ә. Кызым! Асия! Кил әле минем яныма.

Ш а к и р. Минем янда гына тор. Кызым, бердәнберем!

К ә р и м ә. Асия ул синең кызың түгел! Әйттерде түгел! Әйттердең тәки!

Ш а к и р. Нәрсә-ә-ә?! Нәрсә дидең?

К ә р и м ә. Асия синең кызың түгел!

А с и я. Әни! Син ни сөйлисең? Рөстәм! Нәрсә соң бу?

Р ө с т ә м. Тынычлан, матурым! Ачуы килгәндә, кеше ни әйтмәс!

К ә р и м ә. Мин дөресен әйттем! Кызым, балам, аңла, зинһар!

Ш а к и р. Мин моңа ышанмыйм!

Ф ә р и д ә. Ышанырлык та түгел шул.

Н ә с и м. Кәримә, болай ук ярамый. Артыкка китте. Уеннан уймак чыгаруың бар.

К ә р и м ә. Нигә этисе кем дип сорамыйсыз?

Ш а к и р. Җитте!

К ә р и м ә. Тыйма мине! Соң инде! Асиямнең этисе – Камил!

Ф ә р и д ә. Камил?!

К ә р и м ә. Кызым, ничә ел йөрәгемдә йөрткән серемне әйттем. Камил – синең этиең!

Ш а к и р. Алдыйсың!

К ә р и м ә. Камил... Гаебем булса, кичер! Асия – синең кызың! Безнең кызыбыз!

А с и я. Әни! Рөстәм! Хәлем китте...

К а м и л. Кызым!..

Ш а к и р *(шашар чиккә җитеп)*. Мин моңа ышанмыйм! Ышанмыйм! Ышанмыйм!

П ә р д ә.

*2010*

# ИМАН

*Ике пәрдәле драма*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

А р с л а н.
Н у р з и ф а.
Д а м и р.
А з а л и я.
Н а и л.
З ө ф ә р.
Ә д и б ә.
А к б а б а й.

## Б Е Р Е Н Ч Е П Ә Р Д Ә

### Б Е Р Е Н Ч Е К Ү Р Е Н Е Ш

Ишегалды. Сул якта өйнең болдырлы өлеше күренеп тора. Арткы планда баганалары кыйшайган капка, такталары берән-сәрән генә калган койма шәйләнә. Койма тирәсендә берничә яшел куак һәм шактый зур булып, котырып үскән кычыткан, алабута, тигәнәк ише үләннәр күзгә ташлана.

Җиңел машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Башта капкадан үт-мәкче булып, аннары койма аша узарга азапланып бераз әвәрә килгәч, читләтеп, бүтән юл табып, ишегалдына Д а м и р белән Н а и л, алардан калышмаска тырышып, А з а л и я керә. Керә-керешли үк өчесе дә киемнәренә ябышкан тигәнәкләрне йолкыйлар.

Д а м и р *(юлдашларына арты белән борылып)*. Беттеме?

А з а л и я. Сезнеке беткән, Дамир Җәмилевич... Ә минеке?

Д а м и р. Пачти. Наил!

Н а и л. Әү, иптәш Бәдрикәев!

Д а м и р. Азалиянең итәгендә тигәнәк калган.

А з а л и я. Кай төштә? Мин күрмим.

Н а и л *(тигәнәкне алып, Азалиягә сузып)*. Мә, истәлек итеп сакларсың.

А з а л и я. Үзеңнең кесәңә салып тор инде. Куяр җирем юк.

Д а м и р. Кыланмагыз әле!

Н а и л. Безнең авылның исеме җисеменә туры килеп торуын әйт... Тигә-нәк-ле! Шундый матур исем кушканнары өчен рәхмәт бабайларга!

Д а м и р *(йортка карап)*. Сыңар өй дә салып кералмаган башың белән телеңә салынып торма. Бар, Бастырык Хәмитне тап! «КамАЗ»ын кабызсын. Күркә Гариф белән Негр Карахмәтне дә үзеңнән калдырма. Шәүкине дә эләктер! Хәзер үк сүтеп ташлыйбыз моны!

А з а л и я. Шәүкәтне иртә белән күрдем. Капка төп-ләрендә җилфердәп тора иде.

Д а м и р. Монда килеп җиткәнче айный ул... Соңыннан мәгәрич булыр, дип әйт! Нишләп торасың? Бар! Тиз бул!

Н а и л. Синең... сезнең машинагыз белән барып килимме, иптәш Бәдрикәев?

Д а м и р. Атаңныкы булмагач, Бәдрикәевнекенә утыра-сың инде. Карале, хәзер үк китмәсәң, тәпиләргә туры киләчәк. Ярты сәгать вакыт сиңа!

А з а л и я. Берәр тәмлүшкә эләктер әле, Наил абый җаным! Иртән коры чәй генә эчкән идем...

Н а и л. Чәйнең корысы да буламыни аның? Белмәгән идем...

Д а м и р. Телеңә салынма! Оныта язганмын... Габдерәүфне күр! Кызынып ятмасын анда. Бульдозерын рәткә китерсен. Җирне тигезләгәндә ул әбизәтелне кирәк булачак. Бар, тиз бул!

Н а и л. Киттем, иптәш Бәдрикәев! *(Каршында пәйда булган Арсланга бәрелә.)* Бәттәч! Багана дип торам... Кеше икән! Привет! *(Китә.)*

А з а л и я. Наил абый! Эчәсем дә килә икән. Тәмле су алырга онытма. *(Арсланны күрә.)* Здрасте!

А р с л а н. Исәнмесез!

Д а м и р. Бу кадәр ашамсак булырсың икән! Районнан ресторан чакыртыйм мәллә? Әнә теге кычытканнар арасында ашап кына ятарсың...

А з а л и я. Көлмәгез инде, Дамир Җәмилевич. Мин бит диета тотам. Диета тотканда аз-азлап еш ашарга кушалар...

Д а м и р. Кемнәр куша? Поварлармы?

А з а л и я. Кемнәр дип... Гәзиттән укыганымны әйтәм... Шулай ашап бер хатын илле килога ябыккан!

Д а м и р. Азалия!

А з а л и я. Бетте, бетте сүзем, Дамир Җәмилевич...

А р с л а н. Кыһым-кыһым... Исәнмесез!

Д а м и р *(Арсланны әле генә күреп)*. Исән әле, абзый кеше! Безнең эш бик тыгыз. Зинһар, пажалыста, мишәйт итмә! Бар, бар, юлыңда бул! Яз, Азалия!

А з а л и я. Язам, Дамир Җәмилевич. Нәрсә дип языйм?

Д а м и р. Безнең татар яңа йорт салырга тотынганчы, башта бәдрәф төзеп куя. Менә бу төштә, юк, бу өй урынында бәдрәф эшләтәм.

Кирпечтән. Складта аңа гына җитәрлек кирпеч бар. Яз! Пункт беренче, диген, бәдрәфкә кирпечләр, диген... Яздыңмы?

А з а л и я. Яздым, Дамир Җәмилевич!

А р с л а н. Нинди бәдрәф турында сүз бара, иптәш?

Д а м и р. Абзый, син әле китмәдеңмени? Саңгырау түгелдерсең бит?! Бар-бар, юлыңда бул! *(Ихата буйлап сөй-ләнеп йөри.)* Монда ике метрлы койма булса... Бу төшкә пока чатыр корсак... Моннан Сабантуй галәмәт яхшы күренә... Димәк, бу якка алынмалы җиңел койма кирәк булачак. Бу тирәгә кызыл карлыган куаклары, бу җиргә чәчәкләр утыртсак... Матур итеп беседка да эшләтсәм... Өлгерәбез әле! Яз, Азалия! *(Сәхнә алдына килеп, алга карап тора.)* Искиткеч матур да инде безнең авыл табигате!

Арслан әле Дамирга, әле Азалиягә карап башын чайкап тора да болдыр янына килә. Ишекне ачып, өй эченә кереп китә. Аның өйгә кереп киткәнен Азалия күреп кала. Әмма бер сүз дә дәшми.

А з а л и я. Икенче пункт! Тагын нәрсә дип языйм, Дамир Җәмилевич?

Д а м и р. Такталар, диген... Баганалар, җепсәләр, рәшәт-кәләр, диген... Карлыганнарны, чәчәкләрне язарга онытма! Киттеме теге абзый?

А з а л и я. Китте... өйгә кереп.

Д а м и р. Яратмыйм эшсез кешенең карап торганын... Ә?! Нәрсә дидең?

А з а л и я. Өйгә кереп китте, дим.

Д а м и р. Ничек... өйгә кереп китте? Бу бит хуҗасыз өй! Кем әле ул? Кай арада хуҗа булып алган? *(Йорт янына таба килә, аяк астыннан таяк алып, шуның белән ишеккә суга.)* Әй! Кем әле син? Чык монда!

Кинәт тәрәзә ачыла, Арсланның башы күренә.

Нишлисең анда?

А р с л а н. Үз өем, ни телим – шуны эшлим, туган.

Д а м и р. Нишләп синең өй булсын бу! Моның хуҗалары күптән үлде. Чык!

А р с л а н. Гафу итегез, капкалап утыра идем... *(Югала.)*

Д а м и р. Нәрсә ди? Син ишеттеңме, Азалия? Тукмап ташлыйм бит мин бу бәндәне.

А з а л и я. Кызма әле, Дамир Җәмилевич. Капкалыйм, ди бит. Ашасын инде... *(Үзалдына.)* Кеше котыртып... Садист!

Д а м и р. Капкалатам мин аңа хәзер!

Ишектән кермәкче була, кинәт А р с л а н килеп чыга.

Чәчең агарып беткән, акыл кермәгән... Кем син?

А р с л а н. Бая гына әйттем түгелме соң, бу йорт – минем өем! Кичә кайттым...

Д а м и р *(ярсый төшеп)*. Кичә кайттым, имеш! Абзый! Чыгырдан чыгарма мине! Кем син? Исемең, фамилияң ничек, дим мин сиңа?

А р с л а н. Арслан минем исемем. Тәхәветдинов булам.

Д а м и р. Тә-ә-әк... Икенче сорау: бу йортка нинди катышың бар?

А р с л а н. Кайчандыр мин бу өйдә яшәгән идем.

Д а м и р. Тә-ә-әк... Азалия, Васил абыйның фамилиясе ничек иде әле?

А з а л и я. Тә...тә... Абзый әйтте бит... Тәхәветдинов, диде.

Д а м и р. Тәхәветдинов, ызначит! Нәрсә, син Васил абыйның малае, што ли?

А р с л а н. Әйе.

Д а м и р. Васил абыйның малае барлыгын ишетеп белә идем белүен. Тә-ә-әк... Васил абый былтыр җәй көне, нәкъ менә бер ел элек үлде. Рәйсә апа аннан бераз алдарак китте... Абзый кеше, сиңа тагын сорау: ник аларны соңгы юлга озатышырга кайтмадың? Кайда идең син, кайларда йөрдең шул гомер? Мин монда кырык өч ел яшим, әмма сине моңарчы бер дә күргәнем булмады.

А р с л а н. Кайталмадым шул... Шулай килеп чыкты.

Д а м и р. Ым-да-а... Иртәгә кайтасың калган! Бүген эш беткән була иде. Проблема тудырдың син миңа, абзый. Шулай да мәсьәләне уңай хәл итәргә вакыт бар әле...

А з а л и я. Минем ашыйсым килә, абзыйлар...

Д а м и р. Бүлдермәле! Бар әнә, кычыткан аша! Тә-ә-әк... Проблеманы болай хәл итәбез, Ардуан абзый...

А р с л а н. Арслан мин.

Д а м и р. Әйе, шулай бит әле... Болай итәбез, абзый кеше... Хәзер әйберләреңне алабыз да безгә кайтабыз. Ял итәрсең рәхәтләнеп, мунча керерсең... Мунчадан соң бераз мактанышып алырбыз! Кароче, бик шәп итеп кунак итәм мин сине!

А р с л а н. Ни әйтергә теләгәнеңне аңлап җиткермәдем, кем...

А з а л и я. Дамир Җәмилевич ул...

А р с л а н. Нәрсәнедер әйтеп бетермисең. В чём проблема?

Д а м и р. Проблема – менә бу өй! Моны бүген сүтәргә кирәк!

А з а л и я. Ачтан үтерәсез инде тәки! *(Болдыр баскычына барып утыра, ишек тарафына карап иснәнеп ала.)*

А р с л а н. Миннән рөхсәт юк!

Д а м и р. Карап-карап торам да мин сиңа, абзый кеше, тагын бер карап куям. Укымышлы кешегә охшагансың үзең. Әмма бер нәрсәне аңлап җиткермисең... Бу өйгә хәзер син түгел, без хуҗа! Мирас дип, дәгъва белдерә алмыйсың, чөнки моны раслый торган документың юк. Бу өй хәзер колхоз милке санала.

А р с л а н. Колхоз бетте бит инде.

Д а м и р. Не важны. Өй – безнеке. Бетте-китте. Әмма мин проблеманы тыныч хәл итү ягында. Аңлашылды: син Сабантуй күрергә

кайткансың. Бәйрәмнән соң китәчәксең. Шулай бит?! Ул арада өйне саталмыйсың – это однозначно!

А р с л а н. Мин аны сатарга җыенмыйм да...

Машина тавышы ишетелә. Пакет тотып, Н а и л керә.

Н а и л. Иптәш Бәдрикәев, мин килеп җиттем! Тегеләргә әйттем...

Д а м и р. Бүлдерми тор!

А з а л и я *(пакетны тартып диярлек алып)*. Ой! Шундый тәмле исләр килә! Рәхмәт инде, Наил абый җаным! *(Наилнең битеннән үбеп ала.)*

Н а и л. Тагын берәр тәмле әйбер алып килим мәллә?

А з а л и я. Снабженец эше ошап китте мәллә, Наил абый җаным?

Д а м и р. Мишәйт итмәгез әле! Барыгыз, сыптырыгыз моннан!

А з а л и я. Без киттек, киттек! *(Ашый-ашый чыгып китә, Наил дә аңа иярә.)*

Д а м и р. Хәтереңә салып куй, абзый кеше, монда, авылда, бар мәсьәләне дә бер кеше хәл итә...

А р с л а н. Ул кеше син түгелдер бит?

Д а м и р. Мин!

А р с л а н. Нәкъ менә безнең йорт урыны ник шулкадәр кирәк булды соң әле? Башка җир беткәнмени?

Д а м и р. Бер атнадан Сабантуй! Кунак булып зур түрәләр киләчәк! Бу калтырча йорт бөтен авылның ямен җибәреп тора...

А р с л а н. Тел төбеңне аңлый башладым... Моннан бөтен тирә-юнь уч төбендә кебек күренә. Сабантуй карарга килгән кунаклар өчен менә дигән урын! Ял итеп тә, сыйланып та утырырга була...

Д а м и р. Дөрес сукалыйсың, абзый кеше! Бар нәрсәне дә акча хәл иткән заманда яшибез... Нәчәлстволың күңелен күрмәсәң, авылны дәлше яшәтеп булмый. Әйтү шушы: давай, әйберләреңне җыйнаштыр – өйне бушат! Синең белән юкны бушка аударып торырга минем вакытым юк! Шылдымы?

А р с л а н. Аңлашылды. Ләкин фикерем үзгәрмәде: мин өйне сүттермим!

Дамирның кесә телефоны шылтырый.

Д а м и р. Алло! Әйе! Тыңлыйм сезне, Әхмәт Галиеч! Хәзер үк килеп җитәм! *(Телефонын кесәсенә тыгып куя.)* Вобшымты чит кешенең фикере мине кызыксындырмый. Абзый кеше, сиңа бер акыллы киңәш: кунак булсаң, тыйнак бул! Теләгемә ирешмичә туктый торган кеше түгел мин. Белеп тор! *(Чыгып китә.)*

А р с л а н. Адәм баласына кайда да тынгы юк... Аңламассың бу тормышны... Нишләп үзең теләгәнчә генә яшәп булмый икән? Ничә ел читтә чиләндем... Дөнья кудым, имеш! Ятлар кубызына биеп гомер үтте...

Инде туган нигеземә кайтып, җаныма тынычлык тапмаммы дисәм... Йа Хода! Монда да ыгы-зыгылы тормыш көтеп торган икән...

Арслан бертын басып тора. Аннан, җитди бер карарга килгәндәй, капкага таба бара, багананы турайтмакчы була. Кинәт күк күкрәгән тавыш ишетелә. Шул мизгелдә илаһи бер көй яңгырый. Сәхнәгә караңгылык иңеп ала.

Т а в ы ш. Җан тынычлыгын җуйганнарның башларына уй төшә...

Арслан сискәнеп куя. Тавыш иясен эзләп, як-ягына карана. Кинәт кабынган ут көлтәсе яктысында ап-актан киенгән ак сакаллы к а р т пәйда була.

А р с л а н. Ак бабай?! Синме бу?

А к б а б а й. Әйе, олан.

А р с л а н. Мин кайттым, Ак бабай. Кайтып җиттем мин, ниһаять!

А к б а б а й. Юк әле, олан... Син кайтып җитмәдең!

А р с л а н. Бер көнгә соңарсам, нигезсез каласы идем. Алдан кисәтүең өчен рәхмәт сиңа, Ак бабай!

А к б а б а й. Вакыт ат түгел, куалама! Әүвәл уйлан әле син, балакай, уйлан... Уйлану – синең өчен хәзер юаныч та, таяныч та булыр!

Карт югала, сәхнә яктыра.

А р с л а н. Тагын юкка чыкты! Кайтып җитмәдең әле, ди... Менә бит мин монда, нигеземдә басып торам!

Көлешкән тавышлар ишетелә. Бераздан, куышып, З ө ф ә р белән Ә д и б ә керә. Аларның сөйләшүе сәхнәнең алгы өлешендә бара. Арслан, капка баганасына сөялгән хәлдә, аларны күзәтә.

З ө ф ә р *(Әдибәне кочагына алып)*. Тоталмыйсың, тоталмыйсың, имеш! Куып тоттым бит менә!

Ә д и б ә. Һи, мактанчык! Туфлием үкчәмне кырмаган булса, син мине мәңге тоталмый идең.

З ө ф ә р. Нәрсә, әбиләр кәлүше хәзер туфли дип аталамыни?

Ә д и б ә. Әнекәчкәем! Кәлүш кигәнмен икән. Әни су буеннан казларны карап кайт әле дигәч, белештермичә эләктергәнмен инде. Сукыр тавык кебек.

З ө ф ә р. Нәрсә, Әдибә, тавыклар да әбиләр кәлүше киямени хәзер?

Ә д и б ә. Әй... Һәрбер сүзгә бәйләнмәсәнә!

З ө ф ә р. Бетте-бетте! Тантаналы вәгъдә бирәм. Әдибә, бүтән бер сүзеңә дә бәйләнмим! Ипекәем менә! Карале, тавык дигәннән...

Ә д и б ә. Нәрсә?! Син бүтән сүз белмисең мәллә?

З ө ф ә р. Беләм. Бүлдермә Зөфәр абыеңны. Чүтеки мин синнән ике айга олырак...

Ә д и б ә. Аның каравы буйга син миннән ярты санти-метрга бәләкәй!

З ө ф ә р. Тыңлыйсың килмәсә сөйләмим.

Ә д и б ә. Тыңлыйм сезне, хөрмәтле вә гыйззәтле, кадерле вә мөхтәрәм Зөфәр абый... Сездәй затлы кешенең татлы итеп сөйләгәнен тыңларга үлепләр яратам мин!

З ө ф ә р. Кара аны, Әдибә, бүлдереп, кызыгын бетермә, яме! Бая... сине куганда... кызык анекдот искә төште. Бер тавыкны бер әтәч куа икән...

Н у р з и ф а, үтеп барышлый, койма янында туктала, яшьләрнең сөйләшүен бирелеп тыңлаган Арсланга карап ала. Егет белән кыз да, Арслан да Нурзифаның барлыгын сизмиләр.

Ә д и б ә. Әтәче – син, тавыгы минме инде?

З ө ф ә р. Карале, кызый, бүлдермә, дидем бит инде!

Ә д и б ә. Яптым авызымны!

З ө ф ә р. Тавык — алдан, әтәч арттан чаба икән...

Ә д и б ә. Тавык арттан чапмас инде!

З ө ф ә р. Сөйләмим алайса!

Ә д и б ә. Дәвам ит! Әтәч арттан чаба...

З ө ф ә р. Тавык чаба икән, үзе, артына карап, «Бик кызу чапмыйм микән?» дип уйлый икән... Ха-ха-ха!

Ә д и б ә. Үзең генә көлеп бетермә, миңа да калдыр...

З ө ф ә р. Көлү хисе бөтен кешегә дә тигез бирелмәгән шул...

Ә д и б ә. Көлке көлә килер, артыңнан куа килер, дигәннәр борынгылар. Кеше көлдерәм дип, үзең көлкегә кала күрмә!

З ө ф ә р. Йөргән кызың артык җитди булмасын икән ул!
Җитдиләр янына барсаң,
Шаяннар җитми кебек,
Шаяннар янына барсаң,
Җитдиләр җитми кебек,
Яшәүнең кайсыдыр ягы
Гел сине читли кебек.

Ә д и б ә. О-о-о! Син шигырь белән сөйли башладың... Үзеңнекеме?

З ө ф ә р. Түгел. Рөстәм Мингалим дигән шагыйрьнеке! Минекен беләсең бит инде – «Мокамай»!
Дыр-дыр-дырабан,
Мокамай йомырка урлаган...
Әйшә тәтәй тоткан,
Каравылын кычкырткан!

Ә д и б ә. «Шүрәле» дә синеке түгелме тагы?

З ө ф ә р. Әдибә, көлмә, туктап тор! Илһам килде!
Сары, сары, сап-сары
Сары чәчәк саплары.
Әдибәгә сүз әйтмәгез,
Иләс-миләс чаклары...

Шәпме?

Ә д и б ә. Супер... пүчтәк! Кызык, киләчәктә син зу-у-ур шагыйрь булсаң, мин кем булырмын микән?

З ө ф ә р. Зу-у-ур шагыйрьнең менә мондый зу-у-ур корсаклы хатыны булырсың!

Ә д и б ә. Аһ, әле син шулаймы? *(Куышып чыгып китәләр.)*

А р с л а н *(үзалдына)*. Да-а-а... Хәзерге яшьләрнең сөй-ләшүе үзе бер тамаша... Артистлар!

Н у р з и ф а. Заманасына карап, яшьләре дә шундый була инде аның...

А р с л а н *(Нурзифаны күреп ала, танымый)*. Исәнме-сез!

Н у р з и ф а. Кыздыра. Давыл булыр, ахры...

А р с л а н. Нурзифа?!

Н у р з и ф а. Еллар үзенекен итә барыбер... Баганалар да картая...

А р с л а н. Нурзифа?! Син бит бу?

Н у р з и ф а. Микиуллам яр буена ияләште... Барып алмасаң, бөтенләй кайтырга исәбе юк. Үги ана яфраклары тәмлерәктер инде, күрәсең...

А р с л а н. Нурзифа! Мин бу – Арслан! Танымыйсың мәллә?

Н у р з и ф а. Кәҗә абзарда гына асрап яткыра торган мал түгел шул... *(Карашын читкә, еракка төбәп кычкыра.)* Мики! Микиулла! Зимагур булсаң да булырсың икән...

Нурзифа китә, якында гына җырлаганы ишетелә.

Зимагурның чалбары,
буй-буй аның аллары;
Кайда йөрсә, шунда кала
зимагурның маллары...

А р с л а н *(Нурзифа киткән тарафка карап)*. Нурзифа-а, мин идем бит бу... Арслан!

Ут сүнә. Музыка. Кабат кабынган ут яктысы сәхнәнең алгы өлешен генә яктырта. Узган гасырның алтмышынчы елларында популяр булган вальс көе яңгырый. Шул еллардагы яшьләр сыман киенгән Е г е т (яшь Арслан) белән К ы з (яшь Нурзифа) сәхнәгә биеп чыга. Егет белән Кызны Зөфәр белән Әдибә рольләрен башкарган артистлар да уйный ала. Бу күренешне Арслан хәтеренә төшерә дип аңларга кирәк. Бераздан көй өзелә, Егет белән Кыз биюдән туктый.

Е г е т *(кызны кочагына алып)*. Мин бәхетле. Мин шундый бәхетле, Нурзифа!

К ы з. Син китәсең... Мин калам... Безгә тагын шулай биергә насыйп булыр микән, Арслан?

Е г е т. Безнең тормыш әле башлана гына... Барысы да алда, Нурзифа!

К ы з. Миңа нишләптер син укырга китәрсең дә югалырсың кебек тоела...

Е г е т. Курыкма, Нурзифа, югалмам! Мин югала торганнардан түгел. Мин сиңа вәгъдә бирәм: без барыбер бергә булачакбыз!

К ы з. Хатлар язарсыңмы соң?

Е г е т. Синең бер хатыңа мин өч җавап язачакмын, Нурзифа.

К ы з. Чынлап язачаксыңмы?

Е г е т. Честное комсомольское слово! Вәгъдә – иман!

К ы з. Зур сүзләр әйтәсең, Арслан... Кара аны, сүзеңдә тормасаң, мәңге кичермәячәкмен!

Е г е т. Егет сүзе бер булыр! Әйттем бит инде, вәгъдә – иман!

К ы з. Мин сине көтәрмен, Арслан... Тиз кайт!

Е г е т. Җырла әле, Нурзифа. Мин синең җырлавыңны яратам!

К ы з. Нинди җыр җырлыйм соң, Арслан?

Е г е т. Бүген чыгарылыш кичәсендә җырладың бит әле... Шуны!

К ы з. Тыңла алайса, җаным... *(Җырлый.)*

Куш каенда өздерепләр
Әй сайрады кошкаем...
Бергә чакның кадерләрен
Белмәдек шул, дускаем...

Син кайларда микән хәзер,
Җаныкаем-кошкаем?
Юатмакчы булып мине,
Өзгәләнә куш каен.

Өздерепләр сайравыңны
Сагынамын, кошкаем...
Яннарыма кайтчы очып,
Бәхет кошым, дускаем...

Ут сүнә.

**И К Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш**

Клуб. «Көн дә бәйрәм, көн дә туй, бүген бездә Сабантуй!», «Сабантуй – бәйрәмнәрнең бәйрәме», «Милли Сабантуйга рәхим итегез!» дигән лозунг-язулар күзгә ташлана. Агач өстәл белән ике урындык. Бер урындыкта кулындагы кәгазен битенә җилпеп, авыз эченнән көйләп, А з а л и я утыра. Н а и л, тезләнеп, җирдән нидер эзли.

А з а л и я. Карап-карап торам да тагын бер карап куям... Бу кыяфәтең белән син, Наил абый җаным, беләсеңме нәрсәне хәтерләтәсең? Күтәрәмгә калган безнең ферма үгезен! Ха-ха-ха...

Н а и л. Тавык кебек кыткылдап утырганчы, эзләшер идең, ичмасам!

А з а л и я. Беренчедән, синең күлмәк төймәңне эзләргә минем вакытым юк! Икенчедән, күреп торасың бит: Сабантуйда җырлар өчен яңа шаян җыр өйрәнәм! *(Җырлый.)*

Су буена төшкән идем,
Күрдем сине, җанашым...
Төне буе икәү бергә
Йөрдек йолдыз санашып...

Их, их, ихахай!
Ихахай да михахай!

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Йолдызларның чуты юк!
Сине сөйми булдыралмыйм –
Бүтән минем хутым юк...

Их, их, ихахай!
Ихахай да михахай!..

Җил-җил атлап, Д а м и р керә.

А з а л и я *(җырлавыннан туктап, сикереп торып)*. Дамир Җәмилевич?!

Д а м и р. Ихахай-михахай!.. *(Наилгә ишарәле.)* Нишли бу?

А з а л и я. Үзенә пай җире эзли! Җир алып, фермер булам, ди!

Д а м и р. Моңа тагы фермер булу! Башта үзенең дүрт сутый җирен казып бәрәңге утыртып карасын...

Н а и л. Көлмәгез! Бәрәңге жукларына аллергия миндә! «Колорадо» дигән сүзне генә ишетсәм дә, тәнем кычытынырга тотына... Әйттем бит! Менә башланды да инде... *(Җенләнеп кашына.)*

А з а л и я. Тизрәк табибка күрен син, Наил абый җаным. Корчаңгы тиз генә бетми бугай ул!

Д а м и р. Үзе беләдер... Мал врачы бит!

Н а и л. Кашыну ул әле корчаңгы дигән сүз түгел. Әйтеп торам бит, аллергия миндә! *(Кинәт кычкырып җибәрә.)* Таптым! Менә!

Д а м и р. Алтын тапканмыни! Күрсәтмә күземә. Берегез дөньясын онытып җырлый, икенчегез тезе белән идән шомарта... Мин сезгә нәрсә дидем?

Н а и л. Иптәш Бәдрикәев, эш болай тора...

Д а м и р. Аңлашылды!

А з а л и я. Ни бит, Дамир Җәмилевич...

Д а м и р. Кушканны җиренә җиткереп үтәсәгез, премия язам дип әйттемме?!

Н а и л. Әйттегез, иптәш Бәдрикәев.

А з а л и я. Хәзер бирмисезме инде премия? Без бит барып килдек! Бик озак чиләнеп тордык... Шулай бит, Наил абый җаным?!

Н а и л. Чиләнү генәме! Минем баш күкәй кебек пеште!

Д а м и р. Атаңның бозау чәйнәгән эшләпәсен кияргә иде...

А з а л и я. Көлмәгез инде, Дамир Җәмилевич! Без бит уйнап йөрмәдек.

Д а м и р. Йә, ярар... Сөйләштегезме?

Н а и л *(бармагы белән Азалиягә күрсәтеп)*. Сөйләш-тек... икәү.

Д а м и р. Мокытлар! Икегезнең сөйләшүе миңа ниемә хаҗәт! Мин бит сезне, ничек тә юмалагыз, дип җибәрдем.

А з а л и я. Без аны ничек юмалыйк... Өендә юк бит ул!

Д а м и р. Кая киткән?

Н а и л. Зиратта булырга тиеш!

Д а м и р. Тиеш-тиеш... Каян беләсең, бәлки, анда түгел-дер.

Н а и л. Моңарчы Сабантуйга кайтучыларның барысы да зиратка бара торган иде.

А з а л и я. Ай, белсәге-е-ез! Быел бик күп кеше кайткан Сабантуйга. Түбән очтан саный китсәк, Биктимер абзыйның төпчек малае Фәрит – семьясы белән, Гөлзадә апа – яңа ире белән, Фәйзулла абзыйның минем белән укыган малае Равил – өченче хатыны белән... Кәҗә Зиннур белән Каз Вакыйф – үзләре генә...

Н а и л. Син нәрсә... Авыл буйлап, өй борынча тикшереп йөрдең мәллә?

Д а м и р. Туктыйсызмы сез, юкмы? Быты-быты, быты-быты... Конкрет бер эш күрсәткәнегез юк! Премия сорарга дигәндә...

А р с л а н күренә. Тукталып тора.

А з а л и я *(Арсланны күреп, Дамирга куллары белән ишарә ясый)*. Дамир Җәмилевич! Премия! Үзе килде!..

Д а м и р *(Азалиянең әйткәнен ишетмәмешкә салышып)*. Сиңа әйтәм, Азалия! Була шундый кире кешеләр...

А з а л и я. Минем киреләнгәнем юк, Дамир Җәмилевич... Син «ә» диюгә, һәрвакыт «җә» дим!

Д а м и р. Тыңлап бетер!.. Халык өчен дип, көне-төне тырышасың... Рәхәт яшәсеннәр дип, тегесен-бусын төзегән буласың... Инде менә бу бердәнбер милли бәйрәмебез, Сабан туебыз күңелле узсын дип, уттай янып йөрисең... Ничек ярдәм итим диясе урынга... Юк инде, панимаешь! Кемдер синең гөрләтеп алып барган эшеңә аяк чалмыйча калмый...

А р с л а н. Бер тәкъдимем бар иде, Дамир энекәш!

Д а м и р *(әле генә искәргән кыяфәттә)*. Кемгә – энекәш, кемгә – Дамир Җәмилевич!

А р с л а н. Гафу, кем, Дамир Җәмилевич...

Д а м и р *(урындыкка җәелеп утырып)*. Тыңлыйм, абзый кеше!

А р с л а н. Зиратта булдым. Шуннан кайтып киләм.

Д а м и р. Минем юлым көн саен зират яныннан үтә...

А р с л а н. Халыкны җыеп, өмә үткәреп аласы иде.

Д а м и р. Өмә?! Нинди өмә? Бер атнадан Сабантуй!

А р с л а н. Зиратның коймасы тузган. Яңартырга кирәк!

Д а м и р. Мин аны син әйтмәсәң дә беләм! Акча юк!

А р с л а н. Ялгышмасам, әнә теге бердәнбер шәп йорт синеке бугай?!

Д а м и р. Минеке. Шуннан ни?

А р с л а н. Акча тапкансың бит, диюем.

Д а м и р. Нәрсә, хуҗа башым белән мин алачыкта яшәргә тиешмени?! Кычкырып көләчәкләр бит, йөземә бәреп әйтәчәкләр... Үзенә җүнле өй салып кералмаган башы белән ничек ул безне кайгырта алсын, ничек ул авылны күтәрә алсын, диячәкләр... Шулай дип әйтәләр дә!

А р с л а н. Халык өчен ничек тырышасыңдыр, анысы миңа караңгы... Монда күргәннәр бер дә синең файдага түгел. Зират турында әйттем. Мәчет төзелеп бетмәгән. Күпер бүген-иртәгә җимерелеп төшәргә тора. Чишмәләр каралмаган. Юллар начар...

Д а м и р. Вәйт әкәмәт! Сабантуй вакыты җиттеме, гел шулай: тегесе кайта – өйрәтә, бусы кайта – өйрәтә... Алай эшләргә, болай эшләргә кирәк, имеш! Ник үзегез кайтып эшләмисез? Ник булышмыйсыз? Ике-өч көнгә кунакка кайтып, акыл сатып китү җиңел ул... Үзең башта эшләп күрсәт син! Хөкүмәттән, районнан бернинди ярдәм күрмичә, медпункт кына салып кара. Ә мин салдым! Врачын да таптым! Син менә авыр вакытта мәктәпне, китапханәне саклап калып кара! Мин сакладым! Мәктәбе, китапханәсе булмаган авылның киләчәге юк! Син шул турыда уйлаганың бармы? Әйе, син әйткәннәрнең бөтенесен дә эшләргә кирәк. Ләкин акчасыз берни дә кырып булмый. Акча кирәк, акча, акча! Бушка хәзер авылда да беркем эшләми. Зиратны өмә ясап рәткә китереп булыр анысы... Эш бит зират белән генә бетми! Иң элек исәннәрне кайгыртырга, аларның хәлен яхшыртырга кирәк! Гаепләү җиңел ул... Ату, кунакка - кайткан буласыз да...

А р с л а н. Мин аңлыйм... Осуждение – это роскошь для пассивных наблюдателей... Ләкин мин бит булышырга дип кайттым!

Д а м и р. Булышырга? Димәк, син риза?!

А з а л и я. Кызык тәкъдим бу! Безгә спонсорлар бик кирәк, әйеме, Дамир Җәмилевич?!

Н а и л. Яз, Азалия! Тимерне кызуында сугарга кирәк. Арслан Васил улы Тәхәүетдинов, диген... Яз! Читтән кайткан авылдашлардан беренче спонсор, диген... Тигәнәкле авылын төзекләндерүгә фәлән кадәр суммада... суммасын язмый тор... акча бирде, диген...

А з а л и я *(Арысланга карап)*. Йөз сум, дип язып куйыйммы, Арслан абый?

Н а и л. Син нәрсә, Азалия, кунакны мыскыл итәсең! Йөз илле дип яз!

А з а л и я. Бу акчага бер шешә аракы тия. Күркә Гариф белән Шәүки бер яртыга зиратның алгы ягын бүген үк рәтләп чыга ала инде, бер уйлаганда!

А р с л а н. Мин акча белән ярдәм итәм дип әйтмәдем бит әле.

Д а м и р. Кирәкми дә!

А з а л и я. Ничек кирәкмәсен инде? Кирә-ә-әк! Мәсәлән, мин акчалата ярдәмгә бик мохтаҗ!

Д а м и р. Сиңа кияү кирәк! Сүз монда синең хакта бармый. Мин сөйләшкәндә тик кенә тор!

А з а л и я. Между прочим, мин – бухгалтерлар курсын бетергән кеше! Ике икең дүрт икәнне генә беләм!

Д а м и р. Син бухгалтерлыкка укыганда, әйе, ике икең дүрт иде. Дөньялар үзгәрде... Ике икең – биш хәзер!

А з а л и я. Дөнья үзгәрде дип... Мин үзгәрмәдем бит!

Н а и л. Үзгәртерсең сине!

Д а м и р *(Арслан каршына килеп)*. Аңлыйм хәлеңне, абзый кеше. Мондый карарга килү сиңа җиңел булмагандыр...

А р с л а н. Мин...

Д а м и р. Рәхмәт, Арслан ага! Лично үземнән һәм барлык авыл халкы исеменнән!

А р с л а н. Әле рәхмәт ишетерлек эш күрсәтмәдем шикелле...

Д а м и р. Синең тарафтан рөхсәт булу – бу инде үзе зур эш!

А р с л а н. Әллә олыгаю галәмәте инде... Сүзнең ни турыда барганын төшенеп җитмим һаман...

Д а м и р. Тыйнак кешене яратам мин, хөрмәт итәм! Мәгез бишне! Димәк, килештек. Сүтәбез! Наил, җый командаңны!

Н у р з и ф а *(кердә-керешли)*. Бирмә ризалыгыңны, Арслан! Сүттермә өеңне!

А р с л а н. Нурзифа?!

Д а м и р. Нурзифа апа, монда син генә җитмәгәниең! Пажалыста, кысылма ирләр сөйләшкәндә!

Н у р з и ф а. Күзләрем күрә, колакларым ишетә, Аллага шөкер! Мин барысын беләм. Дамир энем, артыгын кыланасың!

Д а м и р. Нишләгән әле мин ул хәтле?

Н у р з и ф а. Түрәләреңә ярыйм дип, ферма малын таратып бетерүең җитмәгән... Инде кеше яшәп яткан йортны сүтәргә җыенасың... Шулай түгел мәллә?

Д а м и р. Барыбер сүттерәм! Искене сүтәргә имею право!

Н у р з и ф а. Иске булса да, нык йорт әле ул! Сүтәргә кирәкми аны, музей итәргә кирәк!

Д а м и р. Нинди музей? Син нәрсә! Бар-бар, тормале монда мишәйт итеп! Кайт өеңә, укып ят намазыңны!

А р с л а н. Үзеңнән өлкән кешегә кычкырма, энекәш... Өстәвенә хатын-кызга! Олыларны хөрмәтли белергә кирәк!

Д а м и р. Өйрәтмә! Өйрәтәсең килсә, шәһәреңә кайт та хатыныңны өйрәт! Монда мин хуҗа! Телим икән – кычкырам, телим икән – җикерәм!

Н у р з и ф а. Хет өй түбәңә менеп акырып утыр... Әмма мин өйне сүттермим! Белеп тор!

Д а м и р. Котырган хатын-кыздан да яман нәрсә юк... Тыегыз әле шуны!

А з а л и я. Нурзифа апа, тынычланыгыз, зинһар!

Н у р з и ф а. Мине тыярга кирәкми, тыңларга кирәк!

Н а и л. Баядан бирле тыңлыйбыз бит инде... Тик мин, мәсәлән, йортны нигә сүттермәскә тырышканыңны гына һаман аңлап җиткермим!

Н у р з и ф а. Бүген генә килеп чыккан нәрсә түгел бу... Син бу йортка күптән кыҗрап йөрисең инде. Әниең котыртып торганын да беләм... Белми димә! Гомер буе Рәйсә апаны күралмады әниең. Аннан гел көнләшеп яшәде. Гайбәтен сатмыйм, әмма әйтмичә дә булдыралмыйм!

Д а м и р. Ну-ну! Тагын ниләр беләсең? Әйдә, сөйлә!

Н у р з и ф а. Яшь чагында әниең Васил абыйны бик яраткан...

А з а л и я. Мин белмидерием әле... Кызык бу!

Д а м и р. Яшь чакта кем кемгә гашыйк булмаган да кем кемне яратмаган!

А р с л а н. Нурзифа, үткәнгә кагылма, кирәкми!

Н у р з и ф а. Кирәк! Рәйсә апа белән Васил абый өйләнешкәч тә, аларның араларын бозарга теләп, ниләр генә эшләмәгән ул! Миңа боларны Рәйсә апа үзе сөйләде. Атаң, мәрхүмкәй, бик йомшак кеше иде. Ул да рәхәт күрмәде анаңнан...

Д а м и р. Беттеме сүзең? Инде хәзер мине тыңла: әнидә, тимбулые күптән җир астында яткан әтидә синең эшең булмасын! Аңладыңмы?

А р с л а н. Нервыңны сакла, Нурзифа... Китик әйдә!

Н у р з и ф а. Әйтеп бетермичә китмим әле мин. Үзең белмисеңдер дә әле... Рәйсә апа белән Васил абый – сине үлемнән алып калган кешеләр.

А з а л и я. Үлемнән?!

Д а м и р. Хәтерләмим... Алдыйсың!

Н у р з и ф а. Хәтерләмисеңдер шул... Сабый гына идең бит ул чакта! Онытмаган булсаң, синең дә исеңдәдер әле, Арслан?!

А р с л а н. Минә хәзер исемә төште. Кыш көне иде бит ул!

Н у р з и ф а. Әйе, бик каты салкын кыш иде. Мин сезгә сепаратор сорап кердем... Сез өчәүләп чәй эчеп утыра идегез. Рәйсә апа табын янына чакырды. Мин чәй йотарга да өлгермәдем, кемдер ишек шакыган кебек булды. Тышта җил котыра, буран... Шаку тавышы колакка ялгыш кына ишетелгәндер, диештек. Берзаман бала елаган тавыш ишетелгәндәй булды. Васил абый, бүреген генә эләктереп, өйалдына чыгып китте. Ишек ябылырга да өлгермәде, ниндидер төргәк күтәреп, Васил абый кире килеп тә керде. Ул төргәк эчендә син идең, Дамир!

Д а м и р. Булмас! Ялган бу!

Н у р з и ф а. Рәйсә апа сине җылы, йомшак юрганга төр-гән вакытта, чүпрәк-чапрак арасыннан Васил абый кәгазь табып алды. Анда «Баланың атасы Васил» дигән өч кенә сүз язылган иде... Ул вакытта мондый нахак сүзне күтәрүе җиңелдән булмагандыр Васил абыйга!

Д а м и р. Барыбер ышанмыйм!

Н у р з и ф а. Өч көннән соң килеп, ызгышып, анаң сине кире алып кайтып китте... Йорт сүттерәм, имеш! Их, син! Рәйсә апа белән Васил абыйның рухлары алдында баш ияр идең, ичмасам!

Д а м и р. Теләсә нишләгезсәнә! *(Чыгып китә.)*

Авыр тынлык. Музыка. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кабат янган ут сәхнәнең алгы өлешен генә яктырта. Сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелә. З ө ф ә р Ә д и б ә н е күтәреп керә.

Ә д и б ә *(чытлыкланып)*. Зөфәр, дим! Төшер инде!

З ө ф ә р. Төшермим! Мин сине гомер буе шулай күтәреп кенә йөриячәкмен!

Н у р з и ф а күренә, яшьләрне тыңлап тора.

Ә д и б ә. Минем әби әйтә, тасма телләргә ышанма, тасма телләр баш ашый, ди... Төшер, дим!

З ө ф ә р. Перекур! *(Әдибәне җиргә бастыра.)* Ә менә минем бабай әйтә, язгы бозга һәм хатын-кызга ышанма, ди!

Ә д и б ә. Минем әби әйтә, җете кызыл тиз уңа, ди...

З ө ф ә р. Ә минем бабай әйтә, күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге, ди!

Ә д и б ә. Минем әби әйтә, авызың пешмәсен дисәң, өреп кап, ди...

З ө ф ә р. Ә минем бабай әйтә, авызың ни әйткәнне колагың ишетсен, ди... Уф! Сине барыбер җиңеп булмый! Ничьямы?

Ә д и б ә. Ничья. Минем әби әйтә...

З ө ф ә р. Бу хәтле искә төшерүеңә Нурзифа әбине очкылык тотмаса ярый инде...

Нурзифаның елмаеп-көлемсерәп торганы шәйләнә.

Ә д и б ә. Минем әби әйтә, егетең төпле егеткә охшаган, ди.

З ө ф ә р. Чынлап шулай диме? Нурзифа әби акыллы кеше ул!

Ә д и б ә. Борынын артык югары чөймәсә, рәтле кеше чыгар үзеннән, ди...

З ө ф ә р. Нурзифа әби дигәннән... Ни булган аңа? Башка вакытта сәламемне ала торган иде, баягынак исәнләштем – җавап бирмәде... Хәтта ул мине күрмәде дә кебек!

Ә д и б ә. Ачуы килгәндер... Яраткан оныгын калдырып, Мәскәүгә укырга китәсең бит!

З ө ф ә р. Ю-у-ук... Ачуы килгән кешегә бер дә охшамаган иде ул...

Ә д и б ә. Кызы-ык... Син дә игътибар иткәнсең икән. Әбием бүтән көннәрне гел ишегалдында кайнаша иде, бүген иртә белән чәй дә эчмичә чыгып китте. Нишләп йөридер – белгән юк. Бер-бер хәл булмасын тагы. Әйдә, эзләп табыйк әле әбине!

Н у р з и ф а. Мине эзлисе юк, кызым. Мин монда.

Ә д и б ә. Әбием!

З ө ф ә р. Нурзифа әби, исәнмесез!

Н у р з и ф а. Шөкер әле, Зөфәр улым.

Ә д и б ә. Әбием, әле генә без Зөфәр белән сине искә төшергән идек.

Н у р з и ф а. Әби дә картайды дигәнсеңдер инде, кызым...

Ә д и б ә. Юк, бер дә алай димәдем әле. Минем әбием – дөньяда иң матур әби, көннән-көн яшәрә бара, бүген тотып кияүгә бирерлек, дидем! Ышанмасаң, Зөфәрдән сора. Шулай дидем бит, Зөфәр, име?!

З ө ф ә р. Ие! Чынлап шулай диде.

Н у р з и ф а. Ә син ни дидең, Зөфәр улым?

З ө ф ә р. Мин... Мин әйттем... Нурзифа әби акыллы кеше ул, дидем!

Ә д и б ә. Ә мин әйттем, минем әби – иң бәхетле әби, дидем.

Н у р з и ф а. Гомерләр үтә, балалар... Менә сез дә үсеп җиттегез. Мин әйткән исегездә калсын: икәү бергә тапкан бәхет татлы бәхет була. Шул бәхетне югалтырга язмасын берүк! Минем шикелле бер карчык әйткән, ди, бит: «Бәхетем дә табылды, тик бөкрем генә чыкты...» Шулай дияргә язмасын сезгә! Инде табышкансыз, киләчәктә гел бергә булыгыз! Миннән фатиха шул. Барыгыз, балалар...

Ә д и б ә. Әйдә син дә безнең белән, әбием!

Н у р з и ф а. Барыгыз, бар... Мин үзем акрынлап атлармын...

З ө ф ә р. Ярый алайса, без киттек, Нурзифа әби!

Яшьләр чыгып китә. Музыка тавышы астында ут сәхнәне тулаем яктырта. А р с л а н болдыр баскычында башын иеп утыра. Н у р з и ф а Арсланга таба бер-ике адым атлый да тукталып кала.
Пауза.

А р с л а н *(якында кемдер барын сизеп, кинәт башын күтәреп)*. Нурзифа! *(Нурзифага таба атлый.)* Нурзифа! *(Нурзифа китмәкче була.)* Туктале, Нурзифа...

Н у р з и ф а. Мәрхүмкәйләрнең... Рәйсәттәй белән Васил абыйны әйтәм... күзләре гел юлда булыр иде...

А р с л а н. Әнкәй... Әткәй... Гаебем зур... Нишли дә алмыйм...

Н у р з и ф а. Алар рухына дога кылсаң гына инде...

А р с л а н. Мин, әйтергә оят, бер дога да белмим.

Н у р з и ф а. Ике кыйблага оеганның иманы булмас, диләр... Өйрәнергә кирәк!

Арслан сискәнеп куя. Шулвакыт, җил-җил атлап, А з а л и я керә.

А з а л и я. Уф! Эзләмәгән җир калмады... Әле ярый Әдибә белән Зөфәрне очраттым. Нурзифа апа! Миңа син кирәк идең...

Н у р з и ф а. Ни йомыш, Азалия?

А з а л и я. Берүк ачуланмагыз инде... Сүзегезне бүлдердем бугай.

Н у р з и ф а. Юк-юк... Без инде сөйләшеп бетердек.

А з а л и я. Нурзифа апа! Бер атнадан Сабантуй бит инде, әйеме? Быел аны бик шәп итеп үткәрергә җыенабыз... Үзебезнең көч белән. Читтән артистлар да чакырмыйбыз. Җырлаучылар да, биючеләр дә бары тик үзебезнең авыл кешеләре генә булачак. Без, бергәләп, катнашучыларның исемлеген төзедек. Исемлектә син дә бар, Нурзифа апа!

Н у р з и ф а. Минем бит бер дә җырлаганым юк, Азалия үскәнем. Бии белүем дә ташка үлчим генә.

А з а л и я. Нурзифа апа, синең ничек биегәнеңне клубның һәр идән тактасы белә. Биисең! Әле, Алла бирса, җырлавыңны тыңларга да исәп! «Җырлый белмим» дип, берүк тагы әйтә күрмә. Җырлаганыңны белүчеләр дә, күрүчеләр дә бар. Минем әби шаһит: яшь чагыңда бик матур җырлагансың. Шуннан соң бүгенгә хәтле нишләптер бер дә җырламагансың. Бүгенгә хәтле, дидем... Бүген чөнки синең җырлавыңны ишеткәннәр. «Кемнәр ишеткән?» дип сора, Нурзифа апа? Минем энем Илнур белән Пыртманит Марсельнең малае Роберт! Илнур әйтә: «Нурзифаттәй бик матур җырлый икән ул, – ди, – «Зимагурның чалбары, зимагурның маллары» дип җырлады», – ди... Әсәренгән! Зимагур дигән исем дә буламыни ул, ди... *(Көлә.)* Зимагурны кеше исеме дип белгән... Кыскасы, Нурзифа апа, җырлатабыз да, биетәбез дә сине. Әзерлән. Мин киттем. Әйтәсе сүзем шул гына иде. Сүзегезне бүлдем. Ачуланмагыз инде берүк! *(Китә.)*

Пауза.

А р с л а н. Йа Хода! Әле генә башыма ордылармыни: ничә еллар җырламавыңның сәбәпчесе мин булганмын бит! Мин, мин... Барысына да мин гаепле!

Н у р з и ф а. Гаепне тануы җиңел, юуы авыр... Колагымда синең сүзләрең әле дә яңгырап тора: вәгъдә — иман! Вәгъдә – иман! Авыз тутырып нинди җырлау ди ул! Шушы ике сүз миңа рәхәтләнеп сөенергә дә, дөньядан ямь табып яшәргә дә ирек бирмәде. Мин һаман көттем! Бүген җырлый башлавым сине күрү шатлыгыннан түгел... Түгел! Яшьлегемне мәңгегә югалтканымны аңладым мин... *(Җырлый.)*

Еллардан калышмый, юллардан барышлый,
Гомерем йомгагын сүткәндә,
Борылам да карыйм, борылам да карыйм,
Борылам да карыйм үткәнгә...

Болында – чәчәкләр, кулымда – чәчәкләр,
Чәчәкләр түгел лә – яшьле гөл...
Кычкырсам, ишетмәс, кычкырсам, ишетмәс,
Кычкырсам, ишетмәс яшьлегем!

Борылам да карыйм, борылам да карыйм,
Үреләм дә карыйм еракка...
Уйласам – уйлата, җырласам – җылата,
Нишләсәм дә авыр йөрәккә...

Ут сүнә. Көй әкрен генә сүрелә. Кабат янган ут яктысы Арсланга гына төшә. Шулай ук аерым ут көлтәсе астында карт пәйда була.

Нурзифа тавышы *(кайтаваз булып яңгырый)*. Ике кыйблага оеганның иманы булмас... иманы булмас... булмас...

Арслан. Син ник алай дип әйттең, Нурзифа? Бу сүз-ләрең белән ни әйтергә теләдең? Мин имансыз түгел... Имансыз түгел!

Ак бабай. Иман, дисең... Син бу сүзнең асылын тәгаен аңлап әйтмисең әле...

Арслан *(картны күрүенә гаҗәпләнмичә)*. Алайса, син әйт, изге карт... Төшендер асылын.

Ак бабай. Адәм баласы гомере буе нидер эзли, эзләнә... Дөньяга беренче авазын салуга, әле күзләре ачылганчы ук, әнисен, әнисенең сөтле күкрәген эзли... Сөйләшә башлауга, күңелендә туган бихисап сорауга җавап эзли... Тәпи баса... Үсә... Яшьлек чоры башлана... Хәзер инде ул үзенә тиң ярын эзли... Эзли... Эзли... Кемдер таба, кемдер югалта... Кемдер ялгыша, кемдер адаша... Гомер уза... Картлык якынлаша... Адәм баласы яшьлеген, балачагын сагына... Ул шулай җанына тынычлык эзли... Эзли... Таба... Ул арада башына уй төшә. Уй аның янә җан тынычлыгын ала...

Арслан. Нинди уй ул, Ак бабай?

Ак бабай. «Бу дөньяга мин ни өчен килдем? Үземнән соң нинди эз калдырам?» дигән уй. Җирдә эзең каламы синең, олан?

Арслан. Мин бу хакта уйланмадым әле, изге карт. Менә кайттым. Уйланырга вакыт күп хәзер.

Ак бабай. Вакыт күп булалмый. Ул гомер белән бәйле. Ә гомер, үзең беләсең, бик кыска. Кайттым, дисең һаман. Син әле кайтмадың!.. *(Үзен яктырткан ут яктысы белән бергә карт юкка чыга.)*

Арслан. Ни әйтергә тели бу карт? Ник әйтеп бетерми ул? Кайттым бит инде мин!

Ут сүнә. Музыка.
Кабат янган ут сәхнәнең алгы өлешен яктырта. Дамир, аңа ияреп, Наил белән Азалия керә.

Д а м и р *(кесә телефоныннан сөйләшеп)*. Әйе, Әхтәм Галиеч! Юк-юк, машинада түгел, сөйләшалам! Тыңлыйм, Әхтәм Галиеч! Әйе-әйе, барысы да тәртиптә. Әйе, Сабантуйга әзерләнәбез. Сезне дә көтәбез! Ни дисез? Ишетелми. Алло! Алло! Менә хәзер ишетелә башлады. Хәзер тавышыгыз әйбәт ишетелә, дим! Нәрсә? Кем килә? Безгәме?! Кайчан? Аңлашылды. Аңладым, Әхтәм Галиеч! Әһә! Әһә! Бу минем бөтен планны җимерә, кәнишне... Заразы! Юк-юк, сезгә әйтмим мин, Әхтәм Галиеч! Яхшы! Шундук доложу сезгә! Положу түгел, доложу, дим! Әйе, шундук хәбәр итәрмен! *(Телефонын сүндереп, кесәсенә тыга.)* Ё-моё!

Н а и л. Кем килә безгә, иптәш Бәдрикәев?

А з а л и я. Каян килә ул, Дамир Җәмилевич?

Д а м и р. Ё-моё!

А з а л и я. Минем әбием мондый чакта, авыртмаган башка – тимер тарак, ди...

Н а и л. Әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен! Тс-с! Күрмисеңмени, иптәш Бәдрикәев аңына килалмый тора... Мишәйт итмә!

Д а м и р. Ё-моё! Мәскәүдән урыс килә! Безгә!

А з а л и я. Ё-моё!

Н а и л *(Азалиягә сәерсенеп карап)*. Урыс килә, дигәч... Син дә урысча сөйләшә башладың әле.

Д а м и р. Идея! Менә кемнән акча кысып булачак! Беткән баш беткән... Сабантуйны урысча уздырабыз! Өлгерәбез әле!

Н а и л
А з а л и я *(бергә)*. Нәрсә?! Ничек?!

Д а м и р. Кароче, болай... Ишеттегез инде: Мәскәүдән урыс килә! Бүген йә иртәгә монда булачак! Әхмәт Галиеч әйтә, бик зур түрә, ди! Кунакны каршыларга әзерләнергә кирәк! Киттек! *(Китә.)*

А з а л и я. Пошли, Николай!

Н а и л. Күз алдында настоящий маржага әйләндең! Пошли, Мәрүчкә!

Чыгып китәләр. Ут сүнә. Музыка.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урыс көе яңгырап торган мәлдә, пәрдә ачыла. Клуб. «Сабантуй – праздник плуга», «С праздником, дорогие гости!», «Мир, труд, Сабантуй!» дигән лозунглар шәйләнә. Ыгы-зыгы. Барысы да (А з а л и я, Н а и л, З ө ф ә р, Ә д и б ә), эш күрсәткән кыяфәт чыгарып, әрле-бирле килә. Азалия магнитофонга яңа диск куя да, микрофон тотып, сәхнә уртасына баса. Частушка көе яңгырый.

А з а л и я *(җырлый)*. Меня милый не целует,
Ах, какой он молодец.
Он свои большие губы

Бережёт на холодец...

Азалия җырлаган чакта, Наил аның янында артистлана.

А з а л и я. Меня милый не целует,
Говорит: «Потом, потом...»
Я иду, а он на печке
Тренируется с котом!

Тиз-тиз атлап, Д а м и р керә. Бертын ыгы-зыгы килүчеләргә карап тора. Кулъяулыгын чыгарып, маңгаен-битен, муен тирәсен сөрткәли.

А з а л и я. Меня милый не целует,
Говорит: «Боюсь поста!»
А любовь без поцелуя,
Что корова без хвоста.

Едет милый на базар,
Глупо улыбается.
Оказалось зубы вставил,
Рот не закрывается...

Азалия җырлап бетерүгә, урыс биюе көе яңгырый. Әдибә белән Зөфәр теттереп биергә тотына. Бераздан биючеләргә Дамир да кушыла.
Кинәт кесә телефоны шылтыраган тавыш ишетелә. Дамир телефонын колагына куя.

Д а м и р. Стоп-стоп! Туктагыз! Ни хрена да ишетелми. Бездә полный әзерлек бара, Әхтәм Галиеч. Чучканы көтәбез... Тфү! Кунакны көтәбез. Чучка дип ялгыш әйттем, Әхтәм Галиеч... Баш каткан! Шашлыкка ит кирәк бит. Чучка дигәннән... *(Наилгә.)* Оныттырма әле, чучка мәсьәләсен сручны хәл итәсе бар! *(Телефонга.)* Олы юлга, тагын авылга керә торган юлларга постлар куйдым. Кунак күренүгә, хлеб-соль белән каршылаячакбыз. Табын әзер. Сез яраткан борай бәлешенә заказ бирелгән. Әлбәттә, әлбәттә, каз ите белән. Каклаган каз да булыр. Урысларның милли ризык-ларын да онытмадым. Тозлы кыяр, тозлы кәбестә, тозлы гөмбә, кильки... Водка само собой. Плюс шашлык. Менә табынга куярга молочный поросёнок табалмадым әле түлке. Анысын да табармын. Казан ерак түгел... Машина җибәрдем инде. Борчылмагыз. Бар да о’кей булыр. Әбизәтелне, шундук шылтыратам! Однозначно. *(Телефонын кесәсенә тыгып куя, янә кулъяулыгын чыгарып сөртенә.)* Жарко, заразы!

А з а л и я. Эссе шул бигрәк. Кәчтүм кигәнсез өстәвенә. Кунак каршылыйм дигәч тә... Күлмәк өстеннән сары галстугыгыз да бик җиткән инде югыйсә...

Д а м и р. Погоди... Наил, нәрсәне оныттырмаска куштым әле мин?

Н а и л. Чучканы.

Д а м и р. О, да. Маладис, онытмагансың.

А з а л и я. Онытмый ул, онытмый... Аның хәтере бик әйбәт. Эчсә генә кеше танымый башлый.

Д а м и р. Бая шәп җырладың... Син дә маладис! Сара-фан да киеп җибәрсәң, полный марҗа буласың! Наил, нәрсә һаман сузып йөрисең... Өйлән давай Азалиягә!

Н а и л. Күп ашый ул... Мин аңа каян ризык җиткереп бетерим. Җитмәсә, артык күп сөйләшә.

А з а л и я. Слабак! Син хәерчегә кияүгә чыксаң, ачка үләрсең! *(Зөфәр белән Әдибәнең пырхылдап көлүен күреп.)* Хихылдап торган буласыз... Авызыгызны ачсагыз, үпкәгез күренә!

Д а м и р. Булды, җитте! Бетердек сүз боткасын! Кыстати, ботка дигәннән... Урыслар ботка ашыймы әле ул? Аларның милли ризыклары санала микән, диюем?

Н а и л. Боткасын белмим, әмма каша ашыйлар! Армиядә урыс егетләре белән ике ел тары боткасы гына ашадык! Зинһар, иптәш Бәдрикәев, ул ботканы берүк табынга куйдырта күрмәгез!

А з а л и я. Куйдыртсын! Син бит барыбер ул табын янында утырасы кеше түгел... Миңа, мәсәлән, тары боткасы ни, борчак боткасы ни – барыбер ашыйм!

Н а и л. Иптәш Бәдрикәев, мөмкин булса, эш турында гына сөйләшик әле!

А з а л и я. Ашау – тужы эш ул, бик беләсең килсә! Шундый заман килде: хәзер кеше яшәр өчен ашамый, ашар өчен яши... Искерде ул элекке мәкальләр, бетте ул әүвәлге мораль кодекслар, принципсыз принциплар...

Д а м и р. Стоп-стоп! Куда вы паехали? Сүз бит чучка турында бара иде. Безгә немедленно бер чучка кирәк! Кем белә, каян табып була?

А з а л и я. Нишлибез аның белән, Дамир Җәмилевич?

Н а и л. Шашлыкка, диде бит... Ишетмәдеңмени?

Д а м и р. Ё-моё! Мин бит...

З ө ф ә р. Без монда кирәк түгел бугай...

Ә д и б ә. Әйе, безгә китәргә ярыйдыр бит?

Д а м и р. Подождите. Ашыктырмагыз. Сезгә дә чират җитәр...

А з а л и я. Бүлдермәгез Дамир Җәмилевичне!

Д а м и р. Шашлыкны истән чыгара язганмын икән әле... Ул чагында ике чучка кирәк! Берсе – шашлыкка, икенчесе – көрәштә җиңгән батырга! Наил, давай, эшләт башыңны!

А з а л и я. Мәрткә китмәгәнсеңдер бит? Дамир Җәмилевич сиңа әйтә...

Н а и л. Нәрсә төрткәлисең? Ашарга булса – син, баш эшләтергә булса – мин! Сиңа да үз гомереңдә бер мәртәбә генә булса да уйларга ярыйдыр бит?!

А з а л и я. Миңа уйларга ярамый. Уйласам, чәчем агара башлый! Туктагыз әле, мин аңлап җиткермәдем... Көрәштә җиңгән батырга тәкә бирелмимени?

З ө ф ә р. Әйттеләр бит, биреләчәк... Керәшен тәкәсе!

Ә д и б ә. Миңа сүз әйтергә мөмкинме?

Д а м и р. Можно.

Ә д и б ә. Нишлисез сез, Дамир абый? Чучка биреп, көрәш батырын мыскыл итмәгез инде! Борын-борыннан килгән татар Сабан туе бит ул! Халыктан көлмәгез ул хәтле...

З ө ф ә р. Телевидение чакыртырга кирәк! Күрсеннәр безне, белсеннәр... Чып-чын татар авылында урысча Сабантуй! Сенсация бит бу!

Д а м и р. Кирәк дисәм, чакыртырмын да! Атаң кебек кешене өйрәтмәгез, башыгыз яшь әле!

Ә д и б ә. Мин сезнең Сабантуйда катнашмаячакмын!

З ө ф ә р. Мин дә!

Н а и л. Алайса, кайтыгыз да абзар артыгызда ясагыз үзегезчә Сабантуй!

З ө ф ә р. Ә син кысылма! Без синең киңәшкә мохтаҗ түгел!

А з а л и я. Катнашмасагыз, бик исебез китте инде, име, Дамир Җәмилевич?!

Д а м и р. Күренеп тора... Казан Сабан туенда булганыгыз юк икән сезнең. Минем булганым бар. Анда Сабантуй әләмен кемнәр күтәрә дип беләсез? Иван Иванычлар! Андагы Сабантуйны татарча алып баралар дип уйлыйсыздыр, бәлки?! Ялгышасыз! Башыннан ахырынача урысча сөйлиләр анда! Бәйрәмгә килгән кунакларны ни белән сыйлыйлар? Чучка шашлыгы белән! Дөрес, көрәш батырына чучка биргәннәре юк әлегә... Әмма эш шуңа таба бара! Горбачёв әйтмешли, процесс пошел! Бөтен җирдә кемгәдер яраклашу барганда, мин генә читтә калмам бит инде! Минем дә үз урынымда тыныч кына эшлисем, кешечә яшисем килә!

Ә д и б ә. Сез теләсә нишләгез, әмма без Сабантуйны урысча уздыру белән килешмибез!

З ө ф ә р. Әйтүебез шушы!

Н а и л. Сыерлар боз ялаганда, бозаулар тик тора. Сиңа кагыла бу, энекәш!

З ө ф ә р. Гафу ит, Наил абый! Мин бит сине сыер дип белмәдем...

Н а и л. Аһ, яптырниса! *(Зөфәргә ташланмакчы була.)*

З ө ф ә р. Әтәчләнмә, Наил абый!

Д а м и р. Нинди бака туе соң бу, ә? Всё! Кончили! Тфү, заразы... Прекратили! Безгә барыбер чучка кирәк!

А з а л и я. Мин каян табарга икәнен беләм, Дамир Җәмилевич!

Д а м и р. Әйт, сузма!

А з а л и я. Кадермәт абыйларда бар. Ул аларны кеше күзеннән яшереп асрый. Симертеп сатаргадыр инде...

Н а и л. Элекке партком секретарена яшермәсә дә була инде... Хәер, хәзер мулла саналып йөргәч, ояла торгандыр шул!

З ө ф ә р. Ул шулай астыртын гына поп булырга җыенып ятмый микән?

А з а л и я. Яп авызыңны, клоун!

Д а м и р. Всё! Барабыз, алабыз!

А з а л и я. Ә бирмәсә?

Д а м и р. Яманаты читкә чыкмасын дисә, бирер, нибуч! Киттек мулла абзыйларга!

Ә д и б ә. Мин үз сүземне әйттем!

З ө ф ә р. Безгә чучкалы Сабантуй кирәк түгел!

Ут сүнә. Музыка.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут кабат яна. Н у р з и ф а берьялгызы эскәмиядә утыра.

Н у р з и ф а *(җырлый)*.
Җилфер-җилфер искән җилләр-
Туздыралар юл тузанын, юл тузанын.
Сизмисең лә яшь гомернең,
Ай, узганын, ай, узганын...

Алсу гына гөлләрең лә,
Ай, ачылсын, ай, ачылсын, ай, ачылсын.
Сахраларга исләре лә,
Ай, чәчелсен, ай, чәчелсен...[1]

Ә д и б ә керә. Нурзифаның соңгы ике юлны кабатлап җырлаганын тыңлап тора.

Ә д и б ә *(кинәт килеп кочаклап алып)*. Әбием, сәлам!

Н у р з и ф а. Абау! Котымны алдың бит, кызым!

Ә д и б ә. Карап-карап йөрим дә мин... Әллә нәрсә булды әле сиңа, әбием! Өйгә кайтам – өйдә юк син. Гел каядыр китеп югаласың... Җырлыйсың... Моңарчы җырлаганың юк иде. Туктале! Күзләреңдә яшь бөртекләре күрәм. Җылыйсыңмы әллә син, әбием?

Н у р з и ф а. Күпне күрмә, кызым, тиз картаерсың! Яшь түгел ул, тир тамчысы гына... Көне бик эссе – чыдап булмаслык!

Ә д и б ә. Әбием, карале, мин сантый кызга охшаганмынмы?

Н у р з и ф а. Ник алай дип әйтәсең әле, кызым?

---

[1] Татар халык җыры «Исә җил».

Ә д и б ә. Әбием! Мин бит бөтенесен дә күреп торам... Җырлавыңның да, җылавыңның да сәбәбе бар. Шулай бит?! Дөресрәге, сәбәпчесе бар. Кем икәнен әйтимме?

А р с л а н керә.

Н у р з и ф а *(Арсланны күреп)*. Кызым, карале, син кәҗәбезне очратмадыңмы?

Ә д и б ә. Нинди кәҗә? Ни сөйлисең син, әбием. Кәҗәбез юк бит безнең! *(Арсланны күреп ала.)* Һә! Любовь-морковь! Исәнме, Арслан баб... абый! Кәҗә, дисеңме, әбием? Юк шул, очратмадым. Эшем күп, киттем мин, яме! Карагыз аны, йөземә кызыллык китерәсе булмагыз! Тили-тили-тесто... *(Китә.)*

А р с л а н. Оныгың бик чая кыз. Сиңа охшаган!

Н у р з и ф а. Бик үткен, Аллага шөкер! Бәхеткәе генә булсын инде берүк.

А р с л а н. Мондый кыз да бәхетле булмаса... Булыр! Яшьлеге чәчәк аткан вакыт кына әле. Менә... Яшьлек дигәннән... Икәү йөргән сукмаклардан кабат үтеп, иләс-миләс булып кайтып киләм әле, Нурзифа.

Н у р з и ф а. Үләннәр баскандыр инде ул сукмакларны...

Пауза.

А р с л а н. Су буенда Кәбирне очраттым. Исән икән әле. Картайган.

Н у р з и ф а. Авыл санаторий түгел... Картаерсың да! Гомер буе тракторда эшләде. Иртә таңнан төнгә кадәр... Көн саен! Эчүнең дә кимен куймады инде...

А р с л а н. Сөйләшеп тордык. Сине бик мактады. Безнекеләрне бик тәрбияләп торгансың икән... Рәхмәт, Нурзифа!

Н у р з и ф а. Син юк... Әтиеңнәргә акчаң килеп торды анысы... Шуннан гына белдек синең исәнлекне...

А р с л а н. Аңлый алырсыңмы мине, юкмы... Шулай да... Утыр әле, Нурзифа. Утырып тыңла. Сүзем озын булыр... Ашыкмыйсыңдыр бит?

Н у р з и ф а *(утырып)*. Ашыккан чаклар узды инде...

А р с л а н. Кай төштән башлыйм икән?

Н у р з и ф а. Син киттең... Укырга дип...

А р с л а н. Бардым Мәскәүгә... Укырга МГИМОга кердем... Шундый институт бар – институт международных отношений... Мәктәпне алтын медаль белән тәмамлауның файдасы тиде...

Н у р з и ф а. Башлы идең шул...

А р с л а н. Укыганда... беренче курсны тәгәлләгән көн-нәрдә... югарыдан... бер оешмадан килеп минем белән сөйләштеләр... Хрущёв чоры иде бит инде... Үзең беләсең... Идеология көчле... Тагын тегесе-бусы... Яшь чак – җүләр чак... Аннары перспектива дигәндәй... Мин ризалык биреп ташладым... Беркемгә берни сөйләмәскә дип кул куйдырдылар... Көнчыгыштагы бер илгә тәгаенләп, мине шундук әзерли

башладылар. Артка юл ябылды. Авылыңа, әти-әниеңә үзебез хәбәр итәрбез, диделәр...

Н у р з и ф а. Хатларың килми башлады... Мин ни уйларга да белмәдем...

А р с л а н. Кыскасы шул: кырык елдан артык гомерем чит илләрдә узды. Родина-мать өчен, кем әйтмешли, утка-суга кердем... Төрле хәлләр булды, күпне күрде баш... Сөйләсәң, сөйләп бетерерлек кенә түгел! Төшләремдә авылны... сине... әти белән әнине... бик еш күрдем. Төштә генә күрү төштә генә күрү шул инде...

Н у р з и ф а. Син дә баштагы мәлләрдә төшемә еш кер-дең... Аннары – сирәкләдең... Әйтүе генә ансат: кырык ел! Бөтенләй чит-ят дөньяда!.. Ни... Ниме соң...

А р с л а н. Нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңладым, Нурзифа. Әйе, өйләндем. Хатыным – еврей. Балалар икәү. Кыз да малай. Хәзерге вакытта алар Израильдә... яшиләр. Мин монда. Менә шулай килеп чыкты язмышлар... Үзең ничек? Оныгың барлыгын күрдем инде...

Н у р з и ф а. Көттем. Көттем. Көттем... Әниең Рәйсә апа әйтте бервакыт: «Карт кыз булып утырып каласың бит... Чыгып кал кияүгә!» – диде. Мин һаман көттем. Рафис та мине сабыр гына көтте...

А р с л а н. Рафис?! Кайсы Рафис? Мин беләмме аны?

Н у р з и ф а. Беләсең. Гапсаматов Рафис. Бездән бер ел алда укыды.

А р с л а н. Теге... Йомыкый Рафисмы?

Н у р з и ф а. Бик әйбәт кеше иде, мәрхүм... Бер малай үстердек. Кулы эшкә ята иде. Мәчет салам дип хыялланды. Башлаган да иде...

А р с л а н. Без күрәсен чит кеше күрми диләрме әле?!

Н у р з и ф а. Маңгайга язылган язмышыңны тир белән генә сыпырып булмый икән шул, Арслан...

А р с л а н. Нурзифа-ам...

Ерактан (бәлки үткәннән?) җыр тавышы ишетелгән-дәй була.

Куш каенда өздерепләр
Әй сайрады кошкаем.
Бергә чакның кадерләрен
Белмәдек шул, дускаем...

Ут сүнә. Җыр акрын гына тына.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут кабат яна. Клуб. Ә д и б ә белән З ө ф ә р.

Ә д и б ә. Мәхәббәт! Ник син гашыйк җаннарыңа һәрчак мәрхәмәтле түгел? Әле елмайтасың, әле елатасың... Минем бит гел сөенеп, куанып, гомер буе бәхетле булып яшисем килә... Сөясем һәм сөеләсем килә! Ишетәсеңме мине, мәхәббәт?!

З ө ф ә р. Мин сиңа алтын таулар вәгъдә итмимен. Уч төбемдә йөртермен дип тә әйтмимен. Күктән йолдызлар да алып биралмам. Гел-гел асыл ефәккә дә төралмам... *(Әдибә, үпкәләгән кыяфәт ясап, читкә китә башлый.)* Әдибә, мин яратам сине! *(Яшьләр бер-берсенә сыена.)*

Пауза.

Ә д и б ә. Әллә ничә кешедә булдым... Барысы да Сабантуйны урысча үткәрүгә каршы. Әгәр Дамир абый барыбер үз дигәнен итсә, калмыйм авылда. Мин дә китәм шәһәргә!

З ө ф ә р. Ә мин калам! Сине дә җибәрмим!

Ә д и б ә. Синнән сорап тордылар ди...

З ө ф ә р. Сорамасаң сорама... Барыбер җибәрмим! Аңлый-сыңмы син шуны: без дә китсәк, авыл чучка фермасына әйләнәчәк.

Ә д и б ә. Әйләнгән инде ул... Әйләндерәсе юк. Мырыйк-мырыйк килеп йөрүче исерекләр белән бөтен урам тулган. Туктале, нишләп син икенче көйгә җырлый башладың? Укырга китәм, дидең бит!

З ө ф ә р. Югары белемне аны читтән торып та алып була. Күрмисеңмени, авыл бетеп бара.

Ә д и б ә. Илең бетмәгәнгә сөен!

З ө ф ә р. Эшләр гел болай барса, ил бетәргә дә күп калмаячак.

Ә д и б ә. Күтәрәмгә калган авылны да, илне дә син генә күтәрә алмассың... Беләкләреңнең көче җитмәс!

З ө ф ә р. Көлмә-көлмә! Менә мин әйтте диярсең... Килер бер көн, кешеләр шәһәрдән авылга агылып кайта башлаячак әле. Шәһәрдә – эшсезлек, төтен, газ исе... Урамнарында машиналар тыгылган...

Ә д и б ә. Авылда да эш юк!

З ө ф ә р. Эш бар ул... Авыл кешесенең кадерен белүче генә юк!

Ә д и б ә. Дамир кебекләр хуҗа булганда, гади кешегә беркайчан да сан булмаячак!

З ө ф ә р. Безгә авылны саклап калырга кирәк.

Ә д и б ә *(Зөфәрнең маңгаен тотып карап)*. Чирләмисеңдер бит?! Температураң да юк шикелле...

З ө ф ә р. Нигә алай дисең?

Ә д и б ә. Мин бит шәһәргә бөтенләйгә китәм димәдем. Ә син әллә нинди сүзләр сөйли башладың...

З ө ф ә р. Беләм мин, күреп торам... Үзенә бер иярләшкән кешене шәһәр тиз генә ычкындырмый ул!

Ә д и б ә. Туйдым, мин барыбер китәм!

Д а м и р белән Н а и л керә.

Д а м и р. Кая китәсең? Сабантуйны уздырмыйча бер җиргә дә китү юк! Наил, бир әле теге кәгазьләрне. Мин монда кайбер нәрсәләр сызгалаган идем...

З ө ф ә р. Фәнни трактат түгелдер бит?!

Д а м и р. Анысы нәрсә тагы? Юк. Ул әйбер түгел. Речь бу! Килешмәгән урыннары булса төзәтерсез... Наил, әйдә, син укып җиффәр! Мин күзлексез күрмим икән...

Н а и л. Таный торган түгел моны... Врачлар язуы кебек бит бу!

Д а м и р. Китер үземә! Күзлек булса, сиңа әйтеп тә тормыйм мин. Шуны да укый алмыйсың...

Ә д и б ә. Күзлегегез маңгаегызда бит!

Д а м и р. Чучка белән баш каткан... Ярты көн эзләдем мин бу күзлекне.

З ө ф ә р. Берәү астындагысын алты ай эзләгән, ди...

Д а м и р. Бака боты кыстыруны бетердек! Тыңлагыз! Речь! Дорагие друзья! Дорагой Әхтәм Галиеч! И гылубакоаживаемый... гылубакообижаемый... тфү, чёрт!.. Бу сүзне әйтмим генә микән әллә? Юк, әйтергә кирәк! Яңадан башлыйм. Дорагой Әхтәм Галиеч! Гылубокаобожаемый... Вот заразы! Көлмәгез әле! Гылу-бо-ка-у-ва-жа-емый... Во-о-от!.. Густь нашего деревни и села...

З ө ф ә р. Исеме бардыр бит ул «густь»ның?

Н а и л. Исемен глава беләдер... Тик кенә тор! Дәвам итегез, иптәш Бәдрикәев!

Ә д и б ә. Продолжайте, диген!.. Урысчага күчеп барабыз бит!

Д а м и р. Кто не пунял – абясняю: акча!.. Деньги кирәк миңа! Деньги нигә кирәк? Авыл өчен кирәк! Авылны аякка бастыру өчен кирәк! *(Зөфәргә.)* Син бирәсеңме миңа акча? Юк! *(Әдибәгә.)* Синең бармы акчаң? Юк! *(Наилгә, кулын селтәп.)* Синнән сорап та торасы юк! То-то! Ә густь кем? Он – о-о-очень крупный человек! Юк, чиновник! Москве большими деньгими работу имеет!

З ө ф ә р. Дела имеет, диегез...

Д а м и р. Дела ни, работа ни – барыбер эш инде... Панятно?!

Н а и л. Панятно, иптәш Бәдрикәев...

Д а м и р. Киттек дәлше... Ближные родыс... твенники, односельчане и другие наши густи!

А р с л а н керә.

Н а и л. Миндә бер сорау бар, иптәш Бәдрикәев...

Д а м и р. Әгәр если твой вопрос к моему этому работу касается, тогда мужешь твою вопрусы задавать мне. Давай, задавай!

Н а и л. Һавадагы торнага өметләнмәскәдер, бәлки, иптәш Бәдрикәев?! Бирәме әле ул акча, юкмы – белгән юк. Бер урыс өчен урысча Сабантуй үткәреп чиләнгәнче дип әйтүем...

Д а м и р. Попытка – не пытка... Син дә кирегә сукалап тормале!

Н а и л. Бетте-бетте, иптәш Бәдрикәев... Бөтен авыл каршы булганга гына әйттем!

Ә д и б ә. Миндә дә бер сорау бар! Сабантуй әләмен кем күтәрә инде? Быелгы язгы чәчүдә җиңеп чыккан Әхсән абыймы?

Д а м и р. Кәнишне! Ул бит кыр батыры!

Ә д и б ә *(ирония белән)*. Әхсән абый татар бит... Берәр урыс кешесе күтәрсә, әйбәтрәк булмас микән, дим... Тик аны каян аласың? Бездә сыңар урыс та юк!

Д а м и р. Во-во! Аңлый башладың, Әдибә! Яшь кенә булсаң да, башың бар!Сручны урыс табарга кирәк!

А р с л а н *(кинәт сүзгә кушылып)*. Мин генә ярамыйммы? Чүтеки шәһәрдән кайткан кеше. Шаяртам, әлбәттә! Бөтен авыл шау-гөр килә: урыс килә икән, диләр... Сабантуй урысча булачак икән, диләр... Ташлагыз, егетләр, юк эш белән маташмагыз!

Д а м и р. Абзый кеше, син тик кенә тор, яме! Кем монда кандидат сельских наук – синме, минме? Өйрәтергә барыгыз да булдырасыз... Эш акчага килеп терәлсә, кыяклый башлыйсыз... Бармы синдә акча? Булса бир! Үземә дип сорамыйм...

А р с л а н. Мин бит банкир түгел.

Д а м и р. То-то!

Н у р з и ф а керә.

Д а м и р. Нурзифа апа! Үзең күренүең яхшы булды- әле. Сине бик шәп җырлый дип әйтәләр. Сабантуйда урысларның «Ой, мороз, мороз»ын җырларсың! Фураж бирермен!

Н у р з и ф а. Кирәкми миңа бернинди фураж да! Урысча җырлый белмим мин...

Н а и л *(җырлый)*. Ой, мороз, мороз,
Не морозь меня,
Не морозь меня,
Моего коня...

Д а м и р. Вәт-вәт, шушы җырны өйрәтерсең, Наил...

Ә д и б ә. Минем әбием урысча җырламаячак!

А р с л а н. Нурзифа, җырлыйсың килмәсә, җырлама! Үзебезчә генә җырларсың...

Д а м и р. Абзый кеше, чыгырымнан чыгарма! Үзеңә урысча биергә туры килмәгәе!

Н а и л. Менә болайрак итеп...

Биергә тотына, аңа Дамир да кушыла.

Д а м и р. Маладсы без!

Мыш-мыш килеп, А з а л и я керә.

А з а л и я. Уф! Тамагым кипте. Су юкмы? Сез әллә бернәрсә дә белмисез инде?

З ө ф ә р. Сулуы капкан... Явно ат чабышына әзерләнә бу!

А р с л а н. Юк шул... Бернәрсә дә белмибез.

Н у р з и ф а. Бер-бер хәл булмагандыр бит?

Н а и л. Шашлыкка дигән чучка үлгән мәллә?

Ә д и б ә. Әйт инде тизрәк!

Д а м и р. Туктагыз әле! Азалия, кунак килеп җиттеме әллә? Кайда ул?

А з а л и я. Тәки су бирмәдегез! Анда... анда... Кәбир абыйлар зиратның иске коймаларын куптарып яталар. Фәйзулла абзый, тагын Биктимер абзый да шунда.

Д а м и р. Кем кушкан аларга?

А з а л и я. Бу гына да түгел... Негр Карәхмәтләр, Шәүкиләр, Бүре Ниязлар, тагын әллә кемнәр Атнаш чишмәсен рәтләп яталар.

Д а м и р. Кем кушкан аларга, дим?

А з а л и я. Бу гына да түгел... Җимерек күперне сүтеп ташлаганнар...

Д а м и р. Што за чуртавщина?

А з а л и я. Бу гына да түгел... Мәчет... Мәчетне...

Н у р з и ф а. Әллә сүткәннәрме, Ходаем?

А з а л и я. Юк... Сүтмәгәннәр... Исәплиләр. Нинди материаллар кирәк булыр микән, диләр... Фәлән-фәсмәтән, диләр...

Н у р з и ф а. Бирсен Ходай!

Н а и л. «Диләр-диләр...» Ачык итеп сөйлә! Кемнәр шулай ди?

А з а л и я. Кемнәр булсын инде?! Кадермәт абзыйлар! Авыл картлары!

Д а м и р. Нинди башбаштаклык бу? Кем эше? Нишләп мин бернәрсә дә белмим! *(Кесә телефоны шылтырый.)* Алло! Тыңлыйм, Әхтәм Галиеч! Юк әле, күренми һаман. Көтәбез. Нәрсә? Нәрсә дисез? Ничек монда? Юк монда бернинди дә урыс. Мәскәүдән кабат шылтыраттылар?! Хет президент үзе шылтыратсын... Юк бит ул монда, юк! Исем-фамилиясе ничек соң аның хет? Әһә, Толстой... Әһә, пунял. Есть. Доложу. Нимедленны. Өзелде... Толстой... Толстой... Наил! Оныттырма Толстойны! Ничек була инде бу? Әхтәм Галиеч кычкыра: кунак сездә, ди! Бездә юк! Килсә күрер идек. Кунак кына булмады бу... Әллә килеп, бөтен эш белән шул командавайт итеп ятамы?

З ө ф ә р. Мечтать не вредно...

Н а и л. Белмәссең тагы!..

Д а м и р. Наил, кем дидем бая гына?

Н а и л. Толстой, дидегез, иптәш Бәдрикәев.

Д а м и р. Әйе бит әле... «Война и мир»! Исеме Лев теге түрәнең...

Ә д и б ә. Лев Николаевич, димәк!

Д а м и р. Алай түгел... Лев... Васильевич... Туполев... Точно! Лев Васильевич Туполев!

А р с л а н. Мин китим, булмаса...

Н у р з и ф а. Бергә китәбез, Арслан...

З ө ф ә р. Туктагыз әле! Эврика! Мин белдем!

Ә д и б ә. Кычкырмале ул хәтле, Архимед! Нәрсә бел-дең?

З ө ф ә р. Урысның кем икәнен!

Д а м и р. Кем ул? Кайда ул?

З ө ф ә р. Ул монда, безнең каршыда!

А з а л и я. Мин бер урыс та күрмим.

Д а м и р. Кайчан акыл керер микән сиңа? Дуракавәләйт итүдән башка эш белмисең!

З ө ф ә р. Безнең арада кунак бер генә...

Н у р з и ф а. Кунак дип Арслан абыеңны әйтәсеңдер инде?!

Ә д и б ә. Стоп! Миңа да барып җитте!

Н а и л. Безгә дә барып җитсен... Әйтегез тизрәк!

Ә д и б ә. «Лев»ның татарчасы ничек була?

А з а л и я. Шуны да белмәскә! Арыслан була!

Д а м и р. Нәрсә-ә-ә?

Н у р з и ф а. Булмаганны!

З ө ф ә р. Лев – Арслан... Васильевич – Василович...

Ә д и б ә. Туполев – Тәхәүетдинов...

А з а л и я. Тополь... Тупыл... Аңладым! Васил абыйлар бакчасында тупыл бар!

Д а м и р. Син?! Не может быть!

А р с л а н. Может икән шул.

Д а м и р. Паспортың-фәләнең бармы? Булса күрсәт давай!

А р с л а н. Костюмны кимәгән идем... *(Күлмәк кесәсеннән кызыл тышлы кенәгә чыгара.)* Менә бу удостоверение генә ярамыймы?

Д а м и р *(кенәгәне алып карап)*. Кәртечкәдәге кешедә синең чалымнар бар... *(Укый.)* Лев... Васильевич... Туполев... советник президента России... Ё-моё!

З ө ф ә р. Как говорится, знай наших!

Н а и л. Әле ярый өен сүтмәгәнбез!

А з а л и я. Дамир Җәмилевич ничек үзен сугып екмады диген! Баягынак бик ярсыган иде бит!

Н у р з и ф а. Син ата-анаң кушкан исемнән ваз кичкән кешемени әле... Лев Васильевич?

Ә д и б ә. Әбием! *(Әбисен кочаклап ала.)*

А р с л а н. Нурзифа! Зинһар, мине дөрес аңла...

З ө ф ә р. Монда аңлыйсы-нитәсе юк инде, кем әле, дядя Ваня... Ту есть дядя Лёва... Урыс арасында – урыс, татар янында – татар! Ике дөнья – бер морҗа! Миру – мир!

А з а л и я. Бәйләнмәгез әле Лев Николаевичка! Име, Дамир Җәмилевич?!

Д а м и р. Кит әле моннан!

А р с л а н. Нурзифа! Егетләр! Кызлар!

Д а м и р. Акыл саткан була... Сабантуйны урысча үткәрмәгез, имеш! Кем әйтә диген!

Н а и л. Чү-чү, иптәш Бәдрикәев! Артык кызып, эшне бозмыйсызмы? Акча... Акча...

Д а м и р. Бүлдермә! Үзем беләм мин! Кирәк түгел миңа аның акчасы!

А з а л и я. Ярап торыр иде әле.

Д а м и р. Кем соң син? Исем алыштырып, гомер буе урыска тәлинкә тоткан кеше! Җыртып ташлагыз бу лозунгларны! Күземә күрсәтмәгез бүтән!

А р с л а н. Мин беркемгә дә тәлинкә тотмадым. Исем-фамилиягә килгәндә... Заманасы шундый иде.

З ө ф ә р. «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...» Равил Фәйзуллин!

А р с л а н. Идеология, тәрбия бүтән иде. Үсәм дигән кешегә шунсыз мөмкин булмады...

Д а м и р. Үскән, имеш, берәү, зур кеше булган! Идеология, имеш! Тәрбия, панимаешь!

З ө ф ә р. Менә сезнең кебекләр татар халкына, безнең шикелле «икенче сорт» булган башка милләтләргә этлек эшләп яткан да инде! Сез ул милли мәктәпләрне бетерүчеләр! Миллионлаган маңкорт хәзер сезнең эшне бүген дәвам итә. Татар мәктәпләре һаман тернәкләнә алмый, китапханәләр ябыла. Татарча китап кибетләрен подвалга куып төшердегез.

Ә д и б ә. Авылда яшәсәк тә, без бит күреп торабыз! Барысын да ишетеп торабыз!

З ө ф ә р. «Милләт! Халык!» дип җан атып иҗат иткән татар язучылары, театр артистлары, авыл бүген мескен хәлдә яши!

А р с л а н. Монда минем гаебем юк.

Н у р з и ф а. Их, Арслан, Арслан...

Д а м и р. Арслан түгел ул, куян! Гаебем юк, имеш!

А р с л а н. Син дә бит менә бер урыс түрәсе өчен урысча Сабантуй үткәрәм дип очынып йөрдең... Димәк, синең дә миннән әллә ни артык җирең юк.

Д а м и р. Да! Миңа да синдәйләрнең чире йогып өлгерде! Ләкин мин үзем өчен дип тырышмыйм. Халык өчен дип, авыл өчен дип азапланам.

А р с л а н. Халык өчен, халык өчен... Ахыр чиктә барыбыз да халык өчен эшлибез!

Д а м и р. «Без» дип сөйләшмә. Үзең турында гына әйт! Нинди яхшылык эшләдең син татар халкы өчен? Хет бер татарга гына булса да ярдәм иттеңме?

А р с л а н. Иткәнмендер инде... Язып бармадым.

Д а м и р. Язып бармаган берәү... Язып, һәр булышкан кешеңнән кул куйдыртып барырга иде!

Н а и л. Кирәк бит, ә! Васил абый белән Рәйсә апа үзләре нинди әйбәт кешеләр иде...

А з а л и я. Сыердан ала да, кола да туа, диләр...

Н у р з и ф а. И Арслан, Арслан... Җәбрәй кызына өйләндем, дигәч, шикләнеп куйган идем аны...

Д а м и р. Еврей кызы?! Ё-моё!

Н а и л. Ё-моё!

Ә д и б ә. Шамакайланма!

А р с л а н. Нурзифа...

Д а м и р. Хатыны башка милләттән... Балалары бардыр әле?

Н у р з и ф а. Икәү, ди... Монда аларның гаебе юк...

Д а м и р. Мин аларны гаепләргә җыенмыйм да! Димәк, балалары да бүтән милләт кешесе. Үзе – ясны инде – урыс!

А р с л а н. Татар мин, татар!

Д а м и р. Лев Васильевич, әйдә болай килешик. Без сине күрмәдек, син безне белмисең. Авыл халкыннан ләгънәт ишетәсең килмәсә, тизрәк кире кит син лутчы!

А р с л а н. Мин китәргә дип кайтмадым. Мин бөтенләйгә кайттым!

Н у р з и ф а. Өлкән кешегә алай каты бәрелмә...

Д а м и р. Бу әле каты бәрелү түгел... Мин әйтсәм, тагы да берәгәйле әйтә алам...

Н у р з и ф а. Аңлады инде ул, аңлады...

Д а м и р. Нурзифа апа, мин беләм: элек сезнең арагызда мәхәббәт булган... Якламагыз аны!

А р с л а н. Нурзифа, кирәкми. Мин үземне үзем яклый алам. Синең алда гаебем зур. Ләкин нишлим? Мин сиңа аңлатырга тырыштым... Әйе, шулай килеп чыкты... Чит милләт кызына өйләндем. Алны-артны уйлап тормыйча, шулай кирәк дигәч, ата-анам кушкан исемемне алыштырдым. Әмма мин денемне, динемне алыштырмадым!

Д а м и р. Кем белгән сине... Бәлки, гомер буе муеныңа тәре тагып йөргәнсеңдер?!

А р с л а н. Әй, син! *(Дамирның якасыннан эләктереп ала.)* Сүзеңне үлчәп сөйлә!

Н у р з и ф а. Арслан! Кызмале син!

А з а л и я. Дамир Җәмилевич, тынычланыгыз!

Н а и л. Иптәш Бәдрикәев...

А р с л а н. Кешене гаепләү җиңел... Сез мине аңларга тырышыгыз! Денемнән язган булсам, мин монда кайтмаган булыр идем.

Д а м и р. Кайтмыйча кая барасың! Гаиләңә кирәкмисең... Шулай бит?! Эшеңдә дә туйганнардыр... Исемеңне алыштырып яшәсәң дә, син

аларга барыбер чит кеше! Дөрес әйтәм бит?! Исем алыштыру – мескен кешеләр эше ул!

А р с л а н. Их, энем, энем... Һаман бер балык башын- чәйнисең... Мин бит ялгышымны соңлап булса да аңладым...

А з а л и я. Җәмәгать! Минем газиз башыма, ниһаять, барып җитте. Мин белдем барысын да кем эшләткәнен! Зират коймаларын рәтләттерүче дә, чишмәне яңарттыручы да, күперне төзәттерүче дә, мәчетне яңадан төзетә башларга җыенучы да менә ул – Арслан абый икән бит!

Н у р з и ф а. Чынлап та, синең эшме, Арслан?

Д а м и р. Ул булмыйча, кем булсын тагы! Гаебен ничектер юарга кирәк бит инде аңа...

А р с л а н. Зинһар, мине дөрес аңлагыз! Сезнең алда яхшатлануым түгел, бар кылган гамәлем – җаным кушканнан. Мин күп илләрдә, күп җирләрдә булдым. Бездәгедәй гүзәл табигать бер җирдә юк! Бу матурлыкны безгә һич тә югалтырга ярамый. Югалтуы җиңел, табуы авыр. Туган туфракның, туган нигезнең нәрсә икәнен мин шушы яшемә җиткәч кенә аңладым. *(Нурзифа янына килә.)* Нурзифа, мине бары син генә аңлый аласың... Син генә! *(Башын ия.)*

Н у р з и ф а. Мин аңларга тырышам, Арслан...

А р с л а н. Үзеңнең кем икәнеңне беләсең килсә, артыңа әйләнеп кара икән!

Н у р з и ф а. Кешене гомере буе Ышаныч, Өмет һәм Сөю озата бара икән... Шулардан мәхрүм итмә берүк, Ходаем!

А р с л а н. Сынады язмыш – каты сылады! Тормыш дәрьясына чумдырып айкады да чайкады... Айкады да чайкады...

Н у р з и ф а. Әдибә кызым! Зөфәр улым! Безнең язмышны...

А р с л а н. Безнең ялгышны...

Н у р з и ф а. Кабатлый күрмәгез!

А р с л а н. Бөтен ышаныч, бөтен өмет сездә, яшьләр! Берүк иманыгыздан тайпылмагыз!

Д а м и р. Иманың камил булмаса, Ослан тавын алтын итеп сәдака бирсәң дә файдасыз...

Еракта азан тавышы ишетелә. Ут яктысында А к б а б а й күренә.

К а р т. Менә, ниһаять, син кайттың, олан... Асылыңа кайттың, иманыңа кайттың!

Тәэссоратлы музыка.

П ә р д ә.

## КОРЫ КУЫК

*Моңсу комедия*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Ф а р и с.
Н у р м ө х ә м м ә т (Н у р м ы й).
С ә й д ә (С ә й д ә т т ә й).
М и р з ә к и (М и р з ә к ә й).
Ч е г ә н х а т ы н ы.
С ө м б е л.

## **Б Е Р Е Н Ч Е К Ө Н**

Җәйге иртә. Авыл өе ишегалды. Сул якта өйнең болдырлы өлеше күренә. Түрдә, уң як тарафта, лапас шәйләнә. Печән өсте вакыты икәнлеген искәртеп, ярым җимерек коймаларга тырма-сәнәк ише әйберләр сөялгән, сул яктагы коймага терәлеп диярлек «уфалла» арбасы тора – өстенә печән салынган. Арбадан читтәрәк иске кое. Иске икәнлеге шуннан күренә: кое бурасы янтайган, сиртмәсенең чылбыры бар – асылынып тора, чиләге юк.
Алгы яктагы җилкапканы шыгырдатып ачып, берәү керә. Бу берәү башына чит илнеке икәнлеге кычкырып торган, әмма шактый ук тузган кепка сыман әйбер кигән, какча йөзен сакал баса төшкән Ф а р и с. Ул, ишегалдына кергәч, бераз каранып тора. Шуннан соң, угры сыман сак кына атлап, болдырга таба атлый. Шулай ук ишекне сак кына тартып карый. Күрәсең, ишек бикле – ачылмый.

Ф а р и с *(бик кычкырмыйча гына)*. Инәй! *(Тавышын көчәйтә төшеп дәшә.)* Инәкәй, дим! *(Ишекне тарткалап.)* Әткәй! Әткәй, дим! Вәт саңгыраулар!

Шулвакыт ул ишектәге йозакны күреп ала.

Тфү, заразы! Кеше сыман сагынып кайтасың... *(Йозакны әйләндереп карый-карый.)* Ә алар сыра кружкасы чаклы йозак асып куйганнар.

Ул болдыр баскычыннан төшә дә баскыч астына иелеп карый.

Инәкәй, дим! Әткәй! *(Билен турайтып баса.)* Тәмам баш катты. Баскыч астында нишләп ятсыннар инде алар.

Өйгә ялганып киткән коймадан үрелеп карый-карый,
лапаска таба атлый.

Күрешмәгәнгә ничә ел... Сагынып кайтасың... *(Лапас ишеген ачып, эчкә карап кычкыра.)* Инәй, дим! Инәкәй!

Лапас ишеген ачу белән кире яба да «уфалла» арбасы янына килә, печән астына кулын тыгып аны өскәрәк күтәрә.

Әткәй, дим! Вәт карт шайтаннар, ә... Гырылдап кына йок-лап ятасы урында... Монда кешенең башы чатный... Җир шикелле ярылырга тора... Ә алар? Кайдадыр биләмдә йөри... Сагынып кайткан буласың тагы!

Кое янына килеп, аны бер әйләнеп чыга. Капкага арты белән торган килеш, коега иелеп карый.

Коеларының суы да юк бит. Нишләп кенә яталардыр...

Шулвакыт ачык капкадан таушалып беткән күн букчасын аскан Мирзәки килеп керә дә җәһәт кенә, аксый-аксый атлап, Фарис аркасына мылтык сыман итеп таягын китереп тери.

Мирзәки. Руки верх! Атам!

Фарис кулларын күтәрә.

Кту такуй? Эстриләйт буду!

Фарис. Әткәй, бу мин!

Мирзәки. Нәмәдәй әткәй булыйм мин сиңа! *(Арткарак чигенә.)* Анука, назад борылганский!

Фарис кулларын күтәргән килеш борыла.

Фарис. Бәй, Мирзәкәй абзый! Синмени әле бу? Мин сине әткәй дип торам бит. *(Кулларын төшермәкче була.)*

Мирзәки. Стуй! Руки верх! Мин сине ызнайт низнай!

Фарис *(авызын ерып)*. Нәрсә, Мирзәкәй абзый, бу корыган таягың мылтык шикелле ата мәллә хәзер? *(Кулларын янә төшермәкче була.)*

Мирзәки. Стуй! Идрит-кудрит! Минем исемне каян беләсең әле син? *(Артка таба бераз чигенә.)* Әһә, шпиун син, алайса! Анука, кәнсәгә!

Фарис. Нинди шпион? Нинди кәнсә? Син нәрсә, Мирзәкәй абый, танымыйсың мәллә мине?

Мирзәки. Ызнайт низнай! Пашшул артың белән пирут! *(Таягын Фариска төбәгән килеш уңга-сулга йөртә.)*

Фарис күз кырые белән генә җирдә яткан таякны күреп ала һәм кинәт, җәһәт кенә иелеп, шуны эләктерә.

Фарис. Кылычлашабызмы әллә, Мирзәкәй абый?!

Мирзәки. Но-но-но! Брусай таягыңны, шпиун сыңары!

Фарис. Син ташласаң, ташлыйм, Мирзәкәй абый.

Мирзәки. Ах, идрит-кудрит!

Икәүләшеп кылычлаша башлыйлар. Әле берсе артка чигенә, әле икенчесе.

Ф а р и с. Мирзәкәй абый, нүжәли танымыйсың инде мине?

М и р з ә к и. Танымаем. Танырга да теләмәем. Брусай таягыңны!

Ф а р и с. Бу бит мин! Мин – Нурмөхәммәт малае! Фарис мин!

М и р з ә к и. Нәмәдәй Нурмөхәммәт ул тагы? Ызнайт низнайт!

Ф а р и с. Ну... Нурмый малае инде.

М и р з ә к и. Җукны сүләмә, шпиун тәре! Бәләкәй абдый малаеның Каданга китеп җугалганына бишбылтыр.

Ф а р и с. Ничек югалсын инде. Менә бит ул мин!

М и р з ә к и. Син? Синме Харис?

Ф а р и с. Харис түгел инде – Фарис! Нүжәли танымый-сың? Ышанмасаң, менә бу кулны күрсәтәм. Мин бәләкәй чакта син аңа утлы тәмәке баскан иең... Атнаш чокырына качып тәмәке пыскытып ятканда эләктерден дә...

М и р з ә к и. Анука, күрсәт! *(Фарисны таягы белән болдыр баскычына китереп тери.)* Ату ышанмаем.

Фарис Мирзәкигә кулын күрсәтә. Мирзәки таягын төшерә.

М и р з ә к и. Бәй, апай, чыннан да син бәләкәй абдый малае Харис бугай шул.

Ф а р и с. Бугай гына түгел, нәкъ үзе! Нурмый малае Фарис.

М и р з ә к и. Табылдың алайса? Бишбылтырдан соң.

Ф а р и с. И-и, Мирзәкәй абый, артист кешенең туган авылына кайтырга вакыты буламыни инде аның.

М и р з ә к и. Бәй, апай, син әртисмени?

Ф а р и с. Шулайрак иде, ачуланмасаң.

М и р з ә к и. Берләр генә дә синең турыда ишеткән җук бит, апай. Тиливидырдан да күрсәткәннәре булмады...

Ф а р и с. Мин бит, Мирзәкәй абый, особый артист.

М и р з ә к и. Нәмә төсле була инде ул, җәгени мәсәлән, асабуй дигәнең?

Ф а р и с. Юк-бар гына артист түгел, диюем. Әле менә гастрольдән кайтып килешли, юл оңгае булгач, әтәйләрне күреп чыгаем дигән идем.

М и р з ә к и *(болдыр баскычына утырып)*. Әртис дисең инде алайса, кем, Харис апай...

Ф а р и с. Фарис мин, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Әйе бит әле, Фарис бит әле син, апай. Нәмә соң... Очрашу уңаеннан берәр нәмәң җуктыр бит?

Ф а р и с. Короче, да... Ни бит... Чемоданда калды. Чемодан – машинада, машина – Казанда. Казан...

М и р з ә к и *(букчасы белән булашып)*. Апай, стаканың бармы?

Ф а р и с. Стакан да бар иде. Ул да чемоданда калды. Чемодан – машинада, машина...

М и р з ә к и. Җарар, апай... Синдә булмаса, миндә бар... *(Букчасыннан бер шешә аракы белән стакан чыгарып бас-кычка куя.)*

Фариска дәрт керә. Ул кулларын кушырып ала. Тирә-юньгә күз йөртеп чыга да баскычка утыра.

Ф а р и с. Ну, Мирзәкәй абый, үзеңә кушаматны белеп кушканнар да инде.

М и р з ә к и *(стаканга шешәдән аракы агыза-агыза)*. Сталавайны әйтәсеңме?

Ф а р и с. Әйе, сталавай. Сталавай Мирзәкәй.

М и р з ә к и. Кушалар инде, апай. Авылда кушаматсыз кеше булмай инде ул. Менә дөңкеп җиффәр әле! Күрсәт бед авыл мокытларына үдеңнең җегет икәнлегеңне...

Ф а р и с. Вообще-то, Мирзәкәй абый, мин аракы эчмим. Вообще минем эчкән юк. Вообще мин тартмыйм да...

М и р з ә к и. Син моны, агай, Каданыңа кайткач, берәр баганага сөләрсең, җәме. Ә монда кәнфитләнеп утырма. Манчы әйдә! Өлкән абдыеңны көттермә. Аның да менә бу шешә төбе дурлыгында гына булса да, авыды бар. Мә, артыннан кабарга яшел суган белән эпи бирәм...

Ф а р и с *(әле стаканга, әле Мирзәкигә карап)*. Вообще-то, мин эчмим... Вообще-то, өлкән кеше бик кыстагач... *(Калтыранган куллары белән стаканга үрелә.)* Вообще-то, очрашу хөрмәтенә дисәк кенә инде...

М и р з ә к и. Әйдә, җәтрәк кылан инде, апай... Минем ашаганым аркылы килә бит хәдер... Җилпе!

Ф а р и с *(стаканны, дерелдәтә-дерелдәтә, иреннәренә якын китереп)*. Вообще-то... *(Әкрен генә эчә башлый.)*

М и р з ә к и. Вобщетылап утырасың... Авыдыңнан Фа-тихларның абчаркасын үтерерлек махмыр исе килә... Эчмәем, имеш... Мин дә эчмәем аны... Вәләкин эчмәй торганым да җук.

Фарис стаканга салынган аракыны көч-хәл белән эчеп бетерә. Бер кулына буш стакан тоткан килеш, икенчесе белән авызына җил өрдерә. Бермәл сүз дәшми тора.

Ф а р и с *(стаканын куеп, суган кыягына үрелеп)*. Ян-дыра-а-а... Вообще-то...

М и р з ә к и. Катымы? Туты! Миндәлә кәрәчине диләр аны. Нитуште Кадански. Кияү Каданнан апкайткан иде берчак. Ни су түгел, ни аракы. Бүтән җөк итеп апкайтып җөрмә, дидем кияүгә. Хәдер апкайтмай. Миндәләдән генә апкитә. Шәп, ди. Шәп булмайча... *(Стаканга янә аракы агыза.)* Мин дә тәвәккәлләп караем әле.

Ф а р и с *(баш бармагын тырпайтып)*. Класс! Мондыйны күптән эчкән юк иде...

М и р з ә к и *(киная белән)*. Вобшыты, минем эчкән җу-гуе... Кичәдән бирле... Вобшыты, син карап тормале, апай, җәме. Җенем сөймәй,

эчкәндә кеше карап торганны. Ул да ач күдләре белән минекен эчәдер күек... *(Эчә.)*

Ф а р и с *(Мирзәкигә яшел кыяк сузып)*. Ничек соң авылда тормыш итүләре, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и *(Фарис биргән кыякны тәмләп чәйни-чәйни)*. Иртән торабыд, кич җоклайбыд, апай. Катынны күрергә дә вакыт калмай. Вобшыты, менә шушы булса *(шешәгә күрсәтеп)*, тормыш гөрләп бара. Трактор күек. Син, апай, беднең тормыш турында бәләкәй абдыйдан сораштырырсың инде. Лутчы син үдең турында сүлә. Кайларда җугалып җөрдең? Берәр институт бетерәлдеңме?

Ф а р и с. Берне түгел, өчне бетердем, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Кит аннан! Булмаганны сүлисеңдер.

Ф а р и с. Чын инде менә, Мирзәкәй абый. Артистлыкка укыдым, язучылыкка укыдым... Аннан соң теге, бар бит әле... Абыйсын үтергәннәр... Үзе ни инде... Аның турында халык җыры да бар... Карале, онытып җибәрдем... Хәзер, хәзер искә төшерәм... Әллә кем инде... Маңгай чәчен ал тасма белән үргән... Илле яшьтә дөнья бутап, кырык яшендә үлгән... Үзе пеләш инде менә...

М и р з ә к и. Ленин бабаймы әллә?

Ф а р и с. Вот-вот-вот! Шул! Мин менә шул Ленин укыган университетның общагасын бетердем.

М и р з ә к и. Алайсам, дур кеше булгансың икән инде, апай. *(Букчасыннан тәмәке белән шырпы ала.)*

Ф а р и с. Зур дип... Зур инде, әйе, Мирзәкәй абый.

Мирзәки тәмәке кабыза.

М и р з ә к и. Вобшыты, син тартмыйсың бугай, апай...

Ф а р и с *(Мирзәкинең тәмәке төтене суырганын йотлыгып күзәтеп)*. Вообще-то, тартуын тартмыйм инде мин, шул, сиңа иптәшкә дисәм генә... Вообще-то, минем тәмәке чемоданда калган. Чемодан – машинада. Машина...

М и р з ә к и *(Фариска тәмәке белән шырпы суза)*. Мә, апай, күдләреңне ач эт күек мөлдерәтеп утырма.

Фарис тәмәке кабызмакчы була. Шулвакыт ачык капкадан Ч е г ә н х а т ы н ы килеп керә. Тәмәке кабызырга өлгермәгән Фарис та, Мирзәки дә Чегән хатынына текәләләр.

Ч е г ә н х а т ы н ы. Алла сезгә исәнлек-саулык, йорты-гызга иминлек бирсен! Мал-туарларыгыз күп булсын, келәтләрегез ашлык белән тулып торсын! Исәнмесез, асыл егетләр!

Ф а р и с. Аллага шөкер!

М и р з ә к и *(төксе генә)*. Тагын синмени әле бу, алтын бытбылдык? Бу җулысы ни бурлашырга җөрисең?

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Гөнаһ сүз сөйләмә, чибәр егет. Нишләп урлашыйм мин? Ямьсез сүзләр әйтү бер дә килешми синдәй батыр егеткә.

М и р з ә к и. Нишләп җегет булаем мин, алама чүперәк баш! Бар-бар, сыптыр моннан! Мәче күек күдеңне җылтыратып торма! Бар, кеше белән сүләшергә ирек бир.

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Ай-яй-яй, бигрәк усал бүген чибәр абый. Матур җиңги үзеңә ямьсез сүз әйтмәгәндер бит?

М и р з ә к и. Синең минем катында эшең булмасын, җә-ме, ут күз. Җугал күд алдымнан!

Ф а р и с. Сайрасын инде, Мирзәкәй абый, кызык бит.

М и р з ә к и. Сиңа кыдык, миңа кыдык түгел!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Рәхмәт, чибәр егет. Кешене кешедән аера беләсең икән. Каяле, шуның өчен үзеңә бер әйбер күрсәтим әле. *(Букчасын актарырга тотына.)*

М и р з ә к и. Җүләр булып ала күрмә, апай. Былтырларны минем катын менә бу алдарбикәдән заграничный күлмәк алганые. Чуаш күлмәге булып чыкты. Катыргысын гына алыштырган булган, идрит-кудрит тәре!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Менә таптым, чибәр егет. Карале бер генә! *(Хатын-кызлар эчке күлмәген күрсәтә.)* Нәрсә дип әйтә әле татарлар? Суйган да каплаган, диме?! Менә нәкъ суйган да каплаган инде!

Ф а р и с. Миңа нәрсәгә бу үтә күренмәле чүпрәк?

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Сиңа түгел, чибәр егет. Нишләп сиңа булсын? Патша кызыдай сылу хатыныңа!

Ф а р и с. Һы... ха-ха-ха! Минем... минем хатын юк бит!

М и р з ә к и. Ала күрмә, апай. Алдырганчы тырышачак бу тәре!

Ч е г ә н  х а т ы н ы *(Мирзәки сүзләрен ишетмәмешкә салышып)*. Хатының булмаса, булыр! Бүген булмаса, иртәгә булыр! Күзләреңнән күреп торам, би-и-ик чибәр, би-и-ик сылу, алсу алма шикелле би-и-ик татлы шаһзадәгә өйләнәчәксең тиздән. Туктале, тагын бер әйбер күрсәтәм. *(Янә букчасында казынырга тотына, Мирзәки белән Фарис аның уйнаклап торган артына ис китеп карап торалар.)*

М и р з ә к и. Би-и-ик йомшак, би-и-ик дәртле... Тфү! Ала күрмә, апай. Алдана күрмә. Валлаһи дип әйтәм, үдебеднең әртилдә генә чурылган чүпрәгеңне тотып калачаксың! Мирдәкәй абый әйткән ие диярсең. Вәләкин соң булыр...

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Менә! *(Күкрәкчәгә күрсәтә.)* Французский! Берәү генә, бүтән юк. Нәкъ менә синең булачак хатыныңа үлчәп теккәннәр диярсең! Товарын кара син аның: ул төсе, ул җыйнаклыгы...

М и р з ә к и. Ыслушай, дирул бед сахара, тешкә кыдыл борычлы сагыд булып ябыштың бит, ә! Каян беләсең син апайның булачак хатынының күкрәк радмерын? Бәлки, аңа бедрадмирный кирәктер? Бәлки, аңа минем катынны күек биштәр кирәктер? Идрит-кудрит!

Ф а р и с. Шәп! Класс! *(Күкрәкчәне алып, үзенең күк-рәгенә куеп карый.)* Үтергән дә суйган, суйган да каплаган!

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Әйтәм бит, каплаган да суйган инде менә! Ал әйдә, даром-шаром отдам!

Ф а р и с *(күрсенгән булып)*. И-их... *(Мирзәкигә күз кыса.)* Алыр идем мин моны...

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Ал әйдә, ал! Икеләнеп торма!

Ф а р и с. Ни бит... акча чемоданда калган...

М и р з ә к и. Чемодан – машинада, машина – Каданда...

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Уф, сезнең белән сөйләшеп вакытны гына әрәм иттем. *(Каударланып, күкрәкчәне букчасына тыга, букчасының телтебиен тартып ябып куя.)*

М и р з ә к и. Маладис, апай, тәки җегет икәнсең!

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Булмады сез асыл егетләр белән уртак сүз табып. Каяле, киткәнче чибәр абыйны гадать итеп алыйм.

Мирзәки торып баса. Чегән хатыны аңа таба килә. Мирзәки читкә тайпылмакчы була.

М и р з ә к и. Җакын килмә, бур тәре!

Ч е г ә н   х а т ы н ы *(Мирзәкине кулыннан эләктереп, аның күзләренә карый)*. Шундый чибәр абый, шундый мөлаем абый үзе. Киемнәре бигрәк килешеп тора үзенә. *(Бер кулы белән Мирзәкинең пиджагын, чалбарын сыйпап ала.)* Синең белән яшәгән хатын би-и-ик бәхетледер инде... М-м-му-ух! Үземә шундый иркәйләр насыйп булмады...

М и р з ә к и. Кит, кит! Тимә миңа, тимә минем катынга!..

Чегән хатыны Мирзәкинең кулын җибәрә дә Фариска таба атлый.

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Бигрәк усал абый бу, әйеме, чибәр егет?

М и р з ә к и. Синдәй яшел бәрәңгеле кыстыбый янында минем катын күпереп пешкән кабартма! Белдеңме, лыгырдык тел?

Ф а р и с *(Чегән хатынына)*. Юк, юк, минем янга килеп тә торма!

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Юкка тырышасың, чибәр егет. Кайчан өйләнәсеңне, хатының кем буласын беләсең килми мәллә?

Ф а р и с. Кем булсын инде минем хатын? Минем хатын минем хатын булыр инде.

Ч е г ә н   х а т ы н ы *(Фарисның кулыннан тотмакчы була)*. Ә балаларың? Ничә балаң буласын да беләсең килмиме?

Ф а р и с. Син әйтмәсәң дә беләм. Икәү булачак минем бала. Икәү и баста!

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Ю-у-ук, синдәй баһадирның икәү генә булырга тиеш түгел. Ким дигәндә дүртәү булырга тиеш.

Ф а р и с. Калган икесен үзең табарсың, яме. Түлке миннән генә түгел. Давай, лутчы мин синең үзеңне гадать итәм. *(Чегән хатынының кулын үзе тота.)* Тә-ә-әк, юлдан килгәнсең икән. Тә-ә-әк, киткән чакта тагын

юл белән китәсең икән... Ерактан килгәнсең икән. У-у-у, монда гел аркылы торкылы юл да юл...

Чегән хатыны. Анысын мин аның син әйтмәсәң дә беләм. *(Ачу белән этә.)* Гадальщик несчастный!

Зур букчасын күтәреп, капкага таба бара.

Мирзәки. Уф! Тәки котылабыз бугай...

Чегән хатыны *(борылып, реверанс ясый)*. Пока, саран татарлар! *(Чыгып китә.)*

Мирзәки. Аңкау шартлап җарыла дип торам... Әйдә, аракы очып беткәнче, тиешле җиргә шудыра тораек.

Фарис. Вообще-то... Минем йөз граммнан артык эчкән юк югын да...

Мирзәки. Мәйлең, апай...

Фарис. Мәйлең дип... Вообще-то... Корсакка бер кер-гәч инде... Йөз грамм ни, ике йөз грамм ни...

Мирзәки. Алайсам, вобшылап утырма, апай... Җа-ратмаем «жук-жук» дип җәелеп җаткан катыннар күек кыланган кешене. Гөпелдәт әйдә!

Фарис стакандагы хәмерне җәһәт кенә каплап куя.

Фарис. У-ух! Калай түбәдән төшкән кар шикелле чыжылдаплар шуды...

Фарис бер кулы белән эчен уа-уа, икенче кулы белән яшел кыякка үрелә. Мирзәки шешәдә калган аракыны стаканга агызып бетерә.

Мирзәки. Әртис, дисең инде алайсам, апай?!

Фарис. Мидәлле әртис.

Мирзәки. Мидәлле? *(Гаҗәпләнүдән күзләрен шарландырган килеш, стаканны бушата.)*

Фарис. Эһе. Мидәлле.

Мирзәки стаканны букчасына тыгып куя да бер кабымлык ипине авызына озата.

Мирзәки *(буш шешәне Фариска suza)*. Мә, апай, куй шуны берәр җиргә. Бәләкәй абдый күрсә, ачуланыр җә.

Фарис. Нигә? Үзең ал. Кибеткә тапшырырсың.

Мирзәки. Апай, беднең магадиннан әйберне алып кына була. Әгәр алырлык әйбер булса. Буш магадинда буш шешә белән нишләсен ул Мәликә. Су тутырып уйнасынмыни? Бу бит сиңа, апай, Кадан түгел. Эчкән саен буш шешә күтәреп гастранумга чабарга... Ауыл бу! Диривня! Пунялмы, апай?

Ф а р и с. Пунял, Мирзәкәй абый, пунял...

М и р з ә к и. Ту-ты!.. Ыслушай, баягынак нинди мидәл турында сүләйдериең син?

Ф а р и с *(кәчтүм якасын кайтарып)*. Менә, Мирзәкәй абый, кара, күр. Шәп артист булган өчен хөкүмәт бүләк итте.

М и р з ә к и. Хөкүмәт кешене хөрмәтли беләә инде ул, апай. Каяле, кулыма тотып караем әле мидәлеңне. Ай-яй, бик матур мидәл икән!.. *(Мидәлдәге язуны укый.)* Бәрәч, апай, «Мать-героиня» дип җазылган түгелме суң монда?

Ф а р и с. Әйе, шулай дип язылган, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Бә-әй, апа-ай, бу җалтыравык калайны бер кад оясы тутырып бала тапкан катыннарга бирәләрие түгелме суң? Әллә хәдер ир-атларга да бирәләрме? Ни пунял шту-ты.

Ф а р и с. Ни бит, Мирзәкәй абый, хөкүмәтнең миңа тиешле мидәле кайтып җитмәгән иде. Иң главный министр әйтте, иптәш Бәдримуллин, диде, пока шушы мидәлне тагып йөр инде, диде. Сиңа дигәне кайткач алыштырырбыз, диде.

М и р з ә к и. Э-э-э... Алай икән... Алай да була икән... Хөкүмәт белә инде ул, хөкүмәт белә.

Ф а р и с. Әле, «Атказанган артист» дигән мактаулы исем дә бирмәкчеләр иде дә... Мәскәү карышып маташты. Бирдермәскә итә. Миннән көнләшәләр, заразылар.

М и р з ә к и *(аның хәленә кереп)*. Мәскәү тәгәрмәчкә таяк тыкмаса, Мәскәү булмай инде ул, апаем. Син аңа карап күңелләреңне төшермә, әртислегеңне ташлама. Әртис ул беләсеңме кем? Әртис – ул әртис! Карале, апай, әртис дигәннән, син нәмә әртисе суң? Җырлай торган гына әртисме, әллә тиатр уйнай торганмы?

Ф а р и с. Мин, Мирзәкәй абый, мактанып әйтүем түгел, бөтенесен дә булдырам. Җырлыйм да мин, театрда да уйныйм. Менә син уйлыйсың инде, әйеме, сәхнәдә Рәсим Низамов җырлый, дип. Или, мәсәлән... Тагын кем бар әле шулай шәп җырлаучы?

М и р з ә к и *(бераз уйланып торганнан соң)*. Фәния Хәрфи!

Ф а р и с. Әйе, Хәния Фәрхи. Син уйлыйсың инде, алар сәхнәгә чыгып үзләре җырлый, дип. Ничего подобного, Мирзәкәй абый! Мин җырлыйм алар өчен. Алар прусты сәхнәгә чыгып басалар да, теге тавыш акырта торган грушаны тотып, авыз ачып кына торалар. Ә мин алар өчен сәхнә артыннан җырлыйм. Пунялмы инде, үзең әйтмешли?

М и р з ә к и *(ямьшәйгән кепкасы астына бармакларын тыгып, башын кашып)*. Пунялмы дип... Пунял күек сыман инде. Әй, минем баш катлаулы нәмәләрне аңлап та бетермәй ул... Миңа бит, апай, катын әйткән гади сүд дә өч көннән суң гына барып җитә.

Ф а р и с. Моннан соң, Мирзәкәй абый, сәхнәгә үзем чыкмакчы булам. Собственный гәүдәм белән. Җитте кеше өчен сәхнә артыннан җырлап ятулар.

М и р з ә к и. Нәмә, әллә сәхнә артында шулай җатып җырлайлармыни?

Ф а р и с. Юк инде, Мирзәкәй абый. Әлбәттә, басып җырлыйлар.

М и р з ә к и. Басып? Нәмәгә басып? Сине бит барыбер күрмәйләр. Утырып җырласаң да буладыр.

Ф а р и с *(кинәт)*. Мирзәкәй абый, ничә класс бетердең син?

М и р з ә к и. Дүртне. Ә нәмәгә?

Ф а р и с. Нәмәгә-нәмәгә. Күренеп тора, дип әйтүем.

М и р з ә к и. Нәмә күренеп тора?

Ф а р и с. Уф, Мирзәкәй абый, дүрт класс бетергәнлегең күренеп тора, дим.

М и р з ә к и. Э-э-э... шулай диген аны...

Ф а р и с. Хәзер мин, Мирзәкәй абый, халык җырларын эшкәртеп ятам.

М и р з ә к и. Эшкәртеп? Нәмәгә эшкәртәсең ул җырларны? Бүтән эшкәртер нәмә беткәнмени?

Ф а р и с. Синең, Мирзәкәй абый, башыңа киттеме әллә? Ни черта да аңламыйсың.

М и р з ә к и. Әйтәм бит, катын да шулай ди миңа. Пенсиягә чыккач, катынның әйткән сүдләре бер атнадан гына барып җитә башлады башка.

Ф а р и с. Ярар, син тыңла гына, Мирзәкәй абый, «нәмәле» сорауларыңны биреп минем башны катырма, яме.

М и р з ә к и. Катырма дип... катасы булгач ката инде ул баш. Шуңа да баш бит ул. Ту ката, ту авырта...

Ф а р и с. Аңламасаң аңламыйсың икән... Тыңла, халык җыры җырлыйм. Үзем эшкәрттем. «Алмагачлар» көенә.

Алмагачның ботагын ла
Төбенә хәтле утадым.
Үзем кечкенә булсам да...
Их!
Күтәрелә күңелләр...
Шәпме? Үземә ошый. Сиңа ничектер тагы.

М и р з ә к и. Бед бәләкәй чакта бу җырны бүтәнчәрәк җырлай торганыек. Асубенно ахыргы җулын.

Ф а р и с. Син нәрсә, Мирзәкәй абый? Син бәләкәй чакта җырлаганча сәхнәдән җырлап була димени? Шуңа күрә эшкәрттем дә инде мин аны. Көен дә бераз эшкәрттем. Хәзер һәрбер артист шулай эшкәртә.

М и р з ә к и. Эшкәрттем дә эшкәрттем, дисең... Нәмә, эшкәртмичә генә җырлай торган җыр җукмыни халыкта?

Ф а р и с. Бар, нишләп булмасын. Тыңла алайса, шундыйны җырлыйм.

Һайлим, һайлим, һайларга...

Фарис, капкадан башын тыгып карап торган С ө м б е л н е күреп, кинәт җырлаудан туктый.

М и р з ә к и. Ник туктадың, апай?

Ф а р и с *(капкага таба ишарәләп)*. Анда бер туташның гүзәл башы күренә.

Мирзәки капка тарафына борылып карый. Аның йөзе ачылып китә.

М и р з ә к и. У-у-у... Минем кыдым! Ни бар, кыдым?

Фарис әле Мирзәкигә, әле капкадан башы гына күренгән
Сөмбелгә карый.

С ө м б е л. Әткәй, әнкәй сине чакыра!

М и р з ә к и. Башта исәнләш, кыдым. Фарис абдыеңны күрмисең мәллә? Бәләкәй абдыйның җугалган малае табылып кайтты бит.

С ө м б е л. Мин исерекләр белән исәнләшмим.

Ф а р и с *(башын артка чөеп көлә)*. Ха-ха-ха! Ну, каты да әйтте кызың, Мирзәкәй абый!

М и р з ә к и. Анасына охшаган. Анасы да гел шулай каты әйтә.

С ө м б е л. Әткәй, дим! Әнкәй чакыра.

М и р з ә к и. Уф, нәгаләт. Хәдер чыгам, дидем бит инде. Бар, лутчы җәһәт кенә бәләкәй абдый белән Сәйдәттәйгә барып сөенче ал. Югалган малаегыз табылып кайтты, диген. Алар монда, су буенда гына печән киптереп җаталардыр. Тид бул!

С ө м б е л. Әнкәйдән мине сүктерәсең килмәсә, мин кайтканчы өйдә бул! Ишеттеңме, әткәй?

М и р з ә к и. Ишеттем, кыдым, мең кат ишеттем. Бар инде, бар... Фарис абыең өйгә кералмаенча утыра бит әнә. Җулдан кайткан кеше. Чәй эчәсе киләдер...

С ө м б е л. Җарар. Барып әйтәм. Тик син кара аны, җәме!.. Тагын эчә күрмә.

М и р з ә к и. Юк инде, юк инде, кыдым. Эчмәем. Бар.

Сөмбел китә.

Ф а р и с. Синең кызмыни инде бу, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и. Төпчек кыд. Сөмбел. Минеке инде, минеке. Карактеры нәкъ анасы инде. Өдмәй дә, куймай да. Матурлыгы гына минеке.

Ф а р и с. Матур шул. Кыяфәт нәкъ синеке шул, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и *(горурланып)*. Ә кәкже. Планнаштырганда ук уйланылганые шулай буласы. Дөрес, планнаштыруын малай дип планнаштырганыек та... Нәмәшләтәсең ки, кыд булып чыкты. Ничава, кыд да артмый беддән – каткан теддән. Главный сау-сәламәт булсын. Саулык ул, апай, дур байлык!

Ф а р и с. Дөрес әйтәсең, Мирзәкәй абый. Саулык – и бәхет, и байлык ул. Менә минем бөтен нәрсәм бар. Тфү-тфү, күз тимәсен, саулык бар, байлык та бар. Менә бәхет юк инде.

М и р з ә к и. Нәмәшләп, апай?

Ф а р и с. Хатын юк чөнки.

М и р з ә к и. Нәмәшләп, әле син шушы җәшкә җитеп һаман өйләнмәдеңмени?

Ф а р и с. Соң, Мирзәкәй абый, артист кешенең вакыты буламыни инде аның. Һаман юлда. Һаман гастроль дә гастроль. Ту Мамадыш, ту Париж, ту Воркута, ту Кытай... Алты бүлмәле квартирга кайтып бер генә сәгать булса да йокларга вакыт юк. Күптән түгел генә «Волга»ны «Мерседес»ка алыштырдым. Утырып йөрергә вакыт юк. Инде менә җай чыккач, «Мерседес» белән генә кайтырмын диган идем авылга – булмады, шайтан алгыры.

М и р з ә к и. Урлатмагансыңдыр бит, апай. Андый яхшы машинага карак крисләр бик кыдыга, ди бит.

Ф а р и с. Урлатуын урлатмадым, Мирзәкәй абый. Зур урында эшли торган бер дус малай бар минем. Үзенеке ватылгач, минем «Мерседес»ны сорап торган иде. Ниндидер туганының туена кайтырга дипме шунда. Әй, анысы не важно. Менә шул дус, кире Казанга кайткан чакта, «Мерседес»ның карбюраторын юлда төшереп калдырган. Югыйсә бик каты боргалаштыргалаган да идем инде ул карбюраторның шөрепләрен. Дус әйтә, машина йөз метр бара да туктый, йөз метр бара да туктый, ди. Көчкә минем гаражга кайтып җиткән.

М и р з ә к и. Карбюраторсыд килешме?

Ф а р и с. Карбюратор гына булса бер хәл. Бензин кәчәт итә торган насостан шлангы ычкынып, бөтен горючий агып беткән.

М и р з ә к и. Суң, апай, карбюраторсыд, бендинсыд ничек кайта алган синең дус-иптәшең? Машина бит пычагым да атламаска тиеш.

Ф а р и с. Дөрес сөйлисең син, Мирзәкәй абый. Но бит минем «Мерседес» газ белән дә эшли. Бензин урынына менә шул газга көйләп кайткан инде минем дус. Минем инде «Мерседес»ны рәткә китереп торырга вакыт булма-ды. Җитмәсә, чемоданны шунда онытып калдырганмын. Әткәй-инәкәйгә, күрше-күләнгә дип күчтәнәчтер-мазардыр тутырган булган идем.

М и р з ә к и *(кинәт колагын сагайтып)*. Ступ, апай. *(Пышылдап кына диярлек дәшә.)* Бәләкәй абдыйның аяк атлаган тавышы ишетелә. Кайталар. Миңа таярга вакыт. Ату әбиең дөнья җимертер анда. Берәр нәмә тапкач, җаңадан сугылырмын.

Икесе дә утырган урыннарыннан торып баса. Мирзәки чайкалып ала. Шулай чайкала-чайкала, капкага таба атлый. Капкадан озын буйлы Н у р м ө х ә м м ә т белән бәләкәй гәүдәле С ә й д ә керә. Нурмөхәммәт түбәтәй кигән. Берсенең кулында – сәнәк. Икенчесенекендә – агач тырма.

М и р з ә к и. Исәнме, Нурмый абдый! Саумы, Сәйдәттәй! Менә малаегыд кайткан. Шуның хәл-әхвәлен белеп чыгаем дип бер генә минутка кергәнием. Ыйк! *(Очкылык тота.)* Кемдер бик каты сүләй. Ыйк! Катындыр инде! Ыйк! *(Китә.)*

Ф а р и с *(әти-әнисенең каршына йөгереп)*. Әткәй! Инәкәй! Сагыныплар беттем үзегезне! *(Башта әтисен кочак-лый.)* Их, әткәй... Бөтенләй беткәнсең бит!

Моңарчы бөгелебрәк торган Нурмөхәммәт улының сүзеннән соң гәүдәсен турайта. Ләкин улын кочакламый. Сәйдә яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп ала.

Ф а р и с *(әтисен кочагыннан ычкындырып, әнисенә карап)*. Инәкәй! *(Әнисен кочаклый.)* Шыр сөяккә калгансың бит! Чыра тек чыра! Их!.. *(Әллә чынлап, әллә юри елый.)*

Нурмөхәммәт Сәйдә кулыннан тырманы ала.

С ә й д ә. Балам! Улыкаем! *(Фарисны аркасыннан сөя.)*

Икәүләшеп елыйлар.

Ф а р и с *(сулкылдап-сулкылдап)*. Беткәнсез бит... Минсез ничекләр яшәдегез?..

Н у р м ө х ә м м ә т *(улына карап, башын чайкап)*. Әр-тис! Үдгәрмәсә үдгәрмәй икән...

Ул кулындагы тырма-сәнәкне «уфалла» арбасы янына илтеп куя.

С ә й д ә. Кайларда җөрдең, балам?

Ф а р и с *(күз яшен кул аркасы белән сөртә-сөртә)*. И-и, инәкәй... Күрде инде башлар! Булмаган җир калмады. Казанның бөтен тыкрыгын, бөтен чокырын беләм хәзер...

Нурмөхәммәт, болар тарафына карап башын чайкый-чайкый,
болдырга таба атлый. Ишек өстеннән ачкыч алып, йозакны ача.

Н у р м ө х ә м м ә т *(өйгә кереп, ишектән улына карап)*. Әртис! *(Кереп китә.)*

С ә й д ә. Нәмәшләп берләр дә хәбәр җибәрмәдең, улым? Бед бит монда атаң белән ут җотып җатабыд...

Ф а р и с. И-и, инәкәй... Кая ул хәбәр җибәрү. Пучтыга барып конверт алып кайтырга вакыт җитми. Эш тә эш... Инде эшләмәгән эш калмады. Хәтта бер-ике ел саф һава директоры булып та эшләдем.

С ә й д ә. Шулайдыр, улым, шулайдыр. Хуҗа кешенең вакыты булмай инде аның... Соң, бер дә булмаса, пумушнигыңа әйтәсең калган. Ул җадып җибәргән булырые бер-ике кәлимә сүд...

Ф а р и с. Пумушникның, инәкәй, хат язудан башка да эше муеннан аның...

С ә й д ә. Шулайдыр, улым, шулайдыр. Эш кешесенең эше чутсыд була инде аның. Тауык чүпләп бетермәслек. Тауык дигәннән, атаңа әйтергә кирәк әле, тауык суеп бирсен...

Шулвакыт, пычак кайрый-кайрый, өйдән Н у р м ө х ә м м ә т чыга.

Ф а р и с. Сезгә күчтәнәчкә бүләкләр дә алган идем. Их, алып кайтып җиткерә алмадым. Шушы такта баш *(башына сугып ала)* аркасында инде...

Н у р м ө х ә м м ә т *(үзалдына сөйләнеп)*. Аның беркайчан да акылы булганы булмады.

Ф а р и с *(әтисенең сүзләрен ишетмәмешкә салынып)*. Чаллы автовокзалында урлаттым. Бер адәмгә, саклап тор әле дип, биш мең сум акча да биргән идем. Саклаган... Мин туалетка киткәч, чемоданнарны алган да качкан, кабахәт!

С ә й д ә. Хәерле када булсын инде, улым...

Ф а р и с. Ике зур чемодан иде.

Н у р м ө х ә м м ә т *(пычагын кайрый-кайрый, лапас тарафына атлап)*. Фтарой Муенхауҗен!

Ф а р и с *(әнисенең гәүдәсенә карап)*. Берсе-берсе синең чаклы булгандыр.

С ә й д ә. И Ходаем, мөртәт тә кеше булган икән...

Ф а р и с. Тотсам, эһ тә итмичә буып үтерә идем үзен... Менә болай итеп. *(Күзләрен акайтып, үзен үзе буып күр-сәтә.)* Э-э-э... Бәхете!

С ә й д ә. Әстәгыфирулла!..

Лапас тарафыннан тавыкларның куркынып кытаклаган
тавышлары ишетелә.

Ф а р и с. Сиңа, инәй, җиде-сигез сурттан разный яулык алган идем. Тагын күлмәктер-ыштандыр шунда... Әткәйне дә онытмаган идем. Бер тартма одноразовый носкилар, читек-кәвеш, түбәтәй, фырт яңа кәчтүм-чалбар. И такдалие... Их!..

С ә й д ә. Рәхмәт инде, улым. Үдеңнең башың сау булганга шөкрана ит. Башың исән булса, малы табылыр... Бедгә бер нәмә дә кирәкмәй. Беднең, атаң белән, бер аяк монда, икенчесе гүрдә дигәндәй...

Ф а р и с. Алай димә әле син, инәкәй. Чемоданда бит минем гомер буе җыйган акча да киткән. Бер чемоданы гел акча гына иде. Ну шатлыгыннан бер атна эчкәндер инде теге кабахәт!..

С ә й д ә. Милитсәгә дә хәбәр итмәгәнсеңдер инде, улым?

Ф а р и с. Нинди милиция? Исләре дә китми аларның минем чемоданнарга. Алар урлаган машиналарны да таба алмыйлар хәзер, минем бер дусның троллейбусы югалган иде. Менә өч ел инде очына

чыга алмыйлар. Милиция, имеш! Җүнле эш булса, мин эшләр идем анда...

Сәйдә. Шулайдыр инде, улым, шулайдыр. Үдең беләсеңдер...

Лапас ягыннан, суелган тавык тотып, Нурмөхәммәт чыга. Өйгә таба атлый.

Фарис. Хет кесәдә сезгә берерлек берәр нәрсә калмады микән? *(Кәчтүменең уң кесәсенә кулын тыга. Кесәсе төпсез икән – кулы килеп чыга.)* Монысында юк.

Нурмөхәммәт, турсаеп, аның кесә актарганын карап тора.

Фарис *(сул кесәсенә кулын тыга – монысының да төбе юк икән, кулы янә тышка килеп чыга)*. Бусында да юк. Нәрсәдер тыккан кебек идем бит! Ә-ә-ә... *(Кулын түш кесәсенә тыга һәм аннан затлы беләзек чыгара.)* Менә ул! Инәкәй, бу сиңа! *(Әнисенә суза.)* Беләзек!

Сәйдә *(кулларын күлмәк итәгенә сөртә-сөртә)*. Улыкаем, кирәкмәс ие... Акчаңны әрәм итеп... *(Беләзекне ала.)* Бигрәкләр дә матур икән... Рәхмәт яусын инде үдеңә, улым. Ходай Тәгалә үдеңне берүк саулыктан мәхрүм итмәсен.

Фарис. Кулыңа киеп куй, инәкәй. Ярарга тиеш.

Сәйдә *(беләзекне кулына кия)*. Тап-таман, улым. Бәхетең-тәүфыйгың артсын берүк. Гомерең одын булып, калган гомереңне куаныч эчендә үткәрергә ядсын, Ходаем! *(Яулык чите белән күз яшьләрен сөртә.)*

Фарис *(өйгә таба атлаган әтисенә карап)*. Әткәйгә нәрсә бирергә инде. Туктале... *(Чалбар кесәсеннән нидер тартып чыгара.)* Менә, әткәй, сиңа да. Әмирекәнский жвачка. Рәхәтләнеп бер чәйнәрсең. *(Әтисенә таба атлый да шып туктый.)* Әй, синең тешләрең юктыр инде. Үзем генә чәйнәрмен. *(Сагызны кесәсенә кире тыга.)*

Нурмөхәммәт, пычагын тоткан кулын селтәп, башын чайкый-чайкый, өйгә кереп китә.

Сәйдә. Улым, әйдә өйгә керәек. Шунда сүләшербед. Атаң тауык суйган әнә. Шулпа салып җибәрермен.

Фарис. И-и-их... сагынып кайттым да инде үзегезне, инәкәй! *(Әнисен янә кочаклап ала.)* Ун ел ничек түзгәнемне үзем генә беләм...

Өйдән Нурмөхәммәт чыга. Бер кулында – тастымал, икенчесен-дә – кырыну әсбаплары.

Нурмөхәммәт *(карчыгына ымлап, кулындагы әйберләрне суза)*. Менә кырындыр, җуындыр үден.

С ә й д ә. Улым, җуынып ал әйдә. Аннан өйгә кереп, җал итеп алырсың...

Фарис әнисен кочагыннан ычкындыра.
Сәйдә Нурмөхәммәткә таба атлый.

Ф а р и с *(ике кулын да өскә чөеп)*. Их, белсәгез иде сез минем ничек сагынганны!..

Н у р м ө х ә м м ә т *(Сәйдәгә кулындагы әйберләрне биреп)*. Малай сагынга-а-ан... *(Ике кулын Фарис шикелле суза.)*

С ә й д ә. Җарар инде, атасы...

Нурмөхәммәт янә лапас тарафына китә.

Ф а р и с. Безнең авыл ул санаторийларны бәреп ега, инәкәй. Кара инде бу һавасының сафлыгына! Сулаган саен сулыйсы килә. Үпкәләр киңәеп китте хәтта!

Сәйдә өй янындагы коймага беркетелгән юынгыч янына килеп баса. Фарис та аның янына килә.

С ә й д ә. Мә, улым, башта чыраеңдагы җеннәрне кырып ташла. Алайса, бигрәкләр дә карт итеп күрсәтә үдеңне.

Ф а р и с. Кичә генә кырынган идем инде үзе. Нишләтәсең, үлән кебек бәрә дә чыга, бәрә дә чыга...

С ә й д ә. Суы җитәрлектер әле умальникның. Иртән генә яңартып өстәгәнием. *(Улының кырынганын сокланып күзәтә.)*

Ф а р и с *(кырына-кырына)*. Коймалар да череп беткән икән. Әткәй нәрсә карыйдыр...

С ә й д ә. Атаң карт бит инде, улым... Бөтенесенә дә берүде. Бер генә дә өлгереп җиталмай.

Ф а р и с. Әткәй өлгермәсә, председатель бардыр бит колхозда. Ул ни карый? Гомер буе колхозга бил бөккән хезмәт ветераннарын карарга тиештер бит инде ул?!

С ә й д ә. Булыша инде ул, улым, булыша. Хәл кадәри ярдәм итә үде. Бик әйбәт персидәтел ул, беднең Гадинур.

Ф а р и с. Бер дә әйбәтлеген күрмим Газинурыңның. Коймалар черек. Лапас җимерелергә тора. Өйнең нигезе тәмам беткән. Капка шыгырдый. Район башлыгы булсам, мондый председательләрнең иманнарын укытып эшләтер идем мин. Бәхетләре – мин район хуҗасы түгел. *(Кырынып бетерә, пошкыра-пошкыра юына башлый.)* Менә мин саф һава директоры булып алты гына ел эшләдем. Бөтен җирдә порядок иде. Кул астындагылар дер калтырап тордылар.

Нурмөхәммәт, лапаска сөялеп, Фарисның сүзләрен тыңлап тора.

С ә й д ә. Ул кадәрле усал булырга да җарамай, улым. Кешеләрнең дә төрлесе бар. Бер-бер хәл кылып куймагайлары үдеңә.

Ф а р и с *(тастымал белән битен сөртә-сөртә)*. Кылырлар иде дә – куллары кыска. Бөтен Казан начальствосы минем таныш. Хәзер танышларсыз булмый, инәкәй. Мин сиңа – син миңа. Тормыш принцибы!

Нурмөхәммәт боларга таба килә.

Н у р м ө х ә м м ә т *(яннарыннан үтеп барышлый)*. Ко-ры куык! Кешене ышандырам дип уйлыйдыр... Ходай акыл бирмәсә бирми икән кешегә... *(Кулын селкеп өйгә кереп китә.)*

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КӨН

Беренче пәрдәдәге күренеш. Ара-тирә кош сайраганы, эт өргәне, чалгы тавышлары ишетелеп ала. Болдырга күлмәкчән генә Ф а р и с чыгып баса. Рәхәтләнеп бер киерелә.

Ф а р и с. Сәламлим сине, кояш! Син дә мине сәламлә!

Фарис, болдырдан төшеп, юынгычка таба бара. Кинәт, дуңгыз мыркылдаганга охшаш тавыш ишетеп, сагаеп туктый. Тирә-юньгә, аеруча лапаска таба карап.

Әллә инәкәйләрнең чучкалары бар инде?! Ау-у! Мырыйк-мырыйк! Сез кайда-ау?

Мыркылдаган тавыш катырак яңгырап ала. Фарисның күзе коега төшә. Коедан бер пар итек күренеп тора. Итекләр икесе тиң
селкенеп куя.

Ничь-чего себе! *(Тавыш-фәлән чыгармаска тырышып, сак кына якынлаша.)* Ничь-чего себе!

Ниһаять, ул коега күз салырга батырчылык итә –
коега иелеп карый.

Менә сиңа мә! Мирзәкәй абый, син түгелме соң бу? Нишләп ятасың безнең кое чүплегендә?

Кое эченнән Мирзәки тавышы ишетелә.

М и р з ә к и т а в ы ш ы. Кем син? Мөнкирме, әллә Нән-кирме? Кая миңа тиешле хур кыдлары? Атвичай!

Ф а р и с *(ике итекне кысып кочаклаган килеш үзенә таба тартып)*. Чык әле син башта, Мирзәкәй абый. Чык әле. Нишләп ятасың монда? Бәхетең бар икән. Ярый әле әткәйләр коены чүп белән тутырганнар.

М и р з ә к и  т а в ы ш ы. Алла, идрит-кудрит. Аякларны тартып өдәсең бит! Фәрештә дигәч тә... өстеңнән жалутса итәм хәдер...

Ф а р и с. Нинди фәрештә булыйм мин сиңа. Саташма, Мирзәкәй абый. Тапкансың дүтпочмаклы гостиница!

М и р з ә к и  т а в ы ш ы. Тартма, дим, аякларны! Атың коргыры! Кәҗүнни аяклар бар дип беләсең мәллә?

Ф а р и с *(Мирзәкинең аякларын ычкындырып)*. Алайса, үзең чык!

Кое эченнән мышкылдаган, мыгырдаган тавышлар ишетелеп тора. Менә берзаман чәчләре төрле чүп-чар белән чуалып-чорналып беткән Мирзәки башы күренә.

М и р з ә к и. Бәрәч, теге дөнья түгелмени бу? *(Фарисны күреп.)* Апай, әллә синме бу?

Ф а р и с. Мин идем шул, Мирзәкәй абый, әгәр ачуланмасаң...

М и р з ә к и *(башын ике кулы белән дә тотып карый-карый)*. Баш минекенә охшаган... Димәк, баш исән! Кипкесе кая киткән инде тагы? Син күрмәдеңме, апай?

Ф а р и с. Шундадыр инде, Мирзәкәй абый. Аяк астыңа иелеп кара.

Мирзәкәйнең башы югала.

М и р з ә к и  т а в ы ш ы *(шатлыклы)*. Таптым! Аяк белән басканмын икән!.. *(Бөгәрләнгән кепкасын баш очына элеп, Мирзәки күренә.)* Җугалтканмындыр дип котым очты. Өр-яңа кипке бит бу, апай. Дастуй чорында җүн генә бәягә алган ием. Җугалтсам, катын бетерәдерие. Туксанга да җитмәенчә кабергә тыгадырые, валлаһи! Бәхет бар икән... Кая, чыгар инде бу баддан, апай.

Фарис аңа коедан чыгарга булыша.

Ф а р и с. Нишләп төштең син бу коега, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и. Менә мин нәкъ шуны синнән сорармын дигәнием. Өйгә кайтканны хәтерлим, седнең коега ничек эләккәнне хәтерләмим. Әле җарый, бәхеттән, коеның суы булмаган. Тәки эчеп бетерергә туры килгән булырые. Рәхмәт бәләкәй абдыйга! Чүп тутырып дөрес эшләгән...

Кое бурасына сөялеп, җиргә утыра.

Ф а р и с. Кичә, алайса, каты җилпегәнсең син, Мирзәкәй абый. Безнең коега төшеп, иңен-буен үлчәрлек хәлгә килерлек булгач. Әткәй-мазар кушмагандыр бит?

М и р з ә к и. Нәрсәне, апай?

Ф а р и с *(көлеп)*. Мин әйтәм, әллә әткәй сиңа яңа кое бурасы эшләргә заказ бирдеме, дим. Синең турыда китап язарга була.

М и р з ә к и. Апай, көлмә абдаң тиешле кешедән. Алай килешмәй. Син лутчы ядучы булуың турында сүлә, апай. Ату кичә әртислегең

турында сүләдең, ядучылык турысында сүләмәдең... Үдең бит әйттең, ядучылыкка укыдым, дип әйтеп әйттең...

Ф а р и с. Аның нәрсәсен сөйлисең инде, язучы тек язучы.

М и р з ә к и. Син сүлә, сүлә... Ух, баш чатный... Синдә җуктыр бит берәр нәмә? Әй... чумаданда калды, дидең бит әле... *(Кесәләрен капшаштыра.)* Стуй! *(Авызы ерыла.)* Ходаның хикмәте, монда нидер бар. *(Пиджагының түш кесәсеннән бер шешә тартып чыгара.)* Менә! Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына. Мин бит моны утын куышына яшергәнием. Менә өйгә кайтып сорап та торасы булмады. *(Шешә бөкесен теше белән ача.)* Кара син аны, ә! Кичә дур шешәнең яртысын моңа күчергәнием, иртәгә баш төдәтергә кирәк булыр әле дип. Менә кирәге дә чыкты. *(Фариска.)* Җилписеңме? Авыдыннан гына инде, иптәш-гаспадин.

Ф а р и с *(ике кулын да алга сузып)*. Юк-юк, Мирзәкәй абый, күрәсе дә килми. Әткәйләр алдында да уңайсыз.

М и р з ә к и. Маладис, апай! Дөрес эшлисең. Миңа күб-рәк кала. *(Шешә авызыннан гына аракы чөмерә.)* Ух! Әйбәт китте. *(Кул аркасын иснә.)* Хәдер сүлә инде, апай. *(Шешәсен кесәсенә кире тыгып куя.)* Җә, беднең Роберт Миңнуллин нишләп җата анда?

Ф а р и с. Ята инде. Кайчагында йөри дә.

М и р з ә к и. Йөридер-йөридер, беднең Актаныш раюнына гел кайтып җөри ул. Җадамы суң поюмаларын?

Ф а р и с. Яза-яза, нишләп язмасын мин язып биргәч.

М и р з ә к и. Әллә Роберт Миңнуллинга да син җадып бирәсеңме, апай?

Ф а р и с. Кәнишне! Аңа да, бүтәннәргә дә.

М и р з ә к и *(чын күңелдән сокланып)*. Кит аннан, апай? Синдә дә шундый җаду-сыду осталыгы бармыни?

Ф а р и с. Кәнишне!

М и р з ә к и. Менә бит, ә! Беднең авылдан да җадучы чыгар икән. Рәхмәт, апай! Бөтен ауыл исеменнән рәхмәт сиңа, апай! Ниме суң, җадучы халкы нитәме? *(Муенына чиртеп ала.)* Беднең күек әд-мәд эчкәләйме?

Ф а р и с. Эчәләр. Барысын да мин өйрәттем.

М и р з ә к и. Эчкәч, җадып булмыйдыр бит ул, апай.

Ф а р и с. Әйттем бит инде, алар өчен үзем язып бирәм, дип. Әле менә Габдулла Тукай өчен язып ятам.

М и р з ә к и. Бәй, Габдулла Тукай күптән үлгән түгелме суң ул? Әллә монысы малаемы?

Ф а р и с. Юк. Бусы – икенче Тукай. Яшь әле ул. Син аны белмисең.

М и р з ә к и. Шулай дисәң генә, апай. Кая, тагын берад манчыйм әле. *(Кесәсеннән шешәне чыгарып авызына коя.)*

Ф а р и с. Кызың чибәр синең, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и *(шешәне кире кесәсенә тыгып)*. Хе-хе-хе... Әллә күдең төштеме минем кыдга. *(Шаяртып бармак яный.)* Кара аны, хи-хи-хи!

Ф а р и с. Юк инде, Мирзәкәй абый, син нәрсә? Мине кем дип уйлыйсың. Чибәр булганга күрә генә әйтүем.

М и р з ә к и. Кыдым чибәр анысы. Сүд дә юк. Чибә-ә-әр! Бөтен ауылга бер кыд инде, апай. Син андыйны бөтен Каданны айкап чыксаң да табалмайсың.

Ф а р и с. Дөрес сүзгә җавап юк. Казанда гына түгел, бөтен Татарстанда юк синең кыз шикелле кызлар. Мин моны дөньяны аркылы-буйлы иңләгән кеше буларак әйтәм.

М и р з ә к и. Син, апай, салпы җакка салам кыстырмайча гына сүлә. Мин кыдның нинди икәнен үдем дә беләм. Миравай кыд! Ә син, апай, ни-ни-ни! Пунял?

Ф а р и с. Пунял, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Вот так-ты!

Шулвакыт капкадан С ә й д ә килеп керә.

Ф а р и с. Инәкәй, син кайда йөрисең?

С ә й д ә. Тордыңмы, улым? Мин, улым, кадларны су буена куып кайтып киләм әле, бер оңгайдан үдебед печән чапкан җиргә дә сугылдым.

Ф а р и с. Әткәй кайда?

С ә й д ә. Атаң шунда, печән чапкан җирдә. Хәдер кайтам, калган җирне чабып бетерәм дә, диде.

Ф а р и с. Нишлисез инде сез? Үзем чабып бетергән булыр идем инде.

М и р з ә к и. Саумы, Сәйдәттәй?

С ә й д ә. Аллага шөкер, Мирдәкәй күрше, үдең ни хәл-ләрдә?

М и р з ә к и. Кесә – сайский, кәеф – байский, Сәйдәт-тәй.

С ә й д ә. Улым, хәдер самаур җаңартам. Чәй эчәрсең.

Ф а р и с. Ярар, инәкәй.

С ә й д ә. Мирдәки күрше, син дә керерсең.

М и р з ә к и. Рәхмәт, Сәйдәттәй. Мин бүген эчкәнием инде, ике җомры. *(Фариска карап күз кыса.)*

Сәйдә өйгә кереп китә, капкадан С ө м б е л керә.

С ө м б е л. Әткәй, син тагын мондамыни? *(Фариска кыюсыз гына.)* Исәнмесез, Фарис абый!

Ф а р и с. Ис... исәнме, Сөмбел!

М и р з ә к и. Мин, кыдым, чүмәләләрне саклап чыктым. Кешеләр бик җавыдланды бит хәдер. Печәнне урлаулары бар. Менә әле шуннан кайтышлый Фарис абыеңның хәлен белеп чыгаем дип кергәнием.

С ө м б е л. Әткәй, хәдер үк өйгә кайт. Әнкәй борчылып ята анда. Төне буе җокламады. Әйтеп тә китмәгәнсең...

М и р з ә к и *(кинаяләп)*. Борчыладыр инде әнкәң, би-и-ик борчыладыр... Кара кайгыларга баткандыр... Ике җатып бер төшенә дә

кермәгәнмендер әле... Ир кадерен беләмени ул анаң... *(Коега карап ала.)* Җаткан буласың анда печән саклап. Керфеккә керфек тә какмаенча.

Сөмбел. Әткәй! Инде тагын эчкәнсең бит. Бар, тидрәк өйгә кайт. Минем пучтыга барасым бар. Актаныштан гәҗит китергәннәрдер инде.

Мирзәки. Кыдым! Грам да эчмәдем. Кичәгенеке бет-мәй интектерә.

Сөмбел. Эһе! Белмәйләр ди монда синең эчкәнеңне-эчмәгәнеңне! Бар, кайт тидрәк.

Мирзәки. Фарис, апай, әйт әле шуңа, эчмәдем бит, әйеме?

Фарис. Юк-юк, Сөмбел, тамчы да эчмәде. Башка җирдә салган булса гына инде...

Мирзәки. Нәмәдәй башка җир, апай? Әдерләп куйганнар ди анда, печән чүмәләсе төбенә... Аракы түгел, су да юк анда.

Сөмбел. Син, әткәй, Фарис абыйны алдый алсаң да, мине алдый алмассың...

Мирзәки. Бигрәкләр дә каты бәгырьле инде син, кыдым. Бу хәтле анаң сыңары булырсың икән. Җарар, хәдер кайтам. Сүләшеп кенә бетерәек тә.

Сөмбел. Кара аны, бүтән эчмә! Ишеттеңме, әткәй?

Мирзәки. Ишеттем, кыдым, ишеттем. Әрекмән Гаптери күек саңгырау түгел.

Сөмбел. Ишетсәң шул, мин пучтыга киттем.

Мирзәки. Бар-бар, кыдым. Әйбәт кенә эшлә. Гәҗит-мәҗитләреңне җугалта күрмә!

Сөмбел Фариска күз сирпегәндәй карап ала да капкага юнәлә.

Фарис. Сау булып тор, Сөмбел, әлегә.

Мирзәки *(Фариска текәлеп карап)*. Әлегә-мәлегә дип торма, апай. Әйтүем шушы, ни-ни-ни! *(Бармак яный.)* Күрше бәләкәй абдыйның малае дип тормам.

Сәйдә болдыр баскычына чыгып баса.

Сәйдә. Улым, чәй эчәргә кер! Мирдәкәй абыеңа да әйт.

Фарис. Ярар, инәкәй. Хәзер керәбез.

Сәйдә кире өйгә кереп китә.

Мирзәки. Мин, апай, кереп тормам. *(Түш кесәсенә суккалый.)* Мин үдемнең чәйне эчтем инде. Рәхмәт дурлап әйтүеңә. Чыгаем мин. Ишеттең бит әнә... *(Капкага таба ишарәли.)* Түткәң анда ферма үгеде күек дулап җатадыр. Кемне сөдәргә белмәенчә... Какырас мине көтә инде ул. Әле җарай мин бар. Мин дә булмасам, кемне сөдәрие микән түткәң?

Капкадан иңсәсенә тырма салган Нурмөхәммәт керә.

М и р з ә к и *(урыныннан торып, чалбарын каккалый)*. Сау гынамы, Нурмөхәммәт абдый?

Н у р м ө х ә м м ә т. Нихәл, күрше? *(Тырмасын куярга дип, «уфалла» арбасына таба атлый.)*

Фарис, этисенең үзенә бер сүз дә әйтмәгәнлегеннән кыенсынып, үзен кая куярга белмичә, бер урында таптанып тора.

М и р з ә к и. Ару гына, Нурмый абдый. Бүген көн әйбәт күренә. Печәнне чүмәләләп тормайсыңдыр инде. Пакуста килеш кенә җыеп апкайтасыңдыр?

Н у р м ө х ә м м ә т *(өйгә таба атлап)*. Шулай итмәенчә булмас.

М и р з ә к и. Әле менә мин дә үдемнең чүмәләләрне саклап кайтып киләдерием.

Н у р м ө х ә м м ә т *(өйгә кереп китешли борыла да коега ишарәли)*. Беднең кое төбендә синең чүмәләләрмени ул? *(Кереп китә.)*

Фарис эче катып сыгылып төшә.

Ф а р и с. Уф, үләм! Ну әйтте әткәй!

М и р з ә к и. Вәйт шайтан карты. Вәйт җомыкый диген син аны! Коеда җоклаганны белгән бит бу, апай. Сәйдәттәй дә күргәндер инде... Оят, апай. Валлаһи, оят. Пинсәдәге башым белән кеше коесында җоклап җөр инде. Җугайсә, җоклаем дисәң, үдебеднең бодау абдары да бар бит. Вәйт аракы тәре! Тәки Фатыйхларның чучкасына әйләндергән бит. Эчмә, апай! Җүнлегә илтә торган нәмә түгел бу. Шул, ара-тирә, бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә капкаласаң җарый инде... Вобшыты.

Ф а р и с. Эчмәскә иде шул, Мирзәкәй абый, вообще эчмәскә иде.

М и р з ә к и. Дөрес уйлайсың, апай... Синең урында булсам, мин дә шулай уйларыем. Менә әле...

Мирзәкинең сүзе шунда өзелә. Капкадан зур букчасын күтәргән Ч е г ә н х а т ы н ы дулый-дулый керә. Фарис нигәдер сагая.

Ч е г ә н х а т ы н ы *(усал тавыш белән)*. Әһә, икесе дә монда икән! Мине карак дип хур итеп җибәрдегез. Ә үзегез? Үзегез кем? *(Фариска.)* Менә, мәсәлән, син, чибәр егет? Син кем? Син үзең карак түгелмени? Гадалщик несчастный! *(Ачу белән букчасын җиргә куя.)*

М и р з ә к и. Нәмә сүләй бу тел тегермәне, апай?

Ф а р и с. Белмим бит, Мирзәкәй абый. Үзем дә аңламыйча торам.

Ч е г ә н х а т ы н ы. Кара, кара! Аңламыйм дип торган була. Күзен дә йоммый, шулер!

М и р з ә к и. «Шулер» нәмә дигән сүд ул, апай?

Фарис, белмим дигәнне аңлатып, җилкәсен сикертә.

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Аңгырага салынма, абый кеше! Шу-шы яшеңә җитеп шулерның шома карак икәнен дә белмәскә син...

М и р з ә к и. Нәмә, бурның кытыршысы да буламыни?

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Телең белән ботка болгатып торма. Өлкән кеше дип тормам. Борыныңнан сөйрәп үзебезнекеләр янына алып барырмын – ник туганыңа үкенерсең. Давай, бирегез яхшы чакта!

Фарис дәшми.

М и р з ә к и. Син берәр нәмә пунялмы-юкмы, апай? Нәмә сорый ул беддән?

Ф а р и с. Акча сорыйдыр. Чегән хатынына тагын нәрсә кирәк инде... Акча кирәк!

М и р з ә к и. Һы! Акча татарга да кирәк ул! *(Чегән хатынына.)* Әллә бедгә акча биреп торганыеңмы? Нәмә, күдләреңне алартып, тилебәрән орлыгы ашаган күек басып торасың?

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Сез нәрсә? Сез икәүләп миннән көләргә уйлыйсызмы? Ну-ка, бирегез хәзер үк беләзекне!

Ишегалдындагы шау-шуны ишетеп, болдырга С ә й д ә чыгып баса да тамашаны читтән генә күзәтеп тора. Ишегалдындагылар аны күрмиләр.

М и р з ә к и. Беләдек? Нәмәдәй беләдек ул тагын? Син нәмә, чүпрәк магадины, олы абдыеңа җала җагасың. Не смий хедмәт витиранын мыскылларга! *(Фариска.)* Син нәмә, апай, бер сүд дә дәшмәй торасың? Бу катыннан куркып астыңа пес итмәгәнсеңдер бит? Әйт сүдеңне! Җала җакмасын кешегә...

Ф а р и с *(тирән итеп сулыш ала да, башта Мирзәкигә, аннан Чегән хатынына карый.)* Әй син, табор кәбестәсе, чыгып ычкын моннан! Хатын-кыз дип тормам...

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Куркытма, тәти егет! Курка торган халык түгел без! Давай, боргаланмый-сыргаланмый беләзекне бир дә, мин китәм. Авылыгызга бүтән аяк та атламыйм.

М и р з ә к и. Вәт сагыд! Вәт стиморул! Нәмәдәй беләдек?

Сәйдә әкрен генә кулындагы беләзеген сала.

Ф а р и с. Ни сөйлисең син, шантажистка! Ни пычагыма миңа синең беләзегең?

Сәйдә болар тарафына талпынып куя. Бер кулы белән болдыр баганасын кочаклый.

М и р з ә к и. Бу катын бер-бер этлек уйлап килгән. Учас-кавайны чакырмай булмас! Какрас минем өйдә утырадырые. *(Юри китмәкче була.)*

С ә й д ә. Улым!

Өчесе дә Сәйдәгә борылып карый.

Ф а р и с. Инәкәй!

С ә й д ә. Мин барысын да *(беләзекле кулы белән йөрәген тота)* ишетеп тордым... Улы-ым!

Ф а р и с *(әнисенә ташланып)*. Инәкәй!

С ә й д ә *(сыкранып)*. Мә, улым. *(Беләзекне суза.)* Кайтарып бир хуҗасына...

Фарис бермәл беләзекне алырга да, алмаска да белмичә басып тора.

Ф а р и с *(ачыргаланып)*. Инәкәй! Мин сиңа унны алып бирәчәкмен! Инәкәй! Йөзне алып бирәм!..

С ә й д ә. Кирәкми... улы-ым... Мә... бир хуҗасына...

Ф а р и с *(күз яшьләренә тыгылып)*. Инәкәй! Кичералсаң кичер мине...

Фарис, чарасызлыктан гаҗиз булып, калтыранган кулы белән беләзекне ала. Акрын гына борыла да Чегән хатыны янына килә.

Ч е г ә н х а т ы н ы *(Фарис биргән беләзекне алып)*. Йөрәгең юктыр синең... *(Беләзеген кия. Китмәкче була.)*

Ф а р и с *(тоныкланып калган тавыш белән)*. Кичә бу абзыйның кесәсеннән алган иллелекне кире кайтар.

Чегән хатыны күлмәге кесәсеннән акча ала да, Мирзәкинең аяк астына ыргытып, бер сүз дә әйтмичә капкага юнәлә.

М и р з ә к и. И-и, апай, апай... Шушы кәгазьгә калган кешемени мин...

Мирзәки, акчага басып бермәл тын тора да, беткәнсең икән, апай, дигән ишарә ясагандай кул селтәп, аксый-аксый чыгып китә.
Иңсәсенә хат ташучы сумкасы элгән С ө м б е л керә. Фарис аны күрми. Сөмбелнең йөзе нигәдер борчулы.

С ө м б е л. Фарис абый!

Фарис Сөмбелнең үзенә дәшкәнен ишетми.

Фарис абый, дим!

Фарис ишетми.

Фарис абый! Седгә... телеграмма...

Ф а р и с *(сискәнеп)*. Ә? *(Сөмбелне күреп ала.)* Син дәштең мәллә, Сөмбел? *(Елмаерга итә, елмаюы ясалма чыга.)*

С ө м б е л. Седгә телеграмма барые... тик ул...

Телеграмма кәгазен Фариска суза. Фарис алмый.

Ф а р и с. Укы, Сөмбел.

С ө м б е л. Фарис абый... Ачуланма, мин укый алмыйм моны...

Ф а р и с. Укы әйдә, укы. Мин аның эчтәлеген болай да беләм.

С ө м б е л. Ничек? Каян беләсең? Монда бит...

Ф а р и с. Беләм инде, Сөмбел. «Казанга срочно кайт» диелгән анда...

С ө м б е л. Фарис абый! Бу... бу... бөтенләй башка телеграмма... Седнең... синең... *(Кинәт үксеп елый башлый.)*

Ф а р и с. Нәрсә булды, Сөмбел? Нигә елыйсың әле син?

С ө м б е л *(Фарисның күкрәгенә капланып)*. Дөфәр... Дөфәр абый... үлгән!

Ф а р и с. Ә? *(Сөмбел кулыннан телеграмманы тартып ала.)* Энекәш?! Ышанмыйм! *(Телеграмманы укый.)*

Җан тетрәткеч көй. Микрофон аша телеграммадагы текст яңгырый.

М и к р о ф о н д а г ы т а в ы ш. «Ваш сын Зуфар Нурмухамметович Бадримуллин героически погиб при исполнении интернационального долга...»

Ф а р и с *(ачыргаланып)*. Энекәш!

Фарис көтелмәгән хәбәрдән сыгылып төшә. Җиргә тезләнә. Башын җиргә бәрә-бәрә, йодрыклары белән җирне төя.

Энекәш! Зөфәр! *(Елый.)* Эне-кә-ә-әш...

Сөмбел, күз яшьләрен сөртеп, Фарис янына чүгәли. Куллары белән Фариска орынырга да, орынмаска да белмичә тора.

С ө м б е л. Фарис абый, нык бул. *(Фарисның җилкәсенә кулын сак кына куя.)* Нык бул, Фарис абый...

Ф а р и с. Сөмбел!.. *(Сөмбелне кочаклап, башын Сөмбел җилкәсенә куеп үкси.)* Энекә-ә-әш...

С ө м б е л. Фарис абый... Сәйдәттәйләр барлыгын онытма, нык бул!

Сөмбел, урыныннан кузгалып, Фарисны торгызырга азаплана. Кинәт дөнья караңгылана. Тетрәндергеч көй яңгырый. Кисәк кабынган ут көлтәсе болдырда багананы кочаклаган Сәйдәне яктырта.

С ә й д ә. Улыкаем! Дөфәркәем!.. Соңгы өметкәем... *(Хәлсезләнеп сыгылып төшә.)*

Дөнья янә караңгылана. Ут көлтәсе бу юлы болдырда бөкрәеп утырган Нурмөхәммәтне яктырта.

Н у р м ө х ә м м ә т *(салмак кына сөйли)*. Бу җирдә бөтен кеше өмет белән яши. Минем дә өметләрем барые. Бу җиргә килгән Кеше, һич җугы, бер агач утыртырга тиеш, диләр. Мин мең агач утыртканмындыр. Шуларның икесе бигрәкләр дә кадерле агачые... Ике агач... Ике имән! Берсе тамырын тирән җәя алмады, яфракларын яралмады... Бөтен өметем икенчесендә иде. Анысын да менә җәшен сукты.

Пауза.

Корыган агач басты дөнҗаны. Җиллэтәсе, җилләндерәсе килә. Инде җегәр жук, җегәр бетте...

Караңгылык эченнән Фарисның үзәк өзгеч тавышы ишетелә.

Ф а р и с. Әткәй!

Ут сүнә. Хәсрәт-сагышлы музыка.

П ә р д ә.

*1995*

# АЛТЫН КҮКӘЙ, ЯКИ КИНДЕРСЮРПРИЗ

*Ике пәрдәле комедия*

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Л ә з з ә т – 22–24 яшьләрдә, клуб мөдире.
Ф и р ү з ә – 20 яшьләрдә, китапханәче.
Ә с х ә т – 35–40 яшьләрдә, буйдак.
Р ә й с ә – Фирүзәнең әнисе.
М ө н и р – Фирүзәнең әтисе.
В ә с и л ә – Ләззәтнең әнисе.
Х а ф и з – Ләззәтнең әтисе.
Г ө л с и н ә – Вәсиләнең сеңлесе.
Л ә й л ә – 3–4 яшьләрдә, Гөлсинәнең кызы.
Ш а м и л – колхоз (җирле үзидарә) рәисе.
Х ә б ә р ч е – 35–40 яшьләрдәге ханым.
Т е л е о п е р а т о р.
Т ү б ә т ә й л е  м а л а й – 7–8 яшьләрдә.
А в ы л  к а р ч ы г ы.
Б е р е н ч е  х а т ы н.
И к е н ч е  х а т ы н.

## Б Е Р Е Н Ч Е  П Ә Р Д Ә

### Б Е Р Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш

Авыл китапханәсе. Өстәлгә куелган магнитофоннан дәртле-шашкын көй ургыла. Ф и р ү з ә белән Л ә з з ә т төрле хәрәкәтләр ясап, әллә ниләр кыланып бииләр.
Ишектән берәүнең башы күренә. Бу – Ә с х ә т. Ул, бүлмәгә узып, яшьләрнең кыланмышын күзәтә. Әлбәттә, бию белән котырынган яшьләр аны күрмиләр. Әсхәт, бермәл карап торгач, үзе дә биюгә кушыла – яшьләрдән дә әкәмәтрәк итеп биергә тотына. Бераздан- ул, хәле китеп, хәрәкәтләнүдән туктый. Еш-еш сулыш ала-ала, янәшәсендәге урындыкка утыра. Кинәт, урындык җимерелеп, Әсхәт идән-гә мәтәлә. Тавышка яшьләр борылып карый. Идәндә яткан Әсхәтне күреп, Фирүзә магнитофонны туктата.

Ф и р ү з ә. Берәр җирең сынмадымы, Әсхәт абый?

Яшьләр Әсхәткә торырга булыша. Ләззәт урындык ватыкларын җыештыра.

Ә с х ә т *(колак тишекләренә бармакларын тыгып, селкетеп ала)*. Ә?

Ф и р ү з ә *(катырак кычкыра)*. Мин әйтәм, берәр җи-рең, мәсәлән, аягың җә кулың-мазарың сынмадымы, дим, Әсхәт абый?

Ә с х ә т. Әү? Ник кычкырасың ул хәтле! Ишетәм бит мин! Нәрсә дидең?

Ф и р ү з ә *(Ләззәткә карап)*. Үзе ишетми тагы, ишетәм дигән була!.. *(Әсхәткә.)* Аягың!.. Кулың!.. Кабыргаларың!.. Сынмадымы алай-болай, дим?!

Ә с х ә т. Сынса ни! *(Өстәлгә йодрыгы белән суккалап ала.)* Тфү-тфү! Аллам сакласын берүк! Сынса... Син бит барыбер врач түгел!..

Ф и р ү з ә. Врач булмасам соң, йуды гына сөртә беләм мин! Сөртимме?

Ә с х ә т. Ник һаман кычкырып сөйләшәсең? Мин ишетәм бит... *(Магнитофонга ишарәли.)* Менә бу дыңгырдавыкның тавышы кереп тулды колакка... Шуны һич бетереп булмый... *(Газета-журнал актарыштыргалап торган Ләззәткә дәшә.)* Син, Ләззәт энекәш, клуб мөдире булдым дигәч тә... Танавыңны чөеп йөрмә әле! Карап-карап торам мин сиңа... Бер дә өлкәннәрне хөрмәт итмисең.

Л ә з з ә т. Минме, Әсхәт абый?

Ә с х ә т. Син, кәнишне! Ник исәнләшмисең минем белән, ә?!

Л ә з з ә т *(ике кулын сузып)*. Исәнме, Әсхәт абый!

Ә с х ә т. Ту-то! Сәлам, кәнишне, Ләззәт энекәш! Ату йөрисең... Фирүзәңнән башка кешеләрне күрмичә...

Фирүзә, оялып, башын ия.

Л ә з з ә т. Мин бит ни, Әсхәт абый... Ни бит, ни... Мин ни...

Ә с х ә т *(игътибар белән тыңлаган булып, юри Ләз-зәтнең авызына карап тора.)* Ниемне ниткәндә ниемнең ние нитте! Һай, шәп сөйлисең, Ләззәт энекәш! Һәр сүзең алтын кебек! Нәрсә булды сиңа? Тигез җирдә телең абына... Сәхнәгә чыксаң, авызыңда кош сайратасың бит син! Монда «ни бит, ни бит» дип торасың. Сузып йөрмә инде, тот та өйлән! *(Фирүзә белән Ләззәткә карап көлеп җибәрә.)* Мин каршы түгел!

Л ә з з ә т *(авыр сулап)*. Син каршы түгел дә бит... Ни бит... Рәйсә апа белән Мөнир абый каршы!

Ә с х ә т *(көйләп)*. «Каен ауган, сыер яткан барасы юлларыма, бүген булмаса, иртәгә калырсың кулларыма-а...» Мөнир абзаңның каршы булуына ышанмыйм. Кешегә аның ялгыш та аяк чалганы юк! Шулай бит, Фирүзә сеңлем?! Синең әтиең – миравай кеше! Чәчәккә ис китә торганнардан түгел мин үзе, вәләкин Мөнир үстергән чәчәкләрне күрсәм, аларны иснәсәм, билләһи-валлаһи, һич алдамыйм – аракысыз исерәм! Тәк

шту, Мөнир абзыең, туест булачак бабаң үстергән чәчәкләрне иснәп кенә яшиселәрең алда, Ләззәт энекәш! Ә инде Рәйсә апаңа килсәк... Мәсьәлә җитди, кәнишне! Әгәр каршы булмаса, Рәйсә Рәйсә булмас иде! Зәһәр теллеләр шулай каршы булучан инде ул, энекәш... Рәйсәнең теле чәчәгеңне шиңдерергә мужыт анысы... Ну син борчылма, күңелеңне төшермә, барысы да яхшы булыр... Пока! *(Көйләп.)* «Шиңгән чәчкәләр кабат терелер...» *(Китә.)*

Ләззәт, Фирүзәгә якын килеп, аны кочып ала. Үпмәкче була.

Ф и р ү з ә. Ашыкма. Әсхәт абый кире керә хәзер.

Л ә з з ә т. Нишләп? Каян беләсең?

Ф и р ү з ә. Моңарчы сизмәдеңмени. Мин бит – телепат! Кешенең ни уйлаганын ерактан торып беләм.

Л ә з з ә т. Минем хәзер ни уйлаганымны беләсеңме соң?

Ф и р ү з ә. Юк.

Л ә з з ә т. Нишләп?

Ф и р ү з ә. Чөнки син янда басып торасың... Ә мин ерактагы кешенең генә ни уйлавын беләм... *(Ишек шакыйлар.)* Әйттем бит!

Ә с х ә т керә.

Л ә з з ә т. Чынлап та!

Ә с х ә т *(керә-керешли)*. Истән чыккан... Мин бит...

Л ә з з ә т *(шаяртып)*. Ни бит...

Көлешәләр.

Ф и р ү з ә. Мин дә оныткан мын, Әсхәт абый. Әзерләп үк куйган идем, менә ул китап!

Ә с х ә т *(китапны алып)*. Минем бөтен куанычым китап инде! Сердәш тә, киңәшче дә, хатын да...

Ф и р ү з ә. Нишләп өйләнмисең син, Әсхәт абый?

Ә с х ә т. Хәзер соң бит инде, Фирүзә сеңелкәш...

Л ә з з ә т. Баштарак нишләп өйләнмәдең? Йөргән кызың булгандыр бит?!

Ә с х ә т. Бар иде. Мин аны хәзер дә пачти көн саен күрәм...

Ф и р ү з ә. Безнең авылныкымыни? Нигә бергә булмадыгыз?

Ә с х ә т. Хы-хы... Карахтерларыбыз туры килмәде, диләрме әле?! Язмыштыр инде. Рәхмәт китап өчен! Бүген көн күңелле узачак, Алла бирса! Ярый, әлегә! Барасым бар Шәлегә! Шутка! *(Көйләп.)*

Син – сандуга-ач, мин – кае-ен...

*(Китә.)*

Ф и р ү з ә. Кызык кеше дә инде бу Әсхәт абый, име, Ләззәт?!

Л ә з з ә т. Ыһы! *(Фирүзәне үпмәкче була.)*

Ф и р ү з ә. Тиле! Ярамый!

Л ә з з ә т. Мәхәббәтем шундый көчле – ярамыйга карамый!

Ф и р ү з ә. Җә инде, Ләззәт... Кеше күрүе бар.

Л ә з з ә т. Күрсеннәр, белсеннәр! Бөтен дөнья ишетсен: мин яратам!

Ф и р ү з ә. Кемне? *(Көйли.)* «Мин ярата-ам сине, Татарста-ан...»

Л ә з з ә т *(ялгышын төзәтеп)*. Мин Фирүзәне я-ра-там!

Ләззәт җырларга әзерләнә. Көй агыла башлый.

Кулларың – кулларда,
Уйларың кайларда? –
Нигә әле, нигә
Моңсу җанкайларга?

Ф и р ү з ә. Күзләрең – күзләрдә,
Сүзләрсез эндәшә:
«Без бергә гомергә
Янәшә, янәшә!»

Л ә з з ә т
Ф и р ү з ә *(бергә)*. Язмышыбыз агышлары,
Табышлары – безнең кавышу.
Ялгышларсыз, сагышларсыз
Яши алсак иде – бары шул...

Шулвакыт ишектән, кабаланып, Р ә й с ә, аның артыннан ашыкмыйча гына М ө н и р керә.

Р ә й с ә *(Ләззәткә якын килеп, Мөниргә әйтә)*. Күрмәсәң күр, белмәсәң бел: монда көн саен менә шундый бака туе!

Л ә з з ә т *(каушап)*. ...сәнме ...сә...па!.. сәнме ...нир ...бый!

Р ә й с ә *(үчекләп)*. Сән-сән! Зәт-зәт!..

Ф и р ү з ә. Әни!

Р ә й с ә. Тик кенә тор! *(Мөниргә.)* Бакчадагы чәчәкләрең качмый ул! Аларны карыйсы юк. Менә бу чәчкәнең качуы бар!

М ө н и р. Качса... Әллә кая качмый әле. *(Ләззәткә дустанә ишарә ясый.)* Күршегә генә!

Р ә й с ә *(Фирүзәгә)*. Мин сиңа, кеше булмаса, эшеңдә ятма, ишегеңне биклә дә кайт, дидем. Өйдә кырык эш кырык якта кырылып ята...

М ө н и р. Кырылып ятмыйча, биләмнән кайтып кергәнең юк бит!

Р ә й с ә. Ә синең бакчадан кергәнең юк. Куна-төнә чәчәк үстергән була, Мичурин тәре! Шуларны сатып акча эшләсәң, хет бер файдаң булыр иде. Кергән-чыккан кешегә бушка чәчәк өләшеп гомеркәйләрең үтте инде...

Ф и р ү з ә. Әни, дим!

Л ә з з ә т. Фирүзә, мин ни... Миңа китәргә вакыт...

Р ә й с ә. Әле генә барып җиттемени башыңа?! Бар-бар! Торма монда сураеп! Акча эшлә! Җырлап-биеп кенә авылда дөнья көтеп булмый ул!

М ө н и р. Җырлап-биеп кенә йөрми ул, урып-җыю чорында комбайнда эшли. Маладис ул Ләззәт!

Р ә й с ә. Нәрсә әле син монда баядан бирле миңа аркылы килеп торасың? Кеше баласын үтереп мактыйсың, үзеңнең малаең мәллә?

М ө н и р. Җүләр син! Телең ни әйткәнне колагың ише-тәме хет?

Л ә з з ә т. Фирүзә, мин киттем...

Р ә й с ә. Әле син китмәдеңмени? Бар-бар, кайтып калтырча машинагызны рәтли тор, ни кабызалмыйсыз шуны! Кабынса туктаталмыйсыз!

Л ә з з ә т. Яңаны алам мин...

Р ә й с ә. Кайчан?

Л ә з з ә т. Баегач!

Р ә й с ә. «Мин!» дигән була... хәчтерүш! «Баегач!» дигән була... Син баеганчы, тавыклар алтын күкәй сала башлый әле...

Л ә з з ә т. Мин Фирүзәне яратам! Без барыбер тиздән бергә булачакбыз! Менә күрерсез! *(Китә.)*

М ө н и р *(шаяртып)*. Кызым, Ләззәт «тиздән» диде, иртәгә үк түгелдер бит?

Р ә й с ә. Тфү-тфү! Авызыңнан җил алсын! Сине ияртеп алып килгән мин җүләр! Әйдә, күзлекле ромашка, киттек! Кайтабыз! Тиз генә күкәй кыздырып бирермен...

М ө н и р. Туйган инде ул күкәйдән...

Р ә й с ә. Син туйсаң, мин туймадым әле! Әйдә-әйдә, җәтрәк атла! *(Китәләр.)*

Ут сүнә. Музыка.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. Берничә эскәмия, урындык. Өй алдына якын гына итеп өстәл куелган. Өстәлдә савыт-саба, самавыр һәм телевизор.

Абзар-каралты ягыннан хатын-кыз тавышы ишетелә: «Кө-өш! Кө-өш, дим! Тапталасыз бит инде!»

Бераздан тавыш иясе В ә с и л ә күренә. Халатының кесәләре кабарган. Вәсилә өстәлгә таба килә. Р ә й с ә керә.

Р ә й с ә. Әйтә-әйтә телем арды инде... Тыясыңмы син, юкмы бу биздилник малаеңны!

В ә с и л ә. Артың белән киртә җимереп йөрмәле, башта исәнләш... Исән-саумы, Рәйсә!

Р ә й с ә. Исән булмыйча! Үләргә җыенмыйм әле! Әйт малаеңа, йөрмәсен кешене эштән бүлеп!

В ә с и л ә *(халат кесәсеннән тавык йомыркалары алып, өстәл өстендәге коштабакка сала-сала.)* Син бит группада. Калхуз эшендә интекмисең. Минем малай ничек сине эшеңнән бүлсен инде?

Р ә й с ә. Фирүзәгә эшләргә мишәйт итә малаең! Клубында рипититсия ясый-ясый да, минем кызның китапханәсенә кереп, өч тиенлек кәнсирт куя. Чистый бер агитбригада булды инде! Җитмәсә, өйләнәм дип авыз күтәреп торган була. Баерак кешеләр булсагыз иде, ичмасам!

В ә с и л ә. Сез дә әллә кемнәр түгел әле.

Р ә й с ә. Малаеңа әйт, йөрмәсен безнең Фирүзәнең башын бутап! *(Вәсилә кулындагы сәер йомыркага текәлеп.)* Ступ! Нәрсә бу-у-у?.. Кулыңда, дим?!

В ә с и л ә *(йомыркага карамыйча гына)*. Нәрсә булсын – күкәй! Нәрсә, әллә күкәй күргәнең юкмы?

Р ә й с ә. Күкәен күкәй дә... Кара син башта!

В ә с и л ә. Әстагыйм! Абау! *(Йомырканы төшереп җибәрә яза.)*

Р ә й с ә. Әллә алтын инде? Каяле, бир әле тотып карыйм... Шактый авыр күренә... Прастуй күкәйгә бер генә дә охшамаган... Валлаһи газыйм, алтын күкәй бу! Ахирәткәем, алтын бит, күр инде!

Урам якта кемнеңдер бик каты йөткергәне ишетелә.

Р ә й с ә. Яшер! Яшер тизрәк! Чит күз күрмәсен!

В ә с и л ә *(йомырканы халат кесәсенә салып)*. Чит күз дип... Син дә чит күз инде, Рәйсә...

Р ә й с ә. Мин чит түгел, мин – күрше, ахирәткәем! Без синең белән бертуганнар кебек! Һәрвакыт елмаешып, күгәрченнәр кебек гөлдер-гөлдер, гөлдер-гөлдер килеп кенә сөйләшәбез. Үз гомеребездә минем – сиңа, синең миңа бер авыр сүз әйтешкәнебез юк, Аллага шөкер! Хи-хи-хи... Ха-ха-ха...

В ә с и л ә. Гел аркылы да торкылы сөйләшәдериең, көлә дә беләсеңмени син, Рәйсә?

Йөткерү тавышы янә ишетелә.

Р ә й с ә. Яшер! Дәлше, дәлше, эчкәрәк яшер! Сукыр Касыйм бу! Чихут тәре! Күрсә, күргәнен мамент бөтен авылга чәчә... Яшерденме?!

В ә с и л ә. Бүлше никуда! Тагын кая тыгыйм мин аны?.. Ә-ә-әй, куркытып, йөрәк чирлегә әйләндерден инде... Син – җүләр, сиңа карап, мин җүләр! Сукыр Касыйм... Күрми бит ул! Тома-дөм сукыр! Белмисең мәллә?

Р ә й с ә. Касыйммы?! Ул күрмиме? Күрмәс! Әйе! Сине-кеннән, минекеннән шәп күрә аның күзләре...

В ә с и л ә. Ул хәтлүк кычкырма, тыңлап торуы бар...

Р ә й с ә. Курыкма, ерактан ишетми ул... Ә менә күрә!.. Заразы! Беркөнне: «Чихуткадан дөмегәсең бит инде, түберкүлёзник тәре, сасытма

шул тәмәкеңне», – дип, матур гына итеп киңәш биреп тора идем, «Акчаң төшеп кала бит!» – дип, минем менә шушы төшемә – ике күкрәк арасына җыртык бармагы белән ымлаган була... Сукыр тычкан сыңары!

В ә с и л ә. Акчаңны шул төшкә тыкканыеңмыни соң?

Р ә й с ә. Тыкканыем шул, хәерсез... Акчаның төшеп кала язганын күргәч, ул... Ничек тома сукыр булсын! Күрә-ә-ә, бик әйбәт күрә-ә-ә... Карале, кем, ахирәткәем... Сат миңа!

В ә с и л ә. Нәрсәне?

Р ә й с ә. Күкәеңне!

В ә с и л ә. Нинди күкәемне?

Р ә й с ә. Бә-әй, прастуй күкәй сорап тормам инде... Үземдә дә бер казан тутырык! Йөз тәңкә бирәм! Бер күкәй өчен йөз тәңкә күп тә инде... Чукынып китсен! Сиңа, балачак дустыма, чыбык очы туганыма, булачак кодагыема, саранланып торып булмас!

В ә с и л ә. Беренчедән, мин бернәрсә дә сатарга җыен-мыйм! Икенчедән, йөз тәңкә дип, мине тинтәккә, миңгерәүгә саныйсыңмы соң син?

Р ә й с ә. Йөз дә ун тәңкә! Йөз дә унбиш тәңкә! Йөз егерме тәңкә – вәссәлам! Сатулашуны бетерәбез... Хәзер акча алып керәм...

В ә с и л ә. Сатмыйм, Рәйсә! Биш йөз тәңкә бирсәң дә, мең тәңкә бирсәң дә сатмыйм!

Р ә й с ә. Әт-тәч! Әт-тәч! *(Кинәт нидер исенә төшергән-дәй.)* Туктале син, Вәсилә! Күкәйгә сразы хуҗа булырга ашыкма! Тәк, синең әтәчең исәнме әле?

В ә с и л ә. Исән булмыйча! Әнә бит, күрмисең мәллә?

Р ә й с ә. Теге күсе агуы ашап үлә язган әтәчең шушымыный инде?!

В ә с и л ә. Нишләп күсе агуы ашасын ул! Нәрсә сөйлисең син? Бездә күсе-мазарның күренмәгәненә бишбылтыр... Шөкер!

Р ә й с ә. Кер парашугы да ашаганы югыемы?

В ә с и л ә. Синеке кер парашугы ашый мәллә? Нәрсә син минем әтәчкә каныктың әле?

Р ә й с ә. Карап-карап торам да, тагын бер кат карап куям... Синең әтәчең ипатика икән бит!

В ә с и л ә. Нәрсә?!

Р ә й с ә. Ипатика... Юк... Импа... Импа-тинт икән бит ул!

В ә с и л ә. Ә?!

Р ә й с ә. Галубый да бугай әле!.. Йөреше тач тавыкныкы!

В ә с и л ә. Нәрсә әйтмәкче буласың син баядан бирле, ә?

Р ә й с ә. Аңламадыңмыни әле? Синең әтәчеңнең рәте юк – ирлеге беткән! Әйтәм аны, соңгы көннәрдә синең тавыкларың безнекенә ияләште. Кайчан карама, синең тавыклар безнең ихатада, безнең тавыклар – сезнекендә! *(Читкә карап.)* Әллә нәрсәләр сөйли башладым инде... Озын сүзнең кыскасы... Алтын күкәйнең яртысы минеке! Әйдә хәзер үк бүләбез!

В ә с и л ә *(бармакларыннан кәҗә тоягы ясап)*. Әбиең Маһимы?

Р ә й с ә *(аны-моны уйламыйча)*. Маһи.

В ә с и л ә. Иди... туда! Хәзер монда синең белән, пычкы тартышып, күкәй бүлешәсем генә калды! Бар әле, сару кайнатып, эчемне пошырып, башымны катырып, күз көеге булып, бөтен эшемнән бүлеп торма монда!

Ашыгып-кабаланып, капкадан Х а ф и з керә.

Х а ф и з. Тиз бул, тиз бул, тиз бул! Вәсилә! Нишләп телевизор өйдән чыкты?

В ә с и л ә. Баскычка баса күрмә! Буялган!

Х а ф и з *(телевизорны кабызып маташа)*. Да-вай, давай-давай! Кабын инде җәтрәк!

В ә с и л ә. Нәрсә бар? Берәрсе үлмәгәндер бит?!

Р ә й с ә. Мондый эсседә кеше үләмени! Футболдыр әле!

Х а ф и з *(телевизорга бәргәләп)*. Әйдә инде-е!.. Ну?!

Телевизор экранында, шулай ук сәхнә түренә махсус эленгән экранда Шамил сурәте пәйда була.

В ә с и л ә. Әстәгым! Шамил!

Р ә й с ә. Кая барып кергән!

Х а ф и з. Яптык авызны! *(Телевизорның тавышын көчәйтә.)*

Ш а м и л *(экранда)*. Так сказать... примергә минем авылны алыйк! Авылга газ керттем!..

Р ә й с ә. Нәрсә-ә-ә?

Ш а м и л. Урамнарга асфальт юл салдым!..

В ә с и л ә. Әстагым! Кайчан?

Ш а м и л. Зарплатаны айныкын айга биреп барам!..

Х а ф и з. Кит аннан!

Ш а м и л. Чөнки, понимаешь, бүгенгесе көндә мин – хозяйственник! Җирнең настоящий хуҗасы мин, кайсыдыр ки, мәсәлән!.. Бөтен авылны чәчәккә күмдем.

Р ә й с ә. Мөнирнең чәчәкләрен дә үзенеке итте бу!

Ш а м и л. Һәм дә ки... иң күп сөт миндә!..

В ә с и л ә. Сибә бу борчакны...

Р ә й с ә. Вәйт Хуҗа Насретдин! Вәйт Муенхаузен!

Х а ф и з. Тс-с!

Х ә б ә р ч е. Бүлдергәнем өчен гафу итегез, Шамил Бәд-риевич... Минем шуны әйтәсе килә... Сезнең кебек шундый уңган, шундый булган хуҗалар Татарстаныбызда күбрәк булсын иде!..

Р ә й с ә. Алла сакласын!

Х ә б ә р ч е. Сезнең кебек... Җирнең чын хуҗалары...

Экрандагы сурәт кинәт югала.

Х а ф и з *(телевизорга суккалап)*. Тагын күрсәтми. Өч минутка да чыдамый. Дөмегергә генә тора...

Р ә й с ә. Сезнеке хет өч минут кына булса да күрсәтә әле... Безнеке сәвсим эшләми... Ике ай узды бугай инде раюнда ята, римунтта! Карале... Телевизорга төшерәләр дигәч тә... Шамилне әйтәм... Сипте генә борчакны!..

Х а ф и з. Әрсезлеге бар инде үзенең... Малаена ит илтергә дип киткәние, телевизорга ук барып кергән.

В ә с и л ә. Рәхмәт инде. Безнең авылны бөтен республикага танытып сөйләде...

Р ә й с ә. Бер генә минутка кергәнием, озак тордым. Мөниркәемнең тамагы ачкандыр... Тиз генә күкәй пешерергә куйыйм әле... *(Чыгып китмәкче була да, кире борыла.)* Күкәй дигәннән... Хафизга әйтмәдек бит әле...

В ә с и л ә. Бар-бар, Рәйсә, өеңә чык. Хафизга үзем әйтермен... *(Рәйсәне эткәләп-төрткәләп дигәндәй чыгарып җибәрә.)* Уф! Кодагый булгач, ничек түзәрмен?

Ут сүнә. Музыка.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук ишегалды. Х а ф и з белән В ә с и л ә.

Х а ф и з *(көйли)*. Тавыкларым – ояда-а-а,
Оялары-ы – пыяла-а...
Ходай белә ул. Ходай белә. Кемгә күкәй, кемгә кукиш! Алтын күкәй, Вәсилә! Кил әле, кочаклап үбим бер үзеңне.

В ә с и л ә. Син нәрсә инде, Хафизулла! Кеше-кара керүе бар...

Х а ф и з. Кермәсләр!.. И-и-их, әйдәле җырлап җиффәрик әле, карчык!

В ә с и л ә *(җырлый)*. Затлы күлмәкләр алам!..
Алтын алкалар тагам!..

Х а ф и з *(җырга кушыла)*. Мин дә яңа тун алам!..
Искесен утка ягам...

Җырның кушымтасын, бер-берсенә карашып, «Әтәч-Тавык» ролена кереп, бии-бии җырлыйлар.

В ә с и л ә. Рәхмәт сиңа, Әтәч абзый!

Х а ф и з. Рәхмәт сиңа, Тавык түтәй!

И к е с е б е р г ә. Күктән төшкән бәхетебез –
Алтын күкәй, алтын күкәй!

В ә с и л ә *(җырны дәвам итә)*. Чәчләремне ясатам!..

Х а ф и з. Чит илгә барып кайтам!..

В ә с и л ә. Сыер-сарыкны сатам!..

Х а ф и з. Күккә төкереп ятам!..

И к е с е  б е р г ә *(кушымтаны әүвәлгечә җырлыйлар)*.
Рәхмәт сиңа, Әтәч абзый!
Рәхмәт сиңа, Тавык түтәй!
Күктән төшкән бәхетебез –
Алтын күкәй, алтын күкәй!

Кечкенә к ы з ы н житәкләп, Г ө л с и н ә керә.
Гөлсинә керүгә, Хафиз белән Вәсилә, алтын күкәйне кая яшерергә бел-мичә, ары-бире киләләр. Мәш килгән арада, Вәсилә күкәйне яшерә.

Г ө л с и н ә. Апа! Җизни! Корт чаккандай чабышасыз... Умарталарыгыз аермыйдыр бит?!

В ә с и л ә. Бер авылда торып... сине дә күрер көннәр бар икән! *(Ләйләгә.)* Исәнме, үскәнем! *(Аркасыннан сөя.)*

Л ә й л ә. Ә сездә эт бармы?

Х а ф и з. Юк. Без эт асрамыйбыз.

Л ә й л ә. Нигә? Сез бай түгелмени? Телевизорыгыз бар бит.

Г ө л с и н ә. Кызым, авыр сораулар биреп интектермә. Хи-хи-хи!.. Сорау биреп аптыратырга ярата да инде минем кызым. Ни эшләр бетереп ятасыз, апа, җизни.

Л ә й л ә. Ә сезнең попугаегыз бармы?

Г ө л с и н ә. Кызым, җитте! Бар, әнә тавыклар җөри... Шуларга бир сорауларыңны...

Х а ф и з. Балдызны күрмәгәнгә-ә-ә... Урамда кызыл кар яумагандыр бит?! Исәнме, балдыз!

Күрешәләр.

Л ә й л ә *(тавыкларга эндәшеп)*. Ә сезнең алтын күкәегез кайда?

Х а ф и з
В ә с и л ә *(борылып, икесе бергә)*. Ә-ә?

Ләйлә үз-үзе белән сөйләшеп, үз көенә уйнап йөри.

Г ө л с и н ә. Баягынак... Рәйсә апа белән сөйләшкәнне тыңлап торганые... Исендә калдырган икән...

Х а ф и з. Нинди алтын күкәй таптыра ул безнең тавык-лардан?

Г ө л с и н ә. Җизни! Җизникәем! Карале миңа! Нүжәли бер томана, мокыт инде мин, ә?! Апа?! Мин шундыйга охшаганмыни?

В ә с и л ә. Юк. Хәйләкәр төлкегә генә охшагансың!

Г ө л с и н ә. И апа җаным... Бигрәк чибәрләнеп киткәнсең! Безнең җизни әйбәт инде ул – апаны җил-яңгырдан саклап кына яшәтә! Ие бит, апа?! Ие бит, җизни?!

Л ә й л ә *(Хафиз янына килеп)*. Синең... алтын күкәең бармы?

Г ө л с и н ә. Уф, үләм! Ватык телефон белән бер булдың инде... Кызым! Тинтерәтмә җизнине!

Х а ф и з. Юк-юк, сорасын!.. Бала бит! Бала кеше кызыксына инде ул шулай...

Г ө л с и н ә. Апа! Җизни! Хәзер нишлисез инде? Әллә миңа... ну безгә генә сатасызмы?

В ә с и л ә. Нәрсәне... сиңа... сезгә сатарга тиеш без?

Г ө л с и н ә. Апа җаным! Мин чукрак түгел, ишетәм! Мин сукыр түгел, күрәм! Күпмегә сатасыз ул алтын күкәегезне?

Х а ф и з
В ә с и л ә *(икесе бергә, гаҗәпләнгән булып)*. Алтын кү-кә-әй?!

Г ө л с и н ә. Сезгә әртисләнү килешми! Сез алдаша да белмисез! Апа җаным! Җизни җаным! Мин бит бөтенесен дә беләм! Рәйсә апа сөйләде инде! Баягынак шул күкәйне яшерәбез дип чабышадырыегыз... Шулай бит?!

В ә с и л ә. Үтерәм бу Рәйсәне!.. Мөниремә күкәй пешерәсем бар, дип чыгып киткән булды... Бөтен авылга таратып өлгергән!

Г ө л с и н ә. Җизни-и-и!

Х а ф и з. Әү, балдыз!

Г ө л с и н ә. Апа барыбер әйтмәс! Синнән сорыйм әле: күкәегезне нишләтәсез? Сатасызмы инде дигәндәй... Сатарга уйласагыз, карагыз аны, безгә сатыгыз, яме, җизни! Бүтән кешегә ышандырмагыз!

В ә с и л ә. Гөлсинә! Сатмыйбыз!

Г ө л с и н ә. Апа, күрмисеңмени, мин җизни белән сөй-ләшәм! Монда... бу өйдә җизни баштыр бит?!

В ә с и л ә. Бу мәсьәләдә икебез дә баш. Шулай бит, Хафизулла?!

Х а ф и з. Шулай, карчык, шулай!

Г ө л с и н ә. Ярарыгыз соң... Альберт кайткач, икәүләп тагын әйләнербез әле... Бәлки, аңарчы берәр фикергә килерсез...

Х а ф и з. Баҗай берәр җиргә киткән идемени?

Г ө л с и н ә. Бә-әй, ишетмәдегез мәллә? Яңа машина алабыз бит – чит илский! Шуңа дип китте Альберт! Син, җизни, һаман шул «Москвич» белән чиләнәсеңме?

Х а ф и з. Әлегә чаклы йөреп торды әле. Без дә менә иртәгә-берсекөннәргә «Мерседес» алмакчы булып торабыз. Иеме, карчык?! *(Вәсиләгә күз кыса.)*

В ә с и л ә. Ие! Ләззәт тә әйтә, алгач-алгач, шәбрәген алыйк инде, дип әйтә.

Г ө л с и н ә. Альберт белән тагы чит илләрне айкап кайтмакчы булабыз. Ой! Арыдым ул чит илләрдә йөреп! Бармыйча да булмый. Организм чит ил климатына шулхәтле күнекте хәзер, ияләште, хәтта үзебездәге һаваны да сулый алмас хәлгә килдек. Елына бер-ике илгә барып кайтмасак, Альбертның да, минем дә тыннарыбыз кысыла...

В ә с и л ә. Ирең алыпсатар булгач, синә шундый тормышка түзәргә туры килә инде, сеңлем. Менә хәзер безгә дә рәхәтләнеп интегәсе булыр инде, Алла боерса!

Ут сүнә. Музыка.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капка төбендәге эскәмиядә Л ә з з ә т белән Ф и р ү з ә утыра. Ләззәт, авыз эченнән сөйли-сөйли, һавага бармагы белән нидер яза, сызгалый.

Ф и р ү з ә. Кәгазь белән авторучка биримме?

Л ә з з ә т. Кирәк түгел.

Ф и р ү з ә. Нәрсә язасың соң син? Һавада буш урын калмады бит инде!

Ләззәт сул кулы белән комачаулама әле дигән ишарә ясый.
Ә с х ә т үтеп бара.

Ә с х ә т *(тукталып, Фирүзәгә карап)*. Нишли ул?

Ф и р ү з ә *(җилкәсен сикереп)*. Тире иләп, күн эшли! Үзем дә белмим, Әсхәт абый... Сорыйм, сорыйм – әйтми! *(Көлеп.)* Сиңа укыр өчен шигырь яза бугай ул...

Ләззәт, бармагын иреннәренә тидереп, бермәл уйланып тора.

Ә с х ә т. Бармагын суырып тора, бармак суырып язгач, настоящий язучы инде бу! Күр әле син аны, ничек котырып яза! Нәрсә турында икәнен белер өчен, бер-ике җөмләсен укыган булыр идем. Жәл, күзлексез күрмим.

Ф и р ү з ә. Компьютерда бастыргач, бер экземплярын үзем бирермен, Әсхәт абый!

Ә с х ә т. Яхшы. *(Китмәкче була.)* Карале, Фирүзә, Альберт кибетеннән кофе алып килеп эчерт син Ләззәткә! Баш эшләсен, фикер килсен өчен язучы халкы чиләкләп эчә икән аны. *(Көлә.)*

Ф и р ү з ә. Чиләкләп үк түгелдер инде, Әсхәт абый?!

Ә с х ә т. Тучны белмим. Үземнең карап торганым юк. Бәлки, чәйнүкләп кенә эчәләрдер... Ярый, язучы хатыны булам дип артык кылтайма... Әпчехи! Мин барып кайтыйм әле Кытайга... *(Китә.)*

Ф и р ү з ә. Ләззә-әт... Язып бетерәсеңме инде?

Л ә з з ә т *(авыз эченнән генә мыгырданып)*. Бер тиен...

Ф и р ү з ә. Нинди бер тиен ул, Ләззәт?

Л ә з з ә т. Туйга шулхәтле акча кирәк булачак!

Ф и р ү з ә. Бер тиен генәме?!

Л ә з з ә т. Җүләр мәллә син? Нишләп бер тиен генә булсын!

Ф и р ү з ә. Үзең бит әйттең... *(Ләззәтчә әйтергә тырыша.)* Бер тиен, диден...

Л ә з з ә т. И Аллам! Тиздән кем белән яшәячәкмен мин?! Бер тиенгә туй уздырып буламыни? Утыз тугыз мең дә алты йөз унбер сум да бер тиен!..

Ф и р ү з ә. У-у-у!.. Минем биш еллык хезмәт хакы. Шулхәтле үк кирәк буламы туйга? Бу бит коточкыч кү-ү-үп!..

Л ә з з ә т. Кү-ү-үп шул синең өчен! Минем өчен пүчтәк! Мелочь! Мондый вак-төяк акчаны мин кесә расходы өчен генә йөртәм!

Ф и р ү з ә. И кыланчык!.. Хәчтерүш!.. Алтын күкәем бар дигәч тә... Ышанмыйм мин ул алтын күкәйгә! Барыбер ышанмыйм!.. Әни йөри анда очынып! Үз күзләрем белән күрдем, дип! Ипи тотыплар ант итә! Мин барыбер ышанмыйм! Әле мин күрмәдем ул күкәйне... Күрсәм дә, үз кулларым белән тотып карасам да ышанмаячакмын! Була торган хәл түгел бу! Бу, бу синең мәтәштерүең генә!

Л ә з з ә т. Тс-с!

Ф и р ү з ә. Әллә чынлап та синең эш бу?!

Л ә з з ә т. Без булдырабыз! Безнең кулдан килә! Әгәр без теләсәк...
...Яз ясарбыз салкын тайгада.
– Җир безнеке булыр!
Ачулансак,
Шлем киертербез айга да...

Ф и р ү з ә *(үчекләгәндәй итеп)*. Булдырабыз, булдырабыз... Син әле бер нәрсәне белмисең!

Л ә з з ә т. Нәрсәне?

Ф и р ү з ә. Безнең өйдә булган бер әкәмәт хәлне! Кстати, синең аркада булган хәл!

Л ә з з ә т *(мишәрчәләп)*. Да-а-а?! Кит аннан!

Ф и р ү з ә. Әни өйдәге бар булган күкәйләрне ватып бетергән!

Л ә з з ә т *(көлеп)*. Ялгыш өсләренә утырганмыни?!

Ф и р ү з ә. Көлмә-көлмә! Син гаепле аңа! Әни күкәйләрне специәлне ваткан!

Л ә з з ә т. Менә кызык! Монда минем ни катышым бар?

Ф и р ү з ә. Ышанган бит, җүләр! Һәрбер күкәй эченнән әни алтын эзләгән!

Л ә з з ә т. Ха-ха-ха!.. Күз алдыма китерәм Рәйсә апаны... Ха-ха-ха!..

Ф и р ү з ә. Аллага шөкер, күкәй бетте дип, әти башта сөенгән иде... Әтинең күкәйдән аллергия башланды бит! Бер кәчтерүл сыек күкәйнең омлет булып пешәсен белгәч, әти чүт аңын югалтып егылмады... Менә шундый хәлләр!

Л ә з з ә т. Аның каравы эшләр мин теләгәнчә бара... Минем төп максатым – Рәйсә апаны ризалаштыру! Ул ризалык бирсә, хәер, бирмәсә дә, без барыбер бергә булачакбыз!

Ф и р ү з ә. Әни ризалыгыннан башка мин кияүгә чыкмыйм! Белеп тор!

Л ә з з ә т. Ярар-ярар, белеп торырмын. Син дә белеп тор: барыбер минеке булачаксың! Әниең, сине җитәкләп, үзе минем каршыга килеп басачак... «Мин риза, Ләззәт кияү! Кызымны синең кулыңа тоттырам!» диячәк... Менә мин әйтте диярсең!..

Ф и р ү з ә. Карап карарбыз... Син әле минем әнине белеп бетермисең... Дөрес, хәзер аның телендә син генә! Эшләр, чыннан да, әлегә син дигәнчә бара... Тик, син шуны исеңдә тот: минем әнидән бөтенесен дә көтәргә була...

Л ә з з ә т *(янә мишәрчәләп шаяртып)*. Да-а, тёщаның явызы туры килде миңа!

Ф и р ү з ә. Әгәр «тёща» дип торсаң, үпкәлим хәзер...

Л ә з з ә т *(көйләп)*. Үпкәләсәң, әйдә үпкәлә-ә-ә,
Тик кайгылар белән түләмә-ә-ә...
Фирүзә, әйдә үзебезнең җырны җырлыйбыз!

Җырларга әзерләнәләр.

Л ә з з ә т. Әйдә, син башла!

Ф и р ү з ә *(җырлый)*. Кичке җиләс һава,
Зәңгәр эңгер-меңгер.
Ике гашыйк ярда,
Алар – синдер, миндер...

Л ә з з ә т
Ф и р ү з ә *(бергә)*. Язмышыбыз агышлары,
Табышлары – безнең кавышу.
Ялгышларсыз, сагышларсыз
Яши алсак иде – бары шул.

Л ә з з ә т *(җырны дәвам итә)*.
Зәңгәр эңгер-меңгер,
Кичке җиләс һава.
Сулар тып-тын ага,
Сулар – җанга дәва...

Л ә з з ә т
Ф и р ү з ә *(бергә)*. Язмышыбыз агышлары,
Табышлары – безнең кавышу.
Ялгышларсыз, сагышларсыз
Яши алсак иде – бары шул.

Бер-берсенә сыеналар.
Ут сүнә. Музыка.

## **БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ишегалды. Капкадан Х а ф и з белән Ш а м и л керә.

Ш а м и л. Кирәк бит, ә! Каян таптың син ул күкәйне, ә?

Х а ф и з. Оядан. Түлке мин тапмадым аны, хатын тапкан.

Ш а м и л. Не важны! Сез хет аңлыйсызмы соң, бу проблемагыз белән миңа күпме күкәй ясаганыгызны?! *(Хафизның үзенә сәерсенеп карап торуын искәреп.)* Нәрсә дип әйттем мин әле генә?

Х а ф и з. «Күпме күкәй ясаганыгызны!» дидең...

Ш а м и л. Әй, заразы! Баш катып бетте инде бу күкәегез белән! Әйе, мин әйтәм, бу күкәегез белән сез миңа күпме проблема өйгәнегезне аңлыйсызмы, дим?!

Х а ф и з. Соң, салган бит! Монда минем гаеп юк!

Ш а м и л. Кем салган?

Х а ф и з. Тавык.

Ш а м и л. Кайсы Тавык? Тавык Фатихымы, әллә Тавык Хәсәнеме? Кайсысы салган?

Х а ф и з. Син, Шамил, бүлнистә соңгы тапкыр кайчан булган идең? Что-то не то бит синең баш!

Ш а м и л. Нәрсә не то?

Х а ф и з. Мин бит сиңа аракы эчү турында берни әйтмәдем әле...

Ш а м и л. Ничек әйтмәдең? Ничек әйтмәдең?! «Салган!» дидең бит! Мин «Тавык Фатихымы, әллә Тавык Хәсәнеме?» дип сорадым...

Х а ф и з. Дурдом! Мин бит «Тавык салган!» дидем... Тавык!

Ш а м и л. Син нәрсә, һаман издеватсы итәсең миннән! «Тавык салган! Тавык салган!» Дураку ясно – мин салмадым!

Х а ф и з. Сүз бит күкәй турында бара түгелме соң, инәңнең башы? Тавык салган. Күкәй салган. Салган күкәе – алтын! Хатын тапкан. Монда хатынның да, минем дә гаеп юк.

Ш а м и л. Ну, блин! Мине укыткан укытучыларның бөтенесе дә надан иде, ахмак иде!.. Менә...

Х а ф и з. Сизелә шул...

Ш а м и л. Син алардан да ахмаграк! Юк кына нәрсә белән кеше башын катырырга кирәк бит, ә! Та-вык кү-кәй сал-ган дип конкрет әйтеп була югыйсә. Ю-у-ук, аңа кеше башын бутарга кирәк... Минем төпчек малайны син дә укытасыңмы әле?

Х а ф и з. Аллага шөкер, юк. Мин аны теләсәм дә укыта алмас идем.

Ш а м и л. Нигә?

Х а ф и з. Чөнки врачлар кушмый.

Ш а м и л. Нигә?

Х а ф и з. Нигә-нигә? «Кояш» сүзендә биш хата ясый торган малаеңны күрүгә, миндә көлү өянәге башлана...

Ш а м и л. Ыһым-ыһым... Карале, проблемадан читкә киттек...

Х а ф и з. Нинди проблемадан?

Ш а м и л. Сез тудырган проблемадан! Хатының алтын күкәй тапкан бит вакытлы-вакытсыз!

Х а ф и з. Тапсаный! Тели икән – күкәй таба, тели икән – бала... Хатын-кыз бит ул шуңа да!

Ш а м и л. Хатын-кыз дип... Күкәй тапкан хатын турында ишеткәнем дә, аларны күргәнем дә юк иде әле моңарчы...

Х а ф и з. Соң, минем хатын тапты бит күкәй!

Ш а м и л. Ё-моё! Тавык оясыннан тапмадымыни ул аны?

Х а ф и з. Тавык оясыннан тапты.

Ш а м и л *(лып итеп урындыкка утыра, кульъяулыгы- белән битен сөртә)*. Ычкынам бугай инде... *(Кулын йод-рыклап.)* Бәхетең, Макаренко... Минем кул астында эшләмисең... Ну, ничава!.. Салам-мазар сорап килерсең әле, бирермен мин сиңа... майга бутап!

Х а ф и з. Причём тут салам?

Ш а м и л. Синең күкәең аркасында бөтен авылга тап төшкәнен беләсеңме син, ә?

Х а ф и з. Юк.

Ш а м и л. Вот белмисең шул! Ә мин беләм! Синең күкәең турында сорап...

Х а ф и з. Беренчедән, минеке түгел, тавыкныкы! Икен-чедән, алтын күкәй...

Ш а м и л. Шулаймыни?! Белмәгән идем... Менә шул күкәегез турында сорашып идарәгә өзлексез шалтыраталар... «Авылыгызга кералмыйбыз – пычрак, саз!» диләр...

Х а ф и з. Нигә? Дөрес бит инде! Юл юк! Пычрак, саз! Авылга биш чакрым якын килә торган түгел!

Ш а м и л. Син искә төшермәсәң дә мин аның биш километр икәнен беләм! Район булышмый – исәбендә дә юк! Үзем акчасыз! Нәрсәм белән рәткә китерим мин ул юлны?

Х а ф и з. Ике джибың... Монда да, Казанда да өр-яңа коттеджың бар... Сат та шуларны, салдыр юл!

Ш а м и л. Син минем кесәдәге акчаларны санама, яме! Үзем тапкан мал! Анда синең эшең булмасын!

Х а ф и з. Мин бит җүләр түгел! Сизеп торам... Менә әле дә син безнең алтын күкәйдән үзеңә өлеш алырга чамалап йөрисең... Шулай бит?! Шиш! Кукиш сиңа!

Ш а м и л. Ыслушай, Луначарский! Син кайсы авылда яшисең?

Х а ф и з. Үзебезнең авылда.

Ш а м и л. Ю-у-ук, син үзегезнең авылда яшәмисең! Син минем авылда яшисең! Алтын күкәй салган тавыгың да минем авылда яши. Тавыгың да, үзең дә мин биргән ашлыкны ашап яшисез! Шулай булгач?! Күкәйгә мин полный права имею!.. Дөрес, синең ул бер күкәең белән биш километр түгел, ярты километр да юл салдырып булмый! Но?! Күкәй бит берәү генә булмаска мөмкин... Тәк бит? Ыспрашивается, где остальные?

Яшереп, җиргә күмеп куйдыгызмы? Табарбыз! Таптырырмын! Кирәк булса, махсус этләр чакыртып эзләтермен. Кирәк икән, иманыңны укытырга да күп сорамам! Но, мин уйлыйм, эшләр аңа ук барып җитмәстер... Тәк бит?

Х а ф и з. Слушай, син... иптәш Берия!.. Үзебезчә әйтсәк, Шамил Шакалетдинеч! Нучтуж!.. Мин – кешечә, син – бүречә... Болай булмый бит бу, әйеме, Шакалыч! Миңа да синең ысулны кулланырга туры килмәгәе! Теге хәл турында сөйләп, бөтен халыкка рисвай итәм бит мин сине...

Ш а м и л. Нинди теге хәл?

Х а ф и з. Оныттыңмыни?! Кызлар алдында адәм мәс-хәрәсенә кала язган идең бит...

Ш а м и л. Кайчан?

Х а ф и з. Тугызынчы класста укыганда...

Ш а м и л. Шантажга барасың, да?!

Х а ф и з. Кешесенә карап.

Ш а м и л. Ярый, чурт с вами! Күкәең үзеңә булсын! Чукынып кит! Мин юри генә куркыткан булып маташкан идем... Син тагы чынга алгансың! Кирәкми миңа синең алтын күкәең! Минем үземнеке бар! Алмаз күкәй! Әллә ничә каратлы-маратлы!

Х а ф и з. Бардыр-бардыр, ышанам... Тәгаен генә нәрсә кирәк соң сиңа бездән? Сүзеңнең эзе-ние юк!

Ш а м и л. Югалтыгыз сез ул күкәегезне! Или, тиз генә берәрсенә сатып, олактырыгыз! Берочтан тавыкларыгызны да, әтәчегезне дә кырып ташлагыз!

Х а ф и з. Нигә безгә ул хәтле зурдан кубарга әле? Өстән указание килде мәллә?

Ш а м и л. Аңла, Хафизун...

Х а ф и з. Мин сиңа «Хафизун» түгел...

Ш а м и л. Малай чакта шулай шаяртадырыек бит сине... Үзең дә миңа әле генә Шакал дидең... Мин үпкәләмәдем, Хафизун...

Х а ф и з. Мин – Хафиз!

Ш а м и л. Ярый, бетте-бетте! Син аңла мине... Аңларга тырыш... Казаннан, заразы, телевидениедән киләбез, дип шалтыраттылар... Каян ишеткәннәрдер?! Кем җиткергән-дер? Алтын күкәегез турында хәбәр аларга да барып җиткән, каһәр...

Х а ф и з. Килсеннәр соң. Кунак итәрбез.

Ш а м и л. Килсеннәр, килсеннәр... Юл юк бит, анаң сөт түккере!

Х а ф и з. Берәр исән тракторың бардыр бит. Булса, тракторыңа утыртып алып кайтасың инде үзләрен.

Ш а м и л. Трактор бар ла ул...

Капкадан В ә с и л ә керә.

В ә с и л ә. Нишлисез трактор белән? Исәнме, Шамил!

Ш а м и л. Исән әле. Ә-әй! Сезнең бу күкәегез күкәй генә булмады инде!

В ә с и л ә. Хафиз, нәрсә сөйли ул?

Х а ф и з. Ишетеп торасың бит: безнең күкәйне сүгә.

В ә с и л ә. Син нәрсә карап торасың? Сүктермә! Ир бит син!

Ш а м и л. Чәпчемәле, Вәсилә! Мәсьәләне аңламаган башың белән! Монда бик җитди сүз бара...

Х а ф и з. Казаннан корреспондент килә, ди.

В ә с и л ә. Шуннан? Кайсы Харис бандит?

Х а ф и з. Харис бандит түгел, кор-рес-пон-дент! Казаннан килә! Телевидениедән!

В ә с и л ә. Шуннан?

Ш а м и л. Утырган да шуган. Сезгә килә. Менә монда. Ә минем юл юк. Муеннан саз! Билдән камыш!.. Тфү! Билдән саз! Муеннан камыш!

В ә с и л ә. Нишләп безгә килә ул?

Ш а м и л. Белмим инде... Нишләп именно сезгә килә микән?

Х а ф и з. Күкәй күрергә киләм, дип әйткән, ди.

В ә с и л ә. Күкәй кайда да шул бер күкәй инде ул! Казанда беткән микәнни күкәй?

Ш а м и л. Алтын күкәй турында сүз бара, яптырниса!

В ә с и л ә. Ә-ә-ә... Алтын күкәй турында сүз барамыный, яптырмалакай. Алтын күкәй бит, ни бит... Тү-тү!

Ш а м и л. Ничек тү-тү?

В ә с и л ә. Менә болай тү-тү! Тү-тү!

Х а ф и з. Нәрсә түтелдисең син, Вәсилә?

В ә с и л ә. Югалды ул! Ходай бирде, Ходай алды...

Х а ф и з *(борчылып)*. Югалды?

Ш а м и л *(сөенеп)*. Югалды?!

В ә с и л ә. Эзләмәгән җир калмады – юк, беркайда да юк! Рәхәтләнеп утырып бер җыладым да... шуның белән шул!

Ш а м и л *(шатлыгы-куанычы ташып)*. Проблема бар иде – проблема юк! Рәхмәт, Вәсилә! *(Хафизга.)* Сиңа да ыспасибы, профессор! Шалтыратыйм әле хәзер үк! Килеп йөрмәсеннәр... Юлны пычратып! *(Чыгып китә.)*

Х а ф и з. Мин аңлап бетермәдем... Син чынлап әйтәсеңме соң?

В ә с и л ә. Чынлап, Хафиз, чынлап. Мин яшереп куйган җирдә юк!

Л ә з з ә т керә.

Х а ф и з *(Ләззәтне күреп)*. Ләззәт алмады микән?

Л ә з з ә т. Нәрсәне?

Х а ф и з. Күкәйне.

В ә с и л ә. Ул көн буе өйдә булмады бит.

Л ә з з ә т *(башта әтисенә, аннан әнисенә карап)*. Нинди күкәйне? Әй, алтын күкәй турында сүз барадыр инде... Мин алмадым. Әллә югалттыгызмы?

Х а ф и з. Әниең, яшереп куйган урында юк, дип әйтә.

Л ә з з ә т. Куйган җиреңне әйбәтләп карамагансыңдыр, әни... Шунда ятадыр әле...

В ә с и л ә. Карадым, яхшылап карадым, юк алтын күкәй! Бер җирдә юк! Парга әйләнгәндәй юкка чыкты!..

Л ә з з ә т. Өйгә чит кешеләр кермәгәндер инде?

В ә с и л ә. Мин өйдә чакта эт тә кермәде. Менә Касыймнарга гына барып килдем. Мәрзияттәйгә хәер бирермен дип нәзер әйткән идем, вакытында бирәлмичә йөрдем. Әллә шуның аркасында алтын күкәй югалды микән дип уйладым. Бер егерме минут йөргәнмендер инде. Мин кайтканда, әтиең белән Шамил абыең ишегалдында иде... *(Хафизга.)* Сез булганда чит кеше кермәгәндер?

Х а ф и з. Юк.

Л ә з з ә т. Әйдә, әни, күрсәт әле, кая куйган идең? Үзем ныклап карыйм!

Ләззәт белән Вәсилә өйгә кереп китәләр.

Х а ф и з *(кулларын өскә сузып)*. И Ходаем! Нәрсә инде бу, ә?! Кешечә яши башлыйбыз дигәндә генә... Хөкүмәт кебек син дә... Бер кулың белән бирәсең, икенчесе белән аласың... Хәерчене нигә рәнҗетәсең, байлар беткәнмени дөньяда?!

Өйдән Л ә з з ә т белән В ә с и л ә чыга.

Л ә з з ә т. Гениальный план җимерелде!

Х а ф и з. Нинди план ул тагы?

Л ә з з ә т. Җил исте, үлән селкенде, очты китте тузганак!..

В ә с и л ә *(Хафизга)*. Ни сөйли ул?

Х а ф и з *(җилкәсен сикертеп)*. Мин каян белим. Үзеннән сора!

Капкадан Ф и р ү з ә күренә. Аны күрмиләр.

Л ә з з ә т. Очты-очты, каргалар очты!.. Очты-очты, тавыклар очты!.. Очты-очты, күкәй очты!.. Очты-очты, барысы да очты!..

В ә с и л ә. Улым, Ләззәт, ул хәтле йөрәгеңә якын алма... Бетеренмә ул кадәр, баш исән булсын! *(Хафизга.)* Шулай бит, атасы?!

Х а ф и з. Әниең дөрес әйтә... Баш бәласе түгел, борчылма, улым...

Л ә з з ә т. Сез бит бернәрсә дә белмисез! Алтын күкәй генә түгел иде бит ул! Серле күкәй иде! Сере бар иде бит аның!..

Ф и р ү з ә. Нинди сере бар иде, Ләззәт?

Л ә з з ә т *(Фирүзәне әле генә күреп)*. Сюрпризы бар иде!

Музыка. Ут сүнә.

П ә р д ә.

# И К Е Н Ч Е   П Ә Р Д Ә

## Б Е Р Е Н Ч Е   К Ү Р Е Н Е Ш

Беренче пәрдәдәге ишегалды. Караңгы. Каяндыр ут яктысы төшә.
Яңа эт оясы шәйләнә. Ике арадагы койманың бер тактасын читкә шудырып, ишегалдына бер Ш ә ү л ә уза. Як-ягына каранып, эт оясы яныннан үтеп, лапаска таба атлый.

В ә с и л ә *(кинәт эт оясыннан башын чыгарып)*. Һайт! Руки верх! Стрилят буду!

Шәүлә, артка борылып карарга да куркып, кулларын күтәргән килеш басып тора. Вәсилә эт оясыннан чыга да сөяп куелган себеркене ала. Себерке сабы очын Шәүләнең аркасына тери.

Кту такуй?

Ш ә ү л ә. Не стриләй! Татар мин! Не стриләй, Вәсилә! Бу – мин... Мин бу – Рәйсә!

В ә с и л ә. Татар... бу вакытта йоклап ятар... Айлы төндә безнең ишегалдында нишләп йөрисең, Рәйсә? *(«Мылтыгын» җиргә төшерә дә янә эт оясына сөяп куя.)*

Рәйсә, Вәсилә күрмәгәндә генә, бер кәлүшен салып,
аны читкә тибеп җибәрә.

Р ә й с ә. Минме?.. Айлы төндәме?.. Нишләп йөримме? Менә тышка чыкканыем да... Инде чүгәлим генә дигәндә, койма янында әллә нәрсә селкенгән кебек булды. Куркуымнан, кәлүшемне салып шуңа томырдым. Караңгы бит, чамаламыйча катырак ыргыткanмын. Кәлүшем сезнең ишегалдына ук очып кереп киткән! Шуны алыйм дип кергәнием менә...

В ә с и л ә *(Рәйсәнең аякларына карап)*. Бәрәч! Әле генә кәлүшләрең аякларыңда иде бит!

Р ә й с ә. Күзеңә генә күренгәндер.

В ә с и л ә. Алдашып торма инде, Рәйсә, дөресен әйт! Ник кердең безгә?

Р ә й с ә. Карале, син минем лунатик икәнне беләсеңме әле? Мин бит лунатик!

В ә с и л ә. Кем син?

Р ә й с ә. Лунатик мин! Лунатик!!! Караңгыда ишетмисең мәллә?

В ә с и л ә. Ишетәм. Йә, шуннан...

Р ә й с ә. Син башта әйт, лунатикның нинди кеше икәнен беләсеңме?

В ә с и л ә. Әле генә әйттең бит инде... Ул – син!

Р ә й с ә. Дивана! Лунатик ул шундый кеше... Үзе йок-лый, үзе аягүрә йөри... Лапас түбәсенә дә, өй түбәсенә дә менә... Багана башына да... Андый чакта аны уятырга ярамый!

В ә с и л ә. Кемне уятырга ярамый? Синеме? Йокламыйсың бит син! Менә минем каршыда тавык кебек кытак-лап торасың...

Р ә й с ә. Беләсең килсә, йоклыйм мин! Синең белән сөйләшеп торам икән, димәк, мин йоклаган килеш сөй-ләшәм. Менә иртәгә сорарсың – мин боларның берсен дә хәтерләмәячәкмен! Лунатиклар үзләренең нәрсә эшләгән-нәрен белештермиләр алар!..

В ә с и л ә. Менә кызык! Мин синең белән сөйләшәм... Ә син йоклыйсың икән... Безнең ишегалдына керүең дә исеңдә калмыймы?.. Уянгач?

Р ә й с ә. Юк инде, юк, калмый! Йоклыйм, дим бит!

В ә с и л ә *(Рәйсәнең җирдә яткан кәлүшенә таба бара)*. Йоклагач, әйбәт бит инде ул! *(Кәлүшне әйләндереп.)* Ыразмиры бара... Кайсы аякныкы бу? Уң аякныкы икән. Какрас безнекенең арты җыртылган иде... Әйбәт булды әле.

Р ә й с ә. Нишлисең син? Минеке бит ул!

В ә с и л ә. Хәерлегә булсын! Лунатиклар күбәеп китте- әле... Кичә – икәү... Бүген – өчәү... Кергән бере әйбер кал-дырып китә, рәхмәт төшкерләре! Менә кәлүшле дә булдык!

Р ә й с ә. Булмый гына торсын, яме! Минем кәлүш ул!

В ә с и л ә. Син дә тавык урларга кердеңме, Рәйсә? Алтын күкәй югалганын белгәч, тавыкларның үзләрен урларга ниятләгән идеңме?

Р ә й с ә. Син нәрсә?! Син нәрсә?! Кем дип белдең син мине?! Киресенчә, сиңа ярдәм итеп, булышып йөрүем... Төн йокыларымны калдырып... Бикләнмәгән булса бикләрмен дип, кетәклек ишегендәге йозакны тикшерергә кергән идем... Күз-колак булмыйча ярамый.

В ә с и л ә. Йә-йә, телеңә салынма. Мә кәлүшеңне! Ки дә сыптырт, дальтуник!

Р ә й с ә. Дальтуник түгел, лунатик мин!

В ә с и л ә. Миңа димәгәе! Хет Алланың кашка тәкәсе бул! Күземә генә күренмә! Синең кебек күкәй бурлары, тавык караклары аркасында ике төн инде йокы күргән юк!

Р ә й с ә. Җә инде, кодагыйкаем, чәпчемәле ул кадәр! Әйдә, безгә керәбез... Чөкердәшеп чәй эчәрбез. Бал белән, каймак белән.

Ут сүнә. Музыка.

## И К Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш

Шул ук ишегалды. Иртәнге як. Ш а м и л керә. Эт оясын күреп, аның янына килә, суккалап-типкәләп ала. Иелеп, эт оясына башын тыгып караган вакытта өйдән Х а ф и з чыга.

Х а ф и з *(Шамилне күреп)*. Әй-әй-әй! Кереп ятарга уйласаң, ашыкмый тор! Синең бозау хәтле гәүдәңә чамалап эшләнмәгән ул! Авызын зурайтканны көт, хәзер келәттән балта белән пычкы алып чыгам...

Ш а м и л. Тфү! *(Торып баса.)* Башны катырма әле. Ачу килгән чак. *(Эт оясына янә тибеп ала.)* Шыгырдап торган тактадан мәтәштергәнсең... Каян суктың?

Х а ф и з. Бүртенмә зерәгә! Синең пилорамда мондый кәттә такталар юк. *(Эт оясын учы белән сыйпап.)* СыСыСыР тактасы бу! Знак качествалы! Алтмыш тугызынчы елны ярдырган идем...

Ш а м и л. Әкият сөйләмәле монда. Алтмыш тугызынчы ел – без мәктәпкә кергән ел бит ул... Җиде яшь кенә иде бит әле сиңа ул вакытта. И тем более миңа да!

Х а ф и з. Ну, эти ярдырды инде... Мин дә шунда идем. Кем ярдырган булса да барыбер түгелмени хәзер?! Зато күр, кара! *(Эт оясын шакый.)* Һау-һау! Мөмкинме кереп ятарга? Һау-һау! Пажалысты! Рәхим итегез, люкс-номер! Суткасына илле тәңкә! Таныш-белешләргә бесплатны. Рәхмәт, рәхмәт! Спасибо! Мерси! Данке шён! Иң мөһиме, малай, моның түбәсе калай. Яңгыр, кыш көне яуса да, үтәрлек түгел.

Ш а м и л *(Хафизга текәлеп карап тора)*. Син, һау-һау, этләр теле белгече... *(Кыза башлап.)* Мирси-пирси!.. Идрит-кудрит! Нәрсә баядан бирле букый-сукый сүз сөйләп торасың?.. Проблема баштан ашкан вакыт! Өлгереп булмый! Анда эш таралып ята! Монда эш өелеп ята! Ярты авыл, бөтен сәламәт кеше, группада! Эшләргә дисәң, кеше юк. Ә ул, проблеманы хәл иткән чакта, тәгәрмәчкә таяк тыгып, тормоз ясап тик тора...

Х а ф и з. Мәңге хәл ителәсе юк проблемаларыңны күтәреп киләсең дә җитәсең безгә, киләсең дә җитәсең!.. Үземнең проблемаларым юк мәллә минем?! Менә баеп китәбез дигәндә генә алтын күкәй югалды! Тавыкларга да әллә нәрсә булды: ту эчләре китә, ту эчләре ката, ту шуларны урларга маташалар. Хатын бер-бер нәрсә ашаттымы шунда... Икенче көн инде, алтынны түгел, мондый күкәй дә салмыйлар...

Ш а м и л. Нервы какшаганнан шулай була. Нервлары таушалган тавыкларыңның. Или бик каты курыкканнар. Суярга кирәк. Стресс кичергән тавыкларны суеп кына мантый алмассың, так сказать. Андый тавыкларның ите не то була аның... Иренмәсәң, барысын да бер капчыкка җыеп тутыр да илтеп ташла минем ишегалдына. Күбенеп үлгәнче йөрерләр шунда... *(Хафизның җилкәсенә кулын дустанә салып.)* Карале, Хафиз, тәки табылмадымы алтын күкәй?

Х а ф и з. Юк. Эзләмәгән җир калмады.

Ш а м и л. Жәл. Бик жәл. Тагын ныклап эзләргә кирәк булыр... Табарга кирәк. Тапмасак, эшләр харап.

Х а ф и з. Кызык кеше инде син, Шамил. Әле югалтырга кушасың алтын күкәйне, әле табарга кушасың... Нәрсә булды тагы?

Ш а м и л. Киләләр... Барыбер киләләр!

Х а ф и з. Кемнәр килә?

Ш а м и л. Әйттем бит инде. Шулар килә.

Х а ф и з. Аңлатып сөйлә инде. Кемнәр алар «шулар»?

Ш а м и л. Төшерүчеләр инде... Теге тудый-судый сөй-ләтеп снимать итүчеләр... Әйттем бит инде теге көнне... Телевизордан киләләр, дип. Воот...

Х а ф и з. Килмәскә кушып шалтыратам дип киткән идең бит.

Ш а м и л. Үземнең тел аркасында инде. Кем белгән бит аны. Болай буласын белгән булсам, ул хәтле шапырынмаган булыр идем... Киләләр... Төшерүчеләрнең, корреспондентларның безнең данлыклы авылны күрәселәре килә. Гөрләп яши бит безнең авыл, идрит-кудрит.

Х а ф и з. Да-а-а, теге көнне телевизордан эре-эре бор-чакларны күп сиптең шул, яшьти! Синең ул авылыңда минем дә яшисем килә башлаган иде.

Ш а м и л. Кем белгән бит аларның мондый ерак җиргә дә килергә мужыт икәнлекләрен. Күкәй тәгәрәтерлек юлларың булсын иде ул.

Х а ф и з. Күкәй тәгәрәтү турында хыяллана алгач, эшләрең бик үк хөрти түгел әле синең, яшьти. Борчылма, иң мөһиме, башың сау булсын!

Ш а м и л. Рәхмәт, сабакташ! Чын кеше син! Хет син аңлыйсың минем хәлемне. Тап инде шуны. Үзең ничек булса да тап. Эзлә, актар! Чокчын, айка! Алтын күкәйне генә тап түлке!

Х а ф и з. Тапсак та, тапмасак та... Алтын күкәй тылсымлы түгел бит ул. Сихер-михер көче юк аның. Ул бит синең, минем авылны алай тиз генә барыбер әкияти дөньяга әверелдерә алмый.

Ш а м и л. Аның каравы алтын күкәй тегеләрне, корреспондентларны, безнең проблемалардан читкә алып китә ала... Күкәй-күкәй!.. Алтын-алтын!.. Фәлән-фәсмәтән!.. Әтәч-тавык! Секс-мекс! Кем тапты? Тавык тапты? Птичий грипп! И тагдалие!.. Авыл турында бер сүз юк! Күкәй дә күкәй, как будто безнең авыл юк! Сезнең өй бар да, менә шушы ишегалды, лапас, менә бу эт оясы бар!.. И баста! Ну, ничек? Шәп бит?

Х а ф и з. Шәп дип...

Ш а м и л. Хәзер үк сезгә бер трактор утынлык агач китерергә кушармын... Тап! Тиз тап күкәеңне!

Х а ф и з. Нишлим мин синең ул агачың белән?!

Ш а м и л. Мичкә ягарсың.

Х а ф и з. Газ ягам бит мин!.. Үзең әйттең бит телевизордан!

Ш а м и л. Ну бу татарның вакчыллыгы! Ну бу татарның ваклыгы! Әйткән – беткән! Нәрсә һаман искә төшереп торасың инде!.. Синең өчен генә аерым газ кертмәм бит инде... Пока утын як!

Х а ф и з. Ярар, бакча артына китереп аудартырсың алайса... Бирәм дигәндә, алып калырга кирәк. Син саранга ышанып бетеп тә булмый инде...

Ш а м и л. Бу юлы ышан! Валлаһи! Китерерләр! Бөтен өмет – синдә, сабакташ! Бүтән чакларда да ярдәм итәрмен... Тап күкәйне! Табыгыз! Мин кузгалдым... Аларны, килүчеләрне, ашатасы-эчертәсе дә булыр бит әле... Тагын... Тегесе-бусы... *(Кулын селти.)* Ә-ә-әй! *(Чыгып китә.)*

Х а ф и з *(аның артыннан сөйләнеп)*. Тап! Тап! Күкәй дигәч тә! Ыштан төбеннән генә тартып чыгарасы түгел бит аны! Башта ныклап эзләргә кирәк әле... *(Өйгә карап кычкыра.)* Вәсилә!

Ут сүнә. Музыка.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Китапханә. Ф и р ү з ә өстәл янында нидер яза.
Авыз эченнән генә көйли.

Ф и р ү з ә *(тавышы көчәя)*.
Кулларың – кулларда,
Уйларың кайларда? –
Нигә әле, нигә
Моңсу җанкайларга-а-а...

Ашыгып, Л ә з з ә т керә.

Л ә з з ә т. Фирүзә, булды!

Ә с х ә т *(Ләззәт артыннан ук кереп)*. Булса, шәп булган!

Ф и р ү з ә. Исәнмесез, Әсхәт абый! *(Ләззәткә.)* Нәрсә булды?

Л ә з з ә т *(кесәсеннән нәрсәдер чыгармакчы була да кире уйлый)*. Ә-ә-әй... Яңадан әйтермен әле! Исәнмесез, Әсхәт абый!

Ә с х ә т. Космик тизлек белән чабасың... Артыңнан куып җитеп булмый. Син кирәк идең... Исәнме, энем! Исәнме, сеңлем! Өйләнгәч тә шулай кызу йөрерсең микән син, ә?! Ләззәт?!

Л ә з з ә т. Белмим шул, өйләнеп караганым юк.

Ә с х ә т. Әле синең башта өйләнеп карарга гынамыни исәп? Не шути, энекәш! Фирүзә, нәрсә сөйли ул? «Өйләнеп караганым юк», имеш...

Л ә з з ә т. Ялгыш әйттем мин... Фирүзә, син дөрес аңла... Мин алай әйтергә теләмәгән идем...

Ә с х ә т. Акланма, акланма, энекәш... Йә, ярый, кем, Ләззәт, Фирүзә, мин болай, шаяртам гына...

Ф и р ү з ә. Йомышыгыз бар иде мәллә, Әсхәт абый?

Ә с х ә т. Әйе шул. Түлке сиңа түгел. Ләззәт энекәшкә.

Л ә з з ә т. Әйтегез соң, Әсхәт абый...

Ә с х ә т *(Фирүзәгә карап)*. Секрет фирмы! Сеңлем, Ләззәткә бер сүзем бар иде. Сүз дип, сүз түгел инде ул... Сорыйсы бер нәрсә шунда.

Ф и р ү з ә *(колакларын куллары белән каплап)*. Мин ишетмим! Әллә чыгып торыйммы соң?

Ә с х ә т. Юк-юк! Чыгып торма! Ишетмәгән булып кылануың да җитә. *(Ләззәтнең җилкәсенә кулын сала.)* Карале, Ләззәт дус... Менә ни бит

инде, име... «эстрада» дигән сүз бар бит инде, име?! «Сәхнә» дигән сүз бит инде ул үзе... Әйт әле... Менә шул эстрадада, сәхнәдә кем хәзер иң әйбәт җырлаучы?

Л ә з з ә т. Бездә, татардамы? Ир-ат җырчымы, хатын-кызмы?

Ә с х ә т. Ну, татарда булсын әйдә! Ну, хатын-кыз булсын!

Л ә з з ә т. Кемгә кайсы җырчы ошый бит, Әсхәт абый... Берәүгә – Зәйнәп, икенче берәүгә – Мәликә, кемгәдер Алсу ошый. Минем үземә, мәсәлән...

Ә с х ә т *(аны бүлдереп)*. Фирүзә ошый! Анысын беләм. Син менә әйт әле миңа, Мәчтүрәнең җырлавына ничек карыйсың?

Л ә з з ә т *(аптырап, сәерсенеп)*. Мәчтүрә?! Нинди Мәч-түрә? Кайсы Мәчтүрә?

Ә с х ә т. Ә-һә! Кайсы, дисең... Әллә берәр Мәчтүрәне беләсеңме?

Л ә з з ә т. Юк инде-е-е. Бернинди Мәчтүрәне белмим!

Ә с х ә т. Мин дә белмим шул! Ха-ха-ха!

Л ә з з ә т. Ә ник соң үзең, Мәчтүрә ничек җырлый, дип сорыйсың...

Ә с х ә т. Хәзер бит җырчылар куян кебек үрчи... Юк! Болай чагыштырып әйтү матур түгел, име?! Җырчылар бит хәзер гөмбә кебек үсә!.. Бу чагыштыру ярыйсы! Име?! Шуннан чыгып әйтәм инде... Мин йокыдан торганчы, берәр Мәчтүрә исемле гөмбә үскәндер дә, шул бик тиз генә сәхнә йолдызына әверелгәндер... Ә мин, йоклап ятып, шул йолдыз турында ишетми-белми калганмындыр дип кенә соравым... Көндәлек яңалыктан, пресса-радио әйтмешли, хәбәрдар булып барырга кирәк бит! Шулай итеп, син Мәчтүрәне белмисең булып чыкты инде!

Л ә з з ә т. Шушымы синең, Әсхәт абый, секрет фир-мың?

Ә с х ә т. Шуткы! Секрет фирмы түгел – шуткы! Ха-ха-ха! Карале, кинәт исемә төште... Бүген сезгә кунаклар килә икән, име?

Л ә з з ә т. Нинди кунаклар?

Ә с х ә т. Казаннан! Телевидениедән!

Л ә з з ә т. Ә-ә-ә... телевидениедәнме?! Әти шулай дип сөйләнде шул...

Ә с х ә т. Син алай-болай белмисеңме кемнәр килә икән?

Л ә з з ә т. Каян белим инде, Әсхәт абый. Белсә, Шамил абый беләдер... Аңа шалтыратканнар бит!

Ә с х ә т. Әйе шул, кара, минем башка килмичә тора... Кәнишне, белсә, Шамил белә инде...

Л ә з з ә т. Нигә кирәк сиңа кемнәр килүе...

Ә с х ә т. Секрет фирмы!

Шулвакыт ишектә т ү б ә т ә й л е м а л а й күренә.

М а л а й. Ләззәт абый! Син мондамы?

Ә с х ә т. Башта исәнләш, такыр баш!

М а л а й. Әс...әссәламегаләйкүм!

Ә с х ә т. Күрдеңме, Ләззәт?! Ничек исәнләшә хәзер без-нең авыл җегетләре! Маладис, энем! Вәгаләйкүмсәлам! Тот бишне!

М а л а й *(өлкәннәрчә итеп, Ләззәт белән дә күрешә)*. Сине этиең чакыра, Ләззәт абый! *(Фирүзәгә.)* Фирүзә апа, син кайчан кияүгә барасың?

Ф и р ү з ә *(көлеп)*. Ләззәт абыең алмый бит! Һаман суза...

М а л а й *(Ләззәткә)*. Ал инде! Интектермә Фирүзә апаны!

Л ә з з ә т. Күп сөйләшмә! Бүген алам Фирүзә апаңны! Әти үзе кайда соң ул?

М а л а й. Монда түгел инде-е... Өегездә.

Л ә з з ә т. Нигә чакыра?

М а л а й. Мин каян белим. Миңа әйтмәде. Тиз кайтырга кушты.

Ә с х ә т. Киттек әйдә, Ләззәт энекәш... Атаң өйдә важный эш тапкандыр сиңа...

Л ә з з ә т *(малайга)*. Хәзер очып кайта, диген...

М а л а й. Әем лә... Әйтмим. Үзең әйтерсең. Мин әле укырга барам.

Ф и р ү з ә. Бүген мәктәптә ял көне түгелме соң, Гомәр?!

М а л а й. Мин бит мәчеттә дә укыйм.

Ә с х ә т. Һо! Ишеттегезме?! Маладис, энекәш! Синең кебек җегетләр булганда, безнең авыл бетмәячәк әле... Яшәячәк, Алла бирса!

Л ә з з ә т. Фирүзә, мин яңадан киләм, яме!

Ә с х ә т. Бар инде, Фирүзәңне үбеп ал... Без карамыйбыз, име, Гомәр?! Без киттек. *(Көйли.)*
Үп син мине!
Үп син мине!
Үп, үп, үп...

М а л а й. Сау булыгыз!

Әсхәт белән малай чыгып китә.

Л ә з з ә т. Секрет фирмы дигән булып сөйләнде... Бернәрсә дә аңламадым...

Ф и р ү з ә. Хыялый да инде бу Әсхәт абый...

Л ә з з ә т. Аңа рәхәт, аның өйләнәсе юк!

Ф и р ү з ә *(кинәт, үпкәләп, арты белән борыла)*. Соң, син дә өйләнмә алайса!

Л ә з з ә т. И Фирүзә матурым! Мин бит шаярттым гына...

Ф и р ү з ә. Шаяртканыңны каян белим мин...

Л ә з з ә т *(Фирүзәне назлап-иркәләп)*. Ә син бел! Син минем кайчан җитди сөйләшкәнемне, кайчан шаяртканымны әллә каян белергә тиеш!.. Ни әйтсәң дә... Син бит минем булачак хатыным! Бердәнберем! Асыл кошым! Сандугачым-былбылым! Җанкисәгем! Акыллым!

Ф и р ү з ә *(сыенып, татлы сүзләрдән эреп бетә язып)*. Хатының булырмын да бит... Җете кызыл тиз уңмасмы соң?..

Л ә з з ә т. Уңа торганнардан түгел мин, Фирүзәм-гөлкәем! Мин уңмаячакмын!.. Һәрвакыт кызыл ут кебек янып торачакмын!..

Ф и р ү з ә. Кара аны! Сүзеңдә торырсың дип ышанам! *(Көлешәләр.)*

Ут сүнә. Музыка.

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. Өйдән Р ә й с ә чыга.

Р ә й с ә *(үзалдына сөйләнә-сөйләнә, аяк киеме кия)*. Әйттем әле! Каты әйттем! Һе! Әйтмәскә! Хезмәтче итәрләр иде бугай кызымны! Итми генә торыгыз әле менә! Балда-майда гына йөзеп яшәргә тиешле курчак кебек кызымны сез хәерчеләргә бирәмме соң? Гомер булмастайны! Һе!

Сөйләнә-сөйләнә чыгып барган Рәйсә ашыгып килеп килүче
Л ә з з ә т белән бәрелешә.

Р ә й с ә. Уф, котымны алдың, шүрәле!

Л ә з з ә т. Гафу ит, Рәйсә апа! Син генә икәнсең әле... Капка баганасы дип торам. *(Маңгаен угалап.)* Туй алдыннан синяк чыкмаса ярый инде.

Р ә й с ә. Күрсәтермен мин сиңа капка баганасын! Телләнеп, мыскыл итеп тор әле... Туй, имеш... Моннан соң туй дип авыз ачасы булма!.. Ишетсен колагың! Сиңа кыз бирдем юк! Әйттем анаңа да! Каты әйттем! Сез рәхәттә яшәсен дип хезмәтче үстермәдем.

Л ә з з ә т. Мин сине, Рәйсә апа, бирнә турында сөйләшергә кергәнсең дип торам...

Р ә й с ә. Тоттырдым ди сезгә бирнә! Шиш! Кинәт бай булыр идегез бугай...

Л ә з з ә т. Соң, кызың хәерче булып яшәмәс бит инде...

Р ә й с ә. Телгә бетеп торма, яме... Әйттем – бетте! Сиңа кыз бирергә җыенганым юк!

Л ә з з ә т. Бары – бергә, югы уртак булыр инде, Рәйсә апа! Әби, дисәм, әле иртәме, Рәйсә апа? *(Себерке сабын микрофон итеп җырлый.)*
И әби, әби, әби!
Кызыңны бирәсеңме?
Бирмәсәң, урлап алам,
Син шуны беләсеңме?

Р ә й с ә *(киртәдәге бүрәнкәне ала, аны микрофон итеп, җырны дәвам итә)*.
И кияү, кияү, кияү!..
Утлы күмер кисәве!
Сиңа асыл кошымны
Бирергә юк исәбем!

Л ә з з ә т. И әби, әби җаным!
Сиңа бүтән ялынмам.
Туй көнебезгә инде

Алтын балдак алынган!

Р ә й с ә. И кияү, кияү, кияү!
Борыныңны сөрт әле...
Бик тиз өйләнәсеңә
Син ышанып бетмәле!..

Рәйсә, реверанс ясагандай итеп, күлмәк итәген җилфердәтеп ала да кызу-кызу атлап чыгып китә. Өйдән В ә с и л ә чыга.

В ә с и л ә. Нindидер тавыш килгән кебек, дим... Синме соң ул, Ләззәт улым?

Л ә з з ә т. Әти өйдәме? Нигә чакырган?

В ә с и л ә. Әтиеңне Шамил абыең алып китте. Казаннарны каршы алырга киттеләр. Сиңа атаң эт оясын күчереп куярга кушты. Күзгә төртелеп тормасын, ди.

Л ә з з ә т. Нигә? Торсын урынында. Беркемгә дә мишәйт итми бит ул. Эте юк, оясы үзе өрми... Торсын ла!

В ә с и л ә. Миңа соң... Әтиең әйткәнне генә җиткердем. Улым, Казаннан киләсе ул кешеләрне әйтәм... Алтын күкәй төшерәбез дип килүләре ди үзләренең... Юк бит... Алтын күкәй юк бит!

Л ә з з ә т. Бә-ә-әй, сине төшерерләр. Гомер буе эштән бушаганың юк... Көн димисең, төн димисең... Эшең тавык чүпләп бетермәслек. Әтине төшерерләр. Аның кебек фанатик ир-ат укытучылар авылларда сирәк ул хәзер. Акчасы юк – мәшәкате күп.

В ә с и л ә. Безне төшермәсәләр дә ярый... Менә лутчы сине төшерсеннәр. Синнән күпкә кайтыш җолдыз валчыкларын телевизордан көн саен күрсәтеп рәхәтләндерәләр бит... Рәзве син алар кебек кенә җырламыйсың? Җырлыйсы-ың!.. Бөтен шартын китереп, шигырен-такмагын да сөйлисең... Ут чыгарып биисең дә... Гармун уйнавыңны әйтмим дә!.. Фирүзәңне дә төшерсеннәр әнә... Ул да бик матур җырлый. Парлап җырларсыз әле, җәме, улым? Рәйсәнең күзе шар булсын!

Ут сүнә. Музыка.

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. К ы з ы н җитәкләп, Г ө л с и н ә керә. Койма аша Рәйсәнең башы күренеп ала.

Г ө л с и н ә. Ишегалдында беркем дә юк. Без беренче булып килдек, кызым. *(Болдырга таба атлый.)*

Р ә й с ә *(койма аша калкынып)*. Мин беренче дип алай бик сөенмә! Боларга мин бүген ике тапкыр кердем инде. Чиратны кичә кич үк алып куйдым. Списке төзесәң, Рәйсә апаңны беренче итеп яз. Син икенче булырсың.

Г ө л с и н ә. Исәнме, Рәйсә апа җаным! Нинди списке ул тагы? Нинди чират?

Р ә й с ә. Бә-әй, боларга хәзер телевизордан киләләр бит. Беркөнне Шамилнең борчак сипкәнен төшереп күр-сәттеләрме?

Г ө л с и н ә. Мин белмим. Мин күрмәдем.

Р ә й с ә. Күрмәсәң... Әллә нәрсә югалтмадың... Ни... менә шулар... Төшерүчеләр инде. Телевизордан боларны- төшерергә киләләр... Нишләп әле болар гына төшәргә тиеш?! Бездән кай җирләре артык боларның? Менә шуңа әйтәм... Кеше төшкәндә, без дә төшәбез. Мин – беренче, син икенче булырсың. Язып куй спискеңә!

Л ә й л ә *(Рәйсәгә якын килеп)*. Синең киндерсюрпризың бармы?

Рәйсә *(төче телләнеп)*. И-и-и, бигрәкләр дә матур инде үзең! *(Кинәт үзгәрә.)* Нинди киндер? Нинди приз? Бар әле, бар! Башны бутама! Бүлдермә олы кешене! Күрмисеңмени анаң белән сөйләшкәнне!.. Киндер диме шунда, клиндер диме? Клиндереңне өеңә кайткач ашарсың. Мондый җиргә килгәндә, баланы алдан туйганчы ашатып куялар аны... Син дә бала үстерәм дисеңдер инде... Ач бит балаң, бөтенләй кибеп беткән!

Г ө л с и н ә. Исең китмәсен, ач түгел ул. Әле генә... бар бит әле тиз пешә торган кибет бермишиле... Менә шуны ашады.

Р ә й с ә. Бик каты сыйлагансың икән. Җүләр. Балаңның ашказанын бетерәсең бит. Язвы желудкы ясыйсың бит ашказанына. Хет күкәй пешереп ашат, ичмасам. Әнә минеке, Мөнир абыеңны әйтәм... Тужы язвы желудкы белән тилмерә, мескенем. Әле күкәй генә ашап торып бит бу. Синең ул бермишил токмачыңны да ашаса, Мөнир абыеңа ашказанының кирәге дә калмаячак түлке.

Г ө л с и н ә. И-и, бала гына бит әле минем кызым... Ашасын. Ни тели, шуны тутырсын. Үзебез нәрсә ашап үстек инде? Ни күрдек болар кебек чакта? Бүкән чаклы калай савыттан повидло состык та каткан перәннек кимердек!.. Әтәч кәнфитен суырдык та арыш ипие ашадык! Берни булмады ашказанына да... Билләр генә интектерә башлады менә хәзер.

Өйдән В ә с и л ә чыга.

Р ә й с ә. Күп утырып торганнан ул! *(Вәсиләне күреп.)* Чыга теге. Язвы желудкы. Бая бик каты әйттем әле апаңа. Бу юлы әйтми торам. Түзәм. Телем бик кычытса да чыдыйм. Телевизорга төшәсе бар... Күлмәгемне алыштырыйм әле. *(Югала.)*

Г ө л с и н ә. Апа җаным, исән генәме? Кызым, чибәр апаң белән исәнләш!

Л ә й л ә. И-сән-ме, чибәр апа! Синең киндерсюрпризың бармы?

В ә с и л ә. Сау гынамы, үскәнем? Юк шул бернием дә.

Л ә й л ә. Нишләп юк?

Г ө л с и н ә. Кызым, бар, читкәрәк кит әле... Киндерсюрпризны өйгә кайткач үзем бирермен... Бар, бар...

Ләйлә өлкәннәр сөйләшкән вакытта үз иркендә йөри. Өйгә дә кереп, бермәл югалып тора.

В ә с и л ә. Нихәл, сеңлем! Альбертың кайттымы?

Г ө л с и н ә. Юк әле. Сотовыеннан шалтыратты. Бүген кайтырга тиеш.

В ә с и л ә. Исән-сау гына кайтсын инде берүк.

Г ө л с и н ә. Амин! Шулай булсын! Ниме соң, сәгать ничәдә киләләр?

В ә с и л ә. Кемнәр?

Г ө л с и н ә *(кулы белән читкә ишарәләп)*. Шулар инде.

Урамда кемнеңдер «Киләләр! Вәсилә апа!» дигән тавышы ишетелә.

В ә с и л ә. Уф Аллакаем! Бетте баш! *(Әрле-бирле килә.)* Өс-башым да рәтле түгел.

Г ө л с и н ә. Ярамаган тагы! *(Үзе өстендәге киемен рәт-ләштерә.)* Кигән киемең бик әйбәт әле.

Шау-гөр килгән тавышлар якыная. Капка ачыла.
Әүвәл Ш а м и л керә.

Ш а м и л *(Вәсилә белән Гөлсинәгә)*. Исәнләшергә онытмагыз! *(Капкага карап.)* Безнең авыл халкы бик культурный халык үзе болай... *(Кулларын җәеп.)* Кадерле иптәшләр, иптәш кунаклар, рәхим итегез түргә!

Капкадан а в ы л к а р ч ы г ы керә.

К а р ч ы к *(кыймыл-кыймыл атлап)*. Шушында сөйләш-тереп төшерәләрме, Шамил энем?

В ә с и л ә. Ис... исән...

Г ө л с и н ә *(Вәсиләгә төртеп)*. Ашыкма! Исәнләшми тор! Күрмисеңмени, Камиләттәй генә бит әле бу!

Ш а м и л. Ну, Камиләттәй! Ну!.. Мөгезсез сыер кебек гел син йөрерсең инде алдан! Йә, кая тыгыласың инде?! Кая тыгыласың? Кунак иптәшләрне таптап керәсең бит! Кыймылдасаң кыймылда инде җәтрәк! Юл бир хөрмәтле кунакларга! Өеңдә генә ятсаң нәрсә булган инде сиңа! *(Вәсилә белән Гөлсинәгә.)* Булышыгыз инде үзенә, ник катып торасыз? *(Карчыкка.)* Утыз ел клуб мөдире булып эшләгәнсең... Бер тамчы культураң юк!

К а р ч ы к. Дөрес әйтмисең, Шамил энем... Бер генә дә дөрес әйтмисең... Утыз бер ел эшләдем мин мөдир булып... Мин эшләгәндә...

Ш а м и л. Стоп, Камиләттәй! Синең биографияңне тыңларга вакыт юк! Утыртыгыз инде шуны түргә... Табыгыз урын! Культуралы булыгыз инде әзрәк. Рәхим итегез, мөхтәрәм кунак иптәшләр!

К е м д е р. Эткәләмәле! Өскә менәсең бит! Юл бирегез Казан кунакларына!

И к е н ч е  б е р ә ү. Алла! Ой! Аякка бастың бит!

Әүвәл Х ә б ә р ч е  х а н ы м белән Т е л е о п е р а т о р, аннары Х а ф и з, алар артын-нан ук кайсы урындык, кайсы кечкенә эскәмия тоткан к ү р ш е - к ү л ә н керә. Халык кайсы кая җайлаша.

Ш а м и л. Рәхим итегез, рәхим итегез, олы кунаклар! Түр-дән узыгыз!

В ә с и л ә. Ие, ие!

Г ө л с и н ә *(аңа төртеп)*. Исәнмесез, диген!

В ә с и л ә<br>Г ө л с и н ә *(бергә)*. Исәнмесез!

Х ә б ә р ч е  х а н ы м . Исәнмесез, исәнмесез...

Т е л е о п е р а т о р. Здрасте! *(Аппаратурасын көйли башлый.)*

Б е р е н ч е  х а т ы н. Урыс икән! Ә үзе нәкъ минем Сәмигуллага охшаган!

И к е н ч е  х а т ы н. Сәмигуллаң шабашкадан кайтып кермәде... Читтәге малаедыр әле!

Б е р е н ч е  х а т ы н. Тфү-тфү, диген. Авызыңнан җил алсын! Аныкы булырга... Сәмигулла урысча белми бит ул.

И к е н ч е  х а т ы н. Сәмигулла белмәсә, марҗалар белә урысча...

Х ә б ә р ч е *(Гөлсинәгә)*. Гафу итегез... Сез буласыздыр инде, йомырканы, алтын йомырканы тапкан ханым?

Г ө л с и н ә. Сез... булабыз инде... ие... Без буласыз... ие... Йомырканы без...

Ш а м и л. Гөлсинә! Бал корты шикелле нишләп сезләп-безләп торасың? Үз башың буталган, хет кеше башын бутама инде... *(Вәсиләгә ишарәли.)* Телеңне йоттың мәллә? Әйт инде... Мин, диген! Хафиз, хатыныңны чемет әле! Уянсын!

Х а ф и з. Вәсилә!

Х ә б ә р ч е *(телеоператорга)*. Ты готов?

Т е л е о п е р а т о р. Да.

Р ә й с ә *(чәчрәп)*. Ие, күкәйне бу хатын тапты... Мин дә шунда идем. Икәүләп таптык.

В ә с и л ә. Ие, таптык... Мин таптым.

Ш а м и л. Рәйсә, бар әле, мишәйт итмә. Синең монда бер катышың да юк.

Р ә й с ә. Нишләп булмасын, нишләп катышым булмасын? Мин беренче күрдем бит аны. Шулай бит, Вәсилә?! Әйт инде. Телевизорга минем дә төшәсе килә бит...

Ш а м и л. Бар әле, Камиләттәй янында утырып тор. Чират җиткәч, сине дә төшерерләр...

Р ә й с ә. Ничек «чират җиткәч»?! Чират башында мин бит! Мин бит кичә урын алып куйдым. Гөлсинәнең спискесендә мин беренче! Шулай бит, Гөлсинә?!

Ш а м и л. Охрана! Кайсыгыз бар анда? Алыгыз әле моны бер читкә! Иптәш хәбәрчегә сөйләшергә мишәйт итә бит. Менә шундыйлар белән яшәп ятабыз инде авылда. Гафу итегез нас! Извините безне!

Х ә б ә р ч е *(телеоператорга Вәсиләне күрсәтеп)*. В объектив, крупным планом... Короче, сам знаешь... *(Вәсиләгә.)* Шулай итеп, алтын йомырканы табучы сез буласыз инде?!

Р ә й с ә. Әйттем бит инде, ул – табучы, мин – күрүче, дидем!

Ш а м и л. Төшерәләр бит инде, ник бүлдерәсең, ә?!

В ә с и л ә. Башта исәнләшәсе мәле?

Ш а м и л. Тагын нәрсәгә исәнләшәсең, бер исәнләштең бит инде! Хафиз, әйбәтләп аңлат әле хатыныңа... Өйрәт ничек сөйләргә, ничек төшәргә икәнен... Бүтән исәнләшмәсен! Таптым, дисен дә инде... югалттым, дисен! И всё!

Хафиз Вәсиләгә нидер сөйли-сөйли, кулларын селки-селки аңлата.

Р ә й с ә *(янә чәчрәп)*. Реклама! Әйбәт гайбәт! Ак белән кара көрәше! Кайсы дөрес, кайсы ялган! Шамил Бәдриеч белән ток-шоу! Безнең нервылар какшау!

Г ө л с и н ә *(Рәйсәгә ияреп)*. Тәмле ризыклар ашыйсыгыз, татлы сулар эчәсегез киләме? Килсә, «Альберт» кибетенә рәхим итегез! Безнең адрес...

Ш а м и л *(телеоператорга)*. Стоп-стоп, товарищ! Кончайте пока! Этих, ёлки-палки, не снимайте! Они безобразничают, то есть шутки шутят! Лапши на уши вешают! *(Хатыннарга.)* Җиттеме инде сезгә! Нинди бескультурье бу, ә?!

Х а ф и з. Без әзер!

Х ә б ә р ч е. Тишина в студии! Снимаем! Стоп! *(Вәсиләгә.)* Исемегез ничек булды әле?

Х а ф и з. Вәсилә.

Ш а м и л. Вәсилә Кәшбиевна.

В ә с и л ә. Дөрес.

Х ә б ә р ч е. Нәрсә дөрес?

В ә с и л ә. Исемемне дөрес әйттеләр, мин әйтәм...

Б е р е н ч е х а т ы н *(икенче хатынга)*. Телевизорга төшәсең килсә, исемеңне ятлый тор!

И к е н ч е х а т ы н. Нәрсәсен ятлыйсың инде аның... Кем әле мин?

Х ә б ә р ч е. Менә нәрсә, Вәсилә ханым Кәшбиевна! Мин сорау бирәм, сез җавап бирәсез!..

Вәсилә *(Хафизга)*. Янда гына тор. Бергә җавап бирәсез, ди әнә. *(Гөлсинәгә.)* Син дә монда кил, сеңлем! Бергә җавап бирәбез хәзер...

Х ә б ә р ч е. Нишлисез сез, Вәсилә ханым?..

В ә с и л ә. Безме? Без җавап бирергә әзерләнәбез. *(Ләйләгә.)* Үскәнем, син дә кил монда!

Х ә б ә р ч е. Мин бит сезгә генә сорау бирәчәкмен. Һәм сез миңа җавап бирергә тиеш булачаксыз.

Ш а м и л. Гафу итегез, иптәш ханым! Болар культуралы халык булса да, күреп торасыз, «сез» дигәч аптырап калалар. *(Василәгә.)* Вәсилә, сиңа әйтәм. «Сез» дип бу ханым сиңа гына әйтә бит. Син генә җавап бирәсең, яме. «Сез» дигәнне бер дә ишеткәнең юкмы әллә?

В ә с и л ә. Барын бар да, «сез» дигәч каушата бит.

К а р ч ы к. Шамил энем, безне төшерерләр микән? Мин дә бер-ике сүз әйтерием дигән ием, Алла боерса!..

Р ә й с ә. Әле мин төшәсе бар, Камиләттәй! Тик кенә утыр чиратың җиткәнне көтеп!

К а р ч ы к. Мин кем артыннан соң?

Ш а м и л *(ачуы килеп)*. Минем арттан! Дәшми генә торыгыз инде, ә! *(Хәбәрчегә.)* Плёнкагыз беткәнче төшереп калыгыз инде бу Вәсиләне!

Х ә б ә р ч е. Тишина! Снимаем! *(Объективка күрсәтә.)* Менә монда карагыз!

Кулларын артка куеп, Ә с х ә т керә. Коймага сөялеп, әүвәл ишегалдындагыларны күзәтә, аннары игътибарын кунакларга юнәлтә.

Т е л е о п е р а т о р. Не торопитесь! *(Аппаратурасында казына.)* Чёрт побери! Сейчас, сейчас!

Х ә б ә р ч е *(телеоператор янына килеп)*. Что случилось, Артур?! Долго копаешься, сломалась что-ли?

Т е л е о п е р а т о р. Опять звук не пишет.

Х ә б ә р ч е. Приехали, значит! Что будем делать?

Т е л е о п е р а т о р. Не знаю. Ты – командир, решай сама.

Х ә б ә р ч е. Будем притворяться! Как будто у нас всё нормально. Понял?!

Т е л е о п е р а т о р. Да.

Х ә б ә р ч е. Снимаем!

К а р ч ы к *(Рәйсәгә)*. Безне дә снимаем диме?!

Р ә й с ә. Әйе. Яулыгыңны рәтлә. Сорау бирмә түлке!

Б е р е н ч е х а т ы н *(икече хатынга)*. Озакка сузылды... Кайчан безгә чират җитәр... Син нишлисең, биеп күрсәтеп төшәсеңме?

И к е н ч е х а т ы н. Юк. Биеп кенә төшәм...

Х ә б ә р ч е. Вәсилә ханым Кәбшиевна, әйтегез әле...

Ш а м и л. Зинһар, син дип кенә әйтегез үзенә!

В ә с и л ә. Кәбшиевна түгел мин, Кәшбиевна!

Х ә б ә р ч е. Гафу итегез...

Ш а м и л *(төзәтеп)*. Гафу ит...

Х ә б ә р ч е. Гафу ит, Вәсилә ханым... Кәшбиевна! Әйт әле, Вәсилә ханым... Туктагыз әле! Тукта. Мин сездән нишләп алтын йомырка турында сорыйм соң? Югалган ич инде ул, шулай бит?!

В ә с и л ә. Югалды шу-у-ул...

Т е л е о п е р а т о р. Всё нормально! Неполадок устранён!

Х ә б ә р ч е. Яхшы, Артур. Снимай всё подряд!

Т е л е о п е р а т о р. Якши!

Б е р е н ч е  х а т ы н *(нигәдер сөенеп)*. Бу урыс чын урыс булып чыкмады бугай. Татарча да белә... Якшы, ди бит әнә! Башта гына шулай тоелган икән... Сәмигуллага әллә ни охшамаган бу!

И к е н ч е  х а т ы н. Әйе шул. Сәмигуллага охшамаган. Ну, Сәмигуллаң үзе малаена тучны охшаган! *(Көлә.)*

Б е р е н ч е  х а т ы н. Котыртмале!

Х ә б ә р ч е *(телекамерага күрсәтеп)*. Менә монда карап сөйләгез! Әйбәт сөйләсәгез дә, әйбәт сөйләмәсәгез дә камера яздырып барачак! Зинһар өчен, үтенәм, камераны вата күрмәгез. Артур, поставь камеру на штатив! *(Шамилгә.)* Зинһар, Шамил Бәдриевич, күз-колак булып, командир булып торыгыз әле, яме! Мин хәзер киләм... Мин монда гына... *(Башкаларга сиздерми генә читкә китә.)*

Телеоператор камераны сәхнә алдына куя. Сәхнәдәгеләр, камерага сөйлим дип, залдагы тамашачыларга карап сөйлиләр. Аларның сөйләгәнен сәхнә түренә эленгән экран да кабатлап бара.

Ш а м и л *(телеоператорга)*. Пока не снимайте! Уже снимаете? Ладно, алайса снимайте! Иптәшләр! Хөрмәтле авыл кешеләре! Даваегыз, матур итеп кенә... үзебезнең матур эшләребез турында сөйлик әле! Белсеннәр безнең матур эшләребез турында бөтен дөньяда! Күрсеннәр! Соклансыннар! Менә бит нинди матур кешеләр ничек матур итеп яшәп яталар икән! дисеннәр... Бик матур авыллары да бик матур җирдә икән! дисеннәр... Берәрегез әгәр белсә... бар бит әле шундый бер җыр... Ничек әле? Кайда Ләззәт? Ул юкмыни монда? Ләззәт белергә тиеш ул җырны... *(Көйли, такмаклый.)* «Матур эшләребез бар, якты теләгебез бар... Идел төсле... әллә нишли белмәс... ярсу йөрәгебез бар...» Менә шуны берәрегез җырласа, бигрәкләр дә шәп була!..

Сәхнәдә ут караңгылана төшә. Яктылык Хәбәрче ханымны яктырта. Хәбәрче ханым Әсхәт янына якынлаша.

Х ә б ә р ч е. Исәнме, Әсхәт!

Ә с х ә т. Исәнме... Сәлимә! Син... мине таныдыңмыни?!

Х ә б ә р ч е-С ә л и м ә. Танымаска! Син тамчы да үзгәр-мәгәнсең, Әсхәт...

Ә с х ә т. Син дә үзгәрмәгәнсең.

С ә л и м ә. Син элек алдашмый идең, Әсхәт... Мин үзгәрдем, еллар үз эшен эшли.

Ә с х ә т. Син тагы да матурлана төшкәнсең, Сәлимә... Дөресен әйтәм... Чын менә! Хәер, матурлана төшкәнсең дип алдашам... Моңарчы

сине бер дә күрмәгән кеше кебек кыланам... Мин бит сине көн саен диярлек күреп тордым. Мин синсез яшәдем... Әмма синсез дә яшәмәдем. Бу чәчәкләр сиңа, Сәлимә! *(Артына яшереп торган чәчәкләрне Сәлимәгә суза.)*

С ә л и м ә. Чәчәкләр?! Миңамы? Аһ... Әйе бит әле... Син бит минем киләсемне белгәнсең... Рәхмәт, Әсхәт. Нинди матур чәчәкләр!

Ә с х ә т. Безнең авыл чәчәкләре!

С ә л и м ә. Үзеңне күреп торсам да, мин дә синсез яшәмәдем, Әсхәт. Һәрвакыт уемда син идең дип үк әйтмим, чөнки үзең беләсең кавышмыйча аерылышуыбыз сәбәбен...

Ә с х ә т. Эш... эш... эш... Синең өчен беренче урында эш иде шул. Мәхәббәт түгел иде. Хәтерлисең микән, мин сиңа бер шигырь сөйли идем... Дәрдеменд шигырен.

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан...

С ә л и м ә *(дәвам итеп)*.

Биткәенең иң очында миң яраткан...

Ә с х ә т
С ә л и м ә *(бергә)*. Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан!

С ә л и м ә. Исемдә, исемдә... Ул чакны минем чәчләрем озын иде шул! Менә тагын үстерә башладым... Мин хәзер яшьлегемне сагынып яшим... Ялгышымны соң аңладым шул...

Ә с х ә т. Ялгышны төзәтергә беркайчан да соң түгел, Сәлимә...

С ә л и м ә. Мин сине күрер өчен махсус килдем, Әсхәт.

Ә с х ә т. Алтын күкәй сәбәп кенә булганын мин аңладым, Сәлимә.

Сәхнә яктыра.

К а м и л ә т т ә й *(камерага, ягъни залга карап сөйли)*. Сигезенче Мартта да, картлар көнендә дә гел мине онысталар!.. Беркем бернәрсә бирми. Бөтенесенә бирәләр, миңа жук. Үткәнендә Сәлихага ярты кило писүк бирделәр... миңа жук. Зөләйхага ярты кило карабодай калдырып киттеләр... Миңа әпәйт жук. Мөслимәгә кер сабыны бирделәр, мине искә дә алучы жук.

Ш а м и л. Бирербез, бирербез. Тукта инде. Син бит культура кешесе. Клуб мөдире. Онытканбыздыр инде. Пажалысты, гафу ит! Бүген үк бер кило писүк, бер кило карабодай и бер кило кер сабыны китерермен. Лично үзем! Артыгын сөйләмә генә, зинһар, пажалысты!

К а м и л ә т т ә й. Гафу итәм алайса. Зәмзәмияләрдә бер-көнне бик тәмле чәй эчтем... Әкбәр чәе, диде Зәмзәмия. Сиңа әйтәм, кем, Шамил энем, бик тәмле икән Әкбәр чәе! Узган ел өчен булыр, мин әйтәм... Дөрес әйтәмдер бит?!

Ш а м и л. Дөрес-дөрес. Бирермен. Китерермен. Эчәрсең дә эчәрсең.

Р ә й с ә *(телекамерага карап)*. Төшергәндә төшәргә кирәк. Рәйсә Габдерәхим кызы Сәетгәрәева. Мин булам инде. *(Башын иеп ала.)* Җыр!
Алларын алыйм әле,
Гөлләрен алыйм әле...
Җырла-җырла дип әйтмәсләр,
Бер җырлап калыйм әле...

Алларга төрим әле,
Гөлләргә төрим әле...
Музейда йөргән шикелле,
Кибеттә йөрим әле...

Алларга манам әле,
Гөлләргә манам әле...
Өч тиенлек хезмәт хакың –
Шуны да санамале...

Алларын алам әле,
Гөлләрен алам әле...
Мин күтәргән бәя түгел –
Акаеп карамале...

Г ө л с и н ә *(кызын чакыра)*. Кызым, Ләйлә, кил әле! Әйдәле, җырлап күрсәт әле. Сәхнәдә Ләйлә Альбертовна... Альбертовнасы кирәкмидер, име? Сәхнәдә Ләйлә Шәңгәрәева! Булачак якты йолдыз! Иң яктысы булыр әле, Алла боерса! Әйдә, кызым!

Л ә й л ә. Яратам дип җырлыйммы?

Г ө л с и н ә. Сорап торма болардан, мин әйткән икән – җырла! Безнең чират хәзер!

Л ә й л ә. Яратам, яратам,
Яратам, яратам!
Мин сине барыбер
Үземә каратам!

Барысы да гөрләтеп кул чаба.

Г ө л с и н ә. Маладис, кызым! Без булдырдык! Следующий!

Л ә з з ә т, Ф и р ү з ә, М ө н и р керә. Ишегалдындагы тамашага шаккатып карап торалар.

Б е р е н ч е х а т ы н *(икенче хатынга)*. Җырлый белми-сең инде... Әллә ут чыгарып биеп аласыңмы?

И к е н ч е х а т ы н. Ә нигә биемәскә? *(Теттереп бии башлый.)*

Мөнир Әсхәт янына килеп нидер әйтә.

Б е р е н ч е   х а т ы н. Сәмигулла күренмиме? Күренми бугай ла!.. *(Ул да биергә тотына.)*

К е м д е р *(шаяртып)*. Сәмигулла килә!

Б е р е н ч е   х а т ы н *(биюдән шып туктап)*. Беттем, беттем, беттем!.. Сәмигулла күрсә үтерә!

Р ә й с ә. Нишләп куркасыңдыр шул самогон бүчкеңнән! Һич аңламыйм!

Б е р е н ч е   х а т ы н. Кеше алдында биергә кушмый. Өйдә, минем каршымда гына бие, ди.

Р ә й с ә. Биисеңме?

Б е р е н ч е   х а т ы н. Биемәсәң... биетә!

Көлеш. Ләззәт белән Фирүзә Рәйсә янына килә.

Л ә з з ә т. Рәйсә апа, без өйләнешергә булдык! Мөнир абый ризалыгын бирде. Синең ризалыгыңны көтәбез.

Р ә й с ә. Мин әйттем бит инде: мин риза түгел!

Ф и р ү з ә. Әни, син минем бәхетле булуымны телисеңме?

Р ә й с ә. Бәхетле булсын дип тырышам бит.

М ө н и р *(Рәйсә каршына килеп)*. Цветы – в студию! Чәчәкләрне – студиягә!

Ә с х ә т бер кочак чәчәк тотып керә. Мөнир, чәчәкләрне алып, аларның бер өлешен яшьләргә тоттыра, икенче өлешен үзендә калдыра.

М ө н и р. Тыңла, Рәйсәм! Сиңа багышлап шигырь яздым! «Чын сөю» дип атала. *(Сөйли.)*

Чын Сөюнең  
бар икәнен белгәч,  
гел яшисе килде сөелеп...  
Җилдәй җилеп,  
гөлдәй көлеп  
яшим,  
Синең барлыгыңа сөенеп!

Чын сөюнең  
Син икәнен белгәч,  
иркәләндем, сиңа сыенып...  
Иртәләрем-кичләремдә  
яшим,  
Синең барлыгыңа сөенеп!

Чын Сөюнең  
Без икәнен белгәч,

йолдыз яуды җанга сибелеп...
Бәхет кошын
тоткан кебек
яшим,
Синең барлыгыңа сөенеп!
*(Чәчәкләрне Рәйсәгә бирә.)*

Р ә й с ә *(күз яшьләрен сөртеп)*. Син мине җылаттың, Мөнир! Мин сине аңладым, Мөниркәем! *(Кочаклашалар.)* Мин... Без... *(Яшьләргә карый.)* Без риза!

Л ә з з ә т. Ур-ра! *(Фирүзәне кочаклап ала.)*

Ф и р ү з ә. Рәхмәт, әнием! Рәхмәт, әтием! *(Башта әнисен, аннары әтисен кочаклый.)*

Ләззәт кесәсеннән алтын күкәй чыгара.

Һ ә м м ә с е. Алтын күкәй?! Табылды!

Ш а м и л. Югалмаган да булгандыр әле ул...

Л ә й л ә *(Ләззәт янына килеп)*. Минем дә синеке шикелле киндерсюрпризым бар!

Ләйлә кулындагы алтын күкәйне күреп, барысы да таң кала.

Ш а м и л. Икәү?! Минем күземә генә күренәме болар?

Г ө л с и н ә. И-и, кызым, башта әниеңә күрсәтәләр аны!

Л ә з з ә т *(Ләйләгә)*. Каян алдың син моны?

Л ә й л ә *(өйгә ишарәләп)*. Өйдән таптым. Чыршы бизи торган уенчыклар яныннан алдым мин моны. Тартмадан!

В ә с и л ә *(исе китеп)*. Әйе шул! Нәкъ шунда куйган идем! Вәйт тишек хәтер диген!

Ф и р ү з ә. Син ниндидер сюрприз турында әйткән идең, Ләззәт! Нинди сюрприз иде ул?

Л ә з з ә т *(Ләйлә кулындагы күкәйне алып, аның белән нәрсәдер эшли дә эченнән ике балдак чыгара)*. Менә ул сюрприз!

Л ә й л ә *(шатланып)*. Әнием, бу чынлап та киндерсюрприз!

Ш а м и л *(сыкранып, көйләп)*. «Юллар, юллар, харап булды юллар...» Теге икенче күкәең дә чын түгелме?

Ләззәт икенче «алтын күкәй»нең эченнән янә пар балдак ала.

Х а ф и з *(һич ышанасы килмичә)*. Мин башта ук шулай буласын белгән идем... Ышанмаган идем! И-и-их! Ну, ничава... Иң мөһиме, балалар бәхетле булсын!

Ш а м и л. Юллы булып булмасмы дигән идем... Күкәе күкәй төсле булмады. *(Кулын селти.)* Нәрсә, икенче пар балдак запаска шту ли?

К а м и л э т т э й *(Рәйсәгә төрткәләп)*. Карале, әллә берәр нәрсә бирәләрме? Кемнәргә бирәләр? *(Рәйсә дәшмәгәч.)* И-и-и, син дә ишетмисең икән... Ишетмәгәч, бик кыен инде ул...

Л ә з з ә т. Югалгач, икенчене эшләткән идем шул. Балдакларны да яңадан сатып алдым.

Ә с х ә т. Каяле, тотып карыйм әле... Нинди була икән ул балдак дигәннәре! *(Балдакның берсен киеп карый.)* Миңа таман гына бу! *(Икенчесен Сәлимәнең бармагына кидерә дә Сәлимәне үбеп ала.)* Әллә ярады инде?! *(Ләззәткә.)* Акчасын соңыннан бирермен...

Ш а м и л. Сез туктагыз әле, нәрсәдер темнить итәсез бугай?! *(Әле Әсхәткә, әле Сәлимәгә карап.)* Сез бит моңарчы да бер-берегезне белгәнсез, иптәш-товарищлар!

Ф и р ү з ә. Хәтерлисеңме, Ләззәт? Мин аны пачти көн саен күреп торам, дигән иде Әсхәт абый... *(Әсхәткә.)* Менә кемне күздә тоткан булгансың икән, Әсхәт абый!

М ө н и р. Цветы – в студию!

Түбәтәй кигән м а л а й бер кочак чәчәк күтәреп керә. Ул чәчәкләрнең яртысын Мөнир Сәлимәгә бирә, яртысын түбәтәйле малай Әсхәткә тоттыра.

М ө н и р *(Әсхәт белән Сәлимәгә)*. «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә... ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта!» Чын күңелдән котлыйм сезне! *(Ләззәт белән Фирүзәгә.)* Балалар, сезне дә котлыйм!

В ә с и л ә *(Хафизга сыенып)*. Бәхетле булыгыз, балалар!

Ш а м и л. Яшьләр кала авылда... Болай булса, юлы да салыныр, тормыш итүләре дә җайланыр!

Х а ф и з. Алтын күкәйгә рәхмәт. *(Вәсиләгә карап, көй-ләп куя.)* Рәхмәт сиңа, Тавык түтәй...

Ш а м и л. Ял итәрмен дигән идем. Бу арада бәйрәм дә бәйрәм китте әле. Әз капсаң да нехорошо, күп капсаң да нехорошо. *(Телеоператорга.)* Так ведь, дорогой?

Т е л е о п е р а т о р. Лучше сейчас, чем никогда!

Көлеш.

Х а ф и з *(Ләззәткә)*. Җырлале, улым!

М ө н и р. Кызым, син дә кушыл, яме!

Рәйсә *(Вәсиләгә)*. Кодагыйкаем, кушымтасына булса да без дә кушылабызмы?

В ә с и л ә. Кушылабыз, кодагый, кушылабыз...

М ө н и р. Шәпме, кода?!

Х а ф и з. Шәп, кода!

Л ә з з ә т *(җырлый башлый)*.

Кичке җиләс һава,

Зәңгәр эңгер-меңгер...

Фирүзә *(кушыла)*.

Ике гашыйк ярда,
Алар – синдер, миндер...

Җырның кушымтасын кабатлаганда барысы да кушыла.

Язмышыбыз агышлары,
Табышлары – безнең кавышу.
Ялгышларсыз, сагышларсыз
Яши алсак иде – бары шул!

Ләззәт
Фирүзә *(сәхнә алдына килеп, җырламыйча гына)*.

Сулар, еллар агар... без яшәрбез,
Без яшәрбез янып, хисләнеп...
Һәм дәшәрбез икәү, ярга басып:
– Безнең сөю һаман исән! – дип.

Музыка дәвам итә.

Пәрдә.

*2006*

**Балалар өчен әкият-пьесалар**

# ЧӘПӘЛӘЙ ҺӘМ ТӘПӘЛӘЙ МАҖАРАЛАРЫ

КАТНАШАЛАР:

Әкиятче.
Тылсымлы агач.
Чәпәләй.
Тәпәләй.
Һауһауҗан.
Мырау.
Мыргали.

**БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Пәрдә алдына Әкиятче чыгып баса.

Әкиятче *(залдагы балаларга)*. Исәнмесез, балалар!

Балалар. И-сән-ме-сез!

Әкиятче. Телисезме, балалар, мин хәзер әкият сөйлим сезгә?

Балалар. Телибез, телибез!

Әкиятче. Шыттыр-мыттыр, фаласа – сөйли башлыйм алайса...
Баллы икән алмагыз,
Ачы икән тормагыз...

Әкиятем – булган хәл:
Авыз ачып тыңлагыз!
Бүген-кичә үткәндә
Һәм берсекөн җиткәндә,
Мин әле сабый чакта,
Син әле абый чакта,
Ул әле малай чакта,
Әтиләр бабай чакта,
Нәниләр әни чакта
Булган, ди, мондый хәлләр...

Ут сүнә. Әкиятче югала. Акрын гына пәрдә ачыла.
Сәхнәдә – авыл күренеше: ишегалды, өйнең бер тәрәзәле өлеше күренеп тора – тәрәзә ачык, телевизорда мультфильм бара, ахры.
Бүре тавышы ишетелә: «Ну... Ну... заяц, по... погоди!»
Сиртмәле кое. Эт оясы. Оя янында Һауһауҗан йокы симертә. Койманың теге ягында да, бу ягында да агачлар күренә.
Коймага велосипед сөялгән. Салмак кына шомлы-сихри көй агыла башлый. Кинәт ишегалдындагы бер агач «әллә нишли» – ул калтырарга-дерелдәргә тотына... Көй көчәя. Агач шулвакыт яшел җен-паригә әйләнә. Дөресрәге, ул Тылсымлы агачка әверелә.

Тылсымлы агач. У-у-ух! *(Ачык тәрәзә янына килә.)* Туйдырды бу ялкау мәченең бот күтәреп, телевизор-ны өзлексез каравы! У-у-ух! *(Йоклап яткан эт янына килә.)* Туйдым бу ялкау этнең йокы бүсеп ятуыннан! У-у-ух! Нишләтергә инде боларны, ә? Берсе өзлексез шульти-мульти карый, икенчесе көне-төне төш күрә. Тфү, ата ялкаулар! Тәмам эшлексезгә әйләнделәр... Ичмасам, укый-яза да белмиләр бит. Бер-бер чара күрмичә булмас бу ялкауетдиннәргә!

Кинәт Һауһауҗан гырлый башлый.

Кара инде монысына, карагыз инде моның гырлавына!.. Трактормыни! Туктатмасаң, бензине беткәнче гырлаячак бу. *(Янына килеп, Һауһауҗанны селкеткәли.)* Әлү, әлү, Ялкауетдин Тракторович!.. Сүндер моторыңны!

Этнең танавыннан тарта, Һауһауҗан гырлавыннан туктый,
икенче якка борылып ята.

Менә шулай... Ичмасам, гырлавыннан туктады. Бу-у-у... Өстенә менеп «Ламбада» биесәң дә уянмый бу! Юри генә биеп карыйм әле...

«Ламбада» биюе көе агыла. Тылсымлы агач Һауһауҗан өстенә менеп биергә тотына. Бераз хәрәкәтләнгәч туктый.

Ю-юу-ук, боларга чыннан да бер-бер чара эшләмичә булмастыр. Мин бу Йокысимертәевич белән Мультфильмкараевичны мәзәк итәм болай

булгач... Тылсымыңны бик кирәк чакта гына файдаланырсың дигән иде Йөзьяшәр Агач бабам... Кулланырга туры килер, ахры... Тә-ә-әк... Башлыйм алайса... Әфсен-төфсен, чәфсәләй... Финус-кинус, фәсмәрәй... Дөмберт-мөмберт, дәфлитән, авызыңа чап итәм...

Тылсымлы агачның күлмәк яфракларында сүзләр пәйда була.

Әһә, булды шикелле! Әгәр бу Ялкауетдин-Наданетдиннәр монда язылганнарны укый алса, шул чагында гына алар үз халәтләренә кайта алырлар... *(Тәрәзәгә карап, сихри сүзләр әйтә.)* Ечәм-ечәм, фәс-перәс, накчый-накчый, чи-чипес! *(Һауһауҗанга карап, кулларын әллә ниләр кыландыра.)* Һаудыр-һаудыр, асмалай.

Кинәт Тылсымлы агач, әүвәлге халәтенә кайтып, агач булып катып кала. Өй эчендә дөбердәгән, мияулаган тавышлар ишетелә. Ул да булмый, тәрәзәдән башта М ы р а у сикереп чыга, аның артыннан Ч ә п ә л ә й, Т ә п ә л ә й. Ишегалды буйлап куышалар.

Ч ә п ә л ә й. Качма, Мырау, качма, барыбер тотам мин сине!

М ы р а у. Сез түгел, мин сезне куарга тиеш! Мин ашарга тиеш сезне! Белдегезме? Мин мәче чөнки!..

Ч ә п ә л ә й. Юк, син мәче түгел. Син – тычкан! Ә без – мәчеләр!

Т ә п ә л ә й. Әйе, син – тычкан! Ә без – мәчеләр!

М ы р а у. Юк-юк, мәче мин! Мин сезне ашарга тиеш!

Ч ә п ә л ә й. Ашамыйча гына тор әле! Җә ашаган дияр-ләр...

Т ә п ә л ә й. Әйе, ашамыйча гына тор, яме! Без сине үзебез ашыйбыз. Менә хәзер тотабыз да ашыйбыз!

М ы р а у. Якын гына килеп карагыз... Бетерәм мин сезне. Мин – каратист! Мин – кара пояслы мәче, беләсегез килсә!

Ч ә п ә л ә й. Шыттырма, Мырау! Мин ул кара пояслы мәче! Шулай бит, Тәпәләй?!

Т ә п ә л ә й. Әйе, мин ул кара пояслы каратист. Ә Чәпәләй – сары пояслы!

Ч ә п ә л ә й. Син нәрсә, Тәпәләй?! Мин ул кара пояслы!

Т ә п ә л ә й. Әйе, мин ул – кара пояслы!

Ч ә п ә л ә й. Ярар алайса, икебез дә кара пояслы. *(Мәчегә.)* Ишеттеңме, куркак? Без – каратистлар. Без сине хәзер айн-цвайн итәбез... Хи-и-а!

Ул, каратэ күрсәтәм дип, ялгыш Тәпәләйгә тибә. Тәпәләй мәтәләп китә. Мырау агач артында эчен тотып хихылдый.

Т ә п ә л ә й. Син нәрсә, Чәпәләй?! Миңа типтең бит!

Ч ә п ә л ә й. Типмәдем мин сиңа. Син үзең ялгыш минем аякка эләктең.

Т ә п ә л ә й. Эләкте, әйе. Күзләреңне ачып аен-цваенла инде.

Ч ә п ә л ә й. Ярар, җыламасана. Бер типкәннән мәче үлми. Әнә теге куркак тычканны тотарга булыш, ичмасам.

М ы р а у. Тотмый гына торыгыз әле. Хәзер мин сезнең үзегезне тотам. Агач артыннан гына чыгыйм.

Тагын куыша башлыйлар.

Ч ә п ә л ә й. Яхшы чакта тукта, дим, Мырау. Әгәр тук-тамасаң, белеп тор, без синнән кәтлит ясыйбыз!

Т ә п ә л ә й. Пилмән, диген, Чәпәләй. Пилмән яратам мин.

Ч ә п ә л ә й. Кәтлит дигәч кәтлит инде. Мин пилмән камыры яратмыйм.

М ы р а у *(кое бурасы артыннан калкынып)*. Ә мин тотсам, беләсезме, нишләтәм сезне? Мин сезне каклыйм, тозлыйм, табада кыздырам, белдегезме?

Ч ә п ә л ә й. Уф, көлеп үләм! Кем кемне куа соң әле монда?

Т ә п ә л ә й. Әйе, монда кем кемне куа соң әле? Минме, әллә синме?

Ч ә п ә л ә й. Мин, кәнишне!

Т ә п ә л ә й. Юк, мин куам! Күрмисеңмени, тирләп беттем инде.

Ч ә п ә л ә й. Мин күбрәк тирләдем.

М ы р а у. Юк, күбрәк мин шыбыр тиргә баттым. Димәк, мин сезне куам булып чыга.

Ч ә п ә л ә й. Чыга-чыга. Тычкан башың белән күп сөй-ләшеп тор әле, җәме! Хәзер капут ясыйм.

Т ә п ә л ә й. Әйе, ачуны китермә безнең! Капут сиңа хәзер! Ишеттеңме, мерсимадам?

М ы р а у *(кулын югары күтәреп)*. Напасаран! Хәл генә җыйыйм. Бетерәм мин сезне!

Ч ә п ә л ә й. Тәпәләй, син теге яктан чамала, мин бу яктан... Атакага, ур-р-ра!

Т ә п ә л ә й. Ур-р-ра!

Мырау кое өстенә менеп баса. Сиртмә чылбырына эленгән чиләккә ябыша һәм дөбердәп коега төшеп китә.

М ы р а у *(тавышы коедан ишетелә)*. Коткарыгыз, ба-та-ам!

Чәпәләй белән Тәпәләй иелеп коега карыйлар.

Ч ә п ә л ә й. Әйттем мин сиңа, Мырау. Качма, дидем.

Т ә п ә л ә й. Әйе, әйттем мин сиңа, Мырау!

М ы р а у. Кот-ка-ры-гыз!.. Үлә-ә-әм...

Ч ә п ә л ә й. Бераз тагын коен инде, Мырау. Без сине пычрак килеш ашый алмыйбыз бит.

Т ә п ә л ә й. Әйе, юын бераз. Безгә ги-ги-ена сакламыйча һич ярамый. Тешләр бозыла алайса.

Ч ә п ә л ә й. Диз-зен-терия, диген...

Т ә п ә л ә й. Әйе, диз-зен-терия була алайса...

М ы р а у. Кот... кот... ыгыз!.. Зин... зин... һар!..

Ч ә п ә л ә й. Чыгарыйк, булмаса, Тәпәләй... Тотын чылбырга!

Т ә п ә л ә й. Әйе, чыгарыйк, Чәпәләй. Тотын син дә чылбырга!

Икәүләп чылбырны өскә тарта башлыйлар.

Ч ә п ә л ә й. Ай-яй авыр икән бу Мырау. Бер центнер бардыр.

Т ә п ә л ә й. Бер тунны, диген!..

Ч ә п ә л ә й. Коеның суын эчеп бетергән бугай бу?!

Т ә п ә л ә й. Бетермичә! Ул хәтле акыруына! Төптәге ләмне дә йотмаса ярый әле...

Ч ә п ә л ә й. Иренмичә син аш пешерсәң, ашка су салып торасы булмый инде. Хи-хи-хи-хи... Иеме, Тәпәләй?

Т ә п ә л ә й. Ие, Чәпәләй. Ите дә, суы да Мырауның үзендә. Хи-хи-хи...

Мырауны көч-хәл белән өскә чыгаралар да җиргә төшереп яткыралар. Чәпәләй Мырауның битенә суккалый.

Ч ә п ә л ә й. Әллә үлгән инде?

Т ә п ә л ә й. Йөгереп килеп бер тибимме эченә? Хәзер терелә!

Ч ә п ә л ә й *(колагын Мырауның күкрәгенә, йөрәк турысына куеп тыңлый)*. Үлмәгән әле. Тибә йөрәге, дөп-дөп итә...

Т ә п ә л ә й. Дөп-дөп итеп кул белән бер тибимме? Юкса бик яман кул кычыта башлады.

Ч ә п ә л ә й. Ахмак син, Тәпәләй. Кул белән тибәләр димени?

Т ә п ә л ә й. Алайса, аяк белән берне сугам...

М ы р а у *(күзләрен ачып)*. Мин кайда?..

Т ә п ә л ә й *(кулын наган сыман итеп, Мыраугa тибә)*. Хенде хох, мерсимадам!

Эт оясы янында яткан Һауһауҗан куркуыннан сикереп тора,
кулларын күтәрә.

Һ а у һ а у җ а н *(кычкырып җибәрә)*. Бә-ә-ә!..

Чәпәләй белән Тәпәләй аңа борылып карыйлар да көлеп җибәрәләр.

Т ә п ә л ә й. Сиңа әйтмим мин, йокы бүксәсе! Гырлавыңны бел!

Һ а у һ а у җ а н *(кулларын төшереп, күзләрен уып ала)*. Ни булды, ә?

Ч ә п ә л ә й. Тик кенә ят, яме! Юкса сине дә коега чумдырып алырга күп сорамабыз.

Т ә п ә л ә й. Әйе, без сорап-нитеп тормыйбыз. Айн-цвайн! Әллә синең дә су эчәсең киләме? Килсә, чумдырып алам мин сине.

Ч ә п ә л ә й. Тәпәләй, телеңне әрәм итеп сөйләшмә! Ул болай да чылбырда. Качмас. Монысын бәйләп куярга кирәк. Бар, тиз генә бау алып кил!

Тәпәләй бау эзләп китә.

Һ а у һ а у ж а н. Бә-ә-ә... Сез... Сез... Нишлисез сез?

Ч ә п ә л ә й. Тире иләп, күн эшлибез! Күрмисеңмени, ахмак тәкә, ашка ит әзерлибез бит. Тычкан ите!

Һ а у һ а у ж а н. Бә-ә-ә... Кем тәкә, чикылдык, минме? Кем тәкә?

Ч ә п ә л ә й. Син булмыйча, мин булмам инде... Әйе, син – тәкә! Ә менә бу *(ул Мырауга типкәләп ала)*, бу – тычкан. Олы тычкан!

М ы р а у *(аңына килеп)*. Мин... мин... тычкан?! Юк, мин тычкан түгел... Мин – мәче... Мин – Мырау!

Мырау торырга азаплана. Бау күтәреп, Т ә п ә л ә й килеп җитә.

Т ә п ә л ә й. Хенде хох, мерсимадам! Урыныңнан кузгалма! Юкса баш белән берне сылармын!.. *(Чәпәләй белән икәүләп Мырауны бәйлиләр.)*

Ч ә п ә л ә й. Тизрәк бәйлик. Йә тагын качар...

Һ а у һ а у ж а н. Нишләттегез Мырауны? Бауны чишегез хәзер үк! Бә-ә-ә...

Ч ә п ә л ә й. Һай, куркытты берәү! Һай, бер мыегым селкенде...

Т ә п ә л ә й. Чәпәләй, барып тибимме шуның авызындагы радиуына? Баш белән... Баш кычыта башлады... *(Башын кашып ала.)*

Ч ә п ә л ә й. Ашыкма, башта бу тычкан белән эшне бетерик инде...

М ы р а у. Мин тычкан түгел... Сез – тычкан! Мин – мәче! Һауһауҗан, әйт әле, мин мәче бит, әйеме?

Һ а у һ а у ж а н. Әйе, син – мәче. Мәче булмыйча, кем буласың инде син тагы!

М ы р а у. Күрдеңме, Һауһауҗан мине, мәче, диде.

Ч ә п ә л ә й. Дисә ни. Ул ахмак тәкә ни әйтмәс.

Т ә п ә л ә й. Әйе, ул дивана тәкә ни сөйләмәс.

Һ а у һ а у ж а н. Нинди тәкә булыйм ди мин! Мин – эт, эт мин! Һау-һау!

Ч ә п ә л ә й. Өрә белгән тәкә син! Белдеңме, менә кем син!

Т ә п ә л ә й. Әйе, белдеңме инде менә?!

Һ а у һ а у ж а н. Мырау, әйт әле, мин кем?

М ы р а у. Син – эт, ә мин – мәче!

Һ а у һ а у ж а н. Ишеттегезме инде, чикылдыклар? Мин – эт!

Ч ә п ә л ә й. Болар тәмам ычкынганнар, име, Тәпәләй. Һаман үзләренең кем икәнлекләрен аңламыйлар...

М ы р а у *(залдагы балаларга дәшеп)*. Балалар, әйтегезсана, мин мәче бит, әйеме?

Б а л а л а р. Әйе, мәче!

Һ а у һ а у ж а н. Ә мин, балалар, мин эт бит?!

Б а л а л а р. Әйе, эт син, эт!

М ы р а у<br>Һ а у һ а у ж а н *(бергә)*. Ишеттегезме?

Ч ә п ә л ә й. Юк, ишетмәдек. Без бит саңгыраулар. Име, Тәпәләй?

Т ә п ә л ә й. Әйе, без саңгыраулар! Без берни дә ишетмибез. Чәпәләй, син нәрсә дидең?

Ч ә п ә л ә й. Нәрсә дисең, Тәпәләй? Колак берни ишетми. Ашыйсы килә, дисеңме?

Т ә п ә л ә й. Ә? Ишетмим! Әйе, «Ашыйсы килә, дисеңме?» дигәнеңне ишетмим.

Ч ә п ә л ә й. Мин дә синең «ишетмим» дигәнеңне ишетмим. Табибларга күренмичә булмас, Тәпәләй.

Т ә п ә л ә й. Әйе шул. Ишетмәгәч бик кыен. Барырга кирәк табибка.

Ч ә п ә л ә й. Киттек, Тәпәләй!

Т ә п ә л ә й. Ишетмим! Вилсәпид белән китәбезме?

Ч ә п ә л ә й. Әйе! Ишетмәгәч кыен шул. Кайткач, аш пешерербез. Бүген – мәчедән, иртәгә – тәкәдән...

Велосипедка икәүләп атланалар. Чәпәләй рульне тота.

Ч ә п ә л ә й. Пока!

Т ә п ә л ә й. Чау, мерсимадам!

Җырлый-җырлый әйләнеп йөриләр.

## И К Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш

Шул ук ишегалды. М ы р а у бәйләнгән килеш, Һ а у һ а у җ а н чылбырда килеш үз урыннарында яталар. Икесенең дә башлары түбән иелгән. Т ы л с ы м л ы  а г а ч кинәт телгә килә.

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Йә, ничек хәлләрегез?

Мырау да, Һауһауҗан да бер үк вакытта сискәнәләр.

Һ а у һ а у җ а н. Син дәштеңме, Мырау?

М ы р а у. Юк, мин түгел. Ә мин син дип торам.

Һ а у һ а у җ а н. Син дә, мин дә булмагач, кем дәште соң алайса?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Мин дисәм ни әйтерсез?

Мырау да, Һауһауҗан да Тылсымлы агачка текәләләр.

Һ а у һ а у җ а н<br>М ы р а у *(бергә)*. Син?!

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Әйе, мин, мин! Ник шаккаттыгыз?

М ы р а у. Син... сөйләшә беләсеңмени?

Һ а у һ а у җ а н. Гаҗәп! Агач сөйләшкәнне беренче мәр-тәбә күрәм.

М ы р а у. Син кем? Әй, сорап торам тагы. Син агач бит инде.

Һ а у һ а у җ а н. Безнең күз алдында үсте. Бер тапкыр да сөйләшкәне булмады. Ә бүген сөйләшә. Гаҗәп!

М ы р а у. Гаҗәп кенә түгел бу, могҗиза! Гап-гади агач булып агач сөйләшсен инде...

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Мин гади агач түгел, беләсегез килсә... Мин – Тылсымлы агач!

Һ а у һ а у җ а н. Тылсымлы?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Әйе, Тылсымлы агач.

М ы р а у. Алай бик тылсымлы да булгач, әйт әле безгә: кем безне мондый хәлгә төшерде?

Һ а у һ а у җ а н. Әйе, әйт безгә: өтек кенә тычканнар ни сәбәпле безне мәсхәрә итте?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Тычканнар түгел, сез үз-үзегезне көлкегә калдырдыгыз.

М ы р а у. Ничек инде – без?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Шулай. Бик гади. Әгәр сез үтә ялкау булмасагыз, укый-яза белсәгез, мондый хәлгә тармый идегез. *(Мырауга карап әйтә.)* Син тычканнардан дер калтырап тормас идең. *(Һауһауҗанга карый.)* Ә син тәкә төсле бәәлдәп ятмас идең...

М ы р а у. Беренчедән, мин ялкау түгел. Икенчедән, әгәр мин син уйлаганча ялкау икән, аннан кемгә зыян?

Һ а у һ а у җ а н. Әйе, безнең укый-яза белмәвебездән кемгә зыян?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Үзегезгә!

М ы р а у. Ничек инде үзебезгә?

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Соң, башыгызны эшләтеп карагыз инде бераз. Кемнәр ята соң монда пошаманга төшеп? Сез түгелмени?

М ы р а у. Без булсаный! Анда синең ни эшең бар?

Һ а у һ а у җ а н. Ятасыбыз килде дә... Шулай ятабыз әле менә. Вәйт!

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. И-и, рәхәттер инде сезгә, алайса?

Һ а у һ а у җ а н. Әйе, бик рәхәт. Шундый рәхәт инде менә! Чыдаплар булмый рәхәтлеккә. Әйеме, Мырау?

М ы р а у. Әй-йе... Һай, билем!

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Алай бик күңелле булгач, ятыгыз инде алайса. Әллә ярдәм итим микән үзегезгә дигән идем. Күрәм, сез ярдәм-фәләнгә мохтаҗ түгел икәнсез...

Һ а у һ а у җ а н. Синме безгә ярдәм итмәкче? Кит әле, көлдереп үтерәсең бит.

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Ярый алайса, бигайбә! Үзегезгә карагыз инде. Әнә тычканнар да кайтып килә... Юк ла, ялгыш әйттем... Мәчеләр кайтып килә икән... Чәпәләй белән Тәпәләй...

М ы р а у. Чәпәләй белән Тәпәләй? Һай, нишләргә? Хәзер ашыйлар бит инде алар мине...

Т ы л с ы м л ы  а г а ч. Мин әйттем!

Тылсымлы агач әүвәлге халәтенә кайтып катып кала.

Ч ә п ә л ә й белән Т ә п ә л ә й велосипед сөйрәп кайтып керә. Икесенең дә башлары, куллары бинтка чорналган.

Ч ә п ә л ә й. Вилсәпид түгел бу – җенсәпид! Шушы калтырша аркасында чүт башсыз калмадым.

Т ә п ә л ә й. Синең баш нәрсә ул, менә мин кулсыз кала яздым.

Велосипедны төртеп җибәрәләр, ул коймага барып сылана.

Ч ә п ә л ә й. Тәки инвалид кала яздык, име, Тәпәләй?

Т ә п ә л ә й. Ие. Үзең бит, йөртә белмисең...

Ч ә п ә л ә й. Ә син утырып йөри белмисең...

Т ә п ә л ә й. Вилсәпид йөртә белгән мәче күпер астына мәтәлә димени?! Кит, җүләр! Ярый әле Айболит бабай өендә булды... Ул булмаса, эшләр хөрти иде безнең. Минем кул һаман да сызлый әле.

Ч ә п ә л ә й. Карале, боларның тавыш-тыннары юк. Үлмәгәннәрдер бит?

Икәүләшеп Мырау янына киләләр.

Т ә п ә л ә й. Сәлам, мерсимадам!

Мырау дәшми. Боларга карап куркып тора.

Ч ә п ә л ә й. Әллә телен йоткан инде?

Т ә п ә л ә й. Телен йоткан булса, бик начар бит әле бу! Мин тычкан теле ашарга бик ярата идем... м-м-м... *(Ирен-нәрен ялмаштырып ала.)*

Ч ә п ә л ә й *(Һауһауҗанга ишарәләп)*. Борчылма. Әнә тәкә телен ашарсың. Мөгаен, ул йотмагандыр.

Т ә п ә л ә й. Дөрес әйтәсең, тычкан теле булмаган чакта миңа тәкә теле дә ярап тора!

Ч ә п ә л ә й. Ашыйсы килә-ә-ә... Ләкин кызганыч: өч сәгатьсез бернинди ризык та кабарга ярамый безгә.

Т ә п ә л ә й. Әйе шул. Айболит бабай шулай диде бит әле. Тешләрегез урыныннан чыгуы мөмкин, диде шул. Барсы да шул синең аркада. Әгәр күпергә очмаган булсак...

Ч ә п ә л ә й. Мырау белән Һауһауҗанны ашыйм дип, авызны чалшайтып булмый инде, малай, име?

Т ә п ә л ә й. Ие, түзәргә туры килә.

Ч ә п ә л ә й. Тәпәләй, кара әле, бавы бушамаганмы Мырауның? Авызга керде дигәндә генә, кача күрмәсен берүк!

Т ә п ә л ә й. Качып кына карасын! Әй, Мырау, ник дәшмисең? Сөйләшеп кал мәче абзаңнар белән.

М ы р а у. Сез мәче түгел. Мин – мәче.

Т ә п ә л ә й. Миңа димәгәе. Хет юлбарыс бул! Барыбер ашыйм мин сине. Чәпәләй, әллә тоз сибикме моңа. Бик эссе бит көн. Бозылуы бар.

Ч ә п ә л ә й. Кирәкми. Мин тозлы ит яратмыйм.

Т ә п ә л ә й. Анысы шулай шулаен, мин дә тозлы ит яратмыйм. Әрәм була күрмәсен дип кенә әйтүем.

Ч ә п ә л ә й. Бозылса, ник борчыласың?.. Әле бит безнең запаска тәкә бар. Әйе бит, Һауһауҗан?!

Һ а у һ а у җ а н. Күрсәтермен мин сезгә запасны! Орынып кына карагыз.

Т ә п ә л ә й. Кагылмыйбыз без сиңа. Юк-барга көч әрәм итәргә без җүләр түгел лә. Бер-ике сәгатьтән син бит хәзер үзең кәкрәясең. Чөнки ач бит син. Ә без сиңа барыбер ашарга бирмибез. Вәйт!

Ч ә п ә л ә й. Тәпәләй, өйгә кереп бераз ял итеп алыйк. Боларга карагач, гел ашыйсы килеп тора. Үзең беләсең, безгә әлегә ашарга ярамый.

Т ә п ә л ә й. Ял итик соң алайса. Минем йокы сәгатем дә җитте. Режим бит, малай!

Ч ә п ә л ә й. Пока, тычкан әфәнде!

Т ә п ә л ә й. Әйе, пока, мерсимадам!

М ы р а у. Паш-шул!

Т ә п ә л ә й. «Пашшул» итәм бит хәзер. Хи-а! *(Каратэ күрсәтәм дип, үзе мәтәлә.)*

Һ а у һ а у җ а н *(эчен тотып көлә)*. Бә-хә-хә-хә-ә!.. Хә-хә-хә!..

Ч ә п ә л ә й. Егылган мәчедән көлмиләр! Шуны бел, аңгыра тәкә!

Һауһауҗан шым була.

Т ә п ә л ә й *(торып басып)*. Көлдерәм мин аны хәзер! *(Тагын каратэ күрсәтмәкче була.)* Хи-а-а! *(Тагын мәтәлә.)* Тфү! Кул эшләмәгәч, аяк та эшләми.

Ч ә п ә л ә й. Булды, киттек! Җә башыңны ярырсың...

Т ә п ә л ә й. Ух, мин сезне! *(Тегеләргә аягын селки.)*

Өй бүрәнәсендәге зур тишектән эчкә кереп китәләр.

М ы р а у. Уф, тәмам гарык булдым болардан!

Һ а у һ а у җ а н. Мин дә туйдым кыланмышларыннан.

М ы р а у. Ичмасам, бауны да чишеп булмый.

Һ а у һ а у җ а н. Бу агач дөрес әйтте сиңа. Ялкау бул-масаң, мондый хәлгә тармый идең син.

М ы р а у. Ә үзең? Ә үзең? Үзеңне бел, яме!

Һ а у һ а у җ а н. Ә мин нәрсә? Ә мин барыбер көне-төне чылбырда. Ялкауланмас җиреңнән ялкауланырсың.

М ы р а у. Стоп! Мин белдем, белдем! Башыма барып җитте, ниһаять! Безне бит шушы агач акылга утыртырга уйлаган...

Һ а у һ а у җ а н. Ничек инде?

М ы р а у. Ничек инде-ничек инде, ничекнең колагы тишек инде! Шулай. Бик гади бу. Ул безнең ялкауланып ятуыбызны күргән, туйган. Әфсен-төфсенләгән дә мине – куркакка, сине тәкә җанлыга әйләндергән.

Һ а у һ а у җ а н. Ә тычканнарны батыр иткәнме?

М ы р а у. Нәкъ шулай. Тәк шту, безне бу бәладән коткарса, менә шушы агач кына коткара ала.

Һ а у һ а у җ а н. Баягынак без зерә алай ямьсез кыландык.

М ы р а у. Үзең бит, «чыдаплар булмый рәхәтлеккә!» дип шапырынган, мактанган булдың...

Һ а у һ а у җ а н. Ә син... Ә син...

М ы р а у. Ә мин менә монда ятам. Кое янында. Тычканнарга әсир төшкән фил шикелле.

Һ а у һ а у җ а н. Синме фил? Синме фил? Тфү, мәче ыстырамы!

М ы р а у. Ә син – мөгезсез тәкә!

Һ а у һ а у җ а н. Ачуны китермә минем! Юкса тычканнарны чакырам!

М ы р а у. Тс-с-с! Ишетмәсеннәр тагы! Иң яхшысы, безгә хәзер агачтан сорарга кирәк, алсын ул бездән сихерен.

Һ а у һ а у җ а н. Әйе шул. Ник бая ук минем башыма килмәде бу?

М ы р а у. Башың бармыни соң синең! Баш урынында буш чүлмәк бит синең!

Һ а у һ а у җ а н. Җә-җә, сүзеңне үлчәп сөйлә, яме! Матри! *(Агачка дәшә.)* Әй, агач, көлмәсен миннән тычканнар! Ишетәсеңме? Кайтар мине элекке халәтемә!

М ы р а у. Мине кабат батыр мәче ит! Агач, сиңа әйтәм!

Һ а у һ а у җ а н. Безне түгел, мактанчык тычканнарны акылга утырт син!

М ы р а у. Әйе, ул шантырапаларны мәсхәрә ит!

Тылсымлы агач дәшми. Һауһауҗан тезләнеп ялвара.

Һ а у һ а у җ а н. Агач абзыкаем! Агач түтикәем! Тагын кем дип әйтим инде сиңа? Господинкаем!..

М ы р а у *(ялварып)*. Әфәндекәем! Җаныкаем!..

Һ а у һ а у җ а н. Хуҗакаем! Хуҗабикәкәем!

М ы р а у. Мистер агачкаем! Синориттекаем!

Һ а у һ а у җ а н. Иң тәмле сөяккәем!

М ы р а у. Кит әле, Һауһауҗан, агачка шулай дип әйтәләрмени? Татлы каймаккаем! Сөткәем!

Һ а у һ а у җ а н. Нишләп сөт булсын ул, тиле!

М ы р а у. Сөяк тә түгел инде!

Тылсымлы агач һаман дәшми. Күрәсең, аның сөйләшергә исәбе дә юк.

Һ а у һ а у җ а н. Беләсеңме, Мырау, агач сиңа үпкәләгән.

М ы р а у. Нишләп миңа? Бәлки, сиңа үпкәләгәндер?

Һ а у һ а у җ а н. Миңа үпкәли алмый ул. Чөнки мин аңа якынрак ятам.

М ы р а у *(кинәт сискәнеп)*. Чү! Кемдер килә бугай. Ишетәсеңме, җыр тавышы?

Ерактан җыр тавышы ишетелә.

Гыйлем эстәп киткән идем
Ерак-ерак илләргә...
Дөнья гизеп кайтып киләм
Туган-үскән җирләргә!

Җыр якыная, көчәя.

Мин – Мыргали, Мыргали...
Бик бай җырга, моңга мин!..

М ы р а у. Мыргали?! Ишеттеңме, Һауһау, Мыргали кайта! Күрше кайта! Белем алып кайта! Ур-р-ра!

Һ а у һ а у җ а н. Ишетмәскә, Чәпәләйләр кебек саңгырау түгел лә мин!

М ы р г а л и керә. Күзлекле. Шәһәрчә киенгән.
Мырау белән Һауһауҗанны күрми әле.

М ы р г а л и *(һаман җырлый)*. Һич сагынмас кебек идем,
Өйдән чыгып киткәндә...
Сагындырган авылкаем,
Сагындырган икән лә!..

М ы р а у *(шатланып кычкыра)*. Мыргали!

Һ а у һ а у җ а н. Сәлам, күрше!

Мыргали, сискәнеп, җырлавыннан туктый. Әле Мырауга,
әле Һауһауҗанга карый.

М ы р г а л и. Мырау? Һауһауҗан?

Мырау янына килә.

Нишләп ятасың син монда, Мырау? Кем бәйләде сине?

М ы р а у *(үз хәленнән уңайсызланып)*. Мин... Без... Мин...

М ы р г а л и. Нәрсә, әллә Һауһауҗан бәйләдеме? Ә, Мы-рау?

М ы р а у. Мин... Һауһауҗан... э-э-э...

Һ а у һ а у җ а н. Юк, Мыргали күрше, минем эш түгел. Күрмисеңмени, мин үзем дә чылбырда ич. *(Чылбырын чыңлатып ала.)*

М ы р г а л и. Алайса, кем бәйләде соң Мырауны? *(Бауны чишмәкче була.)* Моны бит чияләй бәйләгәннәр!..

Һ а у һ а у җ а н. Әйтергә дә оят инде, Мыргали күрше, Чәпәләй белән Тәпәләй бәйләде аны.

М ы р г а л и. Чәпәләй белән Тәпәләй?

М ы р а у. Мин... без... Әйе шул... алар... әйтергә дә оят инде...

М ы р г а л и. Ышанмыйм! Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел.

Ниһаять, ул бауны чишә. Мырау кулларын угалый. Шулвакыт Ч ә п ә л ә й белән
Т ә п ә л ә й бер-бер артлы килеп чыгалар.

Ч ә п ә л ә й. Бик мөмкин, Мыргалый! Озын муенын боргалый!

Т ә п ә л ә й. Хенде хох, Мыргалый! Руки вверх!

Мырау кое артына кача.
Мыргали әле аңа, әле тычканнарга гаҗәпләнеп карый.

М ы р г а л и. Син кемнән курыктың, Мырау? Болардан түгелдер бит?

Ч ә п ә л ә й. Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына! Тәпәләй, менә тагын безгә бер ыфтарой!

Т ә п ә л ә й. Әйе шул, бәрәңге боткасы өстенә бик шәп ыфтарой бу!

М ы р г а л и *(тычканнарга таба атлап)*. Күрсәтәм мин сезгә хәзер ыфтаройны, тел бистәләре!

Чәпәләй белән Тәпәләй, үзләре дә сизмәстән,
артка таба чигенеп куялар.

Ч ә п ә л ә й. Кара-кара, Тәпәләй, бу малакасус бездән курыкмаган була түгелме соң?

Т ә п ә л ә й. Стуй, малакасус! Кемгә әйтәләр!

М ы р г а л и. Әле сез мине мыскыл итәсезме? *(Өсләренә килә.)* Аздыргансың син боларны, Мырау! Аздыргансың!

Чәпәләй белән Тәпәләй, бер-берсенә елышып,
җәһәтрәк артка чигенәләр.

Т ә п ә л ә й. Чәпәләй, минем ыфтарой ашыйсы килми башлады... Мин первыйга гына да риза...

Чәпәләй дәшми.

М ы р г а л и. Нәрсә, первыйга Мырау белән Һауһауҗан иде мәллә? Хәзер мин үзем сездән первый ясыйм!

Т ә п ә л ә й. Минем тамак тук икән, Чәпәләй. Ә синең?

Ч ә п ә л ә й. Минем дә эпититне җибәрде әле бу тычкан сыңары...

М ы р г а л и. Кем тычкан? Минме? Аһ, җүнсезләр!

Каударланып куа башлый. Тегеләр ишегалды буйлап качып йөриләр.

М ы р а у. Бир кирәкләрен, Мыргали!

Һ а у һ а у җ а н. Шул кирәк ул мактанчыкларга!

М ы р а у *(үзе дә сизмәстән кое өстенә менеп баса да куркуыннан янә кире төшә)*. Напасаран!

Һ а у һ а у җ а н. Рот-фронт!

М ы р а у. Вива, Куба!

Мыргали тычканнарны һаман куып йөри. Тегеләр тоттырмый. Менә бермәлне тычканнар икесе ике якка баса. Мыргали кайсын тотарга белмичә тора.

Т ә п ә л ә й. Мине түгел, Чәпәләйне тот. Мин тәмсез. Мин бүген иртән битне дә юмаган идем.

Ч ә п ә л ә й. Юк-юк, Тәпәләйне тот. Мин өч көн юынмаган инде.

Т ә п ә л ә й. Ә мин – бер атна!

М ы р а у *(кул хәрәкәте белән күрсәтеп)*. Икесен дә берьюлы тот, Мыргали! Менә болай иттереп!

Ч ә п ә л ә й. Хәзер иттерәм мин сиңа, яме, Мырау!

М ы р а у *(урынында очынып)*. Кара, кара! Кемгә кычкырган була!.. Мыргали генә тотсын, иманыгызны укытам мин сезнең! Тот шуларны, Мыргали, вакытны сузма!

Һ а у һ а у җ а н. Давай-давай, Мыргали!

Мыргали тагын куа башлый. Тегеләр бер-бер артлы өй тишегенә кереп югалалар.

М ы р а у *(кулларын селкеп)*. Их, качырдың бит шуларны, Мыргали! Синең урында үзем генә булган булсам!

М ы р г а л и. Булырга иде. Ник курыктың соң?

М ы р а у. Ни бит... Ботинка бавы сүтелгән иде бит!.. Шуны бәйләп азапландым...

М ы р г а л и. Алдашма инде, ичмасам, Мырау!

Өй тишегеннән Тәпәләйнең башы күренә.

Т ә п ә л ә й. Хәзер без сиңа букыс күрсәтәбез. *(Кулы белән үз башына суккалагандай итә. Ялгыш башын бәрә.)* Ай!

М ы р а у *(йодрыгын күрсәтеп)*. У-у, мин сезне!

М ы р г а л и. Азындыргансың син боларны, Мырау, азындыргансың!

Һ а у һ а у җ а н. Көне-төне телевизор карады инде Мырау.

М ы р а у. Ә син көне-төне йокладың.

М ы р г а л и. Йә-йә, әрепләшмәгез! Моннан соң сабак булыр бу сезгә!

М ы р а у. Ә мин барыбер нигәдер куркам. Оят, шул тычканнардан куркам бит.

Һ а у һ а у җ а н. Бә-ә-ә... Ә мин бүген өрүемне оныттым. Тәкә шикелле гел менә шулай бәэлдим... Бә-ә-ә...

М ы р г а л и. Мин юкта нәрсә булды соң сезгә, ә?

М ы р а у. Безне менә бу агач сихерләде. Шул мине куркакка әйләндерүче!

Һ а у һ а у җ а н. Ә мине – бәэлдәтүче!

Мыргали Тылсымлы агач янына килә. Өй тишегенә карый-карый, курка-курка гына Мырау да агач янына килеп баса.
Һауһауҗан да агачка карап тора.

М ы р г а л и. Яфракларга нindидер сүзләр язылган...

Өй тишегеннән бокс бияләйләре кигән Чәпәләй белән Тәпәләй шыпырт кына чыгып, әкрен генә боларга таба киләләр.
Тегеләр аларны күрмиләр.

М ы р а у. Тылсымлы агач бу! Яфракларга берәр сихерле сүзләр язылгандыр әле. Кызганыч, мин укый белмим...

Һ а у һ а у җ а н. Жәл, мин дә укый алмыйм...

М ы р а у. Мыргали, син бит укый беләсеңдер?! Укып күрсәт безгә! Сихерен бездән кире алсын Тылсымлы агач!

М ы р г а л и *(иҗекләп, акрын гына укый)*.

Рәгә ңаслуб ряөсшэ,
Рәгә ңаслуб елмелеб,
Кәриз мәһ шырыт ңаслуб –
Әгләх йыдном ңыссамрат!

Чәпәләй белән Тәпәләй тукталып кала. Тыңлыйлар.

М ы р г а л и *(укуын дәвам итеп)*.

Мондагы яфракларга
Язылгандыр шул хакта:
Аңларсың бу сүзләрне
Укысаң кире яктан...

М ы р а у. Мыргали, укы инде тизрәк кире яктан!

Һ а у һ а у җ а н. Әйе, укы инде тизрәк, Мыргали!

М ы р г а л и. Ашыкмагыз, хәзер укыйм...

Эшсөяр булсаң әгәр,
Белемле булсаң әгәр,
Булсаң тырыш һәм зирәк –
Тармассың мондый хәлгә!

Шулвакыт беренче күренештәге сихри-моңлы көй яңгырап ала. Чәпәләй белән Тәпәләй артларына чигенә башлыйлар. Мырауга кыюлык иңә. Һауһауҗан өреп җибәрә.

Һ а у һ а у җ а н. Һау-һау!

Ч ә п ә л ә й. Һай!

Т ә п ә л ә й. Беттек!

Мырау, Мыргали, Һауһауҗан аларга борылып карый. Мырау кинәт аларга ыргыла. Чәпәләй белән Тәпәләй боксчы бияләйләрен ташлап качалар.

М ы р а у. Мия-яу!

Ч ә п ә л ә й. Караул!

Т ә п ә л ә й. Коткарыгыз, үтерәләр!

Һ а у һ а у җ а н. Һау-һау!

Чәпәләй өй ишегенә керергә азаплана.
Аның артыннан Тәпәләй төрткәли.

Т ә п ә л ә й. Шнель, шнель! Чәпәләй, тизрәк!

Кереп качалар.

Һ а у һ а у җ а н. Һау-һау. Рәхмәт, Мыргали!

М ы р а у. Ми-яу! Рәхмәт сиңа, Мыргали! Мыргали, рәхмәт сиңа! Тылсымлы агач, сиңа да!

Тылсымлы агач ишеткәнен белдереп калтыранып ала да катып кала. Яфраклардагы сүзләр юкка чыга.
Ут сүнә. Сәхнә алдында Ә к и я т ч е пәйда була.

Ә к и я т ч е. Әче икән тормагыз...
Баллы икән алмалар!
Әкиятем шушында
Тәмам булды, балалар!
Тыңлаучысы сез булса,
Сөйләүчесе – мин әле...
Әкиятләрем бер капчык,
Тагын сөйләрмен әле!
Ә хәзергә... хәзергә
Барасым бар Шәлегә –
Сау булыгыз әлегә!

П ә р д ә.

## ЧӘПӘЛӘЙ БЕЛӘН ТӘПӘЛӘЙНЕҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Ә к и я т ч е.
Т ы л с ы м л ы а г а ч.
Ч ә п ә л ә й.
Т ә п ә л ә й.
Һ а у һ а у җ а н.
М ы р а у.
М ы р г а л и.
К ы ш б а б а й.
К а р к ы з ы.

### Б Е Р Е Н Ч Е П Ә Р Д Ә

Авыл өе ишегалды күренеше. Балалар каршында Ә к и я т ч е пәйда була.

Ә к и я т ч е. Исәнмесез, балалар! Исәнмесез, матур кызлар! Исәнмесез, батыр малайлар!

Б а л а л а р. И-сән-ме-сез!!!

Ә к и я т ч е. Җырларын да җырлармын,
Көйләрен дә көйләрмен.
Хәзер сезгә мин өр-яңа
Бер әкият сөйләрмен!

Әкиятем геройлары,
Бәлкем, сезгә таныштыр.
Белмәүчеләр булса әгәр,
Хәзер алар танышыр!

Дәртле-матур көй яңгырый. Сәхнәнең бер ягыннан Чәпәләй, икенче ягыннан Тәпәләй йөгереп керә.

Чәпәләй. Мин – Чәпәләй!
Тәпәләй. Мин – Тәпәләй!
Чәпәләй
Тәпәләй *(бергә)*. Без – тычкан малайлары!
Сез дә, без дә – барыбыз да! –
Табигать балалары!

Икесе дә мәтәлчек атып яисә берәр күңелле-кызык хәрәкәт ясап ала.

Чәпәләй
Тәпәләй *(бергә)*. Исәнмесез, дуслар!
Балалар. Исәнмесез!
Чәпәләй *(кинәт нидер исенә төшергәндәй)*. Тәпәләй!
Тәпәләй. Әү!
Чәпәләй *(юри үчекләп)*. Мин – акыллы! Син – миңгерәү!
Тәпәләй. Аһ! Әле син шулаймы?

Куышып чыгып китәләр.

Әкиятче. Ике тычкан баласын
Инде таныгансыздыр?!
Һауһау белән Мырауны да
Инде сагынгансыздыр?!

Мырау белән Һауһауҗан керә.

Мырау *(залга карап)*. Мыр-рау! Исәнмесез! *(Мускулын капшап.)* Миндә гайрәт, миндә көч!
Һауһауҗан *(үртәп)*. Синнән курка үрмәкүч! Һау-һау-ха-ха!
Йөгереп кереп китәләр.

Әкиятче. Кыскалыкта – осталык! –
Мин моны истә тотам.
Шуңа артык сузмыйча,
Сүземне кыска тотам.

Кояш кебек йөзегез –
Минем күзләр камаша...
Кәнфит суырмый гына,
Сагыз чәйнәми генә

Карыйбызмы тамаша?!

Б а л а л а р. Әйе! Карыйбыз! Карыйбыз!

Ә к и я т ч е. Әфсен-төфсен! Фаласа!
Йә, башладык алайса!

Серле-сихри мизгел. Музыка. Утлар янып-сүнеп ала. Әкиятче югала. Сәхнәдә чыршыга әверелгән Т ы л с ы м л ы а г а ч пәйда була.

Т ы л с ы м л ы а г а ч – ч ы р ш ы *(үзенең барлыгын сиз-дереп, калтыранып-селкенеп ала)*. Әп... әп... әпчехи! И Аллакаем, гомердә булмаганны! Әллә салкын тиде инде?! Әпчехи. Птичий грипп... Тфү! Деревянный грипп эләкмәсен тагы. Мең ел яшәп, моңарчы чирнең ни икәнен белмәдем, Аллага шөкер! Әпчехи. Туктале, янымда гына сумкам бар ич минем. Сумкада термосым бар. Термосымда – шифалы, кайнар чәй. *(Иснәнеп.)* У-ух, нинди хуш исле! Хуш ис дип торган булам, термосның капкачын да ачмаганмын бит әле мин... *(Термосның капкачын ача.)* У-у-у... Менә ичмасам тәмле хуш ис бу-у-у!.. Монда мәтрүшкә бар! Монда карлыган яфрагы бар! Монда гөлҗимеш бар! Монда помидор бар! Помидор бар, дидемме? И җүләр баш, помидор борын. Каян килеп помидор булсын инде мәтрүшкәле, бөтнекле чәйдә! *(Чәй йотып куя.)* Супер! Класс! Чәй чәй инде, фанты-манты, пепси-мепси ише генә түгел! Чудо-юдо! Во! Баллы дип, искусственный су эчәмме соң! Кешеләр шундый су эчеп язвы желудкыдан интегә бит инде...

Туктале, нишләп мин монда, шундый матур балалар каршында, әллә нинди шыртык-пыртык сүзләр сөйләп торам соң әле?! Мин бит матур сүзләр, затлы җөмләләр генә әйтеп сөйләшә белүче агач! Тылсымлы агач! Теләсәм, төрле агачка әверелә алам. Бүген мин – Чыршы. Күреп торасыз. Ни өчен Чыршымы? Чөнки, патамушты, сәбәбе бар, балалар. Кечтеки генә, кечкенә генә... Менә мондый малюсен-кий гына сәбәбе бар. Менә-менә-менә тиздән Яңа ел җитә. Озакламый Кыш бабай белән Кар кызы монда киләчәк! Мин аларга да, тычкан малайлары Чәпәләй белән Тәпәләйгә дә, мәче малае Мырау белән эт малае Һауһауҗанга да бер сюрприз әзерләдем бит әле. Нинди сюрпризмы? Әйтмим әле. Хәзергә сер булып торсын. *(Җырлый.)*

Матур безнең көебез,
Матур безнең җырыбыз...
Мин җырлаем, ә сез әйдә
Куллар чабып торыгыз!

Әфсен-төфсен, чәфсәләй...
Финус-кинус, фәсмәрәй...
Дөмберт-мөмберт, дәфлитән...
Мин үземчә хәл итәм!..

Тычкан кигән киез ката,

Мәче кигән шәп итек...
Чәп-чәп итеп, чәп-чәп итеп,
Кул чабыгыз шәп итеп!

Серле-сихри мизгел. Утлар янып-сүнеп ала. Тылсымлы агач Чыршы кыяфәтендә катып кала. Сәхнә артында «Ну, погоди! Ну, погоди, Тәпәләй! Тотсам, сиңа эләгәчәк! Сиңа кем тоттырсын әле!» дигән тавышлар ишетелә. Бераздан, әлсерәп-мышкылдап, башта – Т ә п ә л ә й, аның артыннан Ч ә п ә л ә й керә. Тәпәләй өйалды баскычына утыра. Иңсәсенә асылган букчасыннан кирпеч сурәте төшерелгән юл хәрәкәте билгесен тартып чыгара да Чәпәләйгә күрсәтә.

Т ә п ә л ә й. Сюда нельзя, Чәпәләй! Въезд запрещён!

Ч ә п ә л ә й *(эчен тотып көлә)*. Ха-ха-ха!.. Дүр-рәк син, Тәпәләй! Шизик-мизик! Бу юл билгесе машина йөртүчеләргә генә кагыла бит. Ә мин – җәяүле! Синең бу «кирпеч»еңне бар дип тә белмим мин! *(Тәпәләйгә таба атлый.)* Ки-а-а!

Т ә п ә л ә й. Ступ! Туктап тор, Чәпәләй! *(Букчасыннан янә бер юл билгесе чыгара.)* Осторожно, дети!

Ч ә п ә л ә й. Детский сад! Ыспрафкалы сычкан! Каян җыйдың син боларны?

Т ә п ә л ә й. Үзең син... Үзең син ыспрафкалы тычкан!

Ч ә п ә л ә й. Каян җыйдың син боларны, иптәш-гаспадин, әфәндем?

Т ә п ә л ә й. Син үзең «әфәндем!» Мин алган җирдә юк инде алар хәзер! Бар иде – юк, вәссәлам!

Ч ә п ә л ә й. Бир миңа берсен!

Т ә п ә л ә й. Хәзер... китереп тоттырам... Тот капчы-гыңны, иптәш-гаспадин!

Ч ә п ә л ә й. Яхшы чакта бир, Тәпәләй!

Т ә п ә л ә й. Тапкан табыш – сатып алыш! Сатып ал!

Ч ә п ә л ә й. Аһ син, бизнесмен сыңары! Жмот! Саран!

Т ә п ә л ә й. Ә син – саранның дусты! Туймас авыз!

Ч ә п ә л ә й. Ә син... Ә син... Памперс!

Т ә п ә л ә й. Теләгеңә ирештең тәки, Чәпәләй... Син мине чыгырымнан чыгардың... капут бит сиңа хәзер, мерсимадам! Бер, ике, өч!.. Качмасаң, үзеңә үпкәлә!.. *(Чәпәләйне куа башлый.)*

Ч ә п ә л ә й. Караул! Спасите! Коткарыгыз! Наших бьют!

Чыршы тирәли куышып йөргәндә, кереп килүче М ы р а у г а бәреләләр.

Абау! *(Күзләрен уып.)* Мырау дип торам...

Т ә п ә л ә й *(шулай ук, күзләрен уып)*. Багана икән! *(Мырауны танып.)* Абау!

Ч ә п ә л ә й. Мырау икән бит! Багана дип торам...

Т ә п ә л ә й. Полундра! Качтык! *(Китмәкче була.)*

Ч ә п ә л ә й. SOS! SOS! Коткарыгыз!

М ы р а у. Нәрсә акырышасыз? Парахутта түгел бит сез, ишегалдында!

Ч э п э л э й. Безнең ишегалды безгә парахут кебек ул, беләсең килсә! Җибәр безне, зинһар...

Т э п э л э й. Әйе, җибәр инде безне, зинһар...

М ы р а у. Куып та интекмәдем... Үзегез үз теләгегез белән килеп каптыгыз. Первыйга берегез, ыфтаройга икенчегез булыр!

Һ а у һ а у җ а н керә дә, сиздермичә генә килеп,
Мыраунын якасыннан эләктереп ала.

Һ а у һ а у җ а н *(Мыраугa)*. Десертка син булырсың, Мырау!

Ч э п э л э й
Т э п э л э й *(бергә)*. Ур-ра! Без котылдык!

М ы р а у. Әле мин сезне ычкындырмадым!

Һ а у һ а у җ а н. Мин дә сине ычкындырмадым әле, Мырау!

Ч э п э л э й. Һауһауҗан, син Мырауны шулай ычкындырмый гына тор инде, яме!

Т э п э л э й. Әйе. Яме?!

М ы р а у. Өйрәтмәгез әле, чикылдыклар! Һауһауҗан үзе нишләргә кирәген сездән әйбәтрәк белә ул. Шулай бит, Һауһауҗан?

Һ а у һ а у җ а н. Ялагайланма, Мырау! Барыбер ычкындырмыйм.

Ч э п э л э й. Мырау, маңгаеңа чебен кунган. Сизмисең мәллә?

М ы р а у. Ә?! *(Чәпәләйне тоткан кулын ычкындырып, юк чебенне куа башлый.)*

Т э п э л э й. Корт та кунган! Без-з-з-з!..

Чәпәләй дә, Тәпәләй дә Мырау кулыннан ычкынып кача.

Һ а у һ а у җ а н. Чәбәләнмәле, вентилятор!

М ы р а у *(чәбәләнүеннән туктамыйча)*. Әнә бит бал корты! Чебен!

Һ а у һ а у җ а н. Тинтәк! Кыш көне урамда бал корты, чебен буламыни?! Бигрәк куркак икән син, әй! Син көзгедән үзеңне күреп тә куркасыңдыр әле!

Ч э п э л э й. Әйе, курка ул, курка.

Т э п э л э й. Сәвсим курка.

Һ а у һ а у җ а н *(Мыраугa)*. Йә, нишлибез, иптәш-товариш?

Т э п э л э й. Бүтәкә, диген.

Һ а у һ а у җ а н. Тик кенә тор. Син үзең бүтәкә.

Ч э п э л э й *(батыраеп, Мырау каршысына килеп)*. Җә, нишлибез? Гафу үтенәбезме?

Т э п э л э й. Извинись, пока я добрый...

М ы р а у. Ычкыналсам, эләктерәм мин сезгә!

Һ а у һ а у җ а н. Ычкынулар едва ли!

Шулвакыт М ы р г а л и килеп керә.

М ы р г а л и. Руки вверх! Хенде хох!

Барысы да кулларын күтәрә.

Мырау *(күреп алып, сөенеп)*. Мыргали! Коткар мине!

Һауһауҗан. Куркыттың бит!

Чәпәләй. Ә мин курыкмадым. Печтек тә курыкмадым. Тырнак очы кадәр дә курыкмадым.

Тәпәләй. Мин дә курыкмадым. Хәтта койрыгым да селкенмәде.

Мырау. Курыкмадым дигән була тагы. Ыштан төбеңә кара. Әнә тәпи астыңны юешләгәнсең... Пес иткәнсең бит.

Тәпәләй. Пес итмәдем мин. Сәвсим пес итмәдем. Тәпи астында кар җебегәнгә генә шулай юеш күренә... Әнә үзеңнең дә тәпи астың юеш...

Мырау. Күпне күрмә, тиз картаерсың, мерсимадам!

Тәпәләй. Ә син – орбит без сахара! Сагыз син, вәйт!

Мыргали. Әшәке телле кешеләр кебек әрләшмәгез әле! *(Чыршыга төртеп күрсәтә.)* Бу ни бу?

Тәпәләй *(сикергәләп, Мыргали әйткәнне кабатлый)*. Бунибу? Бунибу? Бунибу?

Чәпәләй. Пони бу.

Мыргали *(Тәпәләйгә)*. Сикеренмәле чикерткә сыман! *(Чәпәләйгә.)* Күзеңне корт чакты мәллә, агачны ат белән – пони белән бутап торасың!..

Чәпәләй. Мин бит, мин бит шагыйрьләр кебек рифмалап кына әйттем! Бу – ни бу?! Пони бу! Менәтерәк! Шулай иткәч, шигырь килеп чыга.

Тәпәләй. Поэма, диген!

Мыргали. Җүләр сатып тормагыз әле монда, шагыйрь кисәкләре! *(Янә чыршыга ымлап.)* Бу ни бу? Нәрсә бу?

Һауһауҗан. Үзең әйттең бит, прафиссыр! Агач, дидең.

Тәпәләй. Керпе, диген! Моның энәләре бар ич! Ай-яй! Авырттырып чәнчиләр!

Чәпәләй. Шундый зу-у-ур, яшел керпе була димени?!

Мырау. Вәйт әкәмәт! Бу нәмә?.. Бу нәстә?.. Бу нәрсә безнең ишегалдында юк иде бит әле моңарчы!

Мыргали. Чыршы бу. Чыршы агачы. Каян килгән икән ул монда?

Мырау *(чыршы төбендәге магнитофонны күреп)*. Осторожны, бумба!

Чәпәләй. Син үзең бумба! Пастаянны телевизор карап аңгырайгансың инде... Синең иләс-миләс күзеңә гел бумбы күренә башлады әле соңгы вакытта!..

Мыргали. Беләсең килсә, магнитофон бу – шулти-пулти!

Тәпәләй. Аңладыңмы, Мырый?!

Мырау. Тик кенә тор! Маңгаеңа берне чиертермен!

Мыргали магнитофон төймәсенә баса.

Т а в ы ш *(Чыршы сөйли)*. Карап-карап торам да мин сезгә, тагын бер карап куям. Тыңлап-тыңлап торам да мин сезне, тагын бер тыңлап куям. Сез бит әшәкеләнгәннән-әшәкеләнә барасыз, малайлар! Үзегез сизәсезме, гел начар якка авышасыз бит сез?! Бер-берегезгә хөрмәт белән карау юк, олыны – олы, кечене кече итә белмисез. Дуска – дус, иптәшкә иптәш итеп карамыйсыз! Телегезне чүп-чар сүзләр баскан! Матур сөйләшмисез. Бер-берегезне төрткәләргә генә торасыз. Болай яшәргә ярамый, малайлар! *(Залга дәшә.)* Сез ничек уйлыйсыз, балалар? Болай яшәргә ярыймы? Әлбәттә, ярамый! *(Янәшәдәгеләргә.)* Ишеттегезме?

Б а р ы с ы б е р г ә. Ишеттек! Ишеттек!

Т ә п ә л ә й. Ишетмәскә, саңгырау түгел лә без!

Ч ы р ш ы. Бер-береңне хөрмәтләп, үзара дус булып, матур, ягымлы сүзләр белән генә сөйләшүгә ни җитә?! Әдәп төбе – алтын, диләр кешеләр. Әдәпле булырга кирәк. Менә озакламый Кыш бабай белән Кар кызы монда килеп җитәчәк. Алар сезнең тәртипсез икәнегезне күрсәләр шаккатачаклар бит. Бирәсе бүләкләрен дә бирмичә, кире борылып китәчәкләр.

М ы р г а л и. Без сынатмабыз! Шулай бит, малайлар?

Т ә п ә л ә й. Минем өчен ант итмә. Аңладыңмы?

М ы р г а л и *(куркыткан булып)*. Һәйт!

Ч ы р ш ы. Мин әйттем! Кыш бабай белән Кар кызы килгәнче үзгәрмәсәгез, сезгә бүләкләр тәтемәячәк. Яңа ел бәйрәменә дә бара алмаячаксыз. Мин – Чыршы! Мин – Тылсымлы агач! Мин барысын да күреп, белеп торачакмын! Менә шул!

Магнитофон (Чыршы) тынып кала.

Т ә п ә л ә й *(Чыршы булып сөйли)*. Мин барысын да күреп, белеп торачакмын... Күрсәң соң! Белсәң соң! Бик исебез китте. Иеме, Чәпәләй?!

Ч ә п ә л ә й. Атвалис!

М ы р а у. Матур сөйләш, Чичибаш!

Ч ә п ә л ә й. Үзең сөйләш, Мырый-тырый, алай матур иттереп. Кылтый-мылтый кыланып.

М ы р г а л и. Чәпәләй, үскәнем, Мырау белән тәмсез телләнмә. Син бит инде зур җегет. Әдәпле бул, ипле сөйләш Мырау белән.

Ч ә п ә л ә й. Абау! Абау! Абау! Кем өйрәтеп торган була мине... Хәчтерүш!

Т ә п ә л ә й. Әйе, өйрәтмә безне, яме, кәчтерүл!.. Тфү, кәчтерүш!

Ч ә п ә л ә й. Киттек, Тәпәләй! Без болай да әдәплеләр, без болай да тәртиплеләр! *(Мыраუга.)* Ки-а! *(Каратэ күрсәтмәкче була да мәтәлә.)*

Т ә п ә л ә й *(Һауһауҗанга)*. Сиңа да... Ки-а! *(Ул да җиргә мәтәлә.)*

Чәпәләй белән Тәпәләй ух-вах килеп чыгып китәләр.

М ы р г а л и. Йә, нишлибез?

Һ а у һ а у җ а н. Кыш бабай белән Кар кызын лаеклы итеп, э-э-э, лаеклы рәвештә, э-э-э, лаеклы шартларда, э-э-э, лаеклы булып, э-э-э, лаеклы кыяфәттә каршыларга без әзер!

М ы р а у. Әйе, без һәрвакыт әзер! *(Уң кулын маңгаена пионерларча куеп ала.)* Всегда готов! *(Җырлый.)*

Взвейтесь кострами,
Синие ночи...
Мы пионеры –
Дети рабочих!
Близится эра
Светлых годов...
Клич пионеров:
«Всегда будь готов!»

Һ а у һ а у җ а н. Син нәрсә, Мырау? Тилермәгәнсеңдер бит?! Әллә нинди җырлар җырлыйсың!

М ы р а у. Муеннарына кызыл чүпрәк таккан малайлар-кызлар телевизордан шулай дип җырладылар беркөнне. Җырларын ятлап калганыем... Матур җыр бит, иеме! «Взвейтесь кострами...»

М ы р г а л и. Булды, булды! Җитте! Матур-матур, бик матур җыр! Җә, малайлар, эшне үзебездән башлыйбызмы? Чәпәләй белән Тәпәләйне дә тәртипкә, әдәпкә өйрәтәсе булыр... Шулай бит?!

М ы р а у. Мыр-рау! Мыр-рау! Нәкъ шулай!

Һ а у һ а у җ а н. Һау-һау! Һау-һау! Тач шулай!

М ы р г а л и *(җырлый)*. Тәртипле булу кирәк,
Әдәпле булу кирәк;
Тәртипсезләр, әдәпсезләр
Безнең арада сирәк.

Мырау, Һауһауҗан җырга кушылалар.

Олыны олы итик,
Кечене кече итик,
Әниләрне сөендереп,
Дәү булып үсеп җитик.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Ерактан Тәпәләйнең тавышы ишетелә: «Чәпәләй!» Бераздан Т ә п ә л ә й йөгереп керә.

Т ә п ә л ә й *(еш-еш сулап)*. Чәпәләй! Чәпәләй, дим!

Ч ә п ә л ә й *(тавышы өй эченнән килә)*. Әү!

Т ә п ә л ә й. Чык тизрәк монда!

Ч ә п ә л ә й. Нәстә?

Т ә п ә л ә й. Кәбестә. Чык, диләр сиңа!

Ч ә п ә л ә й  чыга. Иснәнеп, киерелеп ала.

Ч ә п ә л ә й. Ник кычкырасың шулхәтле! Шундый тәм-ле, шундый татлы төш күреп кенә, мес-мес итеп кенә, рәхәтләнеп, изрәп кенә йоклап ята идем... Кыш бабай күп итеп бүләк алып килгән, имеш... Бүләкләрен миңа бирә дә миңа бирә бу... Миңа бирә дә миңа бирә бу...

Т ә п ә л ә й. Алай да уятканмын әле! Бөтен бүләк үзеңә генә тиясе булган икән!

Ч ә п ә л ә й. Әйе шул, акырып уятмаган булсаң, Кыш бабай бөтен бүләген дә миңа биреп бетерәчәк иде... Ә мин сиңа шул бүләкләрнең бер-икесен, бәлки, биргән дә булыр идем...

Т ә п ә л ә й. Эһе! Артты ди синнән бер-ике бүләк! Саран бит син! Комсыз!

Ч ә п ә л ә й. Җә-җә, чәпчемә! Үзең гаепле! Үзең уяттың... Юк бүләкне хәзер ничек бирим мин сиңа! Йә, нәрсә әйтмәкче идең ул хәтле акырып?

Т ә п ә л ә й. Суп-пер кыз-зык! Шундый мәзәк хәл булды... *(Эчен тотып көлә.)* Чи-чи-чи... Әкәмәт инде менә... *(Тезләнеп, башын җиргә бәрә-бәрә көлә.)* Чи-чи-чи... ха-ха-ха... Уф, көлеп үләм!

Ч ә п ә л ә й. Көлеп үлгәнче әйтеп кал инде тизрәк!

Т ә п ә л ә й. Анда... *(Кулы белән ишарәли.)* Анда... Ие-ме? Әкәмәт инде!

Ч ә п ә л ә й. Ну?! Давай-давай! Ну! Әйт!

Т ә п ә л ә й *(әйләнә-әйләнә йөреп күрсәтә)*. Выжжыйк-выжжыйк... Выж-выж, кых... Менә машина килә, име, туп-туры килә. Иномарка килә. Чёрный бумер. *(Көйли.)* Чёрный бумер, чёрный бумер... И – бах! Бабах! Кәпис!

Ч ә п ә л ә й. Нәрсә кәпис? Нәрсә бах-бабах?

Т ә п ә л ә й. Машина – кәпис! Чёрный бумер – бабах! Конец фильма – бетте кина, күрсәтелми картина!

Ч ә п ә л ә й. Аңлатып, әйбәт итеп сөйли аласыңмы син, ә, мерсимадам?!

Т ә п ә л ә й. Сөйли алам, кәнишне.

Ч ә п ә л ә й. Ну, сөйлә!

Т ә п ә л ә й. Ну, сөйлим, кәнишне. Машина килә, име?

Ч ә п ә л ә й. Килә...

Т ә п ә л ә й. Чёрный бумер, име?

Ч ә п ә л ә й. Чёрный бумер, ие!

Т ә п ә л ә й. Менә шул... Менә шуның тәгәрмәче... каз оясы чаклы чокырга туры килде дә...

Ч ә п ә л ә й *(куркынып)*. Әллә капландымы?

Т ә п ә л ә й. Ю-ю-у-ук... Ничек әйләнеп каплансын, ул бит кызу килми иде... Прусты дык итте дә сүнде! Сәвсим чокырга төште... Ха... *(Көлмәкче була, әмма Чәпәләйнең чыраен күреп туктап кала.)*

Ч ә п ә л ә й. Ну?! Сөйләдең-сөйләдең... Кайсы төштә көләргә иде соң?

Т ә п ә л ә й. Бездарь син! Надан! Юмор хисе юк синдә!

Ерактан «Кем бар якында? Ярдәм итегезче!..» дигән тавыш ишетелә.

Ч ә п ә л ә й. Ишеттеңме, Тәпәләй?

Т ә п ә л ә й. Ә кәк же. Кәк-никәк чукрак түгелмен!

Ч ә п ә л ә й. Чаптык әйдә! Ярдәм сорыйлар бит! *(Чыга башлый.)*

Т ә п ә л ә й *(иярер-иярмәс кенә)*. Нәрсә?! «Скурый пумыч» мәллә без?

Ч ә п ә л ә й. Әйе! Әйдә, элдердек! *(Чыгып йөгерә.)*

Т ә п ә л ә й *(акрын кыймылдап)*. Үзең элдер! Выж-жыйк, выж-жыйк... *(Машина йөрткән булып кылана.)* Минем чёрный бумер кызу чабарга яратмый... Выж-жыйк, выж-жыйк... *(Чыгып китә.)*

Бераз тынлыктан соң, К ы ш б а б а й ны култыклап, К а р к ы з ы белән Ч ә п ә л ә й керә. Т ә п ә л ә й Кыш бабайның биштәрен аскан.

К а р к ы з ы *(Чәпәләйгә)*. Иплән, иплән, үскәнем... Ме-нә шулай. *(Кыш бабайны җайлап эскәмиягә утырталар.)*

Т ә п ә л ә й *(биштәрне Чыршы янына куеп)*. Уф, бер тунна бардыр бу!

Ч ә п ә л ә й. Нәрсә булды, бабай?

К ы ш б а б а й. Менә, аягымны авырттырдым.

Т ә п ә л ә й. Таеп егылдың мәллә, бабай?

К ы ш б а б а й. Ярый әле сез очрадыгыз... *(Кар кызына ишарәләп.)* Кызымның үзенә генә авырга туры килер иде...

Т ә п ә л ә й *(залга карап)*. Әллә саңгырау инде бу бабай? *(Кыш бабайга кычкыра.)* Таеп егылдың мәллә, дим, бабай?

К а р к ы з ы. Ул хәтле кычкырма, акыллым. Бабай бик яхшы ишетә!

Т ә п ә л ә й. Алайса, ник җавап бирми соң бабай? Мин бит сорау бирдем... Сорау бирдем бит мин!

К ы ш б а б а й. Борчылып соравың өчен рәхмәт, балам! Юк, таеп егылмадым, наный... Кайсыдыр җүнсезе кирпечкә охшаган сурәт төшерелгән юл билгесен каерып алып киткән...

Ч ә п ә л ә й *(Тәпәләйгә төртеп)*. Эһем... эһем...

К а р к ы з ы. Без менә шул юл билгесе булмау аркасында бәлагә тарыдык. Ярый әле шофёрыбыз ул чокырны алданрак күреп өлгерде, югыйсә тагын да күңелсезрәк хәлгә таруыбыз бар иде. Иеме, бабай?

К ы ш б а б а й. Ие, кызым! Бар бит әле һаман да җүн-сезләр, тәртипсезләр... Колакларын борасы бар үзләренең!

Ч ә п ә л ә й *(Тәпәләйне читкәрәк тартып)*. «Чёрный бумер, чёрный бумер...» — дип җырлаган була бит әле, җитмәсә... Көлгән була!.. Синең аркада килеп чыккан хәл бу! Син бит анда бөтен юл билгесен каерып йөргәнсең. Бар, тизрәк барысын да урыннарына беркетеп куй!

К ы ш б а б а й. Балалар!

К а р к ы з ы *(Чәпәләй белән Тәпәләйгә)*. Малайлар! Кыш бабай сезгә дәшә!

Ч ә п ә л ә й
Т ә п ә л ә й (бергә, гаҗәпләнеп). Кыш бабай?!

Ч э п э л э й *(терсәге белән Тәпәләйгә төртеп)*. Беттек!

Т э п э л э й *(авыртудан кычкырып)*. Ай! Авырттырдың бит!

Ч э п э л э й *(Тәпәләйгә йодрыгын күрсәтеп)*. Синең аркада!

К ы ш б а б а й. Кадерле балалар, зур рәхмәт сезгә! Бик ярдәмчел икән сез! Афәрин! Исемнәрегез ничек инде сезнең, балалар?

Ч э п э л э й *(артка чигенә-чигенә)*. Исемнәрме? Безнекеме?

Т э п э л э й *(чигенеп)*. Әйе. Безнекеме?.. Исемнәрме?

К а р к ы з ы. Әйе, Кыш бабай сезнең исемнәр белән кызыксына... Әйтегез инде, малайлар! Көттермәгез!

Ч э п э л э й. Ни бит... Безнең бит әле нитәсе бар!.. Ну-у... *(Тәпәләйгә төртә.)*

Т э п э л э й. Әйе! Ну! Нитәсе бар әле безнең! Безнең бит әле ни бит!

Ч э п э л э й *(Тәпәләйгә)*. Чаптык!

Т э п э л э й. Очтык!

Чыгып йөгерәләр. Т э п э л э й шундук кире керә.
Баскычта яткан юл билгеләрен алып, аларны Кыш бабайга күр-сәтмәскә тырышып, киресенчә, тамашачыларга каратып, чыгу юлына бара. Арты белән чигенә-чигенә.

Исәнмесез! Здрасте! Простите! Без хәзер нитәбез!.. Га-фу итегез!.. Әссәламәгаләйкем! Ыспасибо! Хенде хох! Вәгаләйкүмәссәлам! Рәхмәт! *(Чыгып йөгерә.)*

К ы ш б а б а й. Син, кызым, берәр нәрсә аңладыңмы?

К а р к ы з ы. Юк, бабай. Мин дә берни дә аңламадым...

К ы ш б а б а й. Бик акыллы малайларга охшаганнар... Рәтләп сөйләшеп кенә булмады үзләре белән. Йә, ярый... Бәйрәмгә килерләр әле, шунда очрашырбыз! Карале, кызым, вакытыбыз бар... Әллә, мин әйтәм, репетиция ясап аласыңмы? Яңа җыр өйрәнәм дигән идең бит. Йәле, тагын бер кабатлап җырлап җиффәр әле шул җырны!

К а р к ы з ы. Хәзер, бабай... Кушымтасына син дә кушылырсың, яме, бабай!

К ы ш б а б а й. Ярар, кызым, кушылырмын... Әйдә, башла...

К а р к ы з ы *(җырлый)*. И Яңа ел – өр-яңа ел,
Алда юллар өр-яңа;
Аклык булып, шатлык булып,
Ява карлар дөньяга...

Кар кызы бөтерелеп-биеп җырлаган вакытта, Кыш бабай да
бию хәрәкәтләре ясый.

К ы ш б а б а й
К а р к ы з ы *(бергә)*. Ява карлар, уйный карлар,
Бөтерелеп очалар...
Җем-җем янып, ак йолдызлар
Куна безнең учларга...

К а р  к ы з ы *(дәвам итә)*. И Яңа ел – өр-яңа ел,
Бар табигать өр-яңа...
Бәйрәм булып кил, Яңа ел,
Кил син безнең дөньяга!..

К ы ш  б а б а й
К а р  к ы з ы *(бергә)*. Ява карлар, уйный карлар,
Бөтерелеп очалар...
Җем-җем янып, ак йолдызлар
Куна безнең учларга...

Кыш бабай, аягы авыртуын да онытып, чын-чынлап биеп җибәрә.

К ы ш  б а б а й. Һәй, кызым, маладис! Афәрин! Синең җырлавыңның сихәте тиде бит, кызым... Күрәсеңме бабаеңны, аягы авыртуын да онытты... Ничек теттереп бии!.. Яле, әйдәле, тагын бергәләп биеп җибәрик...

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам...
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам!..
И-их!..

К а р  к ы з ы *(Кыш бабай биегән вакытта такмаклап тора)*.
Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була...
Биегән кеше бай булганчы,
Карт алаша тай була...

К ы ш  б а б а й. Бие, бие, дип әйтәсез,
Ниндирәк бию кирәк? –
Сезнең алда биер өчен
Аккош тәпие кирәк!..
И-их-ма!

Кар  к ы з ы. И-их-ма! ди икән, Кыш бабай!
Теттереп бии икән, Кыш бабай!

К ы ш  б а б а й. Җитте, җитте, кызым! Булды, «биш-ле»лек булды! Мондый очракта кайбер балалар ни дип әйтә әле? Супер! Класс! диләрме әле!

К а р  к ы з ы. Әйе, бабай... Шулай диләр...

К ы ш  б а б а й *(баш бармагын тырпайтып)*. Супер! Класс! Шәп булды бу, кызым! Репетиция генә булмады бу, чын кәнсирт булды! *(Көлә.)*

К а р  к ы з ы. Бабай, әллә, мин әйтәм, бәйрәмгә кадәр авыл белән таныша торабызмы? Бик зур, бик матур авылга охшаган...

К ы ш б а б а й. Шулай дисеңме?! Вакыт бар дисеңме?.. Өйдә соң бер җилләнеп алыйк! Теге шаян тычкан малайларын очратмабызмы әле урамда...

Капчыкны онытып калдырып чыгып китәләр.
Чыршы җиңелчә калтыранып ала.

Ч ы р ш ы. Йә, балалар, әйтегез әле, тамаша ничек бара? Ялыкмадыгызмы әле, арымадыгызмы?

Б а л а л а р. Ю-ю-у-ук!

Ч ы р ш ы. Бик яхшы! Ничек уйлыйсыз, балалар, Чәпәләй белән Тәпәләйнең тәртипләре әйбәтләнерме, яхшырырмы?

Б а л а л а р. Әйбәтләнер! Яхшырыр!

Ч ы р ш ы. Мин дә шулай уйлыйм. Әлегә барысы да нәкъ мин уйлаганча, нәкъ мин теләгәнчә бара. Кыш бабайның менә бу биштәрен онытып калдыруы да зерә юкка түгел, балалар... Шулай кирәк. Мин уйлаган план буенча шулай булырга тиеш иде... Йә, балалар, шым булдык! Әнә кемнәрдер килә... Тс-с!

Чыршы тынып кала. Еш-еш сулап, маңгай тирләрен сөртә-сөртә, Ч ә п ә л ә й белән Т ә п ә л ә й керә.

Ч ә п ә л ә й. Ну, Тәпәләй, тирләттең, шабыр тиргә төшер-дең син мине! Бөтен тәнем манма су!

Т ә п ә л ә й. Нишләп мин тирләтим сине?! Нишләп сине мин тирләтим?!

Ч ә п ә л ә й. Син булмыйча, кем булсын тагы! Син бит бөтен юл билгеләрен куптаручы! Күпме авария синең аркада булырга мөмкин иде. Ярый әле тиз генә кире урыннарына беркетеп куйдык. Бүтән алай эшләмә! Ишетсен колагың! Аңладыңмы?

Т ә п ә л ә й *(борынын тартып)*. Ишетте инде колагым, колакларым! *(Янә борынын тарта.)* Борыным да ишетте бугай...

Ч ә п ә л ә й. Син нәрсә?! Нишләп борын ишетсен инде! Үз акылыңдамы син? Борын бит ул ис сизә... *(Исни.)* Борын ис сизә бит ул... *(Сөйләнә-сөйләнә Чыршы төбендәге биштәргә таба бара.)* Ә-әһ! Сыр исе килә!.. Ә-ә-әһ!.. Перәннек исе килә!..

Т ә п ә л ә й *(иснәп)*. Ә-ә-әһ!.. Чынлап та! Сыр исе килә! Ә-ә-әһ! Перәннек исе килә!..

Ч ә п ә л ә й. Ә-ә-әһ! *(Биштәрне иснәп.)* Капчык исе килә!

Т ә п ә л ә й *(иснәп)*. Ә-ә-әһ! Үзебезнең капчык!

Ч ә п ә л ә й. Нәрсә сөйлисең син, Тәпәләй? Нишләп үзебезнең капчык булсын ул! Бу бит теге... Кыш бабай биштәре!

Т ә п ә л ә й. Бәр-рәч! Әйе шул! Баягынак күтәргәнием бит мин моны. Бер тунны бар бу! Бер тунны, дидемме әле?

Ч э п э л э й. Әйе. Бер тунны, диден! Нигә күзләреңне шарландырып торасың?

Т э п э л э й. Бу бит бер тунны тәм-том, уенчык, сыр дигән сүз! *(Капчыкны ачмакчы булып, як-ягына карана.)* Чәпәләй, әйдә моны үзебезнең келәткә кертеп яшерәбез! Икәү генә!.. Кыш буе тәм-том ашап, симереп, рәхәтләнеп, түшәмгә төкереп яшәрбез! *(Өскә таба төкереп ала.)* Уенчыклар белән дә икебез генә уйнарбыз!..

Ч э п э л э й. Син нәрсә, Тәпәләй!

Т э п э л э й. Ну, ни алайса, әзрәк кенә Мыраугa-а-а, әзрәк кенә Һауһауҗанга-а-а... әзрәк кенә Мыргалигә-ә-ә дә бирербез... Чәк кенә, печтек кенә!

Ч э п э л э й. Син нәрсә, Тәпәләй! Кеше әйберенә тияргә ярамый! Иясеннән, хуҗасыннан башка бер әйбергә дә кагылырга ярамый! Башыңа андый уй бүтән килмәсен! Юл билгеләрен кире урынына куйганда, үзгәрәбез дип сүз бирдек бит!

Т э п э л э й. Мин бит болай гына... Мин бит кулым, тәпием кычытканга гына алмакчы идем... *(Тәпиен кашыган була.)* Менә тәпиемнең кычытуы бетте дә инде...

Ч э п э л э й. Хәзер үк биштәрне Кыш бабайның үзенә тапшырырга кирәк. *(Биштәрне җилкәсенә күтәрмәкче була.)* Булыш әйдә!

Тәпәләй биштәрне күтәрешкән мәлдә, М ы р а у, Һ а у һ а у җ а н, М ы р г а л и керә.

М ы р а у. Без әллә кайлардан эзләп йөрибез... Менә ич алар! Хәзер без сезне тәртипкә...

М ы р г а л и. ...әдәпле сөйләшергә...

Һ а у һ а у җ а н. ...дус булырга...

Ө ч е с е б е р г ә. Өйрәтәчәкбез!

Ч э п э л э й<br>Т э п э л э й *(бергә)*. Нәрсә?!

Ч э п э л э й. Ай, гафу итегез! Артык кычкырып җибәр-дек...

Т э п э л э й. Әйе, гафу итегез безне!..

М ы р г а л и. Нинди капчык күтәрдең син, Чәпәләй?

Һ а у һ а у җ а н *(иснәп)*. Тәмле исләр килә-ә-ә...

М ы р а у. Берәрсенең капчыгын урлагансыздыр әле... Аh сезне! *(Җиңнәрен сызганмакчы була, аңа Һауһауҗан төртә.)* Ә, әйе, гафу итегез, кызып китә яздым...

Ч э п э л э й. Урламадык без бу капчыкны, бу биштәрне.

Т э п э л э й. Әйе, без урламадык моны! Без хуҗасыз әйбергә тимибез!

М ы р а у. Янында хуҗасы булса тияр идегезме әллә?

Т э п э л э й. Ничек инде... Сез безне кем дип белдегез?

Ч э п э л э й *(капчыгын җиргә куеп)*. Без андый малайлар түгел... Бу биштәр – Кыш бабай биштәре. Без илтеп тапшырмакчы идек...

Т э п э л э й. Кар кызы белән икесенә илтеп бирмәкче идек!..

М ы р г а л и. Каян белдегез бу биштәрнең Кыш бабайныкы икәнен? Ачып карадыгыз мәллә?

Т ә п ә л ә й. Штy сез, штy сез! *(Кинәт исенә килеп.)* Сез нәрсә инде, Алла сакласын!

Ч ә п ә л ә й. Алар – Кыш бабай белән Кар кызы – монда булганнар иде... Биштәрне онытып калдырганнар...

Һ а у һ а у җ а н. Хәзер үк үзләренә илтеп бирергә кирәк!

М ы р а у. Кая әле, үзем күтәрим!

Т ә п ә л ә й *(Мырау каршына басып)*. Акылың алтынмы?

М ы р а у. Нәрсә?!

Т ә п ә л ә й. Беләсең килсә, без беренче күрдек, без тапшырабыз биштәрне! Понял?

М ы р а у. Не поня-ял...

М ы р г а л и. Сез нишлисез? Өтәчләнмәгез әле!

М ы р а у. Ай... Гафу итегез... Гафу ит, Тәпәләй... Кызып китә яздым...

Т ә п ә л ә й. Мырау, син дә мине гафу ит! Мин дә кыза яздым...

М ы р г а л и. Малайлар! *(Залга карап.)* Балалар! Кадерле дусларым! Әйдәгез, гел дус булып яшик әле! Бу тормышта дус булып яшәүгә ни җитә! Әйдәгез, моннан соң бер-беребезне үпкәләтмик, рәнҗетмик!..

Һ а у һ а у җ а н. Кычкырышмыйк!..

М ы р а у. Әрләшмик!..

Ч ә п ә л ә й. Әдәпле булыйк!..

Т ә п ә л ә й. Олыны – олы, кечене кече итик!

Шулвакыт К ы ш б а б а й белән К а р к ы з ы керә.

К ы ш б а б а й. Исәнмесез, балалар!

К а р к ы з ы. Исәнмесез, малайлар!

Б а р ы с ы б е р г ә. Исәнмесез!!!

К ы ш б а б а й. Әллә бәйрәм тамашасында чыгыш ясарга әзерләнәсез инде, балалар?

Т ә п ә л ә й *(барысы өчен дә җавап итеп)*. Әйе, Кыш бабай!..

К ы ш б а б а й. Бәй, балам... Син түгелме соң бу? Кайда тагын берегез?

Ч ә п ә л ә й. Мин монда, Кыш бабай!

К ы ш б а б а й. Сез кая югалдыгыз? Исемегезне дә белми калдык бит, иеме, кызым?!

К а р к ы з ы. Әйе, Кыш бабай. Безгә ярдәм иттеләр дә... *(Һауһауҗан, Мырау һәм Мыргали бер-берсенә карашып, җилкәләрен сикертеп куялар.)* Әллә ничек кенә... мәзәк кенә... юкка чыктылар!

Т ә п ә л ә й. Без... без... юкка чыкмадык! Менә ич без! Сезнең алда басып торабыз.

М ы р а у *(Һауһауҗанга)*. Кай арада Кыш бабайга яр-дәм итеп өлгергән бу тычкан малайлары? Ә?!

Һ а у һ а у җ а н *(җилкәсен сикертеп)*. Без аларны пыр туздырып эзләгән вакыттадыр инде...

М ы р г а л и. Тавышланмагыз, зинһар!

К ы ш б а б а й *(Чәпәләй белән Тәпәләйгә)*. Йәгез, исемнәрегез ничек булды инде сезнең?

М ы р а у *(әрсезләнеп)*. Минем исемем Мырау!

К ы ш б а б а й. Бик яхшы. Менә бу матур малайларныкы ничек икән? Җә?

Һ а у һ а у җ а н *(шулай ук әрсезләнеп)*. Ә минеке – Һауһауҗан!

М ы р г а л и. Тик кенә торыгыз инде. Кыш бабай сездән сорамады бит әле. Менә миннән сорамагач, «Мин – Мыргали!» дип әйтми торам бит әле...

К ы ш б а б а й *(көлеп)*. Сезнең исемнәрне белдек. Рәх-мәт. Менә бу җегетләрнекен беләсе килә бит инде.

Ч ә п ә л ә й *(Тәпәләйгә ишарәләп)*. Тәпәләй бу!

Т ә п ә л ә й *(Чәпәләйгә күрсәтеп)*. Ә бу – Чәпәләй!

Ч ә п ә л ә й
Т ә п ә л ә й *(бергә)*. Без – тычкан малайлары!

К ы ш б а б а й. Бик яхшы! Менә, ниһаять, танышып та өлгердек. Каяле, кызым, минем бит бүләкләрем бар иде... Хәтерсез баш! Баягынак без биштәрне монда калдырып киткәнбез ләбаса!.. Биштәр урынындамы, кызым? Күр әле, тиюче-фәлән булмаган икән!

Ч ә п ә л ә й. Юк-юк, монда кеше әйберенә тиюче юк!

Т ә п ә л ә й. Әйе, без кеше әйберенә тимибез!

М ы р г а л и. Без андый малайлар түгел!

М ы р а у. Без – тәртиплеләр...

Һ а у һ а у җ а н. Без – әдәплеләр...

Т ә п ә л ә й. Минем әби әйтә: «Җүләр үзен мактар!» – ди... Ой! Гафу итегез!

К ы ш б а б а й. Зыян юк, балалар. Кайчагында бераз гына мактанырга да ярый ул... Артыкка гына китмәсен... Бүләкләрем бар, дигәнием бит әле...

К а р к ы з ы. Кыш бабай! Бүләкләрне балалар үз һөнәрләрен күрсәткәч кенә бирербез дигән идек бит! Ашыкмыйк әле!

К ы ш б а б а й. Әйе шул, кызым... *(Чәпәләйгә.)* Кил әле, балам. *(Тәпәләйгә.)* Син дә кил, балам. Әллә берәр һөнәрегезне күрсәтәсезме, нәни дускайларым?!

Ч ә п ә л ә й. Була ул! *(Нәфис сүз осталары кебек итеп.)* Сәхнәдә – Чәпәләй белән Тәпәләй! Тычкан халык җыры – «Сырларым»!

Ч ә п ә л ә й
Т ә п ә л ә й *(бергә «Талларым» җырына пародия рәвешендә җырлыйлар).*

Базларымда, идән асларында

Чи-чи килеп күпме җырладым.
Күргән саен гел кимегән кебек
Савыттагы тәмле сырларым.

Сырларым, сырларым, сырларым,
Сезне тагын бер тешләр идем.
Сырларым, сырларым, сырларым,
Сезне тагын бер ашар идем...

Көне-төне ашап, сырлар ашап,
Җырладым да һаман җырладым...
Кичерегез мине, әгәр һаман
Туялмасам сездән, сырларым.

Сырларым, сырларым, сырларым...

Җыр тәмам булуга, барысы да гөрләтеп кул чаба.

К ы ш б а б а й. Рәхмәт, балалар! Афәрин!
К а р к ы з ы. Болар ярдәмчел дә, җырга да оста икән!
К ы ш б а б а й. Кызым, бүләк бирик әле үзләренә!

Күңелле ыгы-зыгы. Чәпәләй белән Тәпәләйгә галәмәт зур сыр кисәкләре тоттыралар.

Ч ә п ә л ә й
Т ә п ә л ә й *(бергә)*. Рәхмәт, Кыш бабай!

Күңелле мизгел, бүләк өләшүләр дәвам итә.

Ч ә п ә л ә й *(Тәпәләйгә)*. Әйбәт булгач, рәхәт икән ул, име, Тәпәләй?!
Т ә п ә л ә й. Мактап кына торалар. Бүләкләр бирәләр! *(Залга карый.)* Сез дә әйбәт булыгыз, дуслар!
Ч ә п ә л ә й. Сезгә дә рәхәт булыр! *(Кулындагы сырын тешли.)* Тәмле, име, Тәпәләй?!
Т ә п ә л ә й. Супер-пуппер!

Төсле утлар уйнаганда, Чыршы алгарак килә.

Ч ы р ш ы *(залга карап)*. Фәстер-фистер, фәсмәтән!.. Тылсымлы сүзләрне минем юри генә әйткәнне аңлаган-сыздыр инде, балалар? Шулай бит? Үзең үзгәрмәсәң, үзеңне үзең үзгәртмәсәң, сине бернинди тылсым да, бернинди сихер-михер дә яхшы якка үзгәртә алмый! Ышанам, ошбу тамашадан соң сез тагын да әйбәтрәк, тагын да тәртиплерәк, тагын да әдәплерәк малайлар һәм кызлар булырсыз! Яңа ел бәйрәме белән котлыйбыз сезне!

Чыршы янына Әкиятче килеп баса.

Ә к и я т ч е. Җырларын да җырладым,
Көйләрен дә көйләдем...
Әле генә сезгә шушы
Әкиятемне сөйләдем.

Рәхмәт сезгә, матур итеп
Тыңлап утырган өчен!
Рәхмәт сезгә, әкиятемне
Аңлап утырган өчен!

Кояш кебек йөзегез –
Минем күзләр камаша...
Шундый күңелле булып
Тәмамланды тамаша!
Бәйрәм белән, кадерле дуслар!

Әкияти тамашада катнашучылар һәммәсе дә сәхнә алдына килә.
Кыш бабай уртага баса.

К ы ш б а б а й. Яңа ел белән котлыйм сезне, балалар! Тәүфыйклы булыгыз! Бәхетле булыгыз!
К а р к ы з ы. Бәйрәм белән! *(Җырлый.)*

Башкалар да җырга кушыла.

И Яңа ел – өр-яңа ел,
Алда юллар өр-яңа...
Аклык булып, шатлык булып,
Ява карлар дөньяга...

Ява карлар, уйный карлар,
Бөтерелеп очалар...
Җем-җем янып, ак йолдызлар
Куна безнең учларга...

Җыр. Музыка. Бәйрәм дәвам итә.

П ә р д ә.

*2006*

## АҢГЫРА САРЫК ҖҮЛӘРЕ

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Б ә р ә н.
К ә җ ә м и л.
К у я н ш а.
Б ү р е т д и н.
Т ө л к и н а з.
А ю л л а.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман аланы. Уң якта, түр почмакта, җыйнак кына өйнең ишекле-тәрәзәле ягы күренә. Ишек өстенә «Куянша» дип язылган такта беркетелгән. Өйнең сул тарафындагы ике агачка челтәрле ятак тарттырылган. Янә бер читтә ике агач үсә – аларга аркылы такта сугылган. Ул капка ролен үти. Өй баскычының бер як кырыенда селкенмәле бүре карачкысы тора.
Кинәт «Тукта, Кылыйша! Иманыңны укытам бит хәзер!» дип кычкырган тавыш ишетелә. Җан-фәрман чабып, «капка»дан К у я н ш а килеп керә дә ишеккә таба ыргыла. Баскыч төбендә тукталып, бу бүре карачкысының корсагына йодрыгы белән тондырып ала һәм, ишекне җәһәт кенә ачып, өй эченә кереп югала. Капкада Б ү р е т д и н күренә. Ул, капкадагы аркылы тактаны абайламыйча, башын шуңа бәрә.

Б ү р е т д и н *(авыртудан үкереп)*. У-у-у-а-ах!.. *(Башын тотып, капка баганалары тирәли әйләнеп йөри.)* У-у-у... Башым ярылды!..

Өй тәрәзәсе ачыла, аннан Куяншаның башы күренә.

К у я н ш а *(үчекләп такмаклый)*.
Тараканнар төште мәллә
Ачыган ашларыңа? –
Калай тәлинкә киеп йөр
Миңгерәү башларыңа!

Б ү р е т д и н. У-у-ух! Кылый күз, имгәк ясыйм мин синнән хәзер!

Ул җәһәт-җәһәт кенә тәрәзәгә якынлаша.
Куянша тиз генә тәрәзәне ябып, эчтән бикләп куя да, телен чыгарып, Бүретдинне үчекли.

Б ү р е т д и н. Чык хәзер үк, чык, дим, яхшы чакта! Тәрәзәңне онталкан итәм! Йөрерсең аннары урман бетереп, пыяла эзләп...

К у я н ш а. Орынып кына кара тәрәзәгә, мин сине әтигә әйтәм! Ул синең колакларыңны борып өзәчәк, белдеңме?!

Б ү р е т д и н. У-у-у... куркытты берәү. Котым ботыма төште менә... Чык, дим, хәзер үк!

К у я н ш а. Чыкмый гына тор әле! Йә чыккан дияр-ләр...

Б ү р е т д и н. Беләсеңме, Кылыйша, мин сине нишләтәм? Мин сине, мин сине... Йотам мин сине! Чәйнәп тә интекмим, кабам да йотам! Ятарсың аннары минем корсак эчендә акырып-бакырып, үкереп-җылап... Әмма соң булыр.

Ул, ишек янына килеп, аны тартып карый. Ишек бикле – ачылмый.

К у я н ш а. Кагылма ишеккә! Ватсаң, үзең ясап бирәсеңне онытма!

Б ү р е т д и н. Ватты ди! Бик кирәге барые ишегеңнең! Хәзер үзең үк «чыгар әле, Бүретдин абзыкаем!» дип ялыначаксың...

Бүретдин өй тирәсеннән агач табып ала да шуның белән
ишекне терәтеп куя.

К у я н ш а *(тавышы өй эченнән ишетелә)*. Нишлисең син, Бүретдин?

Б ү р е т д и н. Тире иләп, күн эшлим! Сизмисең мәллә, ишегеңә терәү куйдым бит. Хәзер, давыл чакырып, өегезне очыртып җибәрәм. Йөри бир күктә очып!

К у я н ш а. Сиңамы соң давыл чакырту! Мактанчык! Билләһи-валлаһи, эти сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәчәк икән!

Б ү р е т д и н. Җитте, Кылыйша, такылдама. Туйдым яшелле-зәңгәрле тавышыңнан...

Бүретдин баскычка җайлап утыра.
Кинәт ерактан кемнеңдер җырлавы ишетелә. Бүретдин сагая.
Җыр тавышы якынайганнан-якыная.

Урманга керим әле,
Урманда йөрим әле.
Бүре-мазар очратып,
Кирәген бирим әле...

К у я н ш а *(тәрәзәдән башын чыгарып)*. Ишеттеңме, Бүретдин? Кемдер синең иманыңны укытырга килә. Бар, тизрәк качып өлгер!

Б ү р е т д и н. Һәйт! Ал башыңны! Акыл өйрәтмә абзаңа!

Капка төбендә Б ә р ә н пәйда була. Куянша тәрәзәдән башын
тартып ала. Бүретдин, Бәрәнне күрүгә, баскычка таба иелә төшә.
Бәрән аны күрми, җырлавын дәвам итә-итә, капкадан уза.

Б ә р ә н. Аюдан да курыкмыйм,
Бүредән дә курыкмыйм...
Мин – Бәрән, батыр бәрән –
Бернидән дә курыкмыйм!..

Б ү р е т д и н *(урыныннан калкынып)*. Тәк-тәк-тәк... Миннән дә курыкмыйсыңмы?

Бәрән Бүретдинне күреп туктап кала.

К у я н ш а *(тәрәзәдән янә башын чыгарып)*. Синнән дә курыкмыйм дип җырлады бит инде... Саңгырау мәллә син?

Б ү р е т д и н *(Куяншага усал караш ташлап)*. Яп авызыңны, Кылыйша! *(Йодрыгын селки.)* Кишер кимерә торган тешләреңне коеп

төшерәм хәзер! *(Бәрәнгә.)* Тәк-тәк-тәк... Миннән... Бүретдин абзаңнан курыкмыйм дисең инде, ә?!

Бүретдин бәрәнгә таба якынлаша.
Бәрән куркуыннан бераз артка чигенә дә кинәт капылт туктап кала.

Б ә р ә н *(катгый итеп)*. Әйе, курыкмыйм! Аюдан да курыкмыйм, арысланнан да. Беркемнән дә курыкмыйм!

К у я н ш а. Маладис! Нәкъ минем кебек икәнсең! Мин дә курыкмыйм бу тәредән!

Б ү р е т д и н. Чурту матыр! Туктыйсыңмы-юкмы син, Куркак батыр? Авызыңны чалшайтам бит!

К у я н ш а *(үчекләп)*. Чалшайтканың барыемы соң?..

Б ү р е т д и н *(Бәрән тирәли әйләнеп)*. Тәк-тәк-тәк... Сосиски кебек кенә гәүдәң белән миннән курыкмаган буласың инде алайса...

Б ә р ә н. Курыкмыйм дип әйттем бит инде мин сиңа!

Б ү р е т д и н. Тәк-тәк-тәк... *(Кинәт Бәрәнне куркытырга теләп кычкырып куя.)* Ам!

Бәрән исе дә китмичә басып торуын белә.

К у я н ш а *(кычкырып җибәрә)*. Уф, көлеп үләм! Уф, эчем катты!

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә, ярсып)*. Ник курыкмыйсың? Курык! Син куркырга тиеш!

Бәрән бер сүз дә дәшми басып тора.

К у я н ш а. Акырма ул кадәр! Бугазыңны җыртасың бит! Күреп торасың ич, керфеге дә селкенмәде... Маладис, Бәрән! Минем кебек бул, бирешмә Бүретдингә!

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә)*. Син... Син... Нишләп курыкмыйсың миннән? Йә, әйт, нишләп курыкмыйсың?

К у я н ш а. Сорау алган буласың... Син нәрсә, Бүретдин, пыркурыр мәллә? Курыкмагач курыкмый инде...

Б ү р е т д и н. Телеңне йоттың мәллә? Сорауга җавап бир: нишләп миннән курыкмыйсың?

Б ә р ә н. Мин аңгыра бәрән чөнки! Шуңа курыкмыйм синнән.

Б ү р е т д и н. Сарыклар гомер-гомергә аңгыра инде алар...

Б ә р ә н. Ә мин аңгыра гына түгел. Мин – аңгыра сарык җүләре!

Б ү р е т д и н. Миңа димәгәе, шыр тиле бул! Әмма син миннән куркырга тиеш! Ә мин сине ашарга тиеш!

Б ә р ә н. Менә кызык! Аңгыра сарык җүләре дә булыйм, синнән куркып та торыйм... Юк инде, Бүретдин бәгырькәем, монысы булмас!

Бүретдин, куллары белән башын тотып, арлы-бирле йөренә.

Б ү р е т д и н. Ярар... Курыкмасаң курыкма, кадалып кит! Әмма мин сине хәзер ботарлап ашыйм.

Б ә р ә н. Ашый алмыйсың, быр-рат!

Б ү р е т д и н *(кабынып)*. Минме?! Мин сине ашый алмыйммы? Сине чәйнәп йотмасам, исемем Бүретдин булмасын!

К у я н ш а *(такмаклый)*. Бүретдин, Бүретдин,
Әгәр ашый алмасаң,
Исемең булыр Шүретдин!..

Б ә р ә н *(Бүретдингә)*. Ашый алмыйсың, чөнки мин – аңгыра сарык җүләре! Әгәр мине ашасаң, үзең дә җүләргә әйләнәчәксең...

К у я н ш а. Ишеттеңме, аңгыра бүре тилесе! Болай да ыспырафкысыз җүләр идең... Тагын да җүләррәк чагыңны күрәселәр бар икән әле...

Б ү р е т д и н *(Куяншага)*. Җиттеме сиңа, юкмы? Хәзер күрсәтәм мин сиңа ыспырафкысыз җүләрнең кем икәнен!

К у я н ш а. Кишер чәчсәм, кишер үсми,
Ташмы әллә җирегез?
Җүләрләнгән Бүретдингә
Ыспырафкы бирегез!
Их-ма!

Бәрән кычкырып көлә.

Б ү р е т д и н. Ник көләсең, ахмак?

Б ә р ә н. Ахмак булганга көләм.

Б ү р е т д и н. Беренче тапкыр күрәм мондый шыр тилене!

К у я н ш а. Ә минем инде икенче тапкыр күрүем. Беренчесе син идең, Бүретдин...

Б ә р ә н. Көлегез әйдә, көлегез... Миңа барыбер. *(Авызын зур итеп ачып исни, киерелә.)* Минем йоклыйсы-ы-ым килә-ә-ә... *(Тирә-юньгә карана, челтәрле ятакны күреп ала.)* Ятып ял итәргә урын да бар икән...

Бәрән ятакка таба бара.

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә кычкырып)*. Ятмыйсың! Тукта хәзер үк!

К у я н ш а. Яткырма аны, Бүретдин. Минем ятак ул! Хәзер үзем чыгып ятам.

Б ә р ә н. Кычкырмагыз әле шулхәтле! Колакларымны тондырып бетердегез тәмам.

Бәрән ятакка ятмакчы була, Бүретдин аның beләгеннән эләктереп ала.

Б ү р е т д и н. Ятмыйсың дип әйттеләр бит сиңа, тинтәк! Хәзер син качарга тиеш. Ә мин сине куарга тиеш. Куып тоткач... *(Авызын чапылдатып ала.)* Тәмләп ашарга тиеш... Кача башла тизрәк! Мин эшләп ашарга яратам!

Б ә р ә н. Мин – аң-гы-ра! Ишетәсезме, аң-гы-ра! Шуңа күрә качарга уйламыйм да. Алай бик качышлы-куышлы уйныйсың килсә, әнә куянны ку!

К у я н ш а. Кара-кара-кара... Бүретдин абзасын өйрәтеп маташкан була, хәчтерүш! Нишләргә икәнен Бүретдин үзе бик шәп белә ул. Шулай бит, Бүретди-ин?!

Б ү р е т д и н. Ялагайланма, Кылыйша.

Б ә р ә н *(үзалдына сөйләнгәндәй)*. Ашыйсы да килә-ә-ә... Иртәдән бирле җүнле ризык капкан юк...

Б ү р е т д и н. Нинди ашау ди ул! Барыбер минем авызга керәсе ич инде синә. Әйдә, сузма вакытны, кача башла!

Б ә р ә н. «Кача башла, кача башла». Туйдырып бетердең инде шул сүзләрең белән. Синнән котылып булмас, ахры... Әйдә болай итәбез, Шүретдин...

Б ү р е т д и н. Шүретдин түгел мин, Бү-рет-дин! Аңладыңмы, миңгерәү?

Б ә р ә н *(кыланчыкланып)*. Аh, мин аңгыраны гафу ит, Бүретдин...

Б ү р е т д и н. Ярар, бер юлга гафу итәм. Тагын бер мәртәбә Шүретдин дип әйтсәң, үзеңә үпкәлә. Аңладыңмы?

К у я н ш а. Аңлады инде, аңлады. Ахмак дигәч тә. Ул түгел, мин аңладым, Шүретдин...

Б ү р е т д и н. Ә син кысылма, такмакчы! *(Бәрәнгә.)* Йә, аңладыңмы, малакасус?

Б ә р ә н. Аңладым, аңладым. Бүтән Шүретдин дип әйтмим сиңа, Шүретдин...

Б ү р е т д и н. Нәрсә дидең?

Б ә р ә н. Аh!.. Тагын гафу ит мине, Бүретдин...

Б ү р е т д и н *(йомшый төшеп)*. Ярар. Бер юлга тагы гафу итәм. Әгәр бүтән әйтсәң... матри!

К у я н ш а. Бүре түгел икәнсең, Бүретдин... Мәмкә икән-сең... Һаман шушы ахмакны ашый алмыйсың. Синең урында мин булса-а-ам... Бу ахмак урынында кишер булса-а...

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә)*. Йә, качасыңмы инде, юкмы, канса канис? Ачлыктан эчемдә бүреләр улый башлады...

Б ә р ә н. Бүреләр? Нинди бүреләр ул тагы?

Б ү р е т д и н. Әй лә... Ялгыш әйттем. Эчемдә сарыклар акыра башлады димәкче идем... Әйдә, кача башла!

К у я н ш а. Кач инде җәтрәк! Бүретдин абзаң сиңа әйтә бит.

Б ә р ә н. Болай итик без, Бүретдин: башта син кач – мин куам. Аннары мин куармын – син качарсың... Әгәр тотсаң ашарсың... Йә, килештекме?

К у я н ш а *(уйлап-нитеп тормыйча)*. Килеш инде, Бүретдин, килеш. Бу җүләр барыбер син әйткәнне тыңламаячак.

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә)*. Ярар, синеңчә булсын. Никадәр тизрәк – шулкадәр яхшырак. Әйдә, куа башла!

Бүретдин йөгереп китә, Бәрән аның артыннан куа.

К у я н ш а. Тоттырма, Бүретдин! Куып тот, Бәрән! Иманын укыт Бүретдиннең! Бүретдин! Тота бит инде сине, кызула! Дүр-рәк!

Капкада Т ө л к и н а з күренә. Бәрән белән Бүретдин бер-бер артлы аңа бәрелеп чыгып чаба. Төлкиназ мәтәлеп кала.

Т ө л к и н а з *(җирдә утырган килеш, тегеләр чыгып киткән якка карап, күзләрен куллары белән уып ала-ала.)* Әстәгыфирулла! Әллә күзләремә генә күренде инде... Алай дисәң, мине төртеп ектылар бит. Гаҗә-әп... Бүрене бәрән куа...

К у я н ш а. Нинди гаҗәп булсын инде – факыт! Бәрән Бүретдинне куа, Бүретдин Бәрәннән кача... Искиткеч тамаша!

Т ө л к и н а з *(урыныннан торып басып)*. Нәрсә, әллә Бүретдин тилебәрән орлыгы ашаганмы? Гомердә булмаган хәл бит бу! Хәчтерүш бәрәннән куркып качсын инде...

К у я н ш а *(тәрәзәдән тышка сикереп)*. Әле монда теге тинтәк... Бәрәнне әйтәм... мактанып торды. «Бүрене тотып ашагач, төлкенең арт сабагын укытам!» – диде. Ие!

Т ө л к и н а з. Юкны сөйләмә! Булмаганны! Мин аның үзенең арт сабагын укытам. Син мине яхшы беләсең. Шулай бит, чалыш күз?

К у я н ш а. Шулаен шулай да, юеш танау... Бүретдин дә башта синең кебек уйлаган иде. Әнә үзең күрдең бит... Факыт!

Т ө л к и н а з. Бүретдин – Бүретдин ул, ә мин – мин! Хәйләкәр төлке, диләр мине! *(Җырлый.)*
Хәйләкәр минем әти,
Хәйләкәр минем бабам.
Кирәк булса әгәр дә,
Хәзер мең хәйлә табам.
Хәйләлимен, алдалыйм –
Алдалыйм дип алдамыйм...

К у я н ш а *(җырлый)*. Тиле түгел икәнне
Беләсеңдер ич минем:
Синең тозак-хәйләңә
Мин барыбер төшмимен...
Алдала син, хәйләлә,
Ләкин миңа бәйләнмә!..
Син шуны исеңдә тот, Төлкиназ: син хәйләкәр булсаң, Бәрән – аңгыра. Үзең беләсең, аңгыраны бернинди хәйлә белән дә җиңеп булмый. Өстәвенә бу Бәрән аңгыраның да аңгырасы, тиленең дә тилесе, җүләрнең

дә җүләре, исәрнең дә исәре, сантыйның да сантые, миңгерәүнең дә миңгерәве, дивананың да диванасы, дүррәкнең дә дүрәге!.. Кыскасы, ишәктән дә хужы! Әле миңа да бәйләнмәкче булган иде, шушы йодрыгым белән берне чыраена манчып кына котылдым... Син борчылма, борчылма... Бәлки, сиңа тимәс тә әле...

Т ө л к и н а з. Тиеп кенә карасын! *(Капка тарафына карап, йодрыкларын селки.)* Хуҗасының бер тавыгын урлап качармын!

К у я н ш а *(Төлкиназга ярарга тырышкан булып)*. Әгәр авылга барсаң, берочтан миңа берәр килограмм тунна ситнер кишер дә алып кайтырсың әле, яме, Төлкиназ?!

Т ө л к и н а з. Ярар. Җай чыкса алып кайтырмын... *(Янә, капка тарафына карап, йодрыгын селкеп ала.)* Ух, мин сине, салам сыйрак!

К у я н ш а *(сүзне икенчегә борып)*. Ничек соң, Төлкиназ, бүген юлың уңдымы?

Т ө л к и н а з. Уңган иде. Менә мо-о-ондый. *(Кулын җәеп күрсәтә.)* Бер әтәч эләктергән идем.

К у я н ш а. Шыттырма инде, Төлкиназ. Шундый әтәч була димени?

Т ө л к и н а з. Ну... моннан аз гына бәләкәйрәк булгандыр инде...

К у я н ш а. Качып котылдымы?

Т ө л к и н а з. Үзем җибәрдем. Чирле булып чыкты. Грипп эләктергән икән.

К у я н ш а. Әтәч үзе әйттемени?

Т ө л к и н а з. Әйе. Суыткычтан салкын сөт алып эчкән булган... Аны ашап, үземә грипп эләктералмыйм бит инде мин. Җитмәсә, шыр сөяктән генә тора үзе.

К у я н ш а. Әле генә, менә мо-о-ондый, дигән идең...

Т ө л к и н а з. Аның йоннары гына калын булып чыкты.

К у я н ш а *(кинәт сагаеп)*. Мышлаган тавыш ишетелә!

Икәүләп, тын калып тыңлыйлар. Бераздан, мыш-мыш килеп, мүкәйләп, Бүретдин килеп керә, аңа Бәрән атланган.

Б ә р ә н. Әйдә, бахбай! На-на!

Т ө л к и н а з *(ярым пышылдап)*. Әстәгыфирулла!

Куянша белән Төлкиназ баскычка елыша төшәләр.

Б ү р е т д и н *(тукталып)*. Уф! Төш тизрәк, аңгыра! Үләм!

Б ә р ә н *(ашыкмый гына Бүретдин өстеннән төшә. Бүретдин мәтәлеп китә)*.

Б ә р ә н. Шушындамы? Китчәле, юкны сөйләмәле... Куян өе каршында Бүре үлә димени... *(Төлкиназны күреп ала.)* Бәррәч!.. Бусы кем тагы?

Төлкиназ Куяншага сыенмакчы була, тегесе аны үзеннән читкә этәрә.

К у я н ш а. Бә... бә... Бәрән, ул... ул минем бе... белән түгел... Мин... мин моны ызнайт незнай! *(Әкертен генә тәрәзәгә таба бара.)*

Т ө л к и н а з. Ку... ку... янша... ту... ту... ганым... Син... син... Нәрсә! Мин... мин... синең җан дустың бит!

К у я н ш а. Нинди җан дустың булыйм мин синең! Юк-юк! Мин сине ызнайт незнай! *(Җәһәт кенә тәрәзәгә үрмәли дә эчке якка мәтәлеп төшә.)*

Бүретдин хәлсезләнеп ята. Төлкиназ әле аңа, әле Бәрәнгә карый.

Б ә р ә н. Син әллә төлкеме?

Т ө л к и н а з. Әб-бизәтелне. Кем... Бәрән туганым... Мин... мин... төлке... Ие!

Бәрән Төлкиназга таба бер-ике адым атлап куя, тегесе, качарга мөмкинлек булмаганлыктан, гәүдәсен арткарак авыштыра.

Б ә р ә н. Нишләп мин синең туганың булыйм?

Т ө л к и н а з. Туганым дип ялгыш әйттем... Юк-юк!.. Син минем туганым түгел... Син минем иң якын дустым! Ә болар... *(Куянша белән Бүретдингә ишарәли.)* Болар – минем дошманнарым...

Б ү р е т д и н *(Төлкиназга)*. Куркак!..

Т ө л к и н а з. Куркакның үзеннән ишетәм...

К у я н ш а *(тәрәзәдән башын чыгарып)*. Ялагай!

Т ө л к и н а з. Ә син... ә син – кишер буры! Вәйт, менә кем син!

К у я н ш а. Ә син – әтәч буры!

Т ө л к и н а з. Ә син – кәбестә корты!

К у я н ш а. Ә син – тавык бете!

Т ө л к и н а з. Ә син... ә син...

Б ә р ә н. Җиттеме сезгә, юкмы, ызгыш чукмарлары!

Т ө л к и н а з. Миңа җитте. Ә менә аңа. *(Куяншага ымлый.)* Җитмәде бугай әле...

К у я н ш а. Җитте-җитте... Миңа да җитте!

Б ә р ә н. Җитсә, бик шәп. Авызларыгызны ябыгыз. Минем йоклыйсым килә. *(Ятакка таба бара.)* Комачауламагыз миңа.

Т ө л к и н а з. Юк-юк... Борчымыйбыз бүтән...

Б ә р ә н. Бүретдин!

Б ү р е т д и н. Әү!

Б ә р ә н. Син минем тынычлыгымны саклarsың, яме! *(Ятакка ята.)*

Б ү р е т д и н. Ә?.. Ярый-ярый... Саклармын.

Т ө л к и н а з. Тәмле-тәмле, татлы-татлы төшләр күреп йокла, яме!

Бәрәннең гырлаганы ишетелә.

К у я н ш а. Уф! Йоклап та китте аңгыра сарык җүләре. *(Бүретдингә.)* Йә, хәлләрең ничек, бахбай? Билкәйләрең авыртмыймы?

Б ү р е т д и н. Көлмә-көлмә, Кылыйша. Сиңа да чират җитәр әле. Бу аңгырадан бөтенесен дә көтәргә була...

Т ө л к и н а з. Чынлап та, өнме соң бу? Әллә төш кенәме?

К у я н ш а. Цирк бу! Аңладыңмы, көлтә койрык? «Бүрене иярләгән бәрән» дип аталган тамаша бу!.. Шулай бит, Бүретдин?!

Б ү р е т д и н *(торып басып)*. Мин таям. Сез үз җаегызны үзегез карагыз.

К у я н ш а. Ничек инде? Ничек инде?

Б ү р е т д и н. Ыштан төбең тишек инде! Таям дидем таям! Вәссәлам!

Т ө л к и н а з. Ә мин сызам! Мин монда ялгыш кына килеп эләктем. *(Китәргә җыена.)* Сезне белмим, сезне күрмәдем.

К у я н ш а. Ә мин? Мин нишлим?

Б ү р е т д и н. Син дә тай!

Т ө л к и н а з. Син дә сыз!

К у я н ш а. Өйне ташлапмы? Шушы ахмакка затлы өйне калдырыпмы? Әти сәяхәттән кайткач үтерә бит мине. Сез нәрсә?

Б ү р е т д и н. Алайса тайма. Кал. Бу җүләрне атландырып йөртерсең... *(Китмәкче була.)*

К у я н ш а. Бүретдин абзыкаем, Төлкиназ түтекәем... Зинһарлап сорыйм... Калдырмагыз мине бу ишәк янында... Паж-жалысты!..

Т ө л к и н а з. Ишәк түгел бу – бәрән!

К у я н ш а. Барыбер, бусы да аңгыра инде. Зинһар, ялгызымны калдырмагыз. Бүретдин абзыкаем, Төлкиназ түтекәем... Мине үтерә бит ул... Аннан соң сезне эзләп табачак та, сезне дә үтерәчәк... Берәм-берәм...

Б ү р е т д и н. Син дөрес сукалыйсың бит, Кылыйша. Чыннан да, бу безне берәм-берәм үтерергә мужыт.

К у я н ш а *(җан кереп)*. Үтер-рә-ә... үтер-рә-ә... Ике дә уйламаячак бу! Үтермәсә дә, гарип калдырачак. Мин әйткәние диярсез менә.

Т ө л к и н а з. Нишлибез, Бүретдин? Моннан котылу әмәлен табарга кирәк.

К у я н ш а. Әллә үзен нитәбезме... *(Үзен үзе буып күр-сәтә.)* Буабызмы әллә?

Б ү р е т д и н. Тс-с! Ишетмәсен тагы.

Бүретдин белән Төлкиназ бер-берсенә карашып алалар да Бәрәнгә таба әкрен генә атлыйлар. Тәрәзәдән Куянша да чыкмакчы була.

Б ә р ә н *(гырлаудан туктый, икенче якка әйләнеп ята, йокы аралаш сөйләнә)*. Шүретдин!.. Син мондамы?

Бүретдин белән Төлкиназ туктап кала.

Т ө л к и н а з *(Бүретдингә)*. Тс-с! Саташып ята...

Тәрәзәдән чыккан Куянша кабат керергә маташа.

Б ә р ә н. Син мондамы... Шүретдин? Тынычлыкны сакла, яме...

Бүретдин белән Төлкиназ кире чигенә.
Куянша тәрәзә тупсасына утыра.

Б ү р е т д и н. Булмый. Уянуы бар.
Т ө л к и н а з. Алайса, бүтән әмәл табыйк.

Бермәл өчесе дә уйга тала. Бүретдин белән Төлкиназ
арлы-бирле йөренә.

К у я н ш а *(кычкырып җибәрә)*. Таптым! *(Тәрәзәдән тышкы якка мәтәлеп төшә.)* Ай!

Т ө л к и н а з.
Б ү р е т д и н. Тс-с-с!

К у я н ш а *(егылган җиреннән торырга азапланып)*. Таптым!..

Б ү р е т д и н. Нәрсә таптың?

Т ө л к и н а з. Әйт тизрәк!

К у я н ш а. Аюга әйтергә кирәк. Ул моны «ә» дигәнче ботарлап ташлый.

Б ү р е т д и н. Дөрес! Монда нидер бар. Әгәр аю бу диванаНы юк итсә, бер мичкә бал бирәбез үзенә.

К у я н ш а. Кайдан аласың ул балны? Авыл умарталыгына барыпмы? Умартачы күрсә атып үтерер...

Т ө л к и н а з. Авылга барып йөрмибез. Аюның үз балын урлыйбыз. Мин аның кышка дип сакланган балы кайда икәнен беләм.

К у я н ш а *(сөенеченнән кулларын чәбәкләп)*. Шә-ә-әп! Башың эшли дә инде үзеңнең!

Т ө л к и н а з *(мактанып)*. Кайберәүләрнеке ише генә түгел инде.

Б ү р е т д и н. Киттек алайса. Бәрән уянганчы аюны алып килик.

Т ө л к и н а з. Барыбыз да китмик. Бу ахмак уянса шик-ләнер. *(Бүретдингә дәшә.)* Куянша калып торсын...

К у я н ш а. Сез нәрсә? Юк-юк, мин калмыйм!

Т ө л к и н а з. Алай-болай уянса, сөйләндерә торыр-сың...

К у я н ш а. Юк-юк! Сездән калмыйм. Сезнең белән китәм.

Б ү р е т д и н. Ярар. Ияр әйдә. Без әйләнеп килгәнче уянмас әле.

К у я н ш а *(сөенеп)*. Уянмый, уянмый! Каты йоклаганы күренеп тора бит әнә! Гырлавын гына карагыз! Трактормыни!.. *(Бәрәннең гырлавы отыры көчәя.)* Әйтәм бит! Үлгән бәрән кебек йоклый.

Т ө л к и н а з. Үлгән бәрән гырлыймыни, җүләр!

К у я н ш а. Үзең син җүләр! Мин бит чагыштырып кына әйттем.

Т ө л к и н а з. Тапкансың чагыштыру!

Б ү р е т д и н. Йә, ярар, җитте. Юкка әрепләшмәгез. Киттек әйдә!

К у я н ш а. Киттек!

Бәрәнгә карый-карый, өчесе дә капкага таба юнәлә.
Китешли Бүретдин янә башын бәрә, бер кулы белән башын тотып, икенчесе белән Куяншага йодрык селки. Алар күздән югалуга, Бәрән торып утыра.

Б ә р ә н. Уф! Буып үтерәләр дип торам.

Шулвакыт, як-ягына каранып, курка-курка гына К ә җ ә м и л керә.

К ә җ ә м и л *(Бәрәнгә)*. Синең өчен борчылып ята-ята бөтен гәүдәм оеды. *(Гәүдәсен, беләкләрен угалап ала.)* Качкан җирдән чыгып, тегеләрнең эчләренә тибәрдәй булдым.

Б ә р ә н. Йә, ничек, Кәҗәмил? Шәп куркыттыммы үз-ләрен? Нәкъ мин әйткәнчә килеп чыкты. Өчесе дә дер калтырап төште.

К ә җ ә м и л. Кем белә, ахыры ни белән бетәр бит әле.

Б ә р ә н. Борчылма. Мин бөтенесен дә уйладым. Син мине әллә чын-чынлап йоклады дип уйлыйсыңмы?

К ә җ ә м и л. Юк, кәнишне. Болардан курыкмыйча йок-лар өчен тимер йөрәк кирәк.

Б ә р ә н. Безнең йөрәкләр тимердән дә нык, Кәҗәмил.

К ә җ ә м и л. Ныклыгын кем белә бит әле. Аю килсә нишләрсең?

Б ә р ә н. Җаен табармын. Бүре хәтле бүрегә атланып йөргәнне.

К ә җ ә м и л. Бүре бүре ул... Ә бусы – аю! Башы казан чаклы, гәүдәсе мунча хәтле!

Б ә р ә н. Булсани. Миңа димәгәе. Әйттем бит инде – мин барысын да уйладым.

К ә җ ә м и л. Мин күрәзәче түгел лә. Синең ни уйлаганыңны мин каян белим.

Б ә р ә н *(җитди)*. Хәзер болар белән сиңа уйнарга туры килмәгәе әле.

К ә җ ә м и л. Ничек инде миңа? Ә син? Син нишлисең?

Б ә р ә н. Курыкма, мин дә монда булам. Боларны бүтән авылга килмәслек итсәк, бии-бии җырлаячакбыз әле без синең белән, Кәҗәмил. Бүген иртән, монда килгәнче, ничек шәп җырладык, ә? Әллә тагын җырлыйбызмы?

Дәртле-шаян көй агыла. Бәрән бии-бии җырлый башлый.

Б ә р ә н. Урманда яши төлке,
Аю, куян һәм бүре.
Безгә, безнең хуҗага
Зыян ясый һәрбере...

Кәҗәмилгә «Син дә кушыл әйдә!» дигән ым-ишарә ясый.
Тегесе икеләнебрәк тора.

Мин – бәрән, ә син – бәти...

К ә җ ә м и л *(җырга кушылып)*. Мин – бәти, ә син – бәрән...

И к ә ү  б е р г ә. Акылга утыртыйк без
Аларны берәм-берәм...

Б ә р ә н *(дәвам итеп)*. Бүре безгә тимәсен...

К ә ж ә м и л. Төлке тавык чәлмәсен...

Б ә р ә н. Аю бал урламасын...

К ә ж ә м и л. Куян кишер алмасын...

Икесе бергә бии-бии җырлыйлар.

Б ә р ә н. Мин – бәрән, ә син – бәти...

К ә ж ә м и л. Мин – бәти, ә син – бәрән...

Б ә р ә н
К ә ж ә м и л *(бергә)*. Акылга утыртыйк без
Аларны берәм-берәм...

## И К Е Н Ч Е  П Ә Р Д Ә

Шул ук күренеш. Тынлык. Челтәрле ятакта К ә җ ә м и л ята. Ул, уры-ныннан торып, куаклык артына поскан Бәрәнгә нидер әйтмәкче була, әмма капка тарафында күренгән Б ү р е т д и н н е, Т ө л к и н а з н ы һәм А ю л л а н ы күреп, янә урынына ята.

Б ү р е т д и н *(калганнарга дәшеп)*. Тс-с-с!

Т ө л к и н а з. Уянмаган әле. Әйдә-әйдә, Аюлла. *(Аюлланы төрткәли.)*

Аюлла атлар-атламас кына кыймылдый.

К у я н ш а. Әйдә-әйдә, курыкма!

Куянша җәһәт кенә, ишек янына барып, терәүне алып куя.
Бүретдин ятак янына килеп карый да өнсез кала. Нидер әйтмәкче була – әйтә алмый.

Т ө л к и н а з *(Аюлланы этеп-төртеп)*. Әйдә-әйдә, Аюлла! Курыкма. Иптәшкә без барын онытма... *(Ятакка күзен төшерүгә, кычкырып җибәрә.)* А-а-а!..

Б ү р е т д и н *(телгә килеп)*. У-у-у-у...

Т ө л к и н а з. А-анда-а-а... а-а-а...

А ю л л а. Э-э-э!..

Артларына чигенәләр. Кәҗәмил урыныннан тора, йокыдан уянгандай кыланып, күзләрен угалый.

К у я н ш а *(шәрран акырып җибәрә)*. Коткарыгыз! *(Җәһәт кенә өйгә кереп кача.)*

К ә җ ә м и л *(үзалдына сөйләнеп)*. Күптән болай тәмләп йоклаган юк иде... *(Аптыраудан авызын ачып карап торган Бүретдингә.)* Рәхмәт, Бүретдин. Эт шикелле тугры икәнсең!

А ю л л а. Шу... шу... шушымы инде сезнең бәрән дигәнегез?

Т ө л к и н а з. Шу... шушы бу... бугай инде-е-е...

Б ү р е т д и н. Шу... шушы дип... *(Кәҗәмилгә.)* Син кем?

Куянша тәрәзәдән башын чыгарып карап тора.

К ә җ ә м и л. Син нәрсә, Бүретдин? Нәрсә булды сиңа? Ни булды сезгә? Минем бәрән икәнлегемне оныттыгыз мәллә?

К у я н ш а *(бик гаҗәпләнеп)*. Бәрә-ән?

А ю л л а. Мин... мин берни дә аңламыйм. *(Бүретдин белән Төлкиназга.)* Кайда сезнең бәрәнегез?

Б ү р е т д и н. Әнә бит...

Т ө л к и н а з. ...каршыда басып тора!

А ю л л а. Әллә сез тилергән... Әллә мин аңгырайган... Нинди бәрән булсын бу! Бу бит бәти! Кәҗә бәтие!

К ә җ ә м и л. Сез нәрсә! Нишләп бәти булыйм. Мин – бәрән! Аңгыра бәрән мин! Җүләр сарык бәрәне!

К у я н ш а *(башын селки, күзләрен челт-челт йома, үзен үзе тотып карый)*. Син... син бәрән булсаң... Мин, мин керпе, алайса.

Бүретдин, Аюлла, Төлкиназ аңа сәерсенеп карыйлар.

К у я н ш а *(Бүретдингә)*. Ә син Бүретдин түгел, бурсык син! *(Төлкиназга.)* Ә син – тиен! *(Аюллага.)* Ә син – кабан дуңгызы!..

К ә җ ә м и л. Менә әкәмәт! Җүләр хайваннар арасына килеп эләктем мәллә мин? Бүретдин, әйт, нәрсә булды сезгә? Әллә мин төш күреп ятаммы? Уятыгыз мине!

Б ү р е т д и н *(Аюллага)*. Миңа калса... Бу бәрән... әгәр дә ул чынлап та бәрән булса... сәвсим *(бармагын чигәсендә биетеп ала)*... ычкынганнар! Бәласеннән башаяк! Тайыйк моннан!

К ә җ ә м и л. Юк-юк, беркая да китмисез! Минем сезнең һәммәгезгә дә атланып йөрисем килә! *(Ятагыннан сикереп төшә дә, Аюлла янына килеп, аның җилкәсенә асылына.)* Әйдә, син башта атландырып йөрт!

Куянша пырхылдап куя. Бүретдин белән
Төлкиназ читкәрәк тайпыла.

А ю л л а. Син нәрсә? Мин бит ат түгел. Аю мин, аю!

К ә җ ә м и л. Ә мин – аңгыра бәрән! Шуннан ни?

Бүретдин әкертен генә капкага таба чигенә.

К у я н ш а. Әй син, Бүретдин, безне бу аңгыра янында калдырып кая таймакчы буласың?

Б ү р е т д и н *(тукталып)*. Юк-юк, таймыйм мин. Өйдә телевизор кабызылган килеш калган иде... Шул искә төште дә...

Т ө л к и н а з *(китмәкче булып)*. Ә мин газга аш куйган идем. Шулпасы парга әйләнгәндер инде...

К у я н ш а. Алдашма! Синең үз гомереңдә аш пешереп ашаганың юк. Гел анда-монда сыйланып йөрисең... Син дә беркая да китмисең!

Т ө л к и н а з. Китмим-китмим... Нишләп китим. Сезне бу ахмак янында калдырып китәмме соң... Юк-юк! Булмаганны.

К ә җ ә м и л. Сезнең арада иң әйбәте Төлкиназ икән.

Т ө л к и н а з *(мактаганга күңеле булып)*. Мин һәрвакыт шулай әйбәт.

К ә җ ә м и л. Аюлла арыгач, сиңа атланып йөрермен. Әзерләнеп тор, яме, Төлкиназ?

Т ө л к и н а з. Ә? *(Хәлсезләнеп, җиргә лып итеп утыра.)*

А ю л л а *(Кәҗәмилгә)*. Төш әле җилкәдән.

К ә җ ә м и л. Нәрсә? Син миңа... аңгыра бәрәнгә шулай дидеңме? Җылыйм бит хәзер. Мин җыласам, каты җылыйм! *(Елаган булып кылана.)* Бә-ә... Бә-ә-ә... Ятим дигәч тә... Мин бит әле аңгыра булуым өстенә ятим дә... Бә-ә-ә-ә... Әти-әниемнән, әбекәем белән бабаемнан, абыем белән апамнан, энем белән сеңлемнән башка беркемем дә юк бит минем! Бә-ә-ә-ә...

А ю л л а. Җә-җә, җылама. Төшеп кенә тор әле җилкәдән... Әйбәтләп утырырсың...

К ә җ ә м и л *(елавыннан туктап)*. Күптән шулай диләр аны...

А ю л л а. Без монда киңәш-табыш итешеп алыйк... Синең күңелеңне ничек күрергә дигәндәй... Аннан соң атландырып йөрермен сине, җәме? Бар, ятагыңда бераз ятып тор.

К ә җ ә м и л. Э-э-э... Качар идегез бугай.

К у я н ш а. Качмыйлар инде, качмыйлар... Бар-бар, әйттеләр бит сиңа, ятып тор.

К ә җ ә м и л. Ярый алайса, мин сезгә ышанам... Ятып торыйм аз гына. *(Ятакка таба бара.)* Тик качсагыз, үзегезгә үпкәләгез – сезне барыбер эзләп табачакмын. Сезнең патшагыз булачакмын!

Т ө л к и н а з. Ярый-ярый, борчылма.

Аюлла, Бүретдин, Төлкиназ бер читкә китеп сөйләшә башлыйлар. К у я н ш а, өеннән чыгып, алар янына килә. Болар бер-берсенә сыенып пыш-пыш килгән арада, поскан җиреннән Б ә р ә н чыга да ятакка барып ята. Кәҗәмил аның урынына кача.

А ю л л а *(ятакка таба борылып)*. Без болай итәргә булдык... кем... бәрән дус...

Б ә р ә н *(ятактан калкып)*. Нәрсә дисең, Аюлла?

Бәрәнне күреп, һәммәсе дә катып кала.

Т ө л к и н а з. Әстәгыфирулла!

Б ү р е т д и н. У-у-у... Җен мәллә бу-у-у?..

К у я н ш а. Тотыгыз мине!

А ю л л а. Берни дә аңламыйм...

Б ә р ә н. Йә, киңәшләштегезме?

Б ү р е т д и н *(башкаларга карап)*. Билләһи дип әйтәм, җен бу! Аңгыра җен!

Б ә р ә н. Мыскыл итмә мине, Бүретдин. Син үзең җен! Нишләп мин җен булыйм... Мин – аңгыра сарык җүләре!

К у я н ш а. Тотыгыз мине, тотыгыз!

Т ө л к и н а з. Мине дә тотыгыз! Хәзер аңымны югалтып егылам...

Б ә р ә н. Йә, кайсыгыз мине атландырып йөртә инде? Минем атланып йөрисем килә... Авылда мин гел атланып йөрим: йә атка, йә эткә, йә мәчегә...

Т ө л к и н а з. Бу сиңа авыл түгел... Урман бу!

Б ә р ә н. Миңа барыбер. Атландырып йөртүче генә булсын...

А ю л л а. Аякларым монда килергә бер генә дә тартмаган иде... Ник сезнең сүзне тыңладым мин...

Кинәт Төлкиназ кулларын бутап чәбәләнә башлый. Барысы да аңа гаҗәпләнеп карыйлар.

Б ү р е т д и н. Нишлисең син, җил тегермәне?

Т ө л к и н а з. Корт! Корт бар! Бал корты! *(Чәбәләнә, бөтерелеп йөри.)*

А ю л л а. Бал корты? Кайда, кайда ул? Безләгәне ишетелми ич!

Безләү тавышын сиздермичә генә Бәрән белән Кәҗәмил чыгара.

Т ө л к и н а з. Әнә бит, әнә! Чагып үтерә мине! Коткарыгыз! *(Әле берсенә килеп тотына, әле икенчесенә барып елыша.)*

К у я н ш а. Килмә-килмә, минем янга килмә! Китермә миңа бал кортын! Мине корт чагарга ярамый. Аллергия!

Б ә р ә н. Нишлисез сез, тилеләр? Мин бер бал корты да күрмим бит! Сез юри кыланасыз бугай...

Т ө л к и н а з *(чабып йөри)*. Аңгыра булуың җитмәгән, сукыр да икәнсең! Әнә бит! Ай! Үтерә! Аюлла, тый бал кортларыңны! Сиңа ияреп килгәннәр алар... Әнә-әнә... Бер өер! Ай!

А ю л л а. Әйе шул... Мин дә күрәм... Әнә... әнә... берсе син чәлдерә язган тавык хәтле! *(Чәбәләнә.)*

Т ө л к и н а з. Без-з-з!.. Без-з-з!.. *(Чабулап йөри.)*

К у я н ш а. Килмә, килмә минем янга!

Т ө л к и н а з. Без-з-з!.. Без-з-з!.. *(Бүретдиннең култык астына башын яшермәкче була.)*

Б ү р е т д и н *(аннан арынырга теләп)*. Кит, кит янымнан! Әнә теге аңгыра янына бар!

Б ә р ә н. Кил-кил, монда кил. Бал кортлары миңа тими алар. Безнең авылныкылар алар!

Т ө л к и н а з. Без-з-з!.. Без-з-з!..

К у я н ш а. Мескенкәем, әллә үзе дә бал кортына әйләнде инде?! Төлкиназ, бар инде җәтрәк, суга барып чум!

Т ө л к и н а з *(Куяншага таба килеп)*. Кайда су? Кайда су? Ай!.. Үтерәләр!.. *(Куяншага елыша.)*

К у я н ш а. Кит әле моннан! Мин су түгел лә!

Б ә р ә н *(исе китмәгән булып)*. Бу кортлар бала кортлар гына... Болар усал түге-ел... Менә безнең авылдагы ана кортларны күрсәгез иде сез! Тавык чәлдерергә килүчеләрнең чакмаган җирләрен калдырмыйлар инде...

Т ө л к и н а з *(безләвеннән, чәбәләнеп йөрүеннән кинәт туктап)*. Ә?

Б ә р ә н *(Төлкиназга карап)*. Беркөнне сиңа охшаган бер төлке безнең авылга тавык чәлдерергә килгән булган... Ну кирәген биргәннәр дә инде кортлар! Көчкә сөйрәлеп качкан...

А ю л л а *(Төлкиназга карап)*. Булыр-булыр... Үземне чакканнары бар...

Б ә р ә н *(Аюллага карап)*. Исән түгелдер инде ул төлке. Үлгәндер... Аннан соң беркөнне бер аю килгән булган... Бал урларга. Кортлар аның да тетмәсен теткәннәр! *(Дәртләнеп сөйли.)* Башы... башы... *(Куяншаның йортына төртеп күрсәтә.)* Менә бу йорт кадәрле булып кабарган-шешенгән, ди... Ул да үлгәндер инде.

К у я н ш а. Аһ!

Б ү р е т д и н. Явыз булсалар булырлар икән!..

Б ә р ә н. Кемгә – явыз, кемгә дус алар...

Т ө л к и н а з *(әсәренеп янә чәбәләнә башлый)*. Су! Су!.. Кайда су? Ай! Чагалар, үтерәләр!..

Чабулап йөри, шулай йөргәндә, качкан җиреннән калыккан Кәҗәмилне күреп ала. Бәрәннән башкалар аны күрми. Бәрән Кәҗәмилгә «Кач!» дигән ишарә ясый, тегесе яшеренә.

Т ө л к и н а з *(куркып чигенә-чигенә)*. Сакаллы... сакаллы... бал корты! Үтерәләр!

Ул чыгып китүгә, Аюлла кулларын болгарга-бутарга тотына. Бәрән ятакка утырып селкенә, боларны күзәтә.

А ю л л а. Тавыклар!.. Тавыклар!..

Б ү р е т д и н *(як-ягына каранып)*. Нинди тавыклар? Кайда?

Бәрән рәхәтләнеп көлә.

А ю л л а. Әнә бит! Әнә бит очалар! Ай! Мине чагып үтерәләр хәзер!..

К у я н ш а *(аптыраганнан гына чәбәләнеп)*. Мескен-кәем... Бусы да җүләрләнде бугай... Бүретдин, моның күзләренә тавык күренә башлады... Сиңа да күренмидер бит?

Б ү р е т д и н *(чәбәләнеп)*. Әлегә юк... Күренми...

К у я н ш а. Ашыкма. Сиңа да күренмәгәе...

Б ә р ә н *(Куяншаның сүзләренә куәт биреп, юри сөй-ләнеп)*. Ә миңа умарталар очканы күренә. Әнә, берәү, икәү...

К у я н ш а. Сиңа күренсә дә ярый. Син болай да җүләр!

Аюлла үрсәләнеп чабып йөри. Шулай йөргәндә,
ул да Кәҗәмилне күреп ала.

А ю л л а *(әле Бәрәнгә, әле Кәҗәмилгә карый-карый, капкага таба чигенеп)*. Очалар!.. Бәрәннәр оча! Кәҗәләр оча! Әнә-әнә! *(Чыгып кача.)*

Бүретдин белән Куянша ул киткән якка карап тора. Бәрән Кәҗәмилне кул изәп чакыра. К ә җ ә м и л урыныннан чыга да әкрен генә Куянша янына килеп баса.

К у я н ш а. Мескен төлке... Мескен аю... Икесе дә күз алдында тилерде. *(Борылып, Кәҗәмилгә уйламый-нитмичә генә дәшә.)* Ыслабаклар, әйеме? *(Кинәт чырыйлап, гудок тавышы чыгарып кычкырып җибәрә.)*

Кәҗәмилне Бүретдин дә күреп ала. Ул, күзләрен челт-челт йомып, әле аңа, әле Бәрәнгә карый.

Б ү р е т д и н *(башын селкеп)*. Син... син мондамы, Кылыйша?

Кәҗәмил белән Бәрән дәррәү кычкырып көлә.

К у я н ш а. Мин... мин... монда бугай... Ә син кайда?

Б ү р е т д и н. Бел... белмим... *(Кәҗәмилгә.)* Син... Син... бәрәнме?

К ә ж ә м и л. Бәрән.

Б ү р е т д и н *(Бәрәнгә)*. Син дә... бәрәнме?

Б ә р ә н. Бәрән инде, бәрән!

К у я н ш а. Сез... сез... Ничәү соң?

Б ә р ә н.
К ә ж ә м и л. Без... без – өчәү!

Б ү р е т д и н. Тот мине, Кылыйша...

К у я н ш а. Син дә мине тот, Бүретдин...

Икесе бергә тотынышалар. Икәүләшеп капкага таба чигенәләр. Кәҗәмил белән Бәрән, җитәкләшеп, аларга таба атлый.

Б ү р е т д и н *(хәлсез тавыш белән)*. Синең качарлык хәлең бармы, Кылыйша?

К у я н ш а. Аяклар кыймылдаган сыман, Шүретдин...

Б ә р ә н
К ә җ ә м и л (икесе бергә). Һәйт!

Бүретдин белән Куянша мәтәлеп китәләр.

К у я н ш а. Караул!

Б ү р е т д и н. Качтык!

Икесе дә тиз-тиз мүкәләп чыгып качалар. Бәрән белән Кәҗәмил кычкырып көлә.

К ә җ ә м и л. Күрмәгәннәрен күрсәттек үзләренә.

Б ә р ә н. Ә син курыккан идең...

К ә җ ә м и л. Без тотынсак булдырабыз инде аны! Шулай бит, аңгыра сарык җүләре? *(Көлә.)*

Б ә р ә н. Шулай-шулай, миңгерәү кәҗә тилесе! *(Ул да көлә.)*

Икесе кочаклашып бии-бии җырлыйлар.

Б ә р ә н
К ә җ ә м и л *(бергә)*. Урманда яши төлке,
Аю, куян һәм бүре...
Бездән ерак йөрерләр
Моннан ары һәрбере.

Б ә р ә н. Мин – бәрән, ә син – бәти...

К ә җ ә м и л. Мин – бәти, ә син – бәрән...

Б ә р ә н
К ә җ ә м и л *(бергә)*. Акылга утырттык без
Аларны берәм-берәм...

Б ә р ә н. Кайтабызмы инде авылга, Кәҗәмил?

К ә җ ә м и л. Чаптык әйдә, Бәрән дус!

Җыр көе астында көлә-көлә чыгып китәләр.

П ә р д ә.

# УРМАНДАГЫ ТАМАША

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Т а з а м а т.
Х ы я л б а й.
С е р л е т а в ы ш.
Ч ү р ә л е.
Т ү р ә л е.
Б ү р ә л е.

Ш а р т у а р.
К а р а т у.
Х ә й б у л а т.
Г а л и я.
А л а - К о л а.
Б и к и.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакча. Алмагач төбендә Хыялбай сузылып яткан.
Арка terәгечле эскәмиядә Тазамат китап укып утыра.

Х ы я л б а й. Әгәр әнә теге зур алма... Юк, тегесе, бәләкәйрәге... кинәт өзелеп... минем башыма төшсә...

Т а з а м а т *(китап укуыннан туктап)*. Карале, Хыялбай, син ничек уйлыйсың, кайчан да булса диюләр, җиде башлы аждаһалар яшәде микән?

Х ы я л б а й *(борылып карамый гына)*. Юк... *(Сөйләнүен дәвам итә.)* һәм мин, Ньютон шикелле, кешеләрне шаккатырырлык...

Т а з а м а т. Шүрәлеләр дә яшәмәде микән?

Х ы я л б а й. Юк... ачыш ясасам! Йә булмаса, җәй көне кар яудыра торган нәмәстәкәй уйлап тапсам...

Т а з а м а т. Ә минем бабай әйтә, яшь чакта шүрәле күрдем, ди...

Х ы я л б а й. Ялганлый ул синең бабаң. Әкият... Йолдызларга оча торган кораб уйлап тапсам ничек булыр икән?.. Төтен чыгаргычы итеп самавыр торбасы куйсам, иллә дә шәп булачак!

Г а л и я керә.
Малайларның сөйләшкәнен сиздермичә генә тыңлап тора.

Т а з а м а т. Мин нишләптер әкияткә ышанам. Шүрәлеләр бардыр төсле. Ә син нигә әкият яратмыйсың, Хыялбай?

Х ы я л б а й. Юк-барга ышанырга минем вакытым юк... Әгәр дә мин самавыр торбасы урынына иске матайның төтен чыгаргычын куеп карасам...

Т а з а м а т. Кызык, бүрәнә ярыгына бармагын кыстырган теге шүрәленең оныклары бар микән?

Г а л и я *(сүзгә кушылып)*. Бар! Берсе – син, икенчесе... *(Көлә.)* Икенчесе – Хыялбай!

Малайлар, борылып, Галиягә карыйлар.

Т а з а м а т. Исәнме, Галия?

Г а л и я. Исәнмесез-саумысыз, әтәчегез күкәй салган, нигә чыгып алмыйсыз?

Х ы я л б а й. Бал корты дип торам, колак төбендә син безелдисең икән. Нәрсә кирәк? Йомышың булса, әйтмә... бабай әйтмешли, атчәливәй! Тазаматка укырга, миңа уйларга мишәйт итмә.

Т а з а м а т. Миңа комачауламый ул. Утыр, Галия, эскәмиягә.

Г а л и я. Утырсам, озак торам. Нишлиләр микән дип, хәлләрегезне белергә генә кергән идем.

Т а з а м а т. Каникулда нишлиләр инде — ял итәләр. Ме-нә без дә ял итәбез.

Х ы я л б а й. Мин ял итмим, мин уйлыйм.

Г а л и я. Без, кызлар, иртәгә урманга барабыз. Теләсәгез, сез дә безнең белән бара аласыз. Шүрәлеләр белән танышып кайтырсыз! *(Көлә.)*

Х ы я л б а й. Мин бармыйм. Минем вакытым юк.

Т а з а м а т. Әйтүең өчен рәхмәт, Галия. Мин барам, Хыялбай да барыр.

Г а л и я. Ярый алайса, мин киттем. *(Китә.)*

Х ы я л б а й. Чаубомбино! Пока! Иртәгә тагын кил.

Т а з а м а т. Галия белән төксе сөйләшмә инде бүтән. Кыз кеше бит ул. Безне дус итеп йөри...

Х ы я л б а й. Башны катырмале. Уйларга комачаулыйсың... Төбе тишек чәйнекне ямап, аны бензин багы итәргә була...

Т а з а м а т. Шүрәлеләрнең исемнәре була микән? Буладыр. Алар да җан иясе бит, име, Хыялбай?

Х ы я л б а й *(җен ачулары чыгып, сикереп торып)*. Тазамат кына түгел, Казамат булып чыктың син, билләһи-валлаһи!

Шулвакыт алмагачның иң зур алмасы Хыялбайның башына
дык итеп килеп төшә.

Х ы я л б а й *(үрле-кырлы сикереп)*. Ай, үләм. Һай, башым ярылды! Беттем, беттем, башсыз калдым! Һай!..

Тазамат эчен тотып көлә.

Х ы я л б а й. Ачу китереп көлмәле, ичмасам... Һай!.. Синең аркада космик кораб уйлап табалмый калдым... Башта бернинди уй калмады...

Т а з а м а т. Яңа Ньютонның башын алма харап итте! Нишләрбез инде моннан соң? И-и, бигрәкләр дә кызганыч... Ха-ха-ха!

Хыялбай җиргә иелеп алманы ала да ачу белән еракка ыргыта. Кинәт дөнья караңгылана. Күк күкрәгәндәй нидер дөберди, шалтырый. Ерактан тавыш ишетелә.

С е р л е т а в ы ш. Ялгыштың, Хыялбай, алманы ыргытып бик нык ялгыштың. Ул алма эчендә син уйлап табарга хыялланган космик корабның сызымнары бар иде. Ялгыштың, Хыялбай! Хыялыңны харап иттең. Ул алманы табу өчен сиңа шактый тир түгәргә туры киләчәк!

Дөнья яктыра. Бакчаның эзе дә калмаган. Урман. Аланлык.
Малайлар элекке халәтләрендә басып торалар.

Т а з а м а т *(як-ягына каранып)*. Кая килеп эләктек без, Хыялбай?

Х ы я л б а й *(ачу белән)*. Кая булсын, әкияткә! Әкият-мәкият, шүрәле-чүрәле дип башны катырдың бит. Менә сөен инде хәзер!

Тазамат. Чыннан да, әгәр дә без әкияттә булсак, нинди кызык булыр иде, име, Хыялбай? Кайткач, малайларга сөйләп, күзләрен дүрт иттерер идек, име?!

Хыялбай *(үчекләп)*. Име, име... Синең аркада космик кораб югалтып...

Хыялбай бер ноктага текәлеп катып кала.

Тазамат. Хыялбай! Хыялбай, дим. Нәрсә булды сиңа?

Хыялбай иреннәрен кыймылдата, нидер әйтә, тик тавышы ишетелми.

Тазамат. Ни булды сиңа, Хыялбай? Телеңне йоттың мәллә?

Хыялбай *(тотлыга-тотлыга)*. А-а-анда... ке-е-емдер... ба-а-ар!

Тазамат Хыялбай төртеп күрсәткән тарафка карый.

Тазамат. Мин беркемне дә күрмим бит.

Хыялбай. Ә-ә-әнә... те-е-егендә... ка-а-ара.

Тазамат. Әй, кем бар анда? Чык монда! Без синнән барыбер курыкмыйбыз. Шулай бит, Хыялбай?!

Хыялбай. Шу-у-улай.

Агач артыннан башта Чүрәленең, аннан Түрәле белән Бүрәленең башлары күренә. Хыялбай Тазаматка елыша.

Тазамат. Чыгыгыз монда. Без сезгә тимибез.

Хыялбай *(пышылдап диярлек)*. Ча-ак-акырма, Та-а-азамат, бе-е-езне... бетерә-ә-әләр бит алар...

Тазамат. Чыгыгыз әйдә, курыкмагыз! *(Хыялбайга.)* Син дә курыкма. Күрәсең бит, үзләре дә шүрлиләр.

Хыялбай *(Тазаматка тагын да елыша төшеп)*. Ми-и-ин ку-у-урыкмыйм.

Башта Чүрәле, аннан Түрәле белән Бүрәле куркып кына агач алдына чыгып басалар.

Тазамат. Йә, таныш булыйк: мин Тазамат булам. Ә бу минем дустым – Хыялбай. Сезне кемнәр дип белик?

Чүрәле *(бераз шикләнеп)*. Без – шүрәлеләр. *(Сул кулы белән маңгаена ике мәртәбә сугып ала.)* Мин – Чүрәле. Ә болар – Түрәле белән Бүрәле.

Түрәле белән Бүрәле, Чүрәле шикелле, үз маңгайларына ике мәртәбә сугып алалар.

Тазамат *(гаҗәпләнеп)*. Сез шүрәлеләрмени? *(Хыялбайга.)* Әйттем мин сиңа, шүрәлеләр булырга тиеш дип. Күрдеңме инде?

Хыялбай. Кү-ү-үрәм...

Тазамат. Сез нишләп йөрисез монда?

Чүрәле. Без монда яшибез.

Түрәле *(бергә)*. Әйе, без монда яшибез. Ә сез ниш-

Б ү р ә л е ләп йөрисез?

Т а з а м а т. Безме? *(Көлемсерәп.)* Без ни... *(Хыялбайга карый)* сезне күрергә дип килгән идек.

Чүрәле, Түрәле һәм Бүрәле, бер-берсенә елышып, артка чигенмәкче булалар, агачка бәреләләр.

Т а з а м а т. Курыкмагыз шулхәтле. Без сезгә тимибез дидек бит. Шулай бит, Хыялбай?

Х ы я л б а й *(башын селкеп)*. Әһә.

Ч ү р ә л е. Без сездән курыкмыйбыз, саклanaбыз гына.

Т а з а м а т. Әйдә, килегез әле мондарак. Сөйләшик. Ачыктан-ачык. Нәрсәдән сакланасыз? Әйтегез. Күрәсез ич, безнең кулда бернинди дә корал юк.

Шүрәлеләр шикләнеп кенә малайларга якынлашалар.

Т а з а м а т. Йә, әйтеп җибәрегез, нәрсәдән сакланасыз инде?

Ч ү р ә л е. Хәйләдән. Сез – хәйләкәрләр. Безне хәйләләп, бүрәнә ярыгына бармакларны кыстырмакчы буласыз.

Т а з а м а т. Андый уйның башка да килгәне юк. Шулай бит, Хыялбай?

Х ы я л б а й. Шулай. Андый уйның башка да... Һай! *(Башын тота.)* Алма!

Шүрәлеләр сискәнәләр.

Х ы я л б а й *(куркуын онытып)*. Малайлар, берәрегез алма тапмадымы? Шундый зу-у-ур! Яшел!

Шүрәлеләр елмаялар.

Т ү р ә л е. Алма бит агачта була.

Б ү р ә л е. Алмагачта, диген.

Х ы я л б а й *(өметсезләнеп, кулын селтәп)*. Тапмадык диегез инде, ичмасам. Карале, алай-болай тапсагыз, миңа бирерсез, яме?!

Ч ү р ә л е *(дустанә елмаеп)*. Ярар. Тапкач та бирербез.

Х ы я л б а й. Алдаламыйсызмы?

Т а з а м а т. Хыялбай, ташлале шул алмаңны. Әйттеләр бит инде сиңа. Шактый тир түгәргә туры киләчәк, диделәр. Үзең әйтмешли, юк-бар белән шүрәлеләрнең башларын катырмале.

Х ы я л б а й *(үпкәле тавыш белән)*. Синең шул булыр инде.

Т а з а м а т. Шулай итеп, сез безне хәйләкәрләр дисез, ә?

Ч ү р ә л е. Әйе. Һәм әшәкеләр дә. Сезнекеләр, урманга килеп, учак ягалар да ниндидер тилерткеч су эчәләр, без аңламый торган сүзләр катыштырып, җырлар җырлыйлар. Аннары бер-берсенә: «Син – хайван! Син – шүрәле!» – диләр дә әүмәкләшә башлыйлар...

Т ү р ә л е. Утаткыч белән җәнлекләрне үтерәләр.

Б ү р ә л е. Әллә нинди тозаклар куялар. Без аларны җыеп яшерәбез. Әле бүген дә сезнекеләрдән икәү тозаклар куеп йөри. Без башта сезне шулар дип уйлаган идек.

Т а з а м а т. Борчылмагыз, без андыйлар түгел. Шулай бит, Хыялбай?

Х ы я л б а й. Әйе, без андыйлар түгел. Гомумән, без андыйлар түгел. Без – әйбәтләр. Безнең башта бары... Һай! Алма!

Тазамат көлә. Шүрәлеләр дә аңа кушыла.

Т а з а м а т. Бу алмаң белән көлдереп үтерәсең син безне, Хыялбай.

Х ы я л б а й. Синең шул булыр инде...

Кинәт ботак сынган тавыш ишетелә. Барысы да сагая.

Т а з а м а т. Курыкмагыз, өлгергән нарат күркәләре генә ул. Шулар җил искән саен коела. Чүрәле дус, теге тозак куючыларның кайсы якка киткәнен карап калмадыгызмы? Без аларны бу урманга икенче аяк басмаслык итәр идек.

Ч ү р ә л е. Без аларның кайда йөргәннәрен белеп торабыз. Хәзер алар *(кояшка карый)* гел туктый торган җирләрендә ял итеп ятарга тиешләр. Ә... аларны ничек итеп урманга аяк басмаслык итеп була соң?

Т а з а м а т. Ничек итеп дип... Хәзер бер-бер хәйлә уйлап табабыз. Хыялбай, яле, башыңны эшләт әле!

Х ы я л б а й. Эшләтерсең монда. Алма төшкәннән бирле берни уйламый. Шул алмадан башка.

Т а з а м а т. Ул алма турында онытып тор инде син, Хыялбай. Тозак куючы абзыйларны акылга утыртырга кирәк бит.

Уйга талалар. Ут сүнә.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Диюләр өне. Ш а р т у а р телевизор карый. Бер почмакта К а р а т у утын түмәре күтәреп басып тора.

К а р а т у. Шартуар хуҗам, кулларым өзелеп төшә инде, җәзагызны кире алсагызсана.

Шартуар ишетми, бирелеп, телевизор каравын белә.

К а р а т у. Шартуар хуҗам, түмәрне идәнгә куярга рөх-сәт итсәгез лә. Сез ашаганнан калган сөякне өч көн буе ялап йөрер идем.

Шартуар дәшми.

К а р а т у. Алтыннан да кадерле хуҗам...

Ш а р т у а р *(кинәт чәрелдәп кычкырып)*. Үтер-рәм!

Карату куркуыннан түмәрен төшереп җибәрә.

Чебен урынына сытам! Туктыйсыңмы-юкмы, хөләпә!

Карату түмәрен алырга иелмәкче була.

Ш а р т у а р. Иелмәскә! Минем фәрманнан башка кыл да кыймылдатмаска дип күпме әйтергә була сиңа, тишек борын!

Карату үрә катып басып тора. Шартуар тынычлана.
Телевизорны сүндерә дә Каратуга таба борыла.

Ш а р т у а р. Карату, җәзаны туктатам. Сиңа сүзем бар. Монда кил!

К а р а т у. Шартуар хуҗам, аяк астыгызда олтан булыйм, тыңлыйм сезне!

Ш а р т у а р. Тыңла һәм хәтереңдә тот. Телевизордан әле генә бер кызыклы тапшыру карадым. Безгә эш чыгарга тора. Бик җаваплы эш. Кыскасы болай: унҗиденче кварталда, теге, шүрәлеләр аланында, ике яшь адәми зат пәйда булган. «Чырмырбыр» телекомпаниясенең атаклы хәбәрчесе Ала-Кола шуларның бер төркем шүрәлеләр белән сөйләшеп торганын сиздермичә генә кинога төшергән. Безнең урманда ял итеп, һава сулап йөргән җанкыяр дусларыбызның арт сабакларын укытырга җыеналар. Сүзнең ни турында барганын аңладыңмы инде хәзер?

К а р а т у. Бик яхшы аңладым, Шартуар хуҗам.

Ш а р т у а р. Аңласаң шул: хәзер үк җанкыяр дусларыбызны эзләп табасың, күрәсең, кисәтәсең. Шулай-шулай, диген. Тизрәк таегыз моннан, диген. Юкса хәлләрегез мөшкел булачак, диген. Аңладыңмы?

К а р а т у. Бик яхшы аңладым, Шартуар хуҗам.

Ш а р т у а р. Җә, нәрсә аңладың инде, тинтәккәем минем?

К а р а т у. Хәлләре мөшкел булачагын аңладым, Шартуар хуҗам.

Ш а р т у а р. Яхшы. Түмәрне урынына куй да күз алдымнан югал. Әгәр дә мәгәр фәрманны җиренә җиткереп үтәмәсәң, үзеңә үпкәлә – җәзаның иң катысын бирәчәкмен! Шылдымы, хөләпә?

К а р а т у. Шылды. Бик яхшы аңлашылды, Шартуар хуҗам! Китәм. Барып җитәм. Әйтәм. Кисәтәм дә кайтам.

Китә. Шартуар ишекле-түрле йөренә.

Ш а р т у а р *(үз-үзе белән сөйләшә)*. Әгәр дә мин болай итсәм, тегеләй була... Әгәр дә мин болай итсәм, тегеләй була... Юк, болай да булмый, тегеләй дә. Тукта! *(Маңгаена сугып ала.)* Шәп фикер! Уйлый торгач тәки таптым бит! Бар да соң инде үземдә баш! Тәмам адәм мәсхәрәсенә калачаклар икән бу бәндәләр. Эч катканчы көләселәр бар икән әле бүген! *(Башын кашып ала.)* Тә-ә-әк... Ала-Коланы чакырасы булыр. Килсен. Күрсен. Кинога төшерсен. Мине. Теге адәми затларны ничек итеп көлкегә калдырганымны да төшерсен сурәткә. Тә-ә-әк... Каяле, шалтыратыйм әле... *(Телефон көпшәсен ала, саннарны җыя.)* Бер, бер... йөз унбер... тагын бер, бер... тагын йөз унбер... Тә-ә-әк... Алло! Алло! Ала-Кола әфәндеме бу?

Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге аланлык. Сәхнәдә – Т а з а м а т белән Х ы я л б а й. Бераздан, ухвах килеп, Ч ү р ә л е, Т ү р ә л е һәм Б ү р ә л е керә. Өчесе бергә ярыгына чөй кыстырылган бүрәнә күтәргәннәр. Чүрәленең билбавына нәни балта кыстырылган.

Ч ү р ә л е. Менә шушы бүрәнә инде ул. Безнең Шүрәле бабай бармакларын шушында кыстырган. *(Бүрәнәне җиргә куялар.)*

Т а з а м а т. Карале, бу бит бик шәп тарихи экспонат! Ничек сакланган бу?

Ч ү р ә л е. Анысын бабай белә инде. Ул саклаган. Өч ел элек вафат булды бабай. Шуңынчы беркемне дә якын китермәде бүрәнәгә. Без ялгыш ярыгына бармак кыстырудан курыкты. Бу бүрәнәнең кайчан да булса кирәге чыгар әле, ди торган иде бабай. Менә бит, тәки бүген кирәге чыкты!

Х ы я л б а й. Бу бүрәнәне, теге абзыйларны акылга утырткач, мәктәп музеена куярбыз, яме, Тазамат?!

Т а з а м а т. Дуслар бирсә алып кайтырбыз.

Ч ү р ә л е. Безгә нәрсә, алырсыз. Без аны барыбер сак-лый белмибез. Шулай бит, малайлар?

Т ү р ә л е. Шулай, шулай.

Б ү р ә л е. Шулай.

Т а з а м а т. Җә, нишлибез? Кузгалабызмы?

Ч ү р ә л е. Бик вакыт. Тизрәк кыймылдарга кирәк.

Барысы да бүрәнәне күтәрергә дип иеләләр. Җәһәт кенә күтәрәләр. Шулвакыт Ш а р т у а р белән А л а - К о л а килеп керә. Ала-Кола киноаппарат аскан. Икесе дә кешеләрчә киенгән.

Ш а р т у а р *(шат елмаеп)*. У-у-уххх! Маладсы, җегетләр, маладсы! Өмәгә бердәм тотынгансыз. Ала-Кола, кинога төшерә башла! Мине дә төшерергә онытма.

Тазамат, Хыялбай һәм шүрәлеләр, берни аңламыйча, бүрәнә күтәргән килеш басып торалар. Ала-Кола кинога төшерә башлый.

Т а з а м а т. Карале, ни... кем, апа...

Ш а р т у а р. Апа түгел, Шартуар абзаң булырмын мин, үскәнем.

Т а з а м а т. Шартуар абзый, нинди өмә ул?

Ш а р т у а р *(гаҗәпләнгән булып)*. Бә-ә-әй, әле сез өмә булганын белмичә эшлисезмени? Хуплыйм, хуплыйм. Маладсы! Дию әйткәч... Тфү! Кеше әйткәч, аны кем дә эшли. Күрәм, сез үзегез башлап йөрергә яратасыз икән. Мондый асыл җегетләр белән җир җимертеп эшләргә була. Маладсы!

Х ы я л б а й. Шулай да, абзый, әйтегез әле, нинди өмә соң бүген?

Ш а р т у а р *(имән бармагын өскә чөеп)*. Бүген, үскәнем, би-и-ик зур өмә! Бүген, үскәнем... бүген... урман чистарту өмәсе! Бүген менә шундый бүрәнәләрне, корыган ботак-чатакларны бер урынга җыеп яндырабыз...

Ч ү р ә л е. Абзый, бу бүрәнәне яндырырга ярамый. Бу бүрәнә...

Аңа, «эндәшмә» дигән ишарә ясап, Тазамат төртеп ала.

Ш а р т у а р. Ярар, сезнеңчә булсын. Монсын яндырмабыз. Бу капка баганасына бик әйбәт икән. Әйдәгез, күтәреп торып арыгансыздыр. Илтеп куйыйк тиешле урынга. Ала-Кола, карап торма. Төшер кинога, төшер. Мине төшер. Аларны да...

Ала-Кола агачка сөялеп тә, иелеп тә, җиргә ятып та төшерә.

Т а з а м а т. Шартуар абзый, безнең дуслар әйтә...

Тазамат Шартуарның койрыгын күреп ала. Шикләнә.

Ш а р т у а р. Әйт, үскәнем, әйт. Йә, нәрсә ди сезнең дуслар?

Т а з а м а т. Шартуар абзый, сезнең артта койрык сыман ниндидер әйбер асылынып тора...

Ш а р т у а р *(каушап)*. Ә-ә-ә... Ниме... син аны әйтәсеңме? Ул бит ни... Ни бит ул... кәҗә тиресе. Билгә ураган идем. Миндә ни бит... ырматиз! Һай ул билемнең сызлаукайлары! Кайчагында шундый итеп чәнчи – үләм дип торам! Шул ырматизга бернинди дә дару-фәлән уйлап таба алмыйлар... *(Сөйләнә-сөйләнә, койрыкны эченә яшерә.)*

Шартуар койрыкны яшергән арада, Тазамат Чүрәленең колагына нидер пышылдый.

Т а з а м а т. Шартуар абзый!

Ш а р т у а р. Әү, үскәнем!

Т а з а м а т. Безнең Чүрәле дус әйтә, безнең өйдә шул ырматизны бетерә торган бик шәп дару бар, ди. Малайлар тиз алып килсеннәр мәллә? Өйләре ерак түгел аларның...

Ш а р т у а р. Өйләре ерак булмаса, тиз генә алып кил-сеннәр соң алайса.

Т а з а м а т. Бүрәле, Түрәле! *(Боларга күз кыса.)* Барыгыз, алып килегез шул даруны.

Тегеләр китәләр дә, куаклык артына посып, боларны күзәтеп торалар.

Т а з а м а т. Һай, бик авыр икән бит бу бүрәнә. Малайлар әйләнеп килгәнче, җиргә куеп торыйк.

Бүрәнәне әкрен генә җиргә куялар.

Ш а р т у а р. Ала-Кола дус, хәзергә төшерми тор...

Ала-Кола агач төбенә утыра да аппараты белән кайнаша башлый. Шартуар йөрене. Тазамат, Хыялбай һәм Чүрәле үзара бәхәсләшкән кебек кыланалар.

Т а з а м а т *(Хыялбайга)*. Юк, син хаклы түгел. Минемчә, Чүрәле дөрес әйтә.

Шартуар боларның сүзләренә колак сала.

Х ы я л б а й. Юк, минеке дөрес! Монда бер бармак кына сыя.
Ч ү р ә л е. Бәхәсләшмә инде, Хыялбай. Ике дигәч ике инде!
Ш а р т у а р *(сүзгә кушылып)*. Ни турында бәхәсләшәсез, үскәннәрем?
Т а з а м а т. Менә Хыялбай әйтә, бу бүрәнә ярыгы бер бармак киңлегендә, ди. Ә без әйтәбез Чүрәле белән икәү, ике бармак киңлегендә, дибез. Шулай икәнен Хыялбай үзе дә күреп тора. Барыбер сүзен бирми – бәхәсләшә.
Х ы я л б а й. Минеке дөрес!
Т а з а м а т. Әнә бит һаман үзенекен сукалый...
Ш а р т у а р. Һи-и, юкка бәхәсләшәсез... Хәзер беләбез аны. *(Бер кулын бүрәнә ярыгына кыстыра.)* Хәзер беләбез... Тә-әк...

Шулвакыт Чүрәле билендәге балтасын ала да бүрәнә ярыгындагы чөйгә сугарга әзерләнә, Шартуар аны күрми.

Т а з а м а т *(тавышын нечкәртә төшеп һәм сузып)*. Дию абзы-ый!
Ш а р т у а р. Әү, үскәнем... Ә?

Шул мизгелдә Чүрәле балтасы белән чөйгә суга. Чөй чыгып оча.

Ш а р т у а р. Ой! Үләм! *(Үрсәләнеп кычкыра, бәргәләнә.)* Төшер... әй, ычкындырыгыз бармакларны! Үләм!

Шулвакыт Шартуар дию халәтенә кайта. Ала-Кола аны кинога төшерә башлый. Башкалар дәррәү көлә. Б у р ә л е белән Т у р ә л е яшеренгән урыннарыннан чыгалар.

Т а з а м а т. Дию абзый, тынычланыгыз... Хәзер ырматизны бетерә бу дару... Ха-ха-ха!
Ш а р т у а р. Уһ! Аһ! Бармакларым минем... *(Ала-Колага ярсып кычкыра.)* Төшермә мине, төшермә! Ух! Сиңа әйтәм, тинтәк сарык!

Ала-Кола аның сүзләрен ишетми, төшерүен белә.

Т а з а м а т. Дию абзый, ырматиз беттеме инде? Әллә һаман да чәнчеп-чәнчеп авыртамы?
Ш а р т у а р. Бетте-бетте... Тизрәк ычкындырыгыз! Үләм!
Х ы я л б а й. Ычкындыруын ычкындырырбыз да ди. Ә син моннан соң нишләрсең микән, дию агай?

Ш а р т у а р. Тизрәк җибәрегез генә... Берни дә эшләмәс идем. Өйдә телевизор гына... тфү... радио гына тыңлап ятар идем. Ала-Колау-у! Ала-Кола дускаем, төшермә инде киногa. Ух!..

Т а з а м а т. Ярар, җибәрик без моны, дуслар. Тәүбә итте бит. Инде яңадан начар уй белән йөри икән... Ул чагында без аның белән башкача сөйләшербез!

Х ы я л б а й. Әйе, без сезнең белән башкача сөйләшербез! Ишеттеңме, дию агай? Чүрәле, әйдә, чөеңне кире сук!

Чүрәле чөйне алып, аны бүрәнә ярыгына тыга да балтасы белән суга башлый.

Ш а р т у а р. Уф! *(Бармакларын бүрәнә ярыгыннан алгач, җиңел сулап куя.)* Сезнең белән бүтән очрашырга язмасын...

Т а з а м а т. Дөрес сөйлисең, дию абзый. Бар, юлыңа ак җәймә.

Ш а р т у а р *(бармакларын угалап)*. Үзегезнең юлыгызга ак җәймә... *(Мыскыл итеп.)* Үскәнкәйләрем! Күңелсез хәлгә тарсагыз, мине искә төшерерсез!

Уфылдап чыгып китә, аны киногa төшерә-төшерә, Ала-Кола да китә.

Х ы я л б а й. Каян килеп чыкты бу дию? Һич башыма сыйдыра алмыйм. Кем әйткән аңа безнең монда икәнлекне?

Ч ү р ә л е. Урмандагы һәр агачның колагы бар, Хыялбай. Әгәр акрын кыймылдасак, тозак куючыларның китеп барулары мөмкин. Дию ялгызы гына эш итмәс...

Т а з а м а т. Шулай шул, Чүрәле дус. Дию тикмәгә генә ишарә ясамагандыр: «Күңелсез хәлгә тарсагыз, мине искә төшерерсез», – диде бит. Җанкыярларны кисәтеп куюлары бар. Җәһәтрәк булыйк.

Кузгалырга әзерләнәләр. Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә уртасында учак яна. Х ә й б у л а т, авыз эченнән нидер көйли-көйли, учакка коры-сары өсти. Сулы казан тотып, Б и к и керә.

Б и к и. Теге чишмә корыган. Кансирвы калайлары гына аунап ята. Инешкә үк барырга туры килде. *(Учак өстенә казан аса.)*

Х ә й б у л а т. Бу кадәр озак йөргәч, мин сине чишмәгә баткансың дип торам. *(Көлә.)* Әле ярый суы кипкән икән.

Б и к и. Үзең бит теге көнне, пычагымамыни бу чишмә безгә, дип, җыен чүп-чарны шунда тондырдың. Хәзер менә синең аркада инешкә чабарга туры килә.

Х ә й б у л а т. Ничава, чишмәләр күп алар, бер җирдә корыса, икенче җирдән бәреп чыгалар. Әйдә, биштәрдәге ризыкларны, теге нәмәстәләрне ә-әнәү җәймәгә чыгарып сал. Сине көтә-көтә, минем эчтә бүреләр улый башлады инде.

Хәйбулат учак тирәсендә кайнаша. Бики биштәрдәге әйберләрне
чыгара башлый.

Х ә й б у л а т *(хыялга бирелеп)*. Бики, теге, соңгы тозакка бик шәп куян эләксә, ә?! Сыйланыр идек тә соң синең белән!

Б и к и. Ашказанын котыртма әле, Хәйбулат абзый. Болай да авыздан сулар килеп тора...

Шулвакыт, еш-еш сулап, К а р а т у керә.

К а р а т у *(тегеләргә карап)*. Уф, өлгердем бит тәки!

Бики кулына тоткан шешәләрне кире биштәргә яшерә.
Каушаганы сизелә. Әле Каратуга, әле Хәйбулатка карый.

Х ә й б у л а т. Син кем? Исәнмесез-саумысызың кая?

К а р а т у. Исәнмесез-саумысыз! Минем исемем – Карату. Сезне кисәтергә килдем.

Х ә й б у л а т. Килгәнсең икән, матур гына китә дә бир. Сау килеш. Юкса сөякләреңне дә җыя алмассың! *(Бикигә карап.)* Йөриләр шунда кешенең тәмле ялын бүлеп. *(Каратуга.)* Бу хәтле дә җен-перигә охшасаң охшарсың икән. Нәрсә, урманда адаштың мәллә?

К а р а т у. Юк, адашмадым. Мин сезне кисәтергә килдем. Тиздән монда шүрәлеләр килә. Сезнең арт сабакны укытырга!

Х ә й б у л а т. Нәрсә?!

К а р а т у *(куркып калып)*. Шүр... шүр... шүр...

Х ә й б у л а т. Күрсәтәм мин сиңа хәзер шүрәлене! Бики! Типкәләп озат бу карачкыны! Тормасын каршыда күзле бүкән булып...

Бики Каратуга таба атлый. Тегесе чигенә.

К а р а т у. Мин бит... сезгә... изгелек... теләп... ә-ә-ә... се-е-ез!

Х ә й б у л а т. Бики, дим!

Бики иелеп таяк ала. Карату чыгып кача.

Х ә й б у л а т *(тынычлана алмыйча)*. Вәйт син аны, ә! Тинтәк тәре! Шулхәтле перигә әйләнгәнче эчмәсә! Шүрәле-шүрәле дип,әкият сатып, безнең белән сыйланмакчы була. Әле ярый, бәхете бар икән. Үзем тотынсам, сөяге дә калмый иде...

Б и к и. Дөньяда әллә нинди кешеләр дә була, име, Хәйбулат абзый?! Эзләп карасаң, безнең шикелле әйбәт кешеләр дөньяда бармак белән генә санарлыктыр әле ул, име?

Х ә й б у л а т. Сөйләп торасың тагын син дә. Безнең шикелле шәп кешеләр дөньяда юк инде ул, юк!

Б и к и. Хәйбулат абзый, әллә, мин әйтәм, шулпа кайнап чыкканчы теге тозакны карап килимме? Бәлки, берәр куян эләккәндер?!

Х ә й б у л а т. Бар-бар, Бики. Мин учакны караштырып торам. Куян эләккән булса, шунда ук суеп алып килерсең. Тунавын монда тунарбыз...

Бики китә.

Х ә й б у л а т *(үзалдына сөйләнеп)*. Һиндер-һиндер, лә-лә-лә... Әллә Бики юкта бераз нитеп... капкалап алыйм микән? Аш кайчан өлгерә әле ул. Шулай итмичә дә булмас...

Җәймә янына килә. Биштәргә кулын тыга. Шулвакыт Б и к и керә.

Б и к и. Хәйбулат абзый, сукыр тычкан да эләкмәгән!

Хәйбулат тиз генә биштәрдән кулын тартып ала.

Х ә й б у л а т. Ә... Эһе-эһе... Эләкмәгәндер шул әле. Тозакны яңа гына куйдык бит... Мин әле монда... Ни... тоз эзлидер идем. Ашны кабып караган идем, тозы җитми сыман тоелды... Дөньяда иң сөймәгән нәрсәм – тозсыз аш. Тозсыз аш ул куян эләкмәгән тозак сыман...

Б и к и. Мин үзем дә тозсыз аш яратмыйм. Баягынак бер савыт тозны ялгыш ашка койган идем. Эчтән шүрләп йөрдем. Хәйбулат абзый иманны укыта икән болай булгач, мин әйтәм. Син дә тозлы аш яраткач, таман гына булыр әле...

Х ә й б у л а т. Дөрес эшләгәнсең, Бики. Тик минем бүген нишләптер аш ашыйсы килми әле. Әллә соң булган ризык-ларны капкалый торабызмы?

Б и к и. Сез ни дисәгез, шуңа риза инде мин, Хәйбулат абзый. Әйдә, аш кайнап чыкканчы...

Шулвакыт Т а з а м а т белән Х ы я л б а й керә.

Т а з а м а т. Тәмле булсын ашларыгыз, абзыйлар!

Х ә й б у л а т *(төксе генә)*. Син әйтмәсәң дә тәмле була ул. Ни йомыш?

Т а з а м а т. Бик зур үтенечебез бар иде, абзыйлар. Мәктәп сәхнәсендә «Шүрәле» спектаклен куймакчы идек...

Х ә й б у л а т. Анда минем ни эшем бар. Миңа димәгәе, «Кәҗә белән Сарык»ны куегыз... Хи-хи-хи! *(Кисәк көлүдән туктап.)* Шуннан?

Х ы я л б а й. Шуңа чөй кыстырылган бүрәнә кирәк булды да урманга килдек...

Х ә й б у л а т. Берегез генә сөйләгез һәм сүзегезне кыска тотыгыз!

Т а з а м а т. Без андый бүрәнәне таптык. *(Сәхнә читенә карап кычкыра.)* Малайлар!

Ч ү р ә л е, Т ү р ә л е, Б ү р ә л е, юри кыланып, бөгелә-сыгыла, ух-вах килеп, теге бүрәнәне күтәреп керәләр дә учак тирәсенә куялар.

Х ә й б у л а т. Болар кемнәр тагын?

Т а з а м а т. Болар – шүрәле булып киенгән безнең малайлар...

Х ә й б у л а т. Шуннан...

Т а з а м а т. Күреп торасыз, бу бүрәнәне сөйри торгач, безнең җеп өзәрлек тә хәлебез калмады... Сигезенче кварталда гына җигүле атыбыз тора. Буш итмәс идек, абзыйлар. Шунда хәтле генә илтешмәссез микән? Төшкә хәтле кайтып җитмәсәк, директор абый ачулана инде...

Х ә й б у л а т. Директорыгызны әйтер идем... Бүрәнә күтәрергә бала-чага җибәрмәсә... Ярар, тиз генә илтеп тә куйдык ди... Ә ул сезнең «буш итмәс идек» дигәнегез ни аңлата?

Т а з а м а т. Безнең декорациягә-мазарга дигән акча бар ие...

Х ә й б у л а т. Ярар, сүз белән тамак туйдырып булмас... Бики, тот әйдә теге баштан! Бу бала-чагадан котылып булмас... Буш итмәбез, дип тә торалар...

Икесе дә бүрәнәгә иеләләр, кулларын ярыкка кыстырып
күтәрмәкче булалар.

Т а з а м а т. Чүрәле, әйдә, булыш абзыйларга!

Чүрәле тиз генә чөйне сугып чыгара. Тегеләр җиргә егылалар.

Х ә й б у л а т *(ярсып)*. Аһ, шайтан балалары! Кагыгыз чөйне җәтрәк! Аһ...

Б и к и. Үләм, Хәйбулат абзый, үләм!.. Ой!..

Т а з а м а т. Ничек соң, абзыйлар, без корган тозак? Куяннарның бәргәләнүе күз алдына килдеме?

Х ә й б у л а т. Аһ син, эт баласы!

Т а з а м а т. Ялгышасың, абзый. Мин дә синең кебек үк кеше. Тик синең кебек ерткыч түгел. Җәнлекләрне дә харап итеп йөрмим. Урманга да зыян китермим. Ә болар... *(Шүрәлеләргә күрсәтә.)* Чын шүрәлеләр. Алар да сезнең кем икәнлегегезне күптән беләә...

Х ә й б у л а т. Кулларны ычкындырыгыз, дим, сабакылар...

Т а з а м а т. Анысы булмас инде, абзыйлар. Бер диюне ычкындырып карадык инде без. Акылга утырганга охшамады. Бәлки, сез, авылга кадәр шушы бүрәнәне күтәреп кайткач, акылга утырырсыз...

Х ә й б у л а т. Кара син аларны, йомыркалар тавыкны өйрәтә башлады... Кулларны ычкындырыгыз, дим!

Х ы я л б а й. Тавышыгызны саклагыз, абзый. Кирәге чыгуы мөмкин.

Шулчак Хыялбай җәймә өстендә бер зур алма күреп ала.

Х ы я л б а й. Алма! Тазамат! Малайлар! Теге алма бит бу!

Хыялбай алмага дип омтыла, әмма аны алырга өлгерми. Хәйбулат алмага җан көче белән тибеп җибәрә.

Х ә й б у л а т. Кеше алмасына үрелмә, малакасус!

Кинәт, беренче күренештәге кебек, дөнья караңгылана. Нидер шалтырый, дөберди.

С е р л е т а в ы ш. Хыялбай! Иртәме-соңмы, син ул алманы табачаксың. Мин сиңа ышанам. Кешелекле бул, туг-рылыклы бул! Тазаматтан үрнәк ал!

Дөнья яктыра. Беренче күренештәге бакча. Х ы я л б а й алмагач төбендә ята. Тазамат эскәмиядә китап укып утыра.

Х ы я л б а й. Әллә төш күрдем инде мин. Бернәрсә дә аңламыйм. Шүрәлеләр, диюләр, җанкыярлар... Кызык!

Т а з а м а т. Мин дә бит синең яныңда идем, Хыялбай. Хәтерләмисең дә. Әкият дөньясында булдык бит!

Х ы я л б а й. Шулай бугай шул. Карале, Тазамат, теге шүрәлеләр нишләде микән инде?

Бакчага Г а л и я керә.

Г а л и я. Бөтен дөньяны бетереп сезне эзләп йөрим. Баксаң, сез монда алма санап ятасыз икән!

Т а з а м а т. Алма санамыйбыз, ә китап укыйбыз. Шулай бит, Хыялбай?

Х ы я л б а й. Шулай. Китап укыйбыз. Әкият китабы!

Г а л и я. Күрше авылда бер кызык хәл булган әле. Ишеттегезме?

Т а з а м а т. Нинди кызык ул? Сөйләп җибәр, булмаса!

Г а л и я. Ике абый урманнан бүрәнә күтәреп кайткан, ди. Ярыгына бармакларын кыстырып...

Тазамат белән Хыялбай сагаеп тыңлыйлар. Хыялбай яткан җиреннән сикереп тора. Башына бер алма төшә. Ул аны сизми.

Г а л и я. Шүрәлеләр кысты, дип әйтәләр, ди. Урманга бүтән аяк та атламыйбыз, дип әйтәләр, ди... Тагын нindидер алма шартлады, дип әйтәләр, ди...

Тазамат белән Хыялбай шаркылдап көлә башлыйлар.
Галия сәерсенеп карап тора-тора да үзе дә аларга кушыла.

Бетте.

## БЕЗ БАРАБЫЗ БӘЙРӘМГӘ

К А Т Н А Ш А Л А Р:

К ы ш м а л а й.
К а р к ү б ә л ә к.
К ы ш б а б а й.
К а р к ы з ы.
М а р с.
Ч у л п а н.
А ю.

Б ү р е.
Т ө л к е.
К у я н.
Җ ә н л е к - җ а н в а р л а р.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәһабәт ак сарай күренеше. Сарай тәрәзәләренең йөзлекләрендәге бизәкләр кар бөртекләрен хәтерләтә. Ике ак мәрмәр баганалы болдыр кыегында «Вакытстан сарае» дип язылган неон утлар уйнаклый. Ап-ак бакча: ак чыршылар, кар чәчәкләр үсеп утыра. Бер читтәрәк фонтан күренә, аннан кар бөртекләре сибелә. Аллеяларда – ак эскәмияләр… Кыскасы, мондагы һәрнәрсә әкияти ак дөньяны хәтерләтә. Кинәт сарай ишеге ачыла. Аннан сөмсерләре коелган ике яшүсмер – актан киенгән К ы ш м а л а й белән К а р к ү б ә л ә к килеп чыга.
Кыш малайның кулында – глобус.

К ы ш м а л а й *(кулындагы глобусны ваемсыз гына зырылдатып)*. Уф, тагын барып булмады! *(Глобусны читкә ыргытмакчы була.)*

К а р к ү б ә л ә к *(Кыш малайның кулыннан тотып)*. Юк-юк, Кыш малай, ыргыта күрмә. Ярамый!

К ы ш м а л а й. «Ярамый, ярамый!..» Ярамаганын беләм лә!.. Ачу килә бит. Былтыр булды былтыр баралмадык. Инде менә быел да өметебез сүнде... Һаман безне баласыталар...

К а р к ү б ә л ә к. Тиз генә үсә алмаганыбызга без генә гаепле түгел инде, иеме, Кыш малай?!

К ы ш м а л а й. Үстек бит инде. Тагын күпме үсәргә була?

К а р к ү б ә л ә к. Сиңа да унике яшь инде, иеме? Миңа да.

К ы ш м а л а й. Нишләп унике генә булсын! Бер елдан унөч яшь тула абзаңа! Син минем яшемне кечерәйтмәле, яме, Кар күбәләк!

К а р к ү б ә л ә к. Менәтерәк, нишләп кечерәйтим ди! Ике елдан минем үземә дә ундүрт яшь тула.

Шулвакыт сарай эчендә көлешкән тавышлар ишетелә.

К ы ш м а л а й *(ишек тарафына ишарәләп)*. Алар бәхетле-е! Алар бәйрәмгә бара! Әйдә китик... Безне күреп, безнең баралмаганны белеп сөенмәсеннәр әле...

Ишектән глобус тоткан К ы ш б а б а й белән иңсәсенә нәни букча аскан К а р к ы з ы чыга.

К а р к ы з ы. Менә, ниһаять, син дә, чал Гасыр бабай әйтмешли, тулы вә-ка-ләт-ле Кыш бабай булдың!

К ы ш б а б а й. Ә син – Кар кызы! Каяле, дүкәмитләргә тагын бер күз йөртеп алыйк әле.

К а р  к ы з ы *(букчасыннан кәгазьләр ала)*. Әле генә караган идек бит инде, Кыш бабай... Гелән-гелән карап, дүкәмитләрне таушалдырып бетермәгәек.

К ы ш  б а б а й. Борчылма, Кар кызы. Тагын бер караганнан гына таушалмый ул! Яле, ниләр язылган анда? Укып җиффәр әле!

К а р  к ы з ы. Монда бик матур сүзләр генә язылган инде, Кыш бабай.

К ы ш  б а б а й *(глобусны кочаклап, аны назлап-иркәләп)*. Укы син, укы! *(Рәхәтләнеп тыңларга әзерләнә.)*

К а р  к ы з ы *(кәгазьне әйләндереп карап)*. Нинди әйбәт кәгазьгә язганнар... Шоп-шома! *(Укый.)* «Яңа ел гали-җә-нап-лары...»

К ы ш  б а б а й *(Кар кызына карап, башын иеп ала)*. Без, ягъни мәсәлән...

К а р  к ы з ы. Әйе... «Яңа ел гали-җә-нап-лары... Кыш бабай белән Кар кызы...» *(Реверанс ясап ала.)* Мин, ягъни мәсәлән... *(Укуын дәвам итә.)* «...Татарстанның Олы Имән урманында узачак бәйрәм тантанасына җибәрелә...»

К ы ш  б а б а й. Шә-ә-әп!

К а р  к ы з ы *(кәгазьләрен букчага сала да кулларын чәбәкләп)*. Искиткеч!

К ы ш  б а б а й *(кулындагы глобусны әйләндереп)*. Карыйк әле, кай тирәдәрәк микән ул Олы Имән урманы? Тә-ә-әк... *(Икәүләшеп глобуска карыйлар.)* Әһә! Менә – Та-тар-стан... Татарстан... Матур исем, әйеме? *(Кар кызы, «әйе» дигәнне белдереп, башын селкеп ала.)* Әһә, таптым! *(Бармагы белән глобуска төртә.)* Менә ул Олы Имән урманы!

К а р  к ы з ы. Күңелем сизә, бик гүзәл урман булырга тиеш!

К ы ш  б а б а й *(бармагын Кар кызының борын очына тидереп)*. Нәфис борыным сизсә сизә инде диген...

К а р  к ы з ы *(күңеле булып)*. Шаяртмале, Кыш бабай.

К ы ш  б а б а й. Куанычтан шаяртасы гына килеп тора шул, Кар кызы.

К а р  к ы з ы. Җырлап та җибәрмисеңме соң, Кыш бабай?

К ы ш  б а б а й. Ә нигә? Җырлыйбыз да без аны! Биеп тә җибәрәбез!

Дәртле, шаян көй агыла. Кыш бабай җырлый башлый. Ул җырлаган чакта, салмак кына карлар ява. Кар кызы башта кул чабып тора.

К ы ш  б а б а й. Карлар ява тын гына,
Әйлән-бәйлән итәләр...
Кыш бабайны...

К а р  к ы з ы *(җырга кушылып)*. ...Кар кызын...

К ы ш  б а б а й. Һәммә җирдә көтәләр...

Җырның соңгы ике юлын янә кабатлыйлар.

К а р  к ы з ы
К ы ш  б а б а й *(бергә)*. Карлар ява тын гына,

Карлар куна учларга...
Ак бәхетләр, шатлыклар –
Бездән теләк дусларга!..

Соңгы ике юлны үзгәртеп җырлыйлар.

Кыш бабай. Якты җырлар...
Кар кызы. ...шат җырлар –
Кыш бабай
Кар кызы (бергә). Бездән бүләк дусларга...

Җыр көе акрын гына ераклаша, сүнә.

Кыш бабай. Ашыгыйк, Кар кызы. Юлга кузгалырга кирәк. Аңарчы, өйгә кайтып, биштәрне дә аласы бар.

Кар кызы. Тылсымлы таягыңны да онытмыйк тагы!

Кыш бабай. Әйе шул. Әле ярый исемә төшердең... Киттек әйдә!

Кар кызы. Киттек, Кыш бабай!

Китәләр. Кыш малай белән Кар күбәләк яшеренгән урыныннан чыга.

Кыш малай. Шатланган булалар...

Кар күбәләк. Алар урынында без булсак, без дә сөенгән булыр идек, иеме, Кыш малай?!

Кыш малай. Әле ничек кенә сөенгән булыр идек! Ичмасам, менә шушы тирәгә булса да җибәрмәде безне чал Гасыр бабай... *(Глобусның култоткасына төртеп күр-сәтә.)*

Кар күбәләк. Син нәрсә, Кыш малай! Анда беркем дә яшәми бит!

Кыш малай. Әй лә... Аптыраганнан әйтәм инде...

Кар күбәләк. Аптыраган-йөдәгән, артын мичкә терәгән!

Кыш малай. Терәрсең дә монда! *(Әрле-бирле йөренә. Кинәт үз башына сугып ала да кычкырып җибәрә.)* Эв-ри-ка! Таптым!

Кар күбәләк. Нәрсә таптың, Кыш малай?

Кыш малай. Таптым! Яңа ел бәйрәменә бару җаен таптым!

Кар күбәләк. Әйт инде тизрәк, Кыш малай!

Кыш малай. Таптым... Без дә бәйрәмгә барабыз!

Кар күбәләк. Ничек итеп?

Кыш малай. Очып китеп!

Кар күбәләк. Ничек очып?

Кыш малай. Глобусны кочып!

Кар күбәләк. Шаяртмале, Кыш малай...

Кыш малай. Ә мин шаяртырга уйламыйм да! Беләсеңме, без дә Олы Имән урманына барабыз!

Кар күбәләк. Безнең дүкәмит юк бит, Кыш малай!

Кыш малай. Ә без дүкәмитсез барабыз.

К а р  к ү б ә л ә к. Дүкәмитсез безгә кем ышансын.

К ы ш  м а л а й. Ышанырлар... Ышандырырбыз!

К а р  к ү б ә л ә к. Соң бит... Анда алар да... Кыш бабай белән Кар кызы да булачак!

К ы ш  м а л а й. Алар кыймылдаганчы, без әллә кайчан анда булабыз инде! Җырла әйдә, Кар күбәләк... әй лә... Кар кызы! *(Үзе җырлый башлый.)*

Мин дә кидем ак оек,
Син дә кидең пар оек...

К а р  к ү б ә л ә к *(җырга кушыла)*.

Әйдә киттек бәйрәмгә!
Әйдә тизрәк барыек!..
Карлар яусын тын гына,
Кунсын алар учларга...
Без үзебез шәп бүләк
Көтеп алган дусларга!..

Җырның соңгы ике юлын болар да янә бер мәртәбә кабатлыйлар.

К а р  к ү б ә л ә к. Кыш малай, син, барабыз-барабыз, дисең дә бит... Безнең бәйрәмдә кия торган киемнәребез юк ич. Киемсез безгә беркем дә ышанмаячак!

К ы ш  м а л а й. Борчылма, Кар күбәләк... әй лә... Кар кызы. Син миңа таян!

Кар күбәләк, Кыш малайның соңгы сүзләрен туры мәгънәсендә аңлап, аның кайсы төшенә таянырга белмичә тора. Ниһаять, ул аның иңсәсенә таяна.

К ы ш  м а л а й *(гаҗәпсенеп)*. Нишлисең син, Кар күбәләк?

К а р  к ү б ә л ә к. Соң... Миңа таян, дисең ич!

К ы ш  м а л а й. Һәй, тиле кызый... Мин бит сиңа акыллы өлкәннәр шикелле образлы итеп кенә әйттем.

К а р  к ү б ә л ә к. Ә-ә-ә... образсыз итеп кенә әйтсәң ничек була?

К ы ш  м а л а й. Образсыз итеп әйтсәк, болай була: син минем тылсымлы сүзләр белүче оста икәнемне беләсең бит инде?..

К а р  к ү б ә л ә к. Беләм, беләм...

К ы ш  м а л а й. Мин менә шундый сүзләр әйтүгә, минем өстә Кыш бабай киеме, синең өстә Кар кызы киеме була да куя! Аңлаганскимы?

К а р  к ү б ә л ә к. Башта ук шулай образсыз итеп кенә әйтәләр аны. Менә хәзер аңлашылды.

К ы ш  м а л а й. Аңлашылса, киттек алайса.

К а р  к ү б ә л ә к. Кит-тек! Олы Имәнгә – бәйрәмгә!

Җитәкләшеп чыгып китәләр.

## **И К Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш**

Матур итеп җиһазланган авыл өе эче. Стенага календарь эленгән – анда «31 декабрь» дигән язу шәйләнә. Көзге каршысына басып, үзенә соклана-соклана, Ч у л п а н җыру җырлый.

Ч у л п а н. Аяз күктә ай йөзә,
Йолдызлар җем-җем яна.
Сибелә якты нурлар
Төнге зәңгәр дөньяга...

Ишек тарафында кулына кәшәкә тоткан М а р с күренә.
Ул, ишек борысына сөялеп, җырны тыңлый.

Ай йөзгән күк йөзендә
Бер йолдыз булсаң иде...
Җем-җем янып, дөньяга
Нур сибеп торсаң иде...

Кинәт Марсның кәшәкәсе, кулыннан ычкынып, идәнгә шапылдый. Чулпан сискәнеп борыла.

Ай!

М а р с. Мин ай түгел, *(сүзгә басым ясап)* пла-не-та! *(Кәшәкәсен иелеп ала.)* Марс мин! Ә син – борчак хәтле йолдызчык! Чулпанчик ягъни!

Ч у л п а н. Куркыттың ич!

М а р с. Пардон, мерсимадам! Мин түгел, менә бу таяк куркытты сине! Гафу ит син аны, пажалысты!

Ч у л п а н *(көлеп)*. Бу кисәү таягы синекедер ич?

М а р с. Бу... син әйткән әллә нинди кисәү таягы түгел... Бу – кәшәкә бу!

Ч у л п а н. Кәкре булгач, барыбер инде... Синекедер бит?

М а р с. Минеке! Кемнеке булсын тагы?

Ч у л п а н. Шулай булгач... Димәк, син мине куркыткан булып чыгасың инде...

М а р с. Ярар. Синеңчә булсын. Тагын бер мәртәбә гафу ит. Карале, син әйбәт кенә җырлыйсың икән бит. Миңа ошады.

Ч у л п а н *(оялып)*. Рәхмәт.

М а р с. Син үскәч Казанга кил. Мин сине җырчы итәм. Мине Казанда бөтен кеше белә. Көн саен телевизордан җырларсың...

Ч у л п а н. И-и, мактанчык!

М а р с. Мин мактанчык булсам, син – Чулпанчик! Икебез дә – «чик-чик»!

Ч у л п а н. Мактанчик түгел, мак-тан-чык!

М а р с. Үзең әйткәндәй, барыбер инде.

Ч у л п а н. Бармыйм мин синең Казаныңа.

М а р с. Нигә?

Ч у л п а н. Шәһәрдә куркам мин.

М а р с. Курыкма. Минем машинага гына утырып йөрер-сең.

Ч у л п а н. Китчәле, мактанчык! Синең машинаң юк бит.

М а р с. Булмаса булыр. Әти алып бирә аны миңа. Вилсәпид алырлык акчабыз бар инде безнең!

Ч у л п а н. Синең әле вилсәпидең дә юкмыни?

М а р с. Минеке юк, дус малайныкы бар... Әй, миңа вилсәпид кирәкми лә... Машина кирәк миңа!

Ч у л п а н. Син әле машинаны йөртә дә белмисеңдер?

М а р с. Өйрәнәм мин. Айн момент! Йә, утырасыңмы минем машинага?

Ч у л п а н. Башта үс, машина ал, аннан карармын...

М а р с. Карыйсы юк. Минем машинага утырасың да җырлап кына йөрисең...

Ч у л п а н. Әй лә, утырмыйм. Куркам. Йә берәр баганага бәрелерсең...

М а р с. Минме? Бәрелде ди! Мин бит сигналны кычкыртам! Пип-пип!

Ч у л п а н *(көлеп)*. Шуннан соң багана читкә тайпыламы?

М а р с. Тайпыла, тайпыла! Тайпылмаса, тормозга басам! Карале, аптыратмале шул баганаң белән... Мин бит сине алырга кергән идем. Әйдә минем белән барасыңмы?

Ч у л п а н. Кая?

М а р с. Урманга. Чыршы бәйрәменә. Шунда җырларсың да.

Ч у л п а н. Нинди чыршы бәйрәме? Урманда андый бәйрәм була димени? Авылда була ич ул!

М а р с. Авылда да була, шәһәрдә дә. Беләсең килсә, урманда да була!

Ч у л п а н. Анда кемнәр бәйрәм итә соң? Урман җән-лекләреме?

М а р с. Әһә! Бүреләр, төлкеләр, куяннар...

Ч у л п а н. Әйем лә... Мин бармыйм. Куркам.

М а р с. Курыкма. Мин барында, сиңа беркем дә тимәс!

Ч у л п а н. Ә син кайдан белдең?

М а р с. Нәрсәне?

Ч у л п а н. Бүген урманда бәйрәм буласын.

М а р с. Бабакай әйтте. Әллә син аның урманчы икәнен оныттыңмы? Ул бөтенесен дә белеп тора. Йә, барасыңмы инде минем белән? Әгәр бармасаң, үзем генә китәм.

Чу л п а н *(икеләнеп)*. Барам. Тик... мин барыбер куркам. Бүре тисә?

М а р с. Курыкма, дип әйттем бит инде мин сиңа. Бабакай әйтә, бүреләр әйбәт кешеләргә тимиләр, ди. Миңа тимиләр дә тимиләр инде... Чөнки мин – шәп кеше! Син дә әйбәттер бит?!

Ч у л п а н. Бел-мим... Ул турыда уйлаганым булмады.

М а р с *(Чулпанны баштанаяк күздән кичереп)*. Болай әйбәт кешегә охшагансың. Сиңа тимәскә тиешләр. Аннан соң син бүген бәйрәм көн икәнен онытма! Кайсы җүләрнең бәйрәмнең ямен җибәрәсе килсен. Әйдә, кыймылда. Соңга калмыйк тагы!

Ч у л п а н. Мин әле матур киемнәремне дә кимәгән...

М а р с. Киен соң!.. Җылырак киен. Салкын тидереп өйдә ятарлык булмасын! Карале, син берәр битлек тә ал инде, яме. Мин бүре булып киенәм.

Ч у л п а н. Ярар, куян булып киенермен алайса. Син аз гына көтеп тор.

М а р с. Аз да түгел, күп тә түгел – биш секунд вакыт сиңа!

Ч у л п а н. Биш секунд? Биш секундта мин сыңар катамны да киеп өлгералмыйм ич!

Чулпан киемнәрен алып кия башлый.

М а р с. Өлгерерсең нибуч! *(Ишетелер-ишетелмәс кенә көйли.)*
Аякта киез ката,
Атлаган саен бата...

Ут сүнә.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Урман клубы. Бәйрәмчә җиһазланган. Урта бер җирдәрәк матур итеп бизәлгән чыршы тора. Тиз-тиз атлап, көлешә-көлешә, Б ү р е белән К у я н килеп керә. Икесе дә букча тоткан.

Б ү р е *(як-ягына каранып)*. Башкалар килеп җитмәгән икән әле. Без синең белән беренчеләр!

К у я н. Килерләр, әле вакыт бар бит.

Б ү р е. Назлыгөл, син бәйрәмгә кем булып киенәсең?

К у я н. Белер идең бугай? Белмичә генә тор әле, яме.

Б ү р е. Әйт инде. Бәйрәмдә барыбер беләм бит.

К у я н. Алдан әйтсәң, кызыгы бетә аның.

Б ү р е. Ә мин, беләсеңме, кем булып киенәм?

К у я н. Әйтсәң беләм.

Б ү р е. Сиңа гына әйтәм. Бүтәннәргә әйтмә, яме? Мин шәһәрдән авылга кунакка кайткан малай булып киенәм. *(Букчасын күрсәтә.)* Киемнәр таптым инде.

К у я н. Ә мин... ә мин... Әй, әйтмим әле...

Б ү р е. Әйт инде, Назлыгөл. Мин әйттем бит.

К у я н. Башкаларга әйтмисеңме соң?

Б ү р е. Юк инде, юк. Ант менә!

К у я н. Мин авыл кызы булып киенәм. Чулпан булып!

Б ү р е. Чулпан? Кайсы... Теге... Куркак кызыймы ул? Быел җәй көне җиләккә килгәч, мине күреп, «Карауы-ыл!» дип кычкырып, тырысын ташлап качканые... Шулмы?

К у я н. Әйе инде, әйе. Нәкъ шул булып киенәм. Тик син бүтәннәргә әйтмә, яме?

Б ү р е. Ярар, дидем бит инде. Ул куркак кызый җырлый да беләдерие түгелме соң?

К у я н. Белә. Бик матур җырлый.

Б ү р е. Сине, алайса, бәйрәмдә җырлатабыз икән.

К у я н. Мин җыр өйрәндем инде. Җырлап күрсәтим-ме?

Б ү р е. Җыр тыңларга яратам мин. Әйдә, сиптер әйдә!

К у я н *(җырлый)*. Аяз күктә ай йөзә,
Йолдызлар җем-җем яна.
Сибелә якты нурлар
Төнге зәңгәр дөньяга...

Б ү р е *(кул чабып)*. Шәп җырлыйсың икән бит син дә!

К у я н. Мин бит Чулпан булып кына җырладым. Бөтенләй җырлый белмим мин...

Б ү р е. Сиңа әртис кенә буласы калган... Зерә әрәм булып ятасың син безнең Олы Имән урманында.

К у я н *(мактаганга күңеле булып)*. Ул хәтле үк үтереп мактама инде, Бүринур. Борыным күккә тия ич.

Б ү р е. Жәл, мин дә синең шикелле җырлый белмим.

К у я н. Аның каравы син такмак әйтә беләсең. Сөйләле берәр такмак.

Б ү р е. Такмак такмак кына шул... Җыр түгел... Ярый инде, бик кыстагач, бер такмак сөйләми булмас.
Югары очтан түбән очка
Бер көчек өреп кайта...
Сукыр тычкан китап укый,
Мәче кикереп ята.

К у я н *(көлә-көлә кул чәбәкләп)*. Тагын берне, тагын берне сөйлә инде!

Б ү р е. Су эчендә печән чаба
Ике сарык, бер тәкә.
Бүре буй үстергән чакта
Кайда идең, бүтәкә?..

К у я н *(көлеп)*. Уф! Көлдереп үтерәсең ич, Бүринур...

Б ү р е *(көлеп)*. Үлә күрмә, Назлыгөл. Мине минават итәрсең җә!..

Шулвакыт тышта көлешкән-сөйләшкән тавышлар ишетелә.

К у я н. Киләләр. *(Тәрәзәгә карый.)* Аю белән Төлке килә!

Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кышкы урман аланы. Агачлар, куаклар. Сул тарафтарак – киселгән төп. Урта бер җирдә үсеп утырган куак янәшәсендәге баганачыкка «Урман клубы» дип язылган күрсәткеч такта беркетелгән. Баганачык яныннан ике юл китә. Мышкылдый-мышкылдый, сул яктан К ы ш м а л а й белән К а р к ү б ә л ә к килеп керә.

К а р к ү б ә л ә к. Уф! Мин арыдым, Кыш малай. *(Агач төбенә утыра.)* Барып җитәбезме инде?

К ы ш  м а л а й. Әз генә түз инде, Кар күбәләк. *(Күрсәт-кеч такта янына килә.)* Менә монда юлны күрсәтүче такта да беркетелгән икән. Әйдә, әйдә, Шүрәле карчыгы шикелле утырма җәелеп!

К а р  к ү б ә л ә к. Аз гына ял итеп алыйм инде, Кыш малай... Арыдым бит!

К ы ш  м а л а й. Барып җиткәч, иркенләп ял итәрбез. Әйдә, әйдә!

Кар күбәләк авырлык белән генә урыныннан кузгала.

К а р  к ү б ә л ә к. Күтәреп бар инде мине, Кыш малай. Син бит арымаган...

К ы ш  м а л а й *(сукранып)*. Болай җәфа буласыңны белгән булсам, сине ияртми идем мин. Әйдә кил, җилкәгә асылын!

К а р  к ү б ә л ә к *(Кыш малайның җилкәсенә ятып)*. Син – такси ди, иеме, Кыш малай?

К ы ш  м а л а й. Әһе. Ике аяклы такси! *(Бер-ике адымны көчкә атлый.)* Ай-яй авыр... Бер тонна бардыр син?!

К а р  к ү б ә л ә к. Тун авыр минем. Үзем ярты кило да юк мин.

К ы ш  м а л а й. Белмим, белмим... Ярты киломы син, ике граммы... Әмма сине сөйрәргә чаналы трактор кирәк. Монысы – факыт! Төш әйдә... Болай итеп барып булмый. Җитәклим генә.

Бераз җитәкләшеп баргач, Кыш малай, тукталып,
артына борылып карый.

К а р  к ү б ә л ә к. Ник тукталдың, Кыш малай?

К ы ш  м а л а й. Бара тор, Кар күбәләк. Мин хәзер.

Кар күбәләк, артына карый-карый бара тора. Кыш малай, күрсәткеч такта янына килә дә аңа бертын карап тора. Аннан баганачыкны куак төбенә таба авыштыра. Тиз генә Кар күбәләк артыннан йөгерә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук күренеш. К ы ш  б а б а й белән К а р  к ы з ы керә.
Кыш бабай аркасында – биштәр, кулында – тылсымлы таяк.

К а р  к ы з ы. Нинди гүзәл урман, әйеме, Кыш бабай?

К ы ш  б а б а й. Нәкъ син сизенгәнчә инде, Кар кызы. Әйдә ял итеп алыйк әле бераз.

Икесе дә бер төп өстенә җайлашып утыралар.
Кыш бабай таягын читкә куя.

К а р  к ы з ы. Җәнлекләр безне көтә-көтә көтек булганнардыр инде?!

К ы ш  б а б а й. Көтәләр инде, Кар кызы, көтәләр. Синең белән мине һәрбер җирдә шулай көтеп алалар. Борын-борын заманнардан бирле калган гореф-гадәт. Алар көтә, без киләбез!

К а р   к ы з ы. Бүләкләр алып, әйеме, Кыш бабай? *(Кыш бабайның биштәренә җиңелчә генә сугып ала.)* Монда бүләкләр барысына да җитәрлек!

К ы ш   б а б а й. Артып та кала әле.

К а р   к ы з ы. Чынлапмы? Аларын нишләтәбез?

К ы ш   б а б а й. Аларын да өләшеп бетерәбез. *(Көлә.)* Кире алып китмәбез бит инде.

К а р   к ы з ы. Мин Яңа ел бәйрәмен шундый яратам, Кыш бабай, шундый яратам! Ә син?

К ы ш   б а б а й. Яңа ел бәйрәмен яратмаучылар юктыр аны, Кар кызы! Мондый искиткеч бәйрәм елга бер генә килә бит!

К а р   к ы з ы. Әйдә инде, Кыш бабай, атлый торыйк! Минем тизрәк бәйрәм тамашасында буласым килә!

К ы ш   б а б а й. Син, Кар кызы, бер генә дә арымадыңмыни соң?

К а р   к ы з ы. Юк, Кыш бабай, кечтеки генә дә арымадым.

К ы ш   б а б а й. Маладис та инде син, Кар кызы! Мәрхәбә! Синең белән бергә бару – үзе бер бәйрәм! Әйдә кузгалыйк, булмаса...

Икесе дә урыннарыннан торалар. Кыш бабай таягын алырга оныта.

К а р   к ы з ы *(ике тарафка китүче юлга карап)*. Кыш бабай, монда юллар икәү бит! Кайсысы белән барабыз?

К ы ш   б а б а й *(юлларга карап)*. Монысыннан китәрбез, шәт. *(Кыш малай белән Кар күбәләк китмәгән юлга таба ишарәли.)* Шушы юл илтер безне, мөгаен...

Китәләр. Алар китүгә, аланга М а р с белән курка-курка гына Ч у л п а н керә. Марсның җилкәсендә нәни биштәрләр – аларга бәйрәм киемнәре салынган.

Ч у л п а н. Марс, мин куркам...

М а р с. Курыкма, Чулпан, килеп җитәбез бит инде. Аз гына барасы калды.

Ч у л п а н. Аз гына барасы калганын каян беләсең, Марс? Син бит шәһәр малае!

М а р с. Шәһәр малае булсам да, мин бит урманчы оныгы! Бабай миңа юлны өйрәтте. Монда юл күрсәткеч булырга тиеш! *(Як-ягына каранып эзләнә, куак төбендә яткан багананы күреп ала.)* Әйттем бит, менә ул! Ауган. Җил аударгандыр инде. *(Торгызырга азаплана.)*

Ч у л п а н *(төп янына килә, шуңа утырыйм дигәндә генә, Кыш бабай онытып калдырган таякны күреп ала)*. Таяк?! Марс, мин таяк таптым!

Күрсәткеч такталы багананы бастырып куйган Марс Чулпанга борылып карый.

М а р с. Таяк? Нинди таяк ул? *(Чулпан янына килә дә таякны кулына алып әйләндереп карый.)* Берәрсе онытып калдыргандыр моны.

Ч у л п а н. Кыш бабайныкы түгел микән бу?

М а р с. Син нәрсә, Чулпан, Кыш бабай таягын онытып йөрмәс инде!

Ч у л п а н. Алай димә, Марс, бабайлар хәтерсез була алар.

Марс таякның түгәрәк башын җентекләп караганда, ялгыш борып җибәрә. Кинәт аланга караңгылык иңә.

Ч у л п а н т а в ы ш ы. Ай! Нинди караңгы! Мин куркам, Марс...

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Караңгылык кинәт яктылык белән алышына. Тирә-юньдә яшеллек күзгә ташлана. К ы ш б а б а й белән К а р к ы з ы аптырап басып калганнар.

К а р к ы з ы. Нәрсә бу? Без кайда, Кыш бабай?

К ы ш б а б а й. Таяк! Минем тылсымлы таягым!

К а р к ы з ы. Мин эсседи башладым, Кыш бабай!

К ы ш б а б а й. Кар кызы, мин бая таякны онытып калдырганмын бит! Һай, хәтерсез башкайларым! Кемдер шуны табып шаярта бугай. Әйдә тизрәк, кире киттек!

К а р к ы з ы. Мин эри башладым, Кыш бабай!

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бишенче күренештәге аланлык. Ул шулай ук ямь-яшел. Ч у л п а н аптырап М а р с к а текәлгән.

Ч у л п а н. Марс, ни булды урманга? Нишләп барысы да ямь-яшел? Кыш кая китте?

М а р с *(аптырап)*. Белми-им... Мин бу таякның башын борган идем. Әллә бу таяктамы хикмәт?

Ч у л п а н. Мин куркам, Марс...

М а р с. Хәзер таяк башын кирегә борып карыйм. Бәлки, чыннан да, Кыш бабай таягыдыр бу?!

Ч у л п а н. Шуныкы инде, шуныкы! Кыш бабайның тылсымлы таягы! Тизрәк бор инде, Марс!

Марс таяк башын кирегә бора. Кинәт урманга янә караңгылык иңә. Аны янә яктылык алыштыра – урман аланы әүвәлге кышкы
халәтенә кайта.

М а р с. Кыз-зы-ык! Могҗиза дисәң дә могҗиза бу!

Ч у л п а н. Мин куркам, Марс... Зинһар, урынына кире куй таякны. Бүтән боргалый күрмә.

М а р с. Юк, таякны калдырмыйбыз. Үзебез белән алабыз. Моны, чынлап та, Кыш бабай калдырган булырга тиеш! Бәйрәмгә баргач, үзенә тапшырырбыз. Бәлки, эзли дә торгандыр инде. Әйдә, ашыгыйк!

Китәләр.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман клубының тышкы яны. Тәрәзә янында К ы ш  м а л а й  белән К а р  к ү б ә л ә к. Тәрәзә аша эчкә карыйлар.

К а р  к ү б ә л ә к. Чыршыны ничек матур итеп бизәгән-нәр!

К ы ш  м а л а й. Син бүрегә кара, бүрегә!

К а р  к ү б ә л ә к. Бүре? Кайда бүре? Мин аны күрмим ич!

К ы ш  м а л а й. Әнә бит! Койрыклы малайга кара! Шул бит инде бүре. Малай кеше булып киенгән!

К а р  к ү б ә л ә к. Күрдем, күрдем! Ул бүремени? Мин аны бит чынлап та малай дип торам.

К ы ш  м а л а й. Әнә тегесе – куян. Күрәсеңме? Кыска койрыклы кызга кара әле.

К а р  к ү б ә л ә к. Күрдем, күрдем! Аны да күрдем! Әйдә, без дә керик инде шунда!

К ы ш  м а л а й. Ашыкма, йә ашка пешәрсең!

К а р  к ү б ә л ә к. Нинди аш? Анда аш күренми бит!

К ы ш  м а л а й. Мин бит сиңа образлы итеп әйттем.

К а р  к ү б ә л ә к. Ә-ә-ә...

К ы ш  м а л а й. Минем бит әле сихер-михер сүзләрен әйтәсем бар. Миңа – Кыш бабай, сиңа Кар кызы булып керергә кирәк.

К а р  к ү б ә л ә к. Әйдә алайса, мине тизрәк Кар кызы ит!

К ы ш  м а л а й. Хәзер. Бас минем янга. Бир кулыңны.

Кулга-кул тотынышып басалар.

К а р  к ү б ә л ә к. Тизрәк, Кыш малай, тизрәк!

К ы ш  м а л а й. Әчтер-печтер, чүпсәләй!.. Кыштыр-мыш-тыр, мүкҗәләй!.. *(Төчкерәсе килеп, авызын зур итеп ача.)* Әп... әп... әпчехи!.. *(Кабат төчкерә.)* Ә-ә-п-чехи!

Икесе дә кинәт сәер Кыш бабайга һәм сәер Кар кызына әйләнә: Кыш малай Кар кызы киеменнән, ак толымнан, ә Кар күбәләк, киресенчә, Кыш бабай киеменнән, сакаллы.

К а р  к ү б ә л ә к *(Кыш малайга бармагын төртеп көлеп җибәрә).* Си... синме Кыш бабай? Көлдереп үтерәсең ич!..

К ы ш  м а л а й *(төксе генә).* Үзеңә кара башта! Аннан көләрсең...

К а р  к ү б ә л ә к *(үзенә карап, сакалын томкалап).* Мин... мин... Ай! Мин кем, Кыш малай? Нишләттең син мине?

К ы ш  м а л а й *(янә төчкерә).* Ә-ә-әп-чехи! Син дә клоун, мин дә клоун! Вәйт менә кемнәр без... Ә-ә-әпчехи!

К а р  к ү б ә л ә к. Миңа карап төчкермәле! Ә-ә-әпчехи!.. Нәрсә булды безгә?

К ы ш  м а л а й. Сихри сүзләрне әйткәндә әпчехиләп ялгыштым... Шулай килеп чыкты...

К а р  к ү б ә л ә к. Хәзер нишлибез инде? Әйдә, тизрәк кабат әйт сихер-михереңне!

К ы ш  м а л а й. Булмый. Бүтән әйтүдән файда юк. Ялгышырга ярамый иде миңа. Төчкерү харап итте.

К а р  к ү б ә л ә к. Алайса, тиз генә элекке халәтебезгә кайтара торган сихри сүзләреңне әйт!

К ы ш  м а л а й. Файдасыз. Андый сүзләр көчсез хәзер. Их, ялгышырга ярамый иде миңа...

К а р  к ү б ә л ә к. Берәр нәрсә уйлап тап инде, Кыш малай. Сакал иякне кычыттыра башлады...

К ы ш  м а л а й. Сиңа да, миңа да түзәргә туры кил-мәгәе!

К а р  к ү б ә л ә к. Кайчанга тиклем түзәргә?

К ы ш  м а л а й. Кыш бабай килгәнче. Безне ул гына әүвәлге халәтебезгә кайтара ала.

К а р  к ү б ә л ә к. Ыз-драсте, кодагый! Килеп җиттек алайса! Уеннан уймак чыгардык!

К ы ш  м а л а й. Нинди уймак? Ни сөйлисең син?

К а р  к ү б ә л ә к. Берни дә сөйләмим. Синең шикелле... *(сүзгә басым ясап әйтә)* о-образлы итеп кенә әйттем...

К ы ш  м а л а й. Ташлале. Шаярта торган чакмыни!

К а р  к ү б ә л ә к. Түтү бәйрәм! Әллүк кирегә! Барысы да синең аркада...

К ы ш  м а л а й. Чәпчемәле син! Уйларга ирек бир.

К а р  к ү б ә л ә к. Башта ук уйлыйлар аны. Көймәң комга килеп терәлгәч түгел...

К ы ш  м а л а й. Нинди көймә турында сөйлисең син? Ычкына башладың мәллә?

К а р  к ү б ә л ә к. Синең шикелле... *(янә басым ясап әй-тә)* о-образлы итеп сөйлим ич!

К ы ш  м а л а й *(ачуы килеп)*. Чукындың инде шул образлы сүзләрең белән! Сине иярткән мин җүләр!

К а р  к ү б ә л ә к. Ияртмәскә иде! Мин монда сакаллы тиле хәлендә калмас идем. Синең аркада бәйрәм күралмый калам хәзер.

К ы ш  м а л а й. Лыгырдама дидем бит инде! Күрәбез ул бәйрәмне! Керәбез дә күрәбез.

К а р  к ү б ә л ә к. Шушы кыяфәт беләнме?

К ы ш  м а л а й. Ә нигә? Шушы кыяфәт белән! Безнең бүтән юл юк. Әйдә атла, ни булса – шул булыр... *(Ишеккә таба бара.)*

К а р  к ү б ә л ә к *(теләр-теләмәс кенә аңа ияреп)*. Күрәселәр алда икән әле!..

Клуб эчендә «Кыш бабай! Кар кызы! Тизрәк килегез!» дигән сүзләр ишетелә.

### ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Дүренче күренештәге урман аланы. К ы ш  б а б а й  белән  К а р  к ы з ы  әүвәл киткән юлларыннан уфылдый-уфылдый кире әйләнеп кайта.

Кар кызы *(агач төбенә килеп утырып)*. Уф! Таякны онытуың аркасында күпме вакытны әрәм иттек, Кыш бабай...

Кыш бабай. Әйтмә дә инде, Кар кызы. Гафу ит мин хәтерсезне. Интектереп йөрттем сине.

Кар кызы. Интегүен интекмәдем лә мин... Кайда соң таягың, Кыш бабай? Кай төштә калдырган идең? *(Як-ягына карана. Кыш бабай таягын эзли.)*

Кыш бабай. Менә шушы син утырган төп кырыена гына куйган сыман идем...

Кар кызы. Монда юк бит, Кыш бабай. Бүтән җирдә калдырмагансыңдыр ич?

Кыш бабай *(һаман эзләнеп)*. Юк инде, Кар кызы, юк... Шушында гына куеп торган идем. Берәрсе тапкандыр да алып киткәндер инде, мөгаен... Хараплар гына булдык... Таяксыз ак сарайга кайтырга ярамый ич безгә!

Кар кызы. Син кайту турында уйлыйсың, Кыш бабай... Әле бит без бәйрәмгә дә барып җитмәгән!..

Кыш бабай. Барырбыз, Кар кызы, барырбыз. Бәйрәм дә күңелле узар. Анысына шикләнмим мин. Менә таяксыз калдык, таяксыз! Шуңа эч поша!..

Кар кызы. Хәзер нишлибез инде, Кыш бабай?

Кыш бабай. Алдан ук кайгырмыйк әле. Бәлки, берәр игелекле җан иясе кулына эләккәндер таяк?! Яхшыга өметләник. Табылыр, иншалла!

Кар кызы. Әйт сүзеңне, Кыш бабай!

Кыш бабай. Кузгалыйк без, Кар кызы. Көттермик дусларыбызны.

Кар кызы урыныннан тора. Күрсәткеч тактаны күреп ала.

Кар кызы. Кыш бабай! Карале, юл күрсәткеч! Баягынак юк иде шикелле...

Кыш бабай *(багана янына килеп)*. Әйе шул. Юк иде, ә хәзер бар. Кызы-ык һәм сә-ер... Бу юл күрсәткеч дөрес күрсәтсә, без бит бая ялгыш юлдан киткән булып чыгабыз түгелме соң?

Кар кызы. Шулай шул, Кыш бабай!

Кыш бабай. Әле күпме адашып йөргән булыр идек... Болай булгач, онытылып калган таякка рәхмәт кенә укыйсы инде безгә!.. Әйдә, Кар кызы, ашыгыйк!..

Кар кызы. Әйдә, Кыш бабай!

Китәләр. Ут сүнә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Клуб эче. Җәнлек-җанварлар чыршы тирәли әйләнә-әйләнә кычкыралар:

– Кыш ба-бай!
– Кар кы-зы!

– Тиз-рәк ки-ле-гез!

Ишектән Кыш малай белән Кар күбәләк күренә. Җәнлекләр аларны күреп кинәт туктап калалар.

Кыш малай. Исәнмесез, дуслар!

Кар күбәләк. Саумысез!

Җәнлекләр бер-берсенә карашалар.

Җәнлекләр *(барысы бергә)*. Ис-сән-ме-сез!

Бүре *(кайсына карарга белмичә)*. Ис-сән-ме, Кыш бабай!

Куян *(күзләрен шарландырып)*. Ис-сән-ме, Кар кызы!

Кыш малай. Бәйрәмегез мөбарәк булсын!

Кар күбәләк *(үзе дә сизмичә сакалын сыйпап)*. Әйе, түгәрәк булсын!

Аю. Бергәләп узсын!

Төлке. Рәхим итегез!

Бүре *(Куянга пышылдап)*. Син берәр нәрсә аңлый-сыңмы?

Куян *(башын селкеп)*. Юу-у-ук...

Кыш малай. Безне сагынып көткәнсездер инде, дуслар?!

Бүре. ...көттек дип...

Куян. ...көттек инде!..

Җәнлекләр *(бергә)*. Ие, көттек инде!

Кыш малай. Атлап түгел, чабып килдек...

Кар күбәләк. Килә-килә арып беттек...

Кыш малай *(Кар күбәләккә пышылдап)*. Мин тагын нәрсә дияргә тиеш әле?

Кар күбәләк *(җилкәсен сикертеп)*. Әллә тагы... Белмим...

Кыш малай *(җәнлекләргә)*. Ә... әйе... Арый-арый килеп беттек!..

Кар күбәләк *(аның толымыннан тартып)*. Ни сөйлисең син, Кыш бабай?

Кыш малай *(каушап, аптырап торган җәнлекләргә)*. Ә... әйе... Бетә-бетә килеп ардык!..

Куян *(«Кыш бабай» янына килә дә аның толымын тотып карап)*. Син... чынлап та Кыш бабаймы соң?

Кыш малай. Кыш бабагыз инде, Кыш бабагыз... Яраткан Кыш бабагыз!

Бүре *(Кар күбәләкнең сакалын тотып карап)*. Син дә... Кар кызымы?

Кар күбәләк. Әйе, Кар кызы мин!

Бүре. Ә нишләп сакалың бар синең, Кар кызы?

Кар күбәләк *(ни әйтергә дә белмичә)*. Сакалмы? Әйе шул, сакалым бар минем. Мин бит... Ни бит...

Б ү р е *(кинәт сөенеп)*. Ә-ә-ә... Белдем-белдем! *(Кыш малайга да, Кар күбәләккә дә карый-карый.)* Сез бит... Кызык булсын өчен шулай иткәнсез... Шулай бит?!

К ы ш  м а л а й *(куанып, Бүренең башыннан сыйпый)*. Башлы да икәнсең үзең! Әйе, без сезгә кызык булсын өчен шулай иттек! Дөрес әйтәмме, Кар кызы?

К а р  к ү б ә л ә к. Дөрес әйтәсең, Кыш бабай. Бик дөрес!

К у я н. Ә-ә-ә-ә... Сезнең бүләкләрегез кайда соң, Кыш бабай?

Кыш малай белән Кар кызы бер-берсенә карашып алалар.

К а р  к ү б ә л ә к. Бүләкләр?!

К ы ш  м а л а й. Нинди бүләкләр? Ә-ә... Бүләк-лә-әр?! *(Кар күбәләккә.)* Кайда безнең бүләкләр?

К а р  к ү б ә л ә к. Кайда дип... *(Кулы белән ишек тарафына ишарәли.)* Шунда инде, шунда!

К ы ш  м а л а й. Ә... әйе... безнең бүләкләр... сезнең бүләкләр...

К а р  к ү б ә л ә к. Хәзер алып киләләр бүләкләрне.

К ы ш  м а л а й *(җанланып)*. Әйе, хәзер алып киләләр. Ярдәмчеләребез алып килә! Әйдәгез аңарчы нитә торыгыз... Һөнәрләрегезне күрсәтә торыгыз...

К у я н. Синең, Кыш бабай, тылсымлы таягың да юк-мы?

К ы ш  м а л а й. Тылсымлы таяк? Нигә ул тылсымлы таяк?

Б ү р е. Чыршы утларын кабызырга!

К ы ш  м а л а й. Ә-ә-ә... утларны кабызыргамы? Әйе шул, аларны кабызырга кирәк. *(Кар күбәләккә.)* Таяк белән кабызалармы аны?

К а р  к ү б ә л ә к *(җилкәсен сикертеп)*. Мин каян белим... Син бит Кыш бабай...

К ы ш  м а л а й. Ни бит... дусларым... Тылсымлы таякны да бүләкләр белән бергә алып киләләр хәзер... Борчылмагыз, бөтенесе дә булыр: бүләкле таяклар да, таяклы бүләкләр дә...

К а р  к ү б ә л ә к *(Кыш малайга карап, аның бутап сөйләвенә аптырап башын селкеп)*. Гаҗәпләнмәгез, дуслар. Кыш бабай юлда килгәндә бик арыды. Арыганлыгы әнә теленә үк чыкты. Шуңа күрә бутабрак сөйли. Син ял итеп тор, Кыш бабай.

К ы ш  м а л а й. Юк-юк, мин арымадым!

К а р  к ү б ә л ә к *(аны эткәләп)*. Арыды, арыды! Хәзер ял итә ул. Урындык бирик әле Кыш бабайга!

Кемдер урындык китереп куя.

К а р  к ү б ә л ә к. Утырып тор, Кыш бабай! *(Пышылдабрак.)* Утыр инде җәтрәк! *(Җәнлекләргә карап елмая.)* Карт шул инде Кыш бабай. Бик тиз арырга гына тора... Шулай бит, Кыш бабай?

К ы ш м а л а й. Шулай, Кар кызы, дөрес әйтәсең... Арырга гына торам. Арымасам да арыйм, арысам да арыйм...

К а р к ү б ә л ә к. Бабай хәл җыя торсын... Ә без... Әйдәгез, дуслар, чыршы тирәли әйләнеп җырлыйк әле!

К у я н. Нинди җыр җырлыйбыз соң?

К а р к ү б ә л ә к. Матур җыр җырлыйк. Сез башлагыз, мин кушылырмын.

Һәммәсе чыршы тирәли кулга-кул тотынышып баса. Кар күбәләк тә алар арасында. Җәнлекләр җыр башлыйлар.

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе.
Син тагын да матур булып
Бизәлгәнсең бу юлы...

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман клубының тышкы ягы. М а р с белән Ч у л п а н тәрәзә аша эчкә карыйлар. Марсның җилкәсендә – биштәр, бер кулында –
Кыш бабай таягы.

М а р с *(клуб эчендәге «Чулпан»ны күреп)*. Менә әкәмәт! *(Әле тәрәзәгә, әле Чулпанга карый.)* Анда да син, монда да син!

Ч у л п а н *(ул да, гаҗәпләнеп, әле тәрәзәгә, әле Марска карап)*. Әйе шул! Анда да син, монда да син!

М а р с. Кыз-зык... Ничек була инде бу?

Ч у л п а н. Мин дә икәү... Син дә икәү... Безнең күзгә генә күренәдер бу, Марс?!

М а р с *(үз башына сугып)*. Белдем, белдем! Барып җитте башыма.

Ч у л п а н. Нәрсә белдең? Әйт инде тизрәк!

М а р с. Беләсеңме, Чулпан, алар... *(Тәрәзәгә ишарәли.)*... Алар... без түгел! Алар мин дә, син дә түгел.

Ч у л п а н. Кемнәр соң алайса?

М а р с. Әнә кара... Мин дигәне – бүре... Син дигәне – куян... Алар без булып киенгәннәр генә! Аңладыңмы инде, Чулпан?!

Ч у л п а н. Әйе шул... Менә хәзер аңладым.

М а р с. Ә без аларның үзләрен кызык итәбез хәзер...

Ч у л п а н. Ничек итеп?

М а р с *(биштәренә ишарәләп)*. Менә бу биштәрне мин тикмәгә генә күтәреп йөриммени? Монда бит без бәйрәмгә кия торган киемнәр! *(Таякны бер читкә куя да биштәрен сала.)* Бер минуттан мин – бүре, син куян булачаксың хәзер... Әйдә киеник җәтрәк!

Киенә башлыйлар.

## УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Клуб эче. Җәнлекләр чыршы тирәли җырлый-җырлый

әйләнүдән туктыйлар.

К у я н. Кыш бабай, чыршыдагы утларны кайчан кабызасың инде?

Б ү р е. Безгә дигән бүләкләрең дә һаман килеп җитми.

К ы ш   м а л а й. Ни бит... балалар... *(Кар күбәләккә.)* Әйт инде син дә берәр сүз...

К а р   к ү б ә л ә к. Хәзер килеп җитә безнең бүләкләр... Тылсымлы таяк та хәзер монда булачак!

К ы ш   м а л а й. Әйе... Борчылмагыз, балалар... Берегез дә бүләксез калмассыз...

К у я н *(Кыш малайга сырпаланып)*. Миңа нинди бүләк бирәсең, Кыш бабай?

К ы ш   м а л а й *(әле Кар күбәләккә, әле Куянга карап)*. Сиңамы? Без сиңа... сиңа без... бүләк итәм... итәбез... Сиңа без...

К а р   к ү б ә л ә к *(аңа ярдәмгә килеп)*. Кыш бабай, нинди бүләк икәнен әйтмичә тор әлегә. Сер булып торсын!

К ы ш   м а л а й. Дөрес әйтәсең, Кар кызы. Сер булып торсын әлегә...

Шулвакыт ишек тарафында бүре булып киенгән М а р с, куян булып киенгән Ч у л п а н пәйда була. Һәммәсе дә аларга текәлә.

Б ү р е *(Марска төртеп)*. Бүре?!

К у я н *(Чулпанга ишарәләп)*. Куян?!

М а р с.<br>Ч у л п а н. Исәнмесез, дуслар!

К ы ш   м а л а й *(Кар күбәләккә)*. Кемнәр болар?

К а р   к ү б ә л ә к. Күрмисеңмени, Бүре белән Куян ич!

Б ү р е *(Марс янына килеп)*. Синме Бүре?

М а р с. Әһә! Мин – Бүре!

К у я н *(Чулпанга)*. Ә син Куянмы?

Ч у л п а н *(чигенеп, Марска елышып)*. Минме?

К у я н *(үчекләп)*. Юк, мин!

Ч у л п а н. Син – Куян...

К у я н. Ә син?

Ч у л п а н. Мин дә Куян...

М а р с. Әйе, ул – Куян. Ә мин – Бүре!

Б ү р е *(әтәчләнеп)*. Син Бүре түгел, мин – Бүре! Чын Бүре мин!

К ы ш   м а л а й. Балалар, балалар! Әйткәләшмәгез! *(Бүрегә.)* Борчылма, син – Бүре, син!

К у я н. Ә мин – Куян, чын Куян!

К ы ш   м а л а й. Әйе, дөрес, син – Куян.

К а р   к ү б ә л ә к. Дуслар, тынычланыгыз әле. Юкка бәйләнмәгез. Болар бит Бүре белән Куян булып кына киенеп килгәннәр. *(Марс белән Чулпанга.)* Шулай бит?

М а р с *(башын селкеп)*. Шулай, шулай.

Ч у л п а н *(Марска елышып)*. Без бит бәйрәмгә дип килдек. Ә сез безгә бәйләнәсез... Мин бит – Чулпан. Авыл кызы мин!

М а р с. Ә мин – шәһәр малае. Марс мин! Авылга кунакка гына кайткан идем...

Ишектә К ы ш б а б а й белән К а р к ы з ы күренә. Бүлмәдәгеләр
башта аларны күрмиләр.

К ы ш б а б а й. Нишләп күңелсез әле сез, дуслар?

Һәммәсе дә керүчеләргә борылып карый.

Б а р ы с ы б е р г ә. Кыш бабай?! Кар кызы?!

Кыш малай белән Кар күбәләккә карыйлар. Тегеләр нишләргә дә белмичә басып торалар.

К а р к ы з ы. Исәнмесез, дуслар!

Җ ә н л е к л ә р *(аптырап)*. Исән-ме-сез!

Б ү р е. Мин берни дә аңламыйм. *(Кыш бабайга.)* Син дә Кыш бабай... *(Кыш малайга.)* Син дә Кыш бабай... Ике Кыш бабай...

К у я н *(әле Кар кызына, әле Кар күбәләккә карап)*. Ике Кар кызы... Мин дә берни дә аңламыйм.

М а р с. Сезнең кайсыгыз чын Кыш бабай соң? Кайсыгыз чын Кар кызы?

К ы ш м а л а й *(Кыш бабайга күрсәтеп)*. Ул... ул – Кыш бабай... Гафу итегез мине!

К а р к ү б ә л ә к. Мин Кар кызы түгел... *(Кар кызын күрсәтә.)* Ул – Кар кызы... Без шаярттык кына... Без... без...

К ы ш м а л а й. Безнең бәйрәмдә катнашасыбыз килде. Бик-бик килде! Кичерегез безне, зинһар!

К у я н. Их, сез!.. Алдакчылар!.. Шулай ярыймы инде?

К ы ш б а б а й. Зыян юк, дуслар. Ачуланмыйк аларны. Күреп торасыз ич, гаепләрен таныдылар. Шулай бит, Кыш малай?

К ы ш м а л а й. Әйе, әйе... Без таныдык... Кичер, Кыш бабай!

К а р к ү б ә л ә к. Гафу ит, Кар кызы!

Кар кызы Кар күбәләкнең чәчләреннән иркәли.

М а р с *(кинәт)*. Таяк! Тылсымлы таяк! Кыш бабай, без бит синең тылсымлы таягыңны тапкан идек! Мин хәзер!

Тиз генә чыгып китә дә тылсымлы таякны алып керә,
Кыш бабайга бирә.

К ы ш б а б а й. Рәхмәт яугыры! Менә бит, Кар кызы, таягыбыз да табылды.

К ы ш м а л а й. Кыш бабай, зинһар, әүвәлге халәтебезгә кайтар инде.

К а р  к ү б ә л ә к. Мине дә, Кыш бабай! Туйдым бу сакалдан! Кычыттыра да кычыттыра, кычыттыра да кычыттыра...

К ы ш  б а б а й. Хәзер-хәзер, дусларым! Тылсымлы сүзләремне әйтим әле... Чухырый-мухырый бәйнәләй, кыштырый-мыштырый әйләнәй!

Кыш малай белән Кар күбәләк әүвәлге халәтләренә кайта.
Һәммәсе дә сөенешеп кычкыра.

К ы ш  м а л а й. Рәхмәт, Кыш бабай!

К а р  к ү б ә л ә к. Рәхмәт сиңа, Кыш бабай! Ачуланма инде безне, яме!

Кыш бабай аларның башларыннан сыйпый.

К ы ш  б а б а й. Бүтән вакытны үз белдеклелегегез белән йөрмәгез, ярыймы?! Алайса, әллә нинди күңелсез хәлләргә таруыгыз бар...

Б ү р е. Кыш бабай, чыршы утларын кабызасыңмы инде? Вакыт җитте бит.

К ы ш  б а б а й. Ашыкма, Бүре...

Ул тылсымлы таякның башын бора да идәнгә дөп итеп төртеп ала, чыршыда утлар гөлт итеп кабына.

Б а р ы с ы  б е р г ә. Ур-р-ра!

К ы ш  б а б а й. Яңа ел котлы булсын, дуслар!

Биштәрен ала да, аннан бүләкләр чыгара башлый.
Аларны Кар кызы өләшә.

К у я н. Бәйрәм башланды. Әйдәгез, чыршы тирәли әйләнәбез!

К ы ш  м а л а й. Әйдәгез!

Җәнлек-җанварлар, Марс белән Чулпан чыршы тирәли әйләнә башлыйлар. Көй агыла. Һәммәсе дә җырлыйлар.

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе...
Син тагын да матур булып
Бизәлгәнсең бу юлы...

Җыр көчәя. Бәйрәм дәвам итә.

П ә р д ә.

# ЯҢА ЕЛ БИШТӘРЕ

К А Т Н А Ш А Л А Р:

Я ң а е л.
Б ы е л.
И л д у с.
А й р а т.
Б а ш т ү р ә.
Б а ш и я.

Б а ш а я к.

## Б Е Р Е Н Ч Е  К Ү Р Е Н Е Ш

Стеналарына «Яшәсен сөеклебез Баштүрә!», «Баштүрәнең һәр сөй-ләгәне дөрес!», «Башөсте, Баштүрә!» дигән язулар һәм Баштүрә сурәт-ләре эленгән бүлмә. Кулларын артка куеп, өстәл тирәли Б а ш т ү р ә йөренә. Ара-тирә баш чүмечен кашып ала, сурәтләргә, язуларга
сокланып карый-карый, җыр суза.

Б а ш т ү р ә. Һин-нә-нәй, мин-нә-нәй,
Кара мамык бияләй.
Кара мамык бияләйне
Мин – Баштүрә кияләй...
Һин-нәләй, мин-нәләй...

Җырлавыннан туктап.

Башия! Башия, дим! Кая олактың, мәнсез?

Мышкылдый-мышкылдый, Б а ш и я йөгереп керә.

Б а ш и я *(башын иеп)*. Тыңлыйм, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә. Минем затлы башымда бер ирртерресный план туды...

Б а ш и я. Синең затлы башыңда бер ирртерр... ирртерр...

Б а ш т ү р ә. Сөйләп бетергәнне көт, надан!

Б а ш и я. Әйе, мин – надан, Баштүрәм! Сөйләп бетергәнеңне көтәм...

Б а ш т ү р ә. Көтмә. Бар, тиз генә теге тинтәкне, Башаяк-ны чакыр монда!

Б а ш и я. Башөсте, Баштүрә. Хәзер теге тинтәкне чакырам. *(Чыгарга таба борыла.)*

Б а ш т ү р ә *(аны туктатып)*. Башия!

Б а ш и я. Әү, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә *(җен ачуы чыгып)*. Ниткән «әү» тагын, надан!

Б а ш и я. Минават, Баштүрәм. Тыңлыйм, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә. Теге затлы җыруны җырла. Аннан соң теге тинтәкне чакырырсың...

Б а ш и я. Теге затлы җыруны җырлыйм, Баштүрәм. Аннан соң теге тинтәкне чакырырмын... *(Җырлый башлый.)*
Затлы бүрек, затлы тун
Кия безнең Баштүрә-әй...

Баштүрә, борынын югары чөеп, рәхәтләнеп, изрәп, җырны тыңлый.

Башбашлар илендә һәркем
Баштүрәне баш күрә-әй...
Их! Яшә, яшәсен...

Б а ш т ү р ә. Ярар, җитәр... Бар. Башаякны чакыр. Тиз бул!

Б а ш и я. Башөсте, Баштүрәм. Хәзер чакырам, Баштүрәм.

Китә. Сәхнә артында аның «Башаяк! Сөекле Баштүрәбез сине чакыра!» дигән тавышы ишетелә. Бераздан Б а ш а я к керә.

Б а ш а я к. Чакырдыгызмы, Баштүрәм?

Б а ш т ү р ә. Минем затлы башымда бер ирртерресный план туды. Сиңа бик җаваплы бер эш тапшырырга уйлап торам...

Б а ш а я к. Мин әзер, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә *(сәгатенә карап)*. Минем алтын сәгать белән моннан утыз ике минут элек Башбүкән исемле шымчымнан бик мөһим иррформмасия алдым: Яңаел килергә чыккан!

Б а ш а я к. Фәрман бир, Баштүрәм. Хәзер юк итәм мин аны.

Б а ш т ү р ә. Ашыкма, надан! Аягыңны түгел, башыңны эшләт бераз. Без аны юк итсәк, тагын шул Иске ел белән торып калабыз бит, тинтәк! Аңладыңмы?

Б а ш а я к. Аңладым, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә. Аңласаң, шул: безгә аның үзе түгел, биш-тәре кирәк! Башбүкән әйтүенчә, ул биштәрдәге шатлык-сөенечләр былтыргыга караганда икеләтә күп икән. Безгә ничек тә шул биштәрне кулга төшерергә кирәк. Әгәр безнең кулга эләксә, зур мәҗлес уздырырга боерык бирәчәкмен... Их, кинәнер идек тә соң!..

Б а ш а я к. Син дигәнчә булыр, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә. Минем затлы башымда туган ирртерресный план мондый. Тыңла...

Баштүрә, берәрсе ишетмәсен дигәндәй, Башаяк колагына нидер пышылдый.

Кара аны, былтыргы Яңаелның биштәрен эләктерә алмадың, бу Яңаелның да биштәрен ала алмасаң, үзеңә үпкәлә!

Б а ш а я к. Биштәр синең кулда булыр, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә. Минем алтын сәгать белән Яңаел килеп җитәргә... *(Сәгатенә карый.)* Тә-ә-әк... бер... ике... Бәй, вакыт аз калып килә икән бит инде... Тәк шту бер аягың монда булсын...

Б а ш а я к. Икенчесе башым кайда – шунда булыр, Баштүрәм!

Китә.

**И К Е Н Ч Е К Ү Р Е Н Е Ш**

Илдуслар өе. Бәйрәмчә җиһазланган. Ашыгып Б ы е л керә. Ул календарь булып киенгән: түшенә «31 декабрь» дип язылган.

Б ы е л *(бүлмәне күздән кичереп)*. Берәү дә юк. Кая киткән инде болар тагын? Соңга калына бит хәзер. Нишләргә? Нишләргә? Кешеләрсез, үзем генә берни дә майтаралмыйм, ичмасам. Ничекләр генә ярдәм итәргә инде...

Шулвакыт көлешкән тавышлар ишетелә. Иңнәренә тимераяклар аскан, кулларына кәшәкә тоткан И л д у с белән А й р а т керә. Быел алар сөйләшкәнне бер читтә тыңлап тора. Малайлар аны күрмиләр.

А й р а т. Малай, тегеләрнең тетмәләрен теттек бит, ә! Бер-бер артлы өч гол бит, өч гол! Капкачы Наилнең телләре тотлыга башлады, мин сиңа әйтим. Шул кирәк аңа, иеме, Илдус? Ату гел кәпрәеп йөри иде. Уен башланыр алдыннан гына мактанып торды бит, җитмәсә: имеш, аның капкасына алка түгел, күлмәк сәдәфе дә үтәрлек түгел, имеш, алканы ул күз йомып та тота ала... Кызык та иттек әле үзен, иеме, Илдус?!

И л д у с. Әйе... Анысы шулай шулаен да...

А й р а т. Туктале, малай, нишләп кинәт кенә кәефең китте әле синең?

И л д у с. Җиңү шатлыгы онытылды әле монда. Бүген кич чыршы бәйрәмендә сөйләячәк шигырь искә төште. Яттан гүпчим белмим бит.

А й р а т. Хи, тапкансың инде үзең, малай, искитәрлек нәрсә. Синең бит хәтер генә ни тора!

И л д у с. Анысы шулай шулаен да...

А й р а т. Чыршы бәйрәменә ярты сәгать кенә калганда да син айн момент әвеш-тәвешлисең. Кая инде синдәге хәтер безгә – каткан тезгә... Син шул турыда уйла: Яңаел безгә нинди сөенечләр алып килер икән?..

Б ы е л *(кинәт телгә килеп)*. Әгәр җитди чаралар күр-мәсәк, бер генә сөенеч тә алып килмәячәк Яңаел!

Илдус белән Айрат тавыш килгән якка ялт борылып карыйлар һәм Быелны күреп алалар.

И л д у с<br>А й р а т *(бергә)*. Кем син?

Б ы е л. Әллә танымыйсыз дамы?

Илдус белән Айрат аңа текәлеп карыйлар.

И л д у с. Кайдадыр күргәнем бар кебек тә...

А й р а т. Минем дә...

Б ы е л. Быел мин!

И л д у с. Быел?

А й р а т. Әйе, шул, тач үзе!

И л д у с. Син бит безгә букча-букча сөенечләр өләшкән идең узган чыршы бәйрәмендә?!

Б ы е л. Сөенечләр... сөенечләр... Мин сезгә күңелсез хәбәр алып килдем әле менә.

А й р а т. Ниткән күңелсез хәбәр ул тагын?

И л д у с. Әйе, нинди хәбәр ул?

Б ы е л. Яңаелның сөенечләр-шатлыклар тулы биштәрен урларга җыеналар. Дөресрәге, ул биштәрне алыштырмакчы булалар...

И л д у с. Кемнәр?

А й р а т. Ничек инде урларга җыеналар?

И л д у с. Каян белдең?

Б ы е л. Былтыр, сезнең янга килер алдыннан, Гасыр бабай миңа өч йөз алтмыш биш көнне ышанып тапшырды да инструкция үткәрде:

«Һәрбер көнеңне күзәтеп тор, әрәмгә узмасын берүк», – диде. Менә бүгенге, соңгы көнемнең һәр сәгатен, һәр минутын күздән кичерә-кичерә тикшереп-барлап йөргәндә, җилләр миңа күңелсез хәбәр җиткерделәр: өстә, Караболыт материгында, Яңаелга каршы әнә шундый явызлык кылмакчы булып яталар...

Айрат. Кемнәр соң алар?

Бые л. Алар әнә шул материктагы Башбашлар илендә яшиләр. Исемнәре дә мәгълүм: Баштүрә, Башия, Башаяк... Былтыр шуларның берсе, Башаяк дигәне, көтмәгәндә миңа һөҗүм итте. Алыш вакытында минем биштәрдәге шактый сөенеч-шатлыкны алып, алар урынына байтак кына явызлыклар, кайгы-хәсрәтләр салып өлгерде. Менә бүген дә әнә шул явыз Яңаелның юлына каршы төшмәкче була. Биштәрне хәйләләп-алдалап алып, аның урынына үзенең кайгы-хәсрәт белән шыплап тутырылган үз биштәрен калдырырга җыена.

Илдус. Алайса, нишләп тик торабыз соң әле без? Тизрәк, ашыгырга кирәк!

Айрат. Әйе, ашыгырга кирәк!

Быел. Әйдәгез, мин юл күрсәтермен...

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Аланлык. Ап-ак биштәр салынган чанасын тартып, җырлый-җырлый Яңаел килә.

Яңаел. Бигрәкләр дә матур дөнья! –
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллеккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм.
Кешеләрнең бик сагынып
Мине көткәнен беләм.
Шуңа күрә сөенечләр,
Шатлыклар алып киләм,
Өләшермен мин аларны,
Тынычлык, бәхет теләп,
Яңа яуган кардай ап-ак
Биштәрем үзем белән...

Кинәт елау тавышы ишетеп, Яңаел җырлавыннан туктый. Тавыш килгән якка кычкыра.

Кем бар анда? Кем елый?

Бәс сарган чыршы артыннан күзләрен уа-уа, Башаяк чыга. Ул балалар кебек киенгән. Сөйләшүе дә балаларча. Яңаел, чана бавын кулыннан ычкындырып, аның янына килә.

Нигә елыйсың, үскәнем? Кем тиде?

Б а ш а я к *(лышт-лышт итеп борынын тарта-тарта)*. Ур... ур... Урбасарлар... Әйем лә... юл... юл... юлбасарлар... минем вилсәпидемне таладылар! *(Кычкырып елый башлый.)*

Я ң а е л. Елама, үскәнем, елама. Мин сиңа икенче вилсә... Туктале, ә нишләп соң монда, урманда, вилсәпид белән йөрисең әле, үскәнем? Кыш көне бит чана шуалар...

Б а ш а я к *(кинәт сискәнеп)*. Ыңк! Мин... ни... вил-сәпидне чанага салган идем...

Я ң а е л. Исемең ничек синең, үскәнем?

Б а ш а я к. Минемме? Башаяк, Баштүрәм!

Я ң а е л. Ай-һай, шаян да малай икән син, ә! Башаяк-баштүрәм дигән исем була димени?

Б а ш а я к *(ялгышканын аңлап)*. Э-э-эм... Ни... Ул минем исем түгел шул... Ие... Кушамат кына... Минем исе-мем – Басыйр.

Я ң а е л. Карале, бигрәк матур исем икән. Басыйр. Ә нишләп син, Басыйр, бу урманда чанаңа вилсәпид салып йөрисең?

Б а ш а я к. Мин бит... Ни... вилсәпидтә бик йөрисе килгәч... җәйне эзләргә чыккан идем... Каршыма урбасарлар... әйем лә... юлбасарлар чыкты да... *(Тагын елый башлый.)* Вә-ә-ә... Ә мине... карга батырдылар. Вә-ә-ә...

Я ң а е л. Елама, үскәнем. Син бит зур егет инде хәзер. Елама, Басыйр. Чанаңны кая яшергәннәрен күрмәдеңме соң?

Б а ш а я к. Ә-әнәү теге чыршы төбендәге көрткә күмде-ләр. Вә-ә-ә...

Я ң а е л. Елама, Басыйр. Чанаңны үзем алып киләм. Ә син туныңны кага тор... *(Китә.)*

Б а ш а я к *(баскан җирендә биеп)*. Ха-ха-ха! Алданды, алданды! Ур-ра, биштәр безнең кулда!

Сикеренгәләп, тиз генә куак артына бара да үз биштәрен алып килә, аны Яңаел биштәре белән алыштыра. Яңаел киткән тарафка карый.

Үскәнем, эзлә чананы, эзлә. Тапсаң, үзеңә булыр... Хи-хи-хи... *(Чыгып йөгерә.)*

Я ң а е л *(кереп)*. Басыйр, син әкәмәт тә егет булып чыктың бит әле...

Ул Башаякның юклыгын күреп аптырап кала. Качкандыр дип уйлап, якындагы куак артларын барып карый.

Басыйр! Басыйр! Кая качтың? Чык әйдә монда!

Башаяк күренмәгәч, Яңаел тагын да ныграк гаҗәпләнә.

Менә кызык... Әллә күзгә генә күренде инде?!

Ул шулай аптырап торганда, Б ы е л, И л д у с, А й р а т керә.

Б ы е л *(сөенеп)*. Ә-ә, Яңаел монда! Исән! Сәлам, Яңа-ел!
Кул биреп күрешә.

А й р а т. Ур-ра, өлгердек!

И л д у с *(чанадагы биштәрне күреп)*. Ур-ра, биштәр дә монда!

Я ң а е л. Нәрсәгә шулхәтле сөенәсез? Берни аңламыйм. Гомумән, әллә сез бөтенегез дә күзгә күренәсез инде?

Б ы е л. Их, Яңаел, белсәң иде син безнең ничек борчылганны! Өлгерә алмабыз дип куркып, җан-фәрманга синең каршыңа чаптык. Тәки өлгердек. Карале, алай-болай сиңа берәр явыз бәндә очрамагандыр бит?

Я ң а е л. Юк-юк, нигә?

Б ы е л. Болай гына соравым...

Я ң а е л. Әле сез монда килгәнче бер кызык хәлгә юлыктым... Җырлый-җырлый килә идем шулай, ишетәм – кемдер елый. Карыйм – бер малай. «Нигә елыйсың?» – дим моңа. «Вилсәпидемне юлбасарлар талады», – ди бу. *(Көлә.)* Шундый да шаян малай инде менә. Басыйр исемле. Кушаматы бигрәк тә кызык! Ничек диде әле? Ә-ә-ә... Исемә төште: Башаякбаштүрәм! Әйе-әйе, Башаякбаштүрәм!

Б ы е л

И л д у с *(бергә)*. Башаяк?

А й р а т

Я ң а е л. Юк, Башаякбаштүрәм, диде. Сезнең шикелле башта мин дә гаҗәпләнгән идем...

Б ы е л *(хәлсезләнеп)*. Биштәр... биштәр...

Илдус белән Айрат чанадагы биштәргә тотыналар, аның авызын чишмәкче булалар.

Б ы е л. Чишмәгез, харап итәсез дөньяны!

Тегеләр туктап кала.

Я ң а е л. Нәрсә булды? Нишләп өчегезнең дә битләре агарды?

А й р а т. Аһ, явыз тәре! Өлгергән бит!

Я ң а е л. Кем явыз? Минме? Аңлатыбрак сөйләгез әле...

И л д у с. Син түгел... Башаяк! Башаяк явыз! Биштәрне алыштырган!

Б ы е л. Әйдәгез тизрәк, Башаякның артыннан куарга кирәк. *(Яңаелга.)* Әйдә, Яңаел, юлда барысын да аңлатырбыз...

Китәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Баштүрә бүлмәсе. Б а ш и я белән Б а ш а я к, йомшак кәнәфигә чумып утырган Баштүрә тирәсендә чүмәшеп, җыр җырлыйлар.

Б а ш и я.
Б а ш а я к.

Затлы бүрек, затлы тун
Кия безнең Баштүрә-әй...
Башбашлар илендә һәркем

Баштүрәне баш күрә-әй...
Их! Яшә, яшәсен...

Б а ш т ү р ә. Ярар, җитәр, тинтәкләрем минем. Яхшы җырлаганыгыз өчен иртәгә берәр нәрсә белән бүләкләрмен үзегезне. Ә хәзер минем затлы соравыма җавап бирегез: затлы боерыгымны ишетмәүчеләр калмадымы?

Б а ш и я. Сезнең затлы боерыгыгызны ишеткәннәргә тагын бер кат ишеттердек, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә. Мәҗлесне затлы итеп бәйрәм залында үткәрергә кирәк. Караболыт материгы гына түгел, бөтен терек-лек шауларлык булсын!

Б а ш и я. Шулай булыр, Баштүрәм!

Б а ш а я к. Шаулатырбыз, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә. Табынга бер генә затсыз ризык та куй-маска.

Б а ш а я к. Сез дигәнчә булыр, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә. Табында тел очына тию белән эри торган балыкларның барча төре булсын!

Б а ш а я к. Тел очына тигәнче эри торганнарын да табарбыз, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә *(сикереп торып)*. Андыйлары кирәкми, надан! Мин әйткәнчә эшләргә!

Б а ш а я к. Башөсте, Баштүрәм. Син әйткәнчә эшләр-без!

Б а ш т ү р ә *(утырып)*. Башия!

Б а ш и я. Әү, Баштүрәм!

Б а ш т ү р ә *(сикереп торып)*. Нәрсә-ә?

Б а ш и я. Минават, Баштүрәм. Тыңлыйм, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә *(утырып)*. Пешекчеләргә минем фәрманны җиткер, затлы уылдык бәлеше пешерсеннәр... Аннан соң кызыл уылдыкны табада кыздырсыннар. Зәйтүн маенда! Шуны әйтергә онытма! Бар!

Б а ш и я *(урыныннан кузгалып)*. Әйтергә онытмам, Баштүрәм. Барам, Баштүрәм. *(Китә.)*

Б а ш т ү р ә. Башаяк, сиңа да эш бар.

Б а ш а я к. Тыңлыйм, Баштүрәм.

Б а ш т ү р ә. Хәзер үк затлы мәҗлес хөрмәтенә күк күк-рәт, яшен яшьнәт!

Б а ш а я к. Башөсте, Баштүрәм. Син дигәнчә булыр... ие дә бит...

Б а ш т ү р ә *(сикереп торып)*. Нәрсә? Әле син, хөрәсән, минем затлы фәрманга каршы киләсеңме? Башыңны кистерәм!

Б а ш а я к. Баштүрәм, хәзер кыш көне бит. Күк күкрәтә, яшен яшьнәтә торган машинаның мае каткан. Шистырналары эшләми. Аннан соң быелга дигән бензин запасы да бетте...

Б а ш т ү р ә. Һе-ем... Ярар. Гаебеңне таныганың өчен бу юлы башыңны кистермим... *(Утыра.)*

Б а ш а я к. Мең рәхмәтлемен, Баштүрәм!

Шулчак төсе качкан Б а ш и я йөгереп керә.
Керү белән, нәрсәгәдер абынып егыла.

Б а ш и я. Киләләр! Киләләр! Беттек! Үтерәләр! *(Өстәл астына кереп кача.)*

Б а ш т ү р ә. Кемнәр килә? Кемнәр бетерә? Кемне үтерәләр?

Б а ш и я. Үтерәләр! Үтерәләр!

Б а ш т ү р ә. Чәчби, дим! Башыңны кистерәм! Минем затлы сорауларыма җавап бир!..

Б а ш и я. Биштәрдәге сөенечләр үзегезгә булсын. Үтерәләр! Үзегезгә булсын мәҗлесегез дә... Үтерәләр!

Б а ш а я к *(Баштүрәгә)*. Баштүрәм, ниткән бу. *(Бармагын чигәсендә биетеп ала.)* Ычкынган! Җүләрләнгән!

Б а ш и я. Син үзең җүләр! Үтерәләр! Кешеләр килә! Яңаел килә!..

Б а ш т ү р ә *(каушап)*. Каян киләләр, чәчби? Тынычлан да тиз генә җавап бир!

Б а ш и я. Шуннан киләләр, шуннан! Качыгыз!

Б а ш т ү р ә *(үзен кулга алып)*. Паникага бирелмәскә! Каршылык күрсәтергә! Башаяк, бар, җәһәт кенә явызлык биштәрен алып кил!

Б а ш а я к. Башөсте, Баштүрәм. Хәзер алып киләм. *(Китмәкче була да туктап кала.)* Баштүрәм, явызлык биштәре Яңаел кулында бит.

Б а ш т ү р ә *(үз башына сугып)*. Аһ, шайтан алгыры, ялгыштык... Затлы коралсыз калдык...

Б а ш и я. Качыгыз! Үтерәләр!

Бүлмәдә ыгы-зыгы куба.
Этешәләр, төртешәләр, качарга урын эзләп азапланалар. Җил-җил атлап, Я ң а е л, Б ы е л, И л д у с һәм А й р а т керә.

А й р а т. Баскан җирегездән кузгалмагыз!

И л д у с *(Баштүрә янына килеп)*. Ялгышмасам, син Баштүрә буласыңдыр инде? Җә, әйт әле, сөенечләр биш-тәрен кая куйдыгыз?

Баштүрә дәшми.

Б ы е л. Биштәр кайда дип сорыйлар синнән?

Б а ш т ү р ә. Билләһи-валлаһи, затлы башым белән ант итәм: мин алмадым, мин күрмәдем.

Я ң а е л. Биштәрем... Сөенечләрсез нишләрмен инде?

И л д у с *(Башия янына килеп)*. Ә син, ялгышмасам, Башия буласың бугай?

Б а ш и я. Әйе, мин Башия булам, хөрмәтлем.

А й р а т. Биштәр кая?

Башия Баштүрәгә карап ала. Тегесе астан гына йодрык күрсәтә.

Б а ш и я. Минават, хөрмәтлем. Күрмәдем, белмәдем...

И л д у с. Тә-ә-әк... *(Башаяк янына килә.)* Ә син...

Б а ш а я к. ...Башаяк булам. Гомердә кеше әйберенә кул сузганым булмады. Мин алмадым.

Я ң а е л. Синмени инде ул «шаян малай»? Мине алдалап, сөенечләр биштәрен алып китүче Башаякбаштүрәм...

Б а ш а я к. Гомердә алдаганым булмады. Беренче тапкыр күрәм сине.

А й р а т. Аһ, явыз, алдакчылар! Мин сезне хәзер...

Б ы е л. Кирәкми, Айрат, тукта! Дошманны үз коралы белән акылга утыртырга кирәк.

И л д у с. Әйе, Быел дус, дөрес әйтәсең. Боларның явызлык биштәре безнең кулда бит. Хәзер мин шул биштәрнең авызын чишәм дә печтек кенә явызлык чыгарам. Ул явызлык, без ни теләсәк, шуны эшләячәк.

Биштәр авызын ачып яба. Бер урында хәрәкәтсез басып торган
Башаяк белән Башия явыз кыяфәткә керәләр. Башаяк Баштүрә янына йөгереп килә дә аның артына тибә.

Б а ш т ү р ә *(ярсып кычкырып)*. Нишлисең син, тинтәк? Миңа түгел, әнә тегеләргә тип!

Б а ш а я к. Әһә, эләктеңме? Мә, минем затлы аягымның тәмен татып карале. *(Баштүрәгә тагын тибә.)*

Баштүрә егыла. Шуны гына көтеп торгандай,
Башия аңа менеп атлана.

Б а ш и я. На-а, малкай! На-а!

Б а ш т ү р ә. Тыегыз бу хөрәсәннәрне! Үтерәләр бит!

А й р а т. Сөенечләр биштәре кая?

Б а ш т ү р ә *(Башияне атландырып йөри-йөри)*. Мин алмадым... Башаяк алды... Ул котыртты...

Б а ш а я к. Әһә, мә тагын берне. *(Тибә.)*

Тәмам хәлсезләнгән Баштүрә идәнгә сузылып ята.

Б а ш т ү р ә. Үт... үт... терәләр! Кот... кот... карыгыз!

Быел Илдуска туктарга ишарә ясый.

И л д у с. Явызлык! Биштәргә кире кайт!

Илдус биштәр авызын ачып яба. Башия белән Башаяк элекке хәлләренә кайта. Баштүрә көч-хәл белән генә торып баса.

Б а ш т ү р ә *(Башия белән Башаякка карап)*. Хөрәсән-нәр...

Я ң а е л. Йә, Баштүрә, минем биштәрем кайда инде?

Б а ш т ү р ә *(башы белән ымлап)*. Минем затлы сейфымда. Хәзер ачам...

Кесәсеннән зур ачкыч ала да сейфны ача.

Я ң а е л. Биштәрем! *(Сейфтан биштәрен ала.)* Ур-ра! Биштәрем табылды. Тизрәк чыршы бәйрәменә ашыгырга кирәк!

И л д у с. Әйе, ашыгырга кирәк! Минем шигырь дә ятлыйсым бар әле.

Б ы е л. Миңа да бәйрәмдә кешеләр белән саубуллашырга кирәк.

А й р а т. Әйдәгез!

Китмәкче булалар.

Б а ш т ү р ә. Туктагыз! Без сезнең биштәрне бирдек. Сез безнекен кире кайтарыгыз.

Б ы е л. Юк инде. Анысы булмас. Мин ул явызлык биштәрен үзем белән алып китәм. Киләчәктә явызлык булмаска тиеш!

Б а ш и я. Хе... Явызлык булмагач, безгә Баштүрә дә кирәкми. Ур-ра! Баштүрә безне буйсындыра алмый. *(Баштүрәгә телен чыгарып күрсәтә.)* Моннан соң мин Башия булмаячакмын. Баширә булачакмын! *(Яңаелга карап.)* Мине дә үзегез белән алыгыз. Минем дә чыршы бәйрәмендә катнашасым килә!

Я ң а е л. Алабызмы, дуслар?

Б ы е л
И л д у с *(бергә)*. Алыйк әйдә.
А й р а т

Б а ш а я к. Мин дә Башаяк булмыйм. Басыйр булам. Алыгыз мине дә!

Я ң а е л. Әйдә!

Китә башлыйлар.

Б а ш т ү р ә. Ә мин? Ә мин?! Явызлыкларым, буйсынучыларым булмагач, мин нишлим инде хәзер? Мине дә алыгыз!

Яңаел җыр башлый. Калганнар аңа кушыла.
Җырлый-җырлый китәләр. Баштүрә дә аларга иярә.

Җ ы р  т а в ы ш ы. Бигрәкләр дә матур дөнья! –
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллеккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм...

П ә р д ә.

## ИШЕГАЛДЫ

К А Т Н А Ш А Л А Р:

А к м у е н – эт.
М ы р м ы р – песи.
Й о н б и к ә – сарык.
М и к и җ а н – кәҗә.
Ч ә ч к ә – сыер.
А й б а ш – ат.
Ч и ч и – тычкан.
К и к р и к н у р – әтәч.
К ы т к ы т ы й – тавык.
А л т ә п и – каз.
Б а к ы л д ы к – үрдәк.
Л а п т ы й – аю.
Б ү р е т д и н – бүре.
Т ө л ә н т ә й – төлке.
К а р к а р ы й – карга.
А р н о л ь д – бульдог.
Вакыйга авылдагы бер йорт ишегалдында һәм урманда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таң вакыты. Ишегалды. Кетәклектән, күзләрен угалап, К и к р и к н у р чыга. Коймага сөяп куелган баскыч янына килә. Киерелеп, җилпенеп ала.

К и к р и к н у р. Йокым бик тәмле иде –
Торасым килми бер дә...
Керфекләр шундый авыр –
Асканнар гүя герләр!

Татлы төш күреп кенә
Йокладым эреп бетеп...
Әллә соң тагын бераз
Алыйммы черем итеп?

Юк шул, юк, һич ярамый,
Көтсә дә татлы төшем...
Таң белән барысын да
Уяту минем эшем!

Офыкта кояш күрәм,
Уянган ул да иртүк...
Торыгыз, әй, торыгыз!
Кик-крик-кү-ү-үк!
Кик-крик-кү-ү-үк!!
Кик-крик-кү-ү-үк!!!

Ишегалдында иртәнге ыгы-зыгы башлана.

А к м у е н. Һау-һау-һау! Кыймылдагыз!
Басыгыз тиз бер рәткә.
Ясыйбыз күнегүләр,
Ясыйбыз физзарядка!

Беттекме җыелышып –
Монданмы барыгыз да?
Карагыз уңга-сулга...
Йә, кем юк яныгызда?
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак! Чичи монда!
Ч и ч и. Һәрчак үз урынымда!
А к м у е н. Күрмимен Микиҗанны...
М и к и җ а н. Ми-ки-ки! Мин дә монда!
А к м у е н. Йонбикә, Айбаш монда...
Күренми, кайда Мырмыр?
Ч и ч и. Мырмырмы? Кайда булсын...
Өйдә ул! Йоклый хыр-хыр...
А к м у е н. Чичи, бар, элдер өйгә –
Алып чык әле үзен...
М ы р м ы р *(өйдән чыгып)*. Кирәкми, Акмуен дус,
Ишетеп чыктым сүзең!
А к м у е н. Бу юлы гафу итәм!
Соңлама болай бүтән!
К ы т к ы т ы й. Кыт-кытыйк! Башла инде!
Күп сүз – чүп... Ташла инде...
Й о н б и к ә. Бә! Сузма инде һаман,
Тәпиләр арды тәмам!
Ч ә ч к ә. Минем сөт савылмаган!
К и к р и к н у р. Минем бит юылмаган!
А й б а ш. Ә мин су коенмаган!
А л т ә п и. Урын-җир җыелмаган!
А к м у е н. Бетердек сөйләшүне!
Тыңлыйбыз мине генә!
Бер, ике! Бер, ике, өч!
Иелдек җилле генә!

Басабыз! Иеләбез!
Басабыз! Бөгеләбез!
Ә хәзер барыбыз да
Атлыйбыз, йөгерәбез!

Чичи, дим! Кая киттең?
Син, әйе! Кире борыл!..
Туктадык йөгерүдән –
Бүгенгә җитеп торыр...

Кайсы кая таралыша. Күңелле ыгы-зыгы.

М ы р м ы р. Сез кая югалдыгыз?
Әйтергә онытканмын!
Хуҗабыз чирләп ята –
Хәле бик авыр аның!
К а р к а р ы й. Кар-кар-кар! Кар-кар-кар!
Сездә яман хәбәр бар?!
М ы р м ы р. Син генә кирәк идең...
Тормале комачаулап!
Тагын йөрерсең инде,
Һәркемгә сөйләп-шаулап...
К а р к а р ы й. Юк-юк. Юк! Нишләп шаулыйм!
Сөйләмим берәүгә дә.
Үзем дә чирләп торам –
Калтырый бөтен гәүдәм!
А к м у е н. Бар-бар-бар! Кайт, дәвалан!
Йөрмәле безне тыңлап.
Синең каркылдавыңнан
Колагым тора чыңлап!
К а р к а р ы й. Киттем мин, очтым, очтым!
Эшлисе эшләрем бар... *(Залга карап.)*
Яңа хәбәрне көтеп
Торган дус-ишләрем бар! *(Китә.)*
М и к и җ а н. Мырый дус! Ишетмәдем,
Ни дидең әле генә?
М ы р м ы р. Хуҗабыз үлеп китсә,
Белерсең әле менә!
А к м у е н. Авырый, дип әйтә бит!
Нишлибез инде хәзер?
М и к и җ а н. Мин дару үләннәре
Җыеп кайтырга әзер!
М ы р м ы р. Кирәкми! Хуҗабызда
Җитәрлек андый үлән...
Ч и ч и. Ә мин кипкән сыр белән
Чирне дәвалый беләм!
М и к и җ а н. Уф, үләм! Синме табиб?
А л т ә п и. Кипкән сыр каян табыйк?
М ы р м ы р. Уфлап тормагыз әле!
Баш катырмагыз әле!

Мин дару бирдем инде,
Яхшырган кебек хәле!
Җитмеш төрле үләннән
Җиде төнәтмәм әзер.
Хуҗабыз йоклый, аңа
Тынычлык кирәк хәзер!
К и к р и к н у р. Алайса, без шаулашмыйк!
К ы т к ы т ы й. Кичәге күк талашмыйк!
К и к р и к н у р. Кичәге ул ызгышны
Син бит үзең башладың...
К ы т к ы т ы й. Ә син... Ә син иң башта
Ник җыердың кашларың?
А й б а ш. Кем дәшсә дә, мин дәшмим!
Б а к ы л д ы к. Мин дә бер сүз эндәшмим!
А к м у е н. Бетердек, дим, тавышны!
Оят хуҗа алдында...
Тәртип булырга тиеш
Безнең ишегалдында!
Й о н б и к ә. Хуҗабыз нишли микән?
Ч ә ч к ә. Тамагы шешми микән?
А л т ә п и. Казанда безгә дигән
Аш, ботка пешми микән?
А й б а ш. Мин солы тансыкладым!
К и к р и к н у р. Мин бодай чүпләр идем!
Ч ә ч к ә. Апара сосар идем!
Ч и ч и. Сыр ашап үтләр идем...
М и к и җ а н. Ә мин... ә мин... мин исә
Чәйнәр идем кәбестә.
Й о н б и к ә. Ә мин баш тартмас идем
Ташкабаклы бәлештән!
М ы р м ы р. Күрәм, сез барыгыз да
Хирыс тамак ягына...
Хәлен белеп чыгармын –
Керим хуҗа янына.

## **И К Е Н Ч Е К Ү Р Е Н Е Ш**

Урман. Алан. Л а п т ы й керә.

Л а п т ы й *(җырлый)*. Карурманда аланнар бар,
Аланнарда җил йөри.
Аланнарда җил йөреми,
Лап-лап атлап мин йөрим...

Карурманда аланнар бар,

Аланнарда – җиләкләр...
Җиләк белән тамак туймый,
Ашасам да чиләкләп...

Карурманда, аланнарда
Мин йөрмимен тик кенә...
Мин умарта эзләп йөрим,
Бал ашыйсым бик килә!..

К а р к а р ы й *(кереп)*. Кар-кар-кар! Кар-кар-кар!
Синең өчен, Лаптый дус,
Миндә яхшы хәбәр бар!

Л а п т ы й. Мин бит саңгырау түгел,
Ник каты кычкырасың?
Хәбәреңне әйт тә сал,
Нигә сузып торасың?

К а р к а р ы й. Ук кебек очып кына
Авылдан килеш минем...
Таушым каты булса да,
Сүзләрем көмеш минем!

Л а п т ы й. Әй, миңа димәгәе,
Хет алтын булсын сүзең!
Тизрәк әйт хәбәреңне,
Бәяләрмен мин үзем...

К а р к а р ы й. Син сорама: «Ник алай?»
Син сорама: «Ник болай?»
Авылда булган хәлләр
Синең өчен бик кулай!

Л а п т ы й. Аптыратма, Каркарый!
Тинтерәтмә, Каркарый!
Сүзеңне тиз әйтмәсәң,
Җилтерәтәм, Каркарый!

Дус-иптәш булуыңа
Мин һич тә карап тормыйм...
Ботарлап ташлыйм хәзер –
Беләсең карахтерны!

К а р к а р ы й. Әйтәм, әйтәм, Лаптый дус...
Минем хәбәр шул хакта:
Авылда хуҗа абзый
Бик яман чирләп ята!

Умартасы барлыгын
Син үзең дә беләсең...
Бакча капкасын күрдем –

Бикле түгел keләсе!

Анда хәзер барсы да
Үз эше белән мәшгуль...
Кичне көт тә син, шунда
Туп-туры әйдә пашшул!
Л а п т ы й. Яхшы хәбәрең өчен
Үзеңне бер сыйлармын...
Иртәгә, берсекөнгә
Бу хакта мин уйлармын!
К а р к а р ы й. Ярый, Лаптый, мин киттем,
Оча торыйм әлегә.
Юл уңаеннан, бәлки,
Сугылырмын Шәлегә... *(Китә.)*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. Мырмырдан кала барысы да биредә.

К и к р и к н у р. Хуҗа чирли, җәмәгать,
Бүген без ял итәбез...
К ы т к ы т ы й. Димәк, җырлап алабыз,
Аннан биеп китәбез!
А й б а ш. Мин кешни генә беләм...
Ч ә ч к ә. Мин күши генә беләм...
К и к р и к н у р. Ә сез без җырлаганда
Янда биеп торырсыз...
Кирәк җирдә «михахай»
Һәм «му» диеп торырсыз!..
Б а к ы л д ы к. Кашык белән шакылдап,
Мин торырмын бакылдап!
К и к р и к н у р. Бу кәнсиртне яңадан
Күрсәтербез хуҗага...
Йә, кем башлап җибәрә –
Кем беренче сүз ала?
А к м у е н. Кем әйтмешли, дусларым,
Мин кәнсиртне бик сөям...
К и к р и к н у р. Сузмыйк әле, җәмәгать,
Ясыйк репетиция!
Ч и ч и. Әйе шул, тизрәк башлыйк...
Минем җырлыйсым килә!
Б а к ы л д ы к. Чичиның чинаганын
Минем тыңлыйсым килә!
Ч и ч и. Син «бак-бак» дигән чакта,
Бакылдап тормам инде...

Җырлармын да чинармын –
Шакылдап тормам инде!
К ы т к ы т ы й. Күп сүз – чүп сүз... Ташлагыз!
Йә, кем башлый? Башлагыз!
К и к р и к н у р. Сезнең ничек хәлегез?
Безнең ничек хәлебез? –
Үзебезнең турында
Җырлап бирик әле без!
Кил, Кыткытый, кил әйдә,
Җырлый башла син әйдә!
К ы т к ы т ы й. Безнең авыл – бик зур авыл:
Йортларының чуты юк...
Каравыл өенең генә
Тәрәзендә уты юк.
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
Ч ә ч к ә. Му-у-у!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Бу... бу... нинди авыл бу-у-у?
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
Ч ә ч к ә. Му-у-у!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Бу... бу... нинди авыл бу-у-у?
А й б а ш. Ми-һа-һа-һа-һа-һа-һай!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!
К и к р и к н у р. Гаҗәп хәлләр, сәер хәлләр
Безнең авылда инде:
Яңгыр кебек ява бездә
Йолдызлар көпә-көндез!
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
Ч ә ч к ә. Му-у-у!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Бу... бу... нинди авыл бу-у-у?
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
А й б а ш. Ми-һа-һа-һа-һа-һа-һай!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!
М и к и җ а н. Урамнарга чыгар хәл юк –
Көн дә кызык тамаша:
Арба сөйрисе урынга,
Этеп йөри алаша!
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак-бак!
А й б а ш. Ми-һа-һай!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!
Й о н б и к ә. Балаларны кызыктырып,
Кәҗә йөртә машина.
Ялгыш таптап китүе бар –
Чыга күрмә каршына...
А й б а ш. Ми-һа-һай! Машина!

Б а р ы с ы  б е р г ә. Чыга күрмә каршына!
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
А й б а ш. Ми-һа-һай!
Бер тычкан сөйрәп килә...
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!
Эчләрен тотып көлә...
А к м у е н. Кибеттән йомырка алып
Кайтып килә бер тавык...
Ләмле суга юлыктымы –
Тәпие китте таеп!
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
А й б а ш. Ми-һа-һай!
Кайтып килә бер тавык...
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!
Тәпие китте таеп...
Ч и ч и. Сыер да, тавык шикелле,
Кибеткә барган бугай...
Авызы колакка җиткән –
Сөт-каймак алган бугай...
Б а к ы л д ы к. Бак-бак-бак!
А й б а ш. Ми-һа-һай!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Ми-һа-ха-ха!.. Ха-ха-ха!

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. К а р к а р ы й  белән  Б ү р е т д и н.

К а р к а р ы й. Бу хәбәрне мин бүтән
Сөйләмим берсенә дә...
*(Кереп килүче бүрене күрә.)*
Кемне күрәм... Бүретдин?!
Селяви, мерсимадам!
Б ү р е т д и н. Ят телдә сөйләшмәле,
Ачуымны китереп!
Азык эзләп йөрешем,
Бар дөньяны бетереп...

Тук чакларым бар иде:
Иртән – ботка, кичен – аш!
Ничә көн йөрим инде:
Корсагым буш – карын ач...
К а р к а р ы й. Иртән генә тукландым,
Мин үзем дә ярым ач!
Шулай да сиңа, дускай,
Булышмыйча ярамас...

Т ө л ә н т ә й керә. Яшеренеп тыңлап тора.

Б ү р е т д и н. Синең яхшылыгыңны
Беркайчан да онытмам...
Әкият итеп сөйләрмен
Бишектәге оныкка!
К а р к а р ы й. Сер итеп кенә әйтәм –
Син үзең уйлап эш кыл:
Өендә чирләп ята –
Хуҗаның хәле мөшкел!

Сизеп торам, Бүретдин,
Күп күргәнсең нужаны...
Тизрәк элдерт авылга –
Сарыгы бар хуҗаның!
Б ү р е т д и н. Кайлардан гына килеп
Чыктың минем каршыма?
Болай булгач, туганкай,
Калҗа булды ашыма...

Ярый, Каркарый, киттем –
Бара торыйм шул якка! *(Китә.)*
К а р к а р ы й. Сау булып тор, Бүретдин!
Бамбарбия! Чау! Пока!
Т ө л ә н т ә й *(яшеренгән урыныннан чыгып, Каркарыйны тотып).*
Күп йөрдем сине эзләп,
Ниһаять, таптым менә!
Бик җайлы-майлы гына
Килеп тә каптың менә!
К а р к а р ы й. Җибәр, дим, җибәр мине!
Т ө л ә н т ә й. Юк инде, җибәрмимен!
К а р к а р ы й. Әйт миңа син, алайса:
Нинди зыяным тиде?
Т ө л ә н т ә й. Сине тоту күптәннән
Минем хыялым иде!
К а р к а р ы й. Мин бит сиңа, Төләнтәй,
Бер зыян да салмадым...
Т ө л ә н т ә й. Синең сүзеңне тыңлап,
Чүт инвалид калмадым!

Хәбәреңә ышанып,
Авылга күпме бардым...
Барган саен, үземне
Хуҗалар тотып ярды!

Соңгы баруымнан соң
Йөрим менә титаклап...
Белер идең хәлемне,
Йөргән булсаң син аксап!
К а р к а р ы й. Җибәр инде, Төләнтәй!
Тимә инде, Төләнтәй!
Т ө л ә н т ә й. Ялынма да, нитмә дә,
Кер менә бу капчыкка!
Сатып җибәрәм сине
Бер убырлы карчыкка...

Киттек әйдә, дускаем!
Киттек, асыл кошкаем!

Төләнтәй капчыкны җилкәсенә салып чыгып китә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. Барысы да шау-гөр килә.

К и к р и к н у р. Кемнәр ничек булдырала,
Хәзер биеп алабыз...
Тәпиләрдән, тояклардан
Ут чәчери – карагыз!

Барысы да биергә тотына. М ы р м ы р, өйдән чыгып,
башын чайкап тора.

М ы р м ы р. Туктагыз, дим, биюдән!
Ишетмисез мәллә сез?
Мин түзәм дә түзүен...
Хет хуҗаны жәлләгез!
А к м у е н. Чү, җитте! Туктап торыйк...
Мырмыр дус дөрес әйтә.
Биербез әле тагын,
Хәзер ял итик әйдә!
М ы р м ы р. Бераз сабыр итегез!
Өр-яңа хәбәр әйтәм:
Хуҗаның улы белән
Шәһәрдән Арнольд кайта!
А к м у е н. Арнольд кайта? Кызык бу!
К и к р и к н у р. Бу – искиткеч яңалык!
Й о н б и к ә. Ул борчак шыттырганны
Бер дә тыңлар чама юк!
М и к и җ а н. Бу юлы шәһәр эте
Ни сөйләр икән безгә?
Ч и ч и. Кирәкми шәһәр эте!

Б а к ы л д ы к. Акмуен җиткән безгә!
А л т ә п и. Кайта икән – мәрхәбә!
А й б а ш. Кунакларны күргән бар...
Ч ә ч к ә. Ул кайтканчы ял итик!
Й о н б и к ә. Таралышыйк, туганнар...

Уйнап-көлеп таралышалар.

П ә р д ә.

## И К Е Н Ч Е П Ә Р Д Ә

### Б Е Р Е Н Ч Е К Ү Р Е Н Е Ш

Еракта авыл күренә. Л а п т ы й керә. Музыка.

Л а п т ы й *(җырлый)*. Мин барам, барам, барам,
Мәче кебек ялманып...
Бал исен сизәм! Димәк,
Авылга күп калмады.

Тиздән, тиздән, бик тиздән
Бал ашармын туйганчы!
Ашармын бал туйганчы –
Буш корсагым тулганчы!

Караңгыга калганчы,
Китим әле мин ары...
Бал исен исни-исни,
Тиздән җитәрмен барып!

Китә. Бераздан Б ү р е т д и н күренә. Янә музыка.

Б ү р е т д и н *(җырлый)*. Бар иде тук чакларым –
Ашаганым ит иде...
Бер атлыйм да сөрлегәм –
Ачтан үләм бит инде!
У-у-у...

Күзләрем бар – күрергә,
Танау бар – ис сизәргә...
Ашамыйча, эчмичә
Күпме мөмкин түзәргә?!
У-у-у...

Чү! Авылны күрәмен!
Сарык исен сизәмен...

Болай булгач, авылга
Барып җитәм тиздән мин!
У-у-у... *(Китә.)*

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ишегалды. Урта бер җирдә, йомшак кәнәфидә, тәкәббер кыяфәттә затлы чылбырлар аскан А р н о л ь д утыра. Аны ишегалдындагылар уратып алган.

А р н о л ь д. Ярый әле машинам
Җилдән җитез җилдерде.
Городтан чыгуга ук
Элдерде дә элдерде!
Б а к ы л д ы к *(башкаларга карап)*.
Кайтуына кай ара –
Шыттыра да башлады...
А л т ә п и. Әкият сөйләргә дисәң,
Эшли моның башлары!
А р н о л ь д. Дорога сездә начар –
Шактый гына җик күрдем.
Хуҗагызның малаен
Чак кайтарып җиткердем!
А к м у е н. Әйтерсең машинаны
Үзе йөрткән диярсең!
Ч и ч и. Бездә мактанчыклар юк,
Бу – шәһәр тәрбиясе!
А й б а ш. Урысча сүз кыстыра –
Татарчасы ыслабый...
Ч ә ч к ә. «Ыслабый» дип торасың
Үзең дә син, и абый...
А й б а ш. Хуҗадан ишеткән сүз,
Ялгыш ычкынды телдән...
Бүтән телне бозмамын,
Гафу үтенәм сездән!
А р н о л ь д. Вижу, сез – культур-мультур...
Сөйләшәсез бик матур!
Ч и ч и. Без булсак культур-мультур,
Ә син... син – кылтыр-мылтыр!
Әй син, солы башагы!
Әйдә бокслашабыз!
А р н о л ь д. Бүген формада түгел –
Болганып тора күңел...
Бокслашырбыз потом...
Көрәшә тор с котом!
М ы р м ы р. Чичи, дим, бик очынма!
Чиртермен бит очыңа!

А р н о л ь д. Ну, сездә хәлләр ничек?
Ашау-эчү, башкасы...
Хуҗагыз больной икән...
Йөриме соң «тачка»сы?
А к м у е н. Безнең хәлләр шәпский,
Ашау гел байларский,
Вак-төяк мәсьәләне
Үзебез җайларский!
М ы р м ы р. Үзеңнең хәлләр ничек?
Б а к ы л д ы к. Кайда булдың, ни күрдең?
А р н о л ь д. Каратэ, бокс... Короче,
Секцияләргә йөрдем...
К и к р и к н у р. Нәрсә соң ул «каратэ»?
К ы т к ы т ы й. Нәрсә соң ул «секция»?
Б а к ы л д ы к. Секцияләр турында
Сөйлә безгә лекция.
А р н о л ь д. Бер сөйләрмен, господа,
Бүген кәеф юк әле...
Әллә кофе эчкәнгә,
Давлением югары!

Хәзер мин сезгә лутчы
Баштан кичкәнне сөйлим...
М ы р м ы р. Ни хәлләр икән өйдә?
Шуны тиз генә белим...

Өйгә кереп китә.

А р н о л ь д. Күлмәк эзләп түтәйгә
Бардым былтыр Кытайга...

## Ө Ч Е Н Ч Е   К Ү Р Е Н Е Ш

Шул ук күренеш. А р н о л ь д н ы ң дәртләнеп сөйләгәне, б а ш к а л а р н ы ң аны тыңлаганы күренә. Койма читләтеп, кача-поса, Л а п т ы й керә.

Л а п т ы й *(залга карап)*. Тс-с-с!
Шым гына утырыгыз!
Беләсез карахтерны...
Кемнең кем булуына
Мин бер дә карап тормыйм!

Як-ягына карана. Умартаны күреп ала.

У-у-ух! Бал исе, бал исе!

Борынымны кытыклый...
Мондый чакта мине берни,
Мине беркем куркытмый!

Умартаның янына килеп, аның капкачын ача.

А к м у е н *(иснәнеп)*. Ниндидер ят ис килә!
Бездә кемдер бар бугай?!
М и к и җ а н. Бездән башка кем булсын...
А й б а ш. Юкка шикләнмә, туган!

Лаптыйны кортлар сырып ала, ул чәбәләнергә тотына.
Аны башкалар күреп ала.

Ч и ч и. Каравы-ыл! Карак бар!

Арнольд, җәһәт кенә урыныннан торып, кәнәфи артына поса.
Башкалар, ни туры килсә, шуның белән коралланып,
Лаптыйга таба якынлашалар.

Л а п т ы й. Чагып үтерәләр бит –
Бал кортларын тыегыз!
А к м у е н. Шул кирәк сиңа, аю!
А й б а ш. Тәмле булсын сыебыз!
Л а п т ы й. Үтерәләр! Каравыл!
Ч и ч и. Акырма, бал карагы!

Лаптый, чәбәләнә-чәбәләнә, көч-хәл белән чыгып кача.

К и к р и к н у р *(баскычка басып)*.
Артына да карамый
Сыптырды гына малай!
Ч и ч и. Шул кирәк ул каракка!
А к м у е н. Йөрмәсен бүтән алай!
М и к и җ а н. Арнольд кайда? Күренми!
Ч и ч и. Курыккандыр бу хәлдән!
А р н о л ь д *(поскан урыныннан чыгып)*.
Бик долго сөйләштегез,
Сезнең авылдаш мәллә?

Б ү р е т д и н күренә. Яшеренеп тыңлап тора.

Б ү р е т д и н *(залдагыларга таба борылып)*. Тс-с-с!
Ч и ч и *(Арнольдка)*.
Курыкканга охшыйсың...
Төсләрең качкан димме?

А р н о л ь д. Гомердә булмаганны...
Нишләп куркыйм ди инде!

Просто миндә тортларга,
Төрле-төрле кортларга,
Колорадо жугына
Аллергия – шул гына!
М и к и җ а н. Бу тирәдә күренми,
Кайда безнең Йонбикә?
А л т ә п и. Абзарда ул! Күптәннән
Тәмләп йокы симертә!
А к м у е н. Йокласын алай булгач,
Торыр, йокысы туйгач!
Б а к ы л д ы к. Арнольдны тыңлыйк тагын!
Ч и ч и. Сипсен әйдә борчагын!

Барысы да Арнольд янына җыела.

Б ү р е т д и н *(залга карап, корсагын угалап)*.
Болай булгач, эш пеште!
Калҗа карынга төште!
*(Абзарга кереп китә.)*
А р н о л ь д. Быел бардым Әлмәткә,
Нефть эзләп, әлбәттә!..
А к м у е н *(иснәнеп)*.
Тынгы бирми һич кенә...
Тагын бер ят ис килә!

Арнольд качарга әзерләнә. Барысы да тирә-якка карана. Җилкәсенә Й о н б и к ә н е салган Б ү р е т д и н н е күреп алалар.

К и к р и к н у р. Кикрикүк! Кикрикүк!
Шул явызны тотыгыз!
Ч и ч и. Без күп монда! Ул – берәү!
Алынмасын котыгыз!

Бүретдин, Йонбикәне җиргә куеп, кая качарга белмичә,
әрле-бирле чабып йөри.

К ы т к ы т ы й. Кыт-кытыйк! Арт сабагын укытыйк!
Б а к ы л д ы к. Бак-бак! Килмәслек булсын кабат!
М и к и җ а н. Ми-ки-ки! Тотсак, бүре минеке!
А л т ә п и. Кыйгак-кыйгак, как-как-как!.. Тоталмыйбыз бит никак!
Ч ә ч к ә. Му-му-му! Бигрәк явыз нәрсә бу!
А й б а ш. Ми-һа-һай! Каян килгән бу нахал?

А к м у е н. Һау-һау-һау! Бәйләп ташлыйм, китер бау!

А р н о л ь д. Һау-һау-һау!.. Гав-гав-гав! Хвост отрежьте пылауга!

Ч и ч и *(Арнольдка)*.
Син нигә куышмыйсың?
Син нигә тик торасың?
Читтән өреп торырга
Син, парень, булдырасың!

Котың ботыңа төшкән...
Торма калтырап болай!
Син бит бая үзеңне
Каратист дидең бугай?!

А р н о л ь д. Һава килешмиме соң?
Кәефем юк нишләптер...
Билне кузгаттым бугай,
Көне-төне эшләп гел...

Бер җай табып, Бүретдин чыгып кача. Өйдән М ы р м ы р чыга.

М ы р м ы р. Бар нәрсә авып беткән...
Нинди гарасат үтте?

А к м у е н. Хикмәтләр булды монда...

Ч и ч и. Әле ярый тиз бетте!

К и к р и к н у р. Беткән эш ул – үткән эш,
Бер сөйләрбез ничек тә...

А й б а ш. Хуҗабыз нишли анда?

Ч ә ч к ә. Үзен ничек хис итә?

М ы р м ы р. Сезнең барыгызны да
Сөендерә аламын:
Хуҗа торып утырды,
Әйтте сезгә сәламен!

Б а р ы с ы б е р г ә. Ур-р-ра!

М ы р м ы р. Тиздән үзе чыгачак...
Сабыр гына көтегез!
Ул чыкканчы бар җирне
Элеккечә итегез!

Барысы бергәләп тиз генә ишегалдын әүвәлге халәтенә кайтаралар.

Ч и ч и *(алга чыгып)*.
Бигрәк уңган инде без!
Ялт иттердек тәки, ә?!

Б а р ы с ы б е р г ә. Шулай итеп, балалар,
Бетте безнең әкият!

К и к р и к н у р. Сезгә уйнап күрсәттек,
Сабак алсыннар диеп...
Дәү үскәч тә, акыллы
Булып калсыннар диеп!
Б а р ы с ы  б е р г ә. Сау булыгыз, балалар!

П ә р д ә.

## ЛӘБИБ ЛЕРОН ИҖАТЫ ХАКЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИПЛӘРНЕҢ ФИКЕРЛӘРЕ

Соңгы елларда төрле жанрларда шактый яңа исемнәр танылуы аеруча сөендерә. Ләбиб Лерон да профессиональ дәрәҗәсе өлгереп җиткән сәләтле язучы, шигырьдә, прозада бердәй иркен йөзә. Әсәрләренә терелек, табигыйлек, камиллек биреп торган хасият – юмор, сатира. Әсәрнең җаны – бала күңеленә ачкыч ул. Монда табыш – кыскалык гарантиясе, калганы укучы күңелендә дәвам итә, аның тормышка мөнәсәбәтен билгеләшә.

Ләбиб иҗатындагы төрлелек сәләтенең колачын күрсәтеп тора. Актив эшли ул, шигырьләр, хикәяләр белән бергә, замана әкиятләре тудырды, пародияләре белән дә танылып өлгерде. Курчак театрына да, миниатюралар театрына да җитешә, язучы үз стихиясендә әнә шулай иркен ачылырга тиеш.

*Шәүкәт Галиев,*
Татарстан Республикасының халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб һәр жанрда да үзен иркен хис итә. Шунысы- әһәмиятле: шагыйрь балалар белән нәкъ аларча сөйләшә, дустанә аралаша. Шигырьләрендә, кечкенә шаян хикәяләрендә бернинди акыл сату юк, акыллы булып кылану юк. Ләбибнең әсәрләрендә бала үз дөньясын күрә, шатлана яисә үзенчә борчыла...

*Зөлфәт,*
шагыйрь, Татарстан Республикасының
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб татар балалар әдәбиятына да, балалар күңеленә дә өстәмә байлык булып урнашырлык шигырьләр таба ала. Табышын балаларча җитез хәрәкәтләр, тиз үзгәрешләр аша уздырып, укучы күңелен үзенә ияртә. Аның вакыйгаларына биреләсең дә, шомалык һәм ритм турында онытасың, бары укыйсы гына килә. Хикмәт – үзгәрештә, вакыйгаларда һәм хәрәкәттә генә дә түгел, Ләбиб сәнгатьчә тәэсир итүнең күптөрле

алымнарын сиземләп яза, шуның белән безне үзенең тагын да зуррак мөмкинлекләре барына ышандыра. Ләбиб Лерон балаларны уйлата, нечкә күңелле, кешелекле, шәфкатьле итә торган шигырьләр язарга омтыла.

*Рөстәм Мингалим,*
Татарстан Республикасының халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб Леронның иксез-чиксез шигъри иҗат мәйданында үз тоткан юлы, үзе генә аралаган сукмагы, үз өлкәсе бар. Ул – юмор-сатира. Яшь язучының бу өлкәдәге эзләнүләре һәм шиксез уңышлары аны профессиональ сыйфаттагы әдәбиятка сукмак салучы яшь әдип дип атарга мөмкинлек бирә.

Ләбибнең көлүе әче, мыскыллы, шәхесне юкка чыгаручан түгел, ә сыгылмалы, ипле, әмма һич кенә дә килешүчән булмаган көлү. Икенче төрле әйткәндә, аның юморы, тупас хахылдау булмыйча, зыялыларча тирән мәгънә салынган эчке елмаю булып тора.

Ләбиб Лерон лирикада да ипле. Ул шигырьдә әтәчләнми, чәчрәп кычкырмый, бер стакан суда тайфун уйнатмый.

Л. Леронның юморны аерыбрак яратуы аның юмористик әсәрләрне проза белән сынап каравыннан да күренә. Аның оста сюжетлы, нечкә кинаяле, культуралы телле кечкенә проза әсәрләре игътибарны үзенә җәлеп итә.

*Гәрәй Рәхим,*
Татарстан Республикасының халык язучысы,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Соңгы елларда юмор бетте дияргә була. Чөнки язучылар бер-берсе белән очрашмыйлар. Дус түгелләр. Юморны аңламыйлар. Үпкәләшәләр. Ләбиб исә, шуңа бирешмичә, юмор, пародия язуны дәвам итә.

*Илдар Юзеев,*
Татарстан Республикасының халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Юмор белән Сатира дигән ашкын атларны укучысын хихахайлату өчен генә әдәбият арбасына җикми Ләбиб. Ул атларга төялгән йөктә көлкеле хәлләр белән аралаштырып тутырылган зирәк фикер, тирән мәгънә булыр, тәрбия бирердәй гыйбрәт тә сизелер...

Ләбиб Лерон – укучысын һәр җөмләсе белән елмайтырлык әдип. Әкәмәтләр, кәмитләр белән тулып ашкан бу илнең күп хикмәтләрен анализлап яши-яши, бихисап кызыклар чыганагына әйләнеп беткән ул.

*Фәнзаман Баттал,*
язучы-сатирик

* * *

Ләбибнең сатирик хикәяләрен укыганда, мин урыс язучысы А. Аверченконы искә төшерәм. Бәлки, Ләбибнең аны укыганы да юктыр. Әмма ачы тел, кыскалык осталыгы, фикерләү үзенчәлеге бертөслерәк сыман. Мөгаен, бу сыйфатлар Чеховтан ук киләдер.

Хәлбуки Ләбиб Леронның тамырлары урыс әдәбиятына түгел, үзебезнекенә – татарныкына тоташкан. Ләбиб дигән-дә, артында Газиз Мөхәммәтшиннар, Фаил Шәфигуллиннар шәүләсе пәйда була сыман.

*Ркаил Зәйдулла,*
шагыйрь, Татарстан Республикасының
Г. Тукай исемендәгеДәүләт премиясе лауреаты

* * *

Безнең татар әдәбиятында аерым каләм әһеленең төрле жанрларда эшләве инде үзенә күрә бер традициягә әверелгән. Илһам чишмәсенең шулай тармакланып китүе, бәлки, халыкның эчке ихтыяҗыннан ук киләдер. Әмма мондый күпкырлы иҗатчы алдына чагыштырмача зуррак таләпләр куела. Әгәр аның әсәрләре бердәй осталык белән язылмаса, ул беркайчан да чын әдип дәрәҗәсенә күтәрелә алмаячак. Бу җәһәттән Ләбиб Лерон шигърият, проза, драматургия, публицистика кебек әдәби жанрлар буенча уңышлы эшләп килә, һәм, иң әһәмиятлесе, аның һәрбер язганында күкләр тарафыннан бирелгән табигый талант чаткысы сирпелеп тора. Ул балалар әдәбиятын да үги итми. Күп кенә әсәрләрендә юмор-сатира башлангычына өстенлек бирелү дә аның иҗатындагы күпкырлылыкның олуг максатларга хезмәт итүен күрсәтә. Киләчәктә дә Ләбиб Леронның шундый булып калуын телим.

*Зиннур Мансуров,*
шагыйрь, Татарстан Республикасының
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Исемнәре күп булган кебек, аның әдәбиятта да үз итмәгән жанры юк бугай. Ул – шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, балалар язучысы да, юморист та, пародияче дә... Һәм иң мөһиме – Ләбиб һәр жанрда да шәп итеп, мавыктыргыч итеп яза белә.

*Газинур Морат,*
шагыйрь, М.Җәлил исемендәге
Республика премиясе лауреаты

* * *

Һәр язучының күңелендә дүрт жанр коткысы ята: гашыйк булса, ул шигырь яза башлый; туган якларын сагынганда – прозага күчә; һәйбәт спектакль карап кайтса – пьеса язарга утыра; зиһен-тәҗрибә туплагач, публицист гаме керә. Ләбиб исә, елның дүрт фасылында берьюлы яшәгән кебек, шушы дүрт жанр халәтендә иҗат итә. Әмма кайсы фасылда, кайсы жанрда эшләсә дә, ул үзенең төп кыйбласына тугры – Ләбиб Лерон коеп куйган сатирик!..

*Камил Кәримов,*
язучы

## ЭЧТӘЛЕК

Әхлак матурлыгы сагында. *Ә. Закирҗанов* ......................

**Пьесалар**

Бәхеткә биш минут кала ..............................................
Кычыткан чыпчыгы ...................................................
Экстрасенс ................................................................
Казыйханда кунакта ...................................................
Иман .........................................................................
Коры куык .................................................................
Алтын күкәй яки Киндерсюрприз ..................................

**Балалар өчен әкият-пьесалар**

Чәпәләй һәм Тәпәләй мажаралары ..................................
Чәпәләй белән Тәпәләйнең Яңа ел мажаралары .................
Аңгыра Сарык җүләре ..................................................
Урмандагы тамаша .....................................................
Без барабыз бәйрәмгә ..................................................
Яңа ел биштәре ...........................................................
Ишегалды ..................................................................

Ләбиб Лерон иҗаты хакында күренекле әдипләрнең фикерләре ......................................................................

Литературно-художественное издание

**Лерон** Лябиб
(**Леронов** Лемон Леронович)

ПЯТЬ МИНУТ ДО СЧАСТЬЯ

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Лерон** Ләбиб
(**Леронов** Лемон Лерон улы)

БӘХЕТКӘ БИШ МИНУТ КАЛА

Мөхәррире *И. Г. Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А. С. Газизҗанова*
Корректорлары *Л. Р. Галимова, Г. М. Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.05.2012.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 22,68.
Тиражы 2000. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru  e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият
комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.